

**Мәгъсум Хуҗин**

# Айның уты сүнгән...

Хикәяләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Х 80

**Хуҗин Мәгъсум**

Х 80 Айның уты сүнгән: Хикәяләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.— 383 б., рәсем белән.

Җыентыкка тупланган әсәрләрдә җәмгыять тормышындагы һәм безнең көннәр кешесенең рухи дөньясындагы үзгәрешләр тасвирлана.

ISBN 5-298-01379-1 © Татарстан китап нәшрияты, 2004





# Иртәнге яңгыр

Язгы яңгыр урыны-урыны белән ява, әле бер төштәгесе дә бүленә-бүленә яварга ярата. Сирәк сибәләп кенә тотына да, туктап тын алгач, чиләкләп ора башлый. Чүчә авылын чыккан-да гына коры иде, ә үр күтәрелгән саен асфальт юл юешләнә-карала барды. Пәнәүгә җиткәндә, машина капоты өстенә бер-ничә эре тамчы бәрелеп чәчелде һәм томалап ук яварга ке-реште.

Әхмәт яңгыр узганын көтәргә дип тормозга да баскан иде, әмма тоташ су аккан тәрәзәдән алдарак яңгырга чыланган ха-тын-кыз шәүләсен күргәч, машинасын аның янына җитеп тук-татты. Юкарак гәүдәле бу кыз басмага җәһәт кенә менеп бас-ты һәм ян тәрәзәнең ачылып бетүен дә көтмичә:

— Абый, син Казанга барасыңмы? — дип сорады.

— Сиңа барыбер түгелме?! Утыр әйдә! Моннан гына кер, яңгыр туктамыйча кузгалып булмый инде,— диде Әхмәт һәм үз ягыннан ишекне ачты.

— Юк, юк, үз урыныңа күч, абый,— диде кыз, кабинага кер-гәч һәм, руль белән утыргыч арасыннан шома гына узып, «ЗИЛ»-ның киң кабинасы уртасына иелеп басты.— Юешләп бетерәм мин синең урыныңны. Киемнәрең дә әйбәт, шоферга бөтенләй охшамагансың.— Кыз Әхмәткә төсмерләгәндәй текәлеп кара-ды, танышын очраткандай, кабина эчен балкытып елмайды.

— Абау, абый җаным, мыегың! Бигрәк килешеп тора үзеңә!

Әхмәт, нигәдер оялып, йөзен читкә борды, ә үзе:

— Тәкелдәмә,— дигән булып ачуланды.

— Мактаганны яратмас кеше дә булыр икән! Мине матур дип мактасыннар иде әле шулай.

— Син мактамыйча да матур.

Әхмәт, алгы тәрәзә пыялаларын сөртер өчен, утыргычлар бүлеме арасыннан чүпрәк алды.

— Бик инде! Матур булсам, сөйгән егетем, мине ташлап, башкага өйләнер идемени?!

— Кем, кем? Кем кемгә өйләнгән?

— Кем булсын! Сөйгән егетем Пашка... Аннага өйләнде,— диде кыз, эч серләрен күптәнге танышына сөйләгәндәй гади тота иде ул үзен.

— Керәшен кызы икәнсең ич, үзебезнең керәшен.

— Әйе шул, Настә, татарча — Нәсимә. Ә син ни атлы, абый?

— Әхмәт. Шулай да, Настя, Пашкаңны сагынып кызганма. Өйләнгән, димәк, мәхәббәтегез шуның кадәр генә булган. Сиңа кияүнең бер дигәне табылыр.— Аннары Әхмәт шаяртып өстәде: — Менә мин дә бар, ахыр чиктә миңа әйтерсең.

— Син әллә кайчан өйләнгәнсеңдер, балаларың үсеп җиткәндер инде.

— Синең хәтлеләр...

— И тозсыз!

— Син тозлы инде бик! Әнә эреп бетәсең, күлмәгеңне сыгып ки, ичмасам.

— Ә минем бүтән күлмәгем дә бар,— дип, чемоданын ачты Настя.— Алыштырыйм әле. Түлке син болайга карама, абый җаным, яме.

— Карыйсы юк инде. Күлмәгең тәнеңә ябышкан. Бөтен байлыгың күз алдында.

— Ябыграк шул мин. Пашка да шуңа яратмады бугай.

— Җәһәтрәк бул, яңгыр тынды, синең көеңне көйләргә дип чыкмадым юлга, бүген үк әйләнеп тә кайтасым бар.

— Төшеп тә калырмын тагын!

— Төшмә инде, Настәү!

— Кайгырма, төшмим. Тегеләйгә карап утыр. Яшь кыз күргәч, күзләре шарайды абыем җанымның...

Әхмәт тыела алмыйча көлеп җибәрде һәм:

— Ни ялварсаң да төшермим хәзер! — диде.— Күңелле булачак икән синең белән баруы.

— Булды әйдә, чаптыр гына машинаңны.

— Бөтенләй үзгәреп киттең син, Настя. Пашкаң юкка ташлаган сине. Чыннан да чибәр икәнсең.

— Бу күлмәгемне туйда киясе идем. Абый җаным, без Казанга кибет ачылуга барып та җитәрбез, име. Туйга яңаны сатып алам. Акчам бар минем, сыер савучы булып эшлим колхозда, акча мул төшә.

— Әллә Пашка туенамы? — дип сизенеп сорады Әхмәт.
— Әйе.
— Чынлап та, кем туена?
— Пашка туена, дим бит инде! Чакырганнар. Аның Аннасы безгә туган тия.
— Гаҗәп икән сездә хәлләр...
— Шулаен шулай да, бармыйча ярамый, туганлык хисе дигән нәрсә бар, Әхмәт абый җаным.
— Анна туган дип тормаган. Пашкаңны тартып алган әле.
— Анна бүтән, мин башка.
— Әйдә, узган эшкә — салават, җырлап җибәр бер, хәсрәтеңне юарсың.
— И-и, Әхмәт абый, җырларга безнең керәшеннәргә куш кына инде!..
Күңелен тирән актарып моңланды да, мәхәббәтен оныткандай шаярды да Настя — машинага җыр юлдаш булды.
Кыз яңа көй башларга тын алган арада:
— Хәзер светофорлар башлана, калганын иртәгә кайтканда җырларсың инде,— диде Әхмәт.
— Акрын гына да ярамыймы?
— Тыныч кына барыйк, Настя,— дип үгетләгәндәй әйтте Әхмәт, кызның теләгенә каршы төшү аның үзенә дә нигәдер авыр иде.
— Син иртәгә дә киләсеңме соң?
— Киләм, сине алырга киләм.
— И-и, Әхмәт абый, шаяртмачы, иртәгә шимбә лә, шәһәрдә эшләмиләр.
— «Сельхозтехника» складлары эшли.
— Алайса, Әхмәт абый, мин сине шушында көтәрмен, шимбә көн автобуста кеше күп була. Аннары синең машинаңа утырып йөрергә дә рәхәт икән.
...Икенче көнне Настя Мамадыш тракты башына төш турында ук чыкты. Шулай да Әхмәт алданрак өлгергән икән — ул Настяны рульгә куйган китабын укып көтә иде.
— Абау, Әхмәт абый, бигрәк тиз булган син бүген.
— Сине күрергә ашыктым.
— Үзем дә шулай, тәүлек буе гел сине генә уйладым. Бүгенге мәҗлескә дә калырга бик кыстаганнар иде, мине Әхмәт абый көтә, дип кенә котылдым.
— Салпы якка салам кыстырырга миннән күп оста икәнсең, Настя.
— Ачуланма инде, абый, шаярмагач та көлмәгәч, бу яшьлек нигә кирәк?! Их, егетем туеннан кайтам бит... Яраталар икән бер-берсен, бәхетле яшәрләр, шәт. Икесе дә әйбәт аларның. Пашкасы да, Аннасы да. Мин дә начар түгел түгелен, Анна кебек барыбер яулык бөркәнгән, тик кешене көчләп яратты-

рып булмый шул. Пашка мине дус итеп кенә йөргән икән...— Һәм Настя тагын бер тирән итеп сулады да мәхәббәтенең тарихын уенлы-чынлы сөйләп ташлады: — Мәктәпне Анна белән бергә укып бетердем мин. Анна Казанга китте дә, ике ел тегү фабрикасында эшләгәч, институтка керде. Ә Пашка без сигездә чагында унда укый иде инде. Мин аларның бер-берсен яратуларын бөтенләй сизмәдем ул вакытта. Пашка, армиядән кайткач, мине озатып йөрде. Мөнәсәбәте әйбәт булгач, Пашка мине яратадыр, дип уйлаган идем, ә аның башына мондый уй кереп тә карамаган, күңелендә Анна булган икән. Анна шәһәрдә булганга күрә генә озатып йөргән икән ул мине, Аннаның туганы булганга хөрмәт иткәндер инде мине. Шуңадыр, күрәсең, ул миңа беркайчан да, яратам, димәде. Их, Пашка, Пашка... Минем белән төннәр буе йөрергә риза иде ул, ә үзе бер генә тапкыр да култыклап та алмады... Бу вакытта инде минем тиңнәрдән егетләр белән үбешмәгән япа-ялгызым гына калганмындыр... Аннары алар гаиләләре белән шәһәргә күчтеләр. Баштарак атна саен кайта иде Пашка, гел очраша идек, авылда без парлап узмаган урам-тыкрык та юктыр инде... Мин үзем генә тилереп яратып йөргәнмен икән аны!.. Туйлары әйбәт булды, шунысына сөендем. Тик бер генә кунакларын ошатмадым, кыз башы белән тап-тар чалбар кигән, озындыр бармаклары, тырнаклары кәкрәеп килгән, куе кызылга буяган тагын аларны. Балконга чыгып карыш буе сигарет кабызып җибәрде, аны сул кулы белән тоткан, бер кулының гына көче җитмәгәндер инде, сул кулын терсәгеннән уң кулы белән терәп тора. Ярый шундый кызга, ак икмәкне кара икмәктән аерып та, бодайны арыштан аермаган кешегә тап булмады Пашка, үзебезнең Аннага өйләнде...

Күпмедер араны сүзсез уздылар. Үшнә күперен чыккач, Әхмәт машинасын туктатты, стакан алып, чишмәгә су эчәргә төште. Настя да аңа иярде.

— Шушы чишмәнең суын яратам,— диде Әхмәт һәм стаканны Настяга сузды.— Эчәсеңме?

Кыз аз гына татып карады да калган суны ерганакка түгеп җибәрде. Әхмәт, эчеп туйгач, бөкрәеп, салкын суны муенына койды, аннары Настя су ташып торды, егет бите-беләкләре кызарып чыкканчы юынды.

— Ирләр юынганда су салып тору үзе бер рәхәт, ди безнең әни. Белеп әйтә икән шул.

Настя сүзләренә Әхмәт:

— Әйдә, Нәсимә, алайса, мин кабат юынам! Миңа да рәхәт! — дип, тагын да иеләрәк төште.

Машина кузгалуга, Настя:

— Әхмәт абый, хәзер светофорлар юк, җырлыйм инде,— диде.

— Җырла, Настя, җырла...

Әхмәт машинасын Кәвәл юлына борды. Настя кинәт каушап-сискәнеп аңа карады.

— Абый җаным, дөрес бармыйсың бит!

— Нигә? Сезнең авыл юлы шушы ла. Сине илтеп куям.

— Ашыгасыңдыр ич, минем хәтле балаң көтә үзеңне...

«Син булырсың, ахры, ул бала, Нәсимә. Баласы да, анасы да»,— дип әйтергә теләде Әхмәт каш астыннан гына көлемсерәп утырган мөлаем кызга. Әмма эчке бер сизенү белән сөйләшмичә баруның әйбәтрәк икәнен аңлады. Һәм алар икесе дә сүз берләшкәндәй тынып калдылар.

Авылга җиткәндә, Настя кулын рульгә куйды һәм Әхмәт машинасын туктатты. Кыз, Әхмәтнең күзләренә туры карамаска тырышып, «җаным»ны кыстырмыйча гына:

— Исән бул, Әхмәт абый. Рәхмәт,— диде.

— Настя, без тагын очрашырбыз микән?! — дип каушабрак кычкырды Әхмәт, кинәт кенә исенә килеп, инде урамга керергә өлгергән кызның ишетмичә калуыннан курыккандай.

Настя, ишетеп, әйләнеп карады, кулын болгады. Боларын аермачык күрде Әхмәт, җилдә чәч бөртекләре җилфердәп кызның йөзенә моңсулык җәелүен дә күрде, тик Настяның иреннәре кыймылдавын гына ерактан күреп җиткермәде. Нәрсә дип җавап кайтарды икән шаян күңелле бу моңсу кыз?

*1977*

# Ак колын

Тимеркүк бия, озын ялын чирәмдә сөйрәп, тау итәгендә утлап йөри. Аны җикмиләр — колыны яшь әле, бер генә атналык. Ак колын ераккарак китә башласа, бия сискәнеп башын өскә чөя һәм, колынның арлы-бирле чабуы шаяру гына икәнен күргәч, тагын чирәмгә иелә. Шулай да ашауга онытылып китми, игътибары бәләкәчендә, аны күзеннән җуймый.

Ә колынга нәрсә — дөньяда аңа ике генә нәрсә хаҗәт: уйный да әнисен имә. Ул әнә әле бер якка, әле икенче якка очынып атыла. Бавы болын читенә җитәрлек итеп кенә арканланган коба бозау янына килә дә, син нигә миңа охшамаган, дигән сыман сәерсенеп карап тора. Бозау башын сузып аңа таба борылгач, бу гаҗәеп хайваннан куркып, болынга кире чаба.

Коба бозау колынга иярә, тик аны куып җитә алмый, каерылып туктап кала. Ул ычкынмакчы булып тартыла, әмма аркан өзелми, өчтән үрелгән юкә муенчак та салынмый, күп тырыша торгач, казык суырылып чыга. Һәм бозау, казыкның якынаеп-ерагаеп сикеренүеннән өркеп, авылга элдертә.

Ак колынга шул гына кирәк — дөнья тагын да иркенәебрәк китте бит! Ул салмак атлап болыннан чыга (үлән башлары аякларга бәрелә һәм колын бөтен тәне белән калтырап куя,— әйе, куркытышуда бозауны җиңүче булсаң да, үлән кытыклаудан дерелдәүне яшерә алмыйсың). Әнисенең башына ышкына да күтәрелеп аптырап кала: нигә кимерә инде үләнне әнисе? Әллә тәмлеме икән — без дә тәмен белеп карыйк бер... Юк, кая инде әни сөтенә җитсен! Колын әнисен тәмләп имә, аннары яңа уен башлый. Болын читендәге тауга бар көченә чабып менә дә үркәчтәге каенлыкка җиткәч туктый, нечкә тавышы белән кешнәп җибәрә. Әнисе, күзләрен зур ачып, колынын карый, колакларын торгызып, газизенең тауга менү сөенеченнән кешнәвен тыңлый, колынын үзенә чакыра. Ак колын, йомшак тоягы чирәмдә таюдан куркыпмы, таудан акрын гына төшә, әнисенә сырпаланып алгач, тагын сөзәк тау түбәсенә чаба, тагын тавышын челтерәтеп кешни...

Биюш бияне алып кайтырга дип килгән иде, әмма йөгән кигезгәндә атның чирәмне, ашап калыйм дигәндәй, ашыгыбрак кимерергә тотынуын һәм ак колынның дөнья белән танышып йөрүен күргәч, ашыктырмаска булды, түмгәккә таянып, колынның тамашаларын онытылып күзәтә башлады.

Әй, уйнасын соң ак колын!.. Чабып менсен тауга!.. Колакка нинди ятышлы-ягымлы аның нәни тояклары белән тыпырдавы! Тыңлагыз әле шул тыпырдау җырын... Тып-тып...

«Сәер кеше инде мин,— дип уйлый Биюш.— Һаман акыл кермәгән — колынның тояк тавышы ничек моң булып таралсын инде? Әллә моны йөрәк тоямы? Кем белгән... Әллә тау сөзәгендә җирнең моң телләре бармы соң?! Туктале, ак колын, әнә шул телләргә басып, көй чыгара икән бит!..»

Көй дигәннән, Биюшнең табигатьтән яңа җыр ишеткәне күп булды инде.

Укырга керәсе елы иде аның. Аерым хуҗалыклар заманындагы соңгы урак өсте иде. Биюшнең әтисе белән әнисе, ат җигеп, таңнан ук уракка киттеләр. Йортта хуҗа булып Биюш калды, тавыкларга җим сипте, каз-үрдәкләрне су буена төшерде. Әнисе, көн буе утырып су типмәсен дип, самоварны кагып, Биюшкә чәйне биш чокырга ясап калдырды. Шакмаклы ашъяулык астындагы икмәк телемнәре, ярмалы бәрәңге Биюшкә, уеннан арып кергәч, дөньядагы иң тәмле сый инде. Бөтенесен әзерләп китәләр аңа, тик атланмайны, эреп йомшамасын өчен, ашаган саен базга төшереп куярга кирәк. Менә шунда төшүе мең газап инде, әй,— кары төбендә генә калган баз эче куркыта аны. Гөберле бакалар анда тулып ятадыр, хәзер алар җәенке авызлары белән синең ялантәпиеңнән каптырып кына алырлар да ояларына сөйрәп алып кереп китәрләр кебек. Һәм Би-

юш баздан ничек атылып чыкканын сизмичә дә кала. Аннары — шап! баз капкачын. Караңгыда ояларын табалмыйча интексеннәр әле гөберле бакалар!..

Биюш өстәл янында баскан килеш соңгы чокыр чәен эчеп бетергәндә, сибәләп кенә яңгыр ява башлады. Тын яңгыр, олылар әйтмешли, игелекле яңгыр иде бу. Әмма кинәт искән җил өй түрендәге балан куаклары өстеннән авыр канаты белән сыпырып узды. Малай, чокырын өстәл кырыена гына куеп, тәрәзәне ябарга үрелде. Шулчак өстәл өстенә җәйгән ашъяулыкны кулы белән ялгыш тартып җибәрде дә чокыр идәнгә төшеп чәлпәрәмә килде. Биюш тәтәй ватыкларын җыйды, әти-әнисенең ачулануыннан шүрләмәде, аның инде моңарчы да әйбер ватып караганы бар, әнисе ачулана башласа, әтисе каршы төшә, бер әйбер дә ватмагач, малай буламы инде ул, ди. Әйбәт итте әле, уйнарга тәтәйләре бетеп бара иде, хәзер зәңгәр бизәклеләре менә ничәү булды, акларын әйтеп тә торасы юк. Оттырмый уйнасаң, шушы бер чокыр ватыклары белән малайларның барлык тәтәйләрен «эһ» дигәнче отып бетереп була. Шулай итәчәк тә Биюш.

Тәтәйләрне җыеп маташканда, чокыр төшеп ватылгандагы чылтыраган тавыш аның колагына кабат ишетелде. Кыска гына бер көй иде чокыр зыңлавы. Биюш һаман ишетә шуны, әмма авызы белән көйләп бирә алмый. Әллә тагын бер чокырны идәнгә төшереп җибәрергәме? Көйне отып булыр иде аннары...

Чокыр идәнгә сабы белән бәрелеп уалды һәм монысының тавышы беренчесенә бөтенләй охшамаган иде. Соң бит аны өстәл кырыена куярга да ашъяулыкны шудырып төшереп җибәрергә кирәк! Менә шулай! Әй, тагын булмады... Ә дүртенчесе беренчесе кебек ватыла менә, белеп торыгыз. Аннары бишенчесе дә... Әллә чәй тәлинкәсен төшереп карапгамы? Берне генә... Монысы бөтенләй коры тавыш белән ватыла икән лә, чылтырау исендә дә юк. Бәлки, кырыны белән төшереп карапгадыр.

Өстәлдәге һәм шкафтагы чокырлар белән тәлинкәләр ватылып бетсә дә, Биюш абайламый ваткандагы зыңлаган көйне кабат ишетә алмады.

Ул өйалдына чыкты. Болдыр ишеген ялантәпие белән этәреп җибәрде — аскы яктан калку сайгакка төртелгәч, ишек дерелдәп торды һәм кыйгачлап ачык калды.

Хәзер җил бөтенләй тынган, яңгыр озакка килгән — утырып ява иде. Әйтерсең ишегалды чирәмнәренә ислемай сибелә иде. Август аена кереп, искерә башлаган җәйне яңартып ала торган яңгыр бу.

Кинәт Биюшнең колагында әлеге көй зыңлап куйды. Тукта, монысы бүтәне бит, чынаяк көеннән җәһәтлеге белән, моңы белән үзгә. Тыңлагыз: алмаш-тилмәш шыпылдыйлар-тыпылдый-

лар яңа көй тавышлары. Әй, тамчылар икән бит, өй түбәсендә тыпырдап бииләр икән! Һәркайсының үз көч-куәте бар, берсе әнә Биюшнең йон тубыдай атылып сикерә, икенчесе такта буйлап шуып кына китә, өченчесе тирә-юньгә чәчрәп бетә. Әмма барысының да шыпылдау тавышлары бергә кушыла да колакка иркәләү авазы ишетелә. Тамчылар түбә тактасындагы су юлына җыелалар да, сыргаланып ага-ага, баскыч төбендәге таш өстенә салган шома тактага егылалар. Монда инде аларның тавышы моңсуланып тоныгая: ахрысы, тамчылар җиргә-туфракка сеңә алмауларына кайгырышалар бугай. Шушы яңгыр көен иң баштан тагын бер тыңлыйк әле, онытылмаслык итеп. Тамчылар һаман ишәяләр-ешаялар, һаман көчәяләр... Җирдәге тактага бәрелеп егылгач кына моңаеп туктыйлар...

Биюш, әтисенең унике телле гармунын алып, сәке йөзлегенә утырды, чокыр ватылгандагы һәм яңгыр яугандагы көйне чыгармакчы булып азапланды. Телләргә нинди генә тәртиптә басып караса да, көйләр табылмады, бармаклар һаман моңарчы да белер-белмәс уйнаган «Авыл көе»н, «Алсу»ны чыгаралар иде. Ә колакта яңа көйләр яңгырап тора. Их, гармунда шуларны уйнап җибәреп йә җырлап күрсәтеп таң калдырсаң икән иптәш малайларны! Бу инде тәтәйле уйнаганда һәм кем күбрәк коену ярышында отудан мең дә мең тапкыр артыграк мактаныч булыр иде. Әмма шул яңа көйләрне уйнап булмый бит әле...

Әти-әнисе чыланып кайтып кергәндә, Биюш һаман гармун кычкыртып утыра иде. Әтисе ватылган чынаяклар өчен Биюшнең йомшак җиренә дәү учы белән бик шәпләп берне тамызгач та, яңа көйләр чыкмады. Хәер, шап иткән тавыш үзе хәйран озак ишетелеп торды, тик монысы әчеттергеч көй иде инде.

Чынаяклар кырылу вакыйгасын әтисе әнә шундый истәлек итте. Биюш өчен исә моның хәтергә сеңеп калу сәбәбе бүтәндә иде.

Әтисенең үз гомерендә шушы бердәнбер сугуына ачу итепме, әллә инде чокыр ватылуның үзенчә бәһасен кайтарырга теләпме, Биюш оста гармунчы булырга үз-үзенә сүз бирде һәм, ТБУМны укып чыкканда, ул авылның оста гармунчысы иде инде. Авыл башындагы болынга кичке уенга төшкәндә, Биюш тә гармунын җилкәсенә аса иде. Тик зурлар уенына керергә аңа әле иртәрәк, шуңа үз тиңнәре белән читтән карап тора. Кайбер көннәрдә, гармунчы егет Салих арыгач, аны түгәрәк уртасына чакырып уйнаталар, шулай да күп кичне ул түгәрәк читендә үткәрә. Уен таралгач кына, яшьтәшләрен ияртеп, болын буйлап — бакчалар артлатып, үз тыкрыкларына хәтле уйнап кайта. Тора-бара яшьләр аның уйнавын күбрәк ярата башладылар. Хәер, Биюш үзе дә инде хәзер егет исәбенә кереп бара иде. Шулай да борын чөяргә иртәрәк булган икән әле. Гармунчы Салих моны аңа бик шәпләп төшендереп тә күрсәтте.

Ул кичне түгәрәк уртасында гел Биюш булды. Яшьләр аны ал-ял бирмичә уйнаттылар. Салих гармунын уйнаштырып караса да, Биюш аның тавышын басып китте. Биюш, шул ярышта җиңү өчен, гармунын бөтен көченә тартып, аякларын киң җәеп куеп, айкала-чайкала уйнады. Аның илһамга чумып көйне бер уйнап чыгуы җырның яңа яңгырашын табу иде, иҗат иде. Шигырь иде бу уйнау! Ул онытыла, гүя моң дәрьясының әллә кайларына китеп, шунда иңләп-буйлап йөри, талчыга төшкәч, кыяга сөялә дә гармунын сикертеп кенә күкрәгенә кыса — каеш бушый, көй акрыная. Моң күген тагын очар коштай иңләү өчен хәл җыю икән монысы. Уйнар өчен аңа әнә шул ике аяк баскан төш җитә, ә моңы белән кешеләрне сихри сәяхәтләрдә гиздереп кайта.

Шуннан соң гармунчы Салих күренмәде. Ул, үзенең җиңелүенә үртәлеп, уеннан бөтенләй киткән иде бугай. Ә Биюш капка төпләренә кайтып җиткәч, Салих әллә каян гына калкып чыкты һәм, Биюшнең уйнап туктагач каешын эләктерергә дә өлгермәгән гармунын кулыннан суырып алып, күреген яньчелдереп бер типте дә дәшми-тынмый гына кабат караңгылыкка чумды.

Кызганыч иде гармун, тавышы матур иде. Биюш аны үзе келәйләп төзәтеп карады, әллә осталыгы җитмәде инде — элекке тавыш яңгырамады. Шәһәрдән яңаны кайтартканнар иде, тик — кем сиңа яхшысын сайлап торсын — уңмадылар, үзең уйнап карап алырга кирәк шул гармунны. Анысы энеләренә кычкыртырга ярады. Шуннан соң, этисе белән икәүләп, иске гармунның күреген яңарттылар.

Һәм тиздән Биюш, җиткән егет булып, уенның уртасына керде, аның инде күз атып йөргән кызы да бар — Фирәвия исемле. Әмма яратуын турыдан гына әйтә алганы юк, кыз үзе дә сизәдер сизүен, шулай да барыбер әйтмичә булмас бит. Бер кичне алар уен урынында икәү генә калдылар. Яратуын бик әйтеп кенә бирәсе дә, тик сүзе табылмый. Гармунда уйнап биргәнне аңласа иде Фирәвия — кеше белмәгән сүзләр эзләп газаплanудан котылыр идең дә куяр идең. Әллә уйнап күрсәтергәме соң?

— Фирәвия, гармун уйныйммы?

— Уйна!

— Нинди көйне?

— Син бит «Алсу»ны яратасың. Ашыкмыйча гына уйна шуны.

Гармун тавышы пышылдап кына чыга. Фирәвия аңа акрын гына кушыла:

...Мин моңланырга яратам
Ярымнан калмасам да...

— Фирәвия, тукта! Ишетәсеңме, җил сызгыра, җил сиңа кушылып җырлый! Әй, ул икенче көй чыгара икән лә...

Биюш гармунын тезләренә куйган да җилне тыңлый. Җинел һәм тиз-тигез агышлы нечкә көй иде бу. Биюш тә сабый сыман Фирәвиянең алдына башын салды, кыз аны кырку чәчләреннән сыпырып иркәләде. Аннары Фирәвия аның күкрәгенә башын куйды. Җил, инде таң җиле, яңа көй башлады.

Аларның мәхәббәтен таң җиле көйгә салып әйтеп бирде. Ярату сүзләре, бәлки, онытылыр да иде, ә җыр, моң онытылмый инде ул.

...Сугыштан соң гына өйләнештеләр алар. Шул авыр елларда башка чыгып, йорт-җир җиткереп, үз көчләренә таянып яшәделәр. Моң-җырга әллә ни вакыт кала торган чак түгел иде. Шулай да, авырлык килгәндә, кычкыру-әрләшү белән ерак барып булмаячагын аңлап, алар бергәләп моңаялар иде. Биюш гармунын ала да үзе яраткан «Алсу» көен уйный, әйтерсең лә бу көй аның Фирәвиясенә багышланган, аның йөзендәге алсу чибәрлекне мактый иде. Фирәвиясенә мең рәхмәт. Биюшкә тавышланырга беркайчан да чама калдырмады. Иренең кәефе кырыла башлавын сизү белән, гармунын кулларына тоттыра һәм, аның җилкәсенә таянып, гел бер сүзләрне әйтә иде.

— Биюш, уйна әле, таң җилләрен сыздырып уйна...

Алар шул җырны гел яңартып яшәделәр. Хәер, әче җилләр дә исми калмады калуын.

Әле былтыр көз генә булып алды шундый хәл. Кашык төшсә, чүмеч тә аның артыннан идәнгә очарга гына тора бит. Фирәвия һич уйламаганда гына Биюшеннән көнләшеп куйды. Моның өчен сәбәбе дә бар һәм бу сәбәп елга агышын туктатырлык зур икән.

— Кибеткә еш керә башлагансың. Ахры, кибетчене күзләвең инде,— диде ул.— Картаеп беткән башың белән кеше көлдереп йөр тагын, балаларың үсеп җиткән. Ирдән кайткан булса да, сиңа кызың булырлык бит ул.

— Әллә кибеткә папирос алырга керергә ярамыймы?!

— Папирос кайгысы булмаган әле. Тутый кош, дип кенә эндәшкәнсең кибетчегә. Синнән алган папиросны тартмас җиреңнән тартырсың, дигәнсең...

Биюшнең шаярып сөйләгән сүзләре кичкә өенә әнә шулай туксанга төрләнеп әйләнеп кайтты. Ул бакча башындагы киселгән каен төбенә утырды. Бу урынның элекке хуҗасы бакча башына төрле агачлар утырткан булган. Алар инде зурлар, алар хәзер, яфракларын коеп, ялангач калганнар. Әнә теге имәннең дә бер яфрагы да юк. Күп елны имәннәр, саргайган-көйгән яфракларын очырмыйча, киләсе елда чыгачак бөреләрне салкыннан саклыйлар бит. Ә моның шәрә ботак-чыбыклары кичке җилдә тибрәлер-тибрәлмәс торалар. Җил котырып искәндә дә аска иелмиләр, тик янга бәреләләр.

Кинәт кенә шәрә агач ботаклары кубыз теледәй булып то-

елды Биюшкә. Карале, көзге җил, аларны чыннан да кубыз итеп, көй суза бит! Тик бу көй нигәдер йөрәккә ятышсыз — чыбыклар әче сызгыралар, кайбер яңа көйләр кебек, йөрәкне үткен пычак белән телгәлиләр, әйтерсең каты ботак-чыбыклар үзләре әнә шул пычаклар иде. Нигә соң бу композиторлар шундый әче җилләрне генә тыңлый башладылар әле? Яңгыр яугандагы, таң җиле искәндәге күңелне яңартучы көйләрне ишетмиләр икән?..

Кубыз... Уйлап карасаң, халык бу уен коралын табигатьтән күчереп ясаган икән. Кемдер, менә шулай Биюш кебек, җилнең ботакларны кубыз теле итеп уйнавын күреп алган да кубыз ясаган...

Кубыз... Хатыннарга юл куйсаң, алар сине кубызга биетәләр инде. Ә кубызга бию менә шушы шәрә ботаклар көенә сикеренгәләү буладыр, шәт. Шуның мәгънәсенә хәзергәчә төшенмичә йөрелгән бит...

Фирәвия дә шулаймы?.. Булмаганны!.. Юк, аның Фирәвиясе мондый әче, моңсыз көйләрне белми, таң көен ярата ул. Әз генә көнчелек галәмәте кузгалып киткән икән — ярата, димәк...

— Кайда йөрисең тагын?! — дип, ярым үпкәләп каршылады аны Фирәвия.

— Бакча башында идем лә... Колакка әллә нинди шыксыз көйләр ишетелде...

— Шулай булыр әле ул, миннән башка гына йөрсәң! Менә мин үзем тыңлатыйм әле сиңа көйләрнең көен...

Фирәвия түрдәге урындыктан өстенә ак җәймә бөркәлгән гармунны Биюшкә китереп тоттырды, үзе аның җилкәсенә таянды...

— Таң җилләренә ияреп уйна...

Биюш белән Фирәвия яшьлекләрен рәхәтләнеп искә алдылар. Өйалды баскычыннан аяк тавышлары ишетелгәч кенә, көйне тыңлаудан туктадылар алар. Кечкенә малайлары уеннан керә иде бугай. Әти-әнисенең көен ишетмәсен әйдә, үз җырын кеше үзе табарга тиеш бит. Хәер, әти-әниләренә охшаган балалар хыялый изге бер яратуда алардан калышмаслар әле. Алай гынамы соң, алар тагын да матуррак, бәхетне зурайтучы көйләр ишетерләр табигатьтән... Киләчәк аларныкы бит, ә табигать көн саен, хәтта минут саен яңа көйләр чыгарып кына тора. Аларны ишетә белергә генә кирәк. Ә ишетсәң инде, син бәхетле, димәк...

Биюш урыныннан кузгалды.

— Ак колынның да инде үз көе бар,— дип сөйләнеп куйды үзалдына.

...Нигә әле аның тауда чабып уйнавы җыр булмаска тиеш

икән? Әллә шуны көйләп караргамы? Авылдашларга уйнап күрсәтеп, бөтен халыкка таратырга иде ак колын көен! Идәнгә төшеп ватылган чокырның чың-көен дә, яңгырның өй түбәсендә оркестр уйнавын да, Фирәвия белән икәве генә тыңлаган таңның мәхәббәт җырын да... Барысын да, барысын да... Хәтта көзге ботакларның сыкрануын да... Йөрәккә сеңеп калган бу көйләр, ә үзләрен һаман авылдашларга уйнап күрсәтеп булмый. Күңелдән гармун телләренә һаман тама алмыйлар алар.

Әллә яңа көйләр җырламакчы булып юкка талпынасыңмы, Биюш? Гомер үтеп бара, теләккә яшьләй ирешергә кирәк булгандыр, мөгаен.

Нигә әле сез, көйләр, күңелдә бикләнеп ятасыз? Бәреп, яңгырап чыгарга көчегез җитмиме? Әллә сез дә картаясызмы?

Хәер, моң картаюны белми. Һәр җырлаган саен яшәрә бара бит җыр. Һәм кеше дә җырлап яшәрә. Димәк... Димәк, өеңә кайтасың да ашъяулык шудырып чокырларны идәнгә төшерәсең — теләгәнеңчә ват, беркем ачуланмый да, «чәбәк» тә итми. Әй чыңлыйлар чынаяклар!.. Теге көйне тагын ишетәсең!.. Ә хәзерге чокырлар алай чыңлармы соң? Ул көйне ишетү өчен теге чактагы зәңгәр бөрчек бизәкле чокыр кирәк түгелме? Һәм үзеңнең дә малай булуың...

Әгәр бүтән көй чыгарып ватылсалар? Начармы? Юк, бигрәк шәп! Яңа көй!..

— Әйдә, бия, кайтыйк, тизрәк кайтыйк әле... Бүген кияү балакай чәйгә дәшкән иде. Кичкә чаклы ак колын көен гармунда уйнарга өйрәнеп куйыйм әле...

...Ак колын сөзәк тауга чабып менә. Нәни тояклары белән, җирдәге моң телләренә басып, көй чыгара...

Әйе, бу дөньяда һәрнәрсәнең үз көе бар шул. Үз моңы...

*1973*

# Зөбәрҗәт әби бирнәсе

Чүлмәк ватуны, капчык сугышын һәм башка шаян уеннарны һәркем күреп тә бетерә алмый. Мәйданда уеннар күп — кайсына өлгермәк кирәк. Ә менә көрәшне, ат чабышын, йөгерешне инде бераү дә карамыйча калмый, чөнки киләсе сабан туена чаклы телдән төшмичә сөйләнәчәк хикмәтләр шушы ярышларга бәйле, шушы ярышлар күбрәк бәхәс тудыра. Шулай да иң кызыгы — халыкның күтәрелеп көлгән чагы — мәйданга йөгерешче картлар килеп кергәч була. Ап-ак ыштан балакларын тездән югары сызганган яланаяклы абзый-бабайларның кабаланулары, узышу дәрте мәйданны кыздырып-җанлан-

дырып җибәрә, аларның йөгергәндә адым саен тукталып торган кебек тоелуы сабан туен рәхәтләндереп елмайта.

Болар сабан туеның һәркемгә билгеле тамашалары, бәлки, алар турында киңәеп сөйләүнең кирәге дә юктыр. Чөнки сүз — бер йөгерешче турында гына.

...Безнең авылда Нуришан картка күбрәк кушаматы белән эндәшәләр иде. Башта аңа Йөгерешче малай, аннары Йөгерешче егет, диләр. Йөгерешче абыйдан Йөгерешче абзыйга күчә. Йөгерешче бабайга әйләнүен безнең буын да хәтерли, монысы оныгы тугач булды.

Нуришан карт кушаматындагы үзгәрешләргә һич тә ачуланмады. Бик тә тыныч холыклы, ягымлы, йомыш тыңлаучан кеше иде ул. Үзенә авыр китерсә дә, күршесенең, гомумән, үтенече төшкән һәр кешенең сүзен кире какмады. Хәер, күп һөнәр иясе дә түгел иде Нуришан карт үзе. Хуҗалыгын ипле алып барырга акылы-осталыгы җиткән гади бер авыл агае иде. Әйе, көченнән килгәнне кызганмас иде, йомыш үтәүгә үзенчә игелекле иде ул. Һәм шуңа күрә аны авыл онытмый.

...Гражданнар сугышы чагында Нуришан Кызыл Армиядә була. Аларның отрядын Колчак гаскәре чолгап алгач, Нуришанны командир чакырып китерә дә:

— Хәлебезне аңлатып торасы юк. Таңда ярдәм килеп җитмәсә, безне калҗага турап бетерәчәкләр. Төн караңгысы төшү белән, юлга чыгасың. Ара синең өчен ерак түгел — күп дигәндә, унбиш чакрым. Хәер, синең арттан пуля да җитә алмый бит. Син китәсең, без камалышта калабыз. Иртәнгә атлы гаскәр алып килмәсәң, безнең туракланган гәүдәләрне генә күрерсең...

Бу риваятьне авылга кем алып кайткандыр, бәлки, отрядны коткаруы турында мактанып-шатланып Нуришан үзе сөйләгәндер — хикмәт анда түгел. Эшнең асылы шул — камалыштагы дусларына вакытында ярдәм килгән.

...Нуришан авылга Гитлер сугышы беткәч тә кайтты. Авыр чор иде: тегесе җитми, монысы юк. Өстәвенә кечерәк авылларга телефон да кертелмәгән иде. Ашыгыч хәбәрне кирәкле урынга тиз генә ирештереп тә булмый.

Нуришанга күршесе ялварып керә, оныгы каты чирли икән. Медсестраны чакырткannар, әмма ул нишли ала соң — сабыйның сукыр эчәгесенә операция ясарга кирәк. Чепьяда андый авырудан һәркемне коткарып кала торган хирург бар барын, тик аңа кем хәбәр итсен...

— Синдә генә бөтен өмет, Нуришан,— ди күршесе.— Докторның үзен алып килә күр. Барлык теләгеңне үтәрмен! Караңгысын караңгы инде, төн бит, таңгача сабый көтмәс шул. Хәле чиктә...

Һәм Нуришан Чепьяга чыгып йөгерә. Шактый юл киткәч:

— Туктале син, карт башкай,— ди ул үзалдына.— Ярый, хәбәр дә иттең ди, хирург барыбер баланы алып килергә кушар. Сабыйны ат арбасында дыңгырдатып йөрерсеңме?!

Һәм ул, кире кайтып, баланы күтәрә дә тагын йөгерә. Сигез чакрым араны ял итә-итә узганмы Нуришан — анысын үзе белгәндер, тик ярты сәгатьтән баланы хирург алдына китереп сала ул.

...Нуришанның йөгерешче булуына бәйле башка хикәятләр дә бар. Әмма шушылары да җитәдер. Тик шунысын гына өстәп әйтик: егет чакта Нуришан күрше авыл кызына гыйшык тоткан, сөйгәне янына кичен йөгереп барып, таңда йөгереп кайтып йөргән, имеш. Монысы бераз бизәкләп кенә җибәрүдер, чөнки егетләр, кызлар янына йөгереп барсалар да, кайтканда адымнарын санап атлыйлар. Аннары Зөбәрҗәт әби — Нуришанның карчыгы — чит авылдан төшкән килен түгел, үз авылыбыз кызы булган.

Менә шулай, Нуришан сабан туенда йөгерештә берәүне дә алга чыгармады. Әле былтыр гына да бу карт, чалбар балакларын тездән югары сызганып куеп, зәңгәрсу күлмәге өстеннән ак билбавын буып, картлар йөгерешендә башкалардан тын алып ял итәрлек алда килгән иде. Аның тезләрен югары чөеп, аякларын алга селтәп атып йөгерүе картлар ярышын гына түгел, бөтен сабан туен ямьләндереп җибәргән иде. Ә быел кар астына су төшкән чакта җирләдек үзен. Быелгы сабан туе аңардан башка инде.

— Көтмәде, тагын бер генә сабан туе узганны көтмәде бу әҗәл!..— дип әйткән икән Нуришан карт.

...Мәйданда барлык ярышлар да тукталды — авыл күпере төбеннән картлар йөгерешкә чыкты. Аларның йөгерүе безгә аермачык күренә.

Картлар ат юлыннан йөгерәләр, һәм аларның рәте тиз арада сирәгәйде, берәүләр шактый алга китте, икенчеләре бөтенләй артта калды. Иң алда Зөбәрҗәт әби, ул хатын-кызлардан ялгызы, шулай да барлык картларны узып килә, тик ике бабай гына аңардан әллә ни калышмыйлар, Зөбәрҗәт әбине куып җитәргә исәпләре. Ай-һай, җиткерерме икән, Йөгерешче Нуришан карчыгы ич әле ул!

Алдагылар мәйданга якынлашалар.

— Әйдә, әйдә, тырыш, Зөбәрҗәт әби! Берсен дә җиткермә!

Тик... Бөтен мәйдан ыңгырашып куйды — Зөбәрҗәт әби сөртенеп егылды.

— Тор инде, тизрәк, артыңнан җитәләр бит!..

Зөбәрҗәт әби кулларына таянып тезләнде, артка борылып карады — якынлаша иде ике карт.

Мәйданнан кемнәрдер куллары белән Зөбәрҗәт әбине куып килүче картларга ишарәләделәр — акрынрак йөгерегез инде, янәсе.

Әллә шуны аңладылармы, әллә инде хәлләре бетә башлаган идеме, ике бабай да акрынайды. Алар артыннан килүчеләр дә, болайга карап йөгерсәләр дә, кирегә чигенгән кебек иде. Хәер, картлар йөгерүе шулай тоелырга да мөмкин инде ул...

Мәйдан тын да алмый.

Зөбәрҗәт әби маңгаена төшкән кашемир яулыгын арткарак шудырды һәм, әлеге ике карт куып җиткәнче җәһәт кенә торып, йөгереп китте!

Мәйдан тирән итеп сулады. Җиңел сулау иде бу!

Колганың иң очына бәйләнгән бүләкләрне Зөбәрҗәт әбигә бирделәр. Зөбәрҗәт әби арада иң озын киҗеле сөлгене алды да:

— Монысы үз бирнәм икән,— диде.

Сабан туе уздыручылар уңайсызланып калдылар.

— Белмәдек бит...

— Хафаланмагыз,— диде Зөбәрҗәт әби.— Мин Нуришан өчен йөгердем бит. Бүләге дә Нуришанга. Мин биргән бирнә Нуришанга эләкте. Бик тә әйбәт булды әле...

*1974*

# *Соң*

Көрт койманы ашып килә. Багана башлары кар өстенә тезгән бүкәннәр кебек, ә яткырып сугылган такталарның өске читләре шул бүкәннәрне әйтерсең бер-берсенә бау белән тарттырып тора. Монда малай-шалайга футбол кыры инде — кар батмый, җир кебек каты.

Гәрәйша, көрттән шуып төшкәч, борылып карады — чаңгы карны анда-монда гына тырнаган иде. «Буран бабай карны ничек тыгызлап өйгән! Балалар бәхетенә инде!» дип уйлады ул. Әмма кузгалып кына китте — чаңгылары кар эченә чумды. «Күр инде, бер адым җир — ике төрле кар! Тыгызлап салынганы сыек шәмәхә төскә манылган, йомшагы — ап-ак. Әллә киресенчәме, ап-агы йомшак, ә сыек шәмәхәсе тыгызмы?»

Уйлый калсаң, бөтен табигать, бөтен дөньясы шулай капма-каршылыкка корылган инде. Кешеләр дә шулай. Бар йомшак күңеллесе, шөкер, чытырман-чәнечке холыклысы да җитәрлек. Сөйгән-сөелгәннәре күп, сөеп тә сөелмәгәннәре дә шактый...

Ул, уйларын таратырга теләгәндәй, ярыштагы кебек ашыгып шуа башлады. Тукта, кая болай очына соң әле ул?..

Гәрәйша шууын акрынайтты. Тик адымласаң да, уйлар аңа тагылганнар, җилдертсәң дә, аңардан калышмыйлар икән.

Үр түбәсен үткәч, иелеп этенә-этенә, түбәнгә — Шушма ягына тизрәк шуып китте ул. Нигә, уйларны да канатландырып, алар белән янәшә очмаска соң? Нигә тыелырга? Ни дип әле теләкләреңне томалап, йөрәккә богау салып яшәргә? Үз тормышыңны үзең корыту, үз бәхетеңне үзең төенләү түгелме соң бу?

Ул Сабый тугаеның кырт киселгән һәм кар ятмый торган ярына терәлгәч кенә шып туктады.

— Киткәннәр икән... Киткән...

Хыял-уйларны аның үз сүзләре йомып куйды.

— Киткән...

Гәрәйша боз өстенә таллык башыннан әйләнеп төште һәм балыкчылардан калган бәкеләргә чаңгы таягы белән төрткәләде. Бәке авызлары чыйраган иде, тишекләрдән пылт итеп су бәреп чыкты — күптән түгел генә кузгалганнар, димәк.

Петрух бабайларны шушында күрергә иде исәбе Гәрәйшаның. Һаман саен өйләренә барып йөрү дә уңайсыз. Әмма соңлады менә.

— Ашыгасы иткәннәр икән... Гадәттә, тәмам караңгы иңгәнче утыралар иде... Балык чиртмәгәндер, күрәсең...

Гәрәйшаның Петров-Петрух дәдәй турында элек тә ишеткәне бар иде, чөнки Петрух — районда яшәүче удмуртлар арасында мәзәкче булып танылган кеше. Аның үзен гомердә күрмәгән кешеләр дә, мәзәк сөйләгәндә, Петрух дәдәй әйткән икән, дип кыстырырга онытмыйлар. Ихтимал, бу шаянлыкларның күбесе Петрухка сылтау гынадыр. Балтач төбәгендә яшәүче удмуртларның җорлыгын бер Петрухка гына кайтарып калдыру дөрес тә булмас. Әмма барыбер Петрух Петрух инде, удмурт дөньясы аны беркайчан да читләтеп үтми.

Алар былтыр җәй генә таныштылар. Петрухлар авылына Гәрәйша эш белән килгән иде. Йомышы шул — дүртенче класс җитәкчесе итеп билгеләнгәч, бу авылдан йөреп укыячак балалар белән алдан ук танышып куярга иде аның исәбе.

Балаларны күреп-сөйләшеп, инде китәр юлга борылганда, Гәрәйшага Петрух дәдәй очрады.

— Безнең сабак балабыз юк, шулай да безгә сугыл. Безнең самоварның чәе тәмле,— дип чакырды Петрух аны.

Карышмады Гәрәйша, үзе дә мәзәкчән удмурт карты белән танышырга теләп йөри иде.

— Авылга килеп, бездә чәй эчмәгән кеше булмаска тиеш, учитель. Аннары ошап куйдың әле син миңа: үзең балаларны барлап килгәнсең. Ә бу, белүемчә, сезнең эштә мәҗбүри түгел бугай. Яратасың, димәк, аларны. Әйдә...

Чәйдән соң Гәрәйша, өй нигезе кырындагы буй тагарак өстенә утырып, папирос көйрәтте. Бераздан Петрух та аның янына чүгәләде.

— Тартасың икән,— диде ул.

— Гадәт инде.

— Син аны урак өстендә генә булса да ташлап тор. Нигә дигәндә, урак өстенең үзенең тәмле исе була. Ә син, тәмәке сөрсетеп, шуны таймый каласың.

Петрух дәдәй мәзәк сөйлидер дип көткән иде Гәрәйша. Аңарга бит мәзәк кенә булсын! Ләкин картның йөзендә-сүзендә шаянлык бөтенләй сизелмәде. Гомумән, аңа Петрух турында моңарчы ишеткәннәре ялгандыр, бу кеше бөтенләй шаярта белмидер сыман тоелды. Бу удмурт агаеның телен мәзәккә бору өчен әллә берәр сәбәп кирәкме, дип уйлады Гәрәйша.

Петрух абзардан бер уч печән алып чыкты.

— Урак өстендә печәннең дә исе үзгә — җитлеккән була, бөркелеп тора,— диде ул.— Бик беләсең килсә, хәзер менә шушы күләгәнең дә исе бар.

Яртылаш кына тартылган папирос, тагаракка каплаган такталар арасыннан суга тидергәч, чыжлап сүнде.

Өйдән зәңгәр күзле Любаша чыкты. Күләгәгә кергәч, аның күзләре тагын да зәңгәрләнә төште. Ничектер җәйге эңгерmeңгердәге урман күле төсен хәтерләтте бу минутта алар Гәрәйшага. Кыз, Петрух белән Гәрәйша яныннан үтеп, капкага юнәлде. Кече капканы яртылаш ачкач, борылып:

— Мон кошки, атай*,— диде.

— Ярар, Любаша, бар...

— Исән булыгыз, Сөйләшми торган абый,— дип күз сирпеде кыз аннары Гәрәйшага. Любашаның нечкә кашлары бөгелеп куйды.— Тагын килегез.

«...Чыннан да, нәкъ Тәгъзимә төсле бит бу кыз! Күз сирпүе дә нәкъ Тәгъзимәнеке...»

— Төпчек кызым,— диде Петрух.— Соңгысы,— дип кабатлады ул бераздан.— Башкалары кош балалары кебек таралыштылар. Любашаны үз яныбызда гына торгызасы иде, әмма без теләгәнчә булмас шул. Сизәм, сизеп торам — төпчегем дә очар...

«Мондый чибәрне ата-ана канаты астында саклап булмыйдыр...» — Гәрәйшаның башыннан шул уй йөгереп узды.

— Әйбәт эшли колхозда. Сарыклар карый, мактапып килә.

«Унган кызны егетләр тиз күрә, Петрух дәдәй...»

— Унынчыны бергә тәмамлаган яшьтәше быел, хәрби училищены бетереп, командир булып кайтты.— Петрух бер мәлгә туктапып калды да ачыклап әйтте: — Сезнең мәктәптә түгел, Чепьяда укыды алар. Егет хәзер йолдызлы погоннар таккан, агайне. Шул чая егет, бер елдан өйләнешәбез, Любаша, дигән икән. Кызның бу хакта безгә тел ачканы юк әле.

* — Мин киттем, эти.

«Хәрбиләр кыю була, эти кеше...»

— Нишлисең бит, ата-бабадан калган йола. Каршы килеп булмас.

«Каршы төшеп тә ни кырырсың, Петрух дәдәй?!»

— Бәхетләре булсын.

«Шулай дисәң инде...»

— Сәер кеше икәнсең, мин һаман лыкылдыйм, ә синең сыңар сүз әйткәнең юк.

«Күңел бутала бугай, Петрух дәдәй...»

— Любаша дөрес сизгән икән, Сөйләшми торган абый, ди.

«Елмайганда кашы аз гына тартылып куйды үзенең...»

— Ярар, сөйләшәсең килмәсә, кыстамыйм.

«Петрух дәдәй, урак өстендә һәрнәрсәнең исе тәмле-татлы була, дисең. Хәтта һаваның да, хәтта күләгәнең дә. Урак өстендә яшьлек исе дә үзгә була икән бит... Бу вакытта уянган мәхәббәтнең дә исе бүтән бугай... Алай буламы соң әле ул?..»

Любашаны өйдә беренче тапкыр күргәч, Гәрәйша каушапсискәнеп, тетрәнеп киткән иде.

— Тәгъзимә!! — дип кычкырып җибәрә язды ул.

Һәм бер мизгелдә аның башыннан бихисап уйлар куышачорнаша бөтерелеп үтте.

«...Юк, Тәгъзимә ничек терелеп кайта алсын!.. Инде елы тулып килә. Кайтса да, ул нигә монда булырга тиеш? Ә бу удмурт кызы ни исемле? Любаша? Шулайдыр шул... Нигә Тәгъзимә түгел? Ул нәкъ Тәгъзимә төсле бит... Тәгъзимәдер әле... Аның төсебите, гәүдәсе гел дә Тәгъзимә инде. Хәтта тавышы да Тәгъзимәнеке кебек — йомшаклыгы колакка ятышлы... Әмма син Любаша икәнсең шул... Тәгъзимә мине яратып күз сирпи иде...»

Петрух белән янәшәләп күләгәдә утырганда, бу уйларны ул кабат, инде ашыкмыйча, күңеленнән саркытып сөзде. Кыз аны сөйләшмәс итте, Любаша үзе...

Карт та әнә туктады. Баштан ук сизенде ул, шуңа күрә Гәрәйша йөрәгенә яра ясамаска, мәхәббәтне кабындырмаска тырышып, дәлилләрне саклык белән эзләп сөйләде. Гәрәйшаны чакырып, ике йөрәкне бер утка салдым бугай мин тилеюләр, дип газаплады Петрух үзен. Бәлки, алар бер-берсен тапмаган-белешмәгән булырлар иде... Уты бер, ә ике йөрәк ике учакта янарлар инде...

Петрухлар авылына җәяүләгәндә дә бер тын алуга — ярты сәгатьтә — барып җитәсең, ерак түгел. Һәм Гәрәйша шушы удмурт авылы ягын якшәмбе саен диярлек урап кайтырга гадәтләнде. Туры Петрухларга керә һәм, озакка тукталмастан, картның хәлен генә белешә иде. Кайчакта Шушманың Сабый тугаенда очрашалар. Шул сәфәрләрдә Любаша туры килсә, кыз аңа һаман да бер сүзне әйтер иде:

— Исәнме, Сөйләшми торган абый!..

Һәм Любаша алдында Гәрәйша чыннан да бер сүз дә сөйләшми. Ә Петрух белән ул бөтенләй сүзсез утырмый. Кыска-мыска соравы белән дә Петрухны озак сөйләтә иде. Бервакыт, җир туңдырып та кар төшәргә өлгермәгән чакта әле, Петрух озата чыккач, аңа болай дигән иде:

— Мин генә кунак булу килешми, үзең дә, Петрух дәдәй, безгә рәхим ит. Апа белән парлап, Любаша да барсын...

— Булмас шул.

— Аңламадым?

— Карчык белән Любаша барсыннар, тыярым юк.

— Син үзең?

— Мин бармыйм.

— Нигә?

— Син гаҗәпләнмә, тәртип шундый инде минем. Ишеткәнең юкмыни бу турыда?..

Шушмадагы асылма басма турына төшә торган тыкрыкка борылгач, Петрух кыска бер хикәятен сөйләде:

— Безнең басу аркылы кайчандыр Гондыр елгасы аккан. Сезнеңчә Аю елгасы була. Хәзер суы киткән инде. Шуның башланган төшендә гөлҗимеш агачлары күп. Шәп агач. Сез, татарлар, аны кайчак тагын да матуррак исем белән атыйсыз — саваплы җимеш, дисез. Карсыз вакытта мин шул саваплы җимеш куаклыгын көнаралаш барып карыйм. Нигәме? Чөнки агачлар гына түгел, ә елга башы үзе дә саваплы кебек. Бирге болында Шушманың элекке эзе күл булып калды. Төнбоеклары тын гына тирбәлә, камышлары сызгырып үсә күлнең. Шунда мин ел саен көймә төшерәм. Үзем инде көймәгә утыра алмыйм, баш әйләнә — картаелды. Кирәк кеше игелеген күрсен. Аннары конюшня утарына кергәч тә әйләнмә кайрак бар. Колхоз оешканнан бирле шунда тора, кайрагы һаман тузмый — шәп икән. Шул кайракның тагарагын ташлар белән терәткәннәр. Бер ягындагы таш тигезләнгән мәрмәрдән дә шома, икенче ягындагысы пычак йөзедәй үткен кырлы. Шундый ташларны мин бүтән җирдә күрә аламмы? Бөтен дөньясына берәр генә алар...

Петрух тун якасын торгызды, сирәк мыегын шомартты.

— Миңа бит, Гәрәйша, көн дә — бәйрәм, күзем ачылгач та күргән әйберләрне көн саен кабат күрәм мин, үзгәрешләрне белеп торам. Бер күргән төшне икенче тапкыр күрә алмау — бәхетсезлектер ул. Минем гел күрергә күнеккән кырларым-тауларым, урманым-суларым бар. Үз авылым...

«Туган якны яратуы үзенчә икән Петрух дәдәйнең...»

— Үз авылым байлыгы җитә миңа. Минем хәтта беркайчан күрше авылга да барганым юк.

«Гадәтең сәер икән, Петрух дәдәй...»

— Кешеләр үзләре килә безгә. Хәтта күрше-тирә кунарга керә. Өегезнең һавасы әйбәт, диләр. Шулай булмый ни, юан нарат бүрәнәләрдән ундүрт ниргәле итеп салдык бит өйне, биек итеп.

«Өй зурлыгында гына хикмәт түгелдер, күңел киң сезнең. Туган җирне бөтенләе белән күңелегезгә сыйдырган кешеләр икәнсез...»

Петрух басма тросын бәйләгән багананың түгәрәкләп шомартылган башына терсәге белән таянды.

— Шулай да авылдан бер тапкыр китеп торырга туры килде. Сугыш кырына барып кайттым. Гитлерның миңа атаган «күчтәнәче» булган икән, мина кыйпылчыкларын ботка санаусыз тутырган иде, докторлар, чүпләп бетерә алмыйча, озак интектеләр. Ә сугыш барыбер матур истәлек түгел.

«Сугыш кыры — иген кыры түгел, дип әйтүең инде...»

— Ачуланма, Гәрәйша, бармыйм мин сезгә, үзең килеп йөр, ешрак кил, Любаша әйткәнчә, Сөйләшми торган абый.

«Любаша бүген күренмәде, эштә булгандыр. Теге чакта, беренче очрашканда, күз сирпеп карады. Миңа күз сирпеде, Тәгъзимә кебек... Нигә икән?..»

— Тавыкның ерак сәфәре — әрәмәлек дигәндәй, мин дә шул авылыбыз тирәсеннән ерак китә алмыйм. Ә балаларым ил гизә. Йөрсеннәр — теләкләре. Любаша да китәр, китәчәк. Булачак кияү, командирымнан рөхсәт сорадым, тиздән кайтам, туй ясыйбыз, дип хат язган. Любаша кияү хатын әнисенә укып күрсәткән, миңа әйтмәде үзе, кызлар сере әнкәйгә сыя шул. Мин яшьләрнең теләгенә каршы килмим. Озатырга җыенабыз Любашаны...

«Шулай тизме?..»

Петрух белән Любашаны Гәрәйша бу яңа ел кергәч тә Сабый тугаенда очраткан иде. Якшәмбеләрдә карт шунда балыкка йөргәли. Любаша да бу көнне аның белән төшкән булган. Гәрәйша алтынчы класста укый торган малаен ияртккән иде. Алар шушы тугайга чаңгыда шуып килгәндә, Петрух белән Любаша балыкны алмаш-тилмәш чыгарып кына торалар иде. Боз өстендә алабугалар, бәртәсләр карга манчылып сикерешәләр.

Малае чаңгы эзе белән яр-тауны сырлап бетерде, ә Гәрәйша гел балыкчылар янында булды. Тәненә суык үтә башласа гына, хәрәкәтләнеп җылынып алды. Ул һаман Любашаның күз сирпеп каравын көтте. Әмма беренче очрашудагы караш кабатланмады. Юк, кабатланмады... Дөресе, Любаша аңа күтәрелеп тә карамады.

Ә малайны озак-озак текәлеп күзәтте. Аның чалбар балакларыннан төерләнеп каткан карларны куптарып төшерде. Йө-

гереп килеп ялтыравык бозда җитәкләшеп шудылар. Хәтта малайны йомшак кына итеп күкрәгенә дә кысты. Тегесе дә Любашага сыенды. Тик бу күз иярмәс тиз булды, икесе дә, хисләрдән айнып, ярамый дигәндәй, бер-берсеннән тайпылдылар. Нәрсә турында уйладылар алар? Ахры, малай — әнисен, Любаша — ул ананы алыштыру мөмкин булмавын...

Әйе, Гәрәйшага бөтенләй карамады, курыкты бугай. Нидән? Кем белә инде...

«Әй йөрәк, нигә җилкенәсең соң әле? Любашаның капкадан чыгып барганда күз сирпүе ялгыш кына булгандыр, ул үзе моңа әһәмият тә итмәгәндер. Әле, бәлки, бөтенләй күз дә сирпемәгәндер. Өлкән бит син, Гәрәйша, Любашадан күп өлкән, инде бер өйләнгән кеше, малаең үсә... Тәгъзимәң юк-югын... Ничек инде — юк? Ә Любаша? Ул Тәгъзимә бит инде, нәкъ Тәгъзимә!.. Әй йөрәк, җилкен әйдә, яшерен сөй дә яшерен көй! Белмәсен дә моны Любаша! Шулай да... Любаша элеккечә бер генә карасын иде. Тик бер генә тапкыр, ял булыр иде сиңа, йөрәк... Арып-талып куймагаең...»

— Бүген Петрух дәдәй ялгызы гына идеме икән, әллә Любаша да төшкән булганмы? Әллә монда бүген башка балыкчылар утырганмы? — дип куйды үзалдына Гәрәйша һәм тугайдагы бәкеләрне тишеп бетергәнче борылып-сырылып йөрде.

Әнә Петрух дәдәйләр авылы. Елга өсләтеп кенә барсаң да була, авыл ягына елга туры ага, әйләнгеч түгел.

Гәрәйша соңгы бәкегә күзләрен кыса төшеп карап торды — керфекләрен бәс сара иде.

«Әллә барып килергәме соң? Ай тула инде күрмәгәнгә. Үткән якшәмбеләрдә чыгып китеп булмады, өй һәм малай мәшәкатьләреннән арынмыйсың...»

Ул рәшәткә буена көрәп өелгән чокырлы-кантарлы көрткә чаңгыларын кадады. Ботинка ырмавындагы карларны себергәч, ишек шакыды.

— Әйдүк! — диделәр эчтән. Һәм Петрух ишекне учы белән сугып ачып җибәрде.— Гәрәйша! Нәрсә син, белмәгән-күрмәгәндәй, ялындырып кына керәсең?!

Гәрәйшаны өйнең Петрух мактаган ләззәтле һавасы кочып алды. Бөтен йорт эче аңа Любашаның карашыдай сирпеп карый иде.

— Бик сагышлы заманнар әле. Туйдан соң өйдә һаман ямансу, инде өч атна үтте югыйсә. Өйдән чыгып та йөрисе килми. Теге командир егет, кияүне әйтәм, Любашаны алып китте бит тәки...

«Киткән икән...»

— Төпчек кызны, соңгы баланы озатуы авыр булды...

«Соңгы... Мәхәббәтнең дә соңгысы була икән, Петрух дәдәй, һәм соңгарганы...»

— Әйдә әле, Сөйләшми торган абый, сыйланып, күңел ачып утырыйк әле бер! Дөньясы үзебезнеке бит, шөкер иткересе!..

«Күңел ачарга риза, Петрух дәдәй, әмма күңел беркайчан да бөтенләй ачылып бетмәс бит, беркемгә дә сөйләнмәячәк сере бар аның. Ялкынын сүндермичә мәңге сөяр, мәңге сызар йөрәк...»

— Бәхетләре үзләре белән булсын кызыгыз-киявегезнең, Петрух дәдәй! Миннән аларга иң изге теләкләр. Ихластан.

— Рәхмәт яхшы сүзеңә. Менә хаты да килде әле Любашаның. Әйбәт барып урнашканнар. Кияү башлы малай шул безнең! Любаша сиңа да сәлам җибәргән. Үзең укы, мә, татарча язган ул төшен.

Гәрәйша хатның соңгы битен ачты: «Атай! Сөйләшми торган абыйның килгәне бармы? Миннән аңарга күп сәлам әйт. Һәм малаена да».

...Любаша өйнең кай төшенәдер яшеренгән дә теге чактагы кебек — капкадан чыгып баргандагы кебек — күз сирпеп карый иде. Карый бит менә, карый, тик үзе күренми генә...

*1974*

# Ул урамнан дүрт уза...

Казаннан китүче автобуслар бу көннәрдә шыплап тутырылган кебек. Кешеләр кысылып кайтырга да риза, тик туктатмасыннар да төшереп кенә калдырмасыннар. Берничә сәгать сыңар аякта торуга да түзәрсең, автобуска эләгүеңә сөен, югыйсә җәяү тәпиләмәссең бит...

Әскәр автовокзалга иртән сәгать алты тулганчы ук килде. Әмма аларның районына ике рейс китте инде, ә ул утыра алмады. Төшкә чаклы өстәмә машина җибәрәчәкләр иде, шуны көтеп карарга булды, бәлки, шунысына эләгер.

— Анысыннан да калсам, җәяүләп кайтам, барыбер кайтам,— дип сөйләнде ул үзалдына.— Чөнки егерме елдан соң кайтырга сүз бирелгән. Кемгә? Үземә. Һәм менә авылдан киткәнгә егерме ел...

Бәхеткә каршы, шул автобуска хәтта билет юнәтте ул. Урыны җайлы түгел, артка карап утыра. Әмма монысы инде вак хәсрәт, вакытында кайтуы кадерле, сабан туена җитешә, димәк.

Шәһәрдән чykканнан бирле тәрәзәдән күзен алмый ул. Тигез кырлар... Еракта урманлы үр... Туган яклар... Күзәтүе кыен, башны боргалап утырырга кирәк. Яшел уйсулыкны, чиста каеннарны күреп рәхәтләнергә өлгермисең, автобус аларны җәһәт үтеп китә — безнең төбәкләргә дә юллар йөгерек икән.

Автобусның түбә капкачлары, тәрәзәләре ачык. Шулай да

тынчу, тирләтә. Әскәр эшләпәсен салып аяклары арасындагы чемоданы өстенә куйды. Аннары кире алып киде — кояш күзне чагылдыра икән. Чигә чәчләре астыннан шуып төшкән тир бөртекләрен сөртте, күлмәк изүен селкеп, тәнен җилләтте. Каршы як тәрәзәләрдән кырларны карамакчы булды, ләкин берни күренми иде — аралык тулы кеше, тагын үз тәрәзәсенә елышты.

Шулай да автобуста күңелле: юлдашлар гел яшьләр, шаяртып сөйләшәләр, дәррәү көләләр. Монда иң карты, шәт, Әскәрдер. Нигә иң карты? Гомер чаңы иллене дә сукмаган кеше ничек карт булсын? Дөресе, арада өлкәне. Менә аның каршында утыручы ике студент Әскәргә кызлары булырлыклар. Алар күмәк шаяруга катнашмыйлар, үз уйлары белән мәшгуль.

— Их, шул педагогиканы тапшырсам! — диде тәрәзә янындагысы, сирәк сипкеллесе.— Беләсеңме, нишләр идем?!

— Нишләр идең?

— Белмим, Гөлфиза. Котылыр идем. Әй, ничек котыласың инде, гомер буе шул педагогикадан имтихан тотасы ла миңа!

— Сопроматны әйт син! — дип, үз фәнен өстен чыгарырга тырышты аралык ягында озын толымын туктаусыз бөтереп утыручысы, Гөлфиза исемлесе.— Җилекне суыра инде! Әллә сабан туена кайтып ялгыш иттекме соң, Шәмсия?

— Елына бер килгән сабан туена ничек кайтмыйсың ди?! Әти-әниләр көтә...— Шәмсия Әскәргә күтәрелеп карады.

— Шулай шул. Мәйданга соңлап төшәрбез, ахырын күргәч, җитәр. Син дә ашыкма. Аз булса да әзерләнербез.

Үзе дә уйламастан кызлар сөйләшүенә колак салып барган Әскәр, алар тукталып калгач, кинәт кенә карашын тәрәзәдән алды һәм шуның белән сер тыңлавын тегеләргә сиздерде.

Әмма уңайсызлануын бетерергә аңа Шәмсия ярдәм итте.

— Абый, сез агрономдыр, әйеме? Минем җизни дә, автобуска утырса, басуны укып бара. Сез дә шулай...

Әскәр җавап кайтарырга өлгермәде, Гөлфиза исемлесе, толымны җилкәсенә ташлап, ялгап китте:

— Минем әти дә шулай, иген басуын күрсә, сүзе гел бер: арыш чәбәләнгән, арпа егылган, борчак җиргә яткан, ничек урырбыз-җыярбыз инде, дип аһ ора...

— Юк, мин агроном түгел, кызлар. Мин гади кеше, гап-гади эшче...

Әскәр белән сүзне Шәмсия башлап җибәрсә дә, кыз бүтән эндәшмәде, Әскәргә ара-тирә текәлеп карый да, аннары, башын иеп, күзләрен кыса төшеп уйлана — кем икән бу абый? Ә Гөлфиза сөйләшергә әвәс икән, Әскәргә сорауларны яудырып кына торды, таныш түгел абыйның кем икәнлеген үзеннән сорады.

— Сез кая кайтасыз соң? Әллә безнең сабан туена көрәшергә барасызмы? Безнең авылга көрәшкә Казаннан ел саен кем дә булса килә.

— Мин көрәшне караучы гына. Барыр төшем — автобус туктаганчы. Аннары ерак калмый, Гөлфиза сеңел.

— Абау, минем исемне дә откансыз! Мин дә соңга хәтле кайтам. Шәмсия күрше авылда төшә. Сез безнең авылныкымы әллә?

— Авылыгыз нинди соң?

— Баштау.

— Юк, мин ул авылныкы түгел, мин читтән, кунакка кайтуым,— диде Әскәр. Һәм бераздан: — Сезнең авылга түгел,— дип өстәде.

Һәм алдап әйтте.

Шул вакыт автобус эчендәге әңгәмәне шофер тавышы бүлдерде:

— Озын-биек тау менәбез. Барлык кызлар да җырласын!

Кайсыдыр кычкырып сорап куйды:

— Нигә кызлар гына?

— Мин үзем егет кеше, шуңа.— Автобусны яңгыратып көлделәр. Шәһәр чыгар алдыннан гына шоферның, оныкларыма, дип, кибеттән күчтәнәчләр алуын беләләр иде.— Аннары, кызлар җырлаганда, автобус тауны очып кына менә!

— Күр әле, шофер абыйның бушка концерт тыңлыйсы килгән икән!

— Билет бәясеннән чигерермен!

— Бушка алып кайт!

— Риза! Кызлар өчен билетны үзем сатып алырмын!

Шофер шаяртмаган икән: чыннан да, җыр ярдәм итте бугай, машина тауның яртысын диярлек икенче тизлек белән үрләде, аннары гына көчәнде. Тау артта калгач, шофер агай алдагыларга ишетелерлек кенә итеп:

— Шәп безнең машиналар! Пассажирлар тиешледән өчләтә артык бит! — диде. Аннары микрофонны кулына алды.— Рәхмәт, кызлар! Булдырдыгыз! Егетләр дә сынатмады! Хәзер антракт!

Әмма инде җыр тукталмады, ярышу китте: берәүләр башлаган җырга икенчеләре кушылмыйлар, бүтән көйгә кычкырыбрак җырлап җибәрәләр. Монда инде тыңлаучы бер Әскәр генә иде. Хәтта шофер да, кайсыдыр якны яклап, авыз эченнән генә көйли. Гөлфиза Әскәрнең тын утыруын килештермәде, күрәсең, уенын-чынын бергә кушып:

— Нигә җырламыйсыз, абый? — дип сорады.— Безнең якка кайтучылар җырларга тиеш! Югыйсә кунак итмәсләр үзегезне!

— Шулаймы? Ярар, алайса...

Әскәр җыр аз гына тукталып торган арада башлап җибәрде:

Яшь гомер, бер узгач,
Кайтмый ул яңадан...

Ул кушылуларын көткән иде, тик бирәү дә булышмады, ахырга кадәр үзенә ерып чыгарга калды. Салонда пышылдашып алдылар:

— Сибә картлач!

— Нигә карт булсын ул?!

— Яшьлеген сагына бит...

— Исеректер әле...— Монысын юка борынлы егет әйтте.

Әскәр аны ишетте һәм, кешеләрне аралап барып, аның бугазыннан кысып алырга каны кызышты. Ләкин кузгалмады, кешене аңламагач, син үзең ямьсез инде, энекәш, дип уйлады. Бәлки, исеректер дә, әмма шәрабтан түгел, ә җыр яратудан, гел дә яратудан гына...

Автобус чаба да чаба. Кырлар шуып кала. Кырларның иң матур чагы. Хәер, кырлар һәрчак матур: кышын кары җемелди, җәй башында менә хәзерге яшеллеге, аннары өлгергән игеннәре белән гүзәл.

Әскәр үзе Гөлфизага сүз кушты:

— Баштау авылы матурмы соң?

— Аннан матур авыл юк та! Урамнары озын, болыннары киң, таулары биек! Минем әтием дә бу якныкы түгел, яраткан да авылыбызны, шунда яшәп калган. Агроном. Килегез безнең авылга, сез дә бөтенләйгә калырсыз!..

— Рәхмәт...

Әскәр аны баядан бирле кемгәдер охшатып килә иде, хәзер шиге калмады. Гөлфиза — Тәкыяның кызы, дип уйлады ул. Җаен табып, алданрак төшәргә кирәк иде. Гөлфиза белән бергә кайтмассың бит инде авылга. Аннары, нигә кайтырга? Кем көтә аны, кеме бар анда? Әйе, кеме бар?.. Ә бар бит! Тәкыя бар! Нигә кайтмаска?! Беркем дә кумас. Тукталыр-кунар кеше беткәнме. Тәкыяны күрәсе килә. Күпме гомер сагыш белән үтте... Нигә бу тормыш шулай корылган икән? Кайтып кер идең менә туп-туры Тәкыяларга! Юк шул. Шулай да моның ни гаебе-гөнаһысы булырга тиеш? Әскәр Тәкыяның мәхәббәтенә дәгъва итми бит инде. Тәкыя, бәлки, аны исенә дә алмыйдыр, күптән оныткандыр. Тик... Күрәсе килә. Әскәрнең үзенә биргән сүзе бар: беренче тапкыр егерме елдан соң кайтырга! Ә ул вәгъдәсендә тора белә. Сүз бирде, димәк, үтәячәк! Кайтыр Баштауга! Һәм менә инде кайта! Күрер Тәкыяны. Ләкин Гөлфизадан аерым кайтып керергә кирәк авылга...

Әскәрнең кинәт уйчанлануын сизде Шәмсия. Ул сәер абыйга ара-тирә текәлеп карый, әйтерсең лә сорамыйча да — йөрәк тулы газапка кагылмыйча, Әскәрнең ашкынулы серенә төшенергә тырыша.

Автобус акрынлап бушый. Шәмсия дә төшәргә җыена башлады. Бу исә Әскәргә җай гына булды.

— Без бөтенләй дә юлдашлар икәнбез, Шәмсия сеңел,— диде ул.— Миңа да хәзер төшәргә.

— Сез, ахырга тикле кайтам, дигән идегез бит? — Гөлфиза аңарга чемоданын чыгарырга булышты.

— Мин болай гына әйткән идем.

Һәм тагын алдады.

Автобус ашыгып китеп барды. Баштауга җитәргә өч чакрымнар калгач, аның өмете тагын өзелде. Гөлфиза, үзе дә сизмәстән, аны максатыннан туктатты.

Тәкыяга тартым Гөлфиза. Тәкыя кара чәчләрен бер толымга үрә иде, әмма ул озын керфекле, зәңгәрсу күзле иде. Иде? Үзгәргәндер,— гомер бит. Кызы үсеп җиткән. Тагын балалары бармы икән? Әскәрне оныткандыр инде, исән дип тә белмидер. Онытмаса да...

Әскәр тыкрык чатындагы таш өстендә утырып тора иде.

— Абый, сез Әскәр исемлеме?

Ул, Шәмсия сүзләренә сискәнеп, урыныннан торды.

— Әйе...

— Мин сезнең кем икәнлегегезне автобуста ук сиздем.

— Әмма сез бит минем кем булуымны берничек тә белә алмыйсыз! Мөмкин түгел.

— Баштан ук сез бөтенләй серле тоелдыгыз. Аннары җырыгыздан сезнең кем булуыгызны аңладым. Гөлфиза сизмәде, ә югыйсә сезнең хакта ул миңа үзе сөйләгән иде. Аңарга әнисе сөйләгән.

— Гөлфиза мине белә, минем барлыкны белә, димәк...

— Баштауга бүген барыбер кайтмыйсыздыр бит инде. Әйдәгез безгә.

— Сезгә?

— Әйе. Нигә аптырадыгыз? Моның ни гаебе бар?! Сезне эти дә белә икән. Мине каршылаганда, ул сезне төсмерләгән. Синең белән бергә төшкән кеше Баштауның Моңлы Әскәре булды бугай, ди.

— Мине барысы да онытканнардыр, дип уйлаган идем...

— Сез нигә кайтмый йөрдегез соң? Кайда хәзер сез?

Әскәр ташка кире утырды. Ул бу киң күңелле кызның чакыруына сөенә иде, аңа хәтта рәхәт булды. Дөнья яхшы кешеләр белән тулы шул! Аның үзенең дә Шәмсиягә эч серләрен ачасы килде — ничек очрый белдең син, әйбәт кызый!

Тик узган гомере турында Шәмсиягә сөйләмәде, бу сагышлы елларны сүзсез генә искә төшерергә мөмкин иде.

...Йөрелде инде. Мин флотта хезмәт иттем. Диңгезне ярattым. Авылдан бөтенләйгә киткәч, сәүдә флотында эшли башладым. Диңгез-океаннарга чыгып китәсең — туган илгә айлар буе, хәтта ел буе кайтмыйсың. Авылга якынрак җирдә булсам, кайтмый түзә алмам дип, нәкъ шундый эшне сайладым. Туган авыл сагындыра, бик кайтыр идем, әмма су өстеннән йөгереп булмый. Әйе, күп нәрсәләр күрдем — дөнья гиздем бит. Онытырга тырыштым. Әмма онытып булмады. Шушы яшемә җи-

теп мин күргән иң матур нәрсә — ул Тәкыяның карашы. Егерме ел инде ул караш күз алдымнан китми. Бәлки, бүгенме-иртәгәме шул карашны тагын күрермен. Кайтуымның максаты да шул...

Шәмсия һаман аның янында басып тора икән, Әскәр уйларына бирелеп моны оныткан да булган, шуңа күрә кызның сүзләренә тагын сискәнеп китте.

— Авырдыр сезгә. Тәкыя апа үзе дә сагынадыр, бәлки. Әмма сиздергәне юк. Үкенгәнен дә әйтми, үкенмидер дә, бәлки. Әйбәт яшиләр алар.

— Миңа, шәт, кире китү хәерлерәктер.

— Үзегез беләсез инде. Шулай да авылыгызны күрмичә ярармы соң...

— Уйлау кирәк. Ә бит барысы да уйланган кебек иде.

— Сабан туена иртәгә бергә барырбыз. Безнең сабан туе ел да Баштауда була. Колхоз үзәге бит. Кайтабызмы?

— Белмим шул. Бәлки, соңрак мин сезгә үзем килермен дә әле.

— Ярар, алайса. Әнә генә безнең өй, яңа рәшәткәле, түр тәрәзәләре ачык.

Әскәр, чемоданын күтәреп, болын ягына төшеп китте. Елгага җиткәч, ярдан су өстенә карап утырды. Юынып алды. Бормалы елга буйлап әйләнеп килде, тагын элекке урынга утырды, су агышын күзәтте...

Аерылышканда кыз белән егетнең вәгъдәсе бер инде — мәңге көтәргә сүз куешалар. Тәкыя да Әскәрне армиягә китәсе көн алдыннан, кичтән әле, ышандырган иде. Бер үк сорау ничә кабатланса да, җавабы да бер генә булды.

— Көтәрсеңме?..

— Көтәрмен!..

Һәм көтте. Башта. Аннары хатлары сирәгәйде. Армия срогын тутырыр алдыннан гына Әскәргә соңгы хаты килде. Хатны гадәтенчә кичкә чаклы ачмады,— шатлыкны шулай зурайтырга күнеккән иде ул. Ә хатта сыңар җөмлә генә булган икән: «Мин кияүгә чыгам».

Шуннан соң авылга әйләнеп тә карамаска уйлаган иде Әскәр. Ни калган анда? Әти-әнисе юк, вафатлар. Туганнар? Алар белән хат аша хәбәрләшергә дә була.

Шулай да кайтты. Үзе күреп ышанды. Тимерче булды. Абыйларында торды. Баштауның озын урамы буйлап, көненә дүрт узды: иртән эшкә барды, төшке ашка кайтты, тагын эшкә китте. Гел бер сукмак — урамның Тәкыяларга каршы ягыннан йөрде. Ә эштән соң, тәрәзәләрдә утлар сүнгәч — таң алдыннан гына урамнан дүртенче тапкырын узар иде. Җырлап.

Ә җырлы таңнар күп булды! Кешеләр моңа ияләнделәр, тә-

рәзәләргә иелделәр. Аның урамнан дүртенче узуын һәркем үзенчә көтте: кемнәрдер моңсуланды, кайсыдыр аны кызганды, берәүләрнең йокы бүлүенә хәтта ачуы чыкты, кайберәүләр Әскәрнең тугры мәхәббәтенә кызыкты.

— Биргән дә соң Ходай Әскәргә моңны...

— Моңланырсың... Сөйгәнең вәгъдәсен җуйгач...

— Берсе алмаган, икенчесе бармагандагы вәгъдә лә...

— Ялгышмады бит Тәкыя. Ире әйбәт...

— Әйбәт тә, яратышулары мәңгегә берекkәнме икән...

— Китә икән Әскәр...

— Борчымасын Тәкыяларны...

—Тимерче алачыгы яныннан узганда гаҗәпкә калдым: чүкеч тавышы да моң булып чыга, мескеннең...

— Хушлаша авыл белән...

— Тәкыясы белән...

— Көче җитеп китсә, кайтмас инде...

— Кайтыр...

Чакыргач, көрешмичә китү уңайсыз иде, Әскәр Шәмсияләргә кереп рәхмәтен әйтте, куна калмады, җәйге төн белән юлга чыкты.

...Шул ук урам. Озын. Киң. Чирәмсез икән хәзер. Машиналар күп йөридер. Каралты-куралар үзгәргән. Элекке йортлар азайган. Менә Тәкыялар йорты. Яңаны җиткергәннәр, ишегалдының түренә салганнар икән. Алты почмаклы.

Таң нәкъ элеккечә. Берни дә үзгәрмәгән. Һәм бөтенесе дә яңа. Ай гына шул элекке. Борынгы юлдаш.

Әллә җырларгамы? Килешмәс. Ә шулай да кайтуымны авылга белдерергә тиеш бит мин!

Ай катында якты йолдыз...

Җыр, Тәкыяларны узгач башланып, авыл башындагы сусыз елгага җиткәндә тынды.

Калдым ялгызым гына...

Сабан туеның гөрләгән чагы. Юк, онытмаганнар икән Әскәрне. Көрешәләр, сыйга чакыралар, сорашалар, җавап биреп өлгереп тә булмый.

Тәкыя ире белән үзе аның янына килде. Чолгап алган кешеләр, сүз куешкандай, берьюлы таралдылар, алар өчәү генә калды. Тәкыяның ире дә озак тормады.

— Сөйләшәсе сүзләрегез бардыр,— дип китеп барды.

Әмма сүзләр тиз генә табылмады.

— Нигә сөйләмисең, Әскәр?

— Нәрсә сөйлим? Һаман да шул инде мин. Үзгәрешсез.

— Өйләнденме?

— Юк.

— Мин сине бик еш уйлыйм. Ирем дә сизенә. Синнән ничек кенә гафу үтенсәм дә...

— Нигә гафу үтенергә? Әйбәт яшисез икән. Димәк, бәхетле. Ялгышмагансың, димәк.

— Зарланмыйм. Барысы да көйле. Кызыбыз үсеп җитте.

— Бергә кайттык.

— Әмма бәхет өчен өеңдә җиһазың тулы тору, тавыш-гауга купмау гына җитми икән. Матурлык кача бездән. Бәлки, мин гаепледер монысына. Чын мәхәббәт булмаган икән ул минем аны яратуым. Гаиләбез сүнәр-сүнмәс учак кебек, ә андый учакны өреп кенә дөрләтеп булмый. Әллә аерылышыйкмы икән, дип тә уйлыйм...

Әңгәмә кинәт өзелеп торды.

— Тәкыя, ireңә рәхмәт, синең белән сөйләшергә миңа ирек куйды. Беләсеңме, безнең кайчаннан бирле икәүдән-икәү генә очрашкан юк иде?

— Син армиягә киткәннән бирле...

— Төгәл егерме дүрт ел... һәм менә мин сине күрер өчен кайттым. Монда очратмасам, өегезгә барачак идем. Гомер буе сине генә яратканга күрә миңа хакым бардыр минем.

— Нигә күзгә туры карамыйсың, Әскәр?

— Куркам.

— Нидән?

— Мин белгән элекке карашың үзгәргәндер дип куркам.

— Армиядән кайткач, син минем белән күрешеп исәнләшмәдең дә бит.

— Синең турыда начар сөйләүләрен теләмәдем, син бит ир хатыны идең инде. Ә аерылышу мәсьәләсендә...— Әскәр, сүзеннән тукталып йомшак кына көлемсерәп алгач, дәвам итте.— Малай чакта ук бер мәзәк ишеткән идем мин. Тупасрак, шулай да сөйлим. Имеш, дөньядагы барлык җан ияләре җыелышканнар да кемнең иң ямьсез икәнлеген ачыкламакчы булганнар. Хәтта әкиятләрдәге диюләр, аждаһалар, өрәкләр килгән җыенга. Һәм, шайтан, арабызда иң котсызы син, дигән нәтиҗә ясаганнар. Шайтан, әлбәттә, килешмәгән, күрегез әнә, күр, арада иң ямьсезе бака, дип шәрран ярган. Бака мескен көзгедәй ялтыраган күл өстенә озак кына карап торган да, башын югары чөеп, авызын зур ачып, яңгыратып әйтеп салган: «Сез хаклы, җәмәгать, мин дә ямьсезләрнең алгы рәтендә, әмма миннән ямьсез җан иясе булуын белергә тиеш бит сез, ул — ireннән аерылып кайткан хатын»,— дигән. Мин синең, гомерем буе яраткан кешемнең, дөньяда иң ямьсез хатын булуын теләмим, Тәкыя. Минем кайтуымның сәбәбе сине ireңнән аеру түгел. Түгел! Синең элеккеге карашыңны тагын бер генә тап-

кыр күрәсем килгән иде. Әмма булмый, карый алмыйм мин синең күзләреңә. Вәгъдәң бозылуы күзләреңдә чагылыр кебек...

Әскәр мәйданга таба китте. Бер читтәрәк Шәмсия белән Гөлфиза басып торалар. Гөлфиза дустының җилкәсенә башын салган. Шәмсия аны култыклаган. Алар Әскәрнең Тәкыя белән сөйләшкәнен күрделәр. Гөлфизаның күзләре яшьләнгән. Шәмсия Әскәргә кызганып карый. Әскәр моны сизде һәм эченнән генә, юк, сеңел, мине кызганырга кирәкми, дип куйды, кызлар ягына борылып, аларга баш какты.

...Кырлар диңгез кебек. Автобус әнә шул диңгез эчендә үзенә ярылган юлдан шуып-йөзеп кенә бара. Шәһәргә ашыга ул.

*1974*

# *Мәхәббәт бит ул...*

## 1

Мәйсәрә, тракторы шып туктагач, аптырап калды. Башта урыныннан кузгалырга куркып утырды, әгәр рульне ычкындырып җиргә төшсә, трактор тезгеннең бушавын көтеп кенә торадыр һәм алып-бәреп чабып китәр кебек тоелды. Әмма бу корыч атның җан билгесе юк иде. Кыз, трактордан төшкәндә, сука өстендә җайлап утырган Ләбибнең җилкәсенә кагылды, аны булышырга чакырды. Ләбиб тракторның кинәт туктавы серенә шулай ук төшенми иде, ул Мәйсәрәнең магнето тирәсендә казынуын башта читтән күзәтеп кенә торды.

— И Ходаем, тагынниләр булды инде? Нигә сүндең син, мотор? — Кыз үксеп куйды.— Нишләтим соң, сыйпыйммы, үбимме үзеңне?..

Ләбиб, моторны кабызырга теләп, сапны көч белән тиз-тиз әйләндерде. Исәбе юк иде кабынырга, хәтта пошкырып та карамады.

— Их, серләреңне белсәм, ялварып-ялварып үтенсәң дә, туктатмас идем мин сине! — Мәйсәрә мотор сүнәргә сәбәпче булган, үзе белгән барлык нәрсәләрне карап чыкты. Барысы да төзек иде.— Ичмасам, син дә белмисең тракторны! — диде ул Ләбибкә.— Мотор кабызырга көчең бар, ә башкасын белмисең шул! — Аның сүзләрендә ялвару да, хәтта үпкә катыш үз итү дә бар иде.— Үзең мине яратам дип йөрисең тагын! Кечкенә генә ярдәмең дә тимәгәч, ярату буламы инде ул!..

Егет Мәйсәрәнең үрсәләнүенә борчылды, әмма ярдәм итәргә көченнән килми иде, шуңа үртәлеп, кашларын җыеп-бөгел-

дереп куйды. Кызның соңгы сүзләрен аңларга тырышып, аңа күзләрен тутырып карады.

— Нигә ачуланам инде мин сине? Бер гаебең дә юк ла синең. Үпкәләмә миңа, яме, Ләбиб...

Ул, әллә кызганып, әллә инде яратып, егетнең аркасыннан сөйде, Ләбибнең кыйшаеп торган пиджак изүен рәтләде.

— Хәзер эшләтәбез без аны, әйе бит, Ләбиб! Без дә булдырмагач, тракторны кем йөртергә тиеш, ди, име?!

Ләбиб кабаланып-ашыгып тракторның багына китереп сукты. Калай бик каты шыгырдады.

— Ы-ы! — диде ул һәм үзләре сөрә торган җир башында калган мичкәләргә төртеп күрсәтте. Мәйсәрәнең сүз әйтүен дә көтмәстән, дәү-дәү атлап, шунда таба йөгерде.

— Сөйләшә дә белсәң син, Ләбиб...— диде Мәйсәрә үзалдына.— Хәер, син монда булмас идең шул. Яшьтәшләрең белән сугышта булыр идең. Бәлки, инде исән дә булмас идең... Безгә — карт-корыга, хатын-кызга, беләге ныгымаган яшүсмергә калды дөньясы! Егетләрдән син генә бар... Керосины беткәнгә сүнгән шул мотор. Минем шуңа да башым җитми. Әй, бер ай курста булып, кайсын гына белеп бетермәк кирәк! Ә син укымасаң да, сөйләшмәсәң дә, тракторның серенә төшенеп киләсең. Сука өстендә генә утырып йөрүгә риза түгел бугай син. Күпмедер ишетүеңнәнме әллә йөрәгең беләнме — мотор тибешен тоясың. Кем булыр идең икән син?..

Трактор торбасыннан йомгак-йомгак аксыл төтен атылды. Төтен һаман карала барды, аннары күзгә күренмәс булды — мотор бер көйгә гөрелдәп эшли иде.

Май бәйрәме көне иде бу. Иртәдән җете кояш күтәрелде, җилсез иде. Төш авышкач, җил купты, кояш сүрәнләнде. Болай тиз үзгәрешнең хафасыз гына булмаячагы сизелеп тора иде. Һәм офыкта башта очлаеп кына күренгән кара болыт һаман калка-үсә барды, бөтен күк йөзенә җәелеп, көнне караңгылатты. Яңгыры да болыттан ишелеп кенә торды — эре бөртекләр Мәйсәрә һәм Ләбиб сөргән туфракны чукый иде. Яшене юк, күкрәве юк, коя да коя. Буразналар күбекле болганчык су белән тулып килә.

Алар, Ләбибнең кожанын бөркәнеп, тракторның биек тәгәрмәче артына чүгәләделәр — иң ышык урын шушы иде. Әмма бу ышык кына коткара алмады, аяк астына су җәелде, кожан токтымал авырайды, салкыны белән тәннәрне басты. Мәйсәрә Ләбибкә елышты, аның тезенә таянды. Бу аларның беренче тапкыр якынаюлары иде.

...Әллә ярата башладым инде мин сине, Ләбиб? Ярату... Ничек сиздермичә генә килә икән ул... Әллә кызганып-җәлләп кенәме? А-а, син минем үзеңә җылы мөнәсәбәтемне кызгану дип аңласаң, син куптарган давыл бу яңгырдан да көчлерәк-

дуамалрак булыр! Бик ярсу кеше син! Ләбиб, әгәр мин сине чынлап торып яратсам? Аңларсыңмы, белерсеңме син минем мәхәббәтемне? Үзең миңа моны ничек итеп төшендерерсең? Менә шулай кочаклапмы? Синең кулларың җылысын тою шундый рәхәт миңа — беләсеңме син шуны? Белмисең, сизмисеңдер, яратсаң, иркәләр идең... Әгәр сиңа кияүгә чыгарга язган булса? Мәйсәрәгә ир генә кирәк, сугышның иң авыр чагында телсез Ләбибкә чыкты, дип сөйләрләрме? Юк, нигә кешеләр турында шулай ямьсез уйларга! Авылдашлар синең әйбәт икәнлегеңне беләләр.

Үзем үкенмәмме соң? Бәхетле булырмынмы? Мин дә бар бит әле, үзең турында да уйламыйча ярамый. Монда мин ныграк аралап карарга тиеш. Мин бәхетсез булсам, син икеләтә бәхетсез сизәрсең үзеңне. Монысы — сиңа икеләтә фаҗига дигән сүз.

Нигә табигать сине телдән мәхрүм иткән соң? Гөрләшеп кенә утырыр идек без хәзер шушы яңгыр астында! Син, яратам, дияр идең, мин рәхәтләнеп сине тыңлар идем! Бер генә сүз — яратам, дигән сүзне генә әйтергә өйрәтсәм мин сине? Өйрәнерсеңме? Бераз ишетәсең бит, димәк, син сөйләшә дә алырга тиеш. Шул сүзне генә әйтергә өйрәнерсең, яме? Һич югында, дим. Өйрәтермен, яме, син бик тырыш, өйрәнерсең, шәт алла. Һәм миңа көн саен, яратам, диярсең... Аңлыйсыңмы син берәр нәрсә, Ләбиб?! Тоясыңмы, сизәсеңме минем уйларымны? Мин сине яра-та-амм...

Мәйсәрә Ләбибкә күтәрелеп карады. Егет аңа мөлаем елмайды. Кыз аның җилкәсенә башын салды.

Егет нәрсә уйлады икән? Уйлый беләме, уйларга сәләтлеме ул? Әллә гел уй белән генә яшимe? Йөрәге тоямы мәхәббәтне? Тойса, уйламый буламы соң!

«...Кешеләр, сугыш, диләр. Авылдан ир-егетләр китеп бетте. Беркайчан да берьюлы болай күпләп китмиләр һәм китүчеләр озак йөрмиләр, тиз кайталар иде. Хәзер авылда егетләрдән бер мин калдым. Башка кеше булмаганга күрә генә миңа елышасыңмы син, елтыр күзле кыз? Мин мескен түгел! Ә шулай да син — минем иң якын кешем! Син хәзер минем кочагымнан чыгып китсәң, миннән дә көчсез кеше булмас. Аннары — мин бөтенләйгә ялгыз. Мин сиңа бу атсыз арбаны йөртергә булыша алырмынмы соң? Син белгәнне нигә мин белмәскә тиеш? Күрерсең менә, өйрәнермен! Йә, кара әле, син алдамыйсыңмы мине?!»

Ләбиб, Мәйсәрәнең җилкәсенә салган кулын кымшатмыйча, икенче кулы белән кызның йөзен үзенә борды. Мәйсәрәнең карашында курку да, ышану-өмет тә бар иде. Егет аның башын күкрәгенә кысты. Кыз карага буялган кулы белән Ләбибнең яңагын сыйпады...

— Кырын син, Ләбиб, чибәр булып йөр. Синдәй егеткә болай ярамый. Менә монда нәзек кенә мыек калдырырсың, сиңа мыек бик тә килешер...

Яңгыр һаман туктамый. Алар инде чыланып бетте.

— Ләбиб, әйдә, кайтабыз! — Мәйсәрә авылга изәп күрсәтте.— Бүген барыбер сукаларлык булмый. Тик син кулыңны җилкәмнән алма, яме...

Басу юлын иңләп кожан бөркәнгән икәү бара.

Их, нигә соң кожан бөркәнергә?!

Алар җитәкләштеләр. Яңгырга чылану үзе рәхәт бит! Яусын, тагын да көчәебрәк яусын!

## 2

Киң урам чирәмендә яңгыр сулары күлләвекләр булып җыелып тора. Әнисә ялантәпиләре белән шуларның берсеннән икенчесенә йөгереп уйный. Инде өсте чыланып беткән, әмма, алсу тасма белән үргән кыска толымнарын биетеп, һаман чәчрәтә бирә. Аннары бу уен туйдырды, капка сукмагын аркылы кискән ерганак янына килде, чыбык белән андагы чүп-чарны чистартты. Ишегалдыннан такта кисәге алып чыкты, аны ерганак өстенә басма итеп салды.

— Басма, басма! — дип сөенеп кычкырды Әнисә.— Мин басма салдым!

Ул нәни басмасы өстеннән әле бер якка, әле икенче якка чыгып йөрде. Әтисе кайтып килә иде, аны күргәч, каршысына йөгерде, ашыктырып басма янына алып килде, аңа басмадан атларга кушты. Ләбиб тактага басмыйча гына атлаган иде, моңа риза булмады, кире борды.

И-и син, әти кеше, үзең дәү инде, үзеңне бөтен нәрсәне белә, диләр, колхозның электр станциясен эшләтә, йортларга якты бирә, дип мактыйлар, ә үзең басманың нигә кирәген дә белмисең икән. Менә кызың өйрәтсен әле...

— Менә монда бас, әти!

Ләбиб аптырап калды. Чынлап торып басса, такта чыдатмаячак иде. Ул мыегын сыпырды — карале, четерекле эш кушасың бит син, кызым! Аннары такта астына кирпеч кыстырды һәм кызына инеш ягына изәп күрсәтте — әнә андагы басма астына да таш өйгәннәр бит...

Алар басмадан әрле-бирле йөреп уйнадылар. Әнисә шатлана иде — өйрәтте бит әтисен! Аннары кыз әтисен күлләвеккә алып керде. Ләбиб карышмады — әйдә соң...

Капкадан Мәйсәрә чыкты. Иренә һәм кызына бармак янады.

— Берсенә бала булып акыл кермәгән, икенчесенә картаеп та керәсе юк. Ах, кая әле мин сезне...— Мәйсәрә Әнисәне куган булды, кызы, әтисе артында бөтерелеп, тоттырмады. Ул

үзе дә суга чыланды. Нигә гаиләдән Мәйсәрә генә калсын икән инде — булгач-булгач, барысы да бергә!

Ләбиб кызын кулына алды. Әнисә аңарга бүгенге шатлыгын аңлатырга кереште. Ул имән бармагын күтәрде дә кире бөкте.

— Менә бер бетте,— диде ул әтисенә һәм имән бармагы белән урта бармагын бергә күтәрде.— Бүген мин икенче класска күчтем! Белдеңме?..

Әтисе башы белән ымлады, кызын йомшак кына итеп күкрәгенә кысты.

## 3

Мәйсәрә мамык шәлен иңнәренә салган килеш кенә урамга чыкты, озын үр ягына карады. Ләбиб кайтса, моторлы чананың уты үр түбәсеннән күренергә тиеш инде. Ә аннан авылга таба әче җил генә шуып төшә, Ләбиб һаман юк, нигәдер соңлады.

Ходаем, исән-сау гына котылса ярый ла Әнисә, дип хафаланды Мәйсәрә. Беренче баласы бит, авыр булыр инде. Бала сиңа кайчан туасын сәгате-минуты белән әйтеп киләме тагын, әле табарга өлгермәгәндер, ә Ләбиб көтәргә уйлагандыр, дип күңелен тынычландырды ул. Кияүләре Фатих Әнисәнең больницада икәнен хәбәр иткәч, Мәйсәрә Ләбибкә шуны аңлаткан иде. Аннары Ләбибне тыеп торып буламы — моторлы чанасына утырып, кичкә каршы район үзәгенә китеп барды.

Үзенә бер-бер хәл булмадымы икән Ләбибнең? Имин генә йөрсә ярый инде. Чанасы белән ерак юлга беренче чыгуы бит әле. Тәки үзе ясады моторлы чанасын, белмәгәне-кыландырмаганы юк, шайтан арбасы да ясар, бер күреп кенә калсын шуны. Мотор гөрелтесен йөрәге белән тоядыр ул. Тел дә бирсә соң аңа!..

Өйгә әйләнеп кергәч тә, Мәйсәрә үткән елларны исенә төшерде, ара-тирә үзалдына сөйләнгәләп тә алды.

...Чын-чынлап әби-бабай булабыз, уза гомер. Теге чакта трактор туктагач, Ләбибкә, ичмасам, син дә белмисең шушы тракторны, үзең, яратам, дисең әле тагын, дигән идем, әй. Бераз үпкәләп тә әйттем бугай. Шуны аңлады инде, күрәсең. Әллә аз гына вакытка тавышы ачылып алдымы — хәзергәчә үзем дә төшенмим. Ишетүен ишетә ул бераз. Яратам дип йөрисең, дигәнен авыл кешеләре, Ләбиб Мәйсәрәгә гашыйк, дип сөйләгәнгә генә әйткән идем. Хак булган икән. Үзем дә яраттым. Мәхәббәт бит ул...

Мәйсәрә, көтә-көтә арып, черемләп киткән иде, иренең кайтуын сизмичә калды. Ләкин ул, Ләбиб тирәсендәге суык болыты таралгач ук, барысын да төшенде. Атылып ишек төбенә килде, калтыранган куллары белән Ләбибнең шатлыктанмы, сал-

кыннанмы кызарган яңакларын кысты, эчкерсез яктылык сирпегән ягымлы күзләренә мөлдерәп карады.

Ләбиб башы-аягы белән салкынга уралып килеп керде дә, кулларын бутый-бутый, Мәйсәрәгә аңлатырга кереште. Әнисәнең кыска буйлы булуына гадәтенчә ишарә ясады, аннары башындагы бүрегенә сугып куйды. Аңлата алмадым, дигән шикелле, мыегын сыпырды.

— Малаймы?!

— Ы-ы!

Ләбиб, барысын да шулай берьюлы аңлата алуына сөенеп, тагын бүрегенә сукты, мыегын рәттән берничә мәртәбә сыпырды: малай туды, малай... онычыбыз туды.

*1975*

# Йолдызлардан ары — йолдызлар

Авылда кичке уен ике төштә була. Берсе елга буенда, монысына буй җиткән егетләр-кызлар йөри, икенчесе мәктәп бакчасында. Анысы — үсмерләр уены, ул иртәрәк оешып, иртәрәк тарала, анда югары класс укучылары гына катнаша. Үсмерләр уенының тарихы бәләкәй, ул сугыштан соңгы еллардан гына башланды. Бу чорда, сугыштан кайткан егетләр гаилә корып җибәргәч, кичке уеннарда егетлек вазифасы тугызынчы-унынчы класс укучыларына төште. Һәм тора-бара үсмерләр, зурраклардан аерылып, үз уеннарын оештырдылар.

Менә шушы үсмерләр уенына узган яз, әле тугызынчыда укыганда, Кәрим Баязиты да керде һәм хәтта уенны тотучыларның берсе булып китте. Баязит килмичә уенны башламыйча торалар, чөнки аңардан башка күңелсез. Ә Баязитка өйгән дә биргән табигать — төрле такмаклар, уен җырлары уйлап чыгарырга аңарга куш, ул сөйләгәндә көлә-көлә яңаклар авыртып бетә.

Бүген Баязит уенга пардан соргылт күлмәк кигән ике кыз арасында килде. Кунакларны мәктәп кызлары белән таныштыргач, яшьтәш егетләре янына ашыкты.

— Медицина училищесында укыйлар, Казанда,— диде ул һәм, кесәсеннән кулъяулык алып, маңгаен сөртте.— Күп тә беләләр соң! Алар белән сөйләшкәндә хур булмас өчен, бөтен белем сандыгымны актардым, җир казыганнан болайрак тирләдем.

— Кемнәргә кайтканнар?

Баязит тиз генә җавап бирмәде, чөнки үзен эре тотарга сәбәбе бар: шәһәр кызлары белән беренче ул танышкан, башкалар белән аралашырга теләрме икән медичка кызлар, бу кадәресе әле сезнең осталыкка-булганлыкка бәйле.

— Безнең больницада практика узачаклар. Урамда очраттым да уенга чакырдым.

— Ә исемнәре ничек?

— Һе, алма пеш — авызыма төш! Мин үземә кирәген белдем: аларның әле өченчесе дә бар икән, Галия исемлесе. Сез инде бу икесенең исемнәрен белергә теләсәгез, авыруга сабышыгыз да больницага кереп ятыгыз. Тик Галия тирәсендә берәрегезне бер күрсәм, үпкәләмәгез!

— Әллә гашыйк булдыңмы?

— Анысы — минем эш!

— Синең аны күргәнең дә юк ич әле.

— Күрмәсә ни! Миңа аның турында сөйләделәр инде!..

Бер дә күрмәгән кызга әллә чыннан да күңеле кузгалды инде Кәрим Баязитының, икенче көнне дәрескә тынып-уйчанланып килде ул. Ни яраткан фәне астрономиядән дә җавабы галәм серләре кебек буталчык булды. Соңгы дәрес бетеп, укытучы чыгып киткәч:

— Тыңлыйсызмы, бер әкият сөйлим! — дип туктатты Баязит классташларын.

— Нинди әкият? — дип сорады Нәкыя. Бу кызның чытлыклану гадәте бар, Баязитның коридорда башына киеп йөргәнен күрсә, бүрегенме, кепкасынмы бәрә дә төшерә, колагын борып алырга да өлгерә. Аннары читкә йөгереп китә дә күзләрен елтыратып Баязитка карый: йә инде, чыраеңны сытма, мин бит сине үз күреп кенә...

— Кыз белән егет турында...

— Алайса тыңлыйбыз!

— Алайса сөйлим!

Баязит кара такта янына чыгып басты, аскы иренен бер бөреп, бер тешләп торды, тәрәзәгә күтәрелеп карады, карашы башта пыялага терәлеп калды, аннары гына язгы ялан кырларны, еракта гы күксел-яшькелт урманны күрде һәм аның зәңгәрсу күзләре очкын чәчә башлады, ул әкият дөньясына чумды.

— Борын-борын заманда, кешеләр гөл үстерә белмәгәндә үк була бу хәл.

Бер кызның сөйгән егете албасты-пәриләргә каршы көрәшкә китә. Кыз аның дию-пәриләрне җиңеп кайтуын көтә, баһадирына бүләк итәргә көн саен болыннан кочагын тутырып чәчәкләр җыя. Ә егет кайтмый да кайтмый, явыз көчләрне кырып бетермәгән әле ул.

Җәйләр үтеп, көз якынлашкач, кызның җыйган чәчәкләре сула башлый. Кыз куркуга кала: егет кышын кайтса, аңарга бүләккә болында чәчәкләр табылмаячак бит. Шуннан кыз хәйләгә керешмәкче, күп итеп чәчәкләр җыя да аларны егете кайтуына сакламакчы була. Иртәгесен бөтен җирне кар каплый, өйдәге чәчәкләр дә шиңә. Кыз аларны сулы савытка утырта.

Чәчәкләргә шунда ук җан керә, яфраклары күтәрелеп, таҗлары ачыла. Инде чәчәкләр тамыр җибәргәч, кыз аларны туфраклы савытларга күчерә, су сибеп тора. Тәрәзә төпләрендәге чәчәкләр шиңми хәзер, гүя алар үзләре үк кызның сөйгән егетенә бүләк булырга телиләр. Бер иртәдән кыз чәчәкләрнең тәрәзәләргә бизәк булып сыкыланып төшүләрен күреп исе китә. Савытларда корыган сабаклары гына калган чәчәкләрнең, ә яфраклары тәрәзә өлгеләренә күчкән! Нәкъ тере чәчәкләр! Салкын рәнҗетә башлагач, тәрәзәләргә күчкәннәр икән чәчәкләр — аларның үзләренең дә кыздан егеткә бүләк буласылары килгән. Кышын тәрәзә пыялаларындагы сыкы бизәкләре шуннан калган, диләр. Якын кешеңә гөл үстерүне явыз көчләрне җиңгән батыр егетен чәчәкләр белән каршылаучы мәрхәмәтле кыз башлаган икән...

— Үзең уйлап чыгардыңмы бу әкиятне?

— Әллә ошамадымы?

— Ярыйсы. Тагын чыгар әкиятләреңне,— диделәр кызлар таралышканда, Нәкыя иң соңыннан кузгалды.

— Кәрим Баязиты, уйлап та чыгарасың инде кайчак тузга язмаганны! — диде ул, аннары озак уйланып торды.— Беләсеңме нәрсә, мин теге кыз булсаммы, егетемнең урап-йөреп кайтуларын көтеп саргаеп үләр идем. Шуңа күрә егетемне дә, иремне дә янымнан адым да читкә җибәрмәс идем...

— Ир белән хатын турында сүз бармый ла монда.

— Аңлыйм мин сине, Кәрим Баязиты, мине беркатлыга санама! Тик менә кем генә булырсың да, ничек кенә яшәрсең икән син бу хыялый башың белән... Галиягә атап чыгаргансыңдыр инде бу әкиятеңне...

— Әйе шул. Бүген без Галия белән Ерак урманга барабыз.

— Барасыз!..

— Барабыз шул! Мин аңа үзебезнең басуларны, Мишәне, болынны күрсәтәм.

— Хыялый баш! Галияне күргәнең дә юк бит әле! Танымыйсың да аны.

— Танымас!

— Алайса, мин моннан соң синең колагыңны сыйпап та карамыйм. Шуны бел, Кәрим Баязиты!

Нәкыя ишекне каты итеп, ашыгып япты, кулындагы алсу капрон косынкасының почмагы кысылып калды, әмма ул аны ишекне ачмыйча гына суырып тартып алды.

...И-и холык та инде бу Нәкыядә! Нигә үпкәләде инде, йә, Баязит Галиягә гашыйк икән — моннан кемгә ни зыян? Әй, бер караганда, күз яшен кызганмыйча елаучы, икенче караганда, шаркылдап көлүче Нәкыянең үпкәләве озакка барырмы соң?! Әллә Баязитның колагымны борчы, дип ялынуын көтәргәме исәбе? Бормасаң, колак авыртмас, шул гына.

Галияне танымыйсың, ди. Ничек кенә таный әле! Өндә күрмәгән белән генә эш бетми, ничәмә-ничә тапкыр төшендә күрде инде ул аны. Сурәтләп күрсәтергәме? Галия Баязиттан кыскарак, Баязит хәзер метр да алтмыш. Галия аның иягеннән генә, юк, түгел, җилкәсеннән. Галия коңгырт чәч толымнары очына ак тасмадан күбәләкләр таккан. Юк, түгел, чем-кара чәчләрен арттан тип-тигез итеп кистергән дә, шуңа күрә йөргән чакта аның чәчләре җилпенеп баралар. Ә күзләре җете коңгырт. Куллары шундый йомшак — Галия бармак очлары белән генә кагылса да, Баязитка рәхәт булып китә. Алай гынамы соң! Быел февральдә грипп эләктергәч, нинди генә дарулар эчсә дә, файдасы тимәде, ә менә бер кыз килеп маңгаена шифалы кулын куйгач, сихәтләнде дә китте Баязит. Галия булган икән бит ул кыз. Әйе, Галиянең кулы йомшак та, шифалы да...

Бервакыт алар, җитәкләшеп йөри-йөри, күл янына барып чыктылар. Циркуль белән сызып ясаган шикелле түп-түгәрәк иде күл. Аның кырыйлары талларга төренгән. Инде буйга үсеп, ян ботаклары су өстенә иелгәннәре дә бар аларның, быел гына чүмәлә-чүмәлә күтәрелгәннәре дә күп. Күл ярының бер урынында гына ике кеше басып торырлык ара калган. Алар шуннан түгәрәк күлгә озак кына карап тордылар. Шулчак Баязит:

— Галия, мин бу күлнең аръягына уйламыйча да йөзеп чыга алам! — диде һәм, Галия сүз әйтергә өлгергәнче, суга сикерде.

Тәнгә рәхәт икән күлнең суы, кемдер сине кулына күтәреп кенә барган кебек. Аргы якта ял да итеп тормыйча, кире борылды Баязит.

— Галия, әйдә, син дә коен! Шундый рәхәт күлдә!

Бөтен табигать тынып торган иде, давыл кубасына булган икән. Давыл кинәт көчәйде, ул, дәү агачларны бөгеп, күл өстенә капларга тели, ә агачлар карышалар, башларын селки-селки артка каерылалар. Су өсте тип-тигез, давыл аңа нигәдер кагылмый, тик күл шомлы. Каршы якка йөзгәндә, күл Баязитны күтәреп торган кебек иде, хәзер исә суы куерды, тәнгә сылана, Баязитны аска сөйри.

Галия суга керергә җыена. Баязитның хәле беткәнен күрә бугай.

— Кермә суга, Галия! Мин үзем...

Ай-һай, үзенең генә хәле җитәр идеме икән, Галия көчле куллары белән тартып чыгармаса...

Ерак урманга барганда, Галиягә шушы турыда сөйләргәме икән әллә? Хәер, кирәкми, Галия белә бит аны. Бәлки, Мишәдән үзе тоткан чәнечкесез алабуга турында сөйләргәдер? Монысы инде чып-чын булган хәл.

...*М*ишә буенда йөргәндә, усал карашлы, таныш түгел бер абый суга кармакларын салды да аңа:

— Чиртсә, алырсың, ычкындырма, кара аны, мин башка кармакларны карап киләм,— диде.

Баязит яр читенә мыштым гына барып чүгәләде.

Һәм менә балык чиртте. Ычкынмаса гына ярар иде, дип, Баязит аны ипләп кенә сөйри башлады. Әмма, каушавыннандыр инде, кинәт тартып җибәрде, кармак җиңеләйде, иртәнге кояшта алабуганың җемелдәгәне генә күренеп калды. Балык ни суга төшмәде, ни комлы ярда да күренми. Кая китте ул? Теге усал карашлы абыйга ничек аңлатырга хәзер?

Алабуга юк. Усал карашлы абый балыкны ычкындырганы өчен аны суга томырса?..

Урыныннан кузгалырга да курыкты Баязит.

Теге абый килеп җиткәч, Баязит, еларга җитешеп, булган хәлне сөйләп бирде.

— Их, син, пешмәгән бәрәңге!..— дип ачуланып ташлады ул.

Усал карашлы абый якынлашкач, Баязит кузгала төште. Һәм шулчак алабуга аның алдыннан комга сикерде. Балык югалмаган икән бит! Теге абыйның усал карашы куркытып куюдандыр, алабуганың алдына төшүен күрмәгән-сизмәгән генә икән малай.

Баязит шатлыгыннан балык өстенә капланды, аны калтыранган куллары белән тотып алып, таныш түгел абыйга бирде. Абый, бер сүз дә дәшмичә, балыкны җилкәсе аша аскан юеш киндер капчыгына салды.

Котылды болай булгач, усал карашлы абый суга атмаячак Баязитны!

Кинәт алабуганы бик кызганды малай. Ничек була соң әле бу: мин котылам, ул тотыламы? Нигә тоттым мин аны? Алдымда күпме ятса да, сыртындагы чәнечкеләре нигә ботыма кадалмады икән? Алданрак сизсәм, теге абый әйләнеп килгәнче, суга җибәргән булыр идем үзен.

Алабуганың чәнечкеләре юк иде. Ә менә теге абыйның чәнечкеле карашы хәзер дә хәтерендә Баязитның...

Галия тыңлармы икән соң бу хикәятне? Кирәге бармы аңа Баязитның усал абый белән очрашуы? Ә нигә сөйләмәскә? Бу дөньяда комсыз һәм үтергеч карашлы кешеләр дә булуын белсен Галия. Югыйсә Галия һәркемне үзе кебек дип уйлыйдыр, теге балыкчы абыйныкы кебек карашны беркайчан да очратмагандыр. Галия бит ул бик тә беркатлы, кешеләрнең әйткән сүзләренә генә түгел, әйтәсе сүзләренә дә алдан ук ышана...

Анысы шулай да, бүген Ерак урманга барганда, Галиягә нәрсә турында сөйләргә икән әле менә? Аждаһаларны җиңгән егетенә атап чәчәк үстерүче кыз турында сөйләсәң инде. Монысы

да батмый, яратам, дип турыдан-туры ярып салу булачак. Галиянең чаялыгы да җитәрлек, көләр үзеңнән. Иң яхшысы — галәм турында кызыклы һәм хикмәтле нәрсә сөйләү. Уйлап чыгарып булса да. Баязит астрономияне шәп белә, анда инде ул югалып калмаячак. Хыялны җигеп күккә сәяхәт итүдә дә Кәрим Баязитына тиңнәр бармы икән тагын авылда?

...Менә алар, тургайлар җырын тыңлый-тыңлый, Ерак урманга баралар. Югары юлдан әйләнеп, Мишә болынына кайталар. Инде караңгы төшкән, күктә җете һәм көләч йолдызлар калыккан.

— Галия, йолдызлар артында нәрсәләр барлыгын беләсеңме? — дип башлый шул чакта Баязит.

— Белмим, Баязит, син әйтсәң, мин моны онытмам,— ди Галия.

Әлбәттә, ул моны белә, Баязитның сөйләвен тыңлыйсы килгәнгә күрә шулай дип җавап кайтара, сизгер күңелле бит ул Галия.

— Йолдызлар артында — йолдызлар.

— Аннары?

— Тагын йолдызлар.

— Аннары?

— Тагын йолдызлар!

— Аннары, аннары?

— Тагын, тагын йолдызлар!

— Аннары...

Сүз шунда җиткәч, Галия сиздермичә генә Баязитка елыша һәм Баязит, кинәт бөтен дөньясын онытып:

— Аннары... аннары мин сине яратам, Галия...— ди.

— Аннары?

— Тагын яратам!

— Аннары, аннары?

— Тагын, тагын яратам...

Табылды бит җае — күрче, ничек җиңел икән мәхәббәтне аңлатуы!..

Баязит быел унынчыны тәмамлый. Галия, практикадан соң, ахыргы курска укырга китә, эшкә монда кайта. Әүвәл Баязит институтка керә, аннары Галия. Аерым торган чаклары да булыр инде, тик Галия Баязитны гел, әкияттәге кыз кебек, йомшак кулларына чәчәкләр күтәреп, җылы күз карашы белән каршылар...

Баязит Ерак урманга бара. Бүгенгә ялгызы гына.

*1977*

# Ак таң

Биек йортлар араларыннан бакчага сыек яктылык төшә, таң яктысы. Караңгылык акрынлап кына сыза, яктылык исә бөркелергә ашыкмый. Төн көнгә изге сәгатьтә, дип теләгән тели, көн исә төнгә рәхмәтен әйтеп елмая. Төннең китү, көннең килү вакыты бу — ак таң.

Бакча уртасында түгәрәк чәчәклек, аның әйләнәсендә эскәмияләр тезелгән. Мәрьям таң ягына караган эскәмиядә, уңга бераз янтаеп, терәлгечкә таянып утыра. Күперенке чәчләре, беретына сыешмыйча, чигәсенә куйган кул аркасын каплый. Ак таңны сокланып-онытылып күзәтә Мәрьям. Ә таң уйларны аңа ташый да ташый, олаулап-олаулап ташый.

Борылыштан трамвай атылып чыкты һәм тукталышта ишекләрен ачып кына япты да, тиздән шәһәрнең бу почмагында да ыгы-зыгы кубасын хәбәр итеп, буш килеш шылтырап чапты. Ул ераклашкан саен, бакчага тынлык кайта барды. Тик бераздан урам ташларына чалт-чолт баскан аяк тавышлары таң тынлыгын тагын урталайга бүлделәр дә Мәрьямнең уйларын куаладылар. Олы гәүдәле бер хатын, кулларын баһадир ирләрчә салмак селтәп, бакчаның кыйгач сукмагыннан Мәрьямгә таба килә иде.

Мәрьям бүген сугышта йөргән киемнәреннән иде. Теге хатынның үзенә турылавын күргәч, ул гимнастерка-юбкасын сыпыргалады, күн итекләренең кунычларын балтырларына сыландырырга тырышып сыйпады, тик куничлар сыланмады. Балтырлар куырыла төшкән икән шул, солдат булып йөргәннән бирле шактый вакыт узган инде. Мәрьям киемнәрен рәтләгән арада, теге хатын, аның янына килеп җитеп:

— Исәнме, апа! — дип яңгыратып сәламен бирде һәм: — Халисә мин, Халисә,— дип, үзе белән таныштырып та куйды.

— Әйдүк, түрдән уз,— дип шаяртты Мәрьям.— Ташларны сытып аякларың талгандыр, ял ит, утыр...

— Әй, баскан җирдән ут чыгарабыз инде анысы, апакаем! — дип, сүзгә дерт кабынды Халисә.— Утырам, утырмыйммы соң! Кайчаннан бирле бер кеше дә узмады лабаса шушы зуп-зур урамнан! Төн буе тәрәзәдән чекерәеп карап утырдым, унике тулгач нигә бер адәм узсын ла! Шәһәр, дип мактыйсыз, кешесе булмагач, нәрсә дип мактарга инде аны? Авылда, ичмасам, төнге урамда егетләр кыз озата. Сине күргән сөенечтән урам шаулатуым инде болай.— Халисә сүзләрен туктаусыз тезә бирде. Бер фикеренең икенчесенә тоташмавын уйламый да, сөйләшергә тансыклавын басарга тели иде ул. Бөтенләй таныш булмаган кеше белән дә тиз аралашып китү осталыгы бар аның.— Синең монда килеп утырганыңны күргәчме, апакаем, туктале, ди-

дем, бу бичаракай да минем кебек ялгызлыктан изаланадыр, чыгыйм янына да бергә-бергә күңеллерәк булыр үзебезгә, дидем. Чыннан да, шулай дидем!

Халисәнең самимилеген ошатты Мәрьям һәм, мин тыңларга риза, дигәндәй, аңа карап елмайды. Шушы нәни генә үз итү дә бәхет иде хәзергесенә Халисәгә. Шулай булмый ни, көрмәкләнгән телне язарга күндәм тыңлаучы табылды ич! Җилкәсенә салган пинжәген алдына алып, аның төймәсен бөтерә-бөтерә, тагын да иркенәебрәк сөйләргә кереште ул.

— Мин бит, апа... Сиңа кем дип дәшим соң әле мин?

— Мәрьям апа.

— Мәрьям апакаем, тынса да тынар икән бу шәһәр дигәнең! Безнең авылда, ичмасам, эт булса да өрә. Эт дигәннән, безнең гал-лә-мәт акыллы этебез бар. Сөйкемле, дип йөртәм мин аны үзем. Иртән фермага барыр вакытым җитсәме, өйалды ишеген тырный шул Сөйкемле. Соңлыйсың, дип искәртүе инде үзенчә. Мине озата бара да каядыр югалып тора, кайтыр чакта әллә каян гына каршыма атылып чыга аннары. Килгәнкилгән, сеңлемнәрдә кунып китәргә булган идем менә, геләнгелән эш ташларга да ярамый бит. Әйе, аннары шул инде... Сеңелләремне әйтәм, яттылар да йокыга киттеләр. Ә мин черем итә генә башлаган идем — Сөйкемле ишекне тырнарга тотынды гына бит! Әллә, Ходаем, минем арттан шәһәргә килгәнме дип, ишекне ачып та карадым. Юк инде, мине монда ничек таба алсын ди ул! Ишекне тырнавы ап-аермачык ишетелә колагыма. Билләһи дә хак менә! Мине эзләп адашып йөрсә, ни хәл итәрсең...

Халисә Мәрьямгә иелә төште һәм:

— Аннарымы, апам, Мәрьям апакаем, аннары...— дип пышылдап кына сүзне икенчегә борды,— казларымның кычкырып-кычкырып каңгылдашканнарын ишетәм.

— Бу вакытта казлар шулай каңгылдыймы соң? Алар көзен...

— Каңгылдыйлар икән шул менә! Каңгылдашмасалар, ишетмәс идем лә. Ап-аермачык инде, үземнең казлар. Колакка үткер мин, минем казлар инде, чынлап торып минекеләр, үз казларымның тавышын аермаска ди мин теге! — Халисә башына килгән уйдан кинәт җилкенде, Мәрьямгә елышып ук дәвам итте.— Мәрьям апа, мин сине каз өмәсенә чакырам, кайтырсың әле, яме. И-и күңелле дә була бездә каз өмәләре! Казларым быел да ишле, ике ояга — егерме дүрт бәбкә. Үзем генә торам мин... И-и шулай инде... Сеңлем менә үсмер чактан ФЗӨгә китте дә шуннан шәһәрдә торып калды. Аңарчы... Ялгызым, гел дә ялгызым... Син борчылма, Мәрьям апа, сине әйбәт кунак итәрмен. Йорт-җирем яңа, мал-туарын, кош-кортын ишле асрыйм. Сеңелләремне авыл сыеннан беркайчан да өзгәнем юк.

Шөкер, өлгерәм, барысына да өлгерәм, каралты-курасын да төзек тотам, мал-туарын карарга да өлгерәм. Әле агач бакчам да бар. Сау-сәламәт кешегә ни авырлыгы бар соң боларның? Сәламәт, дип инде...— Халисә сузып куйган уң аягына күз төшереп алды.— Инде утыз елдан артты фермада эшләвемә. Элек сыер сауган идем, пенсия яшенә җиткәч, бозау карарга күчтем. Пенсиядә булсам да эшлим әле. Нигә эшләмәскә ди?! Көчем барында! Аякның бу кыяфәтенә күптән күнектем инде. Сугышта медсестра булып йөргән идем, белемем марля белән яра бәйләрлек кенә иде инде. Сугыштан соң яра күрә алмас булдым да фермага кердем. Олыгаябыз, Мәрьям апа, уза гомерләр, әле дә бәхетем инде — эшемне яратам. И-и, Мәрьям апакаем, нишли икән инде ул бозаулар миннән башка? Әйбәтләп ашатса гына ярый инде карый калган кыз. Син ул бозауларның акыллылыкларын белсәң икән! Акыллы сабыйлар инде менә, чып-чын сабыйлар. Берсе сыенып иркәләнә, икенчесе юк мөгезе белән сөзгән булып уйный, кайсы тоттырмас өчен тая-тая чабып киткән була...— Ул Мәрьямнең кулларын учына алды.— Әллә бүген үк кайтабызмы, Мәрьям апа, бергә үк! Күңелләрәк тә булыр, кунак-төшем үзе бер бәйрәм миңа.

Мәрьям бу ягымлы хатынны, эчкерсез беркатлылыгы өчен иркәләп, аркасыннан сөйде.

— Бик җәһәт икәнсең син, Халисә,— диде ул, кулын аның җилкәсендә тотты.— Алай ансат кына түгел бит әле сәфәр кылу. Мин дә эш кешесе, шушы бакчаны карыйм.

— Син ял ал, Мәрьям апа!

— Чәчәкләр утыртыр чак җитте, мәшәкать күбәя.

— Чәчәкләр минем бакчамда да күп. Ак чәчәкләр. Орлыкларын җыям да кешеләргә өләшәм. Хатлар язып та сорыйлар. Җибәрәм, җибәрми ни!

— Халисә...

— Әү, Мәрьям апа.

— Юк, минем Халисә исемле кешедән орлык алганым юк.

— Мәрьям апа... Юк, минем дә Мәрьям апага орлык җибәргәнем, үзеннән дә алганым юк. Һай Аллам, танышлар түгел икәнбез. И-и әйбәтләп танышырбыз әле алайса, боерган булса. Боерыр, боермый ни! Син дә чәчәкләр яратасың икән лә!

— Кешеләргә чәчәкләр дә кирәк, Халисә.

— Мин сине, Мәрьям апа, урманга алып менәр идем. Агачлар яфрак ярып бетергәндә, чәчәкләр күп була урманда. Безнең Саба ягы урманнарыннан да матур урман дөньясында юктыр, валлаһи гынам...

— Саба ягы?! — дип сискәнде Мәрьям.

Аның зәңгәрсу күзләре кысылды, иреннәре бөреште, бөтен тәне чымырдады. Әмма Халисә бу үзгәрешләрне күрергә өлгергәнче, Мәрьям элекке халәтенә кайтты.

— Әйе, Байлар Сабасы ягыннан без,— дип, күплеккә күчте Халисә, мактануын яшермәде.— Табигать бай яктан.

— Таныш як...— диде Мәрьям акрын гына һәм карашын ерак ноктага төбәде.

— Әллә син дә безнең яктанмы, Мәрьям апакаем? И-и, чынласаң, без белешләрдер дә әле.

— Юк, Халисә сеңлем.— Мәрьям хәтсез вакыт сүзсез торды. Халисә дә, аның авыр хатирәсенә кагылуын абайлап, беравык дәшмәде.— Тумышым шәһәрдә. Ә Саба ягында бер ел яшәгән идем. Сугышның беренче елында. Укыттым мин анда. Институт тәмамлагач җибәргәннәр иде. Ирем укытырга бара алмады, институт бетерүгә сугышка алдылар... Шуннан бирле сезнең якта булганым юк, дөресе, кунакка барганым юк. Кунак булып барырга да атлыкмадым. Кунакка еш чакырдылар үзе.— Халисәнең нәрсәдер әйтергә җыенуын күргәч, Мәрьям кул ишарәсе белән аны тыйды.— Түгел, сезнең якларны ошатмаудан түгел. Бүтән сәбәп...— Һәм Мәрьям тирән сулап: — Сәбәбе бүтән,— диде.

Алар, ак таң килүен күзәтергә дә онытып, сөйләшмичә утырдылар. Мәрьям уйлары белән сугышның беренче елына чигенеп кайтты, сөйләп сүзе бетмәячәк Халисә аның уйлары агышын өзәргә базмады. Ниһаять, түземе төкәндеме, әллә монда килгәндә үк күзенә чалынган орден-медальләр турында сорарга онытуы исенә төштеме — Мәрьямнең күкрәгенә иелеп шул бүләкләрне карады да:

— Сугышта булгансың икән син дә, орден-медальләрең дә күп икән,— диде. Аның тавышы баягы кебек яңгырамый, басынкыланган иде.— Мин үзем сугышта медальләр генә алдым. Гыйниятемнең дә менә мондый Кызыл Йолдыз ордены бар иде... Бар. Икәү. Медальләре дә бар. Үземнең дә орденнарым икәү булды инде. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән «Почет Билгесе» ордены. Хезмәтемне бәяләп бирделәр орденнарны. Их, Гыйниятем...— Халисә кесәсеннән кәгазь тартма чыгарды, яңа орденын кадады да пинжәген киде.— Шушы орденны алырга килгән идем шәһәргә. Олы йортка чакырып, зур җыелышта хөрмәтләп тапшырдылар.

— Котлыйм сине, Халисә, бәхет өстенә бәхет яусын сиңа!

— Изге теләгеңә рәхмәт, Мәрьям апа.— Һәм Халисә сүзен тагын капылт бүтәнгә борды.— Болай булгач, алып кайтам да алып кайтам мин сине авылыбызга! Сөйләшер сүзләребез күп булыр әле безнең. И-их, Гыйниятем... Ул да сугыш күргән кеше, күргән генәме соң?! Яраланып-имгәнеп беткән иде Гыйниятуллам. Кайтканда, коры җаны гына иде. Ул да сугышның беренче елыннан кайтты, минем шай. Син, сугышның бер елы узгач киттем, дисең. Беребез күрмәгәнне икенчебез күргән, туйганчы сөйләшербез әле...

— Сугышның бер елы узгач киттем,— дип хәтерләргә керешне Мәрьям.— Уку елы беткәч. Сугышка барырга туры килер дип, башыма да кертмәгән идем югыйсә. Авылда укыткан чагымда...— Мәрьямнең бер бушанып аласы килде, тик ул, нәрсәдән сөйли башларга белмичә, уйланып торды.— Төштән соң иде инде, мәктәптә дәресләр беткән иде. Капка төбенә...

Капка төбенә җигүле ат килеп туктады. Үрәчәле чанада артка карап бер кыз утыра, толып кигән. Ат тотучы малай алга карап тезләнгән, бишмәтен озын пута белән буган.

Нинди кешеләр икән алар? Мәрьям һәм аның йорт хуҗасы юлаучыларга каршы чыктылар.

— Чәйләп алырга мөмкинме сездә? Атыбыз да талчыкты,— диде кыз, урыныннан кузгалмыйча гына толыбын җилкәсеннән төшерде.

— Ниткән мөмкин булмасын ди?! Әйдәгез, әйдә! — Хуҗа хатын олы капканы ачты.— Сугыштан кайтасыңмыни, сеңелем? Киемнәрең сугышныкы. Әбәү-ү, култык таяклары нәрсәгә тагын? Җаным ла... Мәрьям, нигә терәлеп каттың, булыш ятьрәк!

Әмма хуҗа хатынның искәртүен ишетмәде дә Мәрьям, ул тораташ катып калган иде. Хуҗа хатын юлаучыга өйалды баскычына күтәрелергә ялгызы гына булышты.

— Әти-әниең кайтуыңа сөенерләр, яраңны күреп кайгырырлар инде,— дип, үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды ул.— Анага бик газиз шул сез, балалар. Үземнең олы улым да сугышта. Ай ярым хаты юк. Исәндерме инде. Әни, кайгырма, дип язган иде язуын. Мин исән-сәламәт кайтырмын, дигән иде. Берүк исән генә була күрсен. Исән булса, кайтыр берзаман. Борган булса.

Яралы кыз фронтта медсестра булган, аның аягы яраланган. Хәзер авылына кайтышы. Ә авылына юл шушыннан икән...

Мәрьям өйгә кергәндә, солдат кыз сәкегә утырып капчыгын чишә иде. Ул бер кечкенә төргәкне өстәлгә куйды. Аягына торып басты, бармакларын батырырдай итеп, тәрәзә яңагына тотынды. Мәрьям өстәлнең ишек каты башына килде, ул солдат кыздан күзләрен алмый, юлаучыларның нигә нәкъ менә аның фатирына тукталуының бер сәбәбе булыр дип уйлана.

— Мәрьям иптәш...— Солдат кыз, Мәрьямнең калтыравуын күреп, тукталып торды да, соңгы кыюлыгын-көчен җыеп: — Мәрьям...— дип кабатлады.

Дөнья кинәт тын калды.

— Мәрьям... Сәлим юк инде...

Мәрьямнең тәненә чеметтереп салкын йөгерде, шунда ук бөтен гәүдәсен эссе куырды.

— Сәли-имем!..— Мәрьям өстәлгә капланды.

Үзе китергән хәбәр солдат кызның да җилкәсен басты, ул чайкалып сәкегә ауды.

Хуҗа хатын бу кайгыга ышанып җитми иде.

— Сәлим үлгәнме?! Булмаганны! Әле былтыр гына, сугышка китәр алдыннан, Мәрьямне безнең авылга үзе китерде бит,— диде ул бәйләнешсез генә.— Гел дә сездә яшәрбез, менә мин фашистны дөмектереп кайтыйм да, дигән иде. Ялгышып әйтмисеңме соң син, сеңлем? Яраң башыңны чуалттымы әллә соң? Малаең булам, диде бит ул миңа. Сәлим үл... Сәлимме?..

— Госпитальдә. Атна элек кенә. Сигез ярасы бар иде шул. Мин, йөрер хәлгә җиткәч, каты яралыларга булыша идем. Якташы икәнлегемә сөенгән иде ул. Соңгы көнне үзе мине чакыртты. Менә шушы хатларны, башка язуларын алып кайтырга кушты, әманәтем, диде. Мәрьямнең үз кулына, өйгә үк кертеп бир, диде.— Солдат кыз өстәлдәге төргәккә сузылды.

— Сәлимем!.. Күңелем дөрес сизгән икән...

Мәрьямнең сулкылдап елавыннан, аның йөрәк әрнеткеч кайгы тавышыннан җир дер селкенә кебек иде...

Тәфсилләмәде Мәрьям, сугышта булуын, аннан соңгы тормышы турында җыйнап-тезеп кенә әйтте. Халисә аны торган саен сагаебрак тыңлады.

— Ирем үлгәнен белгәч, сугышка киттем. Өч ел булдым фронтта, сугыш беткәнче. Өч елга кулыма бер тапкыр да мылтык тотмадым. Кыр госпиталендә эшләдем. Кешене ярасыннан савыктыру иде минем хезмәтем. Сугыштан соң шәһәрдә укыттым. Хәзер инде пенсиядә, шушы бакчаны карыйм. Мин сугышта күргән иң коточкыч нәрсә — көйгән җирләр, корыган агачлар булды. Әле дә күз алдымда, шау чәчәктәге алмагачлар янына бомба төште дә агачны тамырыннан йолкып күккә чөйде, бичаракай алмагачның ап-ак чәчәкләре көеп беткән иде. Әле дә күз алдымда шул алмагач... Сугышта иң авыр яра газиз җиребез өстенә төште. Без тән ярабызны дәвалыйбыз әле, савыгабыз да кайчак. Җирне дәваларга, аны ярасыннан савыктырырга онытабыз, ай-яй тиз онытучан адәм баласы... Җирдә иген шауласын, чәчәкләр үссен, алмагачлары ак таңда ак чәчәк атсын...

Тын тордылар. Мәрьямнең хикәятеннән Халисәнең фикерләре чуалды, бу ак таңда очраткан апасына аның күп-күп сораулар бирәсе килде, тик нindидер көч ул сорауларны артка этәрде. Халисә дә, тормышы турында сөйләп, бушанмакчы булды.

— Ни бит, Мәрьям апа, ни... Мин үзем дә сугышны күргән хатын бит. Башыннан киткән идем, ел тулганда әйләнеп тә кайттым. Менә шушы аяк...— Халисә сузылып торган уң аягын тездән бөгеп тартып китерде.— Ни бит, Мәрьям апа... Аягым яралангач, күпме ара шуышканмындыр, һич кенә дә хәтерли алмыйм шуны. Бомба чокыры кырыена җиткәч кенә аңы-

ма килдем, шуңарчы берни абайламыйча-уйламыйча шуышканмын. Чокырның төбенә карап хәрәкәтсез ятам шулай, пуля сызгыруында да, бомба төшүендә дә гамем юк. Башыма бөтенләй дә тузга язмаган уй килде шул чакта: каз бәбкәсе чокыр читендәге үләнне өзәргә тырышып-тырышып тартыр да, үлән кинәт өзелеп киткәч, чокыр эченә тәгәрәр кебек, шул тирән яра-чокырдан чыга алмас кебек. И-и, авыл хатыны сугышта да каз бәбкәсе белән саташыр ла инде ул... Ни бит, Мәрьям апа, минем Гыйниятем дә сугыштан имгәнеп кайтты бит. Мин аны, ничек кенә дим соң инде... Үземә көчләп дигәндәй өйләндердем бит. Миннән нинди ир булсын, өйләнмим мин, Халисә, ди, синңа биргән вәгъдәмә тугры булсам да, өйләнә алмыйм, ди. Юк инде, Гыйниятулла, дидем, вәгъдәне үзем дә бозмыйм, синнән дә боздырмыйм, бик әйбәт ир-хуҗа булырсың әле, дидем. Йә мин сезгә күчәм, йә сине үзебезгә алып чыгам, дидем. Каршы әйтерлеген тәки дә калдырмадым. Күршеләр булып үстек без. Беләсеңме, Мәрьям апакай гынам, шинелен кидердем дә, җитәкләп-күтәреп дигәндәй, алдым да чыктым Гыйниятулламны үзебезгә! Әйбәт яшәдек. Колхозда шурник булып эшләде. Тик балаларыбыз гына булмады да сугыш яралары иртә алып китте үзен. Чәчәкләр ярата иде Гыйниятуллам, аның өчен дип чәчәк үстерә идем. Хәзер дә аның өчен үстерәм...

Бакчадан җил уйнаклап үтте. Мәрьям белән Халисә каршындагы алмагачның чәчәкләрен ачты шул җил. Алмагач, ак чәчәкләрен тибрәндереп, сугыш авырлыкларын инде күпме заманнар иңнәрендә күтәреп йөрүче, әмма дәһшәтле кырылыш китергән кайгы-хәсрәтләргә бирешмәүче шушы ике хатынны тыныч көн белән котлый иде.

— Бу алмагач безнең шәһәрдә беренче булып чәчәк ата, Халисә,— диде Мәрьям.— Инде менә бишенче яз шулай иртә бизәнә ул. Быел да сынатмады, Җиңү көненә чәчәкләрен ачты. Җирнең гамьле булу билгесе бу.

— Әй мәнсез дә инде мин! Җиңү бәйрәме белән котлыйм сине, Мәрьям апа! Син бүген Җиңү көне булганга күрә солдатча киенгәнсең икән ич!

— Мин дә сине котлыйм, Халисә!

Тагын тын тордылар.

— Мәрьям апа, синең исемең гел Мәрьям булдымы?

— Ничек инде — гелме? Гел Мәрьям инде мин.

— Алайса...

— Туктале, Халисә, моңарчы аңлаешлы сөйләдең, хәзер...

— Юк, син түгел! Аның да исеме Сәлим түгел иде! Түгел иде!

— Кемнең исеме? Кем Сәлим түгел?

— Мин дә бит бер укытучы апага ире үлүе турында сугыштан хәбәр алып кайткан идем...

— Синме?! Туктале, тукта, син чанада артка карап утыра идең, толып кигән идең. Уң аягың... Култык таякларың бар иде, әйеме?

— Кышын юл йөргәндә толып та чана инде.

— Безгә сез чәй эчәргә дип кердегез, әйеме?

— Белмим... Ышанмыйм әле сезгә керүебезгә, Мәрьям апа! Тик станциядән мине дә бишмәтен озын билбау белән буган малай алып кайтты.

— Син буласың ич инде, алайса, миңа Сәлимем турында хәбәр китергән кыз!

— Юк, Мәрьям апа, мин түгел.

— Ашыкма, Халисә сеңлем, дим, хәтерлә, зинһар: Сәлимем үләр алдыннан нәрсәләр диде?

Халисә эндәшмәде, Мәрьям аны беләкләреннән тотып җилтерәтте.

— Онытмагансыңдыр ич: минем исемемне әйтмәдеме, саташкан чакларындамы йә җаны өзелгәндә, балакай, дип, мине чакырмадымы?

— Юк, Мәрьям апа, Сәлим абый түгел минем кулымда үлгән кеше, аның исеме бүтән, мин аның исемен яхшы хәтерлим һәм беркайчан да онытмам. Тик үзем кайгы китергән укытучы апаны һаман эзләп таба алмыйм... Аның исеме Мәрьям түгел иде...

— Ә... ә... Халисә, синең исемең гел Халисәме соң?

— Халисә. Гел.

— Алайса, чыннан да, без бер-беребезне белешүчеләр түгел икән. Миңа Сәлимемнең әманәтен тапшырган кызның исеме Вәсилә иде. Мин аны һаман таба алмыйм. Теге чакта аның кайдан булуын сорарлык хәлдә идемме соң мин... Бәлки, ул сезнең район кызы да булмагандыр, Сәлимемнең әманәтен тапшыру өчен генә мине эзләп тапкандыр... Ел саен барам мин Саба якларына. Тик кунак булып түгел, Вәсиләне эзләп барам. Һаман да таба алмыйм. Бәлки, бөтенләйгә читкә киткәндер, кем белә. Бәлки... Һаман күз алдымда: өйалды ишеге тупсасына култык таякларын терәп үк куйды да, сул аягына бөгелә төшеп, беренче баскычка сикергәч, башы бәрелгән иде. Аның да, синеке кебек, уң аягы яралы иде. Ул да, синең кебек, озын буйлы иде... Мин түгел идем, дисең инде, Халисә?

— Түгел идем... Мин түгел идем! Охшаш кынадыр.

— Шулайдыр... Бу сугышта охшаш язмышлар санап бетергесез күп булды ич...

— Мин түгел идем. Түгел идем.

...Әллә соң, Халисә, Мәрьямнең Сәлиме синең кулыңда... Синең гаебең юк. Мәрьямгә Сәлимнең әманәтен тапшыручы, аңа кайгы хәбәре китерүче чыннан да син булсаң, әйт син мо-

ны, әйт. Әллә соң, Халисә, Мәрьямгә гомерлек кайгы ирештергәндә, йортның дер селкенүе синең Вәсилә булып керүеңнең серен һаман ачмаска кушамы? Шул гарасатның кабатлануы куркытамы сине? Курыкмыйсыңмы? Курыкмыйсың. Әллә соң, Халисә, җир яралары кеше ярасыннан тирәнрәк иде, Мәрьям апаң ирен яшьләй югалту кайгысын оныта төшкәндер, ярасы төзәлеп киләдер, дисеңме? Тән ярасы... Җир ярасы... Мәрьям апаңның бит йөрәк ярасы... Йөрәк ярасының беркайчан да төзәлмәячәген беләсең шул син. Нигә йөрәк ярасын яңартырга, дисеңме? Ә шулай да әйт, миңа гына әйт, син иденме, Мәрьямнең кайгысыннан гарасат котырганда сәкегә ауган солдат кыз син идеңме?..

— Юк! Мин түгел идем! Түгел! Түгел, түгел! Түгел...

Бакчада җил уйный.

Уйна, назлы җилкәй! Күпме газаплар кичергән ике хатынның җәрәхәтле җаннарын иркәлә! Алмагачларның чәчәкләрен ачтың ич әле, Мәрьям белән Халисәнең дә күңелләрен бәхет тутырып ач!

...Бакчада ак таң.

*1980*

# *Исәнме, Раушания!..*

Таралышыр алдыннан бөтен курс белән вәгъдә куешкан идек без: мөмкинлеге булган кешеләр ел саен июньнең соңгы көнендә университет каршында очрашабыз, ә егерме биш елдан соң очрашуга һәркем кайтырга тиеш, кичке сәгать бишкә, тик ирләрсез-хатыннарсыз (соңгы шарт яшьлеккә кайтып карау теләгеннәндер инде, күрәсең).

Һәм менә без очраштык, егерме биш елдан соң. Күрешү, моңсулану, сөенү, күзләр дымлану... Син танымасаң, үзләре сине таныйлар, ә гомумән, таныйбыз икән әле без бер-беребезне, оешкан курс идек шул без.

Кеше күп чакта үземне кысанлыкта сизгәнгә күрә, Кечкенә Фазылның (без аны шаяртып шулай дип йөрттек, ә чынлыкта ул колгасар) итәгенә тагылып өлгердем, биш ел буена барынюгын уртаклашкан дустым мин җебегәнне ярдәменнән ташламас, янәсе. Барыбыз да килдек кебек инде, тик Раушания генә күренми. Әллә ул бик үзгәргән дә мин аны танымыйммы? Раушания, әлбәттә, үзе килеп минем белән исәнләшмәячәк. Фазылдан соравы уңайсыз. Ул Раушанияне танырга тиеш, алар очрашалар булыр, чөнки икесе дә, уку бетергәч, Казанда калганнар иде.

Без университетның җиденче аудиториясенә (лекцияләрне курс белән шушында тыңлый идек) җыелдык. Әңгәмәбез башланырга гына торганда, ишек ачылды һәм — йа Ходай! — Раушания килеп керде. Шул ук Раушания — калын кара кашлары күз кырыена хәтле бөгелеп төшкән, күперенке чәчләре ачык йөзенә бүрек кигәндәй, карашы киң, барыбызны берьюлы күрәдер сыман ул. Гәүдәсе һаман да кызларча җыйнак. Ул, кызларны үбә-кочаклый, үз урынына — алтынчы рәтнең кырыена ук кереп утырды. Мин, Фазыл белән җиденче рәттә, аның артында. Миңа аркасы белән утырса да, мин аның исеменә туры килә торган нурлы йөзен аермачык күрәм кебек. Тик ул мине оныткандыр инде, хәер, биш ел бергә укысак та, белмәде дә бугай ул мине. Раушания бүтән группада иде, әллә шуңа күрә, әллә ул да минем кебек йомыкый булгангамы — мин аның белән биш ел буена бер тапкыр да сөйләшмәдем, хәтта нигәдер исәнләшми дә идек без.

Кинәт Раушания безгә борылды һәм миңа фамилиям белән эндәште:

— Син нигә минем белән исәнләшмисең?

Мин нәрсә дә булса әйтергә өлгергәнче, Фазыл:

— Исәнме, Раушания,— диде.

— Исәнме, Фазыл,— дип җавап кайтарды һәм Фазылның өстәл өстендәге кулына бармак очларын тидереп кенә күреште Раушания. Аннары миңа карады, безнең карашлар очрашты һәм — менә ничек бәхет өләшеп карый икән Раушаниянең күзләре — миңа: — Ә син нигә исәнләшмисең? — диде.

— Белмисеңмени, егерме биш ел инде аның телен йотканына.— Фазылның касыгына төртәсем, юк, шәпләп үк тондырасым килде.

Мин, укытучы сорау биргән бала кебек, урынымнан күтәрелә башладым, әмма Раушания ишарә белән миңа утырырга боерды. Битем төнге учак кебек кызарып яна, тик үзем генә пешәм, ә бу учакның кызуы Раушанияне көйдерми иде.

— И-и, йомыкый да соң син,— диде ул миңа, әле һаман да сүз әйтергә кыймавымны йомыкыйлыкка санады.— Мин бит сине, кешеләр белән тиз аралашып китүдән горурлыгы тыя, дип уйлый идем. Сиңа йөгән киертергә кирәк бугай ич, кай якка тартсаң да карышмый торган кеше, ахрысы, син.— Һәм Раушания тавышын йомшартып: — Исәнме...— дип, бу юлы миңа исемем белән эндәште.

Тормышта төрлесе була, яхшылап та сөйләшәсең, ачуланышасың да дигәндәй. Минем үземнең дә күпләрне әрләгәнем бар, мине дә гел аркадан сыйпап кына тормыйлар, әмма беркайчан да болай җебегәнем юк иде.

...Кемнәрнең хәзер кем булып эшләүләре белән таныштыру бара. Безнең группаның соңгы курстагы старостасы һәркем

турында исемлек буенча сөйләп төште, югыйсә атказанган кешеләребез дә бар, алар турында алдан әйтү дә яраган булыр иде. Бәлки, староста хаклыдыр да — без бит монда барыбыз да тигез. Әмма аның болай эшләвендә, бу тигезлекне тоюдан бигрәк, тәртип саклавы өстенлек итә иде, үзе турында да алфавит буенча әйтеп китте. Ул минем хакта сөйли башлады.

— Һөнәрен үзгәртүче безнең группада берәү генә,— диде ул (тәнкыйтьли идеме мине старостабыз әллә мактарга җыена идеме — аңлап җитмәдем).— Укуны бетерүгә комсомол эшендә булды, аннары чирәм җирләргә китеп барды, хәзер партия эшендә, райкомның беренче секретаре, безнең җитәкчебез, ягъни. Халыклар Дуслыгы ордены кавалеры.— (Монысын мин шаян тонда тутырылган анкетага язмаган идем, үзе каяндыр белгән, тәртипне һәрчак саклый, димәк, старостабыз.) Һәм: — Гаиләсендә үзен әйбәт тота, эчми, тартмый,— дип өстәде. Шаяртырга теләве идеме аның әллә партия работнигының төп сыйфатлары итеп шушыларны саный идеме ул — тагын аңламыйча калдым.

— Күрик әле, нинди була икән ул андый алтын бәясе кеше,— дип шаяртып кычкырды арткы рәттән кайсыдыр.— Торып бассын әле!

— Эчү-эчмәвен тикшереп карарбыз без аның бүген.— (Кесәдән сигарет чыгарып кабызасым килде.)

— Чаларткан егетне...

— Бирешми әле ул,— дип мактады мине Кечкенә Фазыл.

Әлбәттә, староста сүзләрен шаяртуга бору миңа ошады, бая Раушания карашыннан кызарган битләрем уттай янмый иде инде хәзер. Рәхмәт курсташларга — шаяртуны онытмаганнар, димәк, без һаман да студентлар. Элек күңелебез шат, кесәбез буш студентлар булсак, хәзер байлык белән шатлыкка берьюлы ия студентлар...

— Малайлар,— диде Раушания Фазыл белән миңа,— бергә кайтырбыз.

— Шәп малайлар! — дип көлде Фазыл яңгыравык тавышы белән.— Берсенең буйга җиткән ике кызы бар, икенчесенең малае иртәгә өйләнә! Син безгә инде картлачлар, диген.

Раушаниянең йөзеннән җәһәт кенә моңсулык йөгереп үтте, югыйсә ул беркайчан да моңсулана-сагышлана белмидер кебек иде миңа һәм менә бүген дә үзен шук-шат тота бит.

— Картлачлар...— диде ул сузып кына, берьялгызы тауны күтәреп күчергәндәге кебек авыр итеп, эчке киеренкелек белән әйтте Раушания бу сүзне.— Ә шулай да бүген мин сезнең яшьлегегезне күрәсем килә! — Һәм шатланып елмаюдан йөзе ачылып китте, күз төпләренә ияләнә башлаган сызыклар югалдылар.— Шунсыз мин дә бит яшьлегемә кайта алмыйм...— Аның сүзләрендә кабат тыелган, йөгәнләнгән сагыш тоелды.

«...Без Казан урамнары буйлап йөрибез. Өчәүләп. Төн ур-

тасы җитеп килә. Күп сөйләштек, биш ел буена бергә укып та бер-беребез турында белмәгәннәрне белештек. Күбрәк Раушания сөйләде, ул бүген канат куйгандай очына иде. Фазыл да әңгәмәдә еш катнаша, мин тыңлап кына барам. Шулай да миңа бүген рәхәт, чөнки тугры Фазыл һәм мин кайчандыр сәлам бирергә дә куркып йөргән Раушания белән бергә атлыйм.

— Ни өчен соң без синең белән бер дә очрашмадык әле? — диде Фазыл, Раушанияне чытлыкланып көлүеннән туктатты.— Бер шәһәрдә яшибез ләбаса. Юлларыбыз нигәдер кисешмәде.

— Мин аның кисешмәячәген белдем, Фазыл. Әллә нидә бер очратып булыр иде сине анысы. Ә аннары...— Раушания эндәшмичә торды.— Тагын озаклап көтәргәме...

— Очрашырга теләсәк, моннан соң очрашырбыз соң! Мә, менә минем визит карточкам.

Раушания карточканы кулына алып әйләндереп карады да кире бирде.

— Нигә алмыйсың? Кирәге чыкмас, дисеңме? — Фазыл Раушания белән тупасрак сөйләшә, тик Раушания үпкәләми, әгәр мин ялгышып кына каты сүз әйтсәм дә, ул безне ташлап ялгызы гына китеп барган булыр иде, төн уртасы дип тормас иде. Шуңа күрә мин сөйләшмичә баруны дөрескә саныйм, югыйсә Раушанияне кайчан күрәм әле — тагын егерме биш елдан соңмы?..

— Хәтерләдем телефон номерыңны.

— Караңгыдамы? Иреңнән куркасың инде.

— Күңел күзем белән күрдем, вәйт,— дип, телен шартлатып алды Раушания.— Ә иремнән нигә куркырга тиеш әле мин? Сез аны беләсез, ул сезне белә, бездән ике курска гына элгәре укыды ул.— Раушания, балалар үртәшеп уйнагандай, шаяртып өстәде: — Һе, менә бөтен курстан берегез дә игътибар итмәгән идегезме миңа, ә Салават игътибар итте! Сез бит һавадагы кошка үрелә идегез. Минем иремнең акыллы сүзе бар иде: студент чакта үзең белән бергә укучы кызның кимчелекләрен белеп торасың, шуңа күрә ул сиңа начар булып күренә һәм бүтән вуз кызлары белән танышасың, ә алар яхшы, чөнки син аларны дөнья һәм уку мәшәкатьләреннән азат вакытта күрәсең бит. Белдегезме инде?! Менә бу йомыкый да,— диде Раушания, миңа карап,— үзебезнең кызлар алдында мәңге буйдак булып калыр кебек кыланды, ә өйләнгән бит. Йомыкый...

Мин эндәшмәдем, нигә эндәшергә — мине мактау кебегрәк яңгырый ич Раушаниянең әрләве!

— Бирелләм! — диде Фазыл, бөтен урамны яңгыратып көлде.— Тагын бер тапкыр бирелләм! — Һәм ике кулын да югары күтәрде, үрелүе белән күк пәрдәсен ачып җибәргәндәй булды — таң яктысы беленә иде инде.— Шулай да миңа таярга вакыт, дуслар. Иртәгә туй бит, туй! Бердәнбер малаем өйләнә, әмма уңа килен ирдән, шәп егет минем малай, шәп!

Фазылның китәргә җыенуын күргәч, Раушания башын түбән иеп беравык торды да (моңа Фазыл игътибар итмәде, моны Раушаниядән күземне алмаучы мин генә сиздем) икебезне дә култыклап алды.

— Юк инде, Фазыл, озатып куябыз сине,— диде ул, безне кирегә борды.

— Җәяүләпме? Мин Соцгородта ук торам ич,— дип карышмакчы булды Фазыл.

— Казансу күперенә чаклы...

— Аннары менә бу йомыкый безгә кайта, без сине озатыйк башта.

Әмма Раушания Фазылның бу тәкъдимен дә кире какты.

— Бәбәй түгел, үзе генә дә кайта белер йомыкыең,— диде ул.— Җибәрмим әле мин аны, сиңа үч итеп. Гөрләшер идегез бугай төн буе, миннән качып...

Фазылны озаткач, Раушания күңелсезләнеп калды, тик бу озакка бармады, чәчләрен ике куллап артка сыпырды да кинәт дәртсенеп:

— Хәзер мин синең телеңне ачтырам, йомыкый! — диде.— Нигә сөйләшмисең син, чыннан да?

— Мин сине рәхәтләнеп тыңладым.

— Тыңладың! Иртәгә дә тыңларга гына җыенасыңмы? Ә иртәгә барасыңмы Гаталар бакчасына? Мин барам. Курс белән иртәгесен Гаталар дачасында — Идел буенда очрашырга сөйләшкән идек. Аннары утрауга чыгарга иде исәбебез.

— Бармыйча,— дидем мин.— Мин шушы очрашулар өчен ерак җирләрдән кайттым да инде.

— Ә син ерак җирләргә киттең дә югалдың. Берәү белән дә хәбәрләшмәдеңме?

— Фазыл белән язышабыз без.

— Фазыл — бәхетле кеше, бәхете җимерелә күрмәсен берүк.— Раушания җилкәсенә салган пинжәкне, шуып төшә башлагач, иңнәренә күтәребрәк куйды.— Фазылны күргәләдем бит мин бу егерме биш елда, тик эндәшеп туктатмадым, чөнки ул үзе мине күрми иде. Синең читтә икәнлегеңне дә белдем, кызлар әйтте, без кызлар белән очрашкалыйбыз.— Раушания кинәт алдыма төште.— Әйт әле, син минем турында ни дә булса беләсеңме?

Яшьлектәге мәхәббәтен сагына идеме Раушания яки мин, белмим, дип әйтсәм, яшьлеге турында сөйләп шул заманга кайтырга тели идеме,— сорауның мәгънәсенә төшенмәдем. Шулай да мин аңа дөресен әйтергә тиеш идем.

— Мин сине әйбәт белә идем, Раушания. Соңгы егерме биш елың турында бүген ишеттем.

— Белә идең...

— Белә идем... Син беренче курска өч көнгә соңлап килдең.

— Ялгышмыйсың.

— Син бүлдермә инде,— дидем мин кыюланып.— Лекция башланыр алдыннан гына кердең дә әнә шул алтынчы рәттәге урынга утырдың.

— Мин сайламадым, урын буш булгач утырдым, аннары инде күнектем.

— Шулай да бүлдермә син. Югыйсә минем сөйләү куәсенең күпмегә генә җитәсен чамалыйсыңдыр.

— Ә син бүленмә.

— Уку елы башлангач кына күченеп килдегез сез. Украина ягыннан. Әтиең хәрби кеше булган да отставкага чыккан. Университетны тәмамлап, таралышыр алдыннан мин синең урыныңа утырган идем дә, синең миңа турылап килүеңне күргәч, тиз генә артка шылдым. Нигә утырган идем икән мин синең урыныңа...

— Җитәр...

— Җитми! — дидем, тавышым көчәюен сизмичә дә калдым.— Рәттән тезеп сөйлимме сине биш ел буена кайларда күргәнемне?!

— Җитте! Кирәкми, йомыкый...— Раушания ике куллап беләгемне кысты.

Таңгы урамнарда сөйләшмичә йөрүе дә бәхет икән. Шәһәр үзәгенә җиттек.

— Фазыл мәхәббәт шигырьләре яза иде,— дип, тагын Фазылга әйләнеп кайтты Раушания.— Хәзер дә яза микән?

Мин аптырап калдым, чөнки Фазылның шигырь язуын хәтерләмим. Әмма ниндидер көч мине алдарга кушты.

— Хәзер дә яза. Тик ул китап чыгару өчен түгел, үзе өчен генә яза бит.

Дөрес иттем алдап, әгәр язмый, дисәм, Раушаниянең күңеле төшәр иде.

— Син менә беркайчан да шигырь яза алмагансыңдыр,— диде Раушания, минем булдыклылыгыма дөрес бәя бирде.— Син язсаң да нәсер язар идең. Чөнки синдә хыял җитми сыман иде, ә шигырь язарга бай фантазия кирәктер ул.

— Мине хыяллана белми дияргә телисең инде, әйеме?

— Көлдермә! — диде Раушания, башын кыйшайтты һәм йомшак кына көлде.

— Мин көлдерәмме?! Дөресен әйтимме алайса, чын дөресен? Бик беләсең килсә, мин сине беренче тапкыр күргәч үк урлап качтым!

— Мине? Син урлап качтыңмы?!

— Әйе, мин сине урлап качтым! Әтиең-әниең шушы йомыкый малайга кояш кебек кызыбызны бирмибез, дигәч, мин сине урлап качтым. Башта авыр булды безнең тормыш, бер апаның сандык кадәрле генә бүлмәсендә яшәдек, әмма без бәхетле идек, аш-суын бергә пешердек, керләрне дә бергә юдык. Хәтта син

мине кашыклап ашата идең, бер-беребезне күбрәк ашатырга тырыша идек. Шул бүлмәгә без дүртәүләп — малаебыз һәм кызыбыз тугач та — сыя идек. Бабай белән әби дә гафу иткәннәр иде мине, килеп йөриләр, үзләренең иркен фатирында бергәләп торырга чакыралар иде. Без ризалашмадык, тормышыбызны үзебез корабыз, дидек. Алар балаларны үзләренә алып китеп торалар иде. Без һәр фәнне бергәләп укыдык ич синең белән. Университетны бергәләп укыганга гына тәмамладык без. Һавада, биектә-биектә очсаң да, тоттым мин сине, Раушания! Аннары университетны тәмамлагач...

Нишлим мин, тиле? Нигә кирәк үзем генә белгән хыялый тормышны Раушаниягә сөйләү?

Раушания миңа аркасы белән баскан да йөзен куллары белән каплаган иде. Тын гына елый иде ул. Мин аңа таба үрелдем, әмма аны кочагыма алырга көчем җитмәде. Ул, пинжәкне җилкәсеннән алып, болайга карамыйча гына миңа сузды һәм, егылудан курыккандай сак кына атлап, биек йортлар ишегалдына кереп китте. Кузгалыр алдыннан нәрсәдер пышылдады Раушания. Ул, синең хыялый тормышыңны чынга әверелдереп булса икән, дигән кебек тоелды миңа. Әллә, мин дә сине яраттым, дип пышылдадымы ул? Әллә, чыннан да, шулай ук дидеме соң...

Мин ялгызым, япа-ялгызым.

Троллейбуска утырдым.

Соцгородта төштем.

Фазылларга кермәдем.

Нишләргә?

Әнә ич автобус! Кая барса да барыбер түгелме соң, әйләндереп алып кайтыр әле берзаман.

Автобус, шәһәр читенә җиткәч, борылып туктады.

— Соңгы тукталыш, тупик,— диде шофер һәм, бердәнбер пассажиры мине төшергәч, китеп тә барды.

Шәһәр чите. Ары юл юк, тупик ягъни. Үндарак дачалар күренә, анда бүтән юлдан йөриләр, күрәсең. Юк, бу Идел ягы түгел, бүген без җыелачак Гаталар дачасы бу якта түгел.

Ә Раушания килер микән бүген Гаталар дачасына? Фазыл бармаячак бит. Димәк...

Мин синнән ерагая барам, Раушания. Тукта, ни сөйлим мин? Ерагаймыйм. Чөнки син шушы шәһәрдә бит. Дөресрәге, ерагаймыйм да синнән, якынаймыйм да сиңа... Тупикта мин. Әгәр:

— Исәнме, Раушания!..— дип сәламемне бирсәм, ишетерсеңме икән? Шәт, ишетерсең, чөнки син якында, минем каршымда ук басып торасың кебек. Әллә:

— Хуш, Раушания...— дисәм, хушлашуым барып җитмәслек еракта мы син? — Ишетәсеңме син мине, Раушания, Раушанияу-у!

*1980*

# *Тау каршында — тулы ай*

*Сабакташларым Рафаэль*
*һәм Галиябану истәлегенә*

Кәли тавының түбәсеннән шуып китте Рафаэль. Чаңгылары әрем сабакларын керт-керт сындырды, таудан очып кына төшсә дә, йон бияләйләренә, яңа бишмәтенә әрсез тигәнәкләр ябышырга өлгерде. Кар каплаган инешне узып, каршы яр итәгендә туктагач, артка борылып, тауның биеклегенә һәм текәлегенә хәйран калып торды. Күрсәнә, кыядай таудан шуып төште ләбаса ул! Егылмыйча. Горурланырсың да шул, бүтән малайлар, моннан шуу турында уйлауга ук, баскан җирләрендә — табадай тигез төштә дә башлары әйләнеп егылалардыр әле.

Әйе, беренче эзне Рафаэль салды Кәли тавында. Хәзер әнә туры юл сузылган, шуарга теләгән малайлар шусыннар рәхәтләнеп. Курыкмасалар... Тик Кәли тавының түбәсенә басып аска карарга да шүрли алар.

Былтыр турыга эз салынмады. Рафаэль дә шикләнде, турыга шуарга талпынган саен, күзләре үзләреннән-үзләре йомыла һәм таудан кыйгачлап төшә иде ул. Быел бөтенләй дә курыкмады, тауның иң очына өсләтеп килде дә — әй-дә! Каршыдагы тәбәнәк таудан чана-чаңгы шуучы балаларның күзләре дә иярмичә калды хәтта. Алар, Рафаэльнең бу як яр итәгендә елмаеп басып торуына ышанмыйча, әле аңа, әле Кәли тавы түбәсенә карап шаккаттылар: ниндидер сихри көч иясе Рафаэльне, якасыннан гына чеметеп, тау түбәсеннән монда алып куйдымы соң әллә?!

Соклана бирсен бала-чага Рафаэльнең батырлыгына, ә ул, ярты үлемнән исән калганын да онытып, каршы ярга баскычлап менде дә авылның югары очына таба кыйгачлап шуды. Ике яктан да шулай алмаш-тилмәш шуып, Галиябанулар турына менеп җитте. Монда яр капка биеклегеннән дә тәбәнәк һәм төз түбәдәй сөзәк иде.

Малай, Кәли тавында ябышкан тигәнәкләрне чүпләгәч, бияләйләрен киртә казыгы башына куйды, аннары бишмәтен чистартты. Чаңгы бауларын кысып бәйләгәндә, абзар капкасының шыгырдавын ишетте. Ул, иелгән килеш, киртәләр арасыннан абзар ягына карады: бакча уртасындагы сукмактан чиләк-көянтә күтәргән Галиябану инеш суына төшеп килә иде.

Кыз аның янына җитәрәк, башын кырт кына борып, Рафаэльгә карап алды. Галиябану зәңгәр күзле, бу күзләр шундый үткер — алар бер карауда ук әйбернең асылына үтеп керәләр, укыганны шунда ук йотып-отып алалар, синең уеңны укый беләләр кебек иде. Йөзе озынчарак, борыны аз гына җәенке, сирәк кенә эре сипкелләре үзенчә бер бизәк иде. Рафаэль дә зәңгәр күзле,

тик ул үзенең күзләрен тоныграк саный, үткер күрүдә Галиябанудан күпкә калышам, дип уйлый. Галиябанунын карашы һәрчак миһербанлы, ачулануы да яратып иркәләү кебек. Ә Рафаэльнең, ачуы чыкса яки эше алга китмәсә, күзләре ямьсезләнә, киң йөзе бурлатланып яна башлый. Хәзер дә анын йөзе кызарган иде, һәм бу кызару чаңгы шуып җилләнүдән түгел, моның сәбәбе бүтән иде.

— Нигә шумыйсың? — диде Галиябану, киртә өстеннән атлап, инеш ягына чыкты.

Аның бу сүзләре Рафаэльгә, сорау-кызыксынудан бигрәк, вакытыңны әрәм итәсең бит, дигән искәртү булып ишетелде.

— Куркам.

Малай казык башын ике кулы белән дә чытырдатып тотты.

— Нәрсәдән? Шушыннан шуаргамы?

— Куркам шул, чынлап инде.

Малай җилкәсе белән бакчага таба тартылды, сөзәк яр аңа текә кыядай тоелды, төпсез упкын, авызын каерып ачып, аны йотарга җыенып үкерә сыман.

— Курыкма.

— Курыкмыйм алайса.

Рафаэль таудан таяклары белән этенә-этенә иелеп шуып төште дә инеш уртасындагы бәке янына борылып туктады. Галиябану кырыйлары шомарып беткән бәкедән су алды һәм, чиләкләрен элеп, көянтәсен көйле генә селкеткәләп сукмакка чыгып баскач, Рафаэльгә күтәрелеп карамыйча:

— Аңлап булмый торган кеше... малай син,— диде.

— Беләсеңме, мин Кәли тавыннан туп-турыга шуып төштем! Беренче булып!

Рафаэль, бу таудан берәү дә шумаячак, куркалар, дип өстәмәкче иде дә, мактануы артыкка китәсен сизеп, әйтмәскә булды.

— Беләм.

— Ничек инде — беләсең? Син күрмәдең ич.

— Хәбәре килеп җитте.

— Җитте ди сиңа!

— Алайса, үзем күреп тордым, яме!

— Күрдең ди инде бик! Син мәктәптән кайттың гына ич. Мәктәп киемеңне дә салмагансың.

— Минем булган барлык киемем шушылар.

Галиябану, башын аска иеп, такыр тар сукмактан таймыйча-тайпылмыйча өйләренә таба менеп китте.

Яңа бишмәте килешсез утыра кебек тоелды Рафаэльгә, әйе шул, чын-чынлап ятышсыз бу кара тышлы бишмәт аңа. Әнә Галиябанунын төсе уңган бишмәте үзенә ничек килешле. Әй, уңайсыз сүз әйтте бугай ла Рафаэль... Тик күңелне бер нәрсә генә тынычландыра: кыз аңа беркайчан да үпкәләми, үпкәләүнең ни икәнен бөтенләй дә белмидер ул.

Иртәгесен Галиябану беренче дәрескә кыңгырау шалтырагач кына килеп керде һәм, классташларына кемнең булуы-булмавын барлагандай күз сирпегәч, дәфтәр-китабын култыгына кыскан килеш, Рафаэльләр яныннан узып, урта рәттәге өченче партага утырды. Дәрес бетүгә класстан чыгып та китте. Китапханәгә ашыга ул шулай. Алтынчыда гына укыса да, мәктәптә китапханәче булып эшли Галиябану, шуңа күрә үз классы һәм түбәнрәк класс балалары гына түгел, ә җиденчеләр дә аны, олы кеше, эш кешесе итеп, укытучыларга тиң саныйлар иде.

Рафаэль китапханәгә озын тәнәфестә керде, аңардан соң китап тапшырырга-алырга чиратка басучы булмады. Китабын Галиябануга сүзсез генә сузды.

— Тагын аласыңмы?

— Алам.

— Нинди китап укыйсың килә соң?

— Синниндине кушсаң — шуны.

— Менә Марк Твенны укы.

Кыз елмайды. Күр әле, ул кичә Рафаэльнең сүзләренә тамчы да үпкәләмәгән икән ич!

— Тагын бер китап бир,— диде малай, Галиябанунын киңәшенә сөенә иде ул.

— Монысын китергәч.— Кыз, үзенең монда хуҗа булуына горурлануын сиздереп, Марк Твен китабын Рафаэльгә сузды.— Географияңне күбрәк укы. Бүген дүртле алдың бит, көлке. Укытучы сине тулысынча аңлатып сөйләр дип көткән иде.

— Син сөйләдең ич.

— Миннән дә сорагач, яңа тема аңлатырга вакыты кысан калды укытучының.

Рафаэль ык-мык итте, акланмакчы булып:

— Быел беренче тапкыр дүртле алуым ла әле, гел бишле иде,— диде.

— Акланма. Әйтәм ич, дәресеңне әйбәтләп әзерлә. География тау шуу түгел ул сиңа. Кемең мин синең, минем алда акланырга кирәкми.

— Ни... син минем классташым.

— Классташың булгач, тыңла алайса, әйтәм ич, аңлап булмый торган малай син кайчакта. Җиңел генә сорауга да тулы итеп җавап бирә алмыйсың, ә үзең авыр мәсьәләләрне дә ансат кына чишәсең.

— Синең дә бер мәсьәләне дә чишмичә калганың юк. Син классның беренче укучысы.

— Классның беренче укучысы — син. Мактанма.

— Мин мактанмыйм да.

— Мактансаң, эһ дигәнче узармын да китәрмен.

— Мин билге өчен түгел, ә белем өчен укыйм.

— Әй-й, әйтте сүз. Укытучылар билгене белемеңә карап куялар.

Галиябану шүрлектән бәләкәй йозак алды, китапханәне бикләр вакыт җиткән — озын тәнәфес бетеп килә иде.

Бүген соңгы дәрес — табигать белеме. Рафаэльдән дә, Галиябанудан да сорамады укытучы. Бу класста укытучылар, сүз берләшкәндәй, алардан сорамыйлар диярлек, башка укучыларның җавабы канәгатьләнерлек булмаганда гына Галиябануга яки Рафаэльгә сөйләргә кушалар.

Классташлары йөгерә-чаба таралышты. Рафаэль кузгалмады, иягенә таянып, сөртелмәгән кара тактага текәлеп, ялгызы гына утыра бирде. Бераздан тураеп аркасын терәде дә парта капкачы өстендә бармакларын пианино уйнагандай (китапханә бүлмәсендә пианино бар, Рафаэль Галиябанудан рөхсәт сорап, кайчак анда көй җыйгалый) биетеп алды һәм акрын гына җыр башлады:

Көн аяз, килә яз...

Җырларга ярата Рафаэль, борынгы көйләрне бигрәк тә яратып, аларның серле моңын тоеп җырлый ул. Борынгы көйләрне аңа хәзер сугышта йөрүче врач Сәрвәр апасы кечкенәдән үк өйрәткән иде. Өйдәгеләргә озын кичләрдә Сәрвәр белән Рафаэльнең парлап җырлаулары үзе бер бәйрәм була иде.

Малай җырлавыннан кинәт туктады да:

— Әгәр көй язсам? — дип үзеннән-үзе сорап куйды.— Кемгә атап, нәрсә турында көй чыгарырга икән? Нәрсә турындамы? Хәзер... Хәзер... Бишмәт турында! Сугышның безгә дигән киемнәрне тектермәве турында. Галиябану да әнә гел бер күлмәк киеп йөри, алмашка бүтәне юк икән.

Тик кием көе алай тиз генә тумады. Хәер, андый көй була аламы икән соң әле... Хәер, туар әле бу көй. Хәзергә... хәзергә Галиябануның яңа киемнәре булсын иде...

Рафаэль бер җырлап чыккан көен яңабаштан сузды. Аның тавышы, моңы белән тирә-юньне иңләп, ерак-еракларга китә дә салмак кына әйләнеп кайта иде.

Көн аяз, килә...

Ә коридорда, ябылып бетмәгән ишек ярыгына колагын куеп, Рафаэльнең җырын классташы, китапханәче кыз Галиябану тыңлый иде. Зәңгәр күзле Галиябану...

Кичен мәсьәлә чишә алмыйча тәмам иза чикте Рафаэль, кат-кат эшләп, кызарып-бүртенеп бетте, һич тә китап ахырындагы җавапча чыкмый. Галиябану мәсьәләне ансат чишәсең, диде дә, чишелми шул менә монысы. Баш катты инде. Әллә Галиябанудан барып сорыйсы инде, дип уйлады ул.

Галиябануларның урамы бер генә яклы, аларның йорты кар-

шында да сөзәк тау. Зәңгәр күзле кыз шушында чаңгы-чана шуып үскәндер, хәзер дә шугалыйдыр, шуңа күрә биек таулар тирәсендә күренмидер. Әллә уенга чыгарга вакыты юкмы икән аның? Уенны оныттымы икән ул...

Рафаэль, Галиябануларның ишегалды түренәрәк — авышлык беткән төшкә салынган биек йортның тәрәзәләрендә яктылык күренгәч, тукталып калды, капканы ачарга базмады. Мәсьәлә чишкәндә кайда ялгышуын кинәт кенә белеп алды да өйләренә йөгерде.

Кәли тавы турысыннан узганда, үзенең кичәге эзләрен күргергә теләп — бу таудан турыга беркем дә шуып төшмәячәк әле, бик беләсегез килсә! — шуннан әйләнергә булды. Инде мәсьәләне чишү юлы табылды ич.

Тулган ай, Кәли тавының каршысына күтәрелеп, кар бөртекләрен җемелдәтә, кичә Рафаэль салган эзләр янәшәсендәге яңа эзләрне дә киң тасмалар итеп яктырта иде.

Әйе, ике пар эз сузылган Кыятауга...

*1982*

# Яр өстендә — яшел җәннәт

Мучирмә елгасы җәйдән җәйгә саега. Кибә, мескенкәй. Өлкәннәр хәтерләвенчә, аның кысыр калачагы гасыр кергән язда ук сизелгән икән. Урман авызындагы иңкүлектән башланып, авылның түбән очында Олы елгага төшеп коя торган Мучирмә заманында мул ук сулы, салмак агымлы булган. Башында, таркау ерганак-тармакларны каплап, печән куерып үсә хәзер, урта төшләрендә бәләкәй камышлыклар бар, тамагында исә Мучирмәнең сай һәм тымызык суын авыл елгасы, үзенә ияртәсе килмәгәндәй, кирегә тибәреп тора.

Шул тамакта Мәҗит белән Хәмзә кармак салалар. Чиртми колач буе балыклар, хәтта талымсыз ташбаш та эләкми. Чалбарларының балак очларын төйнәп, сөзеп тә карадылар — юк кына, балыкның сукыры да калмаган, ахры, монда. Мәҗит кармагын яр өстенә ыргытты, тал ботагына киптерергә элгән чалбарын алып киде.

— Әйдә, киттек! — дип боерып әйтте ул Хәмзәгә.

— Кая? Хәзерендә чиртә башлый,— дип каршы төште дусты.

— Чирткән ди!.. Киттек, дим ич.

— Чалбар...

— Тәндә кибәр,— дип бүлдерде аны Мәҗит.— Синең эләкмәгән балыгыңа вакыт әрәм иткән ди бик.

— Һе, оста татар, балыкның эләкмәгәне минеке, эләксә...

— Минеке! — дип тагын бүлдерде Мәҗит.

— Кая киттек?

Хәмзә кармагының җимен алыштырып, тәтәлкә астын озынайтып салды. Мәҗит чалбарын киеп алган иде инде. Дустының һаман җыенмавын күреп, кая барасыларын әйтмичә нәни генә ачу итте.

— Җәһәннәмгә! Бик beләсең килсә! Мыштыр, әйдә, дим ич!

— Җәһәннәмдә балык эләгә микән соң? Кармакларны алабызмы?

— Сиңа эләгер, син ал. Мин үземнең кармакны таллар арасына яшереп калдырам.— Мәҗит суалчаннарын, яньчелеп беткән калай тартмадан учына бушатып, суга ыргытты, тартманы тал төбенә ташу суы китереп өйгән чыбык-чабык астына куйды.— Үзебезнең елга балыклары симерә торсын минем суалчаннарны ашап, миңа дигәннәре. Син җәһәннәм елгасы балыкларын сыйларсың, кулың белән тотып авызларына каптырырсың.

— Ә-ә, әйе бит әле, мин тоткан балыклар да синеке булачак.

— Артыр син сараннан, ташбашның сыңар тәңкәсе!

— Син яшьтидән мал кызганып булмый, җәһәннәм балыгының энҗедәй ялтыравыклы тәңкәләрен бөтенләйгә бирермен.

— И-и, мыскыл итмәкче инде үзең! Кем башлырак икәнен соңрак күрербез, агайне.

Ике күрше малай шулай сүз көрәштерергә яраталар, үзенә күрә бер уен бу алар өчен, юанычлы уен. Кайчак кызып ук китсәләр дә, чәкәләшүгә җитмиләр, бер-берсенә кизәнгәннәре дә юк. Авыл белән танышып йөргәндәге мондый эчкерсез бәхәсләр көненә әллә ничә кабынып сүнә.

Алар сусыз Мучирмә эчләтеп менәләр. Мәҗит алдан бара, Хәмзә, җиләк караштырып, арттарак кала. Ара ерагая башласа, кызуланып, дустын куып җитә.

— Мәҗит, дим...

— Тагын нәрсә?

— Тамак ачты...

— Җиләк ашап бүселәсең бит инде.

— Бөрешкән биш җиләк таптым барысы, тел очына да йокмады ла.

— Әнә кәҗә сакалы.

— Таякка әйләнгән инде ул.

— Ат кузгалагын күзең күрмиме?

— Аны күп ашап булмый.

— Тамагың тук икән, алайса.

Юантык Хәмзәгә гәүдәсен тотарга күп ашарга кирәк шул, Мәҗиткә көненә бер тапкыр эчкән бәрәңге шулпасы да җитәдер, очкак кар кебек кенә бит ул. Ә Хәмзә, авызына ризык кермичә торса, хәлдән тиз тая.

— Мәҗит, дим, ардым мин.

— Бәбәй! Чүнник әнә генә, шунда ял итәрбез.

— Кая барабыз соң без?

— Җәннәткә!

— Анда нишләрбез? Без җәннәтне ошаттык та ди, ә җәннәт дигәнең безгә ишеген ачмаса...

Хәмзәнең сүз көрәштерәсе килә дә, тик ач карынга оста шаярта алмыйсың шул.

Мәҗит тә, тиз генә җавап таба алмагач:

— Анда нигә барабызмы? — дип, сорауга каршы сорау гына бирде.

— Әйе инде, синең җәннәтеңдә ни калган безгә?

— Сыйланырга! Минем җәннәттә генә син капкорсагың тулганчы... ашарсың.

— Йөгердек алайса.

Хәмзә йөгереп алга чыкты, әмма ерак китә алмады, яр битендә соңарган җир җиләге күреп, шуңа иелде, аны кабып йоткач, тирәсендәге үләннәрне егып, ишләрен эзләп карады, ләкин җиләк бүтән табылмады. Мәҗит аның яныннан, авызын бөрмәләндереп:

— Тү-тү-түт! — дип сызгырып узды.

Чүнник Мучирмәнең уң ягындагы калкулыкта. Анда юан юкәләр күп, наратлар да шактый, миләшләр дә бар. Биш дисәтинә чамасындагы шушы кечкенә урманны чикләвек куаклары уратып алган. Мәҗит белән Хәмзә тал арасына яшергән озын, төп-төз кармак сапларын былтыр ук шушыннан кисеп төшкәннәр иде.

Чүнник уртасындагы аланда элек каладан бер бай умарта тоткан икән. Байның андагы алты почмаклы, ике катлы, чатыр түбәле йортын һәм озын итеп салынган умарта өен Мәҗит белән Хәмзәнең әти-әниләре күреп беләләр. Хәзер бу биналар сүтелгән инде. Сиртмәле коесы да күмелгән, аның иңгән авызын-чокырын, мал-туар төшмәсенгә, киртә белән әйләндергәннәр. Йорты алдына пар каен утырткан булган бай, алар җәелеп үскәннәр. Чүнниктә ак каүсәлеләр шушы ике сылу гына, бүтән каен юк. Хәер, ачык аланда ел саен яшь үсентеләр орлыктан тишелеп чыга, әмма аларны печән чапканда аралап тормыйлар, үсеп китәргә ирек бирмичә, кыеп кына егалар мескенкәйләрне.

Малайлар шул ике каен арасындагы чирәмлеккә яттылар. Кояшның төштән соңгы бар куәтенә кыздыруын пар каен, күләгә җәеп, шифалы җылыга әйләндерә кебек монда. Дәү агачлар күләгәсе тагын да куерак анысы, тик ешлыкта рәхәтләнеп тәгәри алмыйсың һәм якты аланны бөтенләе белән берьюлы күреп тә булмый.

— Җитте! — дип сикереп торды Мәҗит.— Рәхәт озак булмый.

Хәмзә исә киерелеп йөзтүбән әйләнде, таянды, акрын гына торып басты, өстен ашыкмыйча каккалагач кына, бу юлы сүз көрәштерәсе килмичә:

— Рәхәт озак-озак булса, шәпнең дә шәбе була инде ул,— дип әйтеп куйды. Бераз тукталып торгач: — Рәхәт, Мәҗит яшьтәш, кешенең гомере буена сузылырга тиеш,— дип, олыларча акыл белән өстәде һәм Мучирмә эчендәге сукмакка сүзсез генә төшеп баручы Мәҗит артыннан иярде.

— Их-х, Хәмзә, ярый әле синең баш йомры, синең акыл икебезгә дә бик җитә. Син дус итмәсәң, шыр тилегә калып йөрер идем бит мин, әй. Бик беләсең килсә! — диде Мәҗит. Чүнникне чыгып Мучирмә эченә төшкәнче, Хәмзә сүзләренә җавап эзләгән икән ул.— Синдәге акыл миндә булсамы, өченче классны гына түгел, унынчыны инде күптән бетергән булыр идем дә үз башымнан әллә-әллә нәрсәләр уйлап чыгарган булыр идем инде мин. Бик беләсең килсә!

Мучирмәнең борылышлары чүнник турыннан соң ешая. Шулай да малайлар аларны, яр өстенә менеп, турыга гына кистермәделәр, коры елганың яр асты буйлап көтү салган сукмактан бардылар.

— Җиттек,— дип, кулы белән ишарәләде Мәҗит.

— Якын икән ич синең җәннәт, чүнниктән турыга бәргәндә, чакрым да юк бу,— диде Хәмзә һәм як-ягына карап алды.— Ә җәннәт үзе кайда соң? Әллә җир астындамы? Шунда төшәргә ишеген таба алмыйсыңмы? Чирәм каплап югалттырганмы җәннәтең ишеген?

Шаяртуга китүне монысында Мәҗит тиз тыеп калды.

— Җир астына төшмибез,— диде ул, яман да олысымакланды.— Өскә менәбез. Башта син менәсең.

— Син дустым хакына кылмастайны да кылырмын.

— Кылырсың, нибуч! Ят та шуышып мен өскә!

— Шуышыпмы? Минме? Сиңа тотынып менсәм дә, рәхмәт әйтерсең!

— Ят, дим! Хәзер шуыш! Мин артыңнан этәм.

— Баш ярдан чыкты инде.

— Шалаш күренәме?

— Күренә.

— Габдулла абый шундамы?

— Кеше күренми анда.

— Башыңны бик күтәрмә, дим!

— Юк анда җан иясе.

— Йоклый инде алайса Габдулла абый. Шалаш эчендә. Күләгәдә. Рәхәтләнеп!

Мәҗит Хәмзәнең янәшәсенә менеп ятты.

— Менә боларны күрәсеңме? — диде ул, борчак кузакларына төртеп күрсәтте һәм басу кырыена таба шуышмакчы булды.

— Тукта! — дип, чалбар балагыннан тотып калды аны Хәмзә.

Алар куркудан Мучирмә эченә тәгәрәделәр.

— Күрдеме Габдулла абый? Безне куарга да йөгерәме Габдулла? — Мәҗит елга эчләтеп кенә авылга таярга җыенды.

— Анда Габдулла абый күренми лә.

— Их, син, куркак җан! Нигә туктаттың соң, алайса, мине?!

— Ярамас бит урларга. Өстәвенә Габдулла абый, куып тотып, арканы таяк белән каезласа? Ул бит синнән дә кызурак йөгерә!

— Синең тамак, чыннан да, тук икән алайса. Минем кебек үк ашыйсың килмәгән икән синең.

— Тамак ач та бит, Габдулла абыйдан куркам. Борчак каравылларга остарган ич инде ул, былтыр да малайлардан борчак кузагы урлатмады.

— Курыксаң курык!

— Ач тамагым, тыныч колагым, ди безнең әни.

— Куркам, диден бит. Курык! Нигә менәсе иттең соң? Бу тапкырында артыңнан этәр дип көтмә. Бик беләсең килсә!

Тәвәккәлләделәр. Ярдан шуышып менеп, борчак басуына да шуышып кына керделәр.

Ләкин малайлар тук кузаклар сайлый башларга да өлгермәделәр, яшел җәннәттә гөрелдәвек тавыш ишетелде.

— Сезләрне очратуыма шатмын, дияр иде бүтән берәү булса.

Малайлар җиргә сеңделәр. Авыз-борыннарына туфрак тулды хәтта. Икесе дә, башларын бераз калкытып, кырын күзләре белән генә Габдуллага карадылар. Бу карашлар Габдулланың, сул кулы белән биленә таянып, гәүдәсен тибрәнгән кебек уйнатып торган чагына туры килде. Елмая иде Габдулла, кояшта карайган йөзендә күзләре дә ап-ак тешләре генә ялтырый иде. Эләктегезме, янәсе — малайлар шулай аңладылар. Габдулла кепкасына нәрсәдер салган, ахрысы, аны читләрен йомып уң кулына тотып тора иде. Былтыр аның, борчак каравылларга кергәч, очы ике япьле имән таякны, кабыгын кубарып, пыяла белән шомартканын беләләр, шул сынмас таяктан бигрәк тә шүрлиләр иде малайлар. Ләкин Габдулланың кулында, шөкер, печән әйләндерә торган агач сәнәккә охшаган таягы юк иде.

— Торыгыз,— диде ул, сабыр гына әйтте моны.

Тордылар ике ахири.

— Монда килегез.

Килделәр җан дуслар.

Башларын аска игәннәр. Хәзер, менә хәзер Габдулла яңаклардан ут өерләре чыгарачак, дип көтәләр.

— Кыйнамыйм мин сезне,— диде Габдулла һәм, аякларын басу читендәге ызан эченә төшереп, чирәмгә утырды. Чабатасының мыекларына, аларны хәзер генә күреп алып санагандай, бармак очы белән кагылып чыкты.— Теләсәгез, икәүләшеп ми-

не кыйный аласыз, хәл бетебрәк торган чак минем. Соң, сезнең икегезнең миңа болай да көче җитәдер, сез миннән ике яшькә генә кечкенә бит. Теләсәгез, мине тукмап, борчак кузагын талагыз. Ә минем көчем җитмәганнәргә кул күтәрү түгел, көчем җиткәнне дә кыйнаганым булмады әлегә. Шулай да башта сезне менә шушы кәкре ботак белән сырмакчы идем. Башта, сезнең урлашу ниятегезне белгәч... Хәйләләү әмәле табылыр иде сезне шәпләп торып кыйнарга!.. Башыма бер шәп фикер төште аннары...— һәм ул сүзне кинәт кенә бүтәнгә күчерде.— Эш кушыйммы үзегезгә?

— Нинди эш? — дип, икесе бер үк сүзне әйтте Мәҗит белән Хәмзә.

— Менә син, Мәҗит хәйләкәр, шалаш авызына сөягән имән таякны-сәнәкне йөгереп кенә алып киләсең дә үзегез таптаган борчак сабакларын үрелеп торгызасың.

Мәҗит Мучирмә буйлап шалашка таба чатыр чапты.

— Ә син, Хәмзә куркак-батыр, чүнниккә кире төш тә утын алып мен. Учак ягарбыз, минем эчтә дә бүреләр улый. Шалаш янында утынның күп булуыннан зыян юк, кунаклар тагын килер, тагын учак дөрләтәсе булыр. Болар гына озакка җитмәс.— Габдулла читтәге бер бәйләм ботак-сатакка күрсәтте. Аннары чүнниккә таба борылды.— Ә-менә чүнникнең аргы башындагы шәрәрәк наратны күрәсеңме?

Хәмзә сүзсез генә баш какты.

— Шуның алты ботагы сынып төшкән. Мин аларны басу кырыена чыгарып та куйган идем. Күтәрә алганча алып мен. Икесе юанрак, аларына тотынма, үзем сөйрәрмен әле.

Габдулла, чүнниктән кепкасына тутырып менгән карлыганкура яфракларын салып, кечкенә чиләктә чәй кайнатты. Ач карынга да ярап куя икән коры чәй, өчесе дә яратып эчтеләр. Аннары шалаш эчендә печәнгә ятып ял иттеләр. Тик әңгәмәне тигез корып кына җибәрә алмадылар, күбрәк Габдулла сөйләде, Мәҗит белән Хәмзә ара-тирә генә сүз кыстырдылар.

— Сугыш, малайлар, бетәр ул, әмма сузылуы яман аның,— дип, шалаш авызы ягына борылып таянды Габдулла. Мәҗит белән Хәмзә дә күченделәр.— Без җиңәрбез. Сугыш авырлыкларын күтәрергә безнең җилкәләр чыдасын менә. Сезнең балачагыгызны сугыш йота, ди миңа әни. Үсәрбез дә. Тамаклар да тук, өсләр дә бөтен булыр. Туктагыз әле, сез чалбарларыгызны шуышып пычратып бетергәнсез икән бит. Эләгә икән әле бүген сезгә йомшак итеп сыйпаулар әниләрегездән! Чалбар артыннан чалбар ала торган чаклар түгел...

Имән таягының япьләре белән шалаш алдындагы тапталган төшләрне тырмаштырды Габдулла һәм, көлемсерәп:

— Мин сездән хәйләкәррәк икән,— диде.— Сезнең тавышны мин чүнниктә үк ишеткән идем, үзегезне генә күрмә-

дем, ә тавышларыгыздан танып ук җиткермәдем. Сез елга эчләтеп бардыгыз, мин яр өслэтеп артыгыздан мендем. Әни әйткән сүзләрнең мәгънәсенә шунда төшендем: урман — колак, кыр — күз, ди ул. Мине күрмәдегез, сез шалаш ягына гына мөкиббән китеп карадыгыз. Өлгермәгән әле борчак, малайлар, кузак төшкән генә аңа, аны чәйнәүдән файда юк. Борчакны вакытын күп уздырып чәчәргә туры килде быел, үзегез дә хәтерлисездер. Атлар язга үтә арык чыкты, бөтен колхозыбызга нибары бер трактор иде. Чәчүчеләрен әйтегез тагын, минемише... егетләр. Тубал, орлыкны яртылаш тутырсаң, билдән урталайга бөгеп кенә төшерә. Менә бу тирәдән мин үзем чәчеп узган идем, тигез тишелеп үскән бит, әйеме, дустыйлар...

Малайлар эндәшмәделәр, бер-берсенә карашып кына куйдылар, Габдулла шалаш киштәсенә кыстырган төргәкне үрелеп алды, чүпрәген сүтте, аның эчендә китап иде.

— Әбиләр китабы ич бу! — дип аптырады Мәҗит.

— Син шуны укый беләсеңме? — дип сорады Хәмзә.

— Дин китабы түгел бу, искечә хәрефләр белән язылган гына. Монда җырлар да, мәкальләр дә бар. Таушалган инде, күп төшендә хәрефләре танылмый. Менә бу юлын укып карыйк соң: йөз ел... то-ра-чак... шикелле к-ә-кәсеп кыл... Мин хәзер өч әлифбаны беләм. Мәктәптә латин әлифбасыннан башлаган идек бит безнең класслар, аннары гына хәзергесенә күчтек. Гарәп әлифбасын әти өйрәтте. Безнең тарих шушы әлифба белән язылган, тарих — бөтен кешелекнең байлыгы, аны шәп белергә тиешбез, дия иде минем әти. Тарих китаплары эчтәлеген яттан белгән кебек сөйли иде ул. Тарих китапларын мин дә укып-укып карыйм да, тик аңлап җиткермим. Баш яшь. Әти, сугыштан кайткач, аңлатыр әле шул китапларның эчтәлеген миңа. Гыйлем кеше бит минем әти, сугыш аның белгәннәрен оныттыра алмас әле... Сугыш, малайлар, бетәчәк ул анысы. Без генә надан калмагаебыз менә. Туктагыз әле, бүген кичтән предны күрим дә сезне үземә ярдәмчеләр итеп сорыйм әле мин. Бергәләп китаплар да укырбыз. Барыбер дә эшсез йөрисез. Эшсез йөрү егетлек түгел, сугыш барганда үтәләтә.

— Без комбайнда салам ташлатучылар булабыз,— дип акланды Мәҗит.

— Анысы урак башлангач әле аның. Аңарчы бик рәхәтләнеп миңа булыша аласыз. Көтүне Мучирмәгә күчерәләр, теге яктан көтүчеләр терлекләрне солы басуына менгермәс, бу яктан борчакны без сакларбыз. Ә... ә сез Мучирмәнең холкын беләсезме соң?

— Нинди холкын?

— Ю-ук.

— Мучирмәнең суы йөз ел ярларын тутырып ага икән дә, аннары ул йөз ел кипшереп тора икән, аннары тагын күп сулы

елгага әйләнә икән. Минем этинең бабасы әйтеп калдырган моны. Сугыш беткәч, шул көннәргә чаклы — Мучирмәнең суга туенган көннәрен күргәнгә чаклы рәхәтләнеп яшибез әле без!

...Һәм алар рәхәт яшиләр. Еш очрашалар. Ләкин борчак кузагы вакыйгасын бергәләп искә алырга кыюлыклары җитми. Мәҗит белән Хәмзә урларга җыенулары өчен Габдулладан хәтта гафу үтенергә оялалар, ә Габдулла исә ачтан интеккән малайларны кыйнамакчы булганы өчен ояла. Хәер, аларның үзара гафу үтенерлек гөнаһлары да юк кебек.

Ләкин күңелләрдә төер-яра калган.

Шул төзәлми һаман.

Ләкин ерак еллар басуының өч кенә яралгы борчаклы кузагы тәмен татыган малайлардан сугыш гафу үтенергә тиеш лабаса! Ә яр өстендәге яшел җәннәт-басуда балачакларыннан ук сусыз Мучирмә тулып ташырлык тир түккән Габдуллалар, Мәҗитләр, Хәмзәләр сугышны беркайчан да гафу итмәячәкләр.

*1984*

## Кеше күңеле — үзе бер кояш

Мең дә тугыз йөз... сәнәнең май ае иде. Кичке уңай. Кояшның тәүлек буена аерылып торган офыгына җәһәтләнеп якынаер чагы җитә. Юк ла, кояш офыкка түгел, ә офык кояшка талпына, сагынып талпына ич. Дөресе шулай, безнең галәм үзәгендә кояш лабаса, шуңа күрә барлык нәрсә аңа тартыла.

Тукай Ташаяк ярминкәсенә өйлә алдыннан барган иде. Агач атка атланып әйләнергә ярата ул монда, балачагында атка атланып чабуларның тәтемәве каруын шушы ихлас уен белән алырга тели. Бүген дә бу мавыктыргыч уеннан кесәсендә акчасы беткәч кенә туктады. Әнә шул акча дигән чиктән тыш куәт иясе дөнья мәшәкатьләреннән онытылып тору рәхәтлегенә киртә салды.

«Болгар» номерларына Болак буйлап кайтырга, Евангелистлар урамыннан борылып керергә иде исәбе, чөнки бу яктан кешеләр азрак йөри иде. Үзенең кырыгынчы бүлмәсенә ялгызы гына тизрәк бикләнеп, хыял дәрьясына чумып, каккан-сукканнарны күп кичергән балачагын изге хатирәдә баетасы да баетасы иде. Моның өчен, әйе, каруселънең агач атларына атлану гына аз шул, балачакның хыялда яңаруына ялгыз калып җырлау да кирәк иде.

Әмма Тукай, Печән базары турысына җиткәч, әйләнеч ясыйсы итмәде, базар аркылы кистереп чыгарга булды. Ташаяк ярмин-

кәсе күңеленә китергән балачагын кырыгынчы бүлмәгә тизрәк алып кайтып кунак итү ихтыяҗ иде. Яңа җырлар ишелеп-ташып туар иде аннары.

Инде кичке уңай бит, базарда халык азайгандыр, танышбелешләр очрап туктатмас. Шигырьләренә һәм фельетоннарына кертелгән байгуралар һәм кадими затлар шулай ук таралышкандыр, димәк, оясына поскан эттәй теш ыржайтып калучылар булмас.

Аның игътибарын базар уртасындарак таш өстенә утырган карт җәлеп итте. Ак карт, дигән уй килде Тукайның күңеленә. Башын уңга янтайтып, кашларын сикертеп, мондый тасвирына үзе үк аптырап куйды: кеше ак буламы инде, йә ак тәнле, дисәң, дөрес чагыштыру булыр иде. Ак карт, имеш... Шулай да, картка текәлеп карый торгач, сыйфатламасының хаклыгына инанды. Күңеле ак бу агайның, дип ачыклады бәясен һәм картка турылап борылды.

— Әссәламегаләйкем!

— Вәгаләйкемәссәлам, Тукай әфәнде!

Карт сөрмәдән бизәкләр төшерелгән киң беләзекне җыелма урындык киндерендәге йөзек-балдаклар, алкалар янына куйды, ашыкмыйча гына торып басты, кәзәкиенең аскы каптырмасын эләктерде, шул җайдан кәзәкиеннән чыгып торган күлмәк-итәген сыпырды.

— Сез мине таныйсыз икән,— диде Тукай һәм, «кытай ефәгеннән күлмәк киючеләр күп очрамый, лавкасы киндер урындыктан гына гыйбарәт булса да, агаебыз хәлле кешегә тартым» дип уйлады.

— Таныйм, Габдулла әфәнде. Ахырында, сезләрне бу базарда вә Казан каласында танымаучылар сирәктер, белүчеләр аздыр, вәләкин аңлаучысы юктыр, булса да, бармак белән генә санарлыктыр.

— Кызык, бик тә хикмәтле вә гыйбрәтле бәһа бирдегез сез базар халкына, хосусән базарның даим әһелләренә. Мәгънәсенә төшсәң, Печән базарын гайбәтчеләр, наданнар, комсызлар һәм бүтән шуларга ишләр чуарлый икән. Тик кеше күңелен аңлаучысы юк. Базарга, аның гади халкына түгел, әлбит, ә нәкъ менә мыжгыган корт оясына бәһа бирүдә миннән уздырдыгыз...— Тукай, картка кем дип эндәшергә белмичә, сөйләвеннән туктады, аның гәүдәсен-кыяфәтен күздән җентекләп кичерде. Ак карт буйга кыска, Тукайның үзе чамалы иде. Агай сакал-мыегын пөхтә йөртә икән, йөзе кызгылт, ялтырый, ике бите уртасыннан да янәшә җыерчыклар сызылып килә. Кырдырып алынганнан соң чыгып кына килүче ак чәчләре түгәрәк каракүл-илтер бүреге читеннән камыл сыман төртелергә тора. Ак буйлар сузылган көлсу төстәге киң чалбар балагы читек кунычыннан кайтарып салынган. Тукай, шаяртуын да кушып:

— Тасвирыгызда мине әллә-ә кайда ук артта калдырып алга чаптыгыз, җәнабе гали,— дип эндәшү сүзен тапты.

— Нинди галиҗәнап булыйк ди без! — Ак карт ике кулын бергә селтәде.— Сала агае мин. Нигъмәтҗан атлы булам.

— Үзебезнең кеше икән. Мин дә авыл тумасы бит. Кушлавычтан, Кырлайдан...

— Беләм.

— Беләсез?.. Ә, үзегез бая әйтмешли, аңлыйсызмы соң?

— Шөбһәләнмәгез. Аңлыйм.

— Рәхмәт.

Нигъмәтҗанның күңеленнән бөркелгән пакьлек Тукайны картка тиз якынайтты. Бүлмәсенә ашыгып кайтып, балачагына җырлый-җырлый сәфәр чыгу теләген соңгарак калдырасы итте ул һәм җыелма урындык янына чүгәләде.

— Бизәнү әйберләре белән сәүдә итәсез икән.

— Ямьләнү әйберләре белән,— диде Нигъмәтҗан һәм, сул аягына тезләнеп, ике кулын да аслы-өсле уң тезенә куйды.— Кулыгызга алып карагыз, Тукай әфәнде.

— Рөхсәтме?

— Әлбиттә!

— Әмма минем кызыксынуым сатып алу ниятеннән түгел бит.— Акчасы булмауга ишарәләп, кесәсенә сукмакчы булган иде дә Тукай, моны икърар итүдән кинәт тыелды: татарның мәйдан тотучы шагыйре кесәсендә сукыр тиенсез базарга керүенә сала агае ничек ышансын ди, тиле! Өстәвенә кәпийкәсез килеш, алтын-көмеш әйберләренә күзе төшсен, имеш!

— Матурлар...— диде шагыйрь; киң беләзекнең сөрмә бизәкләренә, китап укыган кебек итеп, карашын йөртеп сокланды.— Кырлай урманнарындагы чәчәкләр төшерелгән, диярсең лә, ә!

— Дөрес таныдыгыз, урман чәчәкләре. Вәләкин Кырлай ягыныкы түгел, үзебезнең Тенеки авылы урманы чәчәкләре. Димәк, бу урманнарның чәчәкләре охшаш.

— Сез...— Икенче беләзектәге бүтән чәчәкләр бизәкләрен күреп, сүзеннән туктады Тукай.

— Әйе, Тенеки авылыннан, көмешчеләр авылыннан мин. Әйе, боларны үзем койдым-ясадым.— Нигъмәтҗан, кәзәки изүен ачып, нәрсәдер алды, аны уң учына күчереп йомды.— Шушы һөнәр белән көн итәбез,— дип, үзе турында тәгаенләп сөйли башлады ул.— Мин үзем — батрак кеше. Җирсез нәселдән. Авылда ундүрт гаилә без. Ерак бабабыз, егерме биш елга солдат хезмәтенә бармас өчен, җирсез калуны кулай тапкан. Икенең берсен сайларга тиеш булгансың бит ул чакта: йә егерме биш ел буена биленә солдат каешы буасың да җир аласың, яисә чирек гасыр гомереңне солдат хезмәтенә бирүдән баш тартасың да җирсез каласың. Һәм инде, игенче шөгыленнән

мәхрүм икәнсең, бүтән һөнәрне өйрәнергә тиешсең. Яшәү әмәлен шулай эзлисең. Соңгы заманда, җиребез булмаса да, солдатка барыбер алалар, әйе. Ә җирләребез барыбер юк. Ямьләнү әйберләре ясау һөнәрен җир иясе кешеләр дә белә. Алар күбесенчә кыш айларында гына, өязгә чыгып, көмеш эше белән йөриләр. Без, җирсезләр, ел әйләнәсенә диярлек читкә китәбез. Әйе, чәчүдә һәм уракта авылдашларга булышкалыйбыз. Менә үзем дә быелгы сабанда күршемә кулдаш булдым. Халык быел сабан чәчүен әйбәт үткәрде. Көннәре дә уңай торды. Уңышы да мул чыгар, шәт. Боерган булса. Әйе, җирдән аерыла алмыйм мин үзем, Тукай әфәнде. Бөтенләйгә аерылу ярамый да аннары. Боларны,— дип, киндер урындык өстендәге ямьләнү әйберләренә ишарәләде Нигъмәтҗан,— күрше-тирәгә сабан чәчүендә булышудан буш араларда ясадым. Өязгә чыккач та сатылырлар иде, вәләкин калага күптән килгәнем юк иде. Казан да сагындырды. Бер уңайдан сәүдә итүне дә кайгырттым. Әлбиттә. Безнең авылда шәп осталар булган, һөнәребез буыннан буынга күчә бит. Хәзер дә чын осталар бар. Кордашым Бичи Габдулласы һәм ки Кәримулла, анысы ир уртасы да булмаган әле, миннән күп яшь. Алар икесе дә коеп күрсәтә инде беләзек-йөзекләрне! Таң каласың!

— Сез дә бик матур койгансыз! — дип соклануын яшермәде Тукай.

Нигъмәтҗан беравык эндәшмәде, уйланып торды.

— Мин дә начар коймыймдыр. Хак әйтәсез. Вәләкин Бичи Габдулласы, сезгә — адаш, ә миңа — кордаш Бичи Габдулласы, һәм дә Хәйрулла Кәримулласы миннән күпкә остараклар. Күпкә остараклар. Әйе. Алар белән ярышуы кыен. Мин аларга өйрәнчеккә генә ярыймдыр. Гәрчә ки малай чактан ук һөнәрем шушы һәм ки Хәйрулла Кәримулласы мин өйләнгән елда гына туган булса да. Әйе. Ә Кәримулланың этисе урта кул оста иде, малае этисеннән һәм ки барыбыздан да уздырды. Ул өязгә чыгып йөрми, авыл кешеләре соравына гына эшли. Авыл халкы аңа, Гадел кеше, дип кушамат бирде. Ә Бичи Габдулласының тагын бер һөнәре бар. Безнең тегермән буасына су Идел кебек җәелә. Авылның ир заты көзге ялтыравык боздa, көмешчеләр өязгә китәр алдыннан, аяк чанасында шуып ярыша. Габдулла кордаш берәүне дә җиткерми инде мәгәр! Хәзер дә иң җитез шуучы — ул!

Ак карт учын ачып кашлы йөзеккә карап торды, аннары учын кабат йомды.

— Фаразан,— дип елмая куйды көмешче оста һәм уң кулын күтәрде дә кире төшерде,— кәсеп итеп, ил-җир күреп йөргәндә, минем үземнең дә эшемне мактыйлар болай. Мактанудан түгел монысы, әмма ки. Дәрәҗәмне икърар итәләр. Бар бу кадәресе. Һәм ки,— дип йомшак кына кеткелдәде Ак карт,—

ил-җирдә үземә тигән кушаматым да бар минем. Кушаматым үземә бик тә ошый.

Тукайга бу кадәресе дә кызык тоелды.

— Ошый? Кушамат ошыймы?! Мин үземә кушамат белән эндәшүне яратмас идем.

— Ошый! Һәм ки мин аның белән горурланып та куям. Карчыгым алдында гына булса да. Һәм ки менә, Тукай энем, сезнең каршыда. Кәсеп итеп йөргәндә, күченәчәк авылга үземнән алда барып җитә кушаматым.

— Ә... шулай да кушаматыгыз ничек соң сезнең, Нигъмәтҗан абзый?

— Ышанычлы кеше, диләр миңа! Ышанычлы кеше! Алтын-көмеш тирәсендә ышанычлы булуың — үзе мәртәбә. Ямьләнү әйберләре ясатучыларга алтын-көмешләренең калганын бөртегенә хәтле кайтарам. Вәләкин,— дип тагын йомшак кына кеткелдәде Нигъмәтҗан,— кушаматны миңа хатын-кызлар такты бугай, һәм ки бөтенләй дә бүтән нисбәттән.

— Кызык... Мәхәббәт-гыйшыкка кагылышлы нисбәттәндер.

Тукай, чүгәләүдән аяклары талып, торып басты, оеган тез асларын ышкыды. Нигъмәтҗан да торды.

— Һе-е... Гыйшыкка мөнәсәбәтле түгел. Мәхәббәтем гомерем буена үз җәмәгатемдә генә булды. Аңа мин бу нисбәттән ышанычлы кеше. Тик балаларыбыз гына юк, кысырлар икәнбез... Ә кушамат болай кушылгандыр, дим мин үзем. Фаразан, бер хатын миннән алтын балдак яисә алка койдырып алды, ди. Чишмә юлында ахирәтләренә мактанмыйча калмый бит инде ул. Мактана. Алкасы алтын лабаса — мактанмый ни! Ахирәтләренең дә шундый алка тагасылары килә. Табигый ки. Ә аларның алтыннары юк, алтын алкага түләрлек акчалары да юк. Көмешләре бар! Әмма көмеш алтын түгел инде. Берәү алтыннан ямьләнсен дә аның ахирәтләре нигә көмешкә калырга тиеш ди әле?! Менә шулчак инде алар минем катка үтенеч белән киләләр. Нигъмәтҗан абзый, диләр, көмешне алтынга син генә әйләндерә аласың, диләр, һәркайсы моның икебез генә белгән сер булуын тели. Моны мин, Тукай әфәнде, сездән сүз чыкмасына ышанганга күрә генә сөйлим,— дип, шагыйрьнең күзләренә карады көмешче оста. Тукай, ризалашуын белдереп, баш какты.— Һәм тырыша Нигъмәтҗан абзыйлары! Көмешкә алтын йөгертә дә алтыннан аерылгысыз итә. Шуннан соң миннән ямьләнү әйберләре ясаткан апайларның дәрәҗәләре тигезләнә дә китә. Барысы да бер кавем, ямьле кавем була аннары, һәркайсының күңел кояшы нурлырак балкый аннары...

— Хикмәт икән...

— Хикмәте шул гына — кешеләрне юандыру. Адәм баласына юану да кирәк бит әле.

— Кирәк, һәм кайчакта бик кирәк!

Шагыйрь урындыктагы ишле булмаган ямьләнү әйберләренә тагын карап торды да китәргә җыенды. Кырыгынчы бүлмә көтә, анда балачакка хыялда ат атланып чабып кайту көтә иде. Аның саубуллашырга әзерләнүен абайлап, Нигъмәтҗан уң кулын тагын күтәрде һәм:

— Берсен дә алмыйсызмы, Тукай әфәнде? — дип сорады.

— Мин алка такмыйм, беләзек кимим бит, Нигъмәтҗан абзый,— дип, шаяртып җилкәләрен селкетте, кашларын сикертте Тукай. Акчам юк, димәс бит инде! — Осталыкка сокланып рәхәтлек кичердем. Шуның өчен рәхмәт сезгә, Нигъмәтҗан абзый. Эшләрегез уң булсын!

Оста карт йөзекле учын ачты. Йөзекнең кашы нур чәчә иде. Балкый каш, әйтерсең уч караңгысында тыелып торган нурлары җиһанны иңләргә-буйларга томырыла иде.

— Менә бу яшьләр йөзеге, шунысын рәхим итеп алыгыз, алайса,— диде Нигъмәтҗан һәм йөзекне, кашын өскә каратып, шагыйрьгә сузды.— Безнең авыл басуында, урман юлы буенда, Торналар күле бар. Йөзекнең кашын шул күлгә охшатып ясарга тырыштым. Читләрендәге сызыклар, үземчә, камышлар, ә уртадагы алсу түгәрәк, үземчә, кояшның, галәмебезнең тотнагы булган кояшыбызның күлдә чагылышы. Алыгыз сез күл кашлы йөзекне, Габдулла энем. Күреп торам ич, ошатасыз йөзекне. Акчагыз җитмиме? Хафаланмагыз. Аның бәһасен мин куям ич! Һәм мин бу бәһане сезнең күңел байлыгыгыз күләменә карап куям. Мин йөзекне сезгә бүләк итәм! Сезнең үз һөнәрегез осталыгын икърар итүем билгесе... һәм истәлегем булсын. Торналар күле кашлы йөзек, мәхәббәт күле кашлы йөзек... Берберсенә төгәл охшаш ямьләнү әйберләрен мин беркайчан да коймадым. Монысының да сыңары юк. Һәм аңа сез лаеклы, шагыйрем!.. Әйе, сез лаеклы. Сезнең сөйгәнегез бардыр бит. Шагыйрьнең сөйгән яры булмыйча калмас! Әйе, бүләгемне сөеклегезгә бүләк итүегезгә күңелем рәнҗемәс. Бурычлы калам, дип уңайсызланасызмы? Хаталанырсыз. Чөнки оста белән оста арасында бурыч була алмый. Инде,— дип, кашларын сикертеп елмайды Нигъмәтҗан оста,— күңел кояшыгызга тап төшмәсен дисәгез — гәрчә моның өчен шөбһәләнергә һич тә ярамый — мин сездән бурычыгызны үземчә түләтермен. Кем белә, тормыш бит, бәлки, безнең авылга да сәфәр чыгарсыз. Мәхәббәт дәрьясыдай сихри ямьле Торналар күлен күрәсегез килер бит әле. Шул чакта миңа багышлап, карчыгым белән миңа атап, бер шигыреგезне көйләрсез.

Тукай бүлмәсенә керүгә үк ишекне бикләде, яртылаш ачык тәрәзәне, һава тиз бөркүләнмәсен өчен, ара калдырып япты. Аягын салып, күлмәкчән калып, урын җәймичә генә мендәрне күпертте дә чалкан ятты. Ташаяк ярминкәсендә туган хыялы-

на — тыныч бүлмәсендә ялгызы гына балачагы хатирәләренә чуму иде аның теләге. Кулларын баш астына куеп, түшәмгә текәлеп озак ятты инде, ләкин балачагындагы кызыклы вакыйгалар да, кимсетүле хәлләр дә, аралашып-буталып, күз алдыннан чабышып кына уздылар. Шагыйрь аларның берсен дә тыеп туктата алмады. Өстәвенә арага базарда очраган Ак карт та килеп керә иде. Тукай, урыныннан тормыйча гына, караватт янындагы аркасы чыбыктан бөгелгән урындыкны читкәрәк этәрде, кечкенә язу өстәлендәге китапка үрелде. Аны актаргалап кире куйды. Шагыйрьне уку да алмады. Ул, чалкан яткан килеш, мендәрен башына тотып кына, тәрәзәгә борылды. Кояш күренми, каршыдагы йортлар арасыннан аның яктысы да беленми иде. Безнең якларга май төне килүенә ишарәләп, офыкны бөркәнеп өлгергән, димәк, кояш.

...Ак карт.

Кунакка чакырды ул.

Йортыбыз Тау урамының уң кулында югарыдан икенче, ди, юк, кара-каршы йортларыбыз, диде. Агач бакчасына кертеп салынганы буш тора икән, шунысын минем карамакка тәкъдим итә. Рәхәтләнеп яшәрсең, юк, яшәрсез, диде.

Борчу ясаучы булмас, теләсәгез, көннәр буена бакчада, алма-шомыртлар күләгәсендә ял итегез. Шигырьләр дә чыгара аласыз, юан имән тумраныннан анда түгәрәк өстәл тора, яркасыннан утыргычы да бар. Йорт-җиребез, каралты-курабыз кимхурдан түгел. Ил йөрим бит үзем, төрлесен күрәсең, үрнәк алырдай нәрсәләр күп илдә, кайсысын үзгәртебрәк, үзенчә яхшыртыбрак корасың тагын.

Илдә матурлык эзләүче шагыйрьсең син, Ак карт!

...Әйтәм ич, комачаулаучы булмас, бала-чагаларыбыз юк. Ихатада сарык-кәҗә дә кош-корт. Җирең булмагач, сыер малы асрау кыенга төшә. Әмма күршеләребез әйбәт, алар сезне сауган шәбендәге сөттән аермас. Өйалды баскычын киң итеп кордык, авыл җыены урынындагы күперчек сыман булды. Карчыгым чисталык ярата, шул баскычны көненә әллә ничәме юып ала. Шунда аякларыгызны салындырып утырып, кичке офыкка карап уйланып, яңа сауган сөт белән сыйланырсыз. Ә кичке офыкның үзгәлекләре күп, көн буена кылган гамәлләрең шунда чагыладыр кебек. Шагыйрь кешегә болары да кирәктер.

Хезмәттән ләззәт табучы шагыйрьсең син, Ак карт!

...Безнең елга авылның буеннан-буена ике яктан да агачларга төренгән, безнең су балыклы. Балыклары яшеренә торган чоңгыллары, яр асты куышлары хисапсыз. Елгабызда кармак салырсыз, балачактагы иң зур балыкны каптыру хыялыгыз безнең авылда чынга ашачак, шунысы шиксез. Ә су коенырга урман ягындагы, басу уртасындагы Торналар күленә йөрерсез. Безнең бакча башлатып кына чыгып китә аласыз, күлгә сукмак

шуннан. Йөзек кашына төшерелгән күлнең сукмагы такыр, аннан яшьләр күп йөри. Мәхәббәт ерак араларны да якынайта, Тукай әфәнде... Габдулла энем.

Мәхәббәтне олылаучы шагыйрьсең син, Ак карт!..

Нигъмәтҗан, куллары белән күкрәген кочаклап, кыек түбәле капканың урта баганасына сөялеп, Тукайның урамга чыгуын карап торды. Хуҗа карт шагыйрьгә Торналар күле сукмагына бакча башыннан төшәргә киңәш иткән иде. Әмма Тукай күлгә сәфәрен үзенчә башларга булды.

— Ихатагыздан ук сукмакка төшәргә сез күнеккәнсез, Нигъмәтҗан абзый,— дип аңлатты ул хуҗасы сүзенә күнмәвен.— Күз алдыгызда ук сезнең эзне таптый алмыйм ич инде.

Шагыйрьнең ихластан әйтүен аңлады көмешче карт. Ул шаян кеше түгел, шатлыктан-сөенечтән һәрчак елмайса-көлсә дә, әллә нидә бер, онытылмасын өчен генә шаярта. Тукайга:

— Шагыйребезнең минем эздән йөрүе миңа мәртәбә генә булыр,— дигән җавабында шул сирәк шаяртуы да катнашкан иде.

— Шулай да.

Һәм әнә шагыйрь Торналар күленә сәфәрен олы капкадан чыгып башлый.

Басуга терәлгән койма почмагына җиткәч, Тукай Нигъмәтҗанга борылып карады, күршеләрнең ихатасы чите буйлап барып күл сукмагына төшәр алдыннан, аңа кул болгады. Ак карт шагыйрь йөзендәге бәрхәдәрле һәм шуңа күрә горур елмаюны моннан да күреп сөенде. Шагыйрь, кунакчыл хуҗасына караган уңайда, авылның түбән башында, елганың сул ягындагы чабылмый торган болында таралышучы көтүне күрде. Моннан, авылның иң биек төшеннән, вак мал бик кечкенә, сыерлар да бозаулар хәтле генә булып күренә иде. Җәйнең иң ямьле чагы, көтүнең иң иртә чыга торган чагы җиткән икән, дип уйлады Тукай.

...Торналар басу уртасындагы күлгә тыелып очып төшәләрдер дә, туйганчы су эчкәч һәм хәл җыйгач, салмак кына җилпенә-җилпенә, тагын ерак сәфәрләренә юл алалардыр.

— Хуш килдегез, торналар!..

— Сау булыгыз, торналар! Канатларыгыз талмасын!..

Һәм шагыйрь күңеленә ташудай ыргылып җырлар килде.

> ...Бер гүзәлдән кайсы шагыйрь, әйтегез, рухланмаган?..
>
> Бик юашлатты мине яшьрен сөюдән җан көю...
>
> Кайсы чакта артык шаян булып китеп...

Их, бу дөнья!..

> Бар иде, ялгыз калып, җырлап юанган чакларым...
>
> Җырлый-җырлый...

Шул чакта Тукай күлнең аргы ягында алсудан киенгән кызны күреп алды. Каян пәйда булды соң ул? Шагыйрь күл әйләнәсен җырлый-җырлый әле генә күздән кичерде ләбаса, күл тирәсендә берәү дә юк, күл өсте тыныч, корбан балыклары да ишкәк белән суга суккандагы кебек сикереп шапылдамыйлар иде.

Кыз, күлне әйләнеп, Тукайга таба килә башлады. Әнә ул атылып үсәргә әзер торган камышлар яныннан салмак кына атлый, ак яулыгын артка бәйләгән, өстендә алсу күлмәк, бала итәкле алъяпкыч. Шагыйрьгә якынаеп җитмәде кыз, туктады. Аның, шатлыктан елмайгач, бит алмаларындагы нәни чокырлары аермачык күренә, ә зәңгәр күзләрендә тирән сагыш иде.

— Габдулла...— дип яратып эндәште кыз.

Тукай өнсез иде, беравык узгач кына, ул кызга каршы бармакчы булды, ләкин кыз аңа кузгалмаска кушты.

— Кем син, гүзәл туташ?

— Мин... мин — сине яратучы кыз, Габдулла!.. Мин сине яратам, Тукаем!

Кыз күлгә турылап борылды да кулларын, акрын гына, бик салмак кына, торналар канаты кебек итеп җилпегәндәй итте.

— Таң кызы! Тукта! Китмә! Ялгызың очма! Көт мине! Бергә...

Таң кызы, тирбәлгәндәй атлап, ераклашты да ераклашты. Галәмебез үзәге кояшка тартыладыр, күккә күтәрелгәләп ала. Сул кулын шагыйрьгә хушлашып болгый. Кулларында беләзек-йөзекләр юк. Ак карт аңа ямьләнү әйберсе нигә бүләк итмәде икән? Хәер, очратмагандыр ул аны...

— Тукта, Таң кызы! Мин сиңа күл кашлы йөзек бүләк итәм! Ак карт минем аны сиңа — сөйгәнемә бүләк итүемне теләде. Таң кызы!.. Күңелем кошы...

— Хуш, Габдулла... Туктатма мине... Күл кашлы йөзек үзеңдә калсын. Күңелемне-кояшымны кара болыт капламады, бүләгеңне алмавымның сәбәбе бүтән — куркам, сине мәңгегә ак бәхетле итә алмам, дип куркам мин! Хуш!.. Хуш, ак күңелле шагыйрем минем!..

...Өч тапкыр хушлашты. Димәк, Таң кызы мине мәңгегә ялгызымны калдырып очты...

— Хуш, Таң кызы! Бердәнбер сөеклем минем!.. Кеше күңеле — үзе бер кояш! Синең мәрхәмәтле кояшың җылысын һәм яктысын мин мәңге тоярмын!..

Шулай да...

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы...

Шагыйребез Габдулла Тукай гомеренең соңгы еллары җәйләрендә туган як авылларында булмаган, димәк, ул Ак карт Нигъмәтҗан авылына шулай ук барып чыкмаган. Хактыр бу кадәресе. Әмма минем моның киресенә ышанасым килде. Хыялында гына булса да, еш кайтып йөргәндер авылларга, кайткандыр.

Ә көмешче оста Нигъмәтҗан бабай Тукай шигырьләрен яттан белә иде, шагыйрьнең тормышы турында аның белән һич аерылмыйча яшәгән дустыдай әвәсләнеп сөйли иде. Ак картны мин дә белеп калдым.

Тукай белән Ак карт калада да, салада да очрашканнардыр, дип тәкрарларга җөрьәт итәм мин. Сөйгән ярның өне өнәмле, диләр. Аз гына үзгәртәм: табынган кешең бөтен барлыгы белән өнәмле.

Торналар күлендә Таң кызын да күргәндер Тукай. Күрмиме соң?!

Тукайны ихластан олылаган шагыйрь Әхмәт абый Фәйзи сүзләре белән (гәрчә бу шигырь юллары бүтән хәлгә мөнәсәбәтле, ләкин монда урынлы килә, минемчә) әйтсәк:

Әмма никтер шушы әкияткә
Ышанасы килде...

*1986*

# *Иңә дә иңә карлар*

Урам уртасындагы кышкы юл тәмамысы такырайды. Чана эзләре көзге боздай шомарды, кояшта күзне чагылдырып ялтырыйлар. Табан эзләре арасын ат тоягы аяусыз төйгечли, бу ерымны сукмак итеп кешеләр дә таптый. Юлда гына түгел, бөтен җирдә кар утырды. Ике атна элек тәүлек буена туктамыйча — әле котырынып, аннары кинәт тыелып — яуган кар Туфаил урам коймасына сызып билгеләгән төштән бер карышка инде. Бураннан соң капка төбен әтисе белән көрәгәч, малай кар тигез яткан турыда коймага тамга салырга бот тиңентен көрт ерып кергән иде. Шунда төшкән эзләр дә җәенкеләнеп саектылар, уртадан сәлперәеп салынган әрекмән яфрагына охшап калдылар.

Салкыннар башлануга, әйе, ике атна булды. Бүген кар бөртекләренең ара-тирә салмак уйнаклавы күренгәли. Төшке уңайга сындырып җибәргән икән шул Кыш бабаң. Тукайга моны Рабига җиңгәсе, авыл сатучысыннан тәм-том алып кайтуыннан соң, икәве әңгәмәсенең ахырына табарак әйтте.

Җиңгәсенең кайтуын Тукай, капканың каты ябылуына сискәнеп, тәрәзәнең бозын кояш эреткән өске өлгесенә борылып карагач, күргән иде. Габдулла янына тиз генә кермәде җиңгәсе. Ул гел шулай инде, Тукайның тынычлыгын бозмый, Тукай ята торган кече өйгә бик кирәктә генә — җыештырырга яки ризык күтәреп кенә керә.

Рабига җиңгәсе ишекне акрын гына шакыды.

— Әйдә, Рабига җиңги...— Сөйләшмичә торудан тамагы карлыккан икән, Тукай тамак кырып алды һәм, җиңгәсе түргә

узганда, инде шактый көр тавыш белән дәвам итте.— Җиңги мине онытмагае, дип хәсрәтләнеп ята идем, иртәдән бирле күренми, дим.

— Юкка пошынасың икән лә, Габдулла! — дип, кулындагы чынаякны өстәлгә куйды Рабига.— Шагыйрьне оныталар диме инде?! Гомер-гомергә булмаганны! Китапка язмаганны! Шагыйрьне, сине, онытсалар да, нигә әле бу начарлык нәкъ менә миннән башланырга тиеш ди?! Барлык юньсезлек шагыйрьне санга сукмаудан башлана, бик беләсең килсә! Бакчы син бу Габдулла исемле егетне, миннән шагыйрьне оныттырмакчы була икән!

Тукай башын акрын гына чайкап елмайды.

— Валлаһи, Ходай тел ачкычлары биргәндер сиңа, Рабига җиңги! Кайчак сүзеңә җавап таба алмыйча аптырыйм.

— Сиңа охшарга тырышам инде,— дип, юри генә ачуланудын сиздерде Рабига.— Аннары килеп, бер нәселдән ич без.

— Бер нәселдән... бер нәселдән үк түгел.

— Әниеңнең бертуганы Кәбирнең хатыны ич мин! Сез мине кабул иткән, мин сезне үз иткән. Шулай булгач, бер нәселдән без. Бик беләсең килсә, шагыйрь Тукай нәселеннән!

— Яман да арттырдың ла, Рабига җиңги! Болай ук кирәкмәс.

— Чынын әйтәм ич! Кәефеңне кырырлык сүз ычкындырмыймдыр ич?

Тукай тагын шатланып елмайды.

— Юу-к, Рабига җиңги! Ризыкларың тәнгә сихәт бирсә, җылы сүзләрең күңел бозларын эретә. Ә күңелдә бозлар бар... Бар! Матди байлыкка гына түгел, мактауга да мохтаҗ бер җан лабаса мин...

— Менә, Габдулла, мичне томалауга үрдәк шулпасы куйган идем. Чуенда мәмрәпләр дә пешкән инде ите, шулпасы да бик тәмле микән, дим. Шушы ботны кимереп, чокырдан шулпасын йотып, минем күңел булырлык итеп сыйланып җибәр, яме.— Рабига кулларын, сабый бала сыманрак итеп, йомшак-акрын гына кушырды.— Сөбханалла, мендәреңнән чыгып очкансың ич син!

— Очты, очты, мендәр очты! Очты, очты... Тукай очты!

— Шаярта тагын! Арkaңны шәрә тактага терәп утырырга ди син, теге... ни... Кузгала төш әле!

Рабига шуышып аска салынган мендәрне иелеп алды да, аны әйләндерә-әйләндерә күперткәч, агач караватбашына сөяде, Габдулланың аркасын,ябык җилкәләреннән тотып, үрдәк мамыгыннан тыгызлап тутырылган шул мендәргә терәттерде. Аннары Габдулланың кулына кайнар шулпалы чокыр тоттырды, ап-ак үрдәк боты салган шәмәхә бизәкле тәлинкәне алдына, юрган өстенә куйды. Мич буендагы эскәмиягә утырып, авыру Тукайның бүген тәм тоеп ашавын күзәтте. Габдулла күзләрен

йома төшеп ризыгын авырдан йотып җибәргәндә, эскәмиягә ябылган палас-киезнең озын чукларын сыпырды. Бу хәрәкәте белән ул, гүя Габдулланың күкрәген сыйпап, аш йотарга булыша иде.

— Чуены белән күтәреп чөмерсәң дә туймассың бу шулпадан!

— Рәхмәт яугыры, шулай диген.

— Тик бүтән бармый. Аннары, дим, кулларның чуен күтәрергә көче җитмәстер.

— Хәлләнерсең, боерган булса. Боергандыр, кайтканда, бигрәкләр дә ябык идең. Сине беренче күрүем иде ич, аптыраплар да калдым. Яшермим. Нигә яшерим ди? Син үзең миннән бер сереңне дә яшермисең ич, туры сүз яратасың ич син. Кәбир абзаңның безнең Тукай кыска буйлы, чандыр, дип әйткәне булса да, ышанмый идем. Язганнарыңны укыгач, каршыма гел дә бер пәһлеван булып килеп баса идең. Алпамшаның үзе инде менә! Дошманнарыңны, малайлар тәтәй чөйгәндәй, күкләргә очыртып кына җибәрәсеңдер кебек! Ир җаны хатын-кыз каравына мохтаҗ шул, син андый иркәләүне татымаган шул... Савыгырсың да өйләнерсең, Аллаһы боерса! Хәзер, сөбханалла, тулыгаеп барасың. Күз генә тимәсен.

Җиңгәсенең өйләндерү теләген турыдан кире какмады шагыйрь.

— Белмим шул,— дип сузып кына моңайды ул. Күзләренә томан пәрдәсе төшеп алды, кинәт кашларын сикертеп күзләрен киң ачкач, йөзенә сабыйларча өмет елмаюы җәелде. Ләкин Тукай сүзне бүтәнгә күчерде.— Нигәдер авыл хәлләрен сөйләмисең, җиңги. Әллә хәбәрләр алып кайтмадың инде?

— Кибетче янында яңа хәбәр булмый диме соң! Сатучының товарыннан да күп инде андагы яңалыклар. Очраган берсе синең хәлеңне белешә, савыгамы, диләр. Сәламәтлеге әйбәтләнә, гәүдәгә тулылана, дим. Шигырьләр чыгарамы, диләр. Әлегә элек язганнарын укып торыгыз, Тукайның шигырьләре, каткат укысаң да, төсен бирми, дим.

— Менә яңаларын да язам.

Тукай баш очындагы шүрлектән кәгазь-каләмен кайшалып үрелеп алды. Рабига, шагыйрьгә бик күп язып өзлегеп китмәскә киңәш итте дә, урам-кибет хәлләренә әйләнеп кайтты.

— Нигә кеше арасына чыгып йөрми, диләр. Безнең ише халыкны үзсенмәведер, диләр. Нишләп Тукай халыкны иш итмәсен, дим, халыкны якын иткәнгә халык шагыйре бит инде ул, дим.

— Мактауга яман да юмартланып киттең әле син бүген, җиңги! Илла күпертеп тә җибәрәсең!

Әмма Рабига үзенекен тезәргә көйләнеп җиткән иде инде.

— Язасы шигырь-җырлары сәламәтлеге какшап торган арада ифрат та күп җыелган, дим. Аннары бу салкыннарда үзебез дә

чыгарга кушмыйбыз, дим. Күрче мине, кирәген әйтергә онытып торам ич — көнне сындырган бит! Әллә, Габдулла, дим, урам тирәсеннән әйләнеп керәсеңме соң бер? Бөтенләй җылыткан менә көнне!

— Хәйләкәр дә соң син кайчак, җиңги! Әмма ки әйбәт хәйләкәр! — Тукай баш астына кулларын куйган иде, учларында башын чайкалдырды.— Үзеңнең миңа кышның салмак чишмә суыдай агылып торган тыгыз һавасын да сулатасың килә, ә үзең, кибетчедән кайтканда киемеңә сеңгән суыкны теге өйдә эретеп бетермичә, минем янга да кермәдең, миңа салкын эләктерүдән шикләндең. Шулай бит!

Рабига, кибеттән кайткач, теге өйдә озак булашуы хәйләсе тотылуына ык-мык итеп тормады, җавабы, балалар бәхәсләшкәндәгегә охшап, авызыннан очып кына чыкты.

— Шулай да, шулай да түгел!

Җиңгәсенең кырт сүзләре Тукайны сискәндерде, әллә ачуландырдым инде, дип шөбһәләнеп уйлады шагыйрь. Рабиганың кәефен кырырга һич тә ярамый, авыру Тукайны бу кышта доктор кебек булып сихәтләндерергә тырышучы, Тукайның үзенә бер өйдә күңелен ялгызландырырга ирек бирмәүче шушы Рабига иде. Шуңа күрә үз янына җиңгәсе керүен көтеп ала, аның белән ачылып һәм бераз иркәлеккә бирелеп сөйләшүдән җанына рәхәтлек таба иде шагыйрь. Олы дөнья белән беренче чиратта җиңгәсе аша бәйләныш тота иде шагыйрь, бу аралашуда хәтта абзыйсы Кәбир дә арырак тарафта тора иде. Тукай Рабиганың күзләрендә ачу галәмәте күрмәде, хаста кунагын дөнья белән бәйләгән кылны өзмәячәк икән җиңгәсе, шунысына шөкер. Рабиганың сүзләренә җавап кайтармады шагыйрь, бераз күтәрелә төшеп, түр тәрәзәнең бозы эрегән өске өлгесе аша урамга карады.

— Боерган булса, бүген урамга чыгарырмын мин сине,— дип, сүзен шулай ук кырыс дәвам итте Рабига. Аннары аның тавышында йомшару илә көчәю алышынып торды.— Абзаңның тунын киярсең, мич башында киез итекләр җылыга тәмамысы туенган. Өс-башың да бигрәк юка шул синең. Сез, кала кешеләре, тән җылысының кадерен белмисездер, шуны белсәгез, зәмһәрир суыкта күлмәк-ыштаннан гына дигәндәй йөрмәс идегез.

Тукай урамны текәлеп күзәтә, җиңгәсенең үз итеп битәрләвенә изрәп төшми, шулай да аның сүзләрен колак яныннан уздырып та җибәрми.

— Каланың да урамнарын кышын учак ягып җылытмыйлардыр лабаса. Таш салкыны да өстәлеп, анда кыш бабай яманрак та куырадыр.

Шагыйрь кискен хәрәкәт белән торып ук утырды, юрганы күкрәгеннән шуып алдына бөялде.

— Әнә кайта!

— Баядан бирле күзләреңне урамнан алмыйча кемне күзәтәсең соң син? — диде Рабига һәм тәрәзә каршына ук барып басты. Тәрәзәне Тукайга каплавын абайлап, тиз генә читкә тайпылды.— Габдулла, рәхмәт яугыры, әллә берәрсенә гашыйк булдыңмы? Алай дисәң, урамда сабактан кайтучы бала-чагадан бүтән кеше күренми. Әллә өйләндереп үк җибәрербез микән соң үзеңне, Габдулла?

— И-и хыялый да соң син, җиңги...

— Алай каршы төшмә, кулыңны да селтәмә! Безнең Өчиле кызларының эшкә уңганлыкларын, төскә чибәрлекләрен, сүзгә осталыкларын белсәңме — сайлап тормыйча да өйләнәчәксең берсенә!

— Өйләнү миңа язмагандыр, җиңги...— Тукай ике кулына да таянды. Аның йөзенә чыккан моңсулык, кинәт елмаеп җибәргәч, югалды.— Соң, шул балаларның мәктәптән кайтуын көтеп алып күзәтәм ич мин! Җиңги, текәлебрәк кара әле: кайсысын ныграк яратыр идең икән син аларның?

— Кайсысын аерып аласың ди? Аларның барысы да бер иш миңа.

— Түгел!! — дип, имән бармагын бастырып, уң кулын каршысында селтәп торды Тукай.— Гәүдәгә-буйга бер чамада булсалар да, күңел байлыклары иш түгел, күңелләренең аермасы зур аларның! Күрәсеңме, кайберләре китап-дәфтәрләрен киндер букчаларына салып җилкәләренә аскан, икенчеләре култыкларына кыстырган. Ә берсе әнә сабак әсбапларын ашъяулыкка төргән дә күкрәгенә кыскан. Аларны икмәк кебек итеп кадерләп ашъяулыкка төргән! Букча тегәргә суккан киндерләре булмаудан түгелдер. Китап-дәфтәр төрергә башка әйбер дә таба алырлар иде. Әмма алай итмәгәннәр бит. Мондый нечкәлекне аңламыйча эшләгәннәрдер, дисеңме? Ихтимал анысы. Ләкин ашъяулык сайлануы хакыйкать. Сабак әсбапларын күкрәгенә ипи итеп кыскан, алардан шулай итеп тә күкрәгенә җылы аладыр ул... Җылы, җиңги, кайры тунда вә киез итектә генә түгел...

— Шул Туфаилне әйтәдер, дигән идем аны,— дип юашланып калды Рабига.— Тәмамысы әллә кем булган шул Туфаил! Мактанчык...

— Нишләп мактанчык булсын ул? Мәктәпкә кергәч, мин аның белән сөйләшкәләдем. Үз яшеннән өстәрәк булып, алган белеменә таянып сүз йөртә, фикерен төптән каерачак, киң итеп каерачак малай ул. Хәзердән үк җете фикерле Туфаил! Ышанып әйтәм мин моны!

— Мактанчык булмый ни! Үзеңә әйтеп кәефеңне җибәрмәм, дигән идем. Әле кибетче катында сөйләп тордылар: Тукайның үзен шигырь сөйләүдә көч сынашырга чакырачакмын, дип, ишләренә мактанган, ди, шул Туфаил.

— Шулай дигәнме?! — Тукайның көрәш сөенеченнән йөзе яктырып, кәефе күтәрелеп китте.— Менә шәп! Җиңги, син бит әйбәт җиңгием минем, шулай булгач, без болай килешик. Көнне җылыта төшсә дә, мине җылы тун вә киез итекләр көтсә дә, мин бүгенгә урамга чыга алмыйм. Хәл юк. Бер йомышымны тыңлачы. Болай итик, син Туфаилнең үзен безгә чакыр! Тукай абыең көтә, диген. Шигъри мәйданда көч сынашырга, диген... Юк, монысын әйтмә.

— Син үзең дә бер сабый җан инде, Габдулла...— дип ризалашты Рабига.

— Җиңги, дим, кара әле, күр әле Туфаилнең нишләвен! — дип, чокыр-тәлинкә күтәреп чыгып баручы Рабиганы кире борды Тукай.— Кар күп яугач, шуның биеклеген коймага тамгалаган иде, хәзер инде карның тыгызланып ни хәтле иңүен карышлый. Гомернең агышын тоя Туфаил!

— Кешенең печтик кенә шөгыленә дә истә-уйда юк бәя биреп куясың син, Габдулла. Кайчакта синең сүзләреңә аптырыйм да калам. Теге почык борынын әйт инде син аның, нәрсә уйлап йөри икән бит, ә...

Туфаил, көрткә башлап үзе төшергән, ике атнада хәйран саеккан эзләргә аякларын яннан каерыбрак салып, капка алдына чыкты.

Тиздән Рабига шул кечкенә Туфаил каршына даны таралган шагыйрь йомышы белән керәчәк.

Ә Тукайга күңелендә көрәш дәрте уяткан Туфаил белән очрашырга ныклап әзерләнергә, яшь дусты алдына күңел сыен мулдан куярга кирәк иде.

Шагыйрь мендәргә аркасын терәде, юрганны күкрәгенә тартып япты, кулларын башы астына куйды да, күзләрен йомылыр-йомылмас кысып, уйга чумды.

Туфаил — нык тормышлы авыл агаеның төпчек малае. Аның әти-әнисе тигез, абыйсы һәм уртада ике апасы бар. Абыйсы, авылның ибтидаи мәктәбендә укырга-язарга өйрәнгәч, крестьян хезмәтенә артыгы кирәкмәс дип, ары укымады. Әти-әнисе дә кыстамадылар, олы баланың кул астына иртә керә башлавы хуҗалыкны бөтен тотуда зур ярдәм иде. Апалары абыстайда сабак алдылар, алар чит ояга утырасы кошлар, читтә беренче чиратта эшкә уңганлыклары белән сыналачаклар. Шулай булгач, бу юлы инде кыз балаларга абыстай биргән китап белемен әти-әнисе җиткәнгә санадылар. Хәзер кызлар да хуҗалыкны тагын да бөтенәйтүдә тырышалар — ата-ана балаларының игелеген әле үзләре көчтә чагында ук күрә башлады.

Туфаилне исә әти-әнисе дә, абый-апалары да, мәктәпкә кергәнче үк хәреф танытып һәм алу-кушу гамәлләренә өйрәтеп,

зур укымышлы кеше итәргә җыеналар. Малай моңа сөенә, өстәвенә ул тырыш һәм һушлы. Шулай да Туфаил гел китапка гына ябышып ятмый, әтисе аңа кечкенәдән үк көче җитәрдәй эшне кушып тора, хезмәткә мөнәсәбәттә җилле тота. Зур галим булгач, иген игүдән бизсәң дә, тырма тырмалауларың сагынып сөйләргә хатирә булыр, ди. Дөрес фикерле.

Ишектән керүгә тукталды Туфаил, шагыйрьгә башын иеп сәламен бирде. Тукай аны үз янына чакырды, күрешергә кулын сузды. Малай карават янәшәсендәге артсыз урындыкка утыргач та, аның кулын җибәрмичә торды, тәненә Туфаилнең кулыннан рәхәтлек агыла иде — баласын сөюдән ата шундый ләззәт табамы икән әллә?!

— Сагындырдың, Туфаил... Кермисең. Көтәм бит.

— Сезгә борчу ясау булыр, димен, Тукай абый.

— Ниткән борчу булсын ди?! Минем яңа язган шигырьләрем дә бар бит, шуларны сиңа укыйсым килә, Туфаил.

— Укыгыз, Тукай абый.

Һәм Тукай Туфаилгә шигырьләр укыды, малай аларны игътибар белән тыңлап, күңеленә сеңдереп барырга тырышты.

Тукай шигырьләрен укып бетергәч:

— Ә беләсезме,— дип кинәт җанланып китте Туфаил,— без сезне мәктәптә бик еш искә төшерәбез! — Ул түбәтәен арткарак этәрде, камзулы иркенләп сөйләшүдән тыеп торадыр кебек тоелды, аның төймәләрен кабаланып ычкындырды.— Тик мәктәпкә килми башладыгыз. Шигырьләрегезне мәктәптә дә шундыен да матур итеп укыган идегез сез — тыңлап рәхәтләндек. Без сезнең барлык-барлык шигырьләрегезне дә ятлыйбыз да, үзегезне чакырып, сөйләп күрсәтәбез әле! Сезнең шигырьләрегез йөрәккә сеңеп тора, алар, улагын тутырган чишмә булып, күңелгә агыла. Мин сезгә, беләсезме, кайсы шигырегезне сөйлим? «Су анасы»н. Юк, аны түгел. «Кәҗә белән сарык хикәясе»н. Анысын да түгел икән лә! Аларын да сөйләрмен, соңыннан.— Ул аягүрә басты.— Элгәре мин сезгә «Шүрәле»не сөйләп күрсәтәм:

Нәкъ Казан артында бардыр...

Каршысында Тукай барлыгын онытты бугай Туфаил, Кырлай урманында Былтыр белән Шүрәлене менә хәзер тәгаен күреп торган кебек итеп, шигырь сөйли ул. Монысын сөйләп бетергәч — Тукай мактарга да өлгермәде — икенчесен башлады:

Сөялгәнсең чатта баганага...

Хәзер инде Туфаилнең карашы идәнгә төбәлгән, кашлары җыерылган, тавышы калынайган иде. Дөрес сайлыйсың, Туфаил энем, һәр сәтырда көлке булмый, дип уйлап алды Тукай.

Аннары Туфаил тагын яңа шигырь башлады. Аннары тагын... Тагын... Аннары шигырьләр сөйләвеннән туктады да — Тукай сүз әйтергә янә өлгермәде — шагыйрьгә сөенечле хәбәрен ирештерде:

— Тукай абый, беләсезме, бер кичне мин ай яктысында чана шуарга чыккан идем. Тау башына килеп җиттем генә — сезнең шигырьләрегез исемә төшәргә тотынды. Берсен-берсе узышып хәтергә төшәләр менә! Һәркайсы мине сөйлә, мине сөйлә, дип кабатлыйлар кебек. Тау кашына бастым да сезнең шигырьләрегезне сөйләдем. Пышылдап кына сөйләдем. Шулай да минем сөйләвемне бөтен җиһан ишетеп торды кебек. Беләсезме, Тукай абый, сезнең шигырьләрне ай да тукталып тыңлады... Тукай абый, сез тизрәк савыгыгыз, яме. Аннары мин сезне таудан чана шуарга алып барам. Их-х, икебез бер чанага утырабыз да бураннар очыртып шуып китәбез!.. Аннары минем сезнең белән басу юлыннан җитәкләшеп барасым килә. Тик анысын җәйгә калдырабыз, яме, сез җәй көне дә безнең Өчилегә кайтырсыз, яме. Ике якта да арышлар башакларын иеп утырганда, басу юлы шундыен да сихри була — адымың саен шул серлелек нигәдер көчәя дә көчәя... Тукай абый, сезнең белән бергәләп, ак пароходка утырып, Иделдә йөзәрбез, яме. Идел зур, диләр, киң, диләр... Тукай абый, бик күп еллар узгач, мин дә олыгаеп чәчләремә чал утыргач, сезнең каршыгызга килермен дә, «Туган тел»не чатнатып сөйләрмен! Яме, Тукай абый?!

Туфаил, Тукай яныннан чыккач, үз йортлары капка төбендә бераз йөренде. Коймага карның биеклеген сызып билгеләде, ә мәктәптән кайтканда, карышлап кына караган иде.

Нигә икән? Әллә... Әллә, Тукайның хәлен күреп чыккач, гомернең сыза баруын билгеләве булдымы Туфаилнең?

Иңә дә иңә карлар. Кеше гомере дә аяусыз иңгән кар кебек сыза барамы?

Әй-й, ямьсез уйларга бирелмикче! Матур уйлар да күп ич! Әнә Тукайның изге күңелле Рабига җиңгәсе бар, шагыйрьне ул беркайчан да онытмаячак! Туфаил дә Тукай абыйсын мәңге-мәңге онытмаячак!..

Тукайның Өчиледә чагы иде бу. Мең дә тугыз йөз уникенче сәнәнең гыйнвар ахыры иде.

*1987*

# Кулаклар колхозы

Юртай авылы малайлары, сабан чәчүе беткәч, атларны Ерак Елга үзәненә төнге көтүгә алып чыга иде. Борын заманнардан килгән бу рәхәт хезмәт печән өстендә тукталып тора да уракка төшкәнче тагын дәвам итә. Атларның бергә көтүгә китү-кайтуы бөтен авылга шатлык иде.

Быел исә, кырда язгы эшләр беткәч, төнге көтүгә чыгучы атлар нибарысы унике баш калды, унике аерым хуҗалык атлары. Кичен һәм иртән кабатлана торган җәйге бәйрәмнең көтмәгәндә кечерәюе Юртайның уйлы кешеләрен пошаманга салды — мал авызына йозак элү адәмне ачка интектерүгә китерәчәк ләбаса!

Кичә исә авыл власте башында торучылар төнге көтүне бөтенләй тыйдылар. Юртайга Бикмураев дигән вәкил килеп төшкән икән, бик усал кеше, ди, төнге көтүне туктату турында шул вәкил башлап әмер биргән.

— Калхуз җирләрендә аерым хуҗалык атлары йөрмәскә тиеш! — дип, аяк тибеп кычкырган Бикмураев.

Бәйрәмхан, шул хәбәрне ишеткәч, Бикмураевны яман сүзләр белән сүгеп ташлады.

— Атасының...— Гражданнар сугышында берсеннән-берсе хәтәр сүзләрне өзлексез тезәргә өйрәнгән иде ул. Ярый ла бу гадәте яу кырында калды, тик сүгенүне Бикмураевның әмере янә теленә салды. Хурлап тиргәүдән бераздан туктады ул. Шулай да сүгенүе сүрәнәеп бетмәгән иде.— Ананның... Аякларың башыңа уралгыры! Һич югы — күн итегеңнең табаны купкыры!

Вәкилнең әмеренә каршы дәлилләр эзләргә кереште Бәйрәмхан һәм, үзенчә, тапты да: колхоз атларын да төнге көтүгә алып чыксыннар соң, җәен ат малын утарда тоту чеп-чи ахмаклык ләбаса. Юртай җирләрендә гомер-гомергә уртак файдаланылган көтүлекләр җитәрлек, аларны колхозныкы иткән игълан яңгырамады әлегә, бәлки, киләчәктә мондый хәл дә булыр, ә хәзергә көтүлекләр — авылныкы, без томана затлардан түгел, җирнең кемнеке булуын беләбез, вәкил агайне; аннары да килеп, безнең Юртай малайларының авылны яратуын аңышмыйсыңдыр син, вәкил кеше, минем Корбәтне төнлә ат көтү бәхетеннән мәхрүм итәсең... Әмереңнең шундый аяныч якларын уйлап бак!..

Начар йоклады Бәйрәмхан. Сискәнеп уяна да Бикмураев белән күңеленнән сүз көрәштерә. Вәкилне егып салган кебек була да тагын йокыга китә. Тик авылга таралган яңа хәбәр һәм Бикмураевның үз әмерен кире алмавы аны тагын куркындырып уята.

Инеш буена төнгә җибәргән атлары янына өч тапкыр төшеп менде Бәйрәмхан. Кара бия өчен борчылды, колын алып кайтыр чагы җитә, аны төнге көтүгә быел чыгармаган иде, кичә, атларын инеш буена гына җибәрәсе булгач, буаз бияне дә иярткән иде. Абзарда тотасы калган икән, дип уйлады ул, әмма инеш буена төнлә төшүләрендә бияне алып та менмәде, төнге көтүне сагынгандыр, быел бөтенләй йөрмәде, яшь колын белән Ерак Елга үзәненә җибәреп булмаячак, аннары ат көтүен тыйды бит теге... аты киткере вәкил, дип фикер йөртте һәм, таң атмастан, бөтенләй үк торды Бәйрәмхан.

— Син йокла, иртә әле,— дип пышылдады ул кузгала башлаган хатыны Хуриягә.— Балалар уянмасын. Икәүләп йөрергә тотынсак, теге өйгә дә ишетелер, эти белән энигә дә тынгы бирмәбез. Минем йокы качты.— Тукталып торды да: — Нишләптер...— дип өстәде.

Ишегалдында йөренә торгач, башына мондый уй килде — Бикмураев әмеренә каршы фикерләрен аның үзенә барып әйтергә булды. Вәкилгә әйтәсе дәлилләре турында, тезләренә таянып, башын тотып, баскычта кабат уйланып утырды.

Хуриянең:

— Сиңа әйтәм, самавыр кайнады, чәй эчеп алыйк,— дигән сүзләре аның аңына тиз генә барып җитмәде. Хатыны: — Бәйрәмхан, чәй ясадым, әйдә, чәй эчәбез,— дип кабатлагач кына уйларыннан бүленде.

— Син дә тордыңмыни? Йоклыйсы идең, миңа карамаска идең.

Ире торганнан соң авыл хатынының йоклап ятмаячагын искәртмичә әйтелде бугай бу сүзләре; әллә гаилә тынычлыгын бозуга үзен гаепле санадымы шунда — шәт, шулайдыр.

— Ни, Хурия, бар, Корбатне уят.

— Баланың таң йокысын бүлдермик. Ашыгыч эш юк ич.

— Уят! Атны алып менәр. Алашаны. Биясе йөрсен, тынычлыгын бозмыйк, тиздән уйнак колын алып кайтыр, шулай боерган булыр, дим.

Бәйрәмхан Коба алашаны һәм Кара бияне инеш буена кичтән тышаулап җибәргән иде. Аңардан күреп, колхозга кермәгән тагын өч кеше атларын төнгә шунда төшереп тышаулады. Берсе Хуриянең абыйсы Шәйхетдин иде.

Чәй эчелде. Бәйрәмхан аның тәмен тапмады. Тугыз яшьлек малае Корбәт Коба алашаны атланып алып менде. Йокысы ачылыр-ачылмас иде малайның, йөгәнен салдырып атны ишегалдына җибәргәч, өйгә кереп түшәгенә чумды, атның нигә иртүк кирәк булуы белән кызыксынмады — йокы тәмлерәк. Әтисе атка яңадан йөгән кидереп, аны тезгененнән җитәкләп капкадан чыкканда, малай йоклый иде инде. Ә Бәйрәмхан Коба алашаны урам уртасына төшерде, авыл советы һәм колхоз кән-

сәләре урнашкан элекке каравыл өенә таба китеп барды. Күршесе, хатынының абыйсы Шәйхетдин ул узганда урамга чыгып тамак кырган иде — туктамады Бәйрәмхан, ишетмәгәндер. Шәйхетдин дә колхозга кермәгән һәм керер исәбе дә юк. Авыл башлыклары кәнсә дигәннәренә чакыртып әгиткә керешкәч, аларның сүзләрен тыңлап та бетермәстән:

— Кыек эшкә тотындыгыз,— дип әйтеп салган иде Шәйхетдин.— Көчли башладыгыз. Хәтерегез тишек-тошык. Бүтән чакта Ленинны мисал итәсез, ә хәзер нигә аның әмерен онытасыз? Крәстиәнгә мөнәсәбәттә көчләү кулланырга ярамый, дигән идеме Ленин? Шулай тәгаенләп әйткән иде. Бу фикере турында ныклап уйлагандыр бит ул. Мин әле дә Ленинга ышанам. Ә сез аңа ышанмыйсыз. Бәлки... Эһем, эһем...— Ул, читкә каеруын әллә инде турыдан юл сабып та моны белгертергә ярамавын аңлап, тотлыгып торды.— Минем кендегем җиргә береккән, ә сез мине калхузга тыгып җирсез калдырырга ниятлисез. Калхузга башлап кем керде. Ярлы-ябагай. Эрвәлүтсия булып унөч ел узгач та үзләренә бирелгән җирнең файдасын күрергә, кадерен белергә иренгән булдыксызлар, калхузга сыенып, эшләмичә тамак туйдыру җаен эзлиләр. Ә сез шундыйлардан яңа бер изүче сыйныф әвәләмәкчесез — Ленин бетергән изүче сыйныф урынын буш тотмаска исәбегез. Үкенечкә каршы. Мине кыеш әгитегезгә бүтән дәшмәгез. Мине кулак ясап куу белән дә өркетмәгез. Эрвәлүтсия биргән җирнең файдасын татып яшәвемне беләсез. Акны кара дип атый алмассыз. Вөҗданыгыз булса. Сау булып торыгыз...

Кәнсәдә бу сөйләшү кичә булган иде. Вәкил булып килгән Бикмураевны күрмәмешкә салынды Шәйхетдин, сүзләрен авыл башлыкларына төбәп әйтте. Шушы кискенлеге турында Бәйрәмхан белән сөйләшүне иртәнгә калдырган иде ул. Тик өлгерә алмады, Бәйрәмхан атын җитәкләп каядыр китеп барды әнә. Инде тыкрыкка борылды, кычкырып туктатырга соңрак, хәер, авыл тынлыгын бозып таңнан сөрән салу да килешми. Кияүне әйтәм, Бәйрәмханны, дип уйлады ул, кояш күтәрелмәстән ат җитәкләп урам йөри, тагын ни әкәмәт кылмакчы икән, ат көтүен туктаттыруга үзенчә баш күтәрүедер, кирәкмәсне майтарып ташлавы ихтимал кызыш җанның. Һай, кияү балакай, синең холкыңа түзеп яшәгән сеңелгә чыдам бирсен, шөкер, җаеңа төшенде, шуңа акылы җитте, безнең нәсел шул, сеңелне әйтәм, Хурияне әйтәм...

Нәселен акыллы санауда мактанып җибәрүе булса да, хак иде бу, нәселгә бирелгән «Акыллы» кушаматы Шәйхетдиннең бабасыннан ук килә иде. Нәселнең һәр кешесенә шушы кушамат тагыла бара: Акыллы Шәйхетдине, Акыллы Хуриясе; Шәйхетдиннең балалары да шушы кушаматны йөртәләр, боерган булса, балаларының балалары да мактанычлы кушаматтан йөз

чөермәсләр. Ә Хурияне... Туктагызчы, Хурияне хәзер Акыллы кушаматы белән атамыйлар икән ич, әй. Кияүгә чыкканнан бирле ул Бәйрәмхан Хуриясе булып китте ич. Алай, нәсел кушаматы ир затларында гына нык саклана шул.

Кушаматы белән мактанып куярга яратса да һәм кияве аңардан ун яшькә кечерәк булса да, Шәйхетдин Бәйрәмханны үзеннән акыллырак саный, шушы көчне тануы ук аның акылы нык булуны аныклый. Кичә ул, колхозга димләүче авыл башлыклары һәм вәкил Бикмураев белән бәхәс тотканда, Бәйрәмханнан ишеткән дәлилләрне дә китергән иде. Изүче яңа сыйныф ясалырга торуы да — кияве сүзләре. Бикмураевның, бу турыда ишеткәч, колаклары тонып, күзләре акайды бугай, дошманына ташланырга җыенган ерткычтай үкереп куйды, әмма Шәйхетдин аның ягына борылып та карамады. Кәнсәдән кайтуга кирәсе калган икән дә бит Бәйрәмхан янына, соң иде шул. Шәйхетдинне кәнсәгә төн урнашкач кына чакыртуы вәкилнең хәйләсе булган икән, Бәйрәмхан белән киңәшергә вакыт калдырмый ягъни, аннары иртүк Бәйрәмханны дәштерә — әнә бит, таңнан аяк киенгән кияү балакай, вәкил катына барышыдыр.

— Имансыз! — дип, вәкил Бикмураевка хәзер генә тәгаен бәясен чыгарды Шәйхетдин.

Ә Бәйрәмханга авыл башлыкларының җыелуын көтәргә туры килмәде, алар кәнсәләрдә иде, озын эскәмиягә тезелешеп утырганнар, каршыларында берәү йөренә — вәкил шул булыр, авылныкы түгел, уң кулын селтәп сөйли, сүзләрен аңлап булмый, ачык тәрәзәдән күн итегенең шыгырдавы сүзләренә караганда аныграк ишетелә. Атын бәйләгәч, кулларын бер-берсенә кагакага, баскычка таба атлады Бәйрәмхан. Шыгырдавык ишекне каерып ачты, эчкә тиз генә кереп, юка киез эшләпәсен салды.

— Әссәламегаләйкем!

Авыл башлыклары — авыл советы һәм колхоз рәисләре, авыл советы сәркатибе һәм колхоз хисапчысы — аның сәламен алдылар, алар каршында басып калган таныш түгел кеше эндәшмәде. Бәйрәмхан аңа атап кына сәламләвен кабатламады. Бикмураевны башта җентекләп күздән кичерде, аннары аңа туры карап:

— Мин шушы Юртай авыл крәстиәне Уразман улы Бәйрәмхан булам,— диде. Тавышы тыныч иде.— Сине кем дип белик?

— Ә-ә, син буласыңмыни авылның кулаклар башлыгы?! — дип, кулларын җәеп алды Бикмураев. Сөенә иде ул, әйтерсең көтмәгәндә мул хәзинә тапты, әй.— Нәкъ сине чакыртырга тора идем.

— Мин үземне, Юртай крәстиәне, дидем. Мин кулак түгел. Шулай булгач, кулаклар башлыгы да була алмыйм.

— Ха! Кулак түгел, ә?! Нигә, алайса, кулак булмагач, калхуз-

га кермисең? Күмәк хуҗалыкка. Нигә башкаларны күмхуҗга каршы котыртасың?

— Котыртмыйм. Тукта, шулай да сине кем дип белик?

— Бик беләсең киләме?

— Әдәпсез кыланасың.— Бәйрәмхан тәрәзә янына барды һәм: — Әнә күрәсеңме? — дип, урамга ишарәләп сорады.

— Нәрсәне?

— Ат башын!

— Сүгенмә, кулак калдыгы!

Авыл башлыклары, урыннарыннан сүзсез генә кузгалып, ишек катынарак елыштылар, өй түрендә, ачык тәрәзә каршында, Бәйрәмхан белән Бикмураев кара-каршы басып калдылар.

— Күрәсеңме, дим?!

— Күрәм, ди. Шуннан ни булган?

— Җан иясе ул. Ашарына кирәк. Сорап ала алмый. Нигә төнге көтүне тыйдың? Безнең Юртайга нигә хуҗа булдың әле син?

— Ә-ә, менә нәрсәдә икән дәгъваң! Тыйдым, ат көтүен мин тыйдым, кулак атларын көтүне! Чөнки миңа, калхузцентр вәкиле буларак, шундый вәкаләт бирелде, күмхуҗга кермәүчеләрнең мал-терлеген көтүгә чыгармаска кушылды. Сыер-сарыкларыгызны да көтүгә чыгартмам!

— Анысы булмас! — дип кычкыруын сизмичә калды Бәйрәмхан.

— Булдырырмын! Әлегә менә бу җебегәннәрегез,— Бикмураев авыл советы рәисе һәм сәркатибе, колхоз рәисе һәм хисапчысы ягына баш какты,— каршы төшеп маташалар. Авылдашларын рәнҗетергә теләмиләр, имеш! Ярлы калхузчыны кулактан аерырга башлары җитми.

— Алай калхузүзәктән үк килгәнсең, инде дә бик белдеклесең икән, әйтеп бир — мин бу атны нәрсә ашатып асрарга тиешмен?

— Үз җирендә үстергәнне ашат!

— Чирәм күпереп үскән чакта атка бодай ашатыйммы? Аннары минем ашлыгым да яңа җиткәнчегә таман гына. Бүгениртәгә колынларга торган биям дә бар. Анысы төнге көтүгә быел йөрмәде.

— Ике атың бармы?!

— Ике атым бар. Кара бия исән-сау колынласа, ат малым өч баш булыр.

— Сез, булдыксыз җаннар! — Бикмураев авыл башлыкларына борылып кычкырды.— Нигә әйтмәдегез аның ике аты булуын? Сез үзегез кулак тегермәненә су коясыз икән монда! Үзегезне шушы кулак белән бергә сөрергә кирәк сезнең!

— Маңгайга тамга сугарга әвәс икәнсең, калхузүзәк,— диде Бәйрәмхан һәм, эскәмиянең урта төшенә утырып, сул аягы-

ның чабата киндерәсе башына эләккән чалбар балагын төшерде, кыска кара чәчләрен алга сыпырды, шулар яткач, озынча йөзе түгәрәкләнә төште.— Тамганы, көтүдән кайтканда адашкач, табып аерыр өчен, гадәттә, сарыкка гына сугалар. Ә мин — кеше! Алар да,— дип, авыл башлыклары ягына учларын җәеп күрсәтте. Куллары зур, йонлач иде, күлмәк җиңнәре тартылгач, беләкләрен дә куе йон каплаганлыгы күренде.— Ләкин хәзергә син минем белән генә сөйләш. Ә сез,— дип, авыл башлыкларына тагын карады ул,— чыгып торсагыз да була, үз хуҗалыгыгызда эшегез бетмәгәндер, инде калхузыгыз эшенә тотынырга да вакыт, кояш калка, күмхуҗга кергән кешенең дә эше крәстиән хезмәте булып каладыр, шәт. Югыйсә төн йокламыйча каравыл өе саклаган кыяфәтегездән авылдашлар куркып качар.

— Бар, кайтыгыз,— дип боерды авыл башлыкларына Бикмураев, үзе кулак дип атаган Бәйрәмхан тәкъдименә ризалашуын абайламыйча калды.— Озак юанмагыз. Миңа май яккан бер-ике телем икмәк, шешәгә тутырып чәй алып килерсез.

Бәйрәмхан, башын чайкап, зур елтыр күзләрен уйнатып алды да, авылдашлары ашыгып чыгып киткәч, көлемсерәп әйтеп куйды:

— Фатирга төшәргә дә вакытың булмаган, ахрысы.

— Кая вакыт ди сиңа! Эш муеннан! Һәм ашыгыч!

Бикмураев өстәл артындагы урындыкка утырды, учлары белән йөзен сыпырды, кул аркалары белән батынкы күз төпләрен озаклап ышкыды, авызын учы белән каплап иснәнде. Кинәт җилкәләрен кызулап селкеткәләде һәм кулларын селеккәләде, бераз тыныч торды. Аннары болай да юка иреннәрен кысты, бөгелмәле кашларын — сәер, мондый нечкә кашлар ирлек кыяфәтен хәйран боза иде — җыерды, батынкы күзләре ярдагы янәшә кош ояларына охшап алды. Аның хәрәкәтләрен күзәтеп утырган Бәйрәмхан, йөзендә иман юк моның, дип уйлады, йөзе... кырт кискән яр сыман.

— Җебегәннең дә җебегәннәре синең авыл башлыкларың! Йөз хуҗалыклы авылда калхуз төзеп бетерә алмасыннар инде, йә!

— Минекеләрме? Калхузга җитәкчелек итәргә алынучыларына мөнәсәбәтем юк. Ә авыл советы башлыкларын мин дә сайладым. Илдәге властька каршы түгел мин. Каршы була да алмыйм, чөнки эрвәлүтсия куйган власть астында рәтле яши башлаган кешемен. Мин өйләнгәч кенә атлы булдык без! Ат... Ә, әйе, мин төгәллекне, дөреслекне яратам. Шулай булгач, әлеге тагын бер нәрсәне искәртим: Юртайда йөз түгел, ә йөз дә сигез ихата бар. Пужумнар юк, авыл зураюга бара.

— Шул йөз дә сигезнең уникесе — тач кулак хуҗалыгы. Тоташ күмәкләшүне шулар тоткарлый. Һәм алар синең коткына бирелгән!

— Алар кулак түгел. Әйткәнемчә, мин дә кулак исәбенә кермим, вәкил агайне, эрвәлүтсиягә чаклы безнең гаилә ярлы иде.

— Менә, менә синең авыл башлыкларың да шуны тукый!

— Хак әйтәләр. Унике хуҗалыктан кулак буларак сөрелерлек бер генә кеше дә юк. Эрвәлүтсиягә чаклы хәлле саналганы — авылыбызның хәзрәте. Аны да эшләмичә баеганга исәпләп булмый. Авыл халкы аңа шәригать нигезендә сәдакасын бирде. Әмма, моңа җавап итеп, хәзрәт халыкны бер иманда тотты. Димәк ки, аңа хезмәте өчен түләнде. Шулаймы?

Бикмураев урыныннан торды, өстәлгә кул аркасы белән суккалады.

— Син нәрсә, мине дә үз ягыңа аудармакчы буласыңмы? Намуслы сәвит работнигын төпсез сазлыкка өстерәргәме ниятең? Үз арбасына мине — чын сәвит кешесен утыртмакчы, әй!

— Ашыкма, калхузүзәк вәкил, минем арбамда сиңа аталган урын юк,— дип, тынычлыгын җуймыйча туктатты аны Бәйрәмхан.— Без ипләп сөйләшик, кычкырышырга тотынсак, хаклыкка җитмәбез. Ә миңа хаклыкның өстенлек алуы — максат. Утыр син, югыйсә миңа очып кунарга торасың. Бу әзмәвер гәүдәң белән мине чебен урынына сытуың мөмкин.

— Кирәк икән — кунармын! Синең кебекләрне авылдан сөреп, күк түбәсенә дә кунармын!

— Ә минем ниятем — синең миңа, минем кебекләргә, үзебез теләгәнчә яшәргә юл куюыңа ирешү. Син безне авылдашлар каршында, район һәм Татарстан җөмһүрияте каршында, ахыр килеп, ил каршында якларга тиешсең. Үзебезчә яшик без. Юл бирегез.

— Мин синең кебекләрне якларга тиешме?! Ю-ук! Калхузга керегез. Безнеңчә яшәгез. Мин вәкил булып килгән Юртай тоташ күмәкләшергә тиеш! Райбашкарма рәисенә сүз бирдем, Юртайны тоташ күмәкләштерәм, сөрсәм дә, ике кулактан арттырмам, дидем.

— Мин калхузга кермәячәкмен.

— Димәк, сөрәбез сине!

— Минем сөргенгә җибәрерлек гаебем юк. Мин җинаять кылмадым.

— Калхузга кермисеңме? Кермисең! Җинаятең бу синең! Башкаларны, унбер хуҗалыкны, калхузга кермәскә котыртасыңмы? Котыртасың! Монысы тагын да зуррак җинаятең, совет властен санламавың! Бик беләсең килсә, җәһәннәмгә үк сөрербез сине!

Бәйрәмхан, ә бит, чыннан да, шундый гаепләр ташларга күп сорап тормас бу калхузүзәк вәкил, дип уйлады. Маңгаен, чәчләрен ышкыштырды, бераз вакыт җавапсыз торды.

— Тавышны күтәрмичә сөйләшергә килешкән идек,— дип

тураеп утырды ул.— Сүздә тору кирәк. Кызып китсәм, холык пырдымсыз, син мине түгел, мин сине чебен урынына сытуым ихтимал, күреп торасың, гәүдәм кукраеп катмаган, ашаганым, биргәненә шөкер, икмәк катысы да бер йотым сөт кенә түгел. Тагын бер кабатлыйм — хөкем чыгарырга ашыкма. Мин котккы белән шөгыльләнмәдем. Совет властен сан итүем турында шулай ук анык әйттем. Инде бүлдермичә тыңла. Мин җиткелекле яшим. Калхузга кушылмаган тагын унбер хуҗалык та ким-хурлардан саналмыйлар. Безнең ишеләрдән калхузга керүчеләр дә булды, шактый алар. Авыл гел ярлылардан гына тормый, совет корылгач, авыл ярлылыктан чыга барды. Белдергәнемчә, мин үзем дә совет булгач кына тамагы туючылар исәбеннән. Моны бөтен Юртай белә. Ләкин мин үзем, үз гаиләм турында кайгыртам, мин башкаларга хуҗа түгел.

— Чеп-чи кулак идеологиясе! Авылыгыз ярлылары турында кем кайгыртырга тиеш? Аларны хөкүмәт җилкәсенә атландырмакчымы син?

Бәйрәмхан, йодрыкларын селтәп, Бикмураевка таба атлады, вәкил ул якынайганчы ук урындыгында артка кайшалды. Шул чакта өйалдында идән шыгырдады, Бәйрәмхан кинәт тукталып калды, кулларын уа-уа урынына кире барып утырды. Шыгырдау тынды, керүче дә булмады.

— Ата ялкауларны үз җилкәмә атландырмам! Эшләрен эш итеп эшләсеннәр. Совет рәхәт яшәргә җир бирде, әмма эшләп аша, диде. Минем җилкәмә йөк җитәрлек өелгән, туачак балаларыма гына буш урыннар бар анда, шуны бел, калхузүзәк вәкил! Инде тагын шуларны да белеп тор, безнең гаиләне авылдан сөрү ниятеңә керешсәң, бик тә кирәк булыр болар сиңа. Гаиләмдә минем сигез җан: эти, әни, үзем, хатыным һәм дүрт балам. Әти-әни картайды, малай мәктәпнең икенче сыйныфына күчте, сеңелләре аяксыз да күтсез дигәндәй, кечесе бишек юешли. Безгә бер сыерның сөте җитми. Кышлаган танабыз бар. Тормыш бит, әле картлыкка чыкмадык, тагын балаларыбыз булыр, мин дә, хатыным да утыз ике генә яшьтә. Ике сыер асрап җибәрербез, дибез. Сарыкларыбыз, кош-кортларыбыз җитәрлек. Атларыбыз, әйе, икәү. Хәзергә.

— Анысын ишеттем. Калхузга атлар күп кирәк. Иң киме — берсен бүген үк алырбыз. Кулак буларак кумаган очракта да, дим.

Бәйрәмхан көлеп җибәрде.

— Ала алмаячаксыз, чөнки Кара биябез — инче. Әнә ул Коба алаша — Кара биянең беренче колыны. Бүген-иртәгә көткән туагыбыз шулай ук инчедән була.

— Инчесе нәрсә тагын?

— Бәрәкалла, син үзебезнең татар адәме ләбаса! Кайда үстең соң син? Инчене белмә инде, әкәмәт!

— Син минем кайда үскәнемне тикшермә! Шул ук син әйткән татар арасында үстем.

— Димәк, татарның гореф-гадәтен белергә мәҗбүрсең. Хатынга үз ата-анасы ягы биргән аяклы мал инче була. Бу аяклы мал гомере буена аның үз милкендә исәпләнә. Хәтта син дә, калхузүзәк вәкил булсаң да, инчене хатыннан тартып ала алмыйсың.

Бикмураев, башын иеп, озын кара чәчләре арасына бармакларын тыкты. Уйлана иде. Әллә шәһәрдә яшәүче гаиләсе исенә төште дә шуның иминлеге өчен хафаландымы — балаларына сауган шәбендәге бер касә сөт юнәтүе дә кыен бит бу бичаракайга; яки Бәйрәмханга ишле гаиләне алып бару авырлыгына төшендеме — калхузүзәк вәкиле дә кешелеклелек сыйфатларыннан мәхрүм түгелдер ләбаса. Ләкин вәкилнең аска карап утыруына икенең берсе дә сәбәп булмаган икән.

— Син миңа яшьтәш икәнсең үзең, ләкин аң дәрәҗәң бик түбән синең,— дип, тагын иснәнде вәкил. Төн йокламавы сиздерә.— Гәзитләр дә укымыйсың икән. Хәзергесе вакытта кайсы гына гәзитне кулыңа алсаң да, кулакларны бетерү турындагы чакыруларны күрерсең. Кулакларга юлбашчыбыз иптәш Сталин бәясе һәр санда бар. Иптәш Сталин яза, партия авылда кулакларны чикләү сәясәтеннән бетерү сәясәтенә күчте, ди. Менә без шушы күрсәтмәгә таянып эшлибез. Җитәкче күрсәтмәләр язылган гәзитләр менә монда йөри.— Бикмураев өстәл почмагында яткан күн сумкага кагылып куйды.— Үземнән калдырмыйм мин аларны! Ә син кулакларны бетерү турындагы карарны да укымагансың. Хәреф танымыйсың, ахрысы. Юртай авылында бу карар үтәлми. Әле мин, авылыгыз башлыкларының бездә кулаклар юк, дигән сүзләренә ышанып, Юртайны тоташ күмәкләштермәкче идем. Хаталык кыла яздым. Үземне дә... Синең кебек ата кулакларның калхузга нигә кирәге бар ди?! Сезне калхузлар-савхузлар алыштыра. Иптәш Сталин шулай дигәнме? Дигән! Кулакларны бетерергә, дигәнме? Дигән! Бөтен партия әйтте моны! Мин — менә шушы карарны үтәргә җибәрелгән вәкил.

Ул күн сумкадан торба итеп төргән газета алды. «Кызыл Татарстан» газетасы иде бу.

— Менә ул — сезгә аталган карар. «Татарстанда кулакны сыйныф булу ягыннан бетерү турында Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы карары» диелгән. Монда, беләсең килсә, кулакларны еракка сөрү яки башка торак урыннарына күчерү турында сүз бара. Баштагы ике пунктын укыйк. Беренчесе болай. Татарстан Җөмһүриятендәге барлык кулакларның, шулай ук Татарстан Җөмһүриятеннән сөрелә торган кулакларның бөтен милкенә конфискация ясарга, дип шартлатып язылган. Икенчесендә, кулак хуҗалыкларының милкенә

конфискация ясаганда, аларга йорт кирәге әйберләре (кием, урын-җир, савыт-саба һәм башкалар) һәм шулай ук өч-дүрт айлык азык продуктлары калдырылырга тиеш, дип билгеләгәннәр. Тиеш, тиеш... Монысын мөмкин, дип тә аңлап була. Ары таба синең кебек төгәллек яратучылар игътибарына санап та күрсәтелә: ике-өч хуҗалыкка бер ат һәм бер сыер, бер хуҗалыкка икешәр сарык һәм ким дәрәҗәдә кирәк булган авыл хуҗалыгы кораллары калдырыла. Аңладыңмы?

Бикмураев, соравына җавап көтмәстән, укуын дәвам итмәкче иде дә, Бәйрәмхан аны:

— Йөгерек укыдың, дөрес укыдың, хәрефне әйбәт танныйсың икән,— дип бүлдерде. Аның кулында да «Кызыл Татарстан» газетасының шул ук саны иде һәм ул Бикмураевның укуын чагыштырып барган иде. Моңа вәкил аптырап калды.— Ашыкма, төшенеп укы.

— Син яңалифне танныйсыңмы? Тиз өйрәнгәнсең.

— Нигә танымаска? Аңгыра зат түгелмен. Яңалифнең керә башлавына ике ел, аны танырга өйрәнергә бик җитә бу вакыт. Тик хикмәт карарның төгәл булмавында. Менә син нәрсәне аңлатып бир миңа.— Бәйрәмхан газетасына уң кулының имән бармагын төрткәләде.— Бер ат һәм бер сыер ике хуҗалыккамы әллә өчкәме калдырыла? Бер хуҗалыкка икешәр сарык, дигәнен ничек аңларга? Бөтен җөмһүрияттә бер хуҗалыкка гына ике сарык калдырыламы яисә һәр хуҗалыкка ике сарыкмы? Өч-дүрт айлык ризыкка күпме нәрсә кирә?

— Юкка башыңны катырма, Бәйрәмхан! Син кулакларның ничек сөрелгәнен белергә тиешсең. Аларга бернәрсә дә калдырылмый!

— Кулакны куучылар карарны боза! Карарда бернәрсә дә калдырылмавы әйтелмәгән!

— Анысы безнең колакка тукылган! Карарда инче-минче турында сыңар сүз дә юк. Халык гадәте, фәлән-төгән, дип сайрап, атлы булып калмакчысың, ә! Хәйләкәрсең! Ата кулак!

— Димәк, син мине башка авыл кешеләрен куган кебек кумакчы буласың? Кичә син минем атымны ач калдырдың, бүген минем авызымнан ризыгымны тартып алырга исәбең!

— Нигә мин куам ди? Авылдашларың карар чыгарып сөрәчәк.

— Алай... Шулай да син, калхузүзәк вәкил, байлыгым турында минем үз авызымнан ишет.

— Кәгазьгә терки барыйммы?

— Анысы — синең эш. Әйе. Минем каралты-курам төзек. Уру-сугу машиналарым бар. Бурыч биреп тору ширкәте акчасына алган идем аларны, бурычым вакытында кайтарылды. Өйләребез кара-каршы, урам ягындагысын әти салды, анысының аскы ниргәләре туза башлаган, егерме биш ел торган йорт

чөнки, тәрәзә яңакларын былтыр гына кабат алыштырдык, түбә тактасы черемәгән. Әчкәрге йортны мин җиткердем. Өйләнгәч. Ике балабыз тугач кына әле. Анысы яңага исәпләнә, димәк. Хәзергесе көндә мин шул өйнең икенче катын күтәрәм.

— Ике катлы йорт саласыңмы?! Авылың башлыклары шуны да яшергәннәр бит миннән! Астыртын җаннар!

Бәйрәмхан вәкилнең авыл башлыкларына кагылышлы сүзләрен бу юлы игътибарсыз калдырды. Бикмураевка карамыйча сөйләвен дәвам итте.

— Әйе, йортның икенче катын күтәрәм. Нигезен шуңа исәпләп салган идем. Гаилә ишле. Кысан. Балаларны укытасы, әйбәт тәрбияне иркенлектә бирәсе иде үзләренә. Укымышлы, дәрәҗәле гаиләләрдәге кебек. Хыялда гына калыр микәнни болар... Их-х, баш эшләп җиткермәде, шул фикер башка алдан кермәде, хәзер соңдыр. Карале, вәкил иптәш,— дип, Бикмураев каршына җәһәтләнеп барды Бәйрәмхан,— болай эшләсәк, ни... Болай итик без,— дип буталып алды, шул арада фикерен авылны тоташ күмәкләштерергә килгән вәкил һичшиксез аңларлык итеп түгәрәкләргә тырышты.— Әйе, нәкъ шулай итик — бүгенгә чаклы калхузга кермәгән кешеләрдән аерым калхуз оештырыйк!

— Бер авылда ике калхузмы? Хәзерге калхуздан... тәк... сигез тапкырга кечкенәрәк калхузмы? Кемгә кирәге бар ди ул сезнең бәп-бәләкәй калхузыгызның? Болай да калхузыгыз зурдан түгел.

— Безгә — унике хуҗалыкка кирәк! — дип, үзенең тапкыр фикеренә рухланып китте Бәйрәмхан.— Җирне йөз дә сигез ихатага уртак иткәнче, аның бер өлешен унике генә гаиләгә тоташ итү хәерлерәк. Бәлки, унике генә гаилә булып та калмас идек. Башта төзелгән калхуздан кайберәүләрне үзебезгә алыр идек. Теләкләре булса. Үзебезгә тиңнәрен.

— Баеракларын, шулаймы?

— Нигә баеракларын гына? Эш сөючеләрен.

— Син калхузның персидәтеле булыр идеңме?

— Нигә мин рәис булырга ди? Әнә...— диде дә капылт тукталды Бәйрәмхан, колхозүзәк вәкиле алдында кемне дә булса тәгаенләп атавы әләк-ошак булып аңлашылуы башына китереп сукты, ә рәислеккә хатынының абыйсы Шәйхетдинне исендә тоткан иде.

— Йә, йә, кемне?

— Кемне, дип... Кемне сайласалар, шул булыр иде безнең хуҗалыкның башлыгы. Моны хәл кылырга ялгызымның вәкаләте юк.

— Бушка хыялланма, Бәйрәмхан! Сөрәбез сине! Авылдан берәүне булса да сөрмәсәм, минем үземә гаепне тау итеп өя-

чәкләр. Кулаклардан калхуз оештыру өчен җибәрелмәгән мин монда! Күмхуҗ кулактан башка гына була ала. Кулаклар өереннән күмәк хуҗалык оештырмакчысың, ә?! Барып чыкмас! Мондый коткыңа бүген үк берәр чарасын күрербез! Күрермен! Кулаклар калхузы оештырмакчы, әй!

Бәйрәмхан монысына нинди җавап кайтарырга белмәде, башын чайкап аптырап калды.

— Мәрхәмәт белмәс бәндә икәнсең,— дип, ишеккә таба юнәлде ул.— Син кешене терeләй тунарга әзерсең. Эрвәлүтсия, дидек, совет, дидек, тигез хокук, дип мактандык.— Бәйрәмхан кире борылды да: — Гражданнар сугышында эрвәлүтсияне яклап сугыштым мин! — дип күкрәк какты.— Эрвәлүтсия кешесе мин!

— Шапырынма! Мин дә гражданнар сугышында кулга кылыч тоттым. Мактанмыйм бит. Ә синең гражданнар сугышында кайсы яклы булуыңны тиз ачыкларбыз! Хәер, аклар ягында инде, югыйсә хәзер кулаклар калхузы оештырырга җыенмас идең.

— Мин аклар ягындамы?! Их-х, ата-бабаңны... Кем үстерде икән сине?! — Бәйрәмхан, йодрыкларын йомарлап, Бикмураевка таба атлады.— Совет тәрбияләде микәнни соң сине миһербансыз итеп? Юктыр, алай түгелдер. Бүгенге көнгә каян табылдың икән син? Чеп-чи җәллад бит син!..

Ачык тәрәзәдән:

— Эти-и! — дигән тавыш ишетелде.

Малае Корбәт иде. Бәйрәмхан тәрәзәгә атылды.

— Эти! Кара бия колынлыйсы итә!

— Тезгенен ычкындыр алашаның! — дип кычкырды малаена Бәйрәмхан һәм, кабаланып, тәрәзәдән төшә башлады, киндер алъяпкычы кадак башына эләгеп ертылды, шуны ычкындырганда терсәге бәрелде дә, бер өлге пыяла челтерәп-чыңлап коелды.

Малае Корбәт үзен тыныч тота, бик әһәмиятле эш башкаручы кеше кебек җитди иде.

— Ашыкма, эти. Пыяланы әрәм иттең, үзебез куясы була бит аны,— диде ул. Бер уңайдан этисе әлегә белмәгән эшен мактанып хәбәр итте.— Эти, Кара бияне мин алып мендем. Алашаны алырга төшкәч, аның ялваргандай торуы күз алдыма килеп уяндым. Ашыкма син, эти. Кара бия янында бабай белән Шәйхетдин абый калды. Әни синең кая киткәнеңне белмәде. Шәйхетдин абый кәнсәдә түгел микән, дигәч, мин туры монда йөгердем.

Малаеның сүзләре Бәйрәмханның аңына барып җитмәде. Ул атка инде атланган иде, тезген очы белән Коба алашага уңлы-суллы сукты, һәм аты урыннан ук чабып китте. Корбәт арттан йөгерде.

Бикмураев ачык тәрәзәдән:

— Аты шәп күренә кулакның! Мондый атлар калхузга бик тә кирәк,— дип уйлап куйды.

Авылда беренче төн ат көтүе чыкмаса да, Коба алашаның тояк тавышлары иртән атларның юыртып-сөенешеп кайтуларын искәртте. Кайдадыр — әллә колхоз атлары ябылган утарда, әллә колхозга кермәгән хуҗалык ишегалдында — Коба алашаның тояк тавышларын ишетеп, ахрысы, ат кешнәде. Аннары аңа тагын, тагын кушылдылар. Зур булмаган Юртайда бер мәлдә ат кешнәүләре тоташ җыр булып яңгырады. Моңсу иде бу җыр. Моңсулыкка авылда беренче тапкыр ат көтүе чыкмавы сәбәпче иде. Юк, алай гына түгел икән, Кара биянең колынларга торуы авылда күмәк кешнәү кузгаткан икән! Тик Коба алаша гына кушылып кешни алмады, ул томырылып чаба иде. Колын туды. Бия колын. Аңа исем кушарга Бәйрәмхан, этисе белән киңәшкәч, Корбәткә әйтте.

— Колын үсеп җиткәндә, син ат җигәргә ярарсың,— диде ул.— Аны үзең карап үстерерсең.

— Әти, мин аны иң элек тырмага җигәрмен, яме!

Бәйрәмхан, колынга сокланып торган Корбәтнең җилкәсенә кулын салып, аны үзенә елыштырды.

— Атны башта сиртмә арбага җигеп өйрәтербез, улым. Шулай кирәк.

— Алайса, башта тарантаска утырып урам әйләнәм!

— Монысы бөтенләй дә ярамый. Сөрхәнтәйлеккә йөз тотуың булыр иде монысы, тырай тибеп йөрүче итеп үстермим ләбаса мин сине. Атка элгәре җиңел йөк тарттырырсың. Кара биянең соңгы колынлавыдыр бу. Шуңа күрә колынга исемне син куш. Үз атыңа.

Малай, үзенә аталган колыны булудан дулкынланып, югалып калды, исемне тиз генә таба алмады. Беравыктан:

— Кара... Кара...— дип кабатлады. Кара бия, дияргә иде исәбе. Исем табышуда булышып җибәрүен көтеп этисенә карады, әмма этисе малаеның үз башын эшләтүенә өметләнде.— Кара... Кара... Юк, аның энисе Кара бия... Әти, таптым! Бәләкәй бия!

— Ярар. Тик, улым, колын гәүдәгә, сөбханалла, Кара биянең үзеннән кечкенә булмаячак.

— Кара биянең колыны булгач, анасыннан барыбер бәләкәй була ич инде ул!

— Мин риза. Шулай уйлавың хәерле.

Төш узгач, Корбәт Шәйхетдинне чакырып чыкты. Бу йомышны үтәгәч, этисе аңа уенга онытылып югалмаска, өй тирәсендә булырга кушты. Ә Бәйрәмхан белән Шәйхетдин баз өстенә корылган такта алачык эченә кереп сөйләштеләр. Монда бөркү түгел, аннары кергән-чыкканның күзенә чалынмыйсың,

алачык түр өй каршындагы җимеш бакчасы почмагында, урамнан узучыларга тавышлары ишетелмәячәк.

Бәйрәмхан, кәнсәдә соңгы мәлдә кызып сикереп торуын һәм ашыгудан тәрәзә ватуын да әйтеп, колхозүзәк вәкиле белән әңгәмәсенең эчтәлеген сөйләде.

— Тәрәзәдән йөрергә яратасың инде син,— дип көлеп куйды Шәйхетдин.— Андый гадәтең бар.

— Нәрсәгә ишарәләвең булды бу?

— Сеңелгә өйләнергә теләвеңне безгә ничек ирештергән идең? Оныттың мәллә? — дип һаман да көлемсерәде Шәйхетдин, аның шаяртырга тырышуы Бәйрәмхан сөйләгән сүзләрне күңеленә сеңдереп өлгерү өчен кирәк иде.

— Әй-й, ташлачы!..— дип кул селтәде Бәйрәмхан.— Аңлап торасың лабаса, шаяртыр чак түгел! Безне авылдан сөрергә җыеналар! Ашыгыч чарасын күрергә кирәк.— Һәм өйләнүе күз алдына килде дә, үзе дә елмайды.— Ә-ә, ә... Инде хәтереңә төгәл төшерәсең килсә, Шәйхетдин абзыкай, Хуриягә өйләнәчәгемне тәрәзәдән кереп әйтүем мәсьәләне ашыгыч хәл итәргә кирәклектән иде, урамнан әйләнеп ишегездән керергә вакыт калмаган иде!

...Хәтерендә бу хәл Бәйрәмханның.

Ян бакчага бәрәңгене кичә утыртып бетерделәр. Күрше Шәйхетдиннән ат алып торып, сука белән ярдырып салдылар. Булышырга күрше-тирә керде, Хурия дә бар иде. Соңгы ике елда Хурия Бәйрәмхан белән бик аралашмас булды, бала чакта, буйга җиткәндә дә, Бәйрәмхан тирәсендә чәтелдәп йөрер иде үзе югыйсә. Әле быел, кар эреп беткәч инде, кичке уңайда очраштылар да Хурияләрнең капка төбендәге эскәмиядә утырып тордылар. Гаҗәп тә булды инде: элек чәте-чәте килә торган Хурия ни сөйләшми, ни кереп китми, утыра шунда телен йотып, Бәйрәмханга туры карамаган булып. Кичә бәрәңге салганда да гел Бәйрәмханның әнисе янында булды, егетне күрмәмешкә салынды. Күрше Хуриянең, Акыллы Хуриясенең үзен тотышы нигәдер үзгәрде. Әллә Бәйрәмханга гына шулай тоеламы соң бу...

Бәйрәмхан белән әтисе иртәдән бәрәңге бакчасының түр киртәсен яңартып кора башлаганнар иде. Озакка сузылды, баганалары черегән икән, яңа баганаларга ырмау алу кулны тотты, ә югыйсә баганаларны алыштырырга исәпләмәгәннәр иде. Шулай инде — искегә тимә... Соңгы багананы утырткач, әтисе ишегалды тирәсендәге эшләрне карарга кереп китте, соңгы торыкны Бәйрәмхан үзе генә тотып бетерә иде инде. Киртәләр арасына куярга тезләнеп шакмак кискәндә, янына әнисе килде.

— Күршеләргә димче керде.

Егет эндәшмәде.

— Әллә ишетми инде. Хурияне димлиләр! Чукрак!

Бәйрәмхан, кашларын җыерып, күзләрен акайтып, әнисенә карады, әйтерсең күршегә димче килүенә әнисе гаепле иде. Кул пычкысын селтәп атты, сикереп торды да, үзләренең һәм күршеләренең бакчаларын кисеп, Хуриячләргә таба йөгерде. Алты почмаклы йортның түрдәге урта тәрәзәсе ачык иде, өйдә табын янына утырырга җыенучыларны сискәндереп, шул тәрәзәгә килеп капланды, өйдәгеләр аны-моны аңышып өлгергәнче, кереп каршыларына да басты.

— Хуриягә мин өйләнәм! — дип ярып салды ул.— Димчегә ризалык бирмисез! Күрегезче бу күршеләрне, астыртын эш йөртмәкчеләр!

— Кыз димләү турында сүз булмады бит әле, Бәйрәмхан энем,— дип, күрше егетен дуамалланудан туктатырга тырышты Шәйхетдин.

— Булырга тора! Әмма булмаячак! Син, Шәйхетдин абый, Хуриягә әтисе урынына калган кеше, мин җибәрәчәк димчегә әзерлегеңне күр!

— Бәйрәмхан, безнең өйнең ишеге дә бар, ишектән керәсе идең.

— Ишегегездән кергәнем бар, Шәйхетдин абый. Киләчәктә кияү булып керермен! Шулай боерган! Ә син нигә терәлеп каттың? — дип эндәште аннары аралыктан чыгар-чыкмас торган Хуриягә.

— Мин...

— Мин дә мин! Менә шул — мин сиңа быел өйләнәчәкмен! Алла боерса, быел игеннәребез уңар да көзге байлык мул булыр. Быел гына, димим, гел тук-рәхәт яшәрбез. Аңладыңмы шуны, Хурия?

— Мин...

— Йә, ярар, син дә мин!

— Син... Син, Бәйрәмхан, шуннан да соңга калдырмассың инде, яме...— дип пышылдады Хурия, Бәйрәмхан ишек катына якынайгач, үзенең авыз читләре калтыранды, күзләре челт-челт йомылып ачылды, егет тупсаны атлаганда, аңа омтылмакчы булды, әмма егетнең барыбер туктамаячагын сизде, дымсу күзләрен яшереп, йөзен каплады...

— Хуриягә өйләнәчәгемне тәрәзәдән кереп әйтсәм дә, сеңлең белән әйбәт яшибез, Шәйхетдин абый,— дип хәтерләүләргә чик куясы итте Бәйрәмхан.— Беләсең, мин хатынны какмыйм. Аннары да килеп, Хурия үзен беркайчан да кактырмаячак.

— Менә, кияү балакай, синең унике хуҗалыктан калхуз оештырырга ниятләвең берәүләр ишектән йөргәндә,— дип, әңгәмәнең үзәгенә төште Шәйхетдин,— икенчеләрнең тәрәзәдән керүе кебек булмас микән? Властьлар бер авылда ике калхуз ясауга бармастыр.

— Ялгышасың, Шәйхетдин абый! Ишектән куганда тәрәзәдән керергә исәп җыймыйбыз. Без икенче ишек кисәбез. Ә властьлардан күмәкләшеп рөхсәт сораганчы, аерым хуҗалыкларның кечкенә калхузга берләшергә ризалыкларын белергә кирәк. Аларга мин йөри башласам, вәкилгә барып ирешәчәк тә коткы таратуга санаячак моны вәкил.

— Бу йомышны миңа йөклисеңме?

— Сиңа да ярамый.

— Кемгә ярый соң?

— Әти әйтә, өчебез, ди, син, мин һәм әти үзе, һәркайсыбыз берәрсенә барыйк, аннары бүтәннәрдән алар белешер, ди.

— Кода дөрес әйтә.

— Ләкин һәркайсына уйлану өчен аз булса да вакыт кирәк. Җавапны белер өчен чылбырны буынлап сүтәбезме? Безнең кайда аяк басуыбызны да күзәтеп торачаклар. Төннең дә күзе бар хәзер. Ашыгырга кирәк безгә, вәкил бик коры тотмакчы, әйтәм ич, сезнең өйләргә, ди, авыл советы белән калхуз кәнсәләрен күчерәчәкбез, ди.

— Тәгаенләп тә куйган. Башкаларның йортларын нишләтер икән соң?

— Табарлар, таркату җаен тиз таба андыйлар. Сизеп торам, Шәйхетдин абый, терелләй тунаячаклар безне! Кая гына сөрсәләр дә, көн күрсәтмәячәкләр. Үз иленә яшәргә урын бетте. Җәллад кулыннан узганчы, бисмилланы әйт тә хет үзеңнеүзең...

— Әстәгъфируллаһ диген!

— Гаиләмдә тагын җиде җан... Үзем генә булсам, һич кичегүсез үземә-үзем кул салыр идем.

— Туктале, кияү, ялгыш-яман уйга керәсең.

— Көн бетте безгә...

— Бәлки, кияү, синеңчә булыр — аерым калхуз оештырырга рөхсәт бирерләр. Нигә куркырга икән миңа, барысын да үзем йөреп чыгам! Бәлки, оешкан калхузга керергә кирәктер, ни язганын авылдашлар белән бергә күрербез.

— Юк инде, абзыкай, кермим мин анда! Аннары да килеп, мине ул калхузга алмыйлар. Бүген инде алмыйлар! Миңа кулак тамгасы сугылды. Ә кулакларны төзелгән калхузга алмыйлар. Аларны бетерү турында гына сүз бара. Ә бетерүне ничек аңларга? Үтерүме?.. Минем хатынның бертуган абыйсы булганың өчен сине дә алмаулары бик ихтимал. Менә нинди заманнар җитте!..

Җимеш бакчасында аяк тавышы ишетелгән кебек булгач, алар икесе дә алачык ишегенә карадылар. Бәйрәмхан ишек янына ук килде, бакчада кеше-кара күренмәде, аяк тавышы кабат ишетелмәде. Кемдер йөргән кебек тоелган гынадыр, күрәсең.

— Мин менә болай уйлаган идем,— диде Бәйрәмхан, бүкәнне Шәйхетдин янынарак күчереп утырды. Алъяпкычы кесәсеннән кәгазь чыгарды.— Монда бер генә җөмлә: «Сез унике хуҗалыктан авылда аерым калхуз оештырырга ризамы?» Шушыны һәркайсына укытырга кирәк. Бүген малайның башы күккә тигән көн, кемгә кереп сөенечен әйтсә дә, гаеп саналмас. Җавапны һәркем үзе җаен табып ирештерер.

— Баланы катыштыру дөрес булмас.

Алачыкның арткы ягындагы такта тавыш бирде. Бәйрәмхан язуны оекбашы кунычына бөгәрләп тыкты, Шәйхетдин, тәмам каушап, урынында боргаланды.

— Әти... Әти, дим, мин ул өйләрне хәзерендә йөгереп кенә йөреп чыгам! Әти...

— Ах-х, синмени әле анда малай актыгы! Кер монда!

Корбәт, алачыкка керүгә үк, Бәйрәмхан аның колагын борды.

— Алла-а!.. Әти, колакны өзәсең-ң-ң!..

— Өзелсен! Яшертен сүзне качып-посып тыңлый торган колакның булмавы хәер!

— Мин туакка, Бәләкәй биягә инде, үлән өзәргә дип кергән идем ич! Үзегез ишетелерлек итеп сөйләшәсез бит...

— Яңа туган колын үлән ашаган ди сиңа, аңгыра баш!

— Бәләкәй бия минем кулны ялады бит, мин аны ашарга сорый дип белдем...

— Син менә шушы кәгазьне кемнәргә укытачагыңны бел — булырсың егет!

— Бәйрәмхан, баланы бутамыйк бу эшкә. Уйла әле.

Ләкин Бәйрәмхан Шәйхетдин ягына кул гына селтәде.

— Башын эшләтеп үссен минем малай! Инде сабый түгел.— Аннары Корбәтне колынга исем кушкандагыча үзенә елыштырды.— Улым, шушы язуны калхузга кермәгән кешеләрнең йорт башлыкларына укыт. Анда латин һәм гарәп хәрефләре белән бер үк сүзләр язылган. Риза булганнары сиңа әйтеп үк җибәрсеннәр, калганнары үзләре миңа хәбәр итәр. Туктале, син калхузга кергән кешеләрнең дә кайберләренә сөенечеңне әйт, тик аларга кәгазьне укытма. Бутый күрмә, яме. Йөгереп кенә йөр...

Корбәт йөгереп кенә йөрде, кәгазьне тиешсез кешеләргә укытмады. Әтисе кушкан йомышны төгәл үтәвенә сөенә иде ул. Ләкин өйдә аны көенечле хәл көтә иде. Үзе барган кешеләрнең барысының да авылда аерым колхозга берләшергә ризалыкларын әтисе белмичә калды. Бәйрәмханны, район үзәгеннән килеп, алып киткәннәр иде инде. Вәкил Бикмураев, Юртайдан район үзәгенә телефон чыбыгы сузылмаган булса да, милициягә хәбәр салу әмәлен тапкан, димәк. Бәйрәмхан әйткәндәй, әшәкелек кылуда җәһәтлеккә һәм үҗәтлеккә кем шушылай ныклап өйрәтте икән бу бәндәне...

Уразманов Бәйрәмханны раймилициядә тынчу һәм караңгы келәткә яптылар. Кулга алынуының иртәгесен үк күкрәк баласын күтәреп килгән хатыны Хурияне аның белән очраштырмадылар, китергән ризыкларын алмадылар. Хурия ире ябылган келәт янына бара башлагач, аны җилтерәтеп милиция башлыгы бүлмәсенә алып керделәр. Мондый түрәләрне күреп белмәгән авыл апасының начальникка үтенечен әйтергә көче җитмәде. Тәрәзәләре идәннән түшәмгә җиткән зур бүлмәнең (нэп заманыннан соң төрмәгә утыртылган бай йорты була бу) тупсасын атлап керүгә телсез калды, баласын тартып алуларыннан куркып, күкрәгенә ныграк кысты. Каты ук кысты бугай, сабый елап җибәрде. Хуриянең авыз читләре калтырана, бөтен гәүдәсе дерелди иде. Тик аның бу хәрәкәтләре Бәйрәмхан өйләнү турында хәбәр иткән чактагыдан үзгә иде, ул чактагы шатлык урынына хәзер кайгы иде. Озакка сузылачак һәм онытылмас кайгы иде...

Бәйрәмханны ябылудан атна туласы көнне иртән чыгардылар. Хурия аны, кууларына һәм үзен дә ябып кую белән куркытуларына карамастан, милиция бинасы янында беркая китмичә көтте. Ирен күргәч, кулындагы төенчеге төшеп китте, баласын ычкындырмаска көче җитте, Бәйрәмханга таба берничә адым атлады да акрын гына сыгылып җиргә утырды. Аның каршына әле атна элек кенә кодрәт иясе булган Бәйрәмханы килә иде. Килә иде? Юк, килми, ә инде ап-ак чәчле, җилкәләре салынган, аяк буыннары тотмаучы Бәйрәмханы сөйрәлә иде — бер атнада кешене менә нинди хәлгә калдырып була икән...

Хәлсез ир хатыны белән баласы янына егылды.

— Исән...

— Исән, Хурия... Тик... бу кызыбыз төпчегебез булыр инде... Боламык ясадылар миннән...

Хурия, баланы әтисе алдына куеп, төенчекне алып килде, ашъяулыкта моннан ике төн элек абыйсы Шәйхетдин качып кына китереп киткән ризык бар иде әле. Каршыдагы тыкрыкка керделәр. Киртә буена утырып тамак ялгадылар. Кайту ягына атладылар. Хурия шул чакта теге көнне Корбәтнең йомыш белән барган кешеләрдән аерым колхоз төзергә ризалык алып кайтуын әйтте.

— Алайса,— дип туктады Бәйрәмхан,— алайса... райбашкармага кереп, үз калхузыбызны оештырырга рөхсәт алыйк. Тагын кайчан монда килермен аннары, эшне бетереп кайтырга кирәк.

— Әйтәсем калмаган икән.

— Юк, юк, алай димә, Хурия. Безнең бит әле Юртайда яшисебез бар. Безне төзелгән калхузга инде алмыйлар. Унике ихатадан ширкәт булып, кендегебез киселгән җирдә яшәрбез, шәт.

— Әллә кермисеңме соң, Бәйрәмхан? Киемнәрең керлән-

гән. Дәү кеше янына болай керү уңайсыз. Яланбаш килеш тагын.

— Ә-ә, эшләпә онытылган икән. Мин аны баш астына салып йоклый идем.

— Чәчләрең ап-ак...

Бәйрәмхан чәчләрен сыпырды.

— Агарганмы... Ярар, кайчан да булса барыбер агарасы инде. Баш исән булсын.

Райбашкарма рәисе катына ук керә алды Бәйрәмхан, авылдан олы үтенеч белән килгән ярлы кешегә санап, аны тоткарламадылар. Тик йомышы уңмады, райбашкарма башлыгы Юртайда тагын бер колхоз оештырырга рөхсәт итмәде.

— Социализмга кулаклар колхозы кирәкми, Уразманов! — дип кырт кисте ул.

— Без кулаклар түгел, үз көчебез белән көн күрүчеләр. Без аерым ширкәт булырга телибез.

— Телисез? Ә син башкаларның теләген каян беләсең?

— Мин барысының да ризамы-юкмы икәнлеген белешергә малайга кушкан идем. Алар риза булган, хатыным шуны әле әйтте. Мин моны вакытында белмәдем, малай кайтып өлгергәнче мине милиция алып китте.

— Их син, мескен кулак калдыгы! — дип көлде райбашкарма рәисе.— Кыяфәтеңә кара, хөрәсән бит син! Нинди колхоз оештыра аласың ди син! Колхоз оештырырга Бикмураевлар кирәк! Малае да колхозга каршы үгеткә керешкән икән моның, ә! Аннары,— дип, тавышын тагын да кискенәйтте рәис,— авылың хәлләрен белмисең икән син, авылыңнан аерылгансың.

— Ябылуда идем.

— Сине авылдан аерып торган арада, Уразманов, вәкил Бикмураев шәп эшләде Юртайда! Авылны тоташ күмәкләштерде дияргә була. Сезнең өчен тырыша лабаса. Ул чагында колхозчылар сөрелмәячәк. Ә син, тинтәк, шуны аңламыйсың. Күмәкләшергә тешең-тырнагың белән каршы торган булдың. Бикмураевны кыстык бераз, ату бит элек барган авылының яртысын кулак буларак сөрде, чамасыз кыланды. Юртайдан бер-ике хуҗалыкны гына сөрермен, алай да булдыра алам, дип сүз бирде. Тәк. Юртайда кичәгесе көнгә... Тәк, тәк...— Райбашкарма рәисе өстәл өстеннән бер бит кәгазь аерып алды.— Тәк... Юртай менә монда икән. Юртайда кичәгесе көнгә күмәкләшмәгән өч кенә хуҗалык калган. Димәк ки, син кулаклар колхозы оештыру турында тилереп кенә йөрисең.

Сындырганнар икән күбесен, дип уйлады Бәйрәмхан.

— Ә сез өч хуҗалыктан калхуз булып берләшергә рөхсәт бирегез! Бер авылда ике калхуз ярамый, дисәгез, без ширкәт булыйк соң!

— Әйтәм ич, тилермә, Уразманов! Иртәгә Юртайда колхоз-

га кермәгән, бәлки, бер син калырсың. Яхшылыгым тисен үзеңә — тизрәк Юртаеңа сыпырт та сөрелергә әзерләнә тор!

— Хәзергә теләсә нәрсә кыласыз, кайчан да булса башыгызны тотарсыз. Ә бит элгәре башыңны тотып уйлану мәслихәт...

Алар авылга кичкырын кайтып керделәр. Капка төбенә җиткәч, урам як өйдән Бикмураев тавышын ишетеп туктады Бәйрәмхан: «Ни кыла монда бу җәллад?»

Тәрәзә турына барды. Өй эчендә элекке җиһазлар сирәк күренде. Бикмураев һәм авыл башлыклары каршында Шәйхетдин белән Юртайның хәзрәте калтыранып утыра иде.

Эчкәрге өйдә тын. Мунча тәрәзәсендә тонык ут күренә.

Бәйрәмханнарның ике өен дә колхозга алу турында, үзләренә сөрелгәнчегә чаклы мунчада яшәргә боерып, авыл җыены бүген карар чыгарган икән. Абзар-курага, мал-туарга әлегә тимәгәннәр. Мунчада бүген сигез җан кунарга тиеш иде. Ләкин Бәйрәмхан, авыл җыены карары белән ризалашмыйча, барысына да йоклау урынын келәткә күчертте. Әле төн озынаюга керешмәгән, төнгә көндезге җылы мулдан кала, келәттә туңмаслар.

Болай булгач, китәргә әзерлек күрергә кирәк иде. Бәйрәмхан, үзләренә нинди маллар — атларның берсенә булса да төянеп китәргә кирәк ләбаса — калдырылачагын белергә теләп, авыл башлыклары янына керәсе иде дә, Хурия, телеңне әрәм итмә, дигәч, бу фикереннән кире кайтты.

Шулай шул, колхозүзәк вәкиле Бикмураев, кулакны сыйныф булу ягыннан бетерү турындагы карарда бер хуҗалыкка ат калдыру әйтелмәгән, дип кенә авызыңны йомачак. Әллә соң... Әллә соң, тукмап акылга утыртыргамы бу вәкилне?! Юк, дип башын чайкап уйлануында булды Бәйрәмхан, инде аңа көчем җитмәячәк, аннары, әти әйткәндәй, ишәкне колагын кисеп кенә чапкын итеп булмый. Ишәк шулай ук түшәк кадерен белмәс, ишәккә алтын ияр куйсаң да, һаман ишәк булып калачак ул. Гаҗәп бит, әй, мин дә, Бикмурай да эрвәлүтсияне яклаганбыз. Ә хәзер, ил тынычлангач, бер-беребезгә дошманнар...

Билгесез сәфәргә әзерләнә башладылар. Карт белән карчык та күтәрә алырлык төенчекләрен төйнәделәр, киемнәренең яңаракларын киделәр. Балаларын йоклаткач, Хурия дә җыенды. Бәйрәмхан җыенуга катнашмады, мунчада су җылытып юынып алгач, келәт ишеге яңагына сөялеп сүзсез утыра бирде. Әти-әнисенең, Хуриянең синең аркаңда шушы хәлгә төштек, дип рәнҗүләреннән курка иде ул. Ләкин аңа берсе дә үпкә белдермәде. Малае Корбәт йокламый икән, урыныннан торып этисенең тезенә таянды.

— Әти, без барачак төштә мәктәп бармы соң? Мин татарча гына укый беләм бит. Аннары тагын, Бәләкәй бия арыр инде ул, име. Аны арбага яткырып булмыймы соң?

Бәйрәмхан Корбәтнең башыннан сыйпады, малай йокыга изрәгәнче озаклап сөйде.

— Шундый сорауларың булуы хәерле, улым. Мәктәп... Татарча... Бәләкәй бия арыр, дисең инде. Үзебез дә арымагаек...

Төн уртасында капка төбенә җигүле ат килеп туктады. Ишегалдында ят тавышлар ишетелде. Бәйрәмхан келәт ишеген ачты.

— Менә кайда качып ята икән ата кулак! — диде милиционерларның берсе.— Бездән кача алмассың! Киен! — дип боерды ул Бәйрәмханга.— Тизрәк бул! Малаең кайда? Кечкенә агентка да дөнья күрсәтик!

Бу юлы Бәйрәмхан белән бергә аның тугыз яшьлек малае Корбәтне дә алып киттеләр.

...Утызынчы елның июнендә таркатылган бу гаиләдән Юртайга кайтып йөрүче булмады. Бәйрәмханның әти-әнисе, хатыны Хурия һәм Бәйрәмхан үзе инде күптән вафат, гүрләре Юртай карьясе каберстанында түгел, төрле төбәктә. Корбәтнең сеңелләре, хәтта өлкәне дә — Юртайдан киткәндә алты яшь тулганы да — авылны хәтерләмиләр. Ә Корбәт авылын онытмый, аның анда бик кайтасы килә.

Кайтыр да иде... Ләкин әтисе белән аны алып киткән чакта бер йөз дә сигез ихатадан торган Юртай авылы беткән икән инде. Шулай да Корбәткә Юртайда хәзер дә атларны төнге көтүгә алып чыгалардыр кебек. Тын кичләрдә малайлар, атларына атланып, авыл башындагы күпер төбенә җыелалардыр... Көн узып бер-берсен сагынышкан атлар кешнәшәләрдер... Иртән тук атлар Юртай урамына юыртып килеп керәләрдер... Алар арасында Корбәтләрнең Юртай ихатасында туган соңгы колын — Бәләкәй бия дә бардыр кебек.

*1988*

# Кубыз

Бүген Миргаяз абый безне тагын куып йөриячәк. Белеп торабыз моны. Бүген якшәмбе көн бит. Ә Миргаяз абыйның менә бер ел инде якшәмбе көнне безне — Әрәмә урамы малайларын кумыйча калганы юк. Бер ел элек авылда җомга көнне ял итәләр иде, ул чакта Миргаяз абый безне куып та йөрми иде. Ялны якшәмбегә күчергәч, шундый гадәте башланды аның. Ял көне дип, олылар әйткәндәй, авыл кешесенә ял-йол юк ла инде ул. Базар булганы өчен генә ял көне диләрдер якшәмбене. Әнә шул базар төш алдыннан тарала. Кырыктартмачы Вәлиулла бабайның әйберләрен җыя башлавы базар бетүенә ишарә. Ул ап-ак сакаллы, почык борынлы, сүзенең тәмен белеп сөйләшә торган кеше, сату иткәндә гел ак киндер алъяпкычтан була.

Явым-түшемле көндә арбасы яки чанасы өстенә калын киндердән чатыр корып куя. Ә Миргаяз абый базарның башыннан ахырынача кырыктартмачыга булыша. Аның ярдәме читтәрәк торган әйберләрне Вәлиулла бабайга алып бирүдән гыйбарәт, кечкенә әйберләргә ул бөтенләй кагылмый, боларын кырыктартмачы үзе янындарак тота. Аннары кармак, каптырма кебек әйберләрне Миргаяз абый тубалдай куллары белән аерып та ала алмас иде, болар ишеләр белән сату иткәндә, Вәлиулла бабайның куллары исә уйнап кына тора. Без кырыктартмачының әнә шул осталыгына сокланабыз, Вәлиулла бабай тирәсендә гөжләшүебез аның тартмаларындагы әйберләргә кызыгуыбыздан безнең. Бу тартмалар авыл малайларына кирәкле нәрсәләр белән тулы: буяу карандашлары, телле кармаклар, кубызлар, тагын-тагын бик күп әйберләр. Тик базарчы бабай, безнең кесәбез такырлыгын белептер инде, аларны акчага сатмый. Сөяк җыеп китерәбез без аңа, әйберләрен сөяккә алыштыра ул.

Сөякләрне Миргаяз абый үлчәп ала, кемнең күпме китерүен Вәлиулла бабайга әйтә дә кырыктартмачы безгә кирәкле әйберне үзе алып бирә. Базарчының безгә әйбер бирүен Миргаяз абый сөенеп карап тора. Шул чакта ул бездән күбрәк шатлана кебек миңа. Әйбер алган һәр баланы куандырырга сүзен дә таба, күп сөйләшергә яратмаучы Миргаяз абыебыз бу вакытта, олылар әйткәндәй, Вәлиулла бабайга тиң сайрый.

— Сиңа, бәгырькәй,— диде ул бүген миңа,— кубызның гел дә үзе уйный торганы эләкте. Вата күрмә, яме. Вәлиулла бабай синең өчен дип кенә алып килгән моны. Карале, чынлап торып үзе уйный икән бит бу!

Һәм кубызны калын иреннәре арасына кысты да бармаклары белән чиртергә кереште. Миргаяз абый елмаеп уйнаса да, күе сагышлы иде. Юан бармаклары белән каты чиртеп, кубызның телен сындырмагае, дип куркып тордым. Уйнап бетергәч, Миргаяз абый базарчы арбасы астындагы капчыкны үрелеп алды һәм эчендәге сөякләрне үлчәү тәлинкәсенә куя башлады.

— Вәлиулла бабай,— диде ул,— карт базарчыга Миргаяз абый да шулай эндәшә иде,— мин дә күп итеп сөяк китердем бит әле сиңа. Миңа да кармаклар, тасмалар, карандашлар бир әле син.

Миргаяз абый кырыктартмачыдан алган әйберләрен балаларга берәмтекләп өләште. Миңа шәп кармак эләкте. Китергән сөякләре бәясенә болай күп әйберләр тимәгәндер, чөнки Вәлиулла бабайның кайбер тартмалары бөтенләй бушап калды, Миргаяз абый аңа акча да биргәндер. Моны мин хәзер шулай уйлыйм, ә теге вакытта без, Миргаяз абыйдан бүләк алган балалар, байлыгыбыз белән бер-беребезгә мактанышып, Вәлиулла бабайның һәм Миргаяз абыйның базардан китүләрен дә күрмичә калган идек.

Базардан кайтышлый Миргаяз абыйның бер чүлли аракы алуы турында хәбәр бөтен авылга таралды. Ул чакта, аракы эчмәскә үгетләп, клуб стенасына һәм капка баганаларынаябыштырылган чакырулар, исерекбашның шешә кочаклап пычракта аунавын тасвирлап төшерелгән рәсемнәр юк иде үзе. Халыкка мондый үгет-нәсихәт нигәдер кирәкми иде, ә кемнең дә булса кибеттән аракы алуы турындагы хәбәр тиз йөри иде.

Базарчы Вәлиулла бүген дә Миргаяз абыйларда тукталган иде. Кырыктартмачының аты әнә әрәмәлек буена тышаулап җибәрелгән, әле куерып үсәргә өлгермәгән үлән ашап йөри. Арбасы капка төбендә, атны нигә ишегалдына кертеп туармыйлардыр инде, арба-чана гел урамда калган була. Без моның, әйе, сәбәбен белмибез. Шулай да безнең — Әрәмә урамы малайларының да кайчак башлары эшли, атның капка төбендә туарылуын без Миргаяз абыйның үзләренә кунак килүе белән бөтен урамга мактануы, дип юрыйбыз.

Урамыбыз озын түгел үзе һәм бер генә яклы. Шулай да без аны зурга саныйбыз. Һәм авылдагы иң матур урам ул. Елганы безнең яктан агачлар төргән, аннары биш-алты адымнар киңлектә печәнлек калдырылган да бәрәңге бакчалары башлана. Ә йортлар каршыдагы тауга һәм шул тау асты буйлап сузылган әрәмәлеккә карый. Елгадан шактый читтәге, әмма тау асты чишмәләреннән туенучы шушы әрәмәлектән ат юлына хәтле киң чирәмлек бар. Без, Миргаяз абый белән Вәлиулла бабайның чыгуын көтеп, шунда уйнап йөрибез. Бүген озакладылар алар, башка атналарда базарчының ашыгуы сизелә иде, бүген, капкадан чыккач та, эскәмиядә сөйләшеп утырдылар. Без берәм-берәм дә, икешәрләп тә алар яныннан йомышлы кешеләрдәй узгалап китәбез. Миргаяз абыйның безне тотып алуыннан шикләнмибез әле. Чөнки аның безне куып йөрергә Вәлиулла бабайны озатып җибәргәч кенә тотыначагын беләбез.

Яннарыннан узып барам. Алар мине бөтенләй дә күрмәгән кебек. Икесе дә аска караганнар. Вәлиулла бабайның сакалчәчләре генә түгел, йөзе дә ак, гел шулайдыр ул, суыкта юл кайтса да, эссе мунчада чабынса да, йөзенең аклыгы югалмыйдыр. Ә Миргаяз абыйның йөзе бүген кызара төшкән, тар читле эшләпәсен маңгаен бөтенләй дә ачык калдырып кигән. Маңгай өстендә тир бөртекләре дә күренә, шуларны кул аркалары белән алмаш-тилмәш сыпыра. Нәрсә турында сөйләшүләрен аңышмадым, тавышлары акрын иде.

Атны Миргаяз абый җитәкләп алып килде. Базарчы бабай атка Миргаяз абый кулыннан алып эшлея киертте, аны озаклап ат буена бергәләп көйләделәр, түгәрәк тәңкәләрнең һәркайсын диярлек чүпрәк белән ышкып сөрттеләр. Атның, яңа киемгә күнегә алмыйча, тәне чымырдап торды. Вәлиулла бабай арбага җайлап утырып чөңгергәч, ак ат элгәре акрын гына

адымлады да, хуҗасы дилбегә каккач, зур тояклары белән җирне доң-доң иттереп, арт санын алпан-тилпән авыштырып, тәңкәле эшлеясен уйнатып, салмак юыртырга кереште. Без әле ишетеп кенә белгән ерак авылына кайтып китте кырыктартмачы Вәлиулла бабаебыз. Тагын бер атнадан безнең авыл базарына киләсен онытмаса ярый инде. Алдагы якшәмбедә безгә нәрсәләр алып килер икән базарчы бабаебыз?..

Миргаяз абый базарчыны авыл башыннан чыгып киткәнче карап калды. Аннары безгә таба борылды. Ә без, әрәмәлек буенда куакларга ышыкланып, аның куа башлавын көтә идек инде. Бүген әүвәле кайсыбызны куа башлар да кайсыбызны беренче итеп тотар икән... Ә без аңа тиз генә тоттырмаячакбыз! Ачык төштә ул безне дәү адымнары белән хәзерен дә куып җитәр иде, шуңа күрә без әрәмәлектән чыкмыйбыз шул, әрәмәлекнең өстән агач очлары кушылып каплаган тар аралыкларына сыймый ул, шунлыктан иелебрәк йөгерә дә безне тиз генә тота алмый. Менә хәзер йөгерергә тотыначак Миргаяз абый. Әнә ул безгә таба килә дә башлады инде. Нәкъ миңа турылап килә!..

Ләкин Миргаяз абый кинәт туктады да әрәмәлекне буеннан-буена күзеннән кичерде, безне барлавы инде. Аннары, барыбызга атаптыр инде, бармак янады, үзе елмая иде. Ул безгә ерак калмаган иде бит, күзләре кысыла төшкәне, нәрсәдер әйтеп, иреннәрен кыймылдатуы күренде. Өйләренә таба борылды Миргаяз абый, адымын зур атлап кузгалды, башын игән иде. Кечкенә капканы кулын артка сузып кына япты, безгә карамады.

Йөгерә-йөгерә кумады ул безне бүген. Без, куак ышыкларыннан чыгып, аның кереп китүен нәүмизләнеп карап калдык...

Шул җәйдә без гаиләбез белән туган авылыбыздан күченеп киттек, еракка, Пермь тирәсенә үк барып чыктык. Ел чамасыннан соң, районыбыздагы башка авылга кайтып тордык. Озак вакытлар туган авылга кайтылмады. Соңрак, Казанда укыганда, авылыбызда еш булдым, республика читендәге районга эшкә җибәрелгәч, сәфәр чыгуым сирәгәйде. Кайткан чакларда да Миргаяз абыйны күрергә туры килмәде.

Авылыма мин алтмышынчы елның җәендә ял вакытым буе торырга кайттым. Туган-тумачаның хәл-әхвәлен белгәч, кармакларымны көйләп, су буена төштем. Елгабызның кай төшендә балыкның шәп чиртүен онытмаган идем. Әмма электә ярлары тулып торган елганың суы кибәргә җиткән иде. Басмалар да юк. Су аркылы чыгарга ташлар гына салынган. Биек ярлар сусызлыктан корышып каткан, урыны-урыны белән убылып ишелгән, электә елганы ике яклап төргән юан таллар да сирәгәйгән. Балыклы чоңгыллар эзләп, елга буйлап бардым. Уйлавымча, алар саегып бетмәгән булырга тиеш иде.

Миргаяз абый, үз бакча башларында ярга килеп төртелгән

талга утырып, кармак сала иде. Анда су җәелеп тора, элекке чоңгылларның берсе, димәк. Елга эчләтеп сак килергә тырышсам да, Миргаяз абый мине күреп алды. Баш кагып сәламемне бирдем. Ул мине үз янына чакырып ишарәләде. Тар шарламаны сикереп чыктым да аның янына барып чүгәләдем.

— Танымыйм бит үзеңне,— диде ул һәм тамагын йомшак кына кырып куйды.

Кемнең улы булуымны әйткәч, кармагын онытып, күзләрен челт-челт йомгаклап, миңа текәлеп карады.

— Үскәнсең икән,— дип елмайды, шул чакта кара сакалмыеклы йөзе яктырып китте.— Кая әле, аягүрә бас әле! Үскәнсең! Әллә мине дә узгансың инде?

Ул да аягүрә басты. Каршымда, киң җилкәләре салынып бетмәсә дә, инде бөкрәя башлаган, шулай да нык гәүдәле карт басып тора иде. Буйга миннән кайтыш түгел иде әле ул.

— Үскәнсең,— дип кабатлады Миргаяз абый, бу сүзләре минем хәзерге яшемә карата сәер булуына игътибар итмәде.— Әйдә, чәйгә керәбез. Кояш тау түбәсенә утырмыйча,— ул тау ягына күрсәтте,— балык эләкмәячәк. Хәзер безнең суда балык үтә дә азайды, шуңа күрә вакытны бик сайлап кына эләгәләр. Чәй эчкәч төшәрбез балык тотарга, бу чоңгылда безгә балык җитә, җитә әле.

Мин балачактан белгән йорт тәбәнәкләнгән кебек, бүрәнәләре куе чия төсенә кергән, каралты-куралары да элеккеләр, искергәннәр инде. Мөмкинлеге булмагандыр, Миргаяз абый аларны яңартмаган. Йорт каршында сузылган абзарларның урта тирәсендә бер торыклык буш ара хәзер дә бар. Шул арага күрше ягыннан койма тотылган, анысы яңа, шуңа күрә абзарлар рәте, шушы бушлыгы белән, ала-кола күренә.

Гашура апа да... юк, әби инде — Миргаяз абыйның карчыгы — мине сөенеп каршылады. Алар икәве генә яшиләр иде, шуңа күрә чәй янында минем белән иркенләп сөйләшеп утыру үзенчә бер куаныч икәнен алар турыдан сиздерделәр, карт белән карчыкның хәлен белергә авыл кешеләре дә сирәк керәләр икән. Ләкин Гашура әби:

— И-и, һәркайсының үз тормышы, үз мәшәкате, үз кирәген куа инде һәркем,— дип, моны гаепкә чыгармады.— Аннары да яшьләр бик азайды бит авылда. Сугышка чаклы авылыбыз зур да иде, яшьләр дә күп иде, алар өлкәннәрнең хәлләрен белергә өлгерә иде. Хәзер авылда ихаталар кырык сигез генә калса да, карт-карчыгы ишлерәк. Кемнең генә хәлен белеп бетерсеннәр ди, яшьләрне әйтәм.

Без бер вакыйгадан икенчесенә тиз күчтек, шулай да эзлексез барган әңгәмәдән мин малай чакта белеп бетермәгән күп нәрсәләрне хәтеремдә калдырдым. Миргаяз абый (аңа бабай дип эндәшергә күнегә алмыйм) белән Гашура әби сөйләгән-

нәрне бер җепкә тезүе кыен, шуңа күрә сезгә боларның кайберләрен теркәп узып кына ирештерәм.

Миргаяз абый электә, колхозлар башланганчы күптән элек әле, итекче булган икән.

— О-о,— дип, гәүдәсен турайтып алды ул,— тирә-яктагы кайсы гына авылга барып минем турыда сорасаң да, бала-чагасына хәтле, беләбез Итекче Миргаязны, диярләр иде. Шушы һөнәрем гомерем буена барыр, дип уйлаган идем, әмма тормыш бүтәнчә хәл кылды.

Алар утызынчы елда колхозга керергә мәҗбүр булганнар. Яңа уңыш җитәр алдыннан, сез — кулак, шуңа күрә колхозны санга сукмыйсыз, дип, аларның туксан пот ашлыгын, кара айгырны, сыерны, айгыр абзарын сүтеп — тезелешкән абзарлар арасында хәзергәчә буш урында булган ул — һәм егерме җиде данә тәлинкә-чокырны алып чыкканнар, иртәгесен йорт-җирләрен ташлаттырып куарга булганнар.

— Әйберләребезне талап чыккан көнне кичен,— дип сүзгә кушылды Гашура әби,— безгә синең атаң килде. Миргаяз бабаңны, кая барсагыз да якты көн күрмәячәксез, колхозга керергә гариза яз, дип үгетләде. Монда бергә ничек тә яшәрбез, диде. Тик үзегез генә туган авылда озак яшәмәдегез менә. Шул, минем дә авылдан китәсем килми иде. Калдык шулай. Иртәгесен атаңнардан ике пот он алдык. Төнлә барып. Сезнекеләр сәвиткә чаклы җирсез ярлылар иде бит, аларны таламыйлар иде, алар колхозда да иде инде. Бер юлы ике пот он алу күбрәк иде, ләкин Миргаяз бабаң ризыкны мулдан тотып өйрәнгән кеше шул.

— Шул бурычны атаң кире кайтартмады,— дип, бу турыдагы сүзне очлауга барды Миргаяз абый.— Сиңа бурычка биреп торуымны белсәләр — мин бурыч кайтарганны берәрсе күреп калуы да ихтимал бит,— сезнең белән бергә безне дә, кулакка санап, хәзер дә куачаклар, диде. Соңрак, оныт син аны, диде. Кайчандыр үзенә кылган яхшылыгым булгандыр, күрәсең, үзем хәтерләмәдем шуны әмма. Хәзер дә хәтерләмим. Аннары сезнең нәселнең кулына керергә торганны да учламау гадәте бар иде инде. Әле дә хәтеремдә атаңның абыйсы белән булган хәл. Язгы ташу кимегәч, икебез балыкка төштек. Су тонган диярлек инде. Шарламада колач буе җәен чупырдый. Абыең янында басып тора. Капла өстенә ятьмәңне, дип кычкырам. Чүгәләгән дә шул җәеннең шарламадан чыгуына мөкиббән киткән. Мин килеп җиткәнче, койрыгын күрсәтеп чумды җәенең чоңгылга. Хәер, колхозга кергәч, бәрәкәтсезлеккә үзем дә өйрәндем, бик хаҗәтне генә кайгырта башладым. Ләкин атаң киңәшен тоту дөрес булды, гүребез, шулай боерсын инде, туган туфракта булачак. Берәүгә дә ачу тотмадым. Хәер, безгә төшкән кебек кайгыны күтәрүчеләр берәүгә дә ачу тотмаучан булалар.

Колхозда атлы эшкә йөрмәгән икән Миргаяз абый. Моны ул кара айгырын талап алуга протесты итеп аңлатты. Гомумән, кара айгырын алып чыккач, ишегалдына ат кертмәгән ул. Теге чакларда Вәлиулла бабайның атын урамда туару да ишегалдына ат кертмәскә үзенә-үзе биргән сүзенә тугрылыгы булган. Китерелгән утын-салам йөкләре дә капка төбенә бушатылган. Миргаяз абый базар көннәрдә безне куып йөргән елларда ук колхозда күмер яндырган. Кырда тубал күтәреп иген чәчкән, эскерт-кибән куйган, башка чакта каравылда торган. Беренче тапкыр безне — Әрәмә урамы малайларын кумаган көндә базарчы бабай атына киерткән эшлеяне Миргаяз бабай үзе теккән-ясаган булган икән. Кара айгыры өчен. Эшлеяне колхозга бирмәгән, урладылар, дип алдаган.

— Шул эшлея, хәер-рәхмәте, үземә кире кайтты бит,— диде Миргаяз абый һәм матчага кыстырган чыбыктагы төенчеккә үрелде. Чүпрәк эченнән шырпы тартмасы чыкты, аның эчендә эшлея тәңкәсе иде.— Гел дә бериш итеп үзем чүкегән идем тәңкәләрен,— дип дәвам итте ул.— Вәлиулла бабай, сугыш башланып авылларда базарлар беткәч, заготконтор йомышы белән йөрүен ташлады, эшлеяне кире үземә бирде. Ә, әйе, вафат инде Вәлиулла бабай, карчыгы да вафат. Йорты-каралтысы да таркалып бетте. Аларның да, Гашура әбиең белән минем кебек, балалары юк иде бит. Нигез тотарга варислары юк иде, дим.— Миргаяз абый сүзне тагын эшлея тәңкәсенә күчерде.— Тәңкәләрне балаларга өләштем. Бала-чаганың шундый кечкенә бүләккә дә күңеле була бит. Менә монысы, соңгысы, сиңа аталып калган икән. Синең өлешең. Кайчан да булса, хәлебезне белешмичә калмас әле, дип уйлаган идем. Атаң алдында бурычым да бар иде бит.

Миргаяз абый белән Гашура әбинең күңелләренә сеңгән бурыч турында эти-әни әйтүен хәтерләмим мин. Аларның Миргаяз абый һәм Гашура әби турында тәфсилләп сөйләүләре дә истә юк. Хәер, авылдан читтә яшәгәч, һәркемне дә хәтергә төшерергә җае да чыкмагандыр. Миргаяз абый базар көнне малайларны куып йөрүе белән минем күңелгә сеңеп калган бит, ә өлкәннәр моңа, бәлки, игътибар да итмәгәннәрдер...

Мин, Миргаяз абыйдан эшлея тәңкәсен алудан элгәре, баскычта калган сумкамны алып кердем, аңа чит илләрдә эшләнгән кармак-кыллар бирдем. Тик Гашура әби:

— Ни... улым, безнең елга үлде ич инде,— диде.— Басуга чыгарасы нәмәрсәкәйне быелгы ташуда елгага машиналап түктеләр. Миргаяз бабаң елганың төсен бөтенләй бетермәс өчен генә кармак салып утыра ул. Суыбызда җан иясе юк анда, үтереп бетерделәр.

Ләкин Миргаяз абый кармак-кылларны алды.

— Алай димә әле син, карчык. Күңелеңне йомшарт әле.

Белмәссең, киләсе елда балык үрчер дә аннары тиз генә үсеп тә җитәр,— диде ул.— Колач буе җәеннәр үсәр әле безнең елгада! — дип кашларын сикертте.

Тәңкәне, бармаклары арасында ышкыды да учыма салды. Аннары каршыма ук басты да башымнан сыйпады. Безнең белән базар көнне уен ясап, куып тоткач та ул безне шулай сөя иде. Гашура әби дә кытыршы учлары белән яңакларыма кагылып алды. Мин аларның олы фаҗигасен шул чакта гына бөтен авырлыгы белән аңладым — балалары булмады бит аларның... Базарда бала сатылмавын белсә дә, бәлки, Миргаяз абый анда бала алу өмете белән баргандыр; бәлки, Гашурасы аның бала белән җитәкләшеп кайтуын дүрт күз белән көткәндер... Миргаяз абыйның, кырык яшенә җиткәч, беренче тапкыр (һәм гомерендә бер тапкыр!) аракы сатып алуына балалар үстерүгә өмете өзелүе сәбәп булган икән. Бу хакта, әңгәмә барышына җай гына кыстырып, үзе әйтте ул...

Кармак-кылларны кушучына кыскан иде Миргаяз абый. Үз баласыннан беренче бүләк алган кебек сөенә иде ул. Ә без, Әрәмә урамы сантыйлары, безнең белән куышудан үзенә бәхет тапкан, безне башыбыздан сөеп үстергән Миргаяз абыебызга шушыңарчы кечкенә генә бүләк тә бирә белмәгәнбез...

Миргаяз абыйлардан чыккач, әрәмәлектә йөрдем. Караңгы инде. Миргаяз абый белән Гашура әби янына кабат кермәкче булдым. Өй турына җиткәч, акрын-йомшак моң ишетелде. Миргаяз абый кубыз чиртә иде. Саркыгандай гына моң кинәт актарыла башлады. Миргаяз абый белән Гашура әбинең балалар үстерә алмаулары сагышы һәм үзләре теләгәнчә яшәүдән мәхрүмлек кайгысы шул монда бергә кайнашып айкала иде.

*1988*

## Айның уты сүнгән...

*Әнием Бибирауза истәлегенә*

Иоланта, мин бишенче-алтынчы классларда укыганда, бездә торды. Башта, эвакуация белән килгәч тә, аның әнисе һәм әбисе дә безгә өйдәш булдылар. Әнисе белән әбисе авылда өч атналап кына тордылар да кырык беренченең август башында ук Казанга күчеп киттеләр. Иоланта алар белән хат алышты. Әнисенең-әбисенең тормышы тернәкләнүгә хат алган саен сөенде. Иоланта шәһәргә барып йөрде. Әнисе һәм әбисе авылга бер дә кайтмадылар, безгә гел күчтәнәчләр җибәреп тордылар. Минем әни аларны кунакка чакырырга беренче тапкыр кушкач ук, Иоланта:

— Юк. Юу-к, Мәсүфә апакаем, кайтмасыннар! — дип кулларын селтәде.— Монда кайтып эш калдырсалар, аларны эшләреннән чыгарырлар.

Башка юлы, кырык икенченең марты кергәч — моны мин көне-сәгате белән хәтерлим — әни:

— Син дә алар кебек җыр укытасың инде. Барып йөрисең бит әле шәһәргә,— дигәч тә, Иоланта:

— Минем буш көннәрем бар,— дип каршы төште.— Сезнең авыл кешеләре мине, сорасам, бер атнага да җибәреп торалар.— Иоланта, мәктәп директоры, димәде, авылның барлык кешеләренә бер бәя бирде.— Ә әни белән әбине җибәрмәүләре мөмкин. Аннары алар икешәр урында эшлиләр.

— Өенә сыйдырмый безне Мәсүфә, дип, мине ачуланырлар бит. Татар гадәтен санга сукмый, диярләр. Шөкер, әлегә сөтеннән-маеннан, йомыркасыннан-бәрәңгесеннән өзелмибез. Хәзинәмдә бары да якты йөзем — үзләренә.

Иоланта, алай түгеллеген аңлатып, башын чайкады. Елмая иде. Зәңгәр күзләрен тутырып миңа карап алды. Уң кулы белән чәчләрен сыпырды. Аның чәчләре соргылт-коңгырт, калын, дулкыннары эре. Чәч очлары җилкәләренә тигәннәр дә эчкә бөгәрләнгәннәр. Сул кулының бармак очлары белән авызын каплады. Авызыннан сүз чыгуын тыйды кебек. Эндәшмәде. Безнең мәктәпнең җыр укытучысы Иоланта апаның бит алмаларына алсулык йөгерде. Түгәрәк йөзе тагын да матурланды латыш кызы Иолантаның...

Боларга мин нигә игътибар иттем икән? Гүзәллекнең һаман-һаман яңаруы малай кешенең дә күңелен туктаусыз җәлеп итәдер шул...

Шуннан соң әни безгә аз вакытка өйдәш булган апаларны авылга чакырмады. Мин Иолантаның авылдан китеп йөрмәвен теләр булдым. Шәһәрдә ул ике-өч көн генә торса да, аның бездә булмавына ел тулгандыр, еллар узгандыр кебек иде. Өстәвенә әни миңа төксе эндәшә башлады. Март кергән көннән соң шулай кырысланды. Иоланта өйдә чагында мине ачуланмады, ул югында төртке сүзләрен исәпсез сипте. Март кергән көндә Иолантаның гүзәллеге, игелеге, тагын күп-күп изгелекләре чиксез икәнлегенә соклануымны миһербанлы әнием нигәдер ошатмады. Ә минем күңелем, сугыш барса да, шул сугыш кырында әтиемә һәм ике абыема үлем янаса да, әнием еш орышса да, гел яхшы сүзләр генә табарга теләде. Иптәш малайларым белән әрләшүне, кемгәдер начарлык кылып булуын оныта башладым бугай мин.

Иоланта...

Бу дөньяда шуннан да матур исем юктыр! Шушы исемнең сихрилеген белгәч, тормышымдагы һәрнәрсәне күңелемә төгәл сеңдерергә гадәтләндем, уй дәрьясына чумуның рәхәтен таты-

дым. Хыял дөньям Иолантаның мәгъруры матурлыгына, күңеле олылыгына тиң идедер!..

Ә, әйе, болай булды бит әле.

Мартның унбише иде. Мәктәптән кайтып чәй эчкәч, сыер абзарын чистарттым, сарыкларга кич салырга печән бүлеп куйдым. Ишегалды тирәсендә бүтән эш тапмадым, баз юлын ачарга иртәрәк, кар тагын явардыр әле. Аннары баз уңаен такырайтып ук көрәргә дә кирәкми, кар тыгызлангач, баз өстенең ишек төбен генә казып төшәм дә, шул тирәдәге кар базга салырга җитә. Быел безнең авылда кар мул яуды, базга сыймаганын соңыннан таратырмын.

Баскыч төбенә барып утырдым. Кояш җылыта, селкенмәсәң, битне җәйгечә кыздыра хәтта. Сыер да әнә башын кояшка куеп күши. Көз туган ике кара бәрән ишегалдын буйлап-иңләп чабышкалыйлар. Тавыклар да абзар авызында гына тукталып калмаганнар, капкагача сәфәр кылганнар.

Әни кайтып керде. Миңлекәй абый янына барган булгандыр, кулында буш ашъяулык кына иде. Көндезгә бик тәмле итеп кыстыбый пешергән иде, шуны илткәндер. Миңлекәй абый әнинең иң олы туганы ул, ялгызы яши. Үз балалары карасалар да, әни көн саен Миңлекәй абыйның хәлен белмичә калмый.

— Бу кадәр дә ата ялкау булырсың икән! — дип башлады әни.

— Мин абзар тирәсендәге эшләрне бетердем инде.

— Төпчек бала ялкау була, диләр иде аны! Хак икән, Ходаем! Хыялый җан син! Эш сөймәс зат! Ялкауның каралты түбәсендә алабута үсә. Шуны бел!

— Әни, безнең каралты түбәсендә алабута үскәне юк ла.

— Өй түбәсен кар басып төшәргә тора. Шуны да күрмисең, ичмасам!

Менә кая каеруы икән әнинең, түбә карларын көрәр чак җиткән икән. Шулай да мин...

— Әни, авылда әле берәү дә түбә карын көрәмәгән,— дип акланасы иттем.

— Яз мисалын бирә әнә! Кешене көтмә! Син башла! Җыен тузга язмаганын да син башлыйсың бит әле!

— Өй түбәсен хәзерендә ялт иттерәм мин аны!

Мин түбәгә менәргә баскыч куярга да өлгермәдем, әни чиләк-көянтә күтәреп чыкты.

— Әни, суга Иоланта апа...

— Синең Илаһәңне көтсәң! — дип бүлдерде әни.— Юләр баш син, улыкаем!

— Илаһә! Нәрсә ул... Кем ул — Илаһә?

— Хатын-кыз Алла! Синең Аллаң!

Рәхмәт сиңа, әни! Син Иолантага тагын да матуррак исем тапкансың ич! Мин аның үз исеменнән дә әйбәтрәк исем бул-

мыйдыр, дип уйлый идем, ә син аңа үзебезчә исем, Иолантага... Илаһиягә үзедәй гүзәл исем куштың! Илаһия...

Мин бу рәхмәтемне әнигә әйтмәдем. Шушы әйтелмәгән рәхмәтемне әни кайчан да булса барыбер аңлар әле...

Әни капкага таба бара башлауга, Иоланта... юк ла инде, Илаһия кайтып керде. Әнинең алдына җәһәт кенә төште дә аңа сумкасын тоттырды, чиләк-көянтәне үз җилкәсенә салды.

— Ни... ни бит, Иоланта, ни...— дип мәлҗерәп төште әле генә мине ачуланган әни.— Э-э... Бүген озакладың. Ризыкның тәме китә. Кыстыбый пешергән идем.

— И-и, Мәсүфә апа, син пешергән ризыкның тәме китәме соң! — дип елмайды Илаһия.

Күктә кояш балкый, ә җирдә Илаһиянең көләч йөзе кояш булып балкый иде. Ул миңа карамаска тырышкан булды. Карады, башын өскә чөеп, зәңгәр күзләрен тутырып карады.

— Җангәрәй, егылып төшмә яме,— дип, башын сузыбрак кыйшайтты Илаһия. Мин башымны чайкадым. Эндәшмәдем.

— Ни, улым, Җангәрәй, сак була күр,— диде әни. Аның ачуы беткән иде. Илаһия кулында шул бу дөнья, аның көченнән килмәгән нәрсә юк! — Ни, Җангәрәй улым, сиңа булышырга... ни, Миңлекәй абыең килеп җитәр.

Миңлекәй абыйның түбә көрәргә ярдәм итә алмаячагын белә әни, бу сүзләрне фикере таралып киткәч кенә әйтүе инде. Әй, миңа булышчы кирәкми ич! Илаһия чишмәдән гел миңа карап кайтыр бит әле! Ярдәм шул миңа! Тик, сукмак читенә басып, карга бата күрмәсен Илаһия...

— Ни, улым, Җангәрәй, чабаталарыңны ямьсез бәйләгәнсең. Юешне-пычракны чабаталарың үзләре эзләп табарга тора. Алгай-салгай йөрмә. Тәртипсез киенсәң, йөрешең үзеннән-үзе эленке-салынкыга әйләнә дә куя. Алгыр бул. Зирәк-уңган була күр. Нигә итекләреңне кимәдең? Хәзер алып чыгып бирәм. Килбәтең нинди булса, күләгәң шундый булыр, улым. Кешеләр күләгәңнән дә көлмәсен. Кояшы үтә җете бүген, күләгә бик анык төшә...

Мин эндәшмәдем. Әнинең сүзләрен Илаһия ишеткәндер, капканы чыккач туктап торды бугай ул. Әнинең ягымлы сүзләре аның да күңеленә яткандыр...

Кырык икенченең җәйге каникулын Илаһия тулысынча диярлек әнисе-әбисе янында уздырды. Август башында кайтты. Мин колхозда ат җигеп эшләдем. Илаһия кайткан көнне үк ындыр табагына менгән иде. Мин комбайннан ашлык алып кайткач, очраштык без. Исәнләшмәдек. Ул минем җилкәмә кагылып кына алды. Мин, аның күзләренә карап, бер мәлгә тораташ катып калдым. Илаһиянең карашы элеккечә иде. Түгел лә, аның күзләре миннән башканы күрмиләр иде! Без сөйләшмәдек.

Илаһия миңа әрҗәдән ашлык бушатырга булышты. Иптәш малайга да булышты. Бик тә ярдәмчел шул Илаһия. Шәмәрдәнгә ашлык илтәсе көннәрдә ул безгә йөк төяште, безнең — сәфәр чыгучы малайларның — аркаларыбыздан сөяр иде. Илаһия безне араламаган кебек иде, шулай да аның кулы минем җилкәмдә озаграк тора сыман. Әмма моны ындыр табагындагы берәү дә күрмәде, моны мин генә тоя идем...

Кырык икенченең-кырык өченченең кышы авыр булды, ачлык килде. Әни бу кышта кыстыбый-бәлешләр пешермәде, аш бәрәңгесенең генә кабыгын әрчеде. Шулай да ул безне тәүлек буена ач калдырмады. Миңлекәй абыйга да, Илаһиянең энисенә-әбисенә дә өлеш чыгарырга җаен таба иде минем әни. Безнең өч кешелек табыныбыз тигез иде. Әгәр әни мичкә тәгәрәткән бәрәңгене Илаһиягә яки миңа берне артык куйса, Илаһия аны әнинең үзенә сүзсез генә бирә иде. Минем Илаһиягә томырылып карауларымны күрмәмешкә салынса да, еш әрләде мине әни. Кайчак иплэп кенә акландым, кайчак эндәшмәдем.

Бер шимбәдә ачулануына да сүз кайтармадым. Үземә тиешле эшләрне бетергәч, дәрес әзерләргә утырган идем, башыма берни сеңмәде. Ишек уңаендагы ян тәрәзә каршына килеп бастым — шуңа ачуы купкан икән әнинең. Моннан мәктәп буеннан-буена күренә бит. Уйга чумганмын. Әнинең башта әйткән сүзләрен ишетмәгәнмен.

— ... тора шунда корыган агач кебек! Киемең каюы да акка кара ямау булып күренер синең өстеңдә! Аңсыз җан! Кылганың тозсыз! Тозсызны күзсез дә тоя. Юка башлы булып үсәсең бит!

Капка ачылды. Әни, кече якта кыбырсып йөрүе белән, моны күрмәде. Мине әрләвен белде.

— Нәрсә дип тешеңне шыгырдатасың әле? Һе, күр син моны! Чуртан тешен игәгән кебек торуын күр! Эш белмичә үсәсең бит! Каз оясы таралып беткән. Өйдә чит...— Әни сүзенең киртә аша очып чыгуын аңышты.— Өйдә ерактан килгән кеше яши,— дип төзәтте.— Кешеләр бер-берсен сынаучан була. Чыбыклары мең якка тырпаешып торган ояга каз утыртыйммы инде? — Ояны артык хурлап ташлады, ярамаслык түгел әле ул.— Ояты миңа, малаена эш куша белми, диярләр. Хурлык, валлаһи гынам!

Өйалды ишеге ачылды. Әни баскан урынында тукталып калды. Илаһия өйгә кергәнче тагын бер сабагын биреп өлгерде.

— Яшьтән белеп үсмәсәң, һөнәрне соңыннан бурычка алып булмый аны.

Илаһия кергәч, әни үзгәрде дә куйды, йөзе яктырды. Хәтта Илаһиягә пальтосын салырга булышты, әллә каушавыннан булды инде монысы, Илаһиягә беркайчан авыр сүз әйтмәсә дә, аны бик якын итсә дә, моңарчы аны болай иркәләгәне юк иде.

— Ни, улым, Җангәрәй, каз оясы тузыбрак киткән икән. Быелга ярап торыр, дигән идем дә, яңасында бәбкәләре ишлерәк чыгар сыман. Мишә буена талчыбыкка төшәрсең. Үзең үрерсең. Миңлекәй абыең өйрәтер. Белмәгәнеңне, дим. Анысы үзеңнең дә үргәнең бар инде. Ни, Иоланта, әллә син дә Җангәрәй белән чыбыкка төшәсеңме соң? Бер күтәреп менгәнегез ояга җитәр иде.

Үз әниеңнең әрләве дә иркәләп сөюгә әйләнә дә куя шул...

Илаһия бездә икенче кышын торганда авылга тәмам ияләнеп җитте. Казанга да еш бармады. Эвакуацияләнеп килүчеләрдән бу вакытка бүтән кеше калмады. Илаһияне берәү дә чит итмәде, гел дә үз авылыбыз кешесе ул. Хәзер татарча безнең кебек үк сөйләшә. Түгел лә, аның сөйләве йомшак, тавышы ук иркәли. Илаһия белән бер сөйләшкәч, тагын сөйләшәсе килеп тора. Өйдә без татарча сөйләшәбез, әни Илаһиядән өйрәнгән латыш сүзләрен җае саен катыштыра. Безнең авылга килгәндә Илаһия татарча сыңар сүз дә белми иде, русчасы да бикбик чамалы иде. Беренче тапкыр безнең класска җыр дәресенә кергәнен хәтерлим. Баянын — аны үзләре белән алып килделәр — күтәргән иде.

— Сөйли белми,— диде. Без класс белән көлеп туктагач: — Уйнайт итәм,— дип, үзе дә көлде.

Без инде көлмәдек. Илаһия алдына бизәкле кечкенә җәймә җәйде, баянын шуның өстенә куйды да акрын гына уйный башлады. Көе безгә таныш түгел. Аннары кычкыртыбрак уйнады. Башын баян өстенә бер иде дә бер күтәрде. Мишә болынына карый да аннары карашын түшәм почмагына теки. Дәрес буе уйнады Илаһия. Таныш түгел көйләрне без йотылып тыңладык. Аның иң башлап уйнаган көе миңа күбрәк ошады.

...Беркөнне, ут алыр чак җиткәч инде, Илаһиянең баянын алдым да шул көйне чыгармакчы булдым. Баянда түгел, гармунда уйнавым да шуның хәтле генә инде минем. Әмма уйный белмәвемнән ояласы юк иде: әни Миңлекәй абыйның хәлен белә китте. Илаһия мәктәптә, балалар белән опера куймакчы булып йөри. Илаһия беренче дәрестә башлап уйнаган көй күңелемдә яңгырый бит, баянда табам, барыбер табам мин шул көйне! Илаһия кебек итеп барыбер уйныйм!

Илаһиянең кайтып керүен сизмәгәнмен.

Ул:

— Җангәрәй! Нишләвең бу?! — дип кычкырып ук әйткәч кенә туктадым.

Ут кабызды. Пальто изүе чишелгән, әни белән икесе чөкердәшеп бәйләгән мамык шәле башыннан җилкәсенә шуып төшкән. Минем тезләрдә баян күриге сузылган килеш калган. Илаһия каршыма ук килеп басты, кулларын миңа сузды, аларны кинәт кире алып күкрәгенә кушырды.

— Җангәрәй...

Ул каршыма чүгәләде, ике кулы белән дә минем битләремне тотты, баш бармаклары белән күз төпләремне акрын-акрын гына сөйде.

— Җангәрәй... Син бу көйне баянда миңа охшатырга тырышып беркайчан да уйнама. Акыллы бит син. Мин булганда уйнама,— дип, үтенечен кечерәйтте аннары.— Үзем кушсам... Үтенсәм генә, мин янында утырганда гына уйнарсың. Насыйп булса...

Инде студент булып «Иоланта» операсын тыңлагач, мин бу көйнең Иоланта белән Водемонның беренче очрашу дуэты икәнлеген белдем. Оркестр һәм җырчылар башкаруында бу көй тулы яңгырый икән. Шулай да бу көй Илаһия уйнаганча әйтеп бетергесез көчле, тетрәткеч, сөендергеч иде...

Шул ике елның минем күңелемә мәңгегә сеңгән көннәре күп. Мондый көннәрнең, Илаһия белән икәүдән калып, сөйләшмичә дә аңышкан көннәребезнең, дим, кабатланганнары да булды. Ә бу көн кабатланмас, кабатланмаячак. Әллә кабатланырмы икән?..

Алтынчы классның соңгы имтиханын тапшырдым. Кырык өченченең июне иде. Ничәсе икәнлеген әйтмим. Нигә хәзер дә әйтмим — сәбәбен белмим. Ихлас.

Иртәгесен үк колхоз эшенә чыгарга кушканнар иде. Пар җирен сөрәсебез икән. Аннары пар җирен август җиткәнче — арыш чәчәр алдыннан инде — быел кабат сөрдерәчәкләр икән. Шундый әмер төшкән югарыдан.

Нигә җәйнең шушындый изге көнендә мин генә өйдә утырырга тиеш ди? Әнигә бүген амбарлар юарга әйткәннәр иде. Илаһия дә өйдә юк. Кайдадыр, белмим. Авылыбыздагы бер укучыга, синнән менә дигән җырчы чыга, син тумыштан актриса, дип йөри, шул кыз янына киткәндер. Өйдә баяны да күренми.

Эшкә бер башлагач, Мишә буйларын күреп булмас, дип, быел суга тимәгән кармакларымны күтәрдем дә киттем балыкка!

Тик җим казырга онытканмын. Хәер, миңа балык эләгүе кирәкми дә иде. Язгы ташу тынганнан бирле Мишә буенда булганым юк, тын урынга утырырмын да хыялыма чумармын. Хыялымда мин күп нәрсәне күз алдыма башта элем-чалым гына китерсәм дә, аннары тоныклык бетә. Һәм томансыз хыялым сихри дөньям булып әверелә.

Мишәнең уң яктан әрәмәлеккә терәлгән, сулдан ачык Кызлар тугаена җиттем. Монда тирән, монда буй җиткән кызлар гына коена, монда кеше юк, кызлар хәзер су коенырга йөрмиләр диярлек, алар эштә. Бу тирәдә кармак салмыйлар. Монда кызлар патшалыгы, ә алар балык тотмыйлар. Өстәрәк Мишәнең ике яктан да талларга төренгән тагын бер тугае бар. Каз оясына чыбыкка Илаһия белән шунда барган идек. Монда Ми-

шә тирән үк булмаса да, балык чиртүчән, чабакка салырга берничә бөҗәк тотармын әле.

Чү! Суда кемдер чупырдый! Посып кына килеп, Мишәгә карадым. Без тал чыбыклары җыйган төштә Илаһия йөзә иде!

Шым булдым. Озак йөзде ул. Судан чыкты. Җилкәсенә бөгәрләнеп төшкән чәчләрен селкеде. Яр өстенә менгәч, Мишәгә карап басты. Һәр нәрсәнең чиге була, диләр. Дөрес! Илаһиянең гәүдәсе гүзәллекнең чиге иде! Чиге иде!

Илаһия мине күрде. Икебез ике ярда торсак та, безнең күзләребез якыннар иде.

Мин, йөгереп барып, суга чумдым. Аргы ярда Илаһия мине кулын биреп тартып алды. Ул киенеп өлгергән иде инде. Барыбер шундый гүзәл, ак күлмәге юеш тәненә сыланып алсуланып тора.

— Җангәрәй...

Аннары озак эндәшмәде. Мин исә сөйләшер хәлдә түгел идем.

— Җангәрәй... Син киемнәреңне киптергәч кайтырсың...

Ул китте. Яр буйлап китте. Кызлар тугаена җиткәч кенә, борылып кул болгады. Инде еракта булса да, мин Илаһиянең зәңгәр күзләрен күрдем. Миңа караганда гына аның күзләре шулай җете була иде...

Шул кичне без койма буендагы озын имәндә утырдык. Әти аны капка баганаларын алыштырырга дип алып кайткан иде. Өлгерә алмады, үзе дә, ике абый да сугышка киттеләр. Кичләрен безнең капка төбенә күрше-тирә җыела, авыл һәм дөнья хәбәрләре шунда яңара иде. Илаһиягә татарның капка төбендә әңгәмә коруы ошый, имән бүрәнәдә иң башлап ул урын ала иде. Аның уң ягында — әнинең урыны, сулында мин утырам. Кичке әңгәмәләргә Миңлекәй абый да килгәли. Ул, өлкән кеше булса да, бүрәнә башына — читкә утыра, әңгәмәгә катышмый, сүз барышына карап, кул таягы белән бүрәнәгә суккалап кына куя. Бу хакта сөйләүдән тыелыгыз, дию буладыр, чөнки шул шак-шокны ишетүгә, сүз бөтенләй бүтәнгә күчә.

Әни бүген:

— Ай-ай Аллам ла, өйдә эшләрем бар икән лә! — диде дә кереп китте.

Үзе өйдә ут кабызмады. Йокларга ятты бугай. Бераздан башкалар да таралышты. Илаһия белән икәү калдык. Ул минем җилкәмә кулын салды, башымны тартып күкрәгенә кысты. Бу дөньяның рәхәтлеге белсәгез икән сез!..

Мин зәңгәр күкне күрәм. Алай гына түгел лә, мин Илаһиянең зәңгәр күзләрен дә күрәм! Илаһия башын читкә борды, аннары зәңгәр күккә карады. Анда тулы ай. Аңа таба аксыл болытлар йөзә. Шул болытларның кара башы айны каплый бара.

Илаһиянең сөзеп кенә әйтелгән сүзләре ишетелде:

— Айның уты сүнә... Сиңа унөч яшь, миңа егерменче китте... Айның уты сүнгән...

Иртәгесен әни мине таңнан ук уятты.

— Улым, Җангәрәем, торсаңчы. Иоланта китә...

— Ә-ә?!

— Иолантабыз китә. Әйберләрен җыештырды. Төенчеген төйнәде. Баянын безгә калдыра, сиңа. Озатырга Миңлекәй абыең да килеп җитте. Тор инде... Уян инде... Егет кеше шундый чакта йоклап ята диме!..

Уянсам да, мин тормадым. Тора калсам, бу дөньяны җимереп ташлый идем! Шул чактагы кодрәтемә сугыш дәһшәте дә тиңләшә алмый иде!..

Әни белән Илаһия сөйләшә. Өй ишеген япмаганнар, сүзләре миңа аермачык ишетелә.

— Мәсүфә апа, мин мамык шәлне алам, яме. Сезнең төсегез итәрмен.

— Ходаем ла, син үзең бәйләгән шәл ич ул!

— Без аны бергәләп бәйләдек, Мәсүфә апа. Сез өйрәтеп тордыгыз.

— Их, Иоланта, нигә бик кинәт кенә уйладың соң әле? Китмәсәң... Ни, Иоланта, безне онытма...

— Мәсүфә апа, менә сезгә бүләгем. Мине искә төшергәндә шушы яулыкны бөркәнерсез.

Әни җавап кайтармады, кече якка кереп китте бугай, аяк тавышлары шулайга баргандай ишетелде. Миңлекәй абый, гадәтенчә, сәке почмагында посып утырадыр.

Чоланга Илаһия керде. Мин яткан сәкегә утырды. Кулын җилкәмә салды. Бөгәрләнеп кырын яткан идем, чалкан борды. Минем йөземә капланды. Мин аны биленнән кочтым. Хатынкызны беренче кочаклавым иде бу минем... Йөрәк чалып-чалып алды...

Бу хәлләр бик тар арада булды. Түгел лә, Илаһиянең сулышын яңагымда мин бик озак тойдым!

Көн идеме бу, төн идеме — анык белмәдем. Ә әни таңда уяткан кебек иде. Вакыт чамасы югалды.

Өйдән әни белән Миңлекәй абый сүзләре ишетелде.

— Мәсүфә, мәсьәләгә кырысрак килдең,— дип тамагын кырды Миңлекәй абый.— Үзләре, дим, үзләре хәл иткән булырлар иде.

— Нишләп кырыс булыйм ди мин?! Араларына кысылмадым! Үзләре хәл итте бит. Иоланта үзе китте!

— Китте дә...— Миңлекәй абый йомшак күңелле кеше, минем сыман.— Дөнья бу, ниләр булмас, дим дә... Җангәрәй үсеп җитәр бит...

— Син утка май сибәргә җыенма, абый! Сугыштан, Алла

боерса, әтисе кайтыр, ни дип җавап бирермен мин аңа?! Ундүрте тулмаган малаеңны өйләндердем, диярменме? Абыйларыннан уздырып, малайны өйләндергәнсең, кәйтәнле күлмәк тә киертә белмәгәнсең, дип ачуланса, ни диярмен? Аның иң кимендә шулай дип ачуланырга хакы булачак. Ач заман бит, кәйтәнлек бизәгем дә юк. Аптыраш белән йөдәш кергәннәр өйдәш... Икесе тиң шул хәлдә калсыннармы?!

— Алай еракка китмә, Мәсүфә сеңлем. Әтисенә, абыйларына әйтмәссең. Бу хәлне Җангәрәй белән Иоланта үзләре белә дә, аннары син дә мин. Авылда ике бала... ике йөрәк газабын белүче бүтән юк. Дөнья бу... Җангәрәй үсәр...

— Дөнья! Дөнья! Олы дөньяны уйлагач, Иоланатаны озата барырга нигә башыбыз эшләмәде соң?!

— Барыйк әйдә.

— Барыйк та барыйк! Иолантабызның китkәненә инде бишбылтыр! Мишә күперен чыгадыр. И-и, Ходаем ла, Мәсүфә Иолантаны озатмады, дигән мәсхәрәгә калдык лабаса! Кайда куып җитәрмен инде Иолантаны?! И-и, Иолантакаем ла!.. Илаһиякәем лә!.. Җангәрәем минем янымда кала, җанын яшәтергә җайларын ничек тә табармын. Синең әниең-әбиең беләме соң бу хәлләрне? Әллә белмәсеннәр өчен аларны авылга бер тапкыр да алып кайтмадыңмы? Иолантакаем, балакаем ла минем, син ничекләр түзәрсең икән?! Аллакаем ла...

Шуннан соңгысын мин хәтерләмим. Башта әни мине сөйде кебек. Аннары Миңлекәй абыйның кул таягы баш очымда шакылдады бугай. Ерактан, бик ерактан тавыш ишетелде:

— Егет булыйк...

Миңлекәй абый тавышы иде бу.

Әнинең Илаһияне кайда куып җиткәнен белмим. Соңгы очрашулары турында ул миңа беркайчан да сүз әйтмәде. Ә авылда төрле хәбәрләр йөреп алды.

— Иоланта яулыгын онытка да Мәсүфә шуны илтергә йөгергән икән...

— Беләсең килсә, җаныкаем, Мәсүфә Иолантабызны куып җиткән, ди, алар кочаклашканнар да аерылыша алмыйча торганнар, ди...

— Нигә китте икән Иоланта?..

Бу сорауга минем хәзергәчә аңлатмам юк. Тик ахырда шуны гына әйтә алам.

Илаһия бүләк иткән яулыгын әни беркайчан да бәйләмәде, сандыгы төбендә саклады. Хәзер ул яулык миндә. Аны мин, ялгызым гына калгач, башыма бәйлим. Мондый чакларда тилергәнемне дә беләм. Шул тилерүдән мине Илаһия сүзләре айныта:

— Айның уты сүнә... Уты сүнгән...

*1989*

# Кич утырганда

— Ирләр үзләре генә кич утырсалар, шул булыр инде аларның: аракы чөмерерләр дә кабымлыкка хатыннар турында гайбәт чәйнәрләр!

Шулай...

Аракы кайнату бөтенләй тыелса да, барлык ирләр рупордан кычкырып хатыннарын мактап йөрсәләр дә, безләргә бирелгән бу бәя бетмәстер. Чөнки, беренчедән, дөнья хәмерсез калырга якын киләчәктә ризалашмаячак, моңа — хәмерсез калуга — хөрмәтле хатын-кыз кавеме башлап каршы төшәчәк. Икенчедән, хатын-кыз, безләрнең мактавын үз газиз колагы белән ишетеп торса да, моңа ышанмас. Җанкисәкләребезнең безләргә ышанычын үзебез бетердек ләбаса!

Хәер, бер мәзәк тә искә төшә. Аны бер тапкыр сөйләгән дә идем кебек, шулай да кабатлыйм. Ышанычка кагылышлы.

Кайчандыр-кайчандыр, әле атамыз Адәм вә анамыз Һава икәве генә чакта, атамыз Адәм, куктәге кәнсәсенәме әллә башка шөгыле чыгыпмы, эшкә китә. Соңлап кайта.

Анамыз Һава:

— Кайда йөрдең?! — дип сүз кузгата һәм атамыз Адәмне чит түтәйләр тирәсендә чуалуда гаепли.

— Дөньяда синнән гайре хатын-кыз юк ич! — дип сөенеп аклана атамыз.— Мин сине үз кабыргамнан яраттым ич!

— Ә... Ә син башка кабыргаңнан тагын бер чибәркәйне яраткан булсаң?!

Һәм анамыз Һава атамыз Адәмнең кабыргаларын санап карый. Иплән кенә, шаярып-сөеп кенә санаган, имеш. Дөнья яралгач та булган бу хәл.

Шулай да без кич утырырга җыелдык. Әңгәмәне Зөфәр башлады. Киңәш-корашта безнең остазыбыз, хәтәр төшләрне кичкәндә, юламаныбыз ул, юл күрсәтүчебез ягъни. Өстәвенә — монда ул хуҗа, без аның бүлмәсендә. Гомумән, әңгәмәләребезгә Зөфәр юнәлеш бирә. Аның башы йомры, пеләше дә каешланып беткән.

— Мин болай уйлыйм,— диде мәҗлес башлыгыбыз.— Һәм дөресе дә шулай. Башкача була да алмый! — дип, әлегә без белмәгән фикерен катгый раслап та куйды.— Хатын-кыздан да бөек, гүзәл, изге зат юк! Була да алмый! Менә мин үземнең сөеклем турында гына сөйлим. Бардым дачага. Карда йөзеп, өйгә җиттем. Ачык веранданың таянсасына кош кунган. Мине көтеп зарыгуы көн кебек ачык моның. Алдына икмәк сыныгы, сөеклем хәстәрләп җибәргән башка сыйларны куйдым. Тәлинкәгә чәй дә бүлдем. Сөенечемнән шушы кызылтүшкәйнең алдында Пеле типкән туп булып тәгәрәп йөрергә риза инде! Җәһәннәмнең теге ягындагы бакчабызда шушы бәләкәч каршы

алды бит мине! — Зөфәр, урыныннан кузгалып, ишекле-түрле йөренергә кереште. Аның кәнәфиенә яшь мишәр кереп җәелде.— Якын да килми бит кызылтүш сыема! Очты да китте, баланга кунды. Ике балан өзеп капты да тагын каршыма килде. Сайрап куйды. Тагын очып китте. Миләштән авыз итте. Минем яныма килеп сайрады.— Зөфәр өстәлгә карап алды, өстәл өсте шыр иде.— Бакчабызда булган барлык җимешләрдән авыз итте кызылтүш. Минем алга килеп сайрарга да онытмады. Ике төп кара миләш бар безнең,— дип, бүтәнгә күчте Зөфәр.— Ел саен уңышы котырып уңа. Ботаклары сыгылып төшә. Быел да чемнәре карга тиеп тора иде. Кинәт бер көтү миләш чыпчыгы очып килде дә җимешне минутында ялт иттерделәр. Агачлар горурланып турайды. Аннары чыпчыклар минем баш очында әйләнеп күрсәттеләр дә соң! Нәрсәдер әйтәләр болар миңа. Уйга калдым: сөеклем, бакча җимешләреннән кошларга өлеш чыгарып, алардан миңа рәхмәт әйттергән икән бит! Сөеклеләребезне әйтәм, үзләре рәхмәт ишетмәсәләр дә риза, тик безләрнең йөзләребез шатлыктан балкысын да дәрәҗәбезгә кош та төкермәсен!..

Мәсьәләне алдан ныклап уйлап җиткермәгән, ахры, остазыбызның фәлсәфәсе озынгарак китте. Ниһаять, туктады ул. Сүзне яшьтәше, тәпи басканнан бирле ахири дусты, Госманга бирде.

Госманның бүген кәефе шәп. Шешәгә үрелми агаебыз, хәмерне онытты, иртәгә безнең кич утыруыбыз башланган вакыт җитсә, эчүне ташлавына бер тәүлек тулачак. Зәңгәр күзләре уттай яна. Хәтта бөдрә чәчләре дә тынгы белми, дулкынланып уйный иде. Сөйләр сүзе әһәмиятледер, шуңа күрә тыныч кына утыра алмый, ахры.

— Өйдә мин мең елга бер аш пешерәм.— Хатыны пешергән ризык тәме авызына килде бугай, иреннәрен ялап алды Госман.— Әмма тәмле пешерәм инде, барысы да мактап ашый. Малайлар, мәктәптән кайтып ишекне керүгә, борыннарын сузып исниләр. Бүген ашны әти пешергән, дип, минем осталыкны ризык исеннән үк сизәләр. Ашны тәлинкәсе белән күтәреп чөмерәләр. Түземле җаным кайта. Мең елга бер тапкыр төнгә калып эшли ул. Аш бүләм үзенә. Җитте, җитте, эштә чәй эчкән идек әле без, тамагым тук, дип, мине ярты чүмеч тә бүлмәстән туктата түземле җаным. Шулай да ашны кабып карый, бик тәмле булган, дип мактый, моннан соң ризыкны гел синнән пешертербез, дип, мине үсендереп җибәрә. Бәлки, мин пешергән аш тәмле дә булмагандыр, әмма ул мине мактады бит әле. Бу катлаулы тормышта кылган гамәлләремнең ачысы-төчесе, кем белә, санына чыкмаслыктыр. Ә хәләлем, үзенә мактау миннән беркайчан да эләкмәсә дә, мине мактый, минем күңелне күрә белә!..

— Ризык турында сүз чыккач, мин дәвам итәргә тиешмен. Тәртип буенча да мин икән,— дип, сүзләрен берне калдырып тезелгән теш араларыннан сызгыртты Мәүлет. Ул безнең арада иң миһербанлы санала.— Гомер баракта узды. Шуңа күрә моңарчы балалар үстерә алмадык. Үзегез беләсез. Аерым куышта миһербанлы затым белән беренче елыбызны гына чөкердәшәбез. Безгә гел әйбәт хатын-кызлар гына күрше булды. Баракта чакта да, хәзер дә. Күршебездә ялгыз әби яши. Көн саен туй мәҗлесенә тиңләштереп табын әзерли әби. Чакыра. Керәбез. Баракта бар булганны уртага салырга гадәтләнгәнбез. Табынны минем миһербан иям әзерләшә, соңыннан өстәлен гөлт итеп җыештыра. Ризыкны өебездә әзерләп тә мине балда-майда йөздерә алыр иде хәләлем. Вәләкин ул игелекне икеләтә эшли: ялгыз карчыкка булыша һәм бер уңайдан минем сәламәтлекне кайгырта. Әйтәм ич, берьюлы! Миһербанлыкта минем хәләлемә торырлык берәү дә юк!..

— Анысы,— диде дә уң кулының имән бармагын Зөфәргә таба пистолет көпшәсе итеп сузды Латыйфи,— бакча хәлләрен мин дә күп беләм. Былтыр җәй минем кыз район газетасында практика узды. Беренче якшәмбедә үк кайтыр кебек әйткән иде. Әнисе нигәдер таңнан ук борчылды. Өйгә кайтып килим әле, дип китте бу. Йөрим бакчада үзем буе чүпләрне очыннан гына тартып йолкып.— Латыйфи буе белән безне соклandырмакчы булып үрә баскан иде, баш түбәсе түшәмне тишә язгач, лып итеп урынына утырды.— Бакчадагы чүпләр арасыннан кыз мине ничек күреп алгандыр, эти, эти, дип миңа эндәште. Әү, мин әйтәм. Эти, мин сине сагынып кына кайттым, ди. Сөенечемнән башым күккә тиде. Мин телгә килгәнче, кызым, әни кайда ул, дип, күзләре белән бакчаны айкады. Аймылыш булганнар икән алар. Шулай да кызым мине күрер өчен генә кайткан иде! Валлаһи! Мине күрүгә үк оныткан икән — монысы бәла түгел. Анага зур хөрмәт кирәк. Баланы тудыру белән генә түгел, тәрбия кыла белергә кирәк. Кызны миңа да, үзенә дә хөрмәтчел, икебезне дә олылый белә торган итеп үстерде минем акыллы бикәм. Хәзер җаны тыныч, миннән күрмәгән хөрмәтне кызыннан күрә. Минем хәләлем кебек ана була белсен хатыннарыгыз! — дип чакыру ташлады соңыннан Латыйфи.

Чират кояш әйләнеше уңаена бара, сүз миңа, димәк. Ләкин мин хатынны мактыйсы итмәдем. Мактауны яратмый ул. Бигрәк тә мин мактаганны сөйми. Әгәр мин:

— Карчыгым, бу дөньяда синнән дә әйбәт кеше юк! — дип башлап: — Булса да берәү генәдер,— дип дәвам итсәм, гомер иткән хәләлем:

— Ул да булса — син! — дип кырт кисә.

Шуңа күрә карчыгым хакында эндәшмәскә булдым, сүзлә-

рем үзенә ишетелсә, үпкәләве ихтимал бердәнберемнең. Иң дөресе — ирләрне хурлау иде. Моңа мисалларым күп. Хәтта рәсми документлардан күчермәләрем дә бар. Түш кесәмдә йөртәм мин аларны.

— Җәмәгать,— дидем һәм урталай бөкләнгән кәгазьне ачтым,— Октябрь революциясеннән соң ничәмә еллар узды, ләкин хатын-кызга чын азатлык бирә алганыбыз юк. Нинди авыр эш бар, шуны хатыннарга йөклибез. Кем гаепле моңа? Без гаепле, бары тик ирләр генә гаепле! — Кич утыручы егетләр аягүрә торып кул чаптылар. Көчле кул чабулар көчле алкышларга күчте.— Гомер буе без гаепле. Менә утызынчы елга кайтыйк әле. «Крәстиән гәзите»ннән бер хәбәр укыйм мин сезгә. Төбәген һәм гаепле кешеләрнең фамилияләрен укымыйм. Югыйсә аларның туганнары, балалары исәндер, ә сезнең авызда сүз тормый. «...колхозы председателе..., хисапчысы ...— икесенең дә фамилияләре әйтелә, икесе дә ир заты — колхозник арасында кода-кодагыйлык ясап ... батрак подрядчикларны, ятим хатыннарны җәберләгәннәр...— Хисапчының фамилиясе — исерек көенчә ятим хатыннарны куркытып, йортларына ирексез кереп, барлык эш үземнең кулда, нишләтсәм дә була...» дип йөри. Бу бит хатын-кызларны — күрәләтә мыскыл итү! Моны тик хайван җанлы ирләр генә эшли ала. Ары киттек. Сугышта хатын-кызга корал тоттырдык! Акылга берничек тә сыймый бит бу! Хатын-кыз — ана ул һәм шул вакытта үтерүчеме? Хатыннар станок артына басты, урман кисте, трактор йөртте. Без аларны мактаган булдык, янәсе, булдырасыз, сеңелләр, Ватан хакына көчегезне кызганмагыз! Авыр эшкә алынырга теләмәсәләр, куркыттык, янадык. Үзләрен кызганган булдык. Монысын күңелдән генә, үзләренә әйтмичә генә. Ирләрдән дә икейөзле җан иясе юктыр.— Тын кысылды, әмма мин тәмамламаган идем әле.— Икенче кәгазьне алыйк. Бу өзек партия Үзәк Комитетының «СССР авыл хуҗалыгын тагын да үстерү чаралары турында»гы мәсьәләне тикшергән Пленумы карарыннан. Бу Пленум 1953 елның сентябрендә булды. Тарихи Пленум ничек дип карар чыгарамы? Болай ди: «Хатын-кызларның колхоз һәм совхоз производствосында гаять зур ролен билгеләп — авыл хуҗалыгы хәзергә хатын-кыз җилкәсендә, диелсә, дөрес булыр иде — райкомнарны, өлкә комитетларын, крайкомнарны, союздаш республикалар компартияләре Үзәк Комитетларын — ягъни ил буенча — колхозчы хатын-кызлар, МТС һәм совхозлар эшче хатын-кызлары арасында масса-политик һәм культура-агарту эшен көчәйтергә, хатын-кызларны колхоз төзелешенә һәм иген уңышын арттыру һәм терлекчелекне күтәрү өчен актив көрәшкә киңрәк катнаштырырга мәҗбүр итәргә». Авыр аңлашыламы? Авыр язылган, чөнки әһәмиятле карар ул. Апайларга да актив көрәштә бил алышу җиңел булмагандыр. Има-

ным камил: бу вакытта ук игенче хезмәте — бары тик ирләр эше булырга тиеш иде инде. Чөнки гомер-гомергә шулай килгән. Шунысын да аңышыйк: карарны кабул итүче Үзәк Комитет членнары арасында хатыннар үзләре бармак белән генә санарлык була. Һәм хәзер дә без — ирләр — хатыннарны авыр эшкә чакыра торабыз. Мин Балтач төбәгендә Сәрвәр апага Герой исеме бирелүгә бик сөенгән идем. Колхозда тимерче иде ул! Шулай да хатын-кызга чүкеч суктыру аның кулына сугым пычагы тоттыру белән бер! Хатыннарда гына булган мәрхәмәт җитми ирләргә! Чүкеч сугып тимер төяргә менә шушындый әзмәверләр тиеш,— дип, мишәр егетенә төртеп күрсәттем.

— Сугарбыз! Кувалда белән бер генә тондырырмын! Йомры тимереңнән коймак пешәр! — диде мишәр егете. Үткен адәм, югалып калмый.— Мин соңыннан, әлеге чират күршеңнеке, абзыкай,— дип, дилбегәне кулына алмакчы булган иде ул, ләкин әңгәмәне башлаган остазыбыз Зөфәр:

— Бүлдермә! — дип, аның авызын йомды, үзенең ишеклетүрле йөрүеннән бүленер исәбе юк иде бугай.

Газгаликаш торып басты. Шагыйрь җанлы дустыбыз ул безнең. Кайчандыр үзенә шундый псевдоним алган булган. Хәзер дә көненә кимендә йөз сүздән торган шигырь язса да, китап чыгарыр нияте юк.

— Миннән алда нотык тоткан иптәшнең мәрхәмәтсезлек турындагы фикере белән килешик соң. Чыннан да, мәрхәмәтсез бәндә — рифмасыз-ритмсыз шигырь кебек. Димәк ки, галиҗәнаплар, рифмасыз-ритмсыз шигырь, гомумән, юк, бәндә мәрхәмәтсез икән — ул чын мәгънәсендә, гомумән, чын кеше түгел. Ә ирләрдә юньсезлек начар шигырьдәге, гомумән, начарлык хәтле. Юньсезлек нәрсәдән килә? Наданлыктан килә. Шагыйрьләребезне укымыйбыз. Бары тик шагыйрьләр генә хатыннарга гомер буена дан җырлыйлар. Кол Галидән алып бүгенгәчә, ягъни миңача,— «ча»сы бигрәк чар яңгырады,— шулай һәм мәңге шулай булыр. Бөек Тукаебызны алыйк. Тукай хатын-кызларны яратмаган, дип көчәнүчеләр бар. Ә бит Тукай хатын-кызның гүзәллегенә, түземлелегенә, миһербанлылыгына, ана булуына, авырлыкка бирешмәс көченә, ниһаять, алиһәлегенә баш игән. Үги аналарын да хөрмәт белән искә ала Тукай. Әйе, әйе, хатын-кызны Алла итеп санаган ул. Сез аның Сәхипҗамал Волжская-Гыйззәтуллинага мөнәсәбәтен күрегез. Сәхипҗамалның уенына таң калып, аның осталыгын сөйләүнең хаҗәте юк, дип мәкалә яза. Сәхипҗамалның телефоннан шылтыратып күңелен күтәрә. Сәхипҗамалның туган көнендә аңа энҗе чәчәк бүләк итә. Сез аның Сәхипҗамалга багышланган шигырен хәтерләгез.— Газгаликаш җиңнәрен сызганды да Тукай шигырен укырга тотынды:

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын,
Без үләрбез, билгеле, тик үкенечкә калмасын.
Киң күңелле бул эчеңнән, мыскыл ишетсәң, «вак» диген,
Таптасыннар, хурласыннар, тик җаның хурланмасын.

Тукай моның белән нәрсә әйтә? Син — алиһә, ди, син халкыңны алиһә булып кайгыртудан туктама, һәрвакыт алиһә булып кал, ди. Шуңа күрә Тукай Сәхипҗамалга телефоннан шылтыратып хәлен белгәндә дә, кайчан да син үлмисең, ди. Син һәрвакыт алиһә ягъни. Ә алиһәләр үлемсез! Мин үзем дә хәләлемә алиһәм итеп карыйм. Һәм хәләлем алиһәгә һәрьяктан тиң!..

Чират мишәр егетенә барып терәлде. Безнең яңа танышыбыз Зәйни исемле. Кып-кызыл зур-р битле, соргылт чәчле, кычкырып сөйләшкәндә дә иреннәре арасына кәгазь бите дә сыймастыр. Безнең арада иң яше ул, өйләнмәгән. Беркөнне Академия театрында бер каракаш белән култыклашып йөри иде йөрүен. Өйләнешмәкчеләр бугай, мишәр кызы беләгеннән бик кысып тоткан иде, ычкындырыр исәбе юктыр. Мишәр кызы да үткен булырга охшый, ике сүзнең берендә, Зәйнүшем, дип кабатлый. Зәйнине иркәләп кенә тора, күзенең карасы кебек саклый. Шулай да мин Зәйнидән юньле сүз көтмәдем. Сират күперен кичмәгән килеш, шул каракашын мактарга тотынса, чепчи юләр була Зәйниебез. Мактамады бит, әй! Торып басты. Уң кулы белән өстәлгә таянды, учы өстәлнең яртысын каплады. Катырак таянды, өстәл уртадан дуга кебек бөгелде.

— Аңламыйм мин сезне! — диде Зәйни. Өстәлдән кулын алды, өстәл тактасы пружинадай өскә атылды, шөкер, өсте буш иде.— Гап-гади нәрсәгә акылыгыз җитми. Башта менә болай хәл ителә мәсьәлә. Һәркемнең анасы бармы? Бар. Балага иң яхшы кеше анамы? Ана. Димәк, ана буларак, һәр хатын-кыз бөек. Инде мәсьәләне болай чишик. Һәр кыз баланың әтисе буламы? Була. Бала атага кадерле кешеме? Кадерле. Димәк, бала буларак, һәр кыз газиз. Инде нәтиҗә ясыйбыз: һәр хатын-кыз кимендә бер кеше өчен иң әйбәт. Шулай итеп, дөньядагы барлык хатын-кызлар да әйбәт булып чыга. Бетте! Ашыгам. Минем каракаш уңганым әтисенең кызы булуы белән яхшы. Һәм минем балама ана буларак яхшы хатын булачак,— дип бетерде Зәйни, «ч»ны чылатып та күрсәтте соң, Зәйнинең мишәрчәсен оныттыра инде әллә теге мишәр кызы...

— Таралыштык,— диде Зөфәр һәм, ишек бикләргә баракта торып ышаныч казанган Мәүлеткә кушып, чыгып йөгерде, хатыны утырмадан кайтырга тиеш икән, шуңа күрә ашыгуы.

...Кич утыруыбызны төн буе яздым. Иртәгесен укып чыккач:

— Булмаганны! — дип әйтеп куюымны үзем дә сизмичә калдым.

Хәләлемә укыттым.

— Булмаганны! — диде.

Безнең фикерләр туры килде.

Эшкә баргач, Зөфәр укыды. Шул ук сүзне әйтеп кул гына селтәде, хатыны утырмадан аңардан алда кайткан, ахры.

Госман бер армия малайларына аш пешереп ашатудан тәмам арыган кыяфәттә иде.

— Бул... Булма...— дип, сүзен дә әвәләп чыгара алмады.

Мәүлет, Латыйфи һәм Газгаликаш шул ук сүзне кабатладылар. Зәйни дә:

— Булмаганны! — дип, тәрәзә каршына кулын күтәрде, бүлмә караңгыланып китте, соңлавы өчен каракашыннан эләккән бугай.

Безнең барыбызның да фикерләре уртак булып чыкты. Тик менә кайбер нәрсәләрне аңышмыйча калдым. Хәләлем, ирләр хатыннарын мактыймы соң, дип нәтиҗә ясадымы, әллә безнең кич утыруның хәмерсез генә булуына ышанмадымы? Әңгәмәдәшләрем нигә шул сүзне кабатлады икән? Өйләренә кайткач (ә Зәйни сөйгәне янына баргач) булган хәлләрдән соң, кичә сөйләгәннәреннән ваз кичтеләрме? Үземнең дә бу сүзне нигә әйтүемне белмим. Авыздан очты да чыкты ул. Шулай да мин үземне, дөрес сөйләдем, дип саныйм. Кич утырганда, мин хатыннарны мактамадым, ирләрне яманладым. Ә моңа ир заты күнеккән инде. Ходай ни язганын һәм язмаганын күрә дә, түзә дә ир башлары!

Аннары.

Юләр хатынын мактар, диләр. Хатынын яманлаучы — акыллы зат, димәк. Кич утырып хатыннарны хурларга безнең акыл җитмәгән, юләрләр булдык ягъни. Әй-й, юләр, эчкече, хөрәсән, булдыксыз һәм шуның ише барлык сүзләрне дә күтәрергә риза лабаса ирләр! Хатыннар хакына.

*1989*

## Мәгарә

Урамнар чирәмсез. Югары Губаха урамнары. Шәһәрчекнең без утыз җидедә яшәгән урамында пужумнар ишле, үзәктәге ике катлы йортларның күбесе ишексез-тәрәзәсез, ишелгәннәре хәтсез. Кешеләр хәзер моннан чит җирләргә китәләр яки якындагы яңа шәһәргә күчәләр икән. Ә Яңа Губаха шәһәрен мин бала чагымда күргән кулара уңаена салганнар. Шәһәр шул якка таба үсәчәк икән, әлегә уенчак кәлтәле куларага терәлмәгән ул. Ләкин мин кулара ягына бармыйм. Утыз җидедә без качып яткан кулараны һәм шул тирәнең урманын-елга-

сын кабат күрергә, әйтәм ич, йөрәгем җитми. Ә Югары Губахада — иске шәһәрчектә — бала чагым сукмакларыннан кабат-кабат йөрим, мондагы туганнарыма килүемә бишенче көн. Туксан бернең апрель уртасы узгач бу.

Югары Губаханың, аның тирә-ягының утыз җиденче елдан соң бик тә үзгәрүенә илле тугызда килгәч тә гаҗәпкә калган идем. Хәзер күргәч, шәһәрчекнең чыннан да Югары Губаха булуына ышанмыйча тордым.

Элек биек агачлар каплаган таулар шәп-шәрә. Шәһәрчекнең һәр ягы шулай. Югыйсә тауларга йортлар салмаганнар бит — урманнарны тамырыннан кыруның ни хаҗәте булды икән? Элек ярларын тутырып аккан Косьва елгасы хәзер ташу суыннан да тулмаган.

Күмер беткәч, мәгъдәннәр ябыла — шахтерлар язмыш кочагында онытылып кала икән.

Иске шәһәрчектә йорт тергезүче күрмәдем. Ятим йортлар... Авышкан коймалар... Җимерек сарайлар...

Әнә таш йорттан шәлперәйгән кыса гына калган. Шуның янында, юан тупылга сөялеп, йөзен сакал күмгән берәү тора. Аның күзләре дә иреннәре генә күренә, хәтта борыны юк кебек, бәлки, ялпак-җәенкедер. Йөзен күргәч, имәнмичә мөмкин түгел — маймылның кешегә әверелүе карашында чагыла сыман. Тик әлеге маймылның кешегә әйләнүендә бер хикмәт бар — ул киенгән һәм әнә тәмәке кабызды. Шырпысын бөтергәләп сүндерде, читкә атмады, бармакларын аерып төшереп җибәрде. Шырпы, беләүләнгән халатына бәрелеп, аягы кырында сузылып яткан этнең сыртына кунды. Эт моны сизмәде, ул тупасалапай йонлач иде. Аның озын йон арасына тулган ташкүмер комы да тәненең тою сәләтен бетергәндер, күрәсең.

Алар яныннан узасы килмәде минем, ләкин турыларына җиткәндә урамның каршы ягына борылу уңайсыз. Баш кагып исәнләштем. Адәми зат:

— Сәлам. Привет,— диде.

Тавышы тышкы кыяфәтедәй иләмсез түгел, баланыкы сыман йомшак. Мин аның күзләренә текәлдем. Күзләре йокымсыраган. Әмма томан пәрдәсе йокымсыраудан түгел, ә күзләр тумыштан топ-тоныктыр булып тоелды миңа.

Каршысында тукталып ук калганмын, моның сәбәбе, ихтимал, бу кеше миңа таныш лабаса, дигән уй башыма килүдәндер. Тик таныш йөзне сары вә кара йоннар буталышып каплаган. Адәми зат та миңа текәлеп карый иде, хәер, аның җентекләве мине белүеннән түгелдер, Югары Губахада ят кеше күрүеннәндер.

Ул, юлында бул дигәндәй, башын акрын гына селкетте, минем һаман кузгалмавымны ошатмады, китәргә кулы белән ишарәләде. Эте, аның бу хәрәкәтен аңлап, миңа ташланырга мөм-

кин иде, әмма ул йончыган кыяфәттә битараф ята бирде. Юаш эт, күрәсең.

Бу кешенең миңа абыймы әллә энеме икәнен йөзеннән чамалап булмады. Гафу, агайне, син — замана карачкысы, дип хөкем чыгардым мин күңелемнән. Йөзең-битең, кием-салымың шундый бәяләмә таләп итә. Хәясыз бәндәдерсең, оят белсәң, күрексез кыяфәттә урамга чыкмас идең. Югары Губаха кешесеме син әллә горбәттә йөрүеңме? Ләкин туган җиреннән читтә каңгырып йөрүче дә мондый ук алама хәлгә төшмәс, ә сине кешегә охшату кыен хәтта.

Агачка сөялүе хәлсезлегеннән түгел аның. Нык бәдәнле ул. Янынннан узганда, гәүдәсен кодрәт ташламавы минем тәнемә гайрәт уты булып бәрде. Бу бәремдә җир астыннан әле генә чыгарылган тимер салкыны да бар иде. Шактый ара киткәч тә, кайнар ялкынлы да, котып салкынлы да дулкын аркамны көйдерде дә өшетте.

Чатка җиткәч, борылып карадым. Адәми зат йонлач этен күкрәгенә күтәргән, аны уңлы-суллы үбә иде. Аннары этне, бәбәй итеп, беләгенә салды да урамның аргы башына таба китте. Үзе турында кешеләрнең ни уйлавына гамь бирми икән ул. Әмма киң һәм тигез сукмактан барса да, адымнары сак. Каршысына очраучылар аңардан читкә тайпылмыйлар, бәлки, бу абзыйның үзләренә зыян итмәвен беләләрдер. Шулай да тукталып сөйләшмиләр, бәлки, якыннан аралашуны өнәмиләрдер.

Сәер кеше күрүемне туганнарыма әйттем.

— Миркадәм ул,— диде туганнан туган апам.— Мәхлук җан. Гомере заяга үткән.— Һәм бераздан: — Үтте,— дип үзгәртте.

— Югары Губаха кешесемени ул? Акылга зәгыйфь мәлләә?

— Син аны оныткансыңдыр шул,— дип, мине гаҗәпсендерде апам.

— Андый исемле кешене белгәнемне хәтерләмим.

Апа бүлдерүемә игътибар итмәде.

— Шушы Губаха тумасы Миркадәм. Аның хәленә төшкән кешенең акылын җуймаганы сирәктер. Ә Миркадәм акылында. Хәтерләмисеңдер шул,— дип кабатлады апам.— Сез утыз җидедә монда торганда күргән булырсың аны. Малайлар бик тә бердәм идегез. Миркадәм безнең урамга уйнарга килгәли иде. Үзәктәге ике катлы йортта тордылар алар. Өске катында. Хәзер бу йортның кысасы да шыксызланып шиңгән.

— Шунда күрдем мин аны. Сагынып килгәндер. Анда яшәрлек түгел.

— Миркадәм кайда да кунар, туңмас.— Апам тирән сулады да елмайды.— Хәтерләргә тырыш, исеңә төшәр. Бергә уйный идегез. Сирәк килә иде килүен безнең тирәгә. Озын буйлы, ясаткан кебек бөдрә чәчле малай иде ул. Кара бөдрә чәчле.—

Апам тагын елмайды.— Чибәр дә малай иде соң! Син аның күзләрен хәтереңә тизрәк төшерерсең. Иртәнге кояшта тау чишмәсе шома ташларда уйнаклаган кебек җем-җем ялтырый иде Миркадәмнең күзләре!

Менә монысына һич тә ышанасым килмәде. Шундый күзләр иртәнге уңайда мин күргән йокымсырау, томанлы, топ-тонык күзләргә ничек әйләнә алсын ди?! Ләкин апам Миркадәмнең язмышы турында сөйләгәч, коточкыч үзгәрешнең мөмкинлегенә ышандым. Әйе, андый үзгәреш, гомумән, мөмкиндер. Әмма барыбер йөгерештә берәүне дә уздырмаучы, үзе ясаган җәядән укны тәмеккә — ә мишень итеп бакча башындагы биек төпне сайлый идек без — беренче атуда кадалдыручы җитез хәрәкәтчән малайның мин күргән Миркадәмгә әйләнүе хыялда гына мөмкиндер, дигән шигем бетми. Балачактагы осталыкларын хәтерләдем, ләкин мин белгән буйчан малайның бүгенге Миркадәм булуы мөмкинме?.. Җем-җем күзле малай минем күңелдә уйнак булып хәтерләнде. Шулай да ул бүгенге йокымсырау Миркадәм икән. Тик исемен онытකан булганмын мин аның — Миркадәмнең.

Төштән соң Миркадәмне очраткан урамга бардым. Аны күрмәдем. Яңа шәһәргә киттем. Эш юклыктан.

Яңа шәһәрдә сокланырлык үзгә йортлар, хәтергә сеңдерерлек күңел ачу урыннары юк. Яңа шәһәрдә яңача — бездәгечә, ашык-пошык салынган йортлар шырпы тартмаларына охшаганнар. Киләп сарып йөргәч, кайту ягына борылдым. Автобуста кешеләр аз, шәһәрне аркылы узачакбыз, автобус тулыр, Югары Губахага кайтучылар күп була моннан.

Бер тукталышта алдагы ишектән Миркадәм керде, күкрәгенә йонлач этен күтәргән. Баскычтан менгәндә үк шоферга:

— Сәлам. Привет. Хәерле сәфәр,— диде.

Шофер елмаеп баш какты, аның елмаюында кызгану сизелде. Моны Миркадәм күрмәде бугай, үзен кызгануны абайласа да, бәлки, мөнәсәбәтен белдермәс иде.

Миркадәм ашханә тукталышында утыргач, мин аны, сырафәлән эчеп чыккандыр, дип уйладым. Ләкин ул салмыш түгел иде.

Тәрәзә уңаена утырды. Йонлач эте алгы аяклары белән аның җилкәсенә басты, автобустагы кешеләргә карап чыкты. Күзләрендә үтенеч иде этнең — кешеләр, сез минем хуҗамны кимсетмәгез, аның акылы сайрактыр, әмма ул тиле түгел, читләштермәгез аны үзегездән, ялгызлыктан күп интеккән ул, кешеләр, аңа иптәш булудан оялмагыз, хуҗама минем генә иптәш булуым җитми...

Ләкин Миркадәм этенә зар-үтенечен кешеләргә аңлатып җиткерергә ирек бирмәде, аның башын йон каплаган кулы белән алга борды. Миркадәмнең каршысында урын буш иде, шунда

күчтем. Йонлач эт миңа таба үрелеп иснәнде. Миркадәмнең йокымсыраган күзләре мине әллә күрмәде тагын, каршысында утыруыма игътибар итмәде ул.

— Миркадәм, исәнме. Мин сине бала чактан беләм.

Ул сискәнеп сагайды, бер мәлгә күзләрендәге томан пәрдәсе ялт ачылып, миңа томырылып карады да күзләрен йокымсырау тагын басты. Күзләре куркыныч килгәндә җетеләнергә, ял иткәндә томанга капланырга күнеккән, ахры, аның. Әмма мин аңа янамыйм ич, димәк, ул миннән сагаеп шикләнмәскә тиеш иде.

— Утыз җиденең җәендә без очрашкалый идек, бергә уйный идек. Онытмаган булсаң.

Инде сискәнмәде ул һәм балачак танышын очратуга шатланмады. Этенең башын сөеп, тәрәзәдән шәрә тирә-юньгә карап эндәшмичә утырды. Юл буйларында карашны җәлеп итәрлек нәрсәләр күренми иде югыйсә. Чокыр-чакырларда, иңкешләрдә эреп бетәргә өлгермәгән кар, күмер тузанына капланып, саргайган былтыргы үләннәрдән каралыгы белән аерылып тора, тик бу кадәресе Миркадәмне уйга салырлык яңалык түгел, ул моңа күнеккәндер. Ә... бәлки, күнекмәгәндер, безнең бала чактагы урманлы тауларны, чирәмле урамнарны күрәдер Миркадәм?..

Ул кузгалды. Югары Губахага җиткәнбез. Беренче тукталышта ук төштек. Эт, чабып йөреп, аякларын язды, аннары безнең янга сузылып ятты. Миркадәм арзанлы сигарет кабызды, мин тәкъдим иткән фильтрлыны алмады. Сөйләшү оешып китмәде.

Ниһаять, Миркадәм:

— Нигә, алайса, мине белгәч, моны миңа иртән әйтмәдең? — диде.

— Танымадым.

— Мин дә сине танымыйм.

— Апам әйткәч кенә исемә төшердем сине.

— Ә сине исемә төшерергә минем апам юк. Минем беркемем дә юк.

— Берчакны син минем җәямне көйләп биргән идең. Ничек төзәргә өйрәттең.

— Мин өйрәткән бит. Син хәтерлә.

— Син җәядән бик төз ата идең!

— Хәзер дә төз атам.

— Ничек — хәзер дә?!

— Хәзер дә. Җәяләрем дә күп, укларым да шәп. Мәгарәдә алар.

Апам Миркадәмнең мәгарәдә яшәве турында сөйләгәч, әйткәнемчә, моңа ышанып җитмәгән идем. Хәзер инде моны аның үз авызыннан ишеттем. Ялган-йолганнардан ераклыгы сизелеп тора Миркадәмнең, сүзләренең хаклыгына шул ышандыра.

— Җәядән атарга үзебез яшәгән йортның бакча башына чыга идек. Әнә-ә,— дип күрсәттем мин,— урамга буе белән салынган алты почмаклы йорт. Зәңгәр тәрәзәле. Элекке йорт эчтәрәк иде.

— Син яшәгән йортны нигә мин хәтерләргә тиеш ди? Кирәк икән — үзең хәтерлә.

— Әнә ич мәгарәле тауга менә торган сукмак, мәгарә сукмагы, без яшәгән турыда ук. Мәгарә авызы тауның теге ягында, кыялы ягында.

— Минем мәгарәм бүтән.

Кыялы тау мәгарәсе тирәсендә кешеләр ел әйләнә өзелми икән. Альпинистлар кырт киселгән биек кыяга менүдә ярышалар, туристлар борынгы мәгарәне карарга киләләр. Бу якларда мин бүтән мәгарәне белмим. Ә Миркадәмнең мәгарәсе...

— Үзем казыдым мәгарәне,— дип ачыклады ул.

Сүз өзелде. Ләкин аерылышып китеп бармадык. Сөйләшер сүзләр табылып кына торырга тиеш ләбаса, тик алар тел очына килүгә эреп югалалар.

— Син һәр эшне оста эшли идең, хәтта качышлы уйнаганда да таба алмый идек без сине.

— Мине хәзер дә таба алмыйлар.

Тагын берара сүзсез тордык.

— Миркадәм, нигә син минем исемне дә сорамыйсың?

— Мин үз исемемне генә беләм. Башкаларның исемнәрен күптән оныттым. Бу этнең дә исеме юк. Дөньягызны да, үзегезне дә исемнәрегездән мәхрүм иттем! Мин мәхрүм иттем!

Мондый хөкем чыгару өчен хаклыгың бәхәссез булуы кирәк...

— Миркадәм, бәлки, мин сиңа ярдәм итә алырмын? Сиңа нәрсәләр кирәк?

— Миннән бер нәрсә дә артмый. Ни бирсәң дә — алам. Чәлдерәсе булмас.

— Бәлки, монда торып калырсың? Җайларсың тормышыңны.

— Кирәге бар иде! — дип тавышын күтәрде ул, йөзен җыерды бугай, озын сакалы күченгәләде.— Сезнең монда җан асравыгыз минем мәгарә тормышымнан шәбрәк дип белдең мәллә?! Сезнең тормышыгыз нәгъырәдән гыйбарәт! Акырыш та бакырыштан бүтәнне белмисез! Элгәре авылдан шәһәргә ябырылдыгыз, хәзер шәһәрдән авылга таясыз. Ләкин бер нәрсәне аңламыйсыз: борынгыга кайтмыйча — мәгарәгә бөтенләй күчмичә, тормышыгыз барыбер рәтләнмәс!.. Күзгедән карамасам да, белеп торам — сезнең нәгъырәле яшәешегезне күргәч, күзләрем ямьсезләнә минем! Мин — иркендә! Акырышсыз-бакырышсыз мәгарәмдә!

Мәгарәдә ничек көн күрүе турында мин аңардан бер нәрсә дә белә алмадым, сорауларыма җавап кайтармады ул. Яшерен

мәгарә авызын беркайчан да беркемгә дә ачмаска ант иткәндер Миркадәм. Алмасар түгел Миркадәм, кырыс урман һәм шомлы мәгарә кануннары аны әйле-шәйле йөрмәскә, икеләнмәскә өйрәткән.

— Туры ук тәмеккә тияр, җәя кулда калыр,— дип фәлсәфәгә бирелде ул.— Серең ук булып очса, мәгарәң дә очар. Икесе дә очар. Сернең ук булмавы хәерле.— Фәлсәфәсенең мәгънәсен аңлап җиткермәдем.— Шулчакта гына мәгарәң үзеңнеке. Эт тә алып барганым юк анда.

Кичке уңайда мин аңа биштәр тутырып әйберләр илттем. Ул үзләре яшәгән йорт янында йөренә иде, эте үзеннән адым да калмый. Биштәрнең авызын чишеп карады, апам хәстәрләп салган әйберләрне ошатты бугай — тел шартлатты. Эндәшмәде, җимерек сарайга таба китте. Эте иярде. Хуҗасы аны тиздән ялгыз калдырасын сизәдер. Бәйрәме бетә этнең...

Мин дә алар артыннан бардым. Сарайның салынкы ишеге төбенә җиткәч туктады Миркадәм, минем ияреп эчкә керүемне теләмәде.

Бу кешедән файда күтәргә сондыр, игелек юк аңардан, дип уйладым мин. Ләкин мондый уй җимерек йортларның килбәтсез кысаларыдай шыксыз иде, шул шиңгәнлек йөрәгемне куырды: Миркадәмне кеше исеменнән мәхрүм итәргә маташу — гөнаһ! Хаклы... Хаклыдыр... Хаклы Миркадәм!

Мин аны бүтән очратмадым.

Мин аның күзләре иртәнге кояшта тау чишмәсе шома ташларда уйнаклаган кебек җем-җем ялтыравын бер генә тапкыр күреп калдым.

...Миркадәм, сугыш башлангач, шахтага күмер чабарга төшә. Әнисе белән икесе эшләп тапкан мал җитеп бара аларга, сугыш заманына күрә тамаклары тук була. Сугыш бетәсе елда шахта кассасыннан акча урлана. Миркадәмнән шикләнәләр. Чакырталар.

Малай:

— Мин урламадым! — дип ачыргалана.— Абыйлар! Мин угры түгел! Түгел!

Милиция бүлегендәге изоляторның идән астын казып кача ул. Тикшерүчеләр, димәк, гаебе бар, югыйсә качмас иде, урлауда әнисе дә катнашкан булырга тиеш, дигән нәтиҗә ясыйлар. Әнисен гаепсезгә хөкем итәләр, ул төрмәдә вафат була. Шахта кассасын басучыларны соңрак тотканнар тотуын...

Миркадәмнең шушы качудан соңгы тормышы билгесез. Ил буенча йөргәнме ул, әллә башта ук мәгарә казып гел шунда ятканмы — үзенең бу хакта Югары Губаха кешеләренә сөйләгәне юк икән. Туган җирендә, бала чагы үткән Югары Губахада туксанынчы елның җәеннән генә күренә башлаган. Милиция аның монда — туган җирендә! — чит кеше икәнлеген

хәзерендә белеп алган, тик аңа чара күрерлек гаебен тапмаганнар. Хәтта Миркадәмгә, имеш, пенсия бирдертмәкче булганнар. Әмма:

— Ни өчен? Качып яткан өченме? Андыйларга пенсия түләү законда каралмаган! — дип кырт кискәннәр югарыдагылар.

Ә картлар йортында яшәргә Миркадәм үзе теләмәгән. Бер төн кунган ул анда, иртәгесен, таңнан ук, картлар йортының хуҗасын уяткан да хушлашып киткән. Шуннан соң власть кешеләре аның язмышына кул селтәгәннәр — йөри бирсен, яшәгән хәтле яшисе калмаган...

Миркадәмнең язмышы өчен кемне гаепләргә дә белмәссең. Үземе? Юк! Аңа угры, дип яла ягучылар инде исән түгел, димәк, аларны җавапка тартып булмый. Буыннары ныгымаган Миркадәмне җир астына төшереп күмер чабарга мәҗбүр иткән сугыш гаеплеме? Бәлки. Әллә бергә уйнап үскән яшьтәшләрендә — бездәме гаеп? Әгәр нәкъ мин гаепле икән — җәзасын күрергә әзермен. Тик тәгаен әйтегез — гаебем нәрсәдән гыйбарәт?

...Ноябрь азагында Югары Губахадагы туганнан туган апам Миркадәм турында әйтеп хат язды. Миркадәм апамнарга кереп — йортны хәтерләрлек итеп күрсәткән идем бит — мине сорашкан. Йонлач этен күкрәгенә кысып, энегез белән уйнап йөргәннәремне хәтерләмим, дигән.

Бала чакның уены искә төшмәслек булып онытылыр икән, әй... Коточкыч.

*1991*

# Үкалы карлар

Караңгы кабаланып иңә. Капка төбендә утырам. Ике инеш кушылган тамактан гармун дөнья яңгыратып аваз салды. Яшьләрне чакыра — кичке уен башланыр чак җитә. Уенга төшмәмдер.

Бүген ике тапкыр урманга бардык. Бәла дигәнең аяк астында посып та ята, биектән тәгәрәп тә йөри икән. Урак өсте җитәргә торганда, әвеснекнең түбәсе ишелде. Шуны яңартып япмакчыбыз. Кайчы-бәпкәлекләр күп кирәк, искеләреннән яраклылары табылмады. Без бүген өч ат белән икешәр тапкыр алып кайткан агачлар гына чыгышлarлык булмаячак. Кайчы-бәпкәлекләр генә булса да, чыршыны төптән егып ботавы, бигрәк тә озын арбага төяве безгә — үсмерләргә авыр шул. Арылган. Шулпаны да чамасыз чөмергәнмен. Корсак күпте. Кичке уенда берәүне дә биетмичә калдырмыйлар. Уртага чыгып тыпырдый башлауга корсагың шартласа, гомерең буена адәм рә-

тенә керә алмассың. Төшмим кичке уенга! Адәм хуры ясамыйча торсыннар әле миннән! Аннары әлегә кымшанырлык та хәл юк. Көч җыеп әзрәк утырам да кереп ятам. Иртәгә дә урманга барасы.

Түбән очтан, безнең яклатып, берәү килә. Кичке уеннан башланыр-башланмастан ук борылган бу кешенең кем булуы анык шәйләнми. Ашыга. Ара якынайгач кына җил-җил атлавыннан таныдым — уеннан менүче түгел, бригадирыбыз Хәервафа апа икән.

Яныма утырды. Миңа иртәгә Арчага барырга кушты. Авылдаш малайны хастаханәдән чыгарачакларын хәбәр иткәннәр. Арчага комбайн моторын төзәттерергә илткәч, аягын сындырган иде ул.

— Бурлы бияне җигәрсең,— диде Хәервафа апа.

Аның һәр әмерен казык каккандай итеп әйтүенә без күнектек, бригадир апабызга кырыслыгы өчен рәнҗемибез. Үзе җигә торган Бурлы бияне Арчага җибәрәсе булгач, монысы мине шәп ат җиктереп сөендерүдән түгел, авыру кеше хәленә керүдән инде.

— Тарантаска җигәрсең.— Димәк, бу хакта ул колхоз рәисе белән сөйләшкән, чөнки тарантаста рәис кенә йөри, бригадир Бурлы бияне силәгә җигә иде.— Әллә үзем барыйм микән соң? — дип уйга калды ул.— Малай... үсмер башыңнан ялгыз башыңны ерак юлга чыгарам лабаса! Сине урманга җибәреп, Арчага үзем барыйм микән соң әллә? — Мондый икеләнүкабатлаулар аңарга хас түгел иде.— Йорт-җирем ялгыз шул. Ике баланы кемгә калдырасың ди? Әле болай мин өйгә сугылгалап йөрим. Арча — сиңа! Мин синең ат белән бәпкәлеккә барырмын. Бурлы бия юыртырга күндәм. Яктыруга кузгал. Арча ерак. Кырык чакрым.

Арчаның безгә кырык чакрымда икәнен мин дә беләм лә, күп йөрелде инде бу арада. Быел май азагында гына да ике тапкыр керосин алып кайттык. Хәервафа апа, юлның еракльн искәртүе белән, көнен әйләнеп кайта алырсыз микән, дип шикләнүен турыдан әйтеп кенә бетермәде. Көнен әйләнү өчен Бурлы бияне җиктерә бит ул миңа югыйсә.

— Әче таңнан юлга куып чыгарам сине! — дип, апаларга хас булмаганча, тешләрен шыгырдатты Хәервафа апа.— Ерак юлга! Фашист гаепле, энем. Берәр фашистны очратсам, бугазын буар идем! Гөнаһысы булмас иде! — дип кузгалды ул.

Һәм әйткәнен эшләячәк тә ул. Бригадир апабызны ачуы купса, игенә китерүе яман авыр икәнлеген без, сугыш еллары малайлары, шәп беләбез.

...Дилбегәне тимер тоткага бәйләп, тау итәгендә тарантастан төштем. Бурлы бия таш юл читендәге арба тәгәрмәчләре эзеннән алгы аякларын чокып басып, адымын кызулатты. Тау

менгәндә гадәте шундый, авыр араны җәһәтрәк узарга тырыша. Әмма бу юлы йөге юклыгын онытып җибәрде бугай. Берәздан шуны абайлады, акрынайды. Башын каты итеп селкегәч, калын озын ялы уйнаклады.

Тау уртасындарак мин кичә урманга җиккән кебек озын арба тартып менүчеләрне куып җиттек. Бу кешеләрнең йөзләре йончу, киемнәре — алам-салам гимнастерка-чалбар, тиргә батканнар, аркалары хәтта лычма. Ничәү тарталар алар? Дүртәү... Күзләр әлҗе-мөлҗе килә — әллә алтау, әллә сигезәү... Арба артыннан автоматлы солдат бара. Арбада ике йөз литр сыйдырышлы ике мичкә, алар да тирләгән, су тутырылган, ахры, аларга, юпь-юешләр. Арбаның арткы сул тәгәрмәче «салмыш» — тышка кайшала да, эчкә авышып, арба агачын кыршый.

Бурлы бия, юлның таш түшәлгән уртасына чыгып, озын арбаны узды.

Арчаның озын һәм текә тавын җәһәт мендек.

Тимер юл станциясендәге нефтебазага һәм ашлык кабул итү пунктына еш йөрсәк тә, Арчаның үзенә беренче менүем иде. Хастаханәнең кайда икәнлеген бер ападан сорадым.

— Базар яныннан узсаң, турырак булыр,— диде зәңгәр күлмәк кигән, балитәкле ак алъяпкыч япкан апа.

Ул ашыга иде, миңа юлны төенчеген кулыннан кулына күчерә барып әйтте.

Базарга җитәрәк, аркылы урамнан солдатлар килеп чыкты. Сафларга тезелгәннәр, күп алар. Бурлы бияне урам читенә тарттым. Киемнәре баштанаяк яңа бу солдатларның, аркаларында да яңа биштәр. Һәркайсы сул кулына ак күмәч тоткан. Ап-ак, түп-түгәрәк — андый күмәчләрне сугыш башланганнан бирледер күргән юк иде. Нигә биштәрләренә салмаганнар икән күмәчләрен? Нинди солдатлар соң болар? Кораллары юк, погоннары да юк. Сафлар әйләнәсеннән автоматлы солдатлар бара.

Коралсыз һәм погонсыз солдатлар базар мәйданында әле узып киткәннәреннән башка да булганнар икән. Аларны төркемнәргә аералар иде. Өлкән лейтенант фамилия укый да сафлардан чыгучы солдатка кайсы төркемгә кушылырга икәнен күрсәтә. Фамилияләрнең ят булуын ишеткәч кенә аңыштым — немец әсирләре икән алар. Таудан озын арба тартып менүчеләр дә әсирләр булган икән. Тик алары бик тә йончыганнар һәм сәләмә киемлеләр иде. Болары, әйтәм ич, яңа киемнәрдән, кулларында берәр бөтен татар калачы да бар. Биштәрләренә нәрсәдер тутырачаклардыр, биштәр буш йөрмәс бит. Кая баралар алар? Кая алып баралар икән аларны?

Сугыш беткән елның июль уртасы иде бу. Урак башланыр чак җитә, ә безнең әвеснек җимерек. Сугыш чыкмаса, безнең әвеснекне җимерелгәнче яңартырлар иде, иптәш малаебыз Арчага комбайн моторы илтеп йөрмәс һәм гарипләнмәс, моторны

үзебезнең авылда ук төзәтерләр иде. Мин дә, ялгызым ерак юлга чыгып, хокуктан мәхрүм ителгән әсирләрне — хәер, Арчага аларны китермәсләр дә иде — очратмас та идем. Кешенең мескенлеген, газаплануын күрү һәм аңа булыша алмау — үзе үк газап лабаса. Тормышымда бер газап ким булыр иде, дим.

Әсирләрнең берәүләре нигә озын арба тартып су ташыйлар да икенчеләре кулларына калач тотканнар соң әле? Сугыш чыкмаса, миңа бу кызыксыз һәм мәгънәсез сорауга җавап эзләп газапланырга туры килмәс иде.

...Аягы сынган авылдашымны алып кайтканнан соң да Арчада булгаларга туры килде миңа, ә алтмыш икедә Арчага торырга ук күчтек. Бу вакытка, әлбәттә, анда немец әсирләре калмаган иде инде. Арчадан Балтачка китә торган юл буендагы әсирләр зираты әйбәтләп коймаланган һәм тәртиптә иде. Аны элекке әсирләр, Германиядән килеп, карап торалар икән. Немец әсирләре турында белүчеләр дә күп иде әле Арчада.

Безнең оешмада җыештыручы булып Сафифә апа эшли. Теге чакта миңа хастаханә юлын өйрәткән зәңгәр күлмәкле, ак алъяпкычлы апага бик тә охшаган ул. Сафифә апага беренче күрүдә шуны әйттем. Ләкин:

— Мин булмаганмындыр,— диде ул. Аның күзләренә моңсулык җәелде, ишек тоткасыннан кулын алды да: — Белмәссең тагын,— дип, чыгар юлыннан туктап, каршыдагы урындыкка утырды.— Ул көннәрдә кабаланып йөргәләнде инде.— Моны Сафифә апа ваемсызрак итеп әйтте, әмма бу ваемсызлыкта үткәннәргә игътибарсыз булырга тырышуы гына сизелә иде.— Әсирләрне җибәргән...— соңгы сүзе ошап җитмәде бугай, аны: — озаткан,— дип төзәтте,— көннәрдә мәшәкатьләр күп булды. Мескенкәйләр, әсирләрне әйтәм, җәфа чиктеләр дә соң... Олы бер зират калды бит үзләреннән...

Сафифә апа немец әсирләре яшәгән бинада җыештыручы булган. Алар турында ул күп белә иде. Һәм аның хатирәләрендә Иоганн исемле әсир телгә алынмыйча калмый иде.

— Кышын Теләче уңаендагы урманнан чана белән тартып утын ташыйлар иде алар,— дип сөйләде берчакны Сафифә апа. Ул инде әсирләр, дими, алар, дия иде.— Бездәге кебек салкыннарга ияләнмәгәннәр бит. Өсләрендә дә юка. Кул-аякларын өшетеп тә кайткалыйлар иде. Беркөнне Иоганн урманда хәле бетеп егылган да утын өстенә салып тартып кайтканнар үзен. Өшемәгән җире калмагандыр мескенкәйнең. Ярый әле каз мае китереп бирергә башым эшләде. Яшереп кенә инде...

— Алар эшчәннәр иде үзләре. Кушканны бик тәртипләп, чиста итеп үтиләр иде. Иоганн арада пөхтәсе иде. Чандыррак гәүдәле иде ул. Куллары хатын-кызныкыдай кечкенә иде, шундый куллары белән мылтык күтәрә алмагандыр да ул. Тар

йөзле, юка борынлы иде. Гел дә миңа охшаган иде менә. Бертуганнар кебек охшаган идек. Ул миңа туган эне дә, абый да түгел бит югыйсә. Ул — немец егете, мин — татар кызы, ничек туганнар булыйк ди. Уртаклык булса, шул — яшьтәшләрбездер. Минем исемне дөрес әйтеп бетерә алмый иде, Саф-Соф, дия иде. Яныннан узганда шулай эндәшүенә һич ачуым килми иде үзе. Минем исемне үзебезнекеләр эндәшүдән откандыр инде...

Безнең илгә басып кергәч, алар начар кешеләр инде. Тик Арча халкына зарар-зыяннары тимәде аларның. Станциядән аларны озатырга бик күп кеше җыелды. Аларга юлларына бирәр бөтен күмәч биргәннәр иде. Вагоннарга утыртыр алдыннан, Иоганн иптәшләре белән сөйләшеп алды да җыелган кешеләргә болай диде. Хәзер, хәзер, сүзләрен төгәл итеп хәтерлим әле. Менә болай диде. Ачу тотмагыз безгә, онытмагыз да безне, саубуллашканда, бездән күчтәнәч итеп, күмәчләребезне алыгыз, сезгә монда каласы, без берничә көнгә ашамыйча да түзәрбез, без Ватаныбызга кайтабыз, диде. Шулай диде дә миңа күмәчен китереп бирде. Коелдым да иңдем... Ярый әле кулымда төенчегем бар иде, шуны Иоганнга суздым. Алды. Күкрәгенә кысты. Саф-Соф, дип пышылдады. Төенчекне нигә күтәреп чыкканымны хәзер дә белмим үзем, нәрсәләр төйнәгәнемне дә хәтерләп бетермим. Кулъяулык салганымны онытмыйм менә. Шуны күрмичә калмагандыр әле Иоганн...

— Әле былтыр гына аларның кайберләре Арчага килеп киттеләр. Зиратны тәртипләделәр. Үзгәргәннәр, берсен дә танымадым. Алар белән Иоганн юк иде. Мин аны, ни үзгәрсә дә, таныр идем, тик алар арасында юк иде Иоганн. Танымаска ди, миңа охшаган иде бит Иоганн... Үз-үзеңне танымаган кебек була да аннары...

Сафифә апа кияүгә чыкмыйча олыгайган иде. Үзе кебекләрнең күп булуын искәртеп, ул:

— Безгә дигән егетләрне сугыш кырды шул...— дия иде.

...Әсирлек турында миңа элекке бригадирыбыз Хәервафа апа да сөйләде. Аның ире Шәмгун абый немецларга әсир төшкән. Кырык алтынчы ел башында кайтты ул. Ләкин аны, әсирлектә булганы өчен, берничә айдан Себергә озаттылар. Ә Хәервафа апаны, әсир хатыны, дип, бригадирлыктан төшерделәр. Монысына хафаланмады Хәервафа апа. Аның җанын әрнеткәне сугыш вакытында чиккән җәфалары гына да түгел, ире күргән михнәтләр янәшәсендә боларны вак итеп санады ул. Үзгәрде Хәервафа апа. Хәтта йөзендә-кыяфәтендә элекке чалымнар калмады диярлек. Кыйгач кара кашлары гына элекке төсен саклады. Шәмгун абыйны Себергә алып китүгә, чәчләре агарды, йөзен шомлы җыерчыклар басты, озынча гәүдәсе бөкрәя төште, куллары, җитезлеген җуеп, салынды. Сөйләгәндә си-

рәк сүзләрен казык итеп кага торган булды. Моңа ире Шәмгун абый кичергән авырлыкларны үзенеке итүе сәбәптер.

— Колакларым ялгыш ишетәдер, дия идем баштарак, Шәмгун абыең акылыннан каладыр, дия идем,— дип хәтерләде Хәервафа апа.— Этнең тизәк иснәп торуын күргәч, таяк атып куган идем. Дөрес иттең, диде Шәмгун абыең, тамагы тук килеш, тизәк ялап йөрмәсен, диде. Ярылмаган арпа шулпасы бирәләр иде, чөмерәбез дә бетерәбез, аннары бәдрәф артында кемнеңдер йомышлавын көтәбез — кабыклы арпаны тизәктән аерып юа идек, дип сөйләде... Йа Аллам, моңардан да... моңардан да авыр булуы мөмкин түгелдер ич! Шундый хәлгә төшүе генә җитмәгән икән, әсирлегең өчен, дип, үзебезнекеләр, Себергә җибәреп, сәламәтлеген сыктылар Шәмгун абыеңның... Җимерде немец безнең тормышны... Кайчак уйланып куям, әгәр, дим, тере фашистны күрсәм, дим, бугазыннан буар идем, дим. Хатын-кызга болай уйлавы ук гөнаһ гөнаһын. Фашистны очратсам, әле хәзер дә бумыйча барыбер тыела алмас идем...

Әгәр теге чакта Арчага аягы сынган авылдашыбызны алырга бригадирыбыз Хәервафа апа барса, тау менгәндә яки базар янында немец әсирләрен күргәч, нишләгән булыр иде икән ул? Әйткәнен эшләсә, аны гаепләп булыр идеме икән? Әллә аны хаклы санарлар идеме? Юк-юк, мондый сораулар кую үзе үк урынсыз!..

— Соңгы теләге итеп, сәер нәрсә әйтте Шәмгун абыең. Әй, беләсең ич инде син аны.

Хәервафа апа бу хакта кат-кат сөйләде. Һәр сөйләвендә ниндидер яңалык өстәвен көтә идем мин аның. Ләкин сүзләр бер үк иде.

...Раштуа салкыннары узды. Көннәр йомшарды. Гыйнварның егерме өче. Кичке уңай.

— Хәервафа,— диде Шәмгун һәм, хатыны кече яктан чыгып өлгергәнче, юрганын өстеннән шудырып, аякларын, ике куллап күчереп, караваттан салындырды.

— Нигә кузгаласы иттең?

— Хәервафа,— дип кабатлады Шәмгун,— бер үтенечемне үтәче. Урманга барыйк. Хәзер. Икәү генә.

Хатыны ирен бу уеннан кайтырга өндәмәде.

— Барабыз. Урман җәһәннәмдә түгел, өстебезгә авып тора.

Хәервафа ирен җылы итеп киендерде, толыпка төреп, чанага утыртты, иренә үрәчәле, арка терәгечле чана ясаткан иде ул. Ирен чанада тартып йөрүенә авылда гаҗәпләнмиләр — мондый хәлләргә ияләнелә бит. Арчада әсирләрнең биек таудан озын арба тартып менүләренә дә игътибар итүче юк иде. Бу юлы да урамда аларның каршысына очраучылар кая барулары белән кызыксынмадылар. Ә авылдан чыгып китүләрен берәү дә күрмәде, караңгы тиз төште. Урман авызында учак кабын-

гач, аны күрүчеләр булгандыр, ләкин кызыксына-тикшерә килмәделәр.

Озак янды учак. Аны, чанасыннан иелеп, Шәмгун кабызган иде.

Шәмгун, хатынының җилкәсенә асылынып, басып та торды, тик аякларының хәле тиз бетте, чанасына утыртырга кушты. Янына Хәервафа куйган чыбык-ботакларны учакка аткалады.

— Хәервафа, мин үз гомеремдә өченче тапкыр кышын учак ягам,— дип сөенде ул.— Беренчесен сугышта, икенче тапкыр Себер урманында яктым. Һәм менә монысы.

Алар сәгать ун тирәсендә кайттылар. Шәмгунның кәефе күтәрелгән иде.

— Хәервафа,— диде ул, хатыны урынына җайлап яткыргач,— яныма утыр.— Самими сөенү иде аның йөзендә.— Учак яктысында мин ука карлар күрдем. Юк, алай дөрес түгел лә, кар бөртекләре үзләре укалы иде. Укалы карлар...

— Мин дә күрдем аларны...— диде дә иренең күкрәгенә капланды Хәервафа.

...Шулай да Арчага авылдашыбызны алырга бригадирыбыз Хәервафа апа барса, тауда немец әсирләрен очраткач, нишләгән булыр иде икән ул? Нишләсен — сакчы солдатлардан рөхсәт тә сорамыйча, Бурлы бияне озын арбага җигәр иде дә тарантасны артка тагар иде, яисә арбаны тартышыр иде, аларның газабын барыбер киметер иде. Бу очракта Хәервафа апаның ачуы кайтасына мин һич тә шикләнмим.

Ләкин Бурлы бияне ике мичкәле озын арбага мин җигә алмадым. Үзем дә әсирләр янәшәсенә җигелмәдем. Болай эшләү өчен Сафифә-Хәервафалар батырлыгы кирәк икән.

*1992*

# Һомай кошлары

Хәле шәптән түгел Тукайның. Хәтта начар ук.

«Гомерем чигенә җитәм,— диде ул күңеленнән.— Тәнем тоя шуны. Җаным белә тиздән китәрен...»

Габдулла мендәрне җайлап салды. Баш астының текәрәк булуын ошатарак ул. Таянып күтәрелде дә мендәргә аркасын терәде. Дәү йомшак мендәр аның ябык аркасын җылытып кочты.

Бүген дә дуслары килер. Алар белән сөйләшер сүзләр күп. Дуслары барында, бәлки, тамак ялгап та алыр. Ә ялгызы калганда, черем итеп алу һәм уйланудан башка шөгыле юк аның. Язарга, хәтта укырга да хәле җитми. Шөкер, тәне көчен ташласа да, уйланырга дәрманы бар.

...Уйлар... Сез дә инде җанга нигәдер рәхәтлек бирмисез. Сез дә инде җанны алып китәргә җыенасыз...

Болай да аз шатлыкларым бетеп бара. Ләйсән аеның куанычлы үзгәрешләрен тәрәзәдән карап ятарга мәҗбүрмен. Туган аемның. Их-х, урамга чыгасы иде дә... Нишләр идем? Белмим икән лә шуны. Шөбһәле хәл бу. Юк, беләм икән ич! Хастаханә ишегеннән чыгуга ук тәрәзәм турысында әңгәмә коручы ике агайга сәламемне бирермен. Иякләрендә генә сакал үстергән ике агайга. Татарча итеп. Берсенең сакал-мыегы капкара, икенчесенең ап-ак. Берсен-берсе бүлдермичә сөйләшәләр. Гәүдәләрен тотуларында ук горурлык сизелә. Ә-ә... ак сакал-мыеклысы минем танышым лабаса! Тенекинең* Нигъмәтҗан карты.

Ак карт... Теге чакта Печән базарында синең белән әңгәмә коруым истә минем. Беләзек-йөзекләр, алка-чулпылар сатарга килгән идең. Мин товарларыңны, бизәнү әйберләре, дигәч, ямьләнү әйберләре, дип төзәткән идең.

Бу юлы калага ни йомышың төште икән? Сәүдә итәсеңме? Нигә, алайса, базарда түгелсең? Әллә... Әллә минем хаста калуымны ишетеп, хәлемне белергә килүеңме? Нигә, алайса, яныма кермисең? Минем якка ара-тирә күз ташлыйсың, анык ук күрмисеңдер, шулай да халәтемне чама кыласыңдыр. Китеп барыш минем...

Яныма кермәвең мине борчырга теләмәүдән булыр. Син, бәлки, хаклыдыр. Әллә минем бәхиллегемне алырга килүеңме, шагыйрь җанлы Ак карт? Бәхил мин синнән. Бәхил!

Ә син бәхилме соң? Бәхил икәнсең. Килеп күренүең ук — бәхиллегең.

Әмма ки мин сиңа бурычлы калам икән. Миңа багышлап, карчыгым белән миңа атап, бер шигырегезне җырларсыз, дигән идең теге чакта. Мин сезгә атап шигырь яза алмадым. Табылмады ул шигырь, Ак картым!

Бәлки, сезгә багышлап хикәя язарга кирәк булгандыр. Тик мин хикәяләр остасы түгел шул. «Исемдә калганнар»ны хикәягә санап булса гына инде.

Ак карт... Карчыгыңның исеме ничек иде соң әле? Акчулпанмы? Түгел. Ачуланма, Нигъмәтҗан карт, карчыгыңа мин яңа исем кушам — Нурһадә! Чү, хәтерләдем, синең бәхетле хәләлеңнең исеме — Фагыйлә ич! Һәм дә ки сезнең икегез турында хикәя язарга тырышып карыйм.

...Дугадагы җиз кыңгырау сөендереп чылтырый. Тигез агышлы бу моңга юл тузанына атның бах итеп басуы кушыла. Ике

* *Тенеки* — Саба төбәгендәге көмешче осталар авылы.

тавыш аралашып бара — кыңгырау һәм тояк тавышлары. Нигъмәтҗанны җәйге авылның шушы иртәнге җыры уятты. Ат шәп, дип уйлады ул, сузылып ла юырта соң! Күрмичә дә шул абайлана. Сабан туен таңнан искәртүче кайсысы икән? Хәер, кем булса да барыбер түгелме?! Ак таңда ук авылга җыр салуы сөенеч.

Нигъмәтҗан май башыннан бирле өйалдындагы чолан-бүлмәдә йоклый, монда җәйнең исен тоясың. Ул сикереп торды. Төннек тишеге хәтле тәрәзә кысып куелган иде, аны ачып бетерде, битенә таң һавасы бөркелеп сыланды. Кояш күренми әле. Өйдәгеләр уянмасын өчен, ишекне акрын ачты. Биек баскычка аякларын җәеп басты да киерелеп тартылды, иелеп турайды. Бакча уртасындагы сукмактан елгага таба китте. Елга аларның өчпочмакка охшаган бакчасының озын ягына терәлеп ага. Шул яктан ун аршын чамасы җирдә өрәңге-имәннәр, карамаэлмәләр үсә, Саба төбәгенең барлык төр агачлары бар монда.

Карлыганлыкта туктады, дымсу яфракка битен тидерде, тәмле ис борынын йомшак кытыклап рәхәтләндерде. Басмага кереп чүгәләде, кушучлап су алды да, чисталыгына сокланып, шуңа беравык карап торгач, битенә сипте. Аякларын тубыгынача суда чупырдатты. Бу рәхәтлекләр генә тәнгә сихәт биреп җиткермәгән икән, чишенде дә, кулларын баш очына сузып, чоңгылга чумды.

Нигъмәтҗан сабан туена, үзләре янындагы басмадан чыгып, Әрәмәлек урамыннан килде. Сабан туе авылның түбән башындагы Чишмәле тау итәгендә була. Зур тигез урын тау бите мәйданны утырып күзәтергә уңайлы. Чирәм ныгып җиткән, җете кояшта куе яшеллеге сыекланган. Йомшак төс.

Моннан елга өсте тип-тигез булып күренә. Җилсез бүген. Шулай да йомшак җил бардыр, анда-төштә йөзек кашыдай җемелдәгән төрткеләрнең берәүләрен шул яшертен җил өреп сүндерәдер дә яңаларын кабызадыр.

Халык шактый җыелган инде. Бала-чага ишле, тау битендә йөгерешәләр, озын колгага менмәкче булалар, көрәшеп әүмәкләшәләр. Нигъмәтҗан көрәшче малайлар яныннан көлемсерәп узды, тау уртасындарак типкән чишмәгә таба атлады. Иртәнге майлы коймактан су эчәргә теләүдән түгел, ә моннан, биектән, мәйданга инде кемнәр килүен аерып күреп булудан иде. Фагыйлә мондамы икән — егетнең күңелен шул җилкетте. Мәйдан тирәсендә дә, читтәге кызлар төркемендә дә юк иде Фагыйлә.

Ә, әнә ич, иптәш кызы белән басмага керделәр. Урта төштә туктадылар. Фагыйлә кулларын селтәп җибәрде, балыкларга җим сипте бугай.

Нигъмәтҗан таудан йөгереп төште дә, итәктә җыелышкан егетләр белән күрешеп, басмага таба ашыкты.

— Фагыйләсен күргәндер,— дип шаяртты гармунчы егет.— Адымыннан акылы алда йөри Нигъмәтҗанның.

Фагыйләнең иптәш кызы, Нигъмәтҗан якынайгач, басмадан ашыгып чыкты һәм кызлар төркеменә таба борылды. Нигъмәтҗан, Фагыйлә басмадан төшкәндә, кызга булышмакчы булып, кулын сузды. Әмма Фагыйлә:

— Әллә-лә! — дип, кулларын артка яшергәч, рәхәтләнеп көлде егет һәм:

— Сабый син, Фагыйлә! Валлаһи! — дип сөенде.

— Әйе шул!

— Көнең сиңа хәерле белән килсен! Сабан туе котлы булсын, Фагыйлә!

— Рәхмәт яугыры! Үзеңә дә бәхет телим, Нигъмәтҗан, яме, дим.

Алар сабан туе мәйданына таба киттеләр. Нигъмәтҗан бизәкле түбәтәен уңгарак кыңгырайтты, аның түгәрәк йөзенә шулай килешәрәк, борынының бераз почыклыгы бетте шикелле. Ефәк билбавының чуклары, таудан йөгереп төшкәнгәдер, алгарак күчкән икән, аларны янгарак шудырды, кысынкы чуклар төймәләнмәгән кәзәкиенең итәгенә тияр-тимәс тирбәләләр иде.

Фагыйлә яшел күлмәк кигән, ак алъяпкычтан, кара бәрхет камзулы түгәрәк гәүдәсенә сыланып тора. Алсу-яшел бизәкле яулыгын артка бәйләгән, энҗеле калфагы коңгырт-кара чәчләренә төз утырган. Адымнары шундыен да җиңел, кулларын канатлардай җәйсә, күбәләктәй очып китәр сыман ул. Нигъмәтҗанның күзләренә еш карап ала, шул чакта гәүдәсе борыла да озын толымнары бәрелешә, талир тәңкәләре чыңлый. Йөзе шатлыктан балкый Фагыйләнең, йөрәген ышанычлы Нигъмәтҗаны биләүдән инде.

— Фагыйлә...

— Әү, Нигъмәтҗан!

— Кешегә бәйрәм кирәк, име.

— Шулай булмыйча соң!

— Ял дигәне юл йөргән атка кирәк.

— Бик кирәк мал-туарга ял, Нигъмәтҗан. Эш атына бигрәк тә инде. Мал-туарга без бәйрәм ясый белмибез. Үзләре ничек бәйрәм итсеннәр ди инде алар?!

Сабан туе көнендә егет белән кыз арасында бүтән сүзләр әйтелергә тиештер югыйсә. Әмма Нигъмәтҗанга читләтеп йөрү туп-туры юлга чыгу өчен генә кирәк булган икән.

— Эш атына ял — үзе бәйрәм. Фагыйлә, без ат алмабыз, дим, тота алмабыз без аны. Безнең нәсел җирсез бит. Аннары, дим, миңа өязгә көмеш эшенә йөрергә кирәк, ат карау сиңа бәла булыр. Йортны ә-әнә тау башына салырбыз. Урынны шуннан сорарбыз, дим.

— Ярар, Нигъмәтҗан, мин риза. Син ничек хәл итәсең, шулай булыр.

— Ә... әйе икән, шулай шул, бәйрәм кешегә кирәк. Шулай. Тагын бер тапкыр әйтим әле. Бүгенге сабан туе олы бәйрәмең булсын, Фагыйлә!

— Барлык, барлык кешеләрнең, икебезнең уртак бәйрәмебез булсын, яме, Нигъмәтҗан! Һомай кошлары безнең турыда очсын!

...Юк, сезнең хакта хикәя язып булмый икән, Ак картым. Кичерең. Яза алмавыма кулда көч бетүе сәбәп түгел, әмма, йөрәктә дәрман булганда һәм телем әйләнгәндә, мин аны сөйләп тә бирә алыр идем. Мин сезнең гомер буе бәхетле булуыгызны беләм. Ялгыш сүзләр тезәрмен дә икегезнең уртак бәхетен кыярмын, дип куркам. Сезне кәгазьдә генә дә бәхетсез итмәм! Бәхетегез гел бөтен торсын! Бәхетегезгә берәү дә кагылмасын! Мин дә... Бәхетсезлекнең ни икәнен минме белмим соң?!

Юк, юк, минем дә бәхетле чакларым күп булды. Һәр язган юлым — бәхет миңа. Һәм тагын бер бәхетле чагым турында сиңа сөйлимче, Ак картым. Монысы — язылмаганы. Язмышыма да язылмаганы.

...Ялгызым. Кырлай урманы буенда сәйран кылып йөрим. Арыймын мин. Нигә арыйм ди — тәнемдә көчем ташып, башымда хыялым кайнап тора ич. Шулай да ял итеп, күккә карап...

Ятмыйм икән лә мин.

Тарантаста утырам. Пар ат урман буеннан җилдертә. Юлның дыңгыртыклыгы сизелми, тын күл өстендә көймәдә талгын гына йөзәм кебек.

Йөзәм?

Йөзәбез!

Сул ягымда Таң кызы утыра. Таң сылуы.

Миңа назлап карый. Күзләренә дөнья яме сыйган. Сөю тулы Таң сылуының күзләрендә. Аллаһым, тел ачкычы бирче миңа!

— Таң кызы...

— Тукаем...

Таң кызы җилкәмә кулын салды. Аннары кулын иплəп кенә күтәрде дә баш бармагы белән кашларымны сыпырды.

— Тукаем, күр әле, күр! Әнә тарантас башындагы төн гөлен күр әле, күр!

— Иртәнге як ич әле, ахшам чәчәге бу чакта ничек ачылган соң?

— Синең хакка, Габдулла!

— Ышанам мин сиңа, Таң кызы. Яп-яктыда ахшам чәчәген балкытырга синең генә көчең җитә!

— Тукаем, күрче!

Без чавыллыкка җитәбез икән. Яшь каеннар, ябалдашларын бер-берсенә терәп, тын торалар. Юл юк чавыллыкта. Атлар агачларга барып төртелгәнче туктап өлгерерләрме? Туктамадылар. Сөбханалла — атлар алдына тигез юл җәелә бара. Яшел чавыллыкны ак атлар пар сызык сызып бүләләр.

— Күр әле, Габдулла, безне кемнәр озатып баруын күр!

Янәшәбездән куяннар чаба. Аларга төлкеләр кушылды. Шундыен да күп йөгерек куяннар һәм җитез төлкеләр, исәбе саннарына җитмәслек. Аларга боланнар иярде, җиргә йомшак басып, гәүдәләрен сылу уйнатып юырталар. Гаҗәп, чавыллык эченнән барсалар да, куяннар да, төлкеләр дә, боланнар да яшь агачларга бәрелмиләр, аларның алдыннан да тигез һәм чирәмле юл түшәлә.

— Тыңлачы, Тукаем!

Биектән-биектән пар тургай тавышлары ишетелә. Пар сандугачлар өздереп сайрады да дугага килеп кундылар. Моңлы-назлы җырларын безгә карап тагын җырладылар. Ике ягыбыздан ике торна сузылып оча. Күктә һомай кошлары да бар, тик бәхет кошлары үзләре күренмиләр — аларның күңелне рәхәтләндерүче сайравы гына яңгырый.

Юл читендә бүре безгә сокланып утыра. Аю алгы аякларын куллар итеп чәбәкли, безне бергә күрүенә сөенә. Арыслан арт аякларына баскан, алгы аягын кулы итеп болгый, безнең сәфәрне хуплый.

Яшь агачлар кечерәя бара, чавыллык-куаклык зур булмый шул.

Таң кызы кашларымны тагын сыйпады. Минем назга сусаган җанымны ул гына аңлый...

Ак картым! Бәхетле чакларымның берсе менә шушы. Әллә ул сиңа танышмы? Сабан туеннан соң сез дә, Фагыйләкәең белән син, урман буеннан һәм чавыллык арасыннан пар атта җитез кошлардай очкан идегезме? Бу рәхәтне сез дә тойгансыз, бу бәхетне сез дә татыгансыз. Шәт, шәт, шулай! Һәм сезнең бәхетегезгә тиң хыялый бәхетем белән тагын бер тапкыр бәхетлемен.

Тәрәзә каршына тагын килдең, Ак картым. Кулыңны күкрәгеңә куеп, миңа башыңны идең. Мин дә шундый хәрәкәтләр ясарга теләп күтәрелә башлагач, кузгалмаска ишарәләдең.

Бәхиллегеңне бирдең.

Бәхиллегемне кабул кылдың.

Яныма килергә соңламадың син, сизгер күңелле, шагыйрь җанлы Нигъмәтҗан карт.

Мин тагын ялгызым. Бар иде ялгыз калып... Әйе, әйе, ялгыз калудан да бәхет таба идем кайчакта. Күп чакта.

Кышларын мин ялгызым гына Идел өстенә чыга идем дә

туйганчы ауный идем. Ауный белмәсәм дә. Кайберәүләр мине аунатырга күп тырышсалар да, моңа өйрәнә алмадым.

Идел өстен яңгыратып кычкыра идем. Тавышым яңгыравык булмаса да.

Җәйләрен, сахрада баш калкыткан уҗымнар каршына иелеп, җырлый идем. Җырлый белмәсәм дә.

Дөньяны тетрәтеп еш кына елый идем. Елый белмәсәм дә.

Бәхетле мин, Ак картым. Бәхетле булмасам да...

Тукай күптән язган шигырь юлларын күңеленнән кабатлады — шагыйрьгә, хикәядән бигрәк, барыбер шигырь кирәк шул:

> Очырдым һомай, ай, кошларын,
> Таба алмадым кунган төшләрен...

*1992*

# Түбәтәйле кыз

Нурһадә тыкрыктан борылуга, Байназарны күргәч, имрәп сискәнде. Кинәт тукталудан чиләкләрендәге су чайпалды. Әкәмәт — күршесе Байназар капка төпләрендәге эскәмиядә нәрсәдер юнып утыра. Әче таңнан.

...Урамга чыкмаса соң, юныш алачыгы бар ич үзенең, ясыйсы әйберен шунда ясарга кирәктер, эшен үткән-сүткәнгә балачага кебек күрсәтеп утырмаса, мак...

Кыз Байназарга бәя бирүдән кырт бүленде.

...Мине күрмәгәнгә салына. Әллә чыннан күрми тагын, мак... Әй-й, мактанчык түгел лә Байназар...

Нурһадә егет турысына җитеп туктады. Байназар аңа баш кагып кына сәламен бирде, аршин буйлы, киртә юанлыгы агачны кәкре елтыр пәкесе белән юнуында булды. Янына сырлаулы пәкеләрен дә таратып куйган иде.

— Байназар, нәрсә ясыйсың?

— Чукмар.

— Охшый башлаган шул.

— Буынтыгы чукмар башы кебеген сайладым агачның.

— Бу эшеңне дә тиз тотарсың, ахры.

— Кем белә...

— Байназар, миңа үпкәләмәгәнсеңдер ич?

— Юк ла! Туктале, кайсы сүз ояңнан таптың андый... андый сүзне?

— Аптыраганнан әйтүем.

— Аптырама.

— Ярар. Анысы син кирәкмәс эш эшләмәссең.

— Нурһадә, бүген кичен монда утырабызмы?

— Бүген... бүген безнең капка төбендә инде. Сезнең эскәмиядә кичә утырдык ич.

— Бүген дә монда очрашыйкмы, дигән идем.

— Нигә?

— Белмим.

— Киттем. Чиләкләрем авырая.

— Мин күтәреп торыйммы?

— Шулай булмагае ди! Яса әнә чукмарыңны.

— Ясыйм бит.

Кичен Байназар Нурһадәләр капка төбенә барып утырды. Кыз караңгы иңгәндә чыкты.

Алар бер-берсен тәпи басканнан дигәндәй беләләр, терәлеп торган күршеләр алар, өстәвенә яшьтәшләр дә Байназар белән Нурһадә. Шулай да яшь аралары бер елга тула яза — Байназар гыйнварның берендә туган, Нурһадәнең туган көне — шул ук елның утыз беренче декабре. Шуңа күрә Байназар олырак булуын малай чакта сиздергәләде. Нурһадәне абый, диген! дип, көрткә төртеп еккан һәм кызның чәчен тарткан чаклары булгалады.

Әмма болар малайлык шуклыгыдыр. Ә, әйе, Нурһадә аңа абый дип барыбер бер тапкыр да эндәшмәде. Нигәдер инде.

Үсмер чакта яшьтәшләре белән Куаклы тауга менгәннәр иде. Шундагы кояшлы аланда түгәрәкләнеп утырганда, Байназар шәриктәшләре алдында чиккән түбәтәен салды да:

— Эссе кага сиңа,— дип, Нурһадәнең башына кидерде куйды, әй.

Һәм түбәтәй Нурһадәнеке булды да калды, җәй буе киеп йөрде шул түбәтәйне. Өйдә дә гел кигәч, тузды түбәтәй. Яңаны алдылар, анысы искергәч, тагын яңасын юнәттеләр, аннары тагын... Түбәтәйне Нурһадә әле уңгарак, әле сулгарак кыңгырайтып кия. Шуңа карап, күпереп торган дулкынлы чәчләрен артка кайтара да әле бер колагы, әле икенчесе ачык кала. Холкына бәйле түгел болай эшләве. Нурһадәнең, кемдер күңелен рәнҗеткәндә дә — кечкенә авыл тормышында да андый хәлләр була, үзенең кемгәдер ачуы купса да — аңа гадәти сыйфатлар ят түгел, олы җанлы булып калырга көче җитә. Яңак-колакларын алмашлап ачып куюы, бәлки, гөнҗәдәй алкаларын яктыга чиратлап күрсәтергә теләүдәндер. Алкаларның ак чәчәк бөреләре ачылып бетсен өчен. Шулайдыр. Нәкъ шулай.

Алар бу кичтәге әңгәмәдә дә авыл һәм үз гаиләләре тирәсеннән читкә тайпылмадылар. Сүз ояларында мәхәббәткә кагылышлысы юк, ахры, аларның. Әллә бер-берсен күрмичә тора алмасалар да, яратышмыйлар инде тагын, әкәмәт. Әңгәмәләрендә кызышмыйлар, үзара йомшак эндәшергә, салмак-тыныч мөгамәләгә гадәтләнгән инде алар. Киек Каз Юлы ачык беленеп җиткәч, Нурһадә:

— Кит инде,— диде.
— Башта син кереп кит.
— Киреләнмә инде, Байназар. Мин сине карап озатам.
— Юк, минем сине карап каласым килә.
— Чукмарыңны ясап бетерденңме?
— Ясадым. Әйбәт булды.
— Матур итеп ясарыңа шикләнмәдем дә мин. Башына чәнечкеләр куярга онытмадыңмы?
— Чәнечкеләре без очыдай. Ую пәкеләрен беренче тотуым иде.

Иртәгесен Нурһадә судан менгәндә, Байназар капка төбендә утыра иде. Егетнең шунда буласын сизенгән иде дер кыз, бүген имәнмәде. Байназарның кулында быелгы талчыбык иде, шуның яфракларын өзә.

— Нигә ул талчыбык, Байназар?
— Кирәге булыр, дим.
— Сыңар чыбыктан әйбер үреп булмый ла.
— Август ахырында сындырган чыбык шәп чыжлый.
— Шулай дисеңме?
— Нишләп мин диим ди? Мондый чыбыкның кодрәте мин әйтмичә дә озакка җитә.

Кичен алар, көзгә якынлашкан аяз күктә Киек Каз Юлы анык беленә башлаганчы, Байназарлар капка төбендә утырдылар.

Нурһадә иртәгесен чишмәгә суга тагын төште. Ул менгәндә, Байназар тагын капка төбендә утыра иде. Эскәмиягә тимер бөҗра, вак кадаклар һәм кыскарак таяк куйган, янында кечкенә чүкече дә бар. Күн телә ул.

— Байназар...
— Ә-ә, Нурһадә, син икәнсең,— дигән булды егет.— Исәнме. Камчы үрәм әле менә.
— Үр, үр, Байназар, атыңны камчыларга кирәк булыр.
— Булган әйбернең анысы кирәге чыгар. Сезнең сыерыгыз тыңлаусыз.
— Сыерны камчыламыйлар, Байназар. Ат түгел ич ул.
— Шулаймы? Үрәм инде. Башлаган эшне бетермичә ярамый.
— Бөҗрасыннан тотып торыйммы?
— Сезнең затка мондый эшкә катышу тыела.

Кичке очрашуда, Киек Каз Юлы аермачык беленеп җитәрәк, Байназар истә-ушта югында — әй, монысы ялгыштыр, дөресе — кыз моңарчы уйларга да курыккан сүзне әйтте.

— Өйләнәм.

Тик аның бу сүзе Нурһадәгә кагылмый кебек иде. Әй-й, егет халкы инабәтсез лә алар, егетләргә ышанырга ярамый, мәңге-мәңге ышанычсыз алар. Инабәт тагын аларга. Шуңа күрә

яңа хәбәргә Нурһадә аптырамады. Шулай да түбәтәен салмакчы булып кулларын күтәрде, әмма куллары нигәдер түбәтәйне салдырмыйча, батырыбрак кидертте. Югалып калмады кыз.

— Өйлән, Байназар,— диде.

Тик тавышы аз гына калтырады, бу калтырауны күрше егете сизәрлек түгел иде.

— Әни әйтә, өйләнерлек тә акылың юк, ди. Әти — бер өем сүз арасыннан татлырагын табарга оста бит безнең әти — мунча ташы суынганчы, диптер, булган акылың да өйләнә алмыйча чыгып бетә, ди.

— Әти-әни сүзен тыңламау гөнаһ булыр, Байназар.

— Сиңа да кияүгә чыгарга кирәк, Нурһадә.

— Чыгармын әле. Ашыкмыйм. Мин синнән бер яшькә диярлек кечкенә бит. Син үзеңне кайгырт.

— Өйләнүен өйләнәм дә...

— Нигә икеләндең тагын?

— Ансат хәл итәсең син, ә?! Өйләнү, сеңелкәем Нурһадә, хатынлы булу, дим, хәтта ил башлыгы булудан мең дә бер тапкыр кыенрактыр. Хатын, бик беләсең килсә, бер генә ил түгел, ә берьюлы берничә ил!

— И-и, йомры да соң синең башкаең! Уйлап чыгармаган нәрсәсе юк. Күрче, мондыен да акыллы, матур һәмендә гүзәл сүзләрне чолык умартасындагы балдан да тапмассың.

— Хәзерге заман хатыннарын тыңлатырга талчыбык белән камчы гына аз, чукмар да кирәк. Шуңа күрә чукмарны элгәре ясадым.

— Шулай да, Байназар, кулың күтәрә алмаган чукмарны билеңә такма, дигәннәр.

— Карале, ни, Нурһадә, ялгыш сүзләр ычкындырдым бугай. Ни әйткәнемне дә оныттым. Исәвән бәндә мин. Начар сүзне тиз онытам.

— Әйбәт гадәт монысы.

— Нурһадә...

— Нәрсә әйтәсе идең, Байназар?

— Син иртәгә чишмәгә таңнанрак төш, Нурһадә.

— Син әйткәнне гел тыңлыйм ич мин, Байназар.

Бүген Нурһадә чишмәгә төшкәндә дә, аннан менгәндә дә, Байназар капка төбендә юк иде. Хәер, суга төшкәндә, Байназар башка көннәрдә дә булмый иде. Бүген монда булырга тиеш иде бит, таңнанрак төшәргә кичә кичен үзе әйтте ич. Әй-й, инабәт тагын аларга, егетләргә. Ышанычсыз ич алар.

Нурһадә чиләкләрен кертеп бушатты да чишмәгә тагын төште. Күңеле әлсерәп куйды — нигә Байназар аны капка төбендә утырып каршыламады икән?

Кыз чишмә суын икенче тапкыр алып менгәндә, Байназар аны тыкрык почмагында посып көтте. Култыгына чукмар, тал-

чыбык һәм камчы кыстырган иде. Нурһадә, Байназарны күргәч, сөенүен яшермәде. Шулай да:

— Йокы чүлмәге,— дигән булды.

Байназарның моңа кәефе һич тә кырылмады.

— Нурһадә, син яңак-колакларыңны көнаралаш алмашлап ачык калдырасың, име. Мин тешлисе колакларыңны.

Аптырады да калды Нурһадә. Ләкин үзен кулга җәһәт алып:

— Синнән колак тешләткәннәр ди бик! — дигән булды.

Ә үзенең колаклары гына түгел, берара бөтен йөзе кызарып алды. Бурлаттай кызару түгел иде бу, моңсу һәм дә бәхетле кызару иде.

Тыкрык башында сүз алышу шуның белән бетте. Байназарның кулында чукмар, талчыбык һәм камчы, Нурһадәнең җилкәсендә мөлдерәмә сулы чиләк-көянтә иде.

Байназар үзләренең кечкенә ачык капкасына таба борылды. Нурһадә дә — әйтерсең лә гомер-гомергә шулай булган! — аның янәшәсеннән атлады, тик капка төбендә имәнеп туктады.

— Нурһадә...

— Әйе, Байназар...

— Өйләнәм мин.

— Әйттең ич инде. Мин өйлән, дидем.

— Син дә кияүгә чык.

— Әйттем ич инде. Чыгармын, дидем.

Бу сүзләрнең җилкәсен баскан сулы чиләкләрдән чагыштыргысыз авыр булып кыз йөрәгенә ятуын егет сизмәде бугай.

— Ни бит әле... Ни...

— Әйе шул... Байназар...

— Безгә кер син, Нурһадә... Үзебезгә...

Кызның хәлен сизгән икән бит егет! Бу сүзләрдән кыз йөрәгендәге авырлык җуелды, җилкәсендәге сулы чиләкләре очкалак мамыктай калып җиңеләйде.

— Хәзер үкме? Гелгәме?..

— Хәзер үк! Гелгә!

— Минем калфагым бар бит. Шуны киясем калган икән.

— Киярсең, аннары киярсең калфагыңны. Сиңа, әнә ич, түбәтәең дә бик килешә.

— Буш кул белән инде...

— Чиләкләрең тулы ич!

— Суны бер дә чайпалдырмадым анысы бу юлы...

Бергә тәгәрәп үскән ике җанның болай сөйләшүе шаярту кебегрәк иде. Әй-й, кемнәр ничек яратышмаган да кемнәр ничек өйләнешмәгән, дисең!

— Нурһадә.

— Әйе, Байназар...

— Син калын чәчләреңне әле бер, әле икенче җилкәңә саласың, име.

— Сиңа кайсылай ошый, Байназар?

— Миңа...

Байназар янында бүгенгәчә беркайчан да каушап калмаган Нурһадәнең тез буыннары тагын йомшады, чиләкләре капылт авырайды да, авырлыклары бөтенләй бетте дә кебек. Күзләре дымсуланды, аска төбәлде. Аннары карашын Байназарга текәде — нәрсә дияр икән күрше егете? Бу дөньяның бетү-бетмәве Байназар чыгарасы хөкемгә бәйле иде. Нурһадә шул җавапны көтә.

— Миңа...— Тагын озын-озак тынлык.— Миңа син гел, гел ошыйсың, Нурһадә! Гел ошатырмын мин сине!..

Моннан соң алар Киек Каз Юлын гел Байназарлар капка төбендә утырып күзәтерләр инде. Әллә болай кистереп әйтү дөрес түгелме? Киек Каз Юлына Нурһадәләр капка төбеннән дә, Куаклы тау аланыннан да күтәрелерләр әле алар.

*1992*

# Төннең бикле тәрәзәсе

Сукачы малайлар караңгылык иңгәнче кишәрлекләре буен чыгарга өлгермәделәр. Көнне төн бикләде.

Афзал атларына йомшак-акрын гына:

— Тырр,— диде.

Көн кызуы сүрелә башлаганнан бирле сука тартып әлсерәгән атлар капылт туктадылар — малайлар бүген сирәк ял иттергәннәр иде шул.

Басу күлендә, аерылып калган каз каңгылдавына охшатып, бака ачыргаланып кычкырды. Ялгыз түгел икән шом салучы бака, аңа күлдәшләре тирә-юньне яңгыратып кушылдылар. Әй, кычкырмыйлар икән ич бакалар, җырлыйлар икән! Аларның күмәк җыры Афзалның күңелен юандырды. Тик бакалар кинәт тындылар.

Кайдадыр — унда бугай — йокларга соңлаган чикерткә сайрап җибәрде. Өздерепләр лә сайрый матуркай! Канатларын скрипка кылыдай зеңләтеп-сөенеп тибрәндерәдер кечкенәкәй! Аның җырында көнне төн бикләвенә моңсулану да, төнне таң ачарына өметләнү авазы да ишетте Афзал. Тик чикерткә сайравыннан кинәт тынды. Иш-иптәшләре аңа нигәдер кушылмады.

Йолдызлар чекерәйделәр. Тизрәк яктырып янасылары килә. Ай калыкты. Атлар туктар алдыннан сука калаклары, зур кәскә әләгеп, буразнадан чыкканнар иде. Шул яктыравык ике калакка ай ике булып төшеп кунды. Тик җырламыйлар бу айлар. Әллә ай җыр белми инде, белмидер, шуңа күрә тавыш-

сыздыр ул. Минем вазифам — кешеләрне моңландыру, дип, үз кадерен белеп кенә кешеләр җырын тыңлыймы ай, чиксез кодрәте белән кешеләрне үзе җырлатамы ай...

— Яшьтәшләр! — дип кычкырды Афзал күрше кишәрлекләрдәге Ногман белән Мирхәсәнгә.— Нишлибез? Караңгылык капты.

— Шушында туарыйк атларны,— диде Ногман.

— Кишәрлек башына ерак түгел,— дип каршы төште Мирхәсән.— Урта урында сука калдыруны өнәмиләр өлкән агайлар.

— Анысы атлар караңгыда да күрә, буразнаны бозмаслар,— дип, баягы сүзен кире алды Ногман.— Әйберләр дә карама төбендә, барыбер шунда барасы.

— Әйдәгез, малкайлар,— дип, үзе башлаган икеләнүне бетереп, атларын куалады Афзал.— Түзик.

Кырык өченче елның пар сөрүе вакытында көннәр бик эссе торды. Көндез атларны чыдата торган түгел. Малайлар түзәр дә иде. Болай да ядау атларны коры сөяккә калдырмассың бит. Атлар кызганыч. Шуңа күрә сукачылар эшне иртәнге һәм кичке якка көйләделәр, басуда куналар, көн кызуында кайтып ял итәләр.

Малайлар атларын тышаулап җибәрделәр. Басуда үлән куерып үскән, малкайлар таңгача, шәт, ашап туярлар. Яктырганчы Басу күленнән су эчертеп киләсе булыр үзләренә.

Ногман, ялгыз карама төбеннән кармалап, ботаклар җыйды. Мирхәсән белән Афзал бүтән ялгыз агачлар тирәсеннән шактый коры-сары күтәреп килделәр. Мирхәсән бот юанлыгы түмәр дә тапкан иде, шунысы таң беленгәнче җитәр. Кечкенә учак яктылар. Быел бишенче сыйныфны бетергән унөч яшьлек үсмерләргә, бүре-фәлән килүдән куркуларын басар өчен, нәни учак та җитә — бүре, ут күрсә, шул тирәдән титаклап булса да кача, имеш.

Тамак ялгагач, Афзал:

— Яшьтәшләр,— дип сүз башлады,— уйлыйм да уйлыйм, тик һич кенә дә очына чыга алмыйм бер нәрсәнең.

Мирхәсән белән Ногман учакка алмашлап чыбыклар аттылар.

— Уйның очын таба торган заманмы соң хәзер?! — диде Ногман. Аны Афзалның ни уйлавы кызыксындырмады кебек.— Уйлап баш каткан инде. Бетәсе дә булмады бу сугышның...

— Ниткән чияләй уй соң ул? — дип, терсәгенә таянып кырын ятты Мирхәсән.

— Кемнәр булырбыз икән без, дим.— Афзал учактан читкәрәк шуышты, аякларын бөкләп утырды.— Ниләр күрәсе бар икән, дим. Әтиләр кайчан кайтыр икән?

— Әтиләр...— диде дә туктады Мирхәсән.

— Әтиләр...— дип кабатлады да тынын кысты Ногман.

Сүзсез калдылар. Күзләрен йокы басты. Арыганнар иде.

Учакның сүрелүен сизеп, Афзал кузгалды, ботаклар сындырды, түмәрне әйләндерде дә, аларны шуның өстенә салды. Коры чыбык-чабыкка ут гөлт кабынды. Ногман белән Мирхәсән күзләрен уып торып утырдылар. Сүзне тагын Афзал башлады.

— Әтине әйтәм, мине скрипкада уйнарга өйрәтергә бик теләде инде. Өйрәтүен өйрәтте, тик мин остарып җитә алмадым. Татарның танылган артисты булырсың, дияр иде. Төсең-кыяфәтең артистка охшап тора, җыйнак гәүдә скрипкачыга аерата килешә, дияр иде. Синең сәхнәгә җитез генә чыгып, уйнап бетергәч, алкышларны җилкәңә өеп, күңелеңә тутырып, тамашачы белән горур саубуллашуыңны күрермен әле, улым, яме, дияр иде. Миннән рөхсәт сораган кебек әйтә иде монысын. Әти...

Сөйләшмичә тордылар. Тирә-юнь тып-тын. Бакалар да җырламый, чикерткә дә сайрамый. Атларның үлән кештердәтүе дә ишетелми — читкәрәк киткәннәрдер. Учактагы түмәр ялкынсыз гына яна, чертләп сынар ботак-сатаклар беткән...

— Син, Афзал яшьтәш, скрипкада хәзер дә шәп сызасың бит,— диде бераздан Ногман.— Сине тагын да өйрәтергә кирәкми.

— Өйрәнүнең чиге юк, дияр иде минем әти,— дип каршы төште Мирхәсән.— Афзал хәзер дә оста уйный. Әти әйткәндәй, әмма ки аның уйнавы безгә генә: сиңа да, миңа гына, Ногман яшьтәш, шулай тоелмыймы икән? Дуслар булып мактап, зыян ясамыйбызмы Афзалга. Әти мактауның да чамасын белергә куша иде миңа.

— Анысы бар инде,— дип килеште Ногман.— Әтисе Афзал яшьтәштән күпкә остарак уйный иде шул. Сугыш алды сабан туенда әтиеңнең уйнаганын хәтерлисеңме, Афзал? Сыздырып та күрсәтте соң! Җиләс җилләр искән дә кебек, иртәнге чишмәләр челтерәгән дә кебек... Менә, яшьтәшләр, шул чакта мин...— Ногман, фикерен тәмамларга сүзләр таба алмыйча, тукталып торды, ә иптәшләре аның сөйләп бетерүен тын гына көттеләр.— Менә... Без качышлы уйный идек бит әле, име. Афзалның әтисе уйнаганда, җил моңайган кебек булды. Түгел лә! Җил гөрли иде. Малайлар, качыгыз, мин сезне эзләрмен, эзләп табырмын да башыгыздан сыйпармын, дип гөрли иде скрипканың йомшак җилле моңы... Әтиең булдырасың, улым, дип башыңнан сыйпаса икән, име...

— Җанны кузгатырлык итеп уйнасаң, ә! — Афзал күкрәгеп тутырып сулады.— Оста уйнаучыларны да таң калдырырлык итеп өйрән, улым, дияр иде әти. Кулда сука сабы шул хәзергә... Чыбыркы сабын кысып кизәнгән кул скрипка сызгычын биетә микән, дим... Яшьтәшләр, кайчак әллә ниткән тавышларны да скрипка моңы итеп ишетәм мин. Сезгә сөйләгән юк әле... Был-

тыр, кар яткач, инешне Түбән тыкрык башыннан аркылы чыктым. Күпердән йөрү әйләнгеч, дип. Көне кырыс салкын иде, инеш катып өлгермәгән иде әле.

— Аннан йөрелә бит инде,— дип, яшьтәшенең ярамаган эш кылуын яклыйсы итте Мирхәсән.— Ул төштә инеш кыш уртасынача катмый бит, юл була ич ул төштә. Шарлавык бит анда, чана төбенә җитми ич анда су.

— Чыктым шуннан.— Афзал Мирхәсән аклавына килеште.— Чана табанын салкын бабай бозландырып та алды. Шул боз төерчекләре шома юлны скрипка кылы итеп сыза инде менә. Колакка ап-аермачык ишетелә шул тавыш... Тик скрипканың кыллары бушаган да сызгыч табаннардагы төерчек бозлар чәнечкеләнгән кебек. Сыкрый скрипка, җәфалана...

Тын утырдылар. Йокылары качты. Әмма сөйләшер сүзләр дә юк кебек.

Бераздан Ногман:

— Афзал яшьтәш,— диде, ул кыбырсыграк холыклы, түземе бетте,— шулай да син скрипкаңны көн саен уйна.

— Уйныйм ла. Аз уйнала шул. Сул кулның бармаклары язылырга өлгерми. Сул кул белән күпне күтәрмәскә дә тырышам инде. Сугыш бетсә, авыр эштән котылыр идек лә без...

— Менә бит Ходай ничек яраткан — синең сул кулың җәһәтрәк эшләргә тиеш, мин уңын ешрак җигәм.— Ногман уң кулының бармакларын кысып-җәеп язды.— Балта чапсаң да, такта ышкыласаң да, уңына күбрәк авырга килә. Әти дә шулай дия иде. Их-х, миңа да балта эшенә өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле! Әти сугышта булмаса, тиз өйрәтер иде лә — хәзер кулларыма көч керде ич минем.— Ногман кулларын балта чапкандай һәм такта ышкылагандай хәрәкәтләндерде.— Әти осталыгы булса икән миндә!

Әңгәмәдә чират Мирхәсәнгә җитте. Иптәшләренең этиләре һөнәрләрен алачакларына сөенде ул. Ә үзе кем булыр — бу хакта ныклап уйлаганы юк иде.

— Беләсез инде,— дип торып басты Мирхәсән,— минем этинең мактанырлык кул һөнәре юк.— Малай яшьтәшләреннән гәүдәгә шактый калку һәм таза. Ул, кулларын җәеп төнне кочты да, тавышын күтәреп: — Минем эти һөнәре белән халыкны елына бер тапкыр таң калдыра иде! — диде.— Миңа да ике кулымның көчләре тигез булуы кирәк. Сабан туе батыры бит минем эти! Мин дә мәйдан тотучы батыр булам! Миңа алмашка энекәш тупырдап үсеп килә. Аннары аны минем малай алыштырыр... Сугыш бетеп, эти кайткач, сабан туенда икебез дә көрәшәбез әле! Этиләр кайтсын иде!..

— Яшьтәшләр, тыңлагыз әле! — дип кинәт бүлдерде Афзал.— Ишетәсезме? Чикерткәләр сайрый! Сайрамыйлар ла, скрипкада уйныйлар алар! Һәркайсы үзенчә уйный. Аларның

төрлечә уйнарга өйрәтүчеләре бар шул. Берсе үзәккәйне бигрәкләр дә өзә лә! Кичәге ялгыз чикерткә бугай анысы. Өйрәтүче шунысыдыр. Кичә аны башкалары сокланып тыңлап кына торганнар икән. Бүген күмәкләшеп уйныйлар.

Икенче көнне Афзал басуга скрипкасын алып килде. Ногман белән Мирхәсән аңардан ялгыз агачлар тирәләреннән чыбык-чабык җыйдырмадылар. Афзал өчен җир дә сөрерләр иде, Афзал ялгыз карама төбендә скрипкасын уйнасын да уйнасын иде. Остарсын иде Афзал, дөньясында беренче скрипкачы булсын иде аларның яшьтәше Афзал! Ләкин хәзергә һәр сука сабын аерым кеше кысып тотарга мәҗбүр, атларны пар сукага җигеп булмый...

Афзал төнге учак янында скрипкасын туктамыйча уйнады. Мирхәсән белән Ногман серле моңнарны онытылып тыңладылар. Моң җил булып иште, чишмә булып акты, йөрәкләрне кайгы-хәсрәт телгәләнүеннән савыктырды, яшьтәшләрне гүзәллек дөньясында гиздерде. Моң дигәнең сугыш дигән афәтне оныттырып торды. Һәм төнге сукачы малайлар шул афәтнең быел үзләрен, ат урынына талчыктырып җигә-җигә, мәктәпне ташлатасын белмиләр иде әле.

...Атларына Басу күлендә су эчерделәр. Ашыгалар — иртәнге якта, көн кызуына чаклы, кишәрлекләрен сөреп бетерәселәре бар. Тиздән миһербанлы һәм дә сагышлы, көләч һәм дә уйчан кояш төннең бикле тәрәзәсен кодрәтләнеп ачар чак җитә. Яшьтәшләр, шөкер, көнне төннең мәңге-мәңгегә беркайчан да бикли алмаячагын беләләр.

Кишәрлекләрен сукалап бетергәч, малайлар үлән җыйдылар.

— Безнең сыер кызык инде әй — билчән ярата,— диде Ногман.

— Безнекенә эт эчәгесе булсын,— дип, шул үләнне өзде Афзал. Икенчесен, өзмичә, өскә күтәрелде, үзе буе диярлек сузылды эт эчәгесе. Очыннан тартты, үлән урта төштәнрәк өзелде.— Зеңли...

Бу сүзне ул бик акрын әйтте, иптәшләре аны ишетмәде.

— Безнеке әрекмәнне умыра! — дип, үз сыерлары гадәтен әйтте Мирхәсән.— Энекәш сыйлап та күрсәтә инде аны әрекмән белән! Миңа җыярга монда әрекмән юк. Әйдәгез, мин сезгә җыешам.

Үләнле капчыкларны атлар сыртына Мирхәсән күтәреп салды.

— Өлкән агайлар менә шушылай тигезләп салырга кушалар,— дип, капчыкларны төшмәслек итеп җайлады ул.

Кинәт Ногман:

— Без үзебез агайлар икән инде,— диде.

Бу сүзләр Афзалны сискәндерде, бер мәлгә аның күз алды томанланды, гәүдәсен көч ташлады хәтта. Ләкин аңына тиз кайтты, шулай да эндәшмәде. Ногманның көтелмәгән ачышын Мирхәсән шаяртып көчәйтте.

— Агайларның да самайлары, диген!

Афзал, атына атланганчы, скрипкасын сәхрә киңлегендә бер сызып алмакчы булды. Әмма скрипка сулкылдап кына куйды. Афзалның тупасланып баручы кулларының иңбашыннан ук сулкылдавы скрипкасына күчеп өлгергән икән инде.

Кояш та ача алмас шул, ача алмый шул күңелнең-йөрәкнең төнгә бикләнгән тәрәзәсен...

*1992*

## *Кавырсын[1] һәм айбалта[2]*

Егерменче гасыр уртасында — бу хикәядә сурәтләнгән вакыйгадан соң дүрт гасыр узгач — инглизләрдән:

— Доминионнарыгызны бирәсезме әллә Шекспирнымы? — дип сораганнар, имеш. Инглизләр бәйле дәүләтләрне азат иткәннәр, Шекспирны сатмаганнар.

*Автор*

Ихсан кинәт уянды, һәм каршы диварга эленгән келәмдәге ике якты сызык аның күзләренә сихри таяклардай булып күренде — кояш нурлары егетнең җәйге йокы бүлмәсенә өйалды такталары арасыннан ярыклар тапканнар икән. Сызыклар игелек тылсымы да кебек тоелды аңа, һәм ул, дөньяның яңа бизәген тапкан сабыйдай сөенеп, кулларын йомшак кына чәбәкләде.

— Бисмиллаһи, кавырсыннарга охшаганнар ич бу сызыклар,— дип, үзалдына әйтеп куйды да ятагыннан торды.

Кавырсыннарны-сызыкларны сыйпап карыйсы итте, әмма адым атлауга ук капылт туктады.

Кирәкми, кавырсыннарга кагылсаң, аларны яньчүең-сытуың ихтимал. Аларның аз гына да кәкрелеге бик җиткән, бармаклар арасына җайлы кереп утырырлык. Кагылсаң, кавырсыннарның ямьле нурларын җуйдырырсың да аларның язу кодрәтен бетерерсең. Кирәкми.

Һәм егет адымын чикте, кавырсыннарга сокланып озак карап торды. Хыялый бер җандыр ла мин, дип уйлады ул, хыя-

[1] *Кавырсын* — кош канатындагы эре каурый.

[2] *Айбалта* — ярымай формасындагы борынгы сугыш коралы.

лый бәндә... һәм җыр сүзләре исенә төште дә аларны көйгә сузды:

Һаваларда очкан асыл кошның
Кавырсынын алдым каләмгә...

Өйалды ишеге эшермәсен салмак-тыныч кына тартты Ихсан. Ишекнең агач тоткасына сул кулының бармак очлары белән генә төртте. Әмма ишекне буранлы төндәгечә кар көрте терәгән кебек иде, ул ачылмады. Егет, уң учын ишек тактасына куеп, егәрен салып, инде көчәнеп этте. Ачылды ишек, тик үтә дә акрын ачылды, тау елгасы котырынып күшәрелүен кирегә какты диярсең, әй. Ләкин ишек тыштан терәлмәгән һәм болдырда бернинди дә ни-нәмәрсә юк иде. Ихсан ишекне ябып-ачып карады, бик тә җайлы хәзер үзе.

Сәер, дип уйлады егет, ни хикмәт булып алды икән бу ишеккә? Әллә соң Ходай Тәгаләм мине, ниндидер хәвеф-хәтәрдән саклау өчен, бүген өйдән чыгармаска уй иткәнме? Югыйсә бүген көн бисмиллалы җыр белән башланды лабаса... Нигә бүген соңлап уяндым соң әле мин?..

Ул утарның иннегеи төшерде. Атлар, иннекнең икенче башын чыгарганны көтеп тә тормыйча, аның өстеннән сикерделәр дә Иделгә таба юырттылар. Дүрт ат. Бозау хәтле ике эт — Алабай белән Йонлач — атларга иярделәр, аларның урманнан иртәнге биләмнән кайтып килеше иде инде.

Идел тыныч иде. Ихсан, чалбар балакларын тез тиңентен сыдырып, суга керде, шапыр-шопыр юынды. Атлар аңа көнләшкәндәй карап тордылар. Алар инде су эчеп туйган иде, хуҗаның юынып бетерүен көтәләр. Күндәм атлар, Ихсанны ярты сүзеннән һәм күз карашыннан да аңлыйлар. Тик Тайтулагы җилкенчәгрәк холыклы, бишенче яше китсә дә, уен ярата. Хәзер дә, Ихсан янына кереп, аны артыннан башы белән этеп җибәрде, егет суга капланды.

— Ах, әле син шулаймыни?! — сикереп торып Тайтулакка атланды егет һәм аны, нуктасыннан эләктереп, йөздерергә тирәнгәрәк алып керде.

Сайфиянең биек коймасы Иделнең сөзәк яр өстеннән үк башлана, бу якта кечкенә капка гына бар. Аны төнгә дә бикләмичә калдыралар, бүре-фәлән керүдән дә, чит-ят сугылудан да шикләнмиләр, Алабай белән Йонлачка ышаналар. Сайфиягә ерткыч керә калса, Алабай тази ялгызы гына да бүреңне генә түгел, арысланыңны да ботарлап ташлаячак. Шушы капка төбенә җиткәч, Тайтулак Ихсанның иңенә кагылды.

— Иркә җан,— дип, таргыл атны кашкасыннан сыйпады егет.— Олыгаеп барасың бит инде, ә акылың чамалы. Быел ту калдың, әллә кысрак инде син, гел дә колынламаска исәбең, ахрысы. Үзең чапкыр, карасу-кызгылт төсең килешле, кашкаң —

ай. Әйдә, алдан кер алайса.— Ат кузгалмады.— Акыллы икәнсең бит, әй, хуҗаңны башта уздырасың. Һе... һе... Сафагәрәй хан колын чактан ук бик иркәли иде сине, ат җанлы иде мәрхүм. Сине үзе атланып йөрергә үстерәсе иде, тик насыйп булмаган икән... Илне тота белә иде Сафагәрәй хан... Мине дә санга сукты... Кичә Олугымбикә синең турыда сорады, Тайтулак ничек, диде. Акыллы да, чапкыр да, дип мактадым сине, алып килеп күрсәтимме, дидем. Кирәкмәс, диде дә, Сафагәрәй... дигәч, сүзен очлап бетермәде...

Ихсан капка баганасына бәрелде, багана селкенгәләгән кебек булды, егет аны ике куллап селкетеп карады, койма торыгы белән як-якка авышкалады.

...Баганасы чери башлаган икән, алыштырасы булыр. Нинди көн булды соң әле бу — нәрсәгәдер кагылсаң яки карасаң, барысы да чатаклыгын сиздерә: өйалды такталары кибеп, аралары ачылган, коймасы җиргә сыланырга җыена, өйалды ишеге түбенә утырган... Әллә монысы шулай тоелды гына инде, кабат ачып-ябып караганда, бик җай йөрде бит ишек... Боларның барысын да мин юньле тотарга тиеш ләбаса, ханнар сайфиягә сирәкләгәч, салынкы йөргәнмендер шул... Көннәр тоташ яңгырга китеп бозылганчы вакыт бар, сайфиядәге барлык каралты-кураны карап-төзәтеп чыгасы булыр...

Егет өеннән ерак түгел генә җиргә казылган учакка якты. Кичен кисәкләгән итне баздан алып, тимерчыбыкларга кәбаб кыздырырга тезде. Бүкәнгә утырып, уйга чумды, учакка утын өстәштерүе, күмерләрне өйгәләве һәм кәбабны әйләндергәләве искәрмәстән иде. Көн кинәт төкселәнде, шул хәл аны уйларыннан бүлде, һәм ул кояшка күтәрелеп карады. Сыек болытлар кояшны сүрәнләндергән иде. Җырсыз болытлар... Шулай да таң-иртә моңсу иде, ә моңсулык җырсыз булмыйдыр. Бүген көн җыр белән башланды ич, кояш чыгар әле, юка болытларны кыздырып таратыр да ялт итеп, елмаеп чыгар. Әллә аязмасмы, кояшка дөм караңгы хәтәр болытлар ябырылырмы? Юк, шәт, көн бозылмас. Әнә кошлар парлашып очалар, алар кояшны томаларга дәһшәтле болытларга да ирек куймаслар! Күңелгә җыр килә ич!

Пар-пар кошлар...

Әмма егетнең күңеленнән җыр капылт китте. Аның күз алдына арыш басуы җәелде. Иген кыры акрын-салмак тирбәлде, аннары дулкыннар калыная-биегәя барды, кыр тоташтан уңга-сулга сөрлекте, кинәт урталай бүленеп, дулкыннар як-якка күшәрелделәр, ташкыннарга әверелеп, кирегә борылдылар, берберсенә үкерешеп бәреп, күккә чөелделәр дә чәчрәп коелдылар... Ай-һай ла... Хәвеф килмәгәе...

Ничек болай булды соң әле, дип, кашларын җыерып уйлады

Ихсан, саташамдыр, дип, чигәләрен кысып уды. Сайфия янындагы арыш басуын кичә эш иттеләр ләбаса, анда хәзер көлтә чүмәләләре генә горурланып утыра, быел арыш урагын тиз тоттылар — урак ае кергәч, олы эшне ир заты башлавы хәер, дип, беренче учманы Ихсан урган иде, ун көн дигәндә, урып та чыктылар. Акчулпан үтә дә тырышты, җырлап-сөенеп урды, гел сайфиядә яшәүче ике апа белән егет үзе дә сынатмады. Ә бүген шул арыш басуы урылмаган булып, алай гынамы соң — котырынган (Ходай язмаганны!) булып күз алдына килә...

— Ихсан!

Акчулпан эндәшә. Егет, артына борылып карамыйча гына, башын какты. Кыз кечкенә чиләген җиргә куйды да Ихсанның каршына чүгәләде.

— Ни булды сиңа? Авырыйсың мәллә? Ихсан, дим...

— Авырмыйм,— дип башын чайкады егет.— Кичтән озаграк утырганмын да соңлабрак тордым.

— Куркыттың...

— Ничек?

— Ничек, дип... Сиңа ияләндек ич монда... Ике апа да син дә мин генә лә монда...— Акчулпан чиләген алды.— Ихсан, дим, менә иртәнге сөт алып килдем, эчеп җибәр шуны. Тукал сыер сөте, шул мүкләкнең сөтен яратасың бит син. Бетер, бетер, эчеп бетер, ир кеше шуның хәтле дә сөт эчмәскә ди!

— Егет кеше,— дип көлемсерәп төзәтте Ихсан.

Акчулпанның йөзенә кызыллык йөгерде, якты күзләрен зур ачып егеткә текәлде, нәрсәдер әйтергә теләп, кызыл иреннәрен дерелдәтте, тик сүзләре онытылган иде, Ихсанга бармак янады — мутланма син, егеткәй. Шул соңгы ымы Ихсанның күңеленә ятты, ул урыныннан сикереп торды, кызның алсу маңгаеннан сөяргә үрелде, әмма кулын, кыз башын арткарак тарткач, аңа тидермичә кире алды.

— Син үзеңнең нинди көчле-кодрәтле икәнлегеңне беләсеңме, Акчулпан?! Белмисеңдер...

Кыз башын алгарак сузып кыйшайтты, нурлы йөзенә елмаю җәелде, якты түгәрәк күзләре тормышның кадерен белүдән сөенә иде — егеткә сүз белән җавап кайтармады Акчулпан.

— Синең уйнак кашларыңны сикертеп бер ым кагуың җитте. Дөнья тәмам ачылды да китте!.. Кичтән үк күңел тырнала башлады. Күз алдында гарасат капылт кына дуамаллана да мине гәрдап кырыена китереп асылындыра, шул упкынга очмас өчен, бармак очларым уелып-ертылып беткәнче тырышам, сызлавына чыдый алмыйча, бармак очларыма карасам, алар менә, шөкер, исән-сау. Гәрдап кырыенда үзем генә дә түгел бугай...

— Мин дәме? Мине...

— Син дә. Күп без... Халык... Акчулпан, әнә кояш чыкты!

Кояш, сүлпән һәм өмете качкан болытларны аралап, Идел

буена, хан сайфиясенә, шул сайфиядә хезмәттә торучы Ихсанга һәм Акчулпанга бәхет индереп елмаерга тырыша иде.

— Алайса, син кичә җыр чыгара алмадың инде, Ихсан.

— Җыр табылмады, Акчулпан. Әйтәм ич, өй эченә кара пәрдә җәелеп иңә, шәмнең утын як-якка ия. Шәмнең яме юк, шәмдәле булмагач... Җыр чыкмады, кавырсынны тешләп сытып, изеп бетергәнмен, тик җыр юк — шунысы хәвеф...

— Ә син хәвефләнмә, егет,— дип, Ихсанның чигүле түбәтәен төзәтте кыз. Аның күзләре якты өметләрдән мөлдерәмә иде.— Мин сиңа каз канатындагы кагыну каурыйларын көздән күп итеп, күп итеп әзерләп куярмын. Көз-кыш буена язарсың да язарсың!

Ихсан өеннән калач (аны кичә Акчулпан пешереп керткән иде), савыт-кашыклар алып чыкты. Чирәмгә ашъяулык җәеп, иркен табында кайнар кәбабны икәве тәмләп ашадылар — сый ашына тиң булып кызган икән куырма.

Алар урманга керергә җыендылар. Баганалыкка имәнне сөйрәтергә җайлы булыр, дип, Ихсан атны ике тәгәрмәчле арбага җигәргә уйлаган иде дә, Акчулпан:

— Бүген кулазак арбага җикмә әле,— дип каршы төште.— Минем синең белән янәшәдә утырып барасым килә.

Егет карышмады.

— Баганалыкны буена кирәкчә кисәрбез алайса,— диде ул.— Оныттырмассың әле, Акчулпан, Озын аланны узгач, Сусыз елгачык ярында яшь ак чыршы бар. Кармак сабына кисәргә ниятләп карап йөрим шуны. Биегәйде инде, юанаюы җитә. Шушы айда кисеп, кабыгын юнып күләгәдә киптергәч, кармак сабына җиңел дә, сыгылмалы-нык та була ак чыршы.

— Синең тормышны белүеңә сөенәм мин, Ихсан. Син барбар нәрсәне беләсең. Һөнәрләрең бихисап. Кармак саплыкны бүген кисәргә кирәк икән... Озак яшәрсең син, Аллаһы боерса.

— Яшәрбез.

Кыз ризалашып-шатланып башын какты. Ул арбага икесе утырырга киезне җайлады. Егет, атны җигеп бетергәч, казык башыннан киң читле эшләпәсен алып киде. Озын чобасын селтәп киң җилкәләренә элде, күлмәк җиңнәрен тотып, киндер җиләненең җиңнәрен беләзегенәчә төшерде, чобасы-җиләне изүен каплады, билбавын кысып ук буды. Акчулпан кара камзулын төймәләде, арбага менеп утырганчы, толымнарының камзул итәгеннән чыгып торган очларын янынарак шудырды. Кузгалдылар. Алабай ат алдына төште, Йонлачны сайфиядә калдырдылар — анда ике хатын ялгызлары курыкмасыннар, яннарында ышанычлы сак булуын тойсыннар. Тайтулак юлга чыкмавына үпкәләде бугай, йомшак-елак кешнәде, чапкыр атның әлегә камыт-ыңгырчакны тоеп караганы юк, аңа чуклы ияр килешә, ияргә күнекте ул.

Арбада янәшә утырган егетнең һәм кызның йөзләреннән дә, тоҗы киемнәреннән дә көнгә пакьлек бөркелә. Их-х, бу көннең яманын шул арулык-чисталык җиңсә икән...

Хан сайфиясе наратлыкта, монда бүтән төр агач үсми диярлек, имәнлек Идел буе урманының басу ягында, анда хәтле җиде мең адымнар чамасы — барыр юл хәйран ерак.

Ихсан, дилбегәне тартып, атны юыртуыннан тыйды. Атның калышуын сизгән Алабай да чабудан туктады, башын җиргә сузып иснәнде дә акрын адым белән кузгалды. Атны юырттырмау егеткә сүз башлау өчен кирәк булган икән.

— Акчулпан, көзгә өйләнешербез, боерган булса.

— Кар төшкәчкә дип килештек бит. Ризалыгымны нигә кабатлатасың?

— Мондый сүзне кабатлаудан зыян юк. Төнәген Олугымбикә килгән иде бит. Сез моны белмичә дә калдыгыз. Кыңгыраулары чыңын ерактан ук ишетеп, олы капканы ачкан идем. Тик ул сайфиягә керәсе итмәде, тарантасыннан төшмәде. Мине янына чакырды. Барып башымны идем. Аның йөзенә хәсрәт сеңгән иде, туты тагын да каралган, күз уймалары тирәнәйгән, югыйсә мондый чокыраю ханбикәбезгә хас түгел, дала баласы бит ул. Сайфиядә иминлекме, дип сорады. Дүртегез дә исән-саулармы, диде. Әйбәт җавапларыма сөенде. Өйләнешү турында вәгъдәңне бозмадыңмы, Акчулпан да сүзенә тугрымы, дип белеште. Җавапларымны тагын хуп күрде. Синең өчен җавап бирдем ич, миңа кияүгә чыгарга ризалыгыңны шуңа күрә кабатлаттырдым.

— Сөйләп бетер, Ихсан...

— Бетте инде. Олугымбикә, Сафагәрәй ханыгызның игелеген онытмагыз, бәхетле булыгыз, диде дә атларын кирегә борырга боерды.

— Без өйләнешкәнче бүтән килмәячәк икән, алайса, Ханбикә. Шулай да ул безне котлаган! Безгә бәхет теләгән! Мине күрмәвенә һич тә үкенмим. Теләген сиңа әйткәч, мин мең-мең кат разый! Сиңа әйткәч, миңа әйткән кебек инде, Ихсан. Сафагәрәй хан да сиңа үз улы кебек итеп карый иде.

— Сиңа үз кызы кебек итеп.

— Сайфиядәге ике апага үз туганнары кебек итеп. Апалар картайгач, аларны тәрбиягә үзебезгә алырбыз, яме, Ихсан.

— Сайфиядә бергә яшәп күнектек ич инде без. Гомергә таралышмабыз.

...Сафагәрәй, Казан ханлыгында өченче тапкыр тәхеткә утыргач, Идел буенда сайфия төзетте. Җәйге ял урынына еш килә алмаса да, сайфияне тәртиптә тотты ул. Мондагы ике катлы зур йортны һәм хәзер хатыннар яши торган йортны салганда, каралты-кураны корганда, осталар күп булды. Сайфия тәмам җитешкәч, анда хезмәткә баласыз, илле яшьләр чамасындагы

ир белән хатынны, хәзер дә монда яшәүче ялгызак бертуганнар ике хатынны һәм ятимнәр Ихсан белән Акчулпанны гына калдырды. Ир белән хатын, Сафагәрәй хан вафат булгач, китәргә Ханбикәдән рөхсәт сорадылар, сәбәбен әйтмәделәр, Сөембикә аларның теләгенә каршы төшмәде, бәлки, төп сәбәбен — хезмәттәге ир белән хатынның Сафагәрәй вафатын авыр кичерүләрен төшенгәндер. Тыныч һәм күндәм холыклы ир белән хатын киткәч, сайфиядә хезмәттә дүртәве генә булдылар, һәм хәзер дә дүртәве яшәүләре. Ә электә ир белән хатын һәм Ихсан яшәгән йорт егетнең ялгызы карамагына торып калды. Тик Сөембикә Сафагәрәй хан вафатыннан соң монда сирәк килә, кичә менә сайфиянең капка төбеннән дә узмады.

— Сафагәрәй хан халыкны үз итте,— дип, ханнар турындагы сүзен яңартты Ихсан.— Ул хәтта мине дә санга суга иде. Олугымбикә белән киңәшкәндә, мине яннарыннан кумый иде.

— Синнән сер чыкмасына ышанган алар, Ихсан...

— Сафагәрәй хан безнең парлап биюебезне ошата иде, име, Акчулпан...

— Берчакны ул миңа, син шагыйрь җанлы, изге җан, диде...

— Ә беләсеңме, берчакны ул миңа нәрсә диде? Җырларыңны яз, диде, халык таныр сине, халык таныр, диде.

— Әйткән идең шул...

— Ә шагыйрен танымаган түрәләрдә өмет юк, андыйлар — төфәйлиләр, үз таңнарын гына кайгыртучылар, диде. Шундыйлар, илнең түренә басу өчен, бүтәннәрне гаепкә күмеп черчек эзлиләр, табалар сылтавын, диде. Илгәсәрләр андыйлар, ил тиләләренең тиләләре, дип бәя кылды. Ялгыз эт арттан килеп өрмичә кабар, җырларыңда шуны да онытма, дигән иде Сафагәрәй хан миңа. Лаеклы эшең булса, шагыйре итеп таныр сине халык, дип тә кисәтте.

— Без ханнарыбызга черкен булмадык, име, Ихсан. Шөкер. Моннан соң да күңелләрен кайтармыйк, чиркандырмыйк аларны, ханнарыбызга тугры булыйк.

— Теге кукамай... тәхеткә утыра күрмәсен тик. Халыкка көн бетәчәк. Сиңа да, миңа да.

— Шаһгалине әйтәсең... Килеш-килбәте коточкыч җанварныкы, сурәбәтнең... Әй-й, ямьсезлек турында җитте лә, гүзәллек турында сөйләшик!

Егет кызга таба борылып утырды.

— Гүзәллек — син ул...

— Юк ла... Ханбикәбезгә тиңләшерлек бөтен дөньясында табылмас! Күзләре дә, чәчләре дә томрый кара, чем-кара, йөзе тыйнак, аннан көч-акыл бөркелә, гәүдәсенең сылулыгына сокланмаучы юктыр, өстәвенә кулларында эш уйнап тора. Кер уарга ярата ул. Сафагәрәенең киемнәрен җыр көйләп уа да Иделдә үзе чайкый иде. Иделдән Сафагәрәенең ак күлмәген

беләгенә аерым салып менәр иде, беренче итеп шуны эләр иде... Сафагәрәй хан вафатыннан соң, аның сайфиядә кер уганы булмады...

Сүз инде Ханбикә турында барды. Һәм Ихсан Сөембикәнең чаңгы шуувы турында сөйләде.

...Былтыр беренче кар төшкән көндә Сөембикә сайфиягә төшкә чаклы ук килеп җитте. Чәйләп тә тормыйча, Ихсанга тиз генә чаңгы әзерләргә кушты.

— Чаңгылар көйле, Олугымбикә.

Егет Ханбикәгә җыйнак киез итекләр бирде, аякларына киңчә каен чаңгыларны җайлап киертте. Ханбикә дохасын салмыйча гына шуа башлаган иде дә, сайфиядән йөз адымнар китүгә үк, эче-тышы йонлы тунын салып Ихсанга сузды. Сөембикә акрын шуды, әмма чаңгыларда нык тора, егылмаячагына ышана иде. Акрын шуса да, аның мамык шәленә җил ябышкан — шәл телләре җилдә тирбәлеп иркәләнәләр иде. Алабай белән Йонлач аларны озата йөрделәр. Әйләнеп кайткач, Сөембикә өйгә керергә ашыкмады. Егет доханы аның җилкәсенә салды. Сөембикә, аякларын җәебрәк басып, әтрафка горур карап торды. Сайфиядәгеләргә «Мин беренче карда юл саптым. Юл ярдым. Мин юл салдым!» дип сөенеп-сөенеп сөйләде.

Ихсан капканы ябарга барды. Капка төбендә үк ак кар өстендә кояш нурларында җемелдәүче кызгылт-сары нокталар күрде. Иелеп караса, болар гәрәбә муенса икән.

— Ләкатә! Табылдык! Ләкатә таптым! — дип, бөтен тавышына кычкырды Ихсан һәм бар көченә Сөембикә янына йөгерде.— Олугымбикә, муенса...

Сөембикә муенын капшады, муенсасы юк иде. Шуннан соң гына — муенса үзенеке булуы ихтималын белгәч кенә — ул Ихсан сузган гәрәбәләрне алды.

— Кешем,— дип олылады Ханбикә хезмәтчесен,— ләкатә кычкырмасаң да, мин синең аны урламавыңа, ә табуыңа ышаныр идем...

Сөембикә, кичә килгәч, менә шул муенсаны Ихсанга биргән иде.

— Өйләнешкән көнегездә Акчулпанга минем бүләгем итеп тапшырырсың,— диде Ханбикә.— Мин анда күренмим, йөземкыяфәтем...— дип кырыс кына өстәде.— Бүтән бурычым калмый... Сонгый булмагыз, хәзергечә табигый яшәгез, чын түгелне кылмагыз... Ходай Тәгаләдән язмагыз...

Боларын Ихсан, Ханбикәнең кичә сайфиягә килүе турында сөйләгәндә, Акчулпанга әйтмичә калдырды, хәзер дә сиздермәде — Олугымбикә бүләкне тапшырырга өйләнешү көнен көтәргә кушты ич.

...Имәнлеккә җитәрәк Ихсан, йомшак, моңлы тавышы белән:

Кыйблаларга очкан аккошларның... —

дип җыр башлады.

Карап тордым тезелеп үтүен... —

дип, нечкә-челтерәвек тавышы белән кушылды аңа Акчулпан...

Арбаны кендегеннән төшереп, тезгенне ычкындырып аркалыкны бушаткач, атны ачыклыктагы чирәмгә җибәрделәр. Алабай ат янында калды, хуҗалары үзләрен-үзләре саклый ала ягъни.

Егасы имәнне сайлагач, Акчулпан Ихсанга:

— Син әнә тегеләйгә карап төпкә утырып тор,— диде.— Мин әйтмичә болайга борылма, яме.

Күнде егет, кызга аркасын куеп, чуалышкан үләннәрне, алар арасыннан йөгерүче бөҗәкләрне күзәтте. Каршыдагы биек агачларның очларына күтәрелеп карады — алар күк белән тоташканнар кебек, араларыннан сыек болытлар күренгәли.

— Болайга борыл, Ихсан...

Акчулпан корыган имәнгә сул кулы белән үрелебрәк таянган, Ихсанга уң яны белән тора, гәүдәсен чәчләре каплар-капламас, егеткә күзләрен тутырып карый иде. Ихсан ихтыярсыздан урыныннан күтәрелә башлагач, кыз, кулы белән ишарәләп, кузгалмаска кушты. Моны сүз белән әйтсә дә, ара егет ишетерлек иде — аралары ун адым да тартмас.

Ялангач иде Акчулпан... Гүзәллекне күреп дөньясын оныткан Ихсан кызны баштанаяк кат-кат күзәтте, учына ияген куеп, тезенә таянды — гүзәллеккә текәлебрәк сокланырга теләде, тик таратып салган, тез асларына җиткән кара чәчләр Акчулпанның тәнен яшергәннәр иде. Алар арасыннан алсулыкны күзләреӊ белән эзләп табарга кирәк иде...

Озак дәвам иттеме бу хәл? Егет моны белмәде. Кыз егеткә кинәт алды белән борылды, тик гәүдәсен, ачык калдырмыйча, борылган уңайга чәчләре белән каплап өлгерде. Алды белән басып озак тордымы Акчулпан? Ихсан аңа озак карап тордымы? Вакыт исәбен алырга аларның көчләре җитмәде. Тик шунысы гына бар — кыз басып торып, егет карап торып арымадылар...

— Тегеләйгә борыл, Ихсан... Мин киенәм...

Җилкәсенә кыз башын салгач кына, сихри-татлы дөньядан фанилыкка кайтты егет. Кыз аның беләген ике куллап кысты. Ихсан хәрәкәтсез утырды, сүз әйтерлек хәлдә түгел иде ул.

— Җәйге урманда тәнемне шулай рәхәтләндерергә кызыга идем мин. Рәхмәт сиңа, Ихсан, син мине шуңа ирештердең. Мин синең кагылмасыңа ышандым. Ханбикә һәм син минем иң ышанычлы кешеләрем бит. Мин чиста... һәрчак яхшы булырга дип ханнарыбызга биргән вәгъдәләребезне без беркайчан да бозмаячакбыз ич...

Имәнне, баганалар буе турап төягәч, Ихсан Акчулпанны күтәреп алды. Кыз, егет йөк өстенә утырткачы, Ихсанын муеныннан кочты, аның кочагына сеңде. Бу аларның беренче тапкыр шулай якынаюлары иде. Алар битләрен битләргә сыйпадылар, ләкин үбешергә кыймадылар...

Ихсан кармак саплыкка дип кискән озын таякны такта сарай эченә кертеп куйды, аннары гына йөкне бушатырга кереште. Бауны чишкәч, имән баганалыклар, дөңгелдәп тә шыңгырдап, ике якка тәгәрәделәр. Егет соңгы агачны — төп буен арбага аударып төшерде, шулай да юан агач тегеләреннән дә иләмсезрәк тавыш чыгарды. Шул дыңгылдау Ихсанны сискәндереп җибәрде. Кинәт аның күз алдына Идел өсте килеп басты. Һәм ул Иделгә таба йөгерде. Елганы күрүгә, шып туктады.

...Чын мәгәр, Идел өсте коточкыч ямьсез, аны җыерчыклы җәймә булып кан каплаган кебек. Чиркангыч җәймәне котырынган дулкыннар рәхимсез җыера. Идел кан елый. Юк, бу аның елавы түгел икән лә, Идел, электә үзенә аккан каннарны күрсәтеп, кабат кан коюлардан сак булыгыз, дип, адәм балаларын кисәтә икән...

Ихсан кояшка карады.

...Чын мәгәр, елан кыяфәтле кара болыт кояшны кылыч булып кискән кебек. Кояш кан елый. Юк, бу аның елавы түгел икән лә, Кояш, аң булыгыз, мин сез койган каннарны күреп кызардым, дип, адәм балаларын кисәтә икән...

Ихсан сайфиягә тыны кысылып йөгереп кайтты. Атлар утарына җитмәстән үк:

— Чапкыр! Тайтулак! — дип кычкырды.

Хуҗасының мондый кабалануын моңарчы белмәгән Тайтулак, Ихсан нуктасыннан эләктергәч, башын каерып, читкә сикерде. Ихсан аны очып диярлек кабат тотты, ашыгып йөгән киертте, иярләде, менеп атланды да, ияр дәге камчысын чишеп ала-ала, атны сайфия эчендә үк куалады. Инде Тайтулакны чаптырып барышлый, Акчулпанга һәм хатыннарга:

— Акчулпан, атны туар! Атларны ач итмәгез! — дип боерды.— Этләрне алып калыгыз! Миңа иярмәсеннәр! Казан каласында бохран купкан! Коточкыч борылу-түнтәрелү! Өч төштән төтен күтәрделәр!

Ихсан бераздан, Тайтулакны дуамал куалап, кире кайтты. Кулына хәтфә келәм тоткан Акчулпан янында атын шып туктатты.

— Ияреӊ астына чапрак салырга оныткансың...

— Кирәкми! — дип кул селтәде Ихсан һәм өенә таба йөгерде. Өеннән күз ачып йомганчы — әллә шул ләхзә дә узмады инде — айбалта тотып чыкты. Акчулпан янына килгәндә, тышкы ярсуы бераз басылган иде.— Монсыз ярамый, Акчулпан,— дип, кызга иелеп пышылдады ул,— минем язганнарым

арасында бер төргәк булыр. Олугымбикә кичә миңа гәрәбә муенсасын калдырды. Сиңа бүләк итеп. Мин кайтмасам, үзең актарып алырсың...

Акчулпан башын чайкады.

— Мин үзеңнән башка бер әйбереңә дә кагылмыйм... Икебез бергә карарбыз...

Кызның бу сүзләрен тояк тавышлары басты. Алабай белән Йонлач хуҗа артыннан ыргылмакчы булдылар — бәйдән ычкына алмадылар. Хан сайфиясе ике сакчы эт һәм өч хатынкыз карамагында калды.

...Казан каласы чыр-чу, кычкырыш-бакырыш, үкереп тә мышкылдап елаш авазлары белән тулган иде. Ихсан Ханбикәне җибәрүләренә шикләнмәде, шуңа күрә ул Чапкырны-Туйтулакны Казансу тамагына таба куалады. Ул килеп җиткәндә, Сөембикә ханны утырткан көймә, Иделгә чыгып, агымга каршы юл алган иде инде. Ихсан Елантау турысына хәтле атта чабып барды да, эчке киемнән генә калып, айбалтасын биленә бәйләп, Иделгә сикерде һәм, көймәне куып җитәргә тырышып, колачлап, кызуланып йөзәргә кереште. Ара ерак түгел, көймәне куып җитәр дә Ихсан, Ханбикәне коткарып калыр — ашык, ашык син, егет!

...Олугымбикә, син — безнеке, китмә бездән. Олугымбикә, син мине күрәсеңме? Мин синең сайфияңдәге Ихсан...

Сөембикә көймә уртасындагы урыныннан торып басты. Аның йөзе бозылган, йөзенең нуры качкан иде. Ул кулларын Казан каласы ягына сузды.

...Мин сине күрәм, Кешем. Соң аңладым хатамны — илгәсәрләрне кызганма, төфәйлиләрне тирәңә китермә икән...

Ихсан биленнән айбалтасын алды, аны, судан чыгарып, югары күтәрде.

...Олугымбикә, мин сине хәзер коткарам...

...Кешем, селтәнмә. Безнең халык, корал тотып селтәнүдән элгәре, эштә селтәнүне хуп күрә. Селтәнмә, кан коймыйк. Кеше каныннан Идел болай да тулы...

Йөзгәндә тирәнлекне юрамыйсың — Ихсанның юлында бөтерелмә чоңгыл очрады. Егет чоңгыл белән көчәнеп, газапланып тартышты. Һәм бирешмәде. Тик явыз чоңгыл аның кулыннан айбалтасын суырып алган иде. Шулай да Ихсан көймә артыннан бөтен көченә йөзде, инде коралсыз калса да, Ханбикәне коткарачагына ышана иде, ахрысы, ул.

...Олугымбикә, китмә коллыкка, мин чураның хәлен беләм, Сафагәрәй хан коткармаган булса, мин коллыкта инде күптән черегән булыр идем, коллар озак яшәми. Олугымбикә, сикер суга, мин сиңа батарга ирек куймам, Тайтулак-Чапкыр янына чыгарбыз да син атланып качарсың...

Сөембикә күзләрен сыпырды, Ихсанны күздән җуеп торды бугай.

...Юк, Кешем, мин кире борылмыйм. Гадәтем андый түгел. Төфәйлиләр, мине сатып, рәхәт кормакчы булдылар. Кеше сату бәрабәренә бәхет яуланмый. Төфәйлиләргә-сатлыкларга үлгәннәрдән көнләшеп яшәр заманнар килерен беләм. Еладым мин. Хәзер дә бик сыкрыйм. Каһәр укыйммы? Дәррәү күтәрелеп якламавы өчен, халкыма каһәр салыйммы? Каһәрләмим. Халкыма илне торгызуда каһарманлык телим. Каһарманлык! Тик илем торып басканчы, күп чорлар узар шул. Идел өсте канлы. Аны чистартканчы, күп гомерләр... Аебызны югалтырга язмасын берүк...

Идел суы чоңгылны узганчы тәнгә йомшак иде, хәзер исә Ихсанның бөтен тәнен чәнчи башлады. Дулкыннар да, агым да каршы, йөзәргә авыр, һай авыр.

Егетнең яныннан кавырсын уйнаклап узды, ләкин ул аны күрмәде. Күрсә дә, алмас иде, чөнки бу чактагы канат вакытсыз җаны кыелган, рәнҗетелгән кошныкы була, ә андый кавырсыннарның җыр язарга, ил язмышын язарга яраксызлыгын, харамлыгын белә Ихсан. Аннары бит әле аңарга быел каурыйлар җыярга да кирәкми, көзен Акчулпан каз канатларындагы каурыйларны күп итеп, күп итеп әзерләячәк...

Кинәт Казан каласыннан түбәнге якта, хан сайфиясе өстендә, киң сызылып яшен яшьнәде, тирә-юньне дер селкетеп, күк кат-кат күкрәде. Шуның тавышы егетнең, суда йөзгәндә дә, колакларын тондырды. Ихсан артына борылып карады. Идел өстендә, сайфия ягында, гыйфрит болыт ыржая иде.

— Ах-х, бетерде...— дип кычкырды Ихсан.

Һәм хәйләкәр дулкын аның авызына су тутырды, куәтлесе баштүбәсенә дулап орды. Әмма егетне батыра алмады дулкын. Ул, соңгы көчләрен җыеп, өскә чыкты. Дулкыннар капылт тынды, шөкер, йөзәргә җиңеләйде.

...Ихсанның маңгаена үткен очлы ук кадалды. Шуннан соң көймә юлыннан йөзүче Ихсан күренмәде...

Ук кадалган ләхзәдә хан сайфиясе өстендә яшен, тагын уйнаклап, олы капканы чартлатты. Ихсанның Чапкырда юырттырып кайтырына өметләнүче Акчулпан шул капкага ышыкланган иде...

Бу фаҗигаләр күз ачып йомган арада булды.

Сөембикә Казан каласы ягына төбәп карады. Ханлык башкаласы аңа инде күренмәде.

Шул ук ләхзәдә яр буйлап арлы-бирле атылып чабучы Чапкыр-Тайтулак, текә яр турысында капылт туктап, үрә басты, ачыргаланып кешнәде дә Иделгә сикерде. Ай-һай ла, кемгә ярдәм итәр икән ул, ярдәм итә алырмы икән?..

*1994*

# Киртә буенда

Ак һәм кызыл карлыганнар яфракларын коеп бетергәннәр, ә каралары әлегә чишенергә теләмәгәннәр, быелгы ботакларда дәү яфраклар мул ук. Илдархан шул яфракларны бер уч җыйды да әнисенә бирде.

— Чәйгә салырбыз, кура яфрагы да кушарбыз,— диде ул.

— Улым, суыткычта туңдырган карлыган бар. Тәмен саклаганы,— дип, әнисе шәһәрдән кайткан улына сыйның тәмлерәген татыттырмакчы булды.

— Яфрак чәе эчәсе килде, әни. Җәй уртасын искә төшерик әле.— Бу сүзләре әнисенә каршы төшү кебек тоелды да Илдархан: — Туңдырган карлыганнан да авыз итәрбез, әни,— дип өстәде һәм, янәшәдәге агач төбенә күчеп, аның хәлсезләнгән ботакларын кисәргә кереште.

Алар биш бала үстеләр, Илдархан — төпчеге. Аның абыйапалары үз гаиләләрен кордылар да төп нигездән киттеләр. Ике абыйсы калага урнашты, апалары авылда калды. Илдархан әлегә өйләнергә исәп итми, университетта дүртенче елын укый ул, прокурор булырга җыена. Гаилә мәшәкатьләренә чумганчы, укуын тәмамларга кирәк, эшли башлагач ук өйләнү уе булмас, элгәре эшкә ныклап күнегү тиеш. Аннары вәгъдәләшкән кызы да юк хәзергә. Хәер, аңа язганы очрар, тормыш дигәнең үзе сайлап бирер кылыклы хәләлен. Ә хәләленең әйбәт холыклы булырына Илдархан ихластан ышана.

Әй-й, бар иде лә ул андый кыз! Тик аның белән кушылу мөмкин түгел инде. Шуңа күрәдер ул матуркай күңелгә бикләп куелды, мәхәббәт дигән изгелек иләмәне колачлы канатларын хәтта җилпетергә дә көчсезләнде. Илдарханның хәтеренә сирәк, бик сирәк төшә ул чибәркәй. Илдархан авылга кайтканда юллары очрашса да, егетнең күңеленә салган йозагын ачтыра алмас ул гүзәлкәй...

Шулай, Илдарханның әти-әнисе төп нигездә икәве генә яшиләр. Олыгайдылар, көчләре ташлый бара үзләрен. Ләкин йортҗирне тәртиптә тоталар, булдыра алган кадәресен үзләре башкаралар, зур эшләр балаларына һәм оныкларына өлешләп бүленгән. Язын-көзен җиләклекләрне һәм җимеш агачларын карау Илдарханга йөкләнгән. Бу һөнәргә ул кечкенәдән әтисе янында, аңа башта комачаулап, соңыннан булышып өйрәнде. Хәзер аңа ни эшләргә икәнлеген боерырга кирәкми, шулай да әтисеннән ара-тирә киңәш сораштыргалый Илдархан. Әмма әтисе төгәл җавап кайтармый, мондый чакта гел:

— Үзең беләсең, улым,— дип әйтүдән узмый.

Хәзер дә Илдархан:

— Бу төпне алыйк мәллә, әти? — дигәч, гадәти сүзләрен кабатлады карт.

Һәм Илдархан карлыганны, әйләнәсен тирән үк казып, тартып чыгарды, төптәге балчыгын беткәнче койды.

— Анысының уңышы быел аз булды шул,— диде этисе.— Нигә икән? — Бу соравы улының бакчачылык белемен сынап карау иде.— Югыйсә менә монысы белән бер елда утырткан идек без аны.

— Алганы яшьләй үк җимешне күп бирде, эти. Яшьтән артыгын тырышты, үзәккә көч килгән. Шулай да булгалый икән, эти.

Илдархан янәшәдәге агач ботакларын сайлап сирәкләргә тотынгач, этисе белән әнисе, кыска эскәмияне ике баштан тотып, аның кырыена күчерделәр. Ял көненә генә шәһәрдән кайткан Илдарханның янында ук булу рәхәтлек бирә иде аларга. Җайлап утыргач, әнисе, улының соңгы фикеренә сак кына ялгап, әңгәмәне бүтән юнәлешкә борды — мондый иплелекне әни кешеләр генә булдыра аладыр.

— Шулай шул, улым, элек буын ныгыту хәерле,— диде әнисе.— Менә Васфияне әйтәм әле, ашыгыбрак кияүгә чыкты да бөтенләй үзгәрде балакай, өлкәннәр төсе инде мескенкәйгә. Өстәвенә кайгы яман да басты үзен. Ирен яптылар.

Илдархан, карлыганның юан ук ботагына кискечнең көче җитмәгәч, бакча пычкысын алды, әмма аны эзгә сала алмыйча азапланды, кулы калтыранды.

— Ун елга,— дип төгәлләүне кирәк тапты әнисе.— Ике сабый күп гомергә ата назыннан мәхрүм.— Әнисенең тел төбендә үтенеч төсмере сизде Илдархан.— Бигрәкләр дә кечкенәләр шул...

— Ятмановның гаебе зурдан, алайса.— Илдархан Васфиянең ирен нигәдер фамилиясе белән әйтте. Хәер, ул аның исемен моңарчы телгә алмады, фамилиясен дә беренче тапкыр атады.— Гаепсез кешегә шундый каты җәза бирмәсләр.

...Шәвәли Ятманов бу як кешесе түгел. Аны хәзерләүләр конторасы башлыгы итеп күрше төбәктән китерделәр. Хезмәт юлында күтәрелү саналган икән Ятмановны бу күчерү, район үзәгендә үк мондый вазифаны башкарырлык кеше табылган булыр иде югыйсә. Ятманов контора хисапчысы Васфиягә беренче күрүдә үк гашыйк булган икән. Озынча буйлы, уйчан карашлы, салмак хәрәкәтле егетне кыз да ошаткан. Алар, озынозакка сузмыйча, туй ясадылар. Илдархан туйга чакырылмады. Хәер, ул, бәлки, туйга кайта да алмас иде, чөнки университетта укуларның кызган вакыты иде. Авылга кайткан чагы туры килсә, чакырылмаса да, бәлки, туйны күрү җаен табар иде. Бәлки. Мондый кыюлыгы гаеп ителмәс тә иде, чөнки Илдархан белән Васфия вәгъдәләшмәгәннәр иде. Илдархан Васфияне ошатса да, аңа яратам, дигәне булмады. Васфия дә Илдарханга мөнәсәбәттә хисләрен дуслыктан уздырмагандай ит-

те. Шулай да алар бер-берсенә бик тә ошыйлар, Илдархан киләчәктә Васфия белән яшәячәгенә ышана иде. Васфия дә шулай уйлагандыр әле, тик ул Илдарханның университет тәмамлап кайтуын көтәсе итмәгән, егетнең студент булуына ярты ел тулмаста ук кияүгә китеп барган. Хәзер әнә ике малае белән тол хәлендә. Өстәвенә җегәре тормыш арбасын тартырлык булып ныгыганчы ук тәртә арасына керде...

Вакыт узуын тоеп-гамьләп бетермәле түгел икән, киләчәккә ният-уйларны гына тәртипкә тезеп, елын-көнен билгеләп буладыр. Шулай, Илдархан дүртенче курска җитте, авылга бәйрәмнәрдә һәм бакча эшләре вакытында гына кайтып йөрде. Шөкер, әти-әнисе исән-сау, аларны башка балалары да ярдәмнәреннән ташламыйлар, гаилә тормышы көйләнгән-күнегелгән тәртиптә бара.

...Октябрь башы иде. Илдархан кичтән кайтты. Иртән бакча эшләрен карады, әти-әнисе гадәтчә аның янында йөрделәр. Алар Илдарханның, укуын тәмамлагач, авылга — район үзәгенә кайтасын беләләр, төп нигезнең таркалмаячагына ышану карт белән карчыкка сөенеч өсти. Әтисенең төпчек улына гаилә кору турында искәрткәне юк, ә әнисе моны читләтеп кенә сиздергәли. Бүген дә Илдархан карлыганнарны кышка бәйләгәндә:

— Васфиянең балалары исәеп килә,— дип сүз кыстырды. Әллә Васфияне килен итәргә теләве инде тагын.— Авыр инде Васфиягә, тырыша инде, балакай, тырыша, тырмаша. Ире ун елын тутырып кайткач, Васфиянең кадерен белсә ярый ла. Ай-һай, гаиләдән бизгән булыр инде ул,— дип нәтиҗә чыгарып та куйды әнисе.— Васфияне үз итмәс, иң яманы — балаларыннан күңеле кайтыр, гөнаһсыз җаннардан...

Бу сүзләрне колак яныннан гына уздырган кебек тоелса да, бераздан Илдархан:

— Ятманов кайтырына озак шул, әле утыра гына башлаган,— диде.

— Озак әле, улым, озак булмаган кая...

Монысына Илдархан җавап кайтармады. Әнисе дә, соңгы сүзләрен ашыгыбрак әйтсә дә, фикерен тәгаенләүдән тыелды. Илдарханга әтисе бау кисеп биреп тора иде, зур шөгыль белән мәшгуль кыяфәт ясады, Васфия белән Ятманов турындагы кыска әңгәмәгә катнашмады. Көндезге чәйдән соң гына, Илдархан кибетләрдән әйләнеп кайтырга чыгып киткәч, карчыгына:

— Әйттем ләбаса — яткын җирне сөрмәкче буласың, дидем,— дип искәртте.— Яткын җирдә иген уңмый. Безнең Тугановлар нәселе булуыбызны онытма.

— Илдарханны үзебез исән чакта башлы-күзле итү хәер иде лә. Күпме гомер калгандыр безнең... Оныклар...

— Әзер оныклар кирәкме сиңа?! Васфия ире белән аер-

ылышмаган лабаса, берьюлы ике ир хатыны була алмый лабаса ул.

— Аерылышуын әфәрмит итмәкче икән шул...

— Ничек инде — аерылыша?! Иренә тугры түгел, димәк. Шундый кешене киленең итәргә җыенасыңмы? Акыллы кызлар беткәнме? Һе... Моннары мондый тиле сүзләреңне кабатлама!

Һәм бу хакта карт белән карчык арасында сүз шунда бетте, бүтән кабатланмаячак инде. Төп нигез хуҗасы чыгарган хөкем нәселдә катгый үтәлә, әйе, карар игълан ителгәнче генә фикер-теләгеңне әйтә аласың. Бәлки, Илдархан да бу мәсьәләдә әтисенең хөкемен көткәндер, шуңа күрә ике балалы хатынга, аны төрмәдәге иреннән аертып, өйләнергә җыенмавына шул сәбәптер. Ә бәлки Васфияне сөя башлау заманы онытылгандыр, ә бәлки электә бөреләнгән мәхәббәтенә күгәрек йозакны ачылмаска салгандыр. Кем белә моны — Илдархан күңелендәгесен ачып сала торганнардан түгел.

Кибетләрнең күбесе бер тирәгә укмашканнар. Илдархан килү уңаеннан чаттагы хуҗалык әйберләре кибетенә керде, инде үзендә булса да, стаканда чәй кайнаткыч алды — укулар тәмамлануга бара, тегесе өйдә торса, яңасы белән эш урынында чәй кайнатыр.

Аннары китап кибетенә юнәлде. Яңа китаплар кайтмаган икән. Шулай да ул монда шактый юанды, китаплар яныннан тиз генә китә алмый ул. Ә кибеттән чыкканда, ишек төбендә үк, аңа каядыр ашыгучы Васфия очрады. Икесе дә сискәнгәндәй булдылар, әйе, нәкъ шулай гына, тик икесенә дә әллә ничек ясалма тоелды бу халәт. Бер-берсенә тартылып та куйдылар, ләкин бу тыныч хәрәкәт тә гайре табигый иде. Васфиянең кинәт як-ягына карануы гына аларны аңнарына китерде.

— Исәнме... Исәнмесез, Васфия.

— Йа Ходаем, күпме гомер күргәнем юк бит инде сине, Илдархан... Үзгәргәнсең, әзрәк буйга да үскәнсең бугай. Акыл иңгән сиңа.

«Син дә үзгәргәнсең. Бик. Әллә буең да кыскарган инде...» Илдархан шулай уйласа да, авызыннан башка сүзләр очты.

— Ә Васфия гел дә элеккечә икән...

— Шулаймы? — дип үпкәләүсез икеләнде хатын. Ул егеткә төбәп карады, ләкин аның карашын тота алмады.— Дөресен үк әйтмисеңдер дә, әмма барыбер сөендердең. Мин...— Васфия, ир хатыны ич, як-ягына каранды — гайбәт кубудан шикләнде, аның алсу йөзе кызарып ук алды.— Мин ашыгам әле...

— Юлыңны бүлмим,— дип, коры гына әйтте Илдархан. Һәм мондый рәсмиятен суытырга теләп: — Юлың уң булсын,— дип өстәде.

— Әй-й, йөгерәм дә чабам инде мин! — Хатын беразга тукта-

лып уйланды.— Барысы да ялгыз башыма калды.— Тагын сүзеннән тукталып торды.— Кичен, балаларны йоклаткач, капка төбенә чыгып утыргалыйм. Бөтен ялым шул. Ун минутлык ял...

Илдархан эндәшмәде, баш кагып кына куйды, бу хәрәкәте ирле килеш тол хәлендәге хатынның нужа камыты муенын кысуын, җилкәләрен басуын аңлау иде. Моны Васфия дә, шәт, дөрес аңлагандыр, аның үзен тотышында үзгәреш сизелмәде, шулай да күңелендә нидер сикеренде түгелме икән — егетнең яхшысы төрле нужага ярый, диләр бит әле.

— Киттем...

— Бирешмә...— Илдархан, монысының да рәсмият калыбы икәнлеген абайлады да: — Чыдам бул,— дип төзәтергә тырышты.

Хатын бер йортны узуга ук борылып басып торды. Аңа егет күренмәде. Карап калмаган икән, дип уйлады Васфия һәм, уфылдап сулады да, йомышлы юлында адымнарын тизләтте.

Илдархан исә кибеткә кергән иде. Сатучыларга:

— Кабат күз йөгертим әле,— диде, түрдәге тарих китаплары шүрлеге янына узды, китапларны җентекләп актарган кебек булса да, уйлары бүтәндә иде.

«Үзгәргән Васфия, бик тә үзгәргән... Биегәндәй генә җиңел йөргән Васфиянең өстенә йөк дыңгычлап өелгән дә аны сыгылдырган, шуңа күрә адымнары авыр. Әй лә, дөрес бәяләмимдер, мин Васфиянең йөрешен күрмәдем ич, шулай да йөрүе аякларына потлы герләр аскандай булып күз алдына килә. Һе... Чәчләрен өчтән үрә иде, тигез ике толым итеп. Хәзер дә, бәлки, шулайдыр, үзенеке түгел кебек озын-салынкы юбка- костюмы эченнән толымнары күренмиләр. Электә маңгае өстенә сыланып яткан чәчләре хәзер калын кыек яулыгын тырпаешып төртәләр бугай. Йөзе ябыкмаган, киресенчә, калынайган-тазарган, юк ла, ишелеп үк җәелмәсә дә, тубырсыкланган икән. Түгәрәк сипкелләре сазлык кыриендагы шәрә-сирәк түмгәкләргә охшый. Һе... Әй лә, нигә тузга язмаган чагыштырулар башка килә соң әле? Туктал, Илдархан агайне, кешегә бәя бирүдә комарланырга-мавыгырга әвәсләнмә. Синең киләчәктәге хезмәтеңдә мондый тайпылулар хаталануларга җиткерәчәк. Ә сиңа, хөкем чыгаруны таләп итүчегә, ялгышу ярамый. Әтиеңнән үрнәк ал — аның хөкем карары һәрчак нигезле. Васфияңне... һе-е... Васфияне күз алдына кабат китер! Әнә ул нинди әдәпле, пакь һәм нәфис! Аның гүзәллеге һичкайчан җуелмас! Туктал, Илдархан, югыйсә бәяң тагын берьяклыга кайтып калачак. Шулай да... Шулай да Васфиянең күзләре аяз, аларны кучкыллы болытлар һичкайчан капламастыр...»

Илдархан кибеттән күзләрен кыса төшеп, иреннәрен алмаш-тилмәш тешләп чыкты, сатучы кызлар белән саубуллашырга онытты.

Кич җитте. Әти-әнисенә киногa барам, дисә дә, капка төбендә сәгать чамасы утырды Илдархан. Күзге караңгылык тәмам иңгәч кенә, биек ярлы инешкә төшүче киң тыкрыкка таба китте. Монда караңгылык куерак иде, аргы башы һич тә күренмәс куыш кебек монда. Йөгерек инеш юып шомарткан ялпак ташларның көндезге җете аклыгы да үтә тоnык. Шулай да Илдархан бормалы инешне кичү өчен кай төшләрдә җәенке ташлар тезелүен белә. Тик җәһәннәм дөмендә, сөртенмәс өчен, аякларыңны шудырып кына атлап йөрүнең ни хаҗәте булды соң әле? Мәгънәсез шөгыль ләбаса бу. Инде авылыңны сагынгансың икән, аның урамнарында син — алар яктыртылган ич — күбрәк нәрсә күрә алыр идең, шәһәрдә авылыңны юксынуың хисләрен тизрәк басар идең.

Һәм егет, озын улаклы чишмә яныннан инде авыл башына җитәрәк шактый сөзәкләнгән ярдан күтәрелеп, ике яктан да тәбәнәк тотылган киртәле тыкрыкка керде. Тыкрыкны адымнарын санагандай узгач, уңга борылды. Һәм кинәт туктады — Васфияләр йорты-ихатасы икән ләбаса! Әмма ирегә китмәде Илдархан. Капка төбендә ике кеше утыра иде, берсенең Васфия икәнлеге шиксез — көндез, тәүлегенә ун минут ял тия миңа, кичен капка төбенә чыгып утырам, дип, сүз уңаеннан гына искәрткән иде ул. Әллә соң Васфиянең шушы сүзләрен Илдархан кичке очрашуга чакыру итеп аңлаган идеме? Югыйсә бу тирәгә юлы төшмәскә тиеш иде. Әллә, Васфия искәртмәсә дә, мондый очрашуны язган булдымы икән...

— Илдархан, син түгелме соң? — дип, урыныннан кузгалды Васфия.

— Мин...— Егет аптырап калды, Васфияне очратырга теләп, әйләнгеч юлдан йөрүе сәбәбен ул шушы мәлдә генә аңлады. Һәм моны яшерә алмады.— Мин... Мин сине эзләп йөрим икән, Васфия...

— Мин дә менә, балаларны йоклаткач, сине көтеп алырга чыктым,— дип, ачыктан әйтеп салды яшь хатын.

— Нигәдер очрашасы килде бит...

— Әйдә, әйләнеп килик,— диде Васфия һәм Илдарханның беләгенә бармак очлары белән кагылды, бу хәрәкәт егетне буйсынырга мәҗбүр итте.— Ә син шунда утырып тор,— дип боерды ул каушауданмы әллә кызык көтүдәнме эскәмиягә береккән яшүсмер сеңлесенә.

— Озак булырсыз ла сез,— дип ризалашмавын белдерде сеңлесе.— Мин ялгызым гына куркам ич.

— Тын гына утыр! Сабыйланма! — дип тупасланды Васфия.— Башыңа кирәкмәс уй тутырма! Нигә әле без озак... озакка икебез генә калырга тиеш ди?!

Алар Илдархан әле генә менгән тыкрыкка борылдылар. Торык буе узгач, туктадылар. Егет киртә баганасына терсәкләре белән таянды, буш бакчадан карашы белән нәрсәдер эзләгән-

дәй итте. Хатын аның янәшәсенә үк килеп басты, егетнең ягына сулышы тиеп узды.

— Илдархан, миңа кара әле. Миңа кара... Минем тугрылыгыма ирем барыбер ышанмас...

Һәм Васфия баскан урыныннан ук өйләренә таба йөгереп китте.

Илдархан, киртә баганаларына терсәкләре белән таянган хәлендә, төн уртасын җиткерде. Бер үк нәрсәләрне рәткә тезеп тә, аларны сүтеп, төрлечә аралаштырып та кат-кат уйланды ул. Ниһаять, катгый карарга килде һәм, тәҗел эше барлыгы әле генә исенә төшкәндәй, йодрыгын йодрыгына бәрде дә ашыгып китеп барды. Тыкрыкны чыккач, Васфияләр капка төбенә таба борылып карады. Анда Васфия белән сеңлесе күренмәде. Хәер, алар инде күптән йоклыйлардыр, Васфия, егетне ялгызын калдырып йөгергәч, сеңлесен җилтерәтеп җитәкләгәндер дә ике сабые янына ашыккандыр. Хәзер, бәлки, ике малаен ике ягына кочып, шыңшыйдыр. Еламасын иде Васфия, күз яшьләрен балалары башларына төшермәсен иде. Күз яшьләренә коенмасыннар иде балалары...

Шәвәли Ятмановны төрмәдән чыгардылар. Аның эшен суд яңадан карагач кылынды бу хәл. Җинаятен кабаттан тикшертүне булачак прокурор Илдархан Туганов башлап йөрде, ахырынача җиткерде. Суд Ятмановны тулысынча акламады аклавын, ләкин җәзаны ике елга калдырды — яңа хөкем карары игълан ителгәндә, ул бу срокны арттырып тутырган иде инде. Илдарханның хезмәте диплом эше итеп бәяләнде, әйбәт бәяләнде. Тик Илдарханга, дәүләт имтиханнары тапшырып, кулына диплом алырга насыйп булмаган икән...

Ятманов, азат ителеп кайткач, Илдарханнарга үзе сугыласы итмәде, гәрчә булачак прокурор, рәхмәтен әйтмичә калмас, дип көткән иде, бу кадәресе игелекне аңлау булыр иде. Хәер, Илдархан бүтәнчә рәхмәтләүне башына да китермәде. Аның балалар һәм Васфия хакына кылган хезмәтенә шул бәя бик тә җитә иде. Шуңа күрә ул, май башында авылга кайткач, кино алдыннан Ятмановның үзе килеп кулын сузуына ихластан сөенде. Тик Ятмановның йөзендә сөмсезлек-тупаслык төсмерен сизде дә аның шатлыгына пычрактан иң киме әдәпсезлек тамчысы чәчрәп ябышкандай булды.

— Әйдә, чыгып керик әле,— диде аңа Ятманов.

— Әйдә.

Васфия аларны читтән күзәтә, иренә нәрсәдер әйтергә җыенып, талпына, ләкин аяклары идәнгә береккән дә аларны аерырга көче җитми кебек иде.

Алар сүзсез тордылар. Теге кичтә Илдархан белән Васфия дә киртә буенда сөйләшмичә торганнар иде. Ятманов эндәшмәгәч, Илдархан:

— Хәлләрең ничек? — дип сорады. Җавап ишетмәгәч: — Нindidер күңелсезлек бар мәллә? — дип кызыксынды.

— Бар,— дип тирән сулады Шәвәли Ятманов. Аның болай офтануын Илдархан төрмәдә һәм хөкем залында очрашуларда күрмәгән иде.— Синең мине азат итүдә булышкан булуыңның сәбәбе беленде... Син минем алдагы гаебеңне юып ташламакчы икән... Син минем хатынны нитеп...

Илдархан башта бу сүзләрнең мәгънәсенә төшенмәде, кинәт аның йөзенә пычракны потлап сиптеләр, намусына шакшы буа суын ердылар кебек тоелды.

Ул сул кулы белән Ятмановның изүен җәһәт бөтереп алды, уңы белән яңак төбенә кундырды. Ятманов сыгылып төште, ләкин Илдархан аны ычкындырмады, аягына бастырды.

— Чамалап... минем кайдан кайтканны онытма...— дип мыгырданды Ятманов.— Мин сине шәбрәк чәпәләргә дә күп сорамам...

— Сорамыйча ук — мә! — дип ысылдады Илдархан һәм тагын берне шәпләп сылады. Ятманов тагын ишелеп ава башлады, ләкин Илдархан Тугановның көченә ачуы да кушылган явызлануы аны турылап бастырды.— Хәсис икәнсең! Синең шакшылыгыңны моңарчы күрмәгәнмен!

— Хатын... хатын...— дип тагын мыгырданды Ятманов.— Хатын синең белән киртә буенда торганын үзе әйтте... Киртә буенда...

Илдархан, нәфрәтен дә кулына күчереп, тагын селтәнеп сукты, Ятманов сыгылырга өлгергәнче, аны җан көченә этеп җибәрде. Хәлсез Ятманов юл кырыена шәлперәеп барып төште, егылган төшеннән арырак шуды хәтта. Һәм Илдархан, кулларын каккалады да, кайтып китте.

Ятманов аны хөкемгә бирде. Туганов кылганын яшермәде, шаһитлар раславы булмаса да, кыйнавын булганча таныды. Ятмановка шәп эләккән икән шул — яңак сөяге чәрдәкләнгән, теш казнасы кузгалган... Шулары ачыклангач, Илдархан Туганов: «Беләктә көч бар икән дә, тик акыл көче чамалыдан чамалы»,— дип уйлады. Аны ике елга хөкем иттеләр. Шартлы рәвештә. Дәүләт имтиханнары башланыр көннәрдә — суд алдыннан — университеттан чыгардылар.

Шулай, диплом дигәне тәтемәде Илдарханга. Хәзер ул колхозның җиләк-җимеш бакчасында эшли. Инде өченче елы. Әйбәт эшли. Карлыганы да, кура җиләге дә былтыр һәм быел мулдан булды. Алманың быелгы уңышын җыеп бетермәле түгел. Ярый әле бала-чага булыша. Илдархан аларны туйганчы сыйлый, өйләренә дә биреп җибәрә.

Шулай, әтисе өйрәткән һөнәре — бакчачы һөнәре ярап куйды Илдарханга. Шулай, борынгылар әйтмешли, һөнәр ашарга сорамый, һөнәр үзе ашата. Әмма теге чакта хуҗалык әйберләре

кибетеннән, прокурор булгач, кирәге чыгар дип алган чәй кайнаткычын әлегәчә тотканы юк. Чәйне алма бакчасында учак ягып кайнатырга гадәтләнде Илдархан...

Алма бакчасы буенда ике кечкенә малай басып тора.

...Киртәләр тәрәзәгә аркылы сугылган бөгелмәс тимерләр сыман. Шул искермәс киртәләр, дөньяның җете яктылыгын тасма-тасма кискәләп, ике малайны томанга кысрыклап ыржаялар... Туктал, Илдархан агайне, тузга язмаган чагыштыруларыңнан туктал...

Ике малай җитәкләшкәннәр. Йөз чалымнары белән нәкъ Васфия инде үзләре. Әллә чыннан да аның малайлары тагын. Бәлки, шулайдыр. Илдархан Васфиянең балаларын танымый, күргәне юк аларны. Малайларда Васфияне төсмерләве, бәлки, охшату гынадыр...

Бакчада балалар кызулана-ярыша алма җыялар.

Ә алмалар күп, бик күп, хәтта алар шап та шоп коелалар.

Хәзерге — җәйге тәмнәрен кышын да сакласыннар иде алмалар.

*1995*

# *Каңгый илендә*

Агач төбе әйләнәсенә чыпчыклар чыркылдашып атылалар да, анда җим чүпләгәч һәм сөенешеп серләшкәч, алмагач ябалдашына дәррәү менеп куналар. Бераздан җиргә тагын мактанышып төшәләр, аннары тагын агачка җырлашып ябырылалар. Алар, шулай өерелеп очканда да, агач ботакларына һич тә бәрелмиләр, бер-берсенә ялгышып та комачауламыйлар.

...Ничек шулай булдыра алалар икән алар? Ничек осталыклары җитә икән аларның моңа?

Хәяли тәбәнәк читән буена баш-башларына юкарак ташлар кыстырып әйләндереп каплаган ярык тагарак өстендә утыра иде. Каршыдагы күршеләренең алмагачларына кунып-төшеп рәхәтләнүче чыпчыклардан көнләшеп тә куйды ул — аларга агачта да, җирдә дә тамак туйдырырга җим мулдан, аларның киемнәре җәйгә дә, кышка да ярый, дип уйлады.

...Әллә очышта чыпчыкларның бер-берсенә комачауламаулары сәбәбе бүтәндәме икән? Мөгаен, алар тамак туйдыруда бер-берсенә ярдәмләшәләрдер, югыйсә өергә җыелып сөенешмәсләр иде...

Хәялине уйларыннан ат аягы тавышлары бүлде. Җигүле ат. Тарантаска җигелгән бугай, кешесе күренми. Аты олы гәүдәле. Дугасы күккә тия, диләр, мондый җигүле атлар турында. Йөгәне һәм эшлеясе алтынсу төймәләр белән чуарланган күк атның адымнары эре. Безнең авыл аты түгел, дип тәгаенләде малай.

...Авылга кунаклар киләдер. Их, кешеләр кунакка да йөрешәләр. Әллә безгә турылыйлар инде? Без кунак чакырмадык ла, әй, кунак чакыру, ди, үзебезгә ашарга да...

Тарантас Хәяли турысына җиткәч, дилбегә тоткан агай атны дәшеп туктатты. Ул кара кыска мыеклы, башына тар читле тәбәнәк эшләпә кигән. Шәмәхә күлмәге, тышланган затлы тире камзулы агайны абруйлы, зыялы итеп күрсәтә. Тарантастан ашыкмыйча гына төште ул, дилбегәне янәшәсендә утырып килгән хатынга тоттырды, аңа акрын гына:

— Син кузгалмыйча тор,— диде дә Хәялигә таба атлады.

Малай тезләре өстендәге карындык тышлы «Әфтияк»не уң кулы белән алып күкрәгенә кысты, сул кулы белән артындагы читәнгә үрелеп тотынып, аягүрә басты.

— Әссәламегаләйкем!

— Вәгаләйкемәссәлам! — дип, агайның сәламен олыларча алды Хәяли.

Агай Хәялине башыннан аягынача сөзеп, гаҗәпләнеп карады. Аның каршында чыра юанлыгыдай алты яшьләр тирәсендәге малай тыйнаклыгын киңчә йөзендә сиземлерәк чагылдырырга тырышып басып тора иде. Шомаруга җиткән кара бәрхет түбәтәенең авырлыгын тырпайган колаклары гына күтәрәдер — түбәтәе үтә зур, димәк, үзенә атап тегелмәгән, этисенеке яки берәр бабайныкыдыр. Чәчләрен түбәтәе бөтенләй каплаган, чәчләре төсе, кашлары кебек булса, чем-карадыр. Җилкәләре салынкы ук түгел үзенең, ит кунса, киңәеп төзәерләр. Карындык тышлы китабын очлы күкрәгенә кыскан куллары тиредән дә сөяктән генә торадыр. Ә... Ә якты шар күзләре ябык йөзен мөлаемландыра, әй.

Булса да булыр икән тән ите кипкән бала, дип уйлады агай. «Синең өчен килдек микәнни?» — дип сорыйсы килде аның. Тик ул тәненнән җаны китәргә торган малайны күрүдән гаҗиз иде.

Агайның мондый халәтен малай сизде-аңышты. Ул, агайның әйтелмәгән соравына турыдан җавап кайтарырга теләп, үзен олыларча тотып:

— Менә шундый инде мин,— диде.— Сез мине алырга килгән булырсыз.— Малайның тавышында каушау юк иде, шулай да аның: — Алсагыз...— дип сузуында шөбһә беленеп алды.

Монысы инде агайга турыдан бирелгән сорау иде. Агай моңа капылт җавап кайтармады, тарантаста аптырап утыручы хатынын, ымлап, янына чакырды. Шуннан соң малайга:

— Күрешик әлгәре... кем, дим соң...— диде.— Минем исемем — Хуҗанур, ә хатыным Мөсәгыйдә була.

Малай да исемен әйтте.

— Хәяли... Хыялый бала күренәсең шул,— дип дәвам итте агай һәм: — Бу кадәресе әйбәт,— дип нәтиҗә чыгарды.

Хуҗанур белән Хәяли ике куллап күрештеләр, малай карындык тышлы юка китабын култыгына кыстырып торды. Мөсәгыйдә Хәялинең аркасына ике куллап кагылып алды, үзенә тартып сөясе килде бугай, әмма моңа җөрьәт итмәде.

— Утырып гәпләшик,— диде Хуҗанур.

— Өйгә узыгыз. Анда кеше юк үзе.

Агай урам як читәннән ун аршын чамасы эчкә кертеп салынган, инде бүрәнәләре карасуланган тәбәнәк өйгә текәлеп карады. Йортның түрдәге тәрәзә (икәү) йөзлекләре бизәксез такта (инде уңган), ә пыялалары чиста-ялтыравык иде. Салам түбә өстендәге бастырык-колгаларның башлары өстә тигез озынлыкта, тар өйалды түбәсе кыеклап-шатрунлап төшерелгән иде.

— Әниең өйдә түгелмени? — дип сүзгә кушылды Мөсәгыйдә, әмма аны ире ишарәләп туктатты.

— Өйдә кеше юк, дим ич.

Алар утырдылар. Хуҗанур бөтен гәүдәсе бизгәк тоткандагыдай калтыранган хатынына Хәялинең сул ягына утырырга ымлады, үзе уңнан урын алды. Малай аларның кайсына карарга белмәде, каушый төште, шулай да Мөсәгыйдәнең йомшак кулы аркасына тиеп алгач, тынычланды, шул мәл хатынның дерелдәвен дә бетерде. Малай белән хатынның бер-берсен баштан ук үз итешүләре билгесе идедер бу. Әмма соңгы сүзне әйтүнең Хуҗанурда икәнлеген алар икесе дә беләләр иде. Ә Хуҗанур әлегә эндәшмәде. Һәм алар шактый ук вакыт сөйләшмичә утырдылар. Ниһаять, агай:

— Әниең...— диде,— Дәрига исемле бит әле, әйеме.— Җавап та көтмәстән, сүзен дәвам да итте.— Әниең Дәрига тиз кайтырмы соң? Монда хәтле килгәч, аны күрмичә китү ярамас.

Агайның карарын төгәл белдермәве Мөсәгыйдә белән Хәялине сискәндерде, икеләнергә урын калдырды аның бу сүзләре. Шулай, алайса, фикерен тәгаенләмәгән икән әлегә Хуҗанур агай. Ләкин ат кузгалып, аны Хуҗанурның каты ук дәшеп туктатуы хатын белән малайның уйлары тирәнәюгә ирек бирмәде. Агай йөгән тезгенен, дуга бөҗрасыннан ашыкмыйча чыгарып, иннек капканың тәбәнәк баганасына чалды. Ул шушы эш белән мәшгуль арада, Мөсәгыйдә Хәялине аркасыннан тагын сөеп алды, малай аның җылы-йомшак тәненә елышарак төште. Хуҗанур, урынына килеп утыргач, тезләре башларын учлары белән ышкыды да малайга тагын карап торды, аннары, иеләрәк төшеп, карашын җиргә төбәде, тамагын кырды.

— Алай икән...— Хуҗанур тагын тамагын кырды.— Син, Хәяли, өнле бала икәнсең, «Әфтияк» укыйсың икән. Синең яшьтәгеләр хәреф тә танымый бит әле,— дип, әһәмиятле сүзне читләтеп башлады ул.— «Әфтияк» сүрәсен башламагансыңдыр әле?

— Башладым инде! — дип сөенде малай.— Иҗексез укыйм инде «Әфтияк»не! Мине Хәбия өйрәтте укырга. Ул үзе дә кечкенә әле, миннән бер генә яшькә зур. Аның әнисе — абыстай, Хәбияне әнисе өйрәтте. Менә генә аларның өе.— Хәяли бая гына чыпчыклар өере кунып уйнаган шау чәчәкле биек алмагачлар арасыннан горурланып күренүче йортка күрсәтте. Тик анда, әле җиргә атылып, әле алмагачларга ябырылып, чыпчыклар очмыйлар иде инде, каядыр киткәннәр икән. Хәяли моны күңеленә нигәдер салып куйды да: — Укыйммы соң? — диде.— Мин тәһарәтле үзем. Ә, ярар, алайса, өйгә кергәч укырмын, яме.

— Ярар, ярар,— дип куәтләде аның теләген Мөсәгыйдә.

— Тыңларбыз,— диде Хуҗанур, аңа катгыйлык хас, күрәсең, малай аның бу сүзен шулай бәяләде.— Хәзергә син үзең турында, үзегез турында сөйлә. Безгә белергә кирәк сезнең хәлләрне, белү хәер. Акылың җиткәнчә сөйлә. Дөресен. Турыдан әйтеп.

— Шулай ит, балам,— дип кушылды Мөсәгыйдә. Бу юлы аны ире ымлап та, әйтеп тә туктатмады.— Ялган-алдау катышмасын, берүк катыша гына күрмәсен. Башың әйбәт эшли икән синең, балакаем, Аллаһе Тәгаләнең кылганы булсын, шәт, ялгышмассың. Төгәле ничә яшь соң әле сиңа? — диде хатын, малайның күлмәгенә караганда таушалмаганрак камзулын тәненәрәк сыландырды.— Барысын да сөйлә, бәйнә-бәйнә сөйлә, без барысын да белергә тиешбез. Бик кечкенәдән акыл утырткансың, боларын, безнең теләкләрне, дим, үзең дә төшенәсең булыр. Үз балаларым юк шул, үземдәдер гаеп, үземдә инде... Ничә яшь икәненнән башла, яме.

Хәяли зур якты күзләрен кул аркасы белән угалады, иреннәрен тешләштергән итте, «Әфтияге»н камзулының эчке кесәсенә җайлап салды, тирән итеп сулады. Үзе-үзләре турындагы хикәятен башларга ашыкмады ул. Аны ир белән хатын ашыктырмадылар, түзем көттеләр.

— «Әфтияк»тән башка китапларны да укыдым инде мин,— дип башлаган иде малай, әмма Мөсәгыйдәнең соңгы киңәшен исенә төшереп: — Ә-ә, әйе, алты яшем тулып дүртенче айга китте, февраль башында туганмын мин,— дип, фикереннән бүленеп алды.— Азын аз әле мин укыган китаплар. Унсигез генә. Юкалар да алар,— дип, баштагы фикеренә кайтты аннары.— Латин хәрефләренә күчәселәр икән бит. Мин андый хәрефләрне танымыйм шул. Урыс хәрефләре бөтенләй дә бүтән икән. Хәбияләрдә андый китаплар да күп. Хәбиянең әтисе безнең хәзрәт бит, укымышлы да, әйбәт тә кеше ул. Мине ярата ул. Әти үлгәч, гел дә әти итеп саныйм инде мин аны. Безгә алар ярдәм итәләр. Ә алар үзләре дә ишле, уникe җан барысы. Әти үлгәч, җирләүне хәзрәт кайгыртты. Барлык чыгым алардан булды, ди әни.

Хәяли сөйләвеннән туктады. Аны ир белән хатын ашыктырмадылар.

— Әти үлгәч... Әтинең елы узган айда булды. Апрельдә. Табынны хәзрәт әзерләтте. Килгән кешеләр белән өебез тулды, ризык җитте, бүтән күрше-күлән дә булышты бит. Хәзрәт әти турында, гөнаһсыз бәндә иде, яшьтән сәламәтлеккә туймады, мәрхүмкәй, диде. Әтинең башына бәрде безнең, баш өянәкле иде ул, башы чатнап-чатнап авырта иде. Шуннан, әти үлгәч, дим, әнинең ялгызына өч бала калдык инде без, аяксыздан ... шул сүз инде, бу җайда әйтелә торган сүз...

Малай тагын бүленде. Мөсәгыйдә аның зур түбәтәен арткарак этәреп куйды. Хуҗанур башын читкә борды, күңеле кинәт йомшый торган гадәте бар, күрәсең.

— Әни бик бетеренде. Без булыша алмыйбыз бит әле аңарга. Тамагың туйганчы әллә нидә бер ашагач, бетеренәсең шул инде, бетеренмичә ди... Шуннан соң әни икебезне балалыкка бирмәкче булды инде. Апам белән мине. Апама сигез генә яшь минем. Энебез бөтенләй дә бәләкәй, дүрте генә тулды. Сез мине уллыкка алсагыз, хәзрәттән дә ризалык сорый күрегез.

Хәяли кипкән иреннәрен ялады, тагын сүзсез торды.

— Хәзер сөйләп бетерәм мин. Күп нәрсә калмады инде.— Малай тагын туктады. Мөсәгыйдә аны үзенәрәк тартты, алдына утыртып сөяргә теләде бугай. Хуҗанур аларга таба карамады.— Мине кызганудан гына уллыкка алмагыз. Кызганмагыз мине, мескен итмәгез. Әни апам белән мине асрамага бирәсен әйткәч, мин үземә-үзем шулай дидем.

Мөсәгыйдә бу сүзләрдән сискәнде, янгарак тайпылды, аның күзләре зур итеп ачылган иде. Шулай да ул каушавын-аптыравын сиздермәскә тырышты, яшелле-кызыллы бизәкләр төшерелгән саргылт яулыгын яңаклары тирәсендә төзәткәләде, җилкәсенә салган мамык шәлен күтәрәрәк итте дә җайлап куйды.

— Балам, юкны сөйләмә, яме! — дип кырыс кына әйтте Мөсәгыйдә.— Минем үз холкым да ирем холкына тартым. Туп-турыдан әйтеш бездә, хәйләсе дә юк, хәрәме дә юк, мәкере күптән юк.

— Мин дә шундый,— дип килеште Хәяли.

— Шулай булмыйча ди! Карале... ни... нигә өйгә кермибез соң без? — дип, урыныннан торырга җыенды Мөсәгыйдә.

Әмма малай:

— Мин сөйләп бетермәдем әле,— дигәч, кузгалмады.

— Сөйлә, сөйлә, балам, бушат күңелеңне, авыр хәлләреңне исеңә төшермәслек ит.

— Әни Дөррия апамны озата китте. Кечкенә энебезне дә үзе белән алды. Инде сәгать чамасы бар аларның китүенә. Тагын шул чамасыз кайтмаслар. Апамны асрамага алырга килә килеп белешкәннәр иде. Бүген булачак әнисе үзе генә кил-

гән. Аларның авылы бездән ун чакрымда ук булса да, безгә күрше авыл икән, Дөррия апамны...

Хәяли Дөррия апасын яңа әнисенең яңа киемнәргә киендереп алып китүен әйтмәкче иде дә, нигәдер тыелды. Ләкин моны Мөсәгыйдәнең күңеле сизенде бугай.

— Карале... ни...— һәм, ниһаять: — Әтисе, дим,— дип әйтеп салды ул,— нигә җебеп утырасың соң син?! Бар әле, атка су эчереп мен. Инешне уздык кына, кайда икәнен беләсең, ашарына сал аннары. Хәялиебезне тарантас башына утыртып, юк, минем алдыма утыртып алып кайтырлык булсын. Юк, элгәре өйгә кереп дога кылыйк. Җебеп утырмачы, дим, әтисе, сиңа әйтәм бит! Тарантас башы астындагы төенчекләрне алырсың. Берсендә — ризыклар. Икенчесендә — киемнәрең, балам...— Мөсәгыйдә арткарак тайпылып Хәялигә карап торды да: — Киемнәрең тап-таман булыр үзеңә, балакаем...— дип, урыныннан сикереп үк диярлек кузгалды.

...Нәкъ шул чакта ике күрше авылның басулары арасындагы юл читендә, тәгәрмәч эзләреннән кала бүтән төшләрен яшь чирәм каплап баручы юл читендә, кечкенә малаен һәм олы баласы Дөррияне кочаклап, Хәялинең әнисе Дәрига елап утыра иде. Ана, җепселләнгән яулыгы читләре белән күзләрен сөртә-сөртә, кызы Дөрриянең уң кулын аның яңа әнисенең уң кулына уң кулы белән тоттырды. Кызны яңа әнисе юлның теге ягына — үзләре авылы ягына алып чыкты. Дәрига Дөрриягә кулын сузды, Дөррия ике куллап Дәригага сузылды. Ләкин юл киң үк иде, сузылган куллар бер-берсенә җитмәделәр...

...Дөррия әйбәт холыклы, уңган булып үсте, үз әнисен дә, тәрбия кылган әти-әнисен дә үзенеке итте. Бу ике гаилә туганлашты. Еш йөрешәләр алар. Инде Дөррия кияүдә, үз балалары үсә. Дөррия тудырган әнисен дә, тәрбия кылган әнисен дә, каенанасын да үз итә, мин бәхетле — минем өч әнием бар, дип мактанып та куйгалый. Бирсен Ходай — бәхет юлдаш булсын барча-барсына.

Ә Хәялине уллыкка алучылар Хуҗанур белән Мөсәгыйдә иде. Егерме җиденче елның май уртасында авылга кунакка кайткан чаклары иде аларның, бу чакта кырык яшь иде аларга. Асрамага-уллыкка ир бала бирелүен ишеткәч, шактый ерак авылдан килгәннәр алар. Хәялинең исә (һәм яңа әти-әнисенең дә) шул китүдән соң авылына кайтканы булмаган. Алар, өчәү булгач, ерак-еракка — таулар иленә күчеп киткәннәр, Дәригага беркайчан да хәбәр салмаганнар. Сәбәбе нидә? Кем белсен инде... Бәлки, Хуҗанур белән Мөсәгыйдә Хәялигә ятимлеген оныттырырга тырышканнардыр... Һәм Хәяли яңа әти-әнисенең бу фикере белән килешкәндер — аның уй йөртү сәләте кечкенәдән үк акыл көченә буйсына иде ич. Шулай да Хәяли-

гә озак еллардан соң туган нигезен күрү, аның яңа эти-әнисенә шул нигезне кабат күрергә Хәяли белән бергә кайту кадәресе насыйп булган икән.

...Алар ике җиңел машина белән кайтып төштеләр. Алдагысын Хәяли, арттагысын аның олы улы йөртә. Алгы машинада Хуҗанур белән Мөсәгыйдә утырган, арттагысында Хәялинең хатыны белән балалары (өчәү!) иде. Өйдә Дәриганың кече улы, аның хатыны һәм балалары (шулай ук өчәү!) таралышмаган иртәнге як иде. Йорт алты почмаклы, тутыя калай белән ябылган. Хәялинең энесе үз машинасында апасы Дөррия гаиләсен алып килергә чыгып китте.

Дәрига башта малае Хәялине танымыйча торган иде, аннары елап та, күзләренең саран ачы яше аша көлеп тә җибәрә иде. Сүзен бер нәрсәдән башлый да аннары бөтенләй бүтән уңайга кереп китә.

— Улыкаем, нигә хәбәрләр бирмәдең соң?! Утыз биш ел узды лабаса... Улым, дим, Хәбия апаңнарны, Игелекле хәзрәт гаиләсен, дим, теге утыз җидедә сөрделәр бит. Син яраткан алмагачлар үсми инде алар бакчасында, анда килгән кешеләр хуҗа... Улым, кайларда булдың соң? Кайларда?

— Кайларда, дип... Менә эти-әни белән Каңгый иленә үк — әкиятләрдә сөйләнә торган ерак-ерактагы таулар иленә дә барып чыктык. Бүз бала Каңгый иленнән кыз ала, диләрме әле? Менә мин дә... килененңне шул илдә таптым...

— Рәхмәтләр генә яугыры бу киленемә дә, бу киленем дә әйбәттер... Улыкаем, пруфиссор ук булып җиттеңме? Рәхмәт инде сине кеше иткән... яңа эти-әниеңә... Зур кеше булгансың, улым, зур кеше. Монда калсаң, тирес арасыннан башың чыкмас иде...

Хәяли, җаен табып, урамга ялгызы гына чыкты. Биек капка төбендә теге замандагы, малайның хәтеренә сеңеп калган ярык тагарак юк иде, анда энесе артлы-терәлгечле эскәмия ясап куйган.

...Хәбия апалар бакчасында алмагачлар юк икән шул, дип уйлады Хәяли. Анда чыпчыклар өер булып, бер-берсенә комачауламыйча, ярдәмләшеп очалар иде. Кешеләр дә шулай оеша алалар икән ич, моны Хәялинең апасы Дөрриянең язмышы-тормышы ук раслый. Әйе, чыпчыклар, алмагач төбе әйләнәсендә сөенеп серләшкәч, тагын агач ябалдашына ябырылалар иде...

Хәяли бәрәңге бакчасына чыкты. Абзар артында ук теге чактагы иннек капка төбенә әйләндереп куелган ярык имән тагарак түгелме соң бу? Шул икән! Череп бетмәгән, әй...

Тиресне эскерттәй итеп өйгән энесе...

Хәялинең башына нәрсәдер белән, авыр-саллы әйбер белән кинәт тондырдылар кебек — «...тирес арасыннан башың чык-

мас иде...» Әнисенең әле күптән түгел генә әйткән сүзләре икән...

«Тиресләребез арасында яшәү Каңгый иле рәхәтлекләреннән шәбрәк, мең тапкыр шәбрәк!» — дип уйлады Хәяли.

Нәкъ шул мәлдә Хәялинең йөрәген куәтле кыскыч сытты...

Хәялинең җансыз гәүдәсе эскерттәй тирескә сыланды...

Җеназада иң бирешкән кеше Хуҗанур карт булды. Әллә бала акылы керде инде үзенә — карчыгы Мөсәгыйдәнең күкрәгенә чәчсезлектән ялтыраган башын салып ачыргаланды ул. Өзгәләнүенең чиге-чамасы юк иде.

— Улым, безне нигә ялгыз калдырасың... Хәялием, әнекәең белән мин бәхеттән мәхрүм бит инде... Ятим-ятимә бит инде без...

*1996–1998*

# Мәңгелек эзләр

Фарук Мангушев иртәнге сәфәрен гадәтенчә сәгать алтыда башлый. Бүген исә өч тулуга ук йокысы кинәт качты да урыныннан сикереп үк торды ул. Гәүдәсен җәһәт селкеткәләп тәнен язды, салкынчарак су агызып тиз-тиз коенды, күңеленнән дәртле-ярсулы җыр көйләп кырынды, йотлыгып чәй эчкәч, кызу-кызу, әмма гадәтенчә килешле киенде дә кабаланып өеннән чыгып та китте. Бәйләнчек йокысызлык чиренең арт санына кызулану-ашыгу гына шартлатып тибә ала, татлы йокыны адәмгә шул гына кайтара, ятакта аунау адәмне йокысызлыкның газаплау кочагына сала, дигән үз кагыйдәсе шулай ашкындырды бугай ялгызак Фарукны.

Гадәтенчә башта үз тирәләрендә күнегелгән сукмак-юллардан йөренде. Истә-оста юк уйларга бирелеп, шәһәр уртасында калып инде сүтелеп бетүгә якынлашкан бистәгә барып җитүен абайламыйча да калды ул. Гадәти юллардан тайпылуына аяк асты пычраклыгы игътибар иттерде аны.

— Аягүрә саташам бугай,— дип, үзалдына әйтеп куйды ялгызак Фарук.

Туктады, кулларын кискен итеп селтәде дә кире борылды. Әмма өйләре ягына юл алмады, яңа шәһәрчеккә таба китте, йөрешен капылт акрынайтты, киҗе-мамык фуфайкасының изүен ычкындырды — ашыгып йөрүдән тирләгән икән. Кесә сәгатен карады.

— Күрче,— дип, тагын үзалдына сөйләнеп алды ул,— өч сәгатькә якын йөрим икән ич. Вакыт узганы беленмәде дә, әй. Күңел бүген ниндидер үзгәреш көтә бугай, югыйсә болай ук ашкынмас иде. Хәерлегә булсын.

Ул яңа йортлар ишегалдындагы терәкле эскәмиягә барып утырды. Куртка кесәсеннән сабын чыгармыйча гына сигарет алды, ләкин аны кабызмады, янәшәсенә куйды, тәмәке тартуны сирәгәйтү, ташларга җыенуы исенә төште.

«Ял вакытында тартуны ташлыйм, дигән идем дә, барып чыкмый, ахрысы,— дип уйлады ул, сигаретын сындыргалап эскәмия башындагы чүп савытына ыргытты.— Бүген — ялымның соңгы көне, утызынчы апрель, бәйрәм узуга эшкә чыгасы. Соңлады быел яз, үтә дә кыстатты. Шәһәр ишегалларында шуңарчы кар бетмәсен инде, йә. Хәзер ашыга ашыгуын, ике көн рәттән кояшы үтә дә җете булды, әллә дөньяны көйдермәкче инде, әй. Бүген дә...»

Фарук уйларының очына җитә алмады, аның янына тулымса гәүдәле, зуррак башлы малай һәм җыйнак гәүдәле, житезҗәһәт хәрәкәтле, томры-кара озын куш толымлы кыз якыная иде. Малайга унике, кызга ун яшь тирәседер. Мәктәпкә барышлары инде, аркаларында — укучы сумкалары. Малай кызны җитәкләгән, аны ашыктыра.

— Соңлыйбыз ич, сеңлем, Фәрхунә, дим, боргаланма, алдыңа кара!

— Фәридун абый, мәктәпкә барасым килми минем! Әнине сагындым ла мин...

Кыз, Фарукның кымшангалап урыннан кузгалыр-кузгалмас утыруын күреп, сүзеннән бүленде. Билгесез көч аны таныш түгел абыйга этәрде. Һәм Фәрхунә Фарукка тартылды, тик адым атлауга ук, бу абыйның якты күзләренә томырылып карап, катып калды.

Билгесез көч Фарукның нечкә хисләргә бирелмәс кырыс холкын йомшартты, ул да урыныннан җәһәт торды (нинди хәл бу — бүген аның хәрәкәт-гамәлләренең күбесе нигә ашыгыч икән?), кызга тартылды, тик адым атлауга ук баскан төшендә катып калды.

Ир уртасы яшеннән чыгып баручы Фарукның һәм әле үсмер яшенә дә кермәгән Фәрхунәнең бик кыска вакытлы охшаш халәтләренә алар үзләре беркайчан да төгәл-тулы бәя бирә алмаячаклар. Шунысы бәхәссез — алар беренче очрашуның әлеге өлешен гомерләре буена онытмаячаклар, әмма аны тасвирларга аларның сүзләре беркайчан да табылмаячак. Тагын шунысы шөбһәсез — шул мизгелдәге хәрәкәтләре аларның бер-берсенә үз булуларын, бер-берсенә кадерле икәнлекләрен мәңгеләштерде. Чөнки аларның халәтләре рәвешия генә түгел, ә рухия дә иде, изгелеккә һәм игелеккә тулаем бизәлгән иде гадәти назга сусаган ике җанның бу халәтләре. Кабат килеп шунысы шиксез — Фарукның һәм Фәрхунәнең әлеге халәтләре бераз читтәрәк боларны күзәтеп торучы малайны да сөендерде, ул әлегә таныш түгел абыйга да, сеңлесенә дә

беркайчан да чит-ят булмаячагын белде, әлеге мизгелнең үзенә дә бәхет китерәсен аңлады. Бәхет дигәнең исә ялгызак Фарук белән Фәрхунәгә генә түгел, ә Фәридунга да тормыш асылы иде. Бәлки, бәхет дигәнеңнең кадерен, инде ни-бар яшәешенә күнеккән Фарукка һәм бала акылы чыкмаган Фәрхунәгә караганда, тормышы китеклеге кыенлыгын-газабын һаман саен ныграк төшенә баручы Фәридун тирәнтенрәк тә аңлыйдыр. Шәт, шулайдыр. Бәлки, нәкъ шуңа күрә танышуны да ул — Фәридун башлагандыр.

— Исәнмесез,— диде Фәридун һәм сеңлесен җитәкләде.

— Абый, абый! Исәнмесез! — дип очынып кабатлады Фәрхунә һәм әле Фарукка тартылды, әле абыйсына сыенды.

— Исәнмесез, балакайлар,— диде Фарук һәм аларның янына ук килде.

Балаларны башларыннан сөеп алды ул. Өлкәннәр һәм балалар арасында була торган шушы гадәти хәрәкәтләрнең тансык рәхәтен алар өчесе дә тиң тойдылар.

— Мәктәпкә барасыз бит. Әйдәгез, мин сезне озатам, яме.

Балалар карышмады. Фарук аларның арасына төште, Фәрхунә аның беләгеннән тотты, ә Фәридун адымнарын Фарук атлавына парлады.

Мәктәп ерак булмаса да, алар күп нәрсәләр турында сөйләшергә өлгерделәр.

— Мин инде өченчедә укыйм,— дип, Фарукның алдынарак төшеп, аңа үрелеп карады Фәрхунә.— Ә Фәридун абыем — бишенчедә.

— Бик әйбәт, балакайлар,— дип хуплады Фарук. Ул урта мәктәпне тәмамлаганнан соң өченче сыйныфта ике ай гына укытучы булып эшләп алган иде, балалар белән якыннан аралашу тәҗрибәсе шуның кадәр генә.— Бик әйбәт,— дип кабатлады ул, аңа балаларның олырак буласылары килә кебек тоелды да: — Тиздән бер сыйныфка югарырак күчәрсез.

— Юк шул менә, бер сыйныфка түгел! — дип, Фарукның күзләренә елмаеп, томырылып карады Фәрхунә.

— Ничек?!

— Фәридун абый да, мин дә ике сыйныфка югары күчәбез! — дип тагын очынды кыз.

Ә абыйсы сүзгә кушылмауны хубрак саный иде. Әллә соң ул, үзләренең ышанычлы кеше белән танышу сөенечен сеңлесенең күңеленә ныграк сеңдерүен теләп, сүзгә сирәк катнаша идеме? Әллә соң, төптәнрәк уйлаучы үсмер буларак, бүгенге очрашуның-танышуның өчесенең дә язмышларын ничек үзгәртәчәген күз алдына китерергә тырыша идеме? Белмәссең. Бәлки, бу фаразларның икесе дә хактыр. Белмәссең. Хәзергә белмәссең. Хисләрен тиз үк сиздермәүчән, үзләренә кагылышлы һәр вакыйгага төптән уйлагач кына бәя бирүчән булып үсүче Фәридун моны,

бәлки, кайчан да булса үзе әйтер. Чыгармасыз кагыйдә булмый дигәндәй, Фарук белән Фәрхунәнең танышуны башлаган мизгелдәге халәтләре генә Фәридунның кырыслануга йөз тоткан холкын йомшартып алды. Хәер, монысы бәхет килүенә сөенүдән иде. Бәхет дигәнең исә һәрнәрсәдән мең-мең кабат көчлерәк шул.

Ә Фәрхунә бәхет килү шатлыгыннан тәмамысы тәэсирләнгән иде.

— Фәридун абый да, мин дә гел бишлегә укыйбыз,— дип, баягы хәбәрен тагын да ачыклый төште кыз.— Шуңа күрә безне ике сыйныфка югары күчерәләр. Без барлык фәннәрдән дә имтиханнар тоттык инде.

— Сезнең әйбәтлегегез йөзләрегезгә үк язылган.

— Чынмы, абый? — Фәрхунә Фарукның беләген кысыбрак тотты.— Сез... дөресен әйттегезме?

— Дөп-дөресен! — Фарук, ике кулын балаларча кушырып селтәп, сүзләренең хаклыгын расларга тырышты.— Чып-чын менә! — дип, кызның соравындагы сүзләрне көчәйтеп кабатлап бетерде ул, монысы да балаларның бәхәсне тулыландырырга теләгәндәгечә самими иде, гөнаһсызлык билгесе иде.

Фәрхунә Фарукның мактавы ихластан икәнлеген күңеле белән тойса да, аңа «дөп-дөресен!» ишетүе тагын да рәхәт булды. Һәм фикерләүдә, гамәлләрдә (кайбер гамәлләрдә) җәһәтләнүче кыз инде бүтәнгә күчте.

— Абый...— диде дә бераз тын торды Фәрхунә.— Абый, мине ике сыйныфка алга күчермәүләре дә бар...— дип тирән итеп сулады.

— Нигә, балакай?

— Мин бүген... икеле алам...

— Ничек? — дип, хәлнең кинәт үзгәрүенә аптырады Фарук.

— Мин... укытучы кушкан бер биремне эшләмәдем.

— Ничек?! — Инде шул ук сорауны Фәридун бирде.— Дәресләреңне әзерләдең ич!

— Укытучы апа безгә болыт турында инша язарга кушкан иде, ә кичә күктә болыт күренмәде. Элек күргәннәремнең нindилеген онытканмын. Төн буе тәрәзәдән карап чыктым. Болыт әсәрен телескоптан карап та тапмас идең. Ай да йолдызлар гына. Болытлар бер урында мәңге тормыйлар шул... Әни дә кайтмады...

— Әнидән башка кунуыбыз беренчесе түгел! — диде Фәридун. Аның күзләре усалланган иде.— Әнине йә эшкә чакырып алганнардыр.

— Чакырганнар ди сиңа! Эшенә ашыгыч чакырсалар, язу язып калдырыр иде ул. Күршеләр әйтте, иртән сәгать унда ук чыгып киткән. Шуннан соң өйдә булмаган. Нигәдер ашыккан, чәй эчкәч, чокырын да юып куймаган. Эшкә ди сиңа! Әни эшеннән кичә иртән кайтты, бүген кичкә генә барасы әле ул.

— Күп беләсең! — дип тупасланарак төште Фәридун.— Башыңа гел кирәкмәсне тутырасың!

— Ә-э ди сиңа! Әти безне ташлады, инде әнидән дә калсак, нишлибез ди без икебез...

Их-х бу балаларның хәйләсезлеге-эчкерсезлеге! Кат-кат хикмәтләргә төреп яшерелергә тиешле сер-уйларын да яралар да салалар кайчак... Күрче, әй, Фәрхунә күңелен дә хафалы сагаюлар биләгән икән. Абыйсы Фәридун, сеңлемнең башында хәтәр уйлар болганмыйдыр, дип йөри иде әлегәчә, баксаң, хәвеф килере сеңлесен дә шүрләтә икән. Бәлки, катырак та куркытадыр әле.

Балаларның күңелсез хәбәрләре-шөбһәләре Фарукны тетрәндерде, әмма ул үзендәге үзгәрешне сиздермәде, сүзне бүтәнгә бору җаен тапты.

— Болытлар турында язарга идеме? — дип, күккә карады ул, калын-күперенке чәчләрен сыйдыра алмаган кепкасы артка шуышты да аны кулына алды.— Фәрхунә, Фәрхунә, әнә ич болытлар!

Кыз да, малай да Фарук күрсәткән якка карадылар.

— Болытлар...— диде дә тукталып торды Фәрхунә.— Яшь болытлар кояш кырыенда тирбәләләр. Алар кояш турысына кермиләр. Кояшны капларга теләмиләр, бу бәхетле болытлар кояшның мәңгелегенә сокланалар икән...

— Менә иншаңны яздың ич! — дип, балаларча куанды Фарук.— Бик матур итеп тасвирладың бит болытларны! Укытучың бишлене һич тә кызганмыйча куячак сиңа.

— Кыска бит ул, өч кенә җөмлә...

— Булса соң!

— Мин иншаны дәрес башланганчы язып та бетерәм әле. Абый, дим, абый,— дип, Фарукның беләгенә асылынды Фәрхунә,— мин иншадан ничәле алганны белергә килегез, яме. Дәресләр беренче яртыда бетә. Абый,— дип барышлый сикеренгәләп-биеп алды Фәрхунә,— безнең өй янына, без очрашкан төшкә килегез. Юк, анда түгел, мәктәп янында Фәридун абыйны бергәләп көтәрбез, аның дәресләре алтау. Юк, анда да түгел, әнә тегендә, без үзебезнең болытларны күргән төшкә! Яме, абый!

Фарук, һич карусыз ризалашып, башын какты. Аның йөзе балкый иде.

Мәктәп янына җитәрәк, Фәридун яңа танышкан абыйсы да, сеңлесе дә моңарчы игътибар итмәгән нәрсәне әкертен генә искәртте.

— Безнең өчебезнең дә исеме бер үк хәрефтән башлана икән...

— Өчебезнең генә түгел шул менә! — дип тагын очынды Фәрхунә.— Фәридун абый, син нигә әнине дә кушмыйсың? Әни

кайтмыйча калгангамы? Әнинең дә исеме «ф» хәрефенә башлана,— дип, Фарукка атап әйтте кыз.— Фәүрия исемле ул. Әни...

Ялгышты кыз. Болай кистереп раслау дөрес түгел түгелен. Чынында Фәрхунә үз гаиләсенә катнашы булган, төгәле гаиләне таркатучыларның берсенең исеме шулай ук шундый хәрефтән башлануын белми иде. Һәм белмичә дә калачак. Хәер, белүе кирәкмидер дә, югыйсә андый кешене якыннанрак белү нечкә хисле кыз баланың күңелендәге җәрәхәтне һәрдаим тырнар иде...

Мәктәп ишеге төбенә җиткәч, Фәридун һәм Фәрхунә борылып карадылар. Тимер челтәр койма аратасына таянып торучы Фарук аларга кул болгады, балалар да шулай ук саубуллаштылар. Кыз, эчкә кергәч тә, ишек янәшәсендәге тәрәзә турысына килеп, тагын кул болгады, Фарук моны күрде, кулын кулга кысып баш өстенә күтәрде.

Алар тыкрыктан чыгып олы юлга борылганчы ук, мәктәп ихатасының аргы почмагына кара «джип» килеп туктаган иде. Аның рулен калын-кара мыеклы, уйнак күзле ир тоткан, ә артта, машина хуҗасына кыйгачлап, түгәрәк үк йөзле — йончый төшкән йөзле, иңбашына тияр-тимәс чем-кара чәчле — каты кыл кебек шома чәчле хатын, посыбрак — сәбәбе бар — утыра иде. «Джип» иясе Фәннан Барышев — менә ул, Фәрхунә белмичә калачак кеше, ә арттагы хатын Фәридунның һәм Фәрхунәнең әнисе Фәүрия Юматашева иде. Алар тирә-юньне җентекләп күзәтә алалар, үзләрен тыштан күреп булмый, чөнки машинаның тәрәзә пыялалары караλтылган иде. Балалар янындагы чит-ят кешене Фәннан Барышев күзләрен ачулы текәп күзәтте, Фарук китеп баргач кына эчкәредәге Фәүриягә таба борылып, утлы күзләрен аңа терәде, тырпайган калын мыегын баш бармагы тырнагы белән шомартты. Аның карашын рәхимсезлек биләгән иде, шул мәрхәмәтсез карашы Фәүрияне кечерәйтә, почмакка сеңдерә бара. Һәм балалары янәшәсендә Фарукны күрүдән Фәүриянең күңелендә шыпырт кына кузгалган бәхете-өмете бөркелеп колачланудан-зураюдан тыелырга мәҗбүр ителде, шулай да бәхеткә ымсыну уалмыйча кала алды.

— Кем ул?

Фәннан Барышевның төрпә-тупас соравында Фарук белән Фәүрияне мәсхәрәләү дә, аларның бер-берсен белешүеннән хурсыну-гарьләнү дә бар иде.

— Белмим...— дип, гәүдәсен турайта башлаган иде дә Фәүрия, ләкин Барышев аны, сугарга җыенгандай, кулын күтәреп бүлдерде.

— Белми, ә! Алдашма! Синең балаларыңа ят кеше үз аталарыдай булган ди! Иреңме! Ирең! Ә син ирем юк, аерылдык, дип алдыйсың! Хәер, ирең түгел! Төнеңне минем белән уздырдыңмы?! Уздырдың! Ире өйдә чакта бер генә хатын да моңа бармый!

Барышев ашыкмыйча, әмма фикерен кире какмаслык итеп сөйләүгә күчте, көч җыйгандай тукталгалап торды. Фәүрия ел чамасы элек якынайган кешесеннән мондый тупаслык һәм кимсетелү көтмәгән иде. Боларны сөяркәңнән ишетү, гәрчә ул үз тәртибен акламаса да — мондый тормыш тәртибе ирсез хатынга ярыйдыр, дип тынычландыра иде ул үзен — һәм кылганын заманның зур гөнаһысы санамаса да, аны хәтта истәнһуштан тайдырды. Фәүрия Фәннан Барышевның мыскыллы битәрен ишетә дә кебек, тик моны уйлау чираклыгы җитми иде, югыйсә ул әңгәмәдәшенең сүзен әйтелеп бетмәстән үк тотып алучан һәм аны шул мәлдә үк бүлдереп кире кагу җәһәтлегенә ия хатын иде.

Барышев машинасын кабызды, моторны бөтен куәтенә үкертте дә сүндерде. Шуннан соң гына каударланып шелтәләвен дәвам итте.

— Әллә син миннән файда эзләп йөрисеңме?! Ха-а! — Барышев артка табарак борылып утырды, сул кулы терсәген руль уртасындагы арага тыкты, кырын яткан халәткә керде, уң кулын йодрыклады, шыксыз йодрыгын сүзләренә басым ясаган җайга селтәде.— Син миннән фатир алырга ниятләдеңме? Бүгенге төндә фатирың турында әйтеп куюың шуның өченме? Мине шуның өчен эзләп таптыңмы?!

— Тукта... Туктагыз берүк...

— Сиңа сүз бирелмәгән! Үзең тукта! Тыңла! Тыныңны чыгармыйча! Югыйсә...— Нәкъ шушы кисәтү яңгырау алдыннан Фәннан Барышевның теләсә нинди әшәкелеккә барырга сәләтле икәнлегенә инанды Фәүрия, бу бәндәнең һәр теләген үтәвенә башкалар карышмаска, ә аңа буйсынырга тиешләр икән.— ...утырган урыныңда ук тончыгырсың! Белеп кал — мин әтрәк-әләм түгел! Абруемны һәммә кеше белә! Сиңа зур фатир бирергә ярты ымым җитә. Ләкин мин моны эшләмәячәкмен! Ишеттеңме?! Өстерәлчек! Мине җумалап, миңа сыланып, фатирлы булмакчы идең, ә?! Мине мескен җанга чыгармакчы идең, ә?! Тоттырдым ди фатир урынына... Байлыгыма кызыктыңмы? Миңа кияүгә чыгарга ниятләдеңме?

— Мин сине... сезне яраттым...

— Яраткан икән! Уйнашчы яратудан мәхрүм! Бигрәк тә эче-тышы мәкердән торган уйнашчы! Миңа хатын булмакчы идеңме?! Бел — безнең дәрәҗәдәге җитәкчеләр хатын аермыйлар. Безнең белән төн үткәрергә теләүчеләр Иделне буарлык! Төн буена йомшак түшәктә тәгәрәшүнең рәхәтен, сауна ләззәтен кадерли беләләр андыйлар! Син түгел!

— Чыгарыгыз... Чыгар мине...

— Ансат котылмакчысың, ә?! Юк инде, балаларыңны озаткан кешенең кем икәнлеген белергә тиеш мин! Кем ул?!

— Белмим...

— Белмисең, димәк. Әйдә, өеңә керәбез! Соңгы тапкыр рәхәттә йөздерим үзеңне! Миннән булсын яхшылык!..

Мондый хурлыклы әмергә буйсынырга мәҗбүр иде Фәүрия. Шул ук вакытта ул үзендә горурлык дигән сыйфатның җитмәвен (бәлки, булмавын?) аңлады, ир затының моңарчы үзенә ябышкактай кадалырга маташуларына, кысрыклап-кысып бәйләнеп йөдәтүләренә каршы тора алуын тискәреләнеп кылану гына икәнлеген төшенә башларга тиеш булды. Аннары, Барышев машинасын кузгатуга ук, егерме адымнар чамасы артта торган ак «Волга»ның койрыктай иярәчәген белә иде. Тышкы кыяфәте таушала төшкән, әмма моторы сәгатьтәй эшләүче, куалашуда «джип»ка тиңләшердәй бу машинада түрә Фәннан Барышевның һәрнәрсәгә әзер тән сакчылары утыра иде. Шул ике әзмәвер түрәнең һәр яман әмерен тавыш-тынсыз үтәячәкләрен дә хәзер генә аңлады Фәүрия. Аларның һәркайсы аны Барышев катына ничә тапкырлар алып килделәр дә ничәмәничә мәртәбә озатып куйдылар ич әнә шул «Волга»да, эче ялт итеп җиһазланган «Волга»да. Сүзгә саран бу... бу робот сыман бәндәләр түрәнең үзеннән уздырырга да күп сорамаслардыр, үзләрен иркен-бәйсез тотар чакларда да аларның күзләрендә иман заты күргәне булмады Фәүриянең.

Барышев кәрәзле телефоныннан тән сакчыларына:

— Тагын бер урында тукталып алабыз,— дип әмер бирде.— Берегез, мин чыкканчы, монда күчеп утырып торыр. Мине эзләсәләр, икешәр тапкыр алмаш-тилмәш кычкыртырсыз. Ашыгыч эзләсәләр генә. Мин телефонны алмыйм. Кырык минуттан артык тормам.

Фәннан Барышев машинасын Фәүрияләр йорты башына китереп туктатканда, каршыдагы сквер буеннан такси кузгалып китте. Аның хуҗасы, капотны ачып, мотор тирәсендә ярты сәгатьләп актарынган булып маташкан иде, әмма болай эшләве үзенчә хәйлә иде, чынында ул Фәүриянең балконда яки тәрәзәдә күренүен көтте. Хатын алдан килешенгән шартлы билге ясауга, аның янына атылачак иде ул. Тик Фәүрия хәбәр салмады. «Бер-бер хәл булмагандыр ла инде,— дип уйлады такси хуҗасы.— Өйдә көтәргә тиеш иде лә. Килешенгән идек лә. Зыян юк, кабат әйләнермен, балалары кайтканчы, вакыт җитәрлек әле».

Янга сөялеп, инде башын нык ук тотып, алга карап утырса да, Фәүрия таныш таксины күрмәде, аның күз алдын куе томан каплаган иде. Ә Барышев Фәүрия белән мөнәсәбәттә үзен алыштыргалаучы бу кешене белми иде.

— Нәрсә терәлеп каттың?! — дип, Фәүриянең күз алдындагы томан пәрдәсен тартып төшерде Барышев.— Чык машинадан! Бергә керәбез.

Фәүрия карышырга уйламады, карышу көчендә түгел иде

ул, бәлки, яратам, дип йөргән кешесе белән соңгы тапкыр, ә үз өендә беренче мәртәбә бергә булу теләге карышу ихтыярын җиңгәндер — ничек булса да, үз көчен чамалап бетермәгәндер.

Фәннан Барышев сакчылары янына әйткән вакытында чыкты. Фәүрияне теләгәнчә изгәч (бер мәлдә, хатын ыңгыраша башлагач, аның маңгаена учы белән каты ук шапылдатты да хәтта), җиңелчә юынды, аннары:

— Күземә чалынма бүтән! — дип, диванда шәп-шәрә яткан хатын янына килде. Әмма хатын аңа игътибар итми, аның күзләре йомык, аның үз уе иде.— Аңыштыңмы?!

— Мин сине... сезне чынлап ярата идем бит... Элегрәк... Мин урамда да сезнең астыгызга ятарга әзер идем... Сез боздыгыз минем гаиләмне...

— Сайра әйдә, сайра!

— Иремә башлап сезнең белән кунып хыянәт иттем. Ул шуны сизенде дә аерылды. Балалар хакына ташламас, дип уйлаган идем...

— Син сөйрәлчек белән нинди ир яшәсен ди! Синең белән яшәргә ярамый гына түгел, синең белән яшәү мөмкин түгел!

— Балага уздым мин...

— Миннән түгел! Миңа тага алмыйсың! Минем синең белән булгалаганны машинадагы ике кешедән бүтән берәү дә белми! Ә алардан сүз чыкмый. Үз этисенә так балаңны!

— Борчылмагыз... төшертермен...

— Үз эшең!

— Әйтегез соңгы сүзегезне...

— Минем хакта беркайчан да беркемгә дә сыңар сүз дә әйтәсе булма! Яшисең килсә...

Барышев, коридорда аяк тавышлары ишетелмәвенә ышангач кына, ишекне акрын ачып, акрын ябып чыгып китте.

Фәүрия Юматашева ишек бикләргә дә тормады. Бераздан соң, кырын ятып, астындагы җәймәне тарткалый-йолыккалый — гәүдәсен күтәрергә хәле юк идедер — өстенә япты. Сәгать чамасы селкенмичә яткач, үзен бераз җиңеләйгәндәй сизде. Һәм, җәймәне идәнгә селтәп атып, кызуланыбрак торды, мендәр тышын, салдырып, җәймә белән бергә ваннага кертеп ташлады. Юынгандай иткәч, караңгы бүлмәдән чуар бизәкле халатын алып киде. Саф һава суламакчы булып, балкон ишеген ачты һәм сквер янындагы таксины, һәм машина янында йөренүче аның хуҗасын күрде. Кашларын җыерып, күзләрен кыса төште — юантык, тәбәнәк буйлы бу яшь егет белән өендә очрашырга сүз куешуын хәтерләде. Һәм аны чакырып билге ясавын абайламыйча да калды. Егет, шуны күрүгә, йорт ишегенә таба йөгереп диярлек китте, балконга кабат карамады, шуңа күрә аңа кермәскә кушарга соң иде инде. Шулай да Фәүрия

аңа ишек ачмаска ниятләде. Ләкин туймас күзле кыбырсык егеткә ишек ачык иде, Фәүрия аны Барышев киткәч бикләргә онытты, ә егеткәй ишекнең ачыклыгын хатынның килешенгәнчә каршылавы итеп аңлады.

— Бер-бер нәрсә булды мәллә? — дип, керә-керешкә чишенеп тә ташлады хатын-кызга сусау егет.

— Кәефем юк иде, ятып торган идем, йоклап киткәнмен,— дип алдады хатын.— Бүген якынаймыйк, ә... Үтенәм...

— Шулай иткән ди! Икенче килүем инде минем! Син бүтән көннәрдә мең сәбәп табачаксың очрашмаска! Мең дә берне булмаса әле...

Һәм сусау егет юантык куллары белән Фәүрияне чытырдатып кысып күтәреп тә алды, җиһазлар күплектән кысанланган бер бүлмәле фатирның бушрак-иркенрәк урынын сайлап, идәнгә сузып та салды. Хатынның өстендә халат кына булуын үзен Фәүриянең бик тә көтеп каршылавы итеп бәяләде ул...

Фәридун белән Фәрхунәне кыз болытларны сыйфатлаган төстә каршылады Фарук, иртән болытларга күтәрелеп караган урынны төгәл табарга тырышты хәтта. Балалар акылына хас мондый гамәле башта үзенә үк көлке тоелган иде, тик бу уйны ул башыннан тиз куды, чөнки кызның таләбен-тәкъдимен үтәү аңа рәхәт иде. Әнә Фәрхунә үзе дә килә! Фарукны күрүгә үк, Фәридунны калдырып йөгерә дә башлады. Аркасына аскан сумкасы бер күтәрелә дә тагын төшә, шуның астында калган калын ук чәч толымнары кысылудан котылып уйнакларга җыеналар иде кебек. Кыз уң кулын бармакларын җәеп югары күтәргән иде, гәрчә кулы буш булса да, андагы кыйммәтле әйбернең йөгергәндә төшеп уалуыннан курка, шуңа күрә кулын төптөз тотып йөгерә, җәелгән биш бармагын — иншадан бишле ич! — Фарукның ерактан ук күрүен тели иде.

Йөгереп килгән уңайга Фәрхунәне күтәреп алды Фарук һәм беләгенә утыртты. Сулышы җиңеләя төшкәч кенә кыз:

— Абый! Абый! Иншадан — бишле! — диде.

— Менә шәп булган! Әйттем бит мин сиңа, бишле аласың, дидем!

— Укытучы апа иншаны иң элек миннән укытты. Бишлене зур-р итеп куйды.

Кыз Фарук беләгендә утырган килеш кенә сумкасын алгы якка бормакчы, дәфтәрен чыгармакчы иде, әмма болай эшләп булмый икән. (Әллә бишле авырлыгы-зурлыгы комачаулады тагын!)

— Ышанам, ышанам ич мин сиңа, балакай! — диде Фарук һәм кызның йомшак битенә күперенке чәчләрен тидерде.

— Абый, дим! Абый! Сез очрамасагыз, мин иншаны язмас та идем, име?

Фарук, кызга ничек җавап кайтарырга белмичә, беравык сүзсез торды.

— Син кояшлы болытларны үзең таптың бит. Мин югында да күрер идең син аларны. Шулай да мине инша язышуга кушуыңа рәхмәт, яме.

— Ярар,— дип, Фарукның чәчләрен кагылыр-кагылмас кына итеп сыпырды Фәрхунә.— Безнең этинең дә чәчләре шушылай күпереп тора. Мин этинең чәчләрен тарарга яратам. Хәзер дә яратам да, тик әни этине безнең янга китертми бит... Төшерегез инде мине, этием беләгендә утырган кебек булды миңа...

Фәрхунәнең соңгы сүзләрен алар янына килеп җиткән абыйсы Фәридун ишетеп торды, әмма моңа мөнәсәбәтен белдермәде, эндәшмәде, Фарук белән олыларча баш кагып кына исәнләште.

— Абый! Абый, дим! Иртәгә мәктәпкә барышлый без тагын очрашырбызмы?

— Мин килермен, балакай!

— Абый! Ә... сезнең үз балаларыгыз... бармы? Аларны мәктәпкә кем озатыр?..

— Мин ялгызым, балакай...— дип тирән сулады Фарук.— Минем гаиләм юк. Әлегә...

— Абый! Абый, дим! Мин ялгыштым бит, иртәгә бәйрәм ич, без укырга дүртесендә генә барабыз. Шул көнне килерсезме?

— Ярар.

— Ә иртәгә килмисез инде, име. Без Фәридун абый белән сезнең янга чыгар идек. Аннары әнине каршыларбыз.

— Килермен!

— Абый! Мин әнине бик-бик сагындым. Кайткандыр инде ул. Безне көтәдер. Күрерсез әле менә безнең әнине. Әйбәт ул — безнең әни... Тик бүген кич эшенә барасы аңа, мин аның белән тагын озаклап булалмыйм инде...

Ләкин Фәүрия балаларын каршылый да, эшенә дә бара алмый иде шул бүген. Аның, такси йөртүче китеп баргач, бүген пычранган әйберләрне ашык-пошык уып киптерергә элгәндә, күз аллары кинәттән караңгыланып китте дә балконнан (алтынчы каттан!) егылып төшә язды ул, сыгылып таянсага ауган гәүдәсен көчкә тотып калды. Үрмәләп өйгә кереп, Фәрхунә ясап калдырган чәйне йотымлагач кына бераз хәл керде. Ярый әле каршыдагы күршеләренең телефоны бар, алардан шылтыратып, «ашыгыч ярдәм» чакырды. Ярый әле тиз килеп җиттеләр. Фәүрияне машинага ике яктан култыклап чыгарып яткырдылар. Әмма сырхауханәгә барып җиткәнче, хатын канга баткан иде инде. Төнге һәм иртәнге яктагы күп кабатланган шөгыльләргә сауна да, еш кына хәмер йоткалаулар да булышкандыр...

Авыруы сәбәбе турында балаларына, алар сырхауханәгә эз-

ләп килгәч, төнлә囀 эштә булдым, кичке уңайда гына үзем шылтыраткач, «ашыгыч ярдәм» чакырдылар, сезгә язу калдырырга өлгермәдем, дип ялганлады ул. Телефоннан шылтыратуы хак аның. Тик ул кичә кичке уңайда Фәннан Барышевка хәл белешеп кенә шылтыраткан, аның белән очрашырга ниятләмәгән иде. Кем белән төн үткәрү турында күптән сайланып утыручы Барышев бер сөяркәсенең хәбәр салуына сөенде, чөнки кайсысын сайлап алу турында баш ватарга кирәкми иде. Әйе, хатыны әниләрендә куна каласын белгәч, аның төне буш иде. Хәер, хатыны аны-моны сизенсә, югарыдагы түрәләр белән бергә идем, дигән еш кабатлана торган җавабы әзер иде аның. Ә хатыны моңа ышанырга (гәрчә ышанмаса да!) тиеш иде.

Иртәгесен Фарук килешенгән вакыттан шактый алда килде, шулай да малай белән кыз аны көтеп утыралар иде инде, хәтта озак ук көтәләр бугай. Балаларның сөмсерләре коелуын агай Фәрхунәнең каршысына йөгермәвеннән үк тойды. Хәлне Фәридун аңлатып бирде, Фәрхунә кыяр-кыймас кына Фарукка сыенып тыңлады. Абыйсы сөйләүдән туктагач кына, ул әйткән хәбәрләрнең кайберсен тәгаенлисе итте.

— Әнинең, ике төн аяк өсте эшләгәч,— диде ул, йокымсырау күзләре өйләре балконына текәлгән иде, әнисен күрү өметедер, күрәсең,— башы бик авырткан, эче бик көйсезләнгән. Кичә кич кенә, сәгать җидедә генә, аңына китерделәр әнине. Безне кертмәделәр. Бүген дә урыныннан торырга ярамыйдыр әле әнигә. Ә без әни янына барыбер барабыз... Әнигә күчтәнәчләрне кичтән үк әзерләдек. Әтигә хәбәр иткән идек, аягымны да атламыйм, диде. Эченнән генә сүгенеп тә куйды бугай, ә безнең әти сүгенә белми иде. Яңа хатыны әнинең хәлен белергә кушса да, аны да тыңламады. И-и, абый, абый, безнең әти бөтенләйгә киткән икән бит... Ә мин аны, Фәридун абый да инде, барыбер онытмаячакбыз... Ә-ә, абый, дим, әни янына безнең белән сез дә барсагыз икән...

«Их-х, бала акылы! Эчкерсезлеген-гөнаһсызлыгын үзе аңлыймы икән соң балакай...» — дип уйлады Фарук. Тик Фәрхунәгә җавабын бу мәгънәдә бирмәде, гаилә корып яшәмәсә дә, тормыш мәхшәрләрен шактый ук кичергәндер, ахрысы, ул.

— Әниегезгә бергәләп тагын күчтәнәчләр алыйк әле,— дип читләтебрәк башлады Фарук.

— Кирәкми, абый! — дип, Фарукның күзләренә бүген беренче тапкыр карады кыз.— Без икебезгә ике сумка тутырдык менә.

— Минем әйткәнне тыңлыйк әле,— диде Фарук, аның сүзләрендә үтенеч тә сизелде, шул ук вакытта Фәүриягә беренче очрашуда (ә алар, һичшиксез, очрашачаклар) әйтергә җыенган шиге-шөбһәсе (моны ул беренче күрүдә үк әйтә дә алмаячак,

моны Фәүриянең үзен тотышы оныттырып торачак) сүзләренә үтенү төсмере дә бирдедер.— Бүгенгә минем сүздән чыкмыйк...

Алар сырхауханәгә өчәүләп бардылар. Ләкин агай сырхауханә янына җитәрәк, балаларның үзләрен генә җибәрде, ә балаларны әниләре янына бүген дә кертмәделәр. Шәфкать туташыннан Фәүриянең хәле әйбәтләнә төшүе турында ишетү балаларга әйтеп бетергесез шатлык иде, алар, моңа бик тә канәгать булып, әниләрен күрергә ялынып сорамадылар.

Кайтышлый Фәрхунә:

— Менә күрерсез әле, күрерсез, әни тиз кайтачак,— дип еш кабатлады.— Әни яшь әле безнең, тиз савыгачак ул. Күрерсез менә, мин әйтте диярсез...

Фарук, иртән очрашуга килгәндә, балаларны кая да булса күңел ачарга алып бару исәбендә иде — бәйрәм көн ләбаса! Әмма күңелсез хәл мондый теләккә аркылы киртә салды. Шулай да аның балалардан аерыласы килмәде, ә аларның өйләренә кереп көн үткәрү ким дигәндә әрсезлек булыр (ул исә, гадәттә, фикерен ярып салса да, тәкәллефсез түгел), чамадан чыгу исәпләнер иде, шуңа күрә бүтән сәбәп тапты. Троллейбус нәшрият тукталышына җитәрәк:

— Әйдәгез, Казансу буенда ял итеп алыйк! — диде Фарук.

Балалар бер-берсенә караштылар, әмма сүз алышмадылар, ризалыклары йөзләренә чыккан иде.

Яр буйлап барганда, ара-тирә тукталып, су өстенә сүзсез генә карап тордылар. Һәркайсының үз уе идеме, әллә өчесенең дә уе бер тирәдә (бер-берләрен табу сөенече һәм киләчәктә бер-берләрен югалтмау) кайнаштымы — бу кадәресе билгесез, чөнки яралып кына килгән бәхет турында башкаларга ашыгып сөйләргә ярамыйдыр да, моның хакында уйлану гына хәер. Әгәр соңгы фараз дөрес икән, моңа су өстенең тып-тынлыгы вә типтигезлеге дә тип-тигез тәэсир иткәндер.

— Фәридун абый,— дип кинәт сүз башлады Фәрхунә, аннары Фарукка да атап эндәште,— абый, сез дә карагыз әле, әнә, әнә су өстенә җил сиптеләр! Әнә, әнә җилне Кремльгә таба тар буй итеп сибеп баралар... Кемнәр сибә икән аны?

— Кемнәрме, әллә кемме? — дип, сүзнең кай таба борыласын абайламыйча сорады Фарук.

— Кем!

— Алайса, безгә гүзәллек күрсәтергә теләүче!

— Алайса, безнең матурлык күрүебезне әнием теләгән дә әниемнең теләге үтәлә! Су өстенә чәчелүче вак-вак җилнең чиге дә юк бугай...

— Матурлыкның, гомумән, табигатьтә һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәттә бик күп яхшы нәрсәләрнең чиге-чите юктыр, минемчә,— дип фәлсәфәгә бирелде Фарук, фикерләрен балаларның аңлавына-аңламавына игътибар итмәде.— Ә галәмдә

ике нәрсә генә чиксез — киңлек тә вакыт. Күккә карасаң, йолдызлар артында йолдызлар булуына, алары артында бүтәннәре җемелдәвенә — гел шулай, арыдан ары — ышанырга тиешсең. Вакыт турында уйлап, борын-борынгы заманнарга кайтырга, киләчәкнең дә киләчәгенә барып җитәргә тиешсең. Моны аңлатуы кыен, моны үзең аңларга кирәк.

Балалар аңларга тырышып тыңладылар, ләкин Фарукның нигә бу хакта сөйләве мәгънәсенә төшенмәделәр. Фәридун сүзсез тыңлады, киләчәгенең нигездә үз акылына, үз гамәлләренә бәйле икәнлеген ул инде беләә, киләчәктә тугры юлдан тайпылмаячагына ышана башлаган иде. Ә сеңлесенә акыл утыртуда булыша алуына шикләнәрәк иде, шуңа күрә Фарукның әлеге сүзләрен Фәрхунәнең ишетә торуын вакытлы санады, сеңлесенә (һәм үзенә дә) Фарук биргән сабакны Фәрхунәнең күңеленә урнаштыруын тели иде ул. Һәм Фәридун сеңлесенең:

— Әйе шул менә, матурлыкның чиге юк шул менә! — дип очынуына сөенде.— Абый, дим, абый,— дип, Фарукның беләгенә кагылды кыз һәм, су читендә үзләренең өч пар эзен күреп, тукталып торгач, фикерен бүтәнгә борды.— Абый, дим, Фәридун абый, син дә, күрегезче, кояш безнең эзләрне мәңгеләштергән! Аларны дулкыннар гел юып-матурлап кына торыр әле...

— Табигать баласысың син, кызыкай! — Фарукның Фәрхунәне иркәлисе килде, әмма балалар үстереп карамаган агай моның җаен җәһәт кенә таба алмады.— Табигать баласысың син,— дип, акрынрак кабатлады Фарук.— Табигатьнең үзенә охшагансың...

— Юк шул менә! — дип, Фарукка беренче тапкыр каршы төште Фәрхунә, тик зиһенләүдә өлгер кызның инде шаяртуга күчүе анык сизелде.— Мин этигә дә, әнигә дә охшаган! Мин — этинең дә, әнинең дә кызы! — Шуннан соң гына ул матурлык турында баярак әйтергә теләгән фикерен тәмамлады.— Безнең эти дә, әни дә бик матур! Менә күрерсез әле безнең әнинең чибәрлеген! Шаклар катырсыз! Абый, дим, әни белән сезне үзем очраштырам әле мин, яме! Фәридун абый белән икебез очраштырабыз.

...Ләкин Фарук Мангушев белән Фәүрия Юматашева балалар ярдәменнән башка гына очраштылар...

Хатынның сырхавы шактый ук катлауланып алды, аны шифаханәдә өч атнага якын дәваладылар. Аның хәлен белергә малае белән кызы көн саен барып йөрделәр, кайчак Фарук та аларга иярде, тик ул Фәүриягә күренмәде.

Фәрхунә:

— Әни савыгып тагын, тагын да чибәрләнгәч очраштырам мин сезне! — дип нәтиҗә чыгаргач та әле танышу кичектерелеп торды.

Фәүрия шифаханәдән өенә кайтасы көнне Фарук Мангушев иртәдән үк айлык сәфәргә китәргә тиеш булды, шуңа күрә ул балалар белән кичтән саубуллашты. Алар беренче очрашудагы урында, терәксез эскәмиядә утырганда, Фәрхунә, сөмсере коелып:

— Август беткәндә генә күрешәчәкбез икән,— диде.— Сез кайтканчы, әни безне авылга, бабайларга кайтарып куячак. Укулар беткән көнне үк кайтара ул безне.— Кыз, урыныннан торып, Фарук янына басты.— Абый, мин сезнең чәчләрегезне тарыйм әле. Тарагым чиста минем.

— Бик чуалышканнармы?

— Юк, минем тарыйсым килә...— Кыз бу эшне, холкына хас булмаганча, озакка ук сузды.— Авылда бабай белән әби янында рәхәт тә, алардан күреп эшкә өйрәнәсең. Ә сезне бик тә, бик тә сагынырмын инде мин... Фәридун абый да сагыначак, әйтми генә ул моны, ул бит бар-бар нәрсәне күңеленә бикләп бара, әнә утыра бит аска карап, сөйләшмичә...

Фарук Мангушев ерак сәфәреннән июньнең унбишендә кайтты. Әйберләрен урнаштырып юынгач, чәйләргә утырган гына иде, телефон шылтырады.

— Кайтуыгыз белән сезне! Исәнмесез!

Шылтыратучы ханымның тавышы гөрлирәк иде, ә ара-тирә көмештәй саф иде.

— Исәнмесез. Рәхмәт,— диде Фарук, хатынның тавышындагы тиз үзгәрешләргә сәерсенеп, дөрес ишеттерәме бу дигәндәй, төребкәгә, колагыннан алып, карап торды.

— Танылыгызмы?

— Тануын танымадым, чөнки мин сезне танышлык дәрәҗәсендә белмимдер. Шулай да кем икәнлегегезне чамалыйм, Фәридун белән Фәрхунәнең әнисеме? Фәүрия...— Фарук, туташмы, дип әйтә язды, әмма тыелды, аның моңарчы берәүгә дә — туташларга да — болай эндәшкәне юк иде, бу сүзне ул кем өчендер саклый иде, шуңа күрә әйтәсен: — ... ханымдыр,— дип тәмамлады.

— Әйе инде!

Фәүриянең тавышы инде ирләргә хас калын чыкты. Холкы да тавышыдай сизгердер бу хатынның, дип уйлады Фарук һәм аның турында нинди фикердә булуын беренче очрашуда ук турыдан әйтергә җыенуы теләге ныгыды.

Ләкин Фәүрияне күрүгә үк моны әйтә алмады ул, янына килүче хатынның кыяфәте һәм эчкерсез тоелган мөнәсәбәте тыеп калды аны, авызыннан бүтән, хәтта уйлаганына капма-каршы сүзләр бәреп чыкты.

— Сез миңа кояш булып килдегез...

Фәүрия Фарукка сөзеп карады да карашын шундук читкә борды, озынчарак алсу йөзен Фарукның хәтеренә тиз генә бер-

кетүен теләмәде кебек — тал чыбыгыдай сыгылучан түгел мин, янәсе.

— Кояш, дисезме?! Рәхмәт. Тик минем ачуланыша белмәвем шулай тоелмадымы икән... Шулай да тәмле теллесездер сез.

— Белмим... Әмма туп-турыдан яручан.— Фарук ниятләгән сүзләрен әйтергә тагын талпынды, әмма тагын тыелды, Фәүриянең үзгәрүчән холкы, үз итүе җиңде бугай.— Әйе, әллибәлли...

— Кешеләрне иркәләп тирбәтергә яратмыйсызмы? Шуңа күрә өйләнмәдегезме? — дип бүлдерде Фәүрия.

— Бәлки. Үзеңә-үзең бәя бирүе үтә дә кыен. Начар кешемендер. Шул ихтималны да алдан ук белеп торыгыз.

— Әйбәтлегегез тавышыгыздан сизелә. Минем балаларым юньсез кеше белән танышмаслар, бала күңеле сизгер ул. Ә Фәридун белән Фәрхунә сезне мактап туймыйлар, бигрәк тә кызым сезне теленнән төшерми...

Троллейбус килеп туктады. Алар урта ишектән янәшә керделәр. Каршыда ялгызы утыручы кыз, Фарук белән Фәүриянең бергә утырырга теләүләрен аңышып, бер урынлы утыргычка күчте. Алар, телефоннан килешенгәнчә, шәһәр үзәгенә киттеләр, Фәүриянең анда күрәсе кешесеме, әллә бирәсе-аласымы әйбере бар икән.

...Алар ике ай буена еш, хәтта көненә икешәр тапкыр да очраштылар, Фарук Фәүрияне кичен эшенә озатты, иртәсен каршылады. Хатын һәрчак яңа танышының килүен көтеп алды, аның күзләрендә йомшак шелтә дә сизелә иде — шул гомер килмичә торалар диме инде! Фарук исә хатынның йомшак исәнләшүеннән үк рәхәтлек тоя иде.

— Кояш булып киләсез сез миңа...— дип кабатлавы ук Фарукның үз дөньясын да иркенәйтә иде.

Моны ишеткәч, Фәүриянең күңеле эри дә якты зур күзләре шатлыгыннан дымсуланып челт-челт йомылгалый иде.

Шулай — яшьлектәгечә бер-берсенә ихлас ияләнделәр алар, һәм үз итүнең-ияләнүнең мәхәббәткә әйләнүен беләләр иде ялгызак Фарук белән ялгыз Фәүрия. Аларның бер-берсеннән яшерер гамәлләре юк кебек, алар беренче һәм соңгы мәхәббәтләре турында бер-берсенә авырлык — күңел китеклеге китермәячәген аңлап сөйләделәр. Мөкатдәслек иде монысы!

Фарук һәр очрашуда:

— Балаларның хәлен белешмәдегезме? — дип сорар иде.

— Иртән генә әйттем бит, кичә телефоннан сөйләштем, дидем, бик әйбәт, дидем. Әти-әниләр янында ич алар. Безнең очрашуларны беләләр ич, Фәрхунә сезгә бер тонна, ди, юк, бер вагон, ди, юк, бабайлар авылыннан шәһәргә хәтле зурлыкта, ди, сәлам әйтергә кушты. Әллә нинди чагыштырулар табып бетергән... Иртән тапшырдым ич сәламен...

— Ә минем тагын ишетәсем килде. Фәридун да, Фәрхунә дә минекеләр бит!

— Мин дә сезнеке...

Фәүрия тагын нәрсәдер әйтмәкче булып авыз ача башлагач, Фарук аны кулына бармак очларын гына тидереп туктатты (бу аңа беренче кагылуы иде, ә бәлки соңгысы да булырдыр). Алар төн уртасына чаклы диярлек шәһәр урамнарында йөрделәр, тик мәхәббәт хакында инде сыңар сүз дә алышмадылар, Фәүрияләр ишек төбендә баш кагып кына саубуллаштылар. Аның каравы күңелләр серләште, киләчәк турында ниятләштеләр кебек...

Иртәгесен Фарук Фәүрияне троллейбуста очратты, хатынның, аны күрүгә, йөзеннән кара болыт шуышып узды, бу көрешү аның өчен чыннан да көтелмәгән иде бугай. Һәм Фарук юлыгышудан тәэсирен:

— Сез бүген миңа кояш булып килмәдегез...— дип турыдан әйтеп салды.

Фәүрия нечкә итеп кырып калдырылган кашларын (кичә генә мондый түгел иде ич алар!) сикертте, зур шакмаклы кофта изүен капламак булып кулын түшенә куйды (тик йомрыларын — иң киме яртылаш — теләгән һәркем күреп өлгергәндер). Һәм хатынның шушылай зәвыксыз киенүе Фарукны бик тә сәерсендерде, канәгатьсезлеген белдереп, башын чайкады ул.

— Кофтама кара тидердем,— дип, хәйләле алдау җаен тапмакчы булды Фәүрия.

— Икейөзлеләнмәгез! — дип, сүзне усал кисте Фарук һәм троллейбус туктауга төшеп тә калды, кирегә китеп тә барды.

Ләкин хатын да троллейбус кузгалганчы төшеп өлгергән иде, ул Фарукны куып җитте, эндәшмәде, Фарукның бәясен кире кагарга сүз тапмады бугай.

— Җенем сөйми алдашуны! — диде беравыктан Фарук. Ул тынычлана төшкән иде, шулай да тавышының ныклыгында ачуы сизелә иде әле.— Ә сез... Сез, кичәге самими аңлашудан соң бит әле, алдашуга барасыз. Кичәге матурлыкны пычракка буярга ничек көчегез җитте?! Сезнең соң сөеклегез яныннан кайтышыгыз лабаса!

Бу сүзләр хатынны аптырауга төшермәде, иң ышанычлы саклану — һөҗүм итү, дигән тәгъбирне күңеленә сеңдергән булгандыр ул, күрәсең. Тик һөҗүм итүченең көчләре саклanучы көчләреннән кимендә өч тапкырга күбрәк булырга тиешлеген генә төшенмәгәндер.

— Кем ул — минем сөеклем? — диде хатын.

Аның йөзендә оялу, хәтта кыенсыну билгеләре сизелмәде, аның әлеге соравында сөяркәсе булу гаеп саналмавы, әгәр сөяркәсенең кемлеген Фарук белмәсә, моның инде гаеп саналмаячагы тоемлана иде. Ә Фарук белә иде, беренче очрашуда ук

әйтергә теләгән сүзләре шул хакта иде аның. Һәм ул Фәридун белән Фәрхунәне беренче тапкыр мәктәпкә озаткан иртәдә «джип» машинасында зур ук түрәне күрүен, артта утыручының балаларның әнисе булуын күңеле белән тоюын сөйләп бирде.

— Сезнең миңа кояш булып килүегез мине бу хакта башта ук әйтүдән тыйды,— диде Фарук.— Без бергә була калсак, мин бу хакта беркайчан да искә алмас идем... Бер нәрсәне исегездә тотыгыз: сөеклегездән сез икейөзлелектән, алдашудан ягъни, һәм сүгенүдән, әйе, әйе, сүгенүдән бүтәнгә өйрәнә алмаячаксыз...

— Теләгән кешем белән очрашырга минем хакым юк мәллә? Мин сезнең алда бурычлы түгел,— дип һөҗүмгә күчмәкче булды хатын.

— Хаклы, хаклы! Хаклы булмыйча соң! — дип, Фәүрия көтмәгәнчә суктырды Фарук.— Әмма сез, хокук дәгъвалаганда, кәрләдән дә кечерәеп калдыгыз, мескен хәлендә сез,— дип көлемсерәде ул.

Югалып калу хатынның исендә дә юк иде.

— Шулай да мин шушы хәлемдә йөз тапкыр бәхетле. Минем аның белән авырып киткән көннән бирле очрашканым юк иде. Бүген мине үзе эзләп тапты, гафу да үтенде. Безнең эштәге хатыннар аңардан... без ума...

— Димәк, чыннан да, акыллары юк. Бәхет мәсьәләсендә исә болай торадыр,— дип фәлсәфәгә кереште Фарук.— Беренчедән, бәхет тапкырланамы? Икенчедән, бәхетне йөзгә генә тапкырлау бик аз түгелме? Уйланыгыз әле...

Алар саубуллашмыйча аерылыштылар. Ләкин иртәгесен үк тагын очраштылар, аннан соң да очрашкаладылар. Күңелләре бер-берсенә тартыла, тик арада калыккан биек киртәне сүтү җаен-әмәлен тапмыйлар иде алар. Сөйләшүләре, кем әйтмешли, гел югары дулкында барды, һавалы сүзләр еш кушылды, акыл сатуга да барып терәлгәләделәр. Берсенең хаклыгын исбатлавында, икенчесенең үҗәтлеген өстен чыгарырга тырышуында мондый сикәлтәле фикерләү табигыйдер дә, күрәсең. Һәм без аларның — Фарук Мангушев белән Фәүрия Юматашеваның — кояшны кара болыт каплаган очрашуларында әйтелгәннәрне бер урынга сайлап тезик. Шуны да искәртик: Фәүриянең бернәрсә турында сөйләшкәндә кырт икенчегә күчүе Фарукның фикерен бутарга тырышудан иде, бу исә дилбегәне кулдан ычкындырудан курку билгеседер һәм аныңише хатыннарның әңгәмә корудагы кылтым гадәтедер, шуңа күрә соңгысы— кылтаю — гап-гади мескен мактану-үсенү генә булып каладыр. Һәм менә беркөнне Фәүрия Фарукны:

— Шушы яшегезгә җиткәнсез, ә яшәргә өйрәнмәгәнсез,— дип гаҗәпләндерде.— Тормыштан барысын да алырга, яши белергә кирәк.

— Яшь бара анысы. Әмма мин сездән күпкә өлкән түгелмен...

— Биш яшькә. Ә бу минем яшь булуымны исбатларга бик җиткән.

— Йөзегездә җыерчыклар, әлегә вак җыерчыклар күренүен...

— Тупас сез, хатын-кызга алай димиләр!

— Үзегезгә үзегезнең җентекләп карап бәя бирүегез зыян итмәс. Бәя дигәннән. Яшәргә өйрәнү, яши белү өчен кылганнарыңны бәяләп уйлана-уйлый белергә дә кирәк.

— Минем кулдан бар эш тә килә. Мин барысын да булдыра алам.

— Шулаймы икән... Үзегезгә бу очракта чамадан тыш ышану, власть — минем кулда, власть барысын да кыла, дип уйлавыгыздан. Әлегә бит власть сездә түгел, сөекле сөяркәгез атланган властька. Ә властька атлануына гына канәгать түгел, аны учына кысмакчы, аны уңга да, сулга да селтәмәкче. Безнең халык түзем, әлегә аның кыланмышларын кичерә. Власть дигәнең — үзенә бер авыру ул. Ремарк кайсыдыр әсәрендә, власть — җир йөзендәге иң йогышлы чир, дигән. Йогышлы чирне бетерүе кыен икәнлеген генә аңлыйсыздыр. Әйе, власть — аны игелек кылу өчен файдаланмасаң — яман чир. Ә сезнең сөяркәгез аны үз мәнфәгатендә генә файдалана.

— Китапча сөйлисез.

— Шөкер, күп укыйм. Һәм китапларны минем игелекле булуым өчен язганнар.

— Шулай да дөньяны мин үзгәртә алам.

— Саташмагыз! Сезнең ишеләр чүплекне генә зурайта. Чүпләрне исә юк итә беләләр хәзер.

— Тупасның тупасы сез...— дип ачуы бүртте Фәүриянең.

Ул ашыгып китеп барды, ләкин, Фарук эндәшеп туктатмагач, борылып, салмак адымнарын да санап дигәндәй атлаучы Фарук янына үзе килде, һәм:

— Миннән сезгә әйбәт истәлек каламы? — дип сорады.

— Миңа кояш булып килүегездән гайре... нинди яхшылыклар кылдыгыз соң сез? Хәер, бу кояш барлык кара болытларны да тарата иде. Минем кояшым булуыгыз җитә иде, бәхет иде миңа. Мин бит нәфесе төкәнмәс, комсыз, туемсыз адәм түгел. Минем байлыгым үзем тудырган — һәм хәзер дә аны зурайтам — дәү-ү, киң-ң дөньям. Үз дөньям! Шул кояш сезнең начар гадәтләрегезнең калкуына ирек бирмәс, юньсезлекләрегезне авызлыклар, дип ышандым.

— Сезнең дөньягызга минем юлым юк.

— Кышкы атлы юлда чалулар, салулар, дип тә әйтәләр, була. Һәм сез мине беренче чалуда ук чанадан төртеп төшердегез. Урын җитмәде сезгә. Чөнки чик дәрәҗәдә үзегез турында гына кайгыртасыз.

— Һәркем үз мәнфәгатен беренче куярга тиеш.

— Шәфкать һәм хакыйкать, рәхимлелек һәм игелек кебек төшенчәләрне онытмыйк.

— Шундый ук начар кеше булгач, нигә мине яратасыз... яраттыгыз соң?

— Лермонтовның бер шигъри юлы искә төште. «И ненавидим, и любим мы случайно» дигән ул.

— Тагын китап сүзе... Рус шигъриятен тирәнтенрәк беләсез бугай...

— Үз шагыйрьләребез иҗатын да беләм кебек. «Ә кемгәдер минем гомерем дә минутына кадәр кадерле» дигән безнең мәхәббәт шагыйребез Гаташ. Һәм шул кешем итеп кабул иткән идем мин сезне. Озак эзләгән идем мин шул кешене... Инде таптым, дигәч үк югалтам... Ә вакыт уза... Әйе, әйе, вакыт чиксез, әмма аның безгә бирелгән өлеше бик тә чикле. Сез беркайчан да минем вакытым кадерен белмәдегез. Нигәме? Чөнки сез үз вакытыгызны да кадерләмисез.

— Тормыштан күп нәрсәләрне алырга ашыгырга кирәк...

— Аңлыйм тел төбегезне — яшьрәк чакның рәхәтен күрергә ашкынасыз. Сезнең коллекциягез, ирләр коллекциягез, бай ук булса кирәк. Минем аңлавымча, фикер сөрешегездән аңлавымча, әлбәттә. Сөекле түрәгездән бүтәннәрен сезнең белән күргәнем юк. Хәер, күп исерекләр белән, берсе, үзегез әйткәнчә, вертолетчы бугай, минем алда, мине читтә калдырып, озаклап әңгәмә коргаладыгыз. Вертолетчыгыз троллейбус тукталышында, кешеләр алдында, сезнең ят төшләрегезне капшаштырды хәтта, димәк, беренче тапкыры түгел. Оятны югалту хәтәр, әлбәттә... Шулай булгач, коллекциягездән берәү төшеп калудан, ягъни минем сезне бәяләп китүемнән ярлыланмассыз. Үзегез дә шул фикердә. Ләкин бу «бөҗра»ның чылбырда төп икәнлеген башыгызга китермәдегезме? Хәтерлик: аз гына вакытка үз итүегездә сез бүтән берәүгә дә белгертмәгән серләрегезне чишә идегез. Мондый чакта сез тәмам тынычлана идегез, чөнки миңа ышана идегез. Хәтерегездә саклагыз шул вакытларны! Оныта алмаячаксыз аларны! Әмма моны минем мактануым яки үземә кирәкмәс ышануым итеп бәяләмәгез. Мондый вакытларның асылын сез мине югалткач, мине үзегезгә кире кайтара алмаслык хәлдә калгач кына аңларсыз. Нигә озак эндәшмисез?

Фәүрия җавап кайтармады.

— Коллекция... Әйе, сез тыштан ялтыраучы артыннан һәр мизгелдә китәргә әзер. Ирләр турында сүз барса, моны һәр итәккә тагылу, диләр...

Тагын очрашкач, Фәүрия:

— Мине тәрбияләмәкче буласыз бит, бүген дә миңа лекция укырга җыенасызмы? — дип, зәһәрен чәчәргә исәпләде.

— Яхшы гамәлдә дә начарлык күрү тамыр җәйгән гадәте-

гез бугай,— дип тыйды аны Фарук. Шунысы анык — соңгы көннәрдә Фәүрия аңа каршы килү көчен җуя бара иде.— Лекцияме, әллә гап-гади киңәшме, үзеңнән өлкән кешене тыңлауның зыяны тимәс.

— Надан шул мин, гыйлемлектә сезнең дәрәҗәгә җитмәгән. Катыргым юк минем,— дип турсайды Фәүрия.

— Нинди катыргы?

— Дипломым юк. Корочка.

— Аңарга китсә, баш миегезнең тышчасы юклыгы хәтәррәк. Һәм башкада да капкач-тышчагыз юк сыман,— дип усалланды Фарук. Ул Фәүриянең тыңлаудан бүтән чарасы калмавын, аның туры бәядән сыгылуын белә иде.— Шуңа күрә, капкадан чыгуга, өегездән чыгуга, сулга карыйсыз. Акылыгызга килегез — балаларыгыз үсеп җитә. Әгәр алар сездән үрнәк алсалар? Әгәр сезгә әниегез шундый үрнәк күрсәткән булса, күңелегезне мәңге төзәлмәслек эзләр сызлатса, әниегезгә мөнәсәбәтегез нинди булыр иде?..— Фарук, бераз тын алып торгач: — Тиле мин,— дип көлемсерәде,— мин бит сезнең кояштай балкуыгызны гасырлар буена күрергә, ягымлы сүзләрегезне гасырлар буе тыңларга әзер идем!

— Гасырлар буена?..

— Әйе, гасырлар буена! Бәхетле тормышның бер көне дә гасырга тиң! Тугрылык безне гасырлардан гасырларга җитәкләп барачак иде...

Сүзсез калдылар. Фәүрия, югалтуының зурлыгын аңлый төшеп, әгәр гафу үтенсәм, мине кичерерме икән ул, дип уйлады. Фарукның да уйлары шул тарафта булган икән.

— Шулай да,— дип дәвам итте ул,— сез миңа кайтырга теләсәгез, мин сезне кабул итәрмен. Тик элгәре барлык кыланмышларыгыз турында ачыктан-ачык сөйләрсез. Боларны башкалардан ишетмәс өчен. Һәм бу сезнең тарафтан миңа ышанычыгыз булыр. Һәм ышанычыгызны явыз нияттә беркайчан да файдаланмам. Ә ышаныч, минем инануымча, кешенең иң күркәм сыйфатларыннан санала, аның күңеле байлыгы сыйфаты. Ә хәзергә сез миңа ышанмыйсыз. Монысы — беренчедән. Икенчедән, сез үзегезгә үзегез ышанмыйсыз. Нәкъ менә үзегезгә ышанудан тормышыгызны кабаттан башлагыз.

— Усал кеше сез... Хатын-кызга ягымлы мөнәсәбәт...

— Әгәр ул лаек булса! — дип тагын усалланып бүлдерде Фарук.— Әмма минем усаллыгым явызлык түгел! Сез миннән кырын-кырын киттегез, ягъни миннән аерыласыгыз да килми кебек. Болай китүегезне җебегәнлек-юашлык итеп аңларга ярамый. Мондый китү — үзе явызлык! Кайчак юләр мин, дип еламакчы буласыз. Ләкин яшегез чыкмый. Чөнки үзегезнең иң явызларның берсе икәнлегегезне әллә белмисез, әллә танырга теләмисез шунда. Мин исә сездән бүтәнчә, үземчә ки-

тәм. Һәм... барыгыз үз юлыгызга! Мин калам. Моны киребеткәнлеккә тиңләмәгез. Югыйсә горурлык белән тискәрелекне буташтырасыз. Ә алар — капма-каршы төшенчәләр. Онытмагыз, башта сез миңа кояш булып килә идегез...

— Әгәр мин китмәсәм?..

— Калырга көчегез җитми сезнең. Әлегә мескен хәлендә сез, һәм үзегез теләп шундый хәлгә төштегез. Ә миңа начар Фәүрия кирәкми!

— Начары кирәкмиме?..

— Кирәкми! Минем дөньяма начарлык керә алмый! Моңа юл бикле! Димәк, димәк... Китегез моннан! Янәшәмнән! Каршымнан! Минем монда горур басып калуым — сездән китүем. Димәк, сез миннән түгел, мин сездән китәм.

— Ничек табармын мин сезне?..

Җавап озак бирелмәде.

— Һәркем үз юлын үзе таба... Димәк, бу кадәресенә үз башыгызны эшләтегез. Сезгә минем кирәклекне хәзергә аңламыйсыз. Минем болай фикерләвем мактану түгел. Сез уйланырга тиешле нәрсәләрне мин төгәл итеп атадым — шул гына. Белергә тиешсез, мин мактанчык түгел. Мин сезне ике ай гына сынадым, шул ике айлык имтиханны да тота алмадыгыз. Ә миңа тоташ икешәр ай сәфәрдә булырга туры килгәли — хезмәтем шундый. Сезгә сак куеп китәргәме? Мондый хәл минем холкыма ят! Сак куюга калгач... Шулай, аерылышабыз. Бу якта — минем сезгә мәхәббәтем,— дип, кулын уңга сузды Фарук.— Дөресе иде. Монысында — сезнең миңа нәфрәтегез. Хәтта нәфрәтләнүегез дә ошады миңа, чөнки ул яшерен түгел. Сезгә минем соңгы көннәрдәге дә әйбәт мөнәсәбәтем ачуыгызны кабарта иде. Каршы төшмәгез,— дип, Фәүрияне сүз башлаудан тыйды Фарук,— югыйсә тагын сөекле сөяркәгездән өйрәнгән алдашуга күчәсез. Әйе, мин сезгә нәфрәтләнмәячәкмен. Мин уртада калырмын. Битараф булырмын сезгә.

— Авырлык минем җилкәне бассын өченме...

— Бәлки. Мин кешегә башлап начарлык кылмыйм, әмма юньсезлеккә җавапсыз калмыйм. Мин барысын да булдыра алам, дисез. Мин андый ук көчкә ия түгелмен. Шулай да сезне гел үз янымда тота ала идем.

— Үзегездән җибәрмәгән булсагыз икән...

— Нигә җибәрдемме? Беренчедән, җибәрмәү миңа җиңелрәк иде, ә җиңел табыш миңа килешми. Икенчеләй — монысы тәртип буенча өченчесе үзе — акылыгызга ышандым. Тагын. Югарырак даирәләрдәге тәртипләргә бик тә кызыктыгыз, анда гел ал да гөл, дип уйладыгыз. Күреп бетерсен барысын да, дидем. Шөкер, мин үз Фәүриямне сездән — бүтән Фәүриядән аерып ала белдем. Минем үз Фәүриям, үз фәрештәм! Мин аны сезгә кайтармаячакмын!

— Сезнең Фәүриягез мине чит итәме?..

— Бик тә!

— Үз янгызда гына торткан булсагыз икән мине...

— Сезгә, бәлки, әлегә генәдер ышанырга ярамый, сезгә ышануның упкынга дөмектерүе ихтимал.

— Монысында сез биек киртәне дә сикереп чыктыгыз бугай. Мин бөтенләй беткән кеше түгел...

— Әмма сез бер секундтан бүтәнчә сайрарга сәләтле!..

Һәм Фарукның соңгы бәясе кире каккысыз булып чыкты.

Фәридун белән Фәрхунәнең иртәгесен төш турында кайтасыларын белә иде Фарук. Автобусны шәһәр үзәгендә каршыларга булды ул, төрле яклардан килгән сәфәрчеләр шунда төшеп бетәләр.

Фәүрия балаларын көтә иде инде. Ул гадәтен бозды — Фарук белән сүз әйтеп исәнләшмәде, аның карашында борчылу сизелә иде. Фарук гадәтен бозмады — баш кагып, сәламен бирде, аның йөзе шат иде.

Алар өзә-төтә генә сүз алышкаладылар.

— Нишләп йөрисез монда?

— Мин балаларны каршыламакчы идем,— дип юаш кына әйтте Фарук.

— Үзем каршылыйм мин аларны. Әнә, машина белән килдем,— дип, арырак торучы кара «Волга»га — монысы кыбырсык таксист машинасы түгел иде — ымлады Фәүрия.

Әллә сөйләшер сүзләр беткән иде, әллә инде бер-берсеннән ерагаю билгесе идеме — алар озак кына тын тордылар, күзләренә дә карашмадылар.

Кинәт Фәүрия:

— Бәбәй табачакмын...— диде.

Фарук бу хәбәрдән, кем әйтмешли, егылып китмәде, керфеге дә селкенмәде бугай аның.

— Гаҗәп түгел,— диде ул һәм көлемсерәп: — Мондый очракта минем әйтә торган тәгъбирем бар — эшләгән эшегез күзгә күренә, димәк,— дип өстәде.— Сез барысын да булдыра аласыз, сез һәрнәрсәгә сәләтле ич. Ә шулай да соңгы соравым бар — сез минем белән яшәү турында кайчан да булса ныклап уйландыгызмы?

— Юк!

— Рәхмәт. Туп-туры җавабыгыз өчен рәхмәт.

Автобус килеп туктады. Фәридун белән Фәрхунә аннан атылып чыктылар да Фәүрия кочагына ташландылар. Аннары кыз Фарукны күреп алды — хәер, ул аны автобустан чыкканда ук күргән иде — һәм йөгереп барып аңа сыенды.

— Абый да килгән! Фәридун абый, күрмисең мәллә Абыебызны?! — дип очынды Фәрхунә.

Тик аның куанычын әнисенең Фарукка атап әйткән битәрләү-кимсетү сүзләре кара болыт булып каплады.

— Нигә сез минем арттан йөрисез? Югалыгыз күземнән!

Баскан төшендә катты да калды Фарук, теле көрмәкләнде, бераздан гына ык-мык итүе бетте.

— Твое лицо ограблено, как сейф... Синең йөзең таланган сейф кебек...— дип, шагыйрь сүзләрен авызыннан көчкә әвәләп чыгарды да, башын аска иеп, җилкәләрен салындырып китеп барды.

Фәүриянең кыланмышыннан балалары аптырашка төштеләр. Балалары алдында иң киме мәгънәсез дорфалык кылуы хатынның үз башына да дөпелдәтеп сукты, ул гәүдәсен тота алмыйча сыгылып төште, ләкин егылмады, җиргә таянып, чүгәләп кала алды.

— Туктатсаң, Фәрхунә, син генә туктата аласың аны...— дип мескенләнде Фәүрия.

Кыз Фарукны куып җитте дә аңа сарылды. Фарук чүгәләде, башы иелгән иде, күзләреннән яшь бөртекләре тәгәрәп чыкты. Кыз аны чәчләреннән сыйпый иде.

— Сезнең чәчләрегез минем әтием чәчләре кебек...

Ә бу вакытта Фәүрия торып басмакчы булып азапланды, тик аякларының җегәре җуелган иде. Кара «Волга» хуҗасы машинасын Фәүрия турысына туктатты да сигналга басты. Хатын шулайга башын борды, күтәргә ишарәләде. Ләкин машина хуҗасы чигәсе янында бармагын бөтергәләде дә Фәүриягә төртеп күрсәтте, син шундый ягъни, һәм машинасын үкертеп кузгалды. Хатын-кызга теге чактагы карсак һәм кыбырсык таксист кебек сусау түгел идеме ул, әллә Фәүриянең кемлеген сизеп алдымы шунда — белмәссең. Фәүрия Юматашева моны көтмәгән идедер, аның чүгәләгән халәтендә күзләрен акайтудан бүтән чарасы юк иде...

Фарук һәм Фәрхунә янына Фәридун килеп җитте, үзенең мондалыгын сиздереп, тамагын олыларча кырды.

— Менә, Фарук абый, шундый хәлләр инде бездә...— дип сузып кына әйтте малай.

Ә Фарук елый да елый иде.

— Фарук абый,— дип, Фәрхунә дә беренче тапкыр исеме белән эндәште аңа — моңарчы исемен әйтмәүләре сәбәбе Фарукны якын кеше итеп тануга өметләнүләреннән — әти итеп! — иде, ахрысы,— Фарук абый, еламагыз инде... Миңа да, Фәридун абыйга да авыр ич сез елагач...— Фарук күперенке чәчле башын Фәрхунәнең култыгына яшерде.— Менә шулай... Чылансын күлмәгем, чылансын, минем үз яшьләремнән дә тиз кибә күлмәгем... Елагыз ла рәхәтләнеп! Мин сезнең күзләрегезне яшереп торам, яме... Кешеләр күрсә, ни булган тагын...

Бераздан Фәрхунә тагын сөйләнеп алды. Фарук белән Фәридун аны бүлдермәделәр.

— Фарук абый, әти янына без өчәүләп барырбыз, яме. Фәридун абый белән мин — икебез генә инде — авылда шулай уйлашкан идек... Әтинең яңа хатыны әйбәттер. Теге чакта, әни сырхауханәгә яткач, әти янына мин бардым ич. Аның яңа хатыны мине җибәрмәскә дә теләде әле менә. Фарук абый, бер сер әйтимме? — Фарук Мангушев, ризалашып, башын кызның култыгында каккандай итте.— Фарук абый, сезгә дә бер әйбәт апа табарбыз, яме... Әйбәт апалар күп, бик-бик күп...

Алар җитәкләшеп баралар.

Өчесенең дә күзләре дымлы.

Фарук Мангушев балаларны өйләренәчә озатты. Алар сүзсез аерылыштылар.

Фәүрия, балалары кайтып кергәндә, өйдә иде инде, ул машина яллаган иде.

Яңа ел башында һава җылытты да суытты, кары һәм яңгыры чиратлашып дигәндәй яугалады. Кичтән шыкырдатып катыра да иртәнгә җепши, төшкә салкын тагын куырып ала. Атна буена шушылай холыксызлану кышның үзен дә туйдырды-ардырды бугай, искечә елның соңгы көнендә, ниһаять, һава торышы тиз генә үзгәрмәскә урнашты кебек. Кыш бабайның миһербаны килүе әллә Фәүрия Юматашеваның туган көне хөрмәтенә булды тагын...

Фәүрия туган көнен моңарчы зурлап билгеләп үтмәде. Кыз чакта җае-мөмкинлеге чыкмагандыр. Ире белән яшәгәндә дә моңа ничектер игътибар ителмәгән. Хәер, өстәлгә шешә менеп утыра иде утыруын, ире, бәлешнең төбенә төшкәнче, шешәнең төбенә алдарак төшеп өлгерә, тәбрик-теләкләр онытыла һәм дә чәчәк-бүләкләр хәстәрләнмәгән була иде. Бу юлы да олы мәҗлес кормыйча, шыпырт-пышын гына узып китәчәк инде туган көне. Элекке көнне хезмәттәш хатын-кызлары, урнашкан тәртип буенча, чәчәкләр бүләк итеп, бәхетле тормыш теләделәр теләвен — шуңа канәгать иде ул.

Шәһәрдә аның туганнары юк, якын дуслары да юк, димәк, берәү дә аны котлап килмәячәк. Шулай да ул барыбер бәлеш пешерергә булды. Бу ризык гаиләнең һәр кешесенең туган көнендә табынга килүе гадәткә кергән иде. Балалары мәктәптән кайтуга, бәлешне пешереп тә өлгертер әни кеше.

Ай-й, кайтып та җиттеләр ич Фәридуны белән Фәрхунәсе! Ишекне кызы шакый — күңелне иркәләп, үзе дә иркәләнепсөенеп, ишекне Фәрхунә генә шулай шакый белә. Фәүрия ишекне йөгереп үк барып ачты.

— Әни! Без сине туган көнең белән котлыйбыз! — дип, ананың муенына асылынды кызы.— Без бәхетле булырбыз, яме...

— Иртән котладыгыз бит инде, кызыкаем.

— Ә без тагын котлыйбыз!..

Фәрхунә, киемнәрен урнаштыргач, ашау бүлмәсенә керде, аның шатлыгы йөзен балкыта иде. Ә кулларын артка яшергән иде кыз. Аның янәшәсенә Фәридун абыйсы кереп басты.

— Әни, син тагын кемнән котлау көтәсең? Миңа гына, юк, Фәридун абый белән икебезгә генә әйт әле...

Фәүрия мондый сорауга башта гаҗәпләнеп торды, аннары Фәрхунәнең текәлеп каравыннан күзләрен яшерде дә, тавышын йомшартып:

— Беркемнән дә көтмим, кызым,— диде.

— Әйт инде!

— Әйттем ич, берәүдән дә көтмим, дидем. Сез тәбрикләгәч, миңа бик җиткән.

— Әни, син соңгы заманда эшкә йөгереп барасың да чабып кайтасың,— дип ипләп кенә сүзгә кушылды Фәридун. Әнисе көтелмәгән сүзләр ишетүдән күзләрен зур ачып аптырап торган арада улы: — Өйгә бикләндең,— дип, фикеренең очына таба барды.— Кайвакыт урамда йөргәләп керсәң, шәп булыр иде. Менә хәзер чыгып кер әле. Без ипи ала кайтмадык, ипи кирәктер...

Әни кеше югалып калды.

— Ипиме... Бәлеш пешерәм ич...

— Фәридун абый белән мин синең кемнең котлавын көткәнеңне беләбез! Син дә, Фәридун абый белән минем кебек, Фарук абыйны сагынасың...

Фәүрия күзләрен тагын да зуррак ачты да сүзсез торды, ә барыбер нинди дә булса җавап бирергә кирәк иде, балаларының елмаеп көтеп торулары шуңа мәҗбүр итә иде.

— Әйе...

— Менә Абыебызның котлавы! — дип, кулындагы конвертны боргалый-селти әнисен кызыктырды Фәрхунә.

Фәүрия конвертка үрелде, тик кызы аны тагын артына яшереп өлгерде.

— Бие, бие! Биесәң генә бирәбез!..

Фәүрия биеп китүен абайламады, уенга тиң шаярту аны балалары тиңенә төшерде дә куйды.

Ул ябыштырылмаган конверт эченнән открытканы алды. Анда «Туган көнең белән, кояшым минем!» дигән басма сүзләр иде.

— Моның... моның кемнеке... Бу бит типографиядә басылган... Бүтән язуы юк... Миңа түгелдер... Абыегыздан... Аңардан түгелдер...

Фәридун белән Фәрхунә Фәүрияне, ике яктан култыклап, тәрәзә янына алып килделәр.

Ишегалдында, тәрәзәгә төбәлеп, Фарук басып тора иде.

Фәүрия открытканы бая Фәрхунәчә боргалады-селтәде. Шушы кызыктырудан соң, Фарукның йөзенә елмаю җәелде, ара

ерак ук булса да, бу бәхетле елмаюны ана да, балалары да аермачык күрделәр.

Фәүрия өйдән йөгереп үк чыгып китте, лифт та көтмәде, баскычтан очып кына дигәндәй төште. Һәм Фарукны йөгереп барып кочаклады.

— Мин сине янымнан бер адымга да җибәрмим!

— Мин синнән ярты адымга да китмим... Тик...

— Барыбер җибәрмим!

— Тик... син салкын тидермәгәең... Өстеңдә юка күлмәк тә аякларыңда башмак кына...

— Әйдә, өйгә... Көтәләр безне анда...

— Тик...

— Тик тә, мик тә түгел! Җибәрмим!

— Тик мин сине ерак-еракка...— дигәч, уйланып торды Фарук.— Менә шушының хәтле ераклыкка...— дип, ике бармагы арасында кәгазь сыярлык кына ара калдырып күрсәтте ул,— еш, бик еш җибәрәчәкмен. Миңа кояш булып килерең өчен...

Фарукны өчәүләшеп озата чыктылар. Әмма аерылып китә алмадылар. Хәер, аерылышу турында уйламадылар алар. Шуңа күрәдер Фарукның фатирына барып керүләре дә көтелмәгәнчә тоелмады.

Фарук диван уртасына утырды, уңыннан Фәридун урын алып өлгерде, сул ягына Фәрхунә сыенды. Фәүрия каршыларында басып калды — аның урыны кайда соң әле?

Әнисенең бу халәте сизгер-җәһәт Фәрхунәнең телен ачтырды. Ул, Фарукны күперенке чәчләреннән иркәли-иркәли:

— Хәзер... Хәзер әйтәм...— диде.— Мин инша язган көндәге кояш тирәли туктаган ягымлы болытлар бәхет яшен хәзер генә коярлар...

Һәм Фәүриянең күзләреннән яшьләр тәгәрәде. Ул Фарукның күкрәгенә килеп капланды.

Фарукның киң кочагына алар өчесе дә сыйдылар.

*1998*

# Фидая хикәясе

## I

Егетне беренче күрүдә үк Садирәнең йөрәге дерт итте. Шул кыска дертләү дөнья агышын туктатып торды. Ярый әле Садирәдәге көтелмәгән үзгәрешне аның үзеннән башкалар сизмәде. Хисләренең янартаудай атылуын киләчәктә томаларга көче җитәр санады ул, тик йөрәгендә янгын дөрләвен берәү дә, хәтта шул утны төртүче егет үзе дә белмәсен, белмәсен...

Һәм моны көннәр, атналар, хәтта ел үтеп тә берәү дә белмәде. Шулай — вакыты җиткәнче Садирәнең йөрәге ялкынланып януын күрмәделәр. Ялкыннар өстендәге ябынча нык булган, димәк. Әмма сер чишелүнең вакыты килде, һәм сөю ялкыннарын каплаган бөркәнчек, күз ачып йомганчы дигәндәй, әллә янды да бетте, әллә очты да китте шунда...

Садирәләргә еш килеп йөрде егет, монда аңа ишек һәрвакыт ачык иде, аның гелгә үз кеше булачагы шиксез иде. Чүкечсез йортта егеткә эш табылып кына торды — йә монысы какшаган да тегесе купкан, йә кием чөе салынган да тәрәзә ябылып бетми. Ә егетнең мондый эшләргә кулы ябыша икән, каккансы-сукканы уңганлыгын бизи.

Өйдә Садирәнең ялгызы гына чакларына да туры килгәләде егет. Ләкин андый очрашуларда тегенди-мондый хәлләргә берсе тарафыннан да ишарә дә кылынмады, егет үзенә нинди дә булса шөгыль тапты, Садирә аның монда булуыннан өй һавасы ук иркенәюенә сөенеп йөрде.

Көннәр эссе тора, өйдәге бөркүлек төнлә дә бетми. Шуңа күрә Садирә, өйне җыештырганда — бүген аның эш көне түгел — су коенгандагыча калып чишенде. Кыңгырау шалтырагач, өстенә халатын элеп, итәк ягын төймәләргә өлгермичә, ишек ачты. Егет балкып килеп керде, бу йортның һавасы (гәрчә бүген эсселек патшалык итсә дә) иркәләвенә инде күнегүе куандыра иде аны.

— Буш вакыт барында, өстәлне җыеп куясы иттем,— диде ул һәм кичә кичен үзе күтәрешеп кайткан төргәкне сүтәргә кереште.

— Чәй куйыйм әле.

— Соңрак.

Садирә егеткә түгәрәк өстәлне җыярга булышты. Бер чүгәләгәч, төймәләнмәгән халат итәкләре ачылды да төз-түгәрәк ботлары егетнең күзләрен яндырды.

Садирә:

— Һай! — дип, тиз генә төзәтенде.

Ләкин ук атылган, тиясе төшенә тигән иде инде. Һәм егетнең кулыннан эш төште, кулының бүтән шөгыльгә тартылуын тыя алмас дәрәҗәгә җитте ул.

Шулай да:

— Ир белән хатын мөнәсәбәтен белгәнем юк әле минем,— дип кузгалып китмәкче дә иде, әмма шул ук вакытта Садирә селкенеп куйды да халат итәкләре ян-якка шуып төште.— Өйләнгәнче, моны берәр ялгыз хатын янына барып өйрәнергә кирәктер инде...

Садирәнең дә җаны-тәне тәмам кызышкан иде.

— Әзерлегең ничек соң?..

— Әй-й, гел әзер лә ул...

— Беркайчан да беркемгә дә бу хакта...

— Нинди хакта?

— Ашыкма... Бу хакта берәүгә дә әйтмәссеңме? — дип таләбен очлады Садирә.

— Юк инде!

— Үзем өйрәтәм сине...

— Бик әйбәт булыр иде!..

Эш узгач, егет, көче кайтып:

— Моны башкача-бүтәнчә дә эшлиләр бугай бит...— диде.

— Ашыкма...

Ләкин берәү — гөнаһсыз кыз бала — сөйгән егетендәге һәм Садирәдәге үзгәрешне әлеге хәлдән соң беренче күрүдә үк сизде, аларның үзләрен тотышларыннан төзәтелмәслек гөнаһның кылынуына тәмам ышангач, Садирәгә һәм егеткә авыр сүзләр әйтмәстән, өйдән китеп барды. Хәтта саубуллашмады.

Ә Садирә белән егет якынаймыйча түзә алмыйлар иде инде. Тик алар өйдә очрашмадылар, моңарчы егетнең еш килүенә һәм үз итеп аралашуына күнеккән күршеләрнең ямьсезлекне дә тиз күрүләре ихтималыннан курыктылар бугай. Шулай булса, оятлары бөтенләй качмаган, димәк. Җәй айларында дүрт дивар арасына кереп бикләнүнең хаҗәте дә юк, әнә, шәһәрдән ерак түгел урманнар күп, анда үткер күзләр сагаламыйлар, кем кемне белгән...

## II

Фидая, биек түшәмгә җитә язган ишекне акрын гына ачып кергәч, бүлмәдәге кешеләрнең күплегеннән аптырабрак калды. Егетләр һәм кызлар, төркем-төркем булып, пышын-пышын да, яңгыратып та гәпләшәләр иде. Кемдер күзләре яшьләнгән тәбәнәк буйлы, тоташ карадан киенгән кызны тынычландырырга тырыша, бүтән төркемдәге колгасар егет, иптәшләре ни әйтсә дә, кулын гына селти — институтка кабул итмәүләренә исе дә китми, аңа дипломны укымыйча да бирәчәкләр, янәсе. Шулай да күпләре укытучыларны гаеплиләр, түбән билгеләр куеп, аларны кыерсытканнар ягъни.

Түрдәге өстәл янында берничә егет һәм кыз тезелешкән иде. Болары сөйләшмиләр, документларны кайтаручы чаларган чәчле чандыр апа каршына баскач кына нинди белгечлеккә имтихан тотып карауларын һәм исем-фамилияләрен атыйлар. Фидая шулар артына басты.

— Ходаем ла, монда да чират,— дип үзалдына шыпырт кына әйтеп куйды ул.

Аның сүзләрен алдындагы егет ишеткән икән, башын гына борып шаярмакчы иде ул, ләкин кызга күзләрен текәп торгач, бөтенләй борылды һәм башта:

— Ашыгасы юк, безнең эшләр төгәлләнгән,— дип нәтиҗә

чыгарудан узмады. Чираты җитәр алдыннан гына, тагын кызга текәлеп: — Чират та чират, дисезме? Ә минә мәхәббәткә беркайчан да чират тезелми! — дип тавышын гүләтте, яңалык табуына сөенә идедер, калын кашлары сикергәләп алды.— Кире каккысыз хакыйкать монысы!

— Сезне институтка алмыйча ялгышканнар икән, хәтта шундый акыл иясен югалтып оттырганнар,— диде Фидая, башланыр-башланмас бәхәстә һич тә җиңеләсе килми иде аның.— Укытмыйча ук диплом бирәсе иде сезгә.

Егет җавап кайтарырга өлгергәнче, аның чираты җитте. Ул (исеме Шәмсуар икән), документларын алгач, китәргә ашыкмады, адым гына чигенде — Фидаяны көтүе икән. Кыз кәгазьләрен тәртипләп сумкасына салгач, Шәмсуар:

— Минә таныштык та,— диде һәм: — Исемең матур икән — фидакарь җан,— дип, сездән сиңа күчте.

— Үзең таныша белмәгәч...

Кызның беренче чибәрләр рәтендә торырлык брюнет егет белән әңгәмәне өзәсе дә килмәгән кебек, түп-түгәрәк һәм йонлач беләкләрен сыпыргалап көченә мактанучы егеткәйне үсендерергә теләмичә битараф калмакчы булуы да сизелә кебек. Ул, бүлмәдән чыгар алдыннан:

— Башкалар ярдәмендә белешүнең ахыры әйбәт бетми бугай,— дип, фикерен еракка илтеп терәде.

— Хорафатларга иярүчән түгелмен! Элек димче әбиләр кавыштырган парлар бик тату яшәгәннәр,— дип, сүзнең бу юнәлешкә керүен чикләде Шәмсуар.

— Җәһәт икәнсең — кавышуга бик тиз җиттең. Зур эштә вак мәсьәләдәге кебек кабаланасың.

— Безнең юл шушыннан башлануын күңелем сизенә. Бергә булырбызмы — монысын белгән юк, ләкин бер-беребезне беркайчан да онытмаячакбыз.

— Башка гамәлләреңдә дә үз көчеңә шулай симерттереп ышанасыңмы икән минә...

— Симерттереп, дисеңме... Ышанам! Күрәсең, ябыклардан түгелмен,— дип шаяруга күчте егет.

— Туктале, нигә тузга язмаганны сөйләшәбез соң без?! Синең сукыр тиенгә тормаган сүзләреңне нигә тыңлап торам соң мин?! Сау бул! Хуш...

Фидая кызуланып троллейбус тукталышына таба китеп барды. Шәмсуар киң маңгаен бераз ышкып торды да, калын кашларын сикертеп алгач, кызны тиз үк куып җитте.

— Ай-һай кырт синең холык, әй!

— Кем белән сөйләшүгә карап!

— Шулай да ипле булыйк. Сиңа да, миңа да рәхәт түгел анысы. Икебез дә институт бусагасында сөртендек, сөртенеп егылдык.

— Ләкин явыз нияттә булсаң, күземә дә күренмә! — дип кисәтте кыз, димәк, ул да танышлыкның башланыр-башланмастан өзелүен теләми икән.

— Нигә мине юлдан язган бәндәгә саныйсың әле? Мин шундыйга охшаганмы?

— Юк та... Нигә тупаслануым сәбәбен үзем дә аңламыйм,— дип йомшарды кыз.

— Безнең бүгенге хәлдә төрлесе була. Шулай да мин институтка керә алмавыма артык кайгырмыйм. Сигезенче класстан соң техникумда укыйсы булган да бит, баш эшләмәгән,— дип, чигәсен бармак очлары белән бәреп шакылдатты егет.— Һөнәр-белгечлекне иртәрәк алырга кирәклеген менә хәзер төшендем.

Кыз да:

— Анысы югары белемсез калуыма мин дә егылып хафаланмыйм. Күңелдә үкенү оемасын, дип кенә тапшырып карадым керү имтиханнарын,— дип ачыла төште.— Әйбәт укытучы чыкмас та идедер әле миннән.

— Киләсе буыннар безнең укытучылар булмавыбыздан, шәт, оттырмаганнардыр.— Һәм Шәмсуар: — Һе, әкәмәт,— дип көлде дә сүзне бүтәнгә күчерде.— Син, Фидая, юкка миңа шикләнеп карыйсың. Сиңа мөнәсәбәттә әшәке ниятем юк. Гомумән, берәүгә дә начарлык кылмыйм. Бик беләсең килсә... Бик беләсең килсә...— дип, бөтен йөзенә елмаю җәелдерде дә тукталып калды ул.

— Бик, би-ик беләсем килә!..— дип чытлыкланды кыз.

— Бик беләсең килсә, мин — туп-тулы мәгънәсендә егет кеше! Һәм шуның белән горурланам! — дип акрынрак, әмма һәр сүзенә сузыбрак басым ясап әйтте егет.— Ә соң... Нигә акланам соң мин?!

Фидая сискәнеп куйды, үзенең кирле-мырлы сөйләвеннән Шәмсуарның болай ук ераккка кереп китүен теләмәгән иде ул, төртмә кисәтүләрен егет бер селтәнүе белән юкка чыгарды да куйды менә, үзен егетнең күңеленә яра ясагандай сизеп уңайсызланды. Алар, кара-каршы басып, шактый озак кына тын тордылар, бер-берсенең күзләренә күтәрелеп карарга кыймадылар. Ниһаять, кыз, нидер әйтмәкче булып, авызын ачкан иде, ләкин сүзе табылмады, танышуларының очраклы булмавын раслаучы әлеге сүзсез аңлашуның ямен җибәрәсе килмәде бугай. Тукталышка җитәрәк кенә:

— Ачуланма, яме, Шәмсуар...— диде Фидая.

— Ярар, Фидая...

Кыз, кибетчек артына елышып, янәшәсендә басып торучы егеттән яшермәкче булып, күзләрен сөртте.

— Менә күрдеңме инде минем җебегәнлекне... Елап та күрсәттем үзеңә...

— Мондый күз яшьләре — гөнаһсызлык билгесе, Фидая...
— Аңладым аңлавыңны, Шәмсуар...
Ары сөйләшмәү аларны бер-берсенә ышанычлы якынайта иде, һәм алар тагын сүзсез калдылар. Шәмсуарның Фидаяны үз итеп култыклыйсы килде, тик моңа кыюлыгы җитмәде. Фидаяның Шәмсуар белән үз итеп җитәкләшәсе килде, ләкин кыймады. Алар, алдан белешкән кебек, тугызынчы трамвай тукталышына бер-берсен әйдәләмичә җиттеләр.
— Кая барабыз соң без? — дип башлап исенә килде егет.— Бер якта торабыз мәллә? Миңа анысы трамвай белән кайту җайрак, без Соцгородта торабыз. Әти-әни, бабай-әби, тагын өч энекәш. Фатирыбыз әйбәт, сугышка чаклы салынган йортта.
— Миңа трамвай да ярый, синнән соң ике тукталыш узам икән мин,— диде кыз һәм, егетнең самимилегенә җавап итеп, үзенең гаилә хәле белән таныштырды.— Без икәү генә, әни дә мин, бер бүлмәле фатирда. Тик...— Кыз егеткә күтәрелеп карады да: — Ары сорашма, яме,— дип кисәтте.
— Ярар.
— Әй-й, нәрсәсе сер соң аның,— дип, бу мәсьәләдә чишелеп бетәсе итте Фидая.— Мин туганда, әти тиешле кешенең инде гаиләсе булган. Мин аны белмәдем һәм белмим. Әни ишарәләвеннән генә сизенәм — безгә ярдәм итеп торгандыр әти тиешле кеше. Үзе, мәҗбүр итмичә. Миңа унсигез тулды, хәзер бөтенләйгә онытырдыр...
— Бәлки, нәкъ менә хәзер табышырсыз. Тормыштаниләр генә булмас...
— Әти, дип эндәшәсе килгән чаклар хисапсыз инде... Хәзер дә... Яшь күренә әле әни, кызлар кебек... Унсигез яшендә тапкан мине...
— Ә бабаң-әбиең? — дип, үзе дә сизмәстән кызыксынды егет, үзенең әбисе һәм бабасы турында искәртүен истә тотты бугай.
— Алар авылда яши. Бик әйбәтләр. Мине бик яраталар. Еш кайтам. Үзләре дә килә. Әни елына бер кайтса кайта. Менә бер серем дә калмады бугай...
— Ә сөйгән егетең?
Фидая көтелмәгән сораудан аптырап калмады, Шәмсуарның белешүе «юк» дигән сүз ишетергә теләвеннәндер кебек тоелды аңа һәм ул:
— Ә синең сөйгән кызың бармы соң?! — дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды.
Әмма Шәмсуар да җебеп төшмәде, изрәгән арыш боламыгы түгел икән егетебез.
— Минем сөйгәнем — син! — дип ярып салды ул.
Кыз, зәңгәрсу күзләрен зур ачып, егеткә текәлеп торгач:
— Тиле! — диюдән бүтән сүз тапмады.

— Менә бәхет — миңа гашыйк булуыңны авыз тутырып әйттең!

— Җитте сиңа, ә!..

— Җитмәде шул! Алдым да кайттым булыр сине үзебезгә! Килен итеп!

— Җитте, дим, ә...

Их-х, Шәмсуар гөнаһсыз теләгән шул вакытта ук үтәгән булса соң...

Алар трамвайда янәшә утырганда гына бу фани дөньяның рәхәт хыялдан гына тормавы чынбарлыгын искәрделәр.

— Мин Оргсинтезга бармакчы идем бит,— диде Фидая.— Анда эшкә чакырып торалар.

— Киттек!

...Их-х, Шәмсуар Фидаяне, юлларын үзгәртмичә, шул вакытта ук үзләренә алып кайткан булса соң... Килен итеп... Их-х, Фидая Шәмсуарны гомер-гомергә үзенеке итәчәгенә ышандырган булса соң, аның гөнаһсыз кыюлыгына тыйнак һәм өметле кыюлыгын өстәгән булса соң... Әгәр шулай булса, аларның язмышларында, бәлки, фаҗига өстенә фаҗига өстәлмәс тә идедер...

## III

Егет белән Садирәнең табигать кочагында кичергән рәхәтлекләре әбиләр чуагына чаклы гына дәвам итте.

Алар Дөбъяз ягы урманыннан кайтышлый автобустан шәһәргә керүгә үк төштеләр. Аерылышасылары килмәде, ерак ук араны җәяүләп уздылар. Әмма икесе ике якка китәр төш һәм чак барыбер җитте. Егет, зур сумканы җиргә куеп, үз әйберләрен алырга дип, кулын сумкага тыкты.

— Хәзер үзем рәтләп бирәм,— дип, аңа булышырга ашыкты Садирә, сумкада актарына башлады.

Алар, берьюлы диярлек ачы кычкырып, сумкадан кулларын алдылар, ләкин кылынасы кылынган иде инде. Урманда сумка эченә ике кара елан кереп яшеренгән булган...

Алар икесе ике сырхауханәгә үзләре бармакчылар иде, бергә булуларын чит-ятларга белгертмәү теләгеннәндер бу кадәресе. Ләкин егет тыкрык буе җир китүгә үк аңын җуеп егылды. Табиблар аны коткара алмадылар, ул бер атнадан соң аңына килмичә вафат булды. Елан чагуы, вакытында чарасы күрелсә, заманы өчен котылгысыз һәлакәт түгел дә түгелен, әмма һәркемнең агуга каршы тору көче төрлечә шул. Садирә исән калды, тик аның бөтен гәүдәсе корышты, өстәл янына һәм йомыш-юлга бару аның өчен ерак сәфәргә әйләнде. Инде менә егерме ел буена шулай...

Ә егетнең сөйгән кызы... Ул ачу-үпкәсенә калкырга ирек куймады, сырхауханәдә егете янында озак-озаклап утырды, ләкин аңа ул да ярдәм итә алмый иде инде. Егете аның исемен әйтеп

бәргәләнгәндә, караучыларга аны тынычландыруда булышты, тик егет аз гына вакытка да саташуларыннан айнымады, кызның күзләренә танышкан чактагыча үз итеп карый алмады...

## IV

...Фидая белән мин болай таныштым.

Җәен без дачада торабыз. Эшкә алтыдагы — беренчесе — автобус белән кайтам. Аннан троллейбуска аның соңгы тукталышында күчеп утырам, анда кешеләр азрак була. Бу көнне дә троллейбуста иркен иде, әнә, тәгәрмәч турысындагы биек утыргычта буш урын бар. Андагы кыз, мин алданрак төшәмдер дип, мине эчкә уздырды.

Кыз үзе сүз башлады. Сөйләшергә-аралашырга яратадыр. Фидая иде ул. Эштән кайтышы, төннән.

Бер тукталыштан соң:

— Өемне узып китәм,— диде Фидая.— Элгәре әнинең хәлен белергә кирәк шул. Ялгызы ул, мин дә ялгызым, торабыз шулай — аеры-йоры, инде егерме ел...— дип җиңелчә уфылдады ул.— Әни авыру минем. Тик мин аның белән бер өйдә — ул өйдә,— дип басым ясады Фидая,— куна алмыйм. Бар инде моның сәбәбе. Ә әнине елан чаккач, аның янында һәр төнне кунган идем. Тик ул өйдә әнине сырхауханәдән алып кайткан көндә дә куна алмадым. Әни дә мәҗбүр итмәде. Әйтәм ич, бар инде моның сәбәбе.

— Язмышыгыз авырлыгына ишарәлисез кебек,— дип, Фидаянең сөйләвен дәвам итүен теләдем мин, ә ул, кыстатмаса да, тәгаенләүгә тиз генә күчмәде.

— Узды инде гомерләр, узды,— дип офтаныбрак суза төште ул.— Пенсия яшем дә җитә...

— Сезгәме? Яшь ич әле сез пенсиягә чыгарга!

Фидая гаҗәпләнүемнең аңарга ярарга маташу түгеллеген аңлады, әмма үз сүзләренең дә ялган булмавын:

— Җитә шул, җитә пенсия яшем,— дип раслады.— Башта эшем җиңел дә иде, гел көндезен генә дә эшли идем. Аннары сәламәтлеккә зарарлы цехка күчтем. Яшисе килмәү кортлары йөрәкне кимергәләгән чаклар иде. И-и, бар инде хәлләр, баштан төрлесе узды... Әле дә узып бетмәгән... Узып та бетмәс кебек... Уйга чумсаң, хикәя язарлык, валлаһи...

Мин сискәнеп куйдым. Ләкин Фидаянең соңгы сүзләре минем хикәяләргә бәйле хезмәтемне белеп әйтүдән түгел иде, карашында мондый хәбәрдарлык сизелмәде. Һәм аның моңарчы мине күреп белмәвенә соңыннан ныклап ышандым.

— Языгыз соң,— дип тыныч кына киңәш иттем мин аңа.

— Хикәягә сыйдыра алмамдыр... Аннары... Булдыра да алмамдыр...

Ул Восстание тукталышында саубуллашып төште.

Икенче көнне иртән мин, дачадан кайтышлый, Фидаяне тагын очраттым. Янәшәсендәге буш урынга күрсәтеп, ул мине үз янына чакырды. Аның күңелендә җыелганны кемгә дә булса сөйләп бушанасы килүе чигенә җиткән идедер.

— Сөбханалла! — дип башладым мин.— Төн буе авыр шартларда эшләп тә йончымагансыз.

Фидая минем мактавымны:

— Бүген черемләп алырга җай булды,— дип читтән уздырды.

— Хикәягезне яза башламадыгызмы? Миңа укытырсызмы?

— Сүз җаеннан әйтелгән теләк кенә булып калыр, ахры, ул...

Восстание тукталышында Фидая белән бергә мин дә төштем һәм аны әнисе йорты уңаена озатып куйдым.

Моннан соң да Фидая белән юлларыбыз туры килгәләде. Кыска вакытлы очрашуларда ул башыннан узганнарны өзәтөтә сөйләде — аңа килгән фаҗигаләрдә аны гаепләмәячәгемә акрынлап кына ышанды. Әмма хикәясен язмады ул.

Һәм мин, аның тасвир кысаларыннан чыкмаска тырышып, ләкин ул кинаяләп кенә узган хәлләрне үземчә күз алдына китереп, Фидая хикәясен яздым, бу язмамның алдагы өч өлеше — шул хезмәт.

Хикәяне Фидаягә укырга бирдем. Ул аксыл тышлы, шакмаклы шома битле дәфтәремне кулына алгач, аны ачарга ашыкмады, тышын беравык йомшак кына сыпырып утырды. Фидая моңарчы минем исемемне генә белә иде, дәфтәр тышындагы фамилиямне күргәч, бәлки, аптырыйрак калгандыр, минем хикәяләрне укыганын яки радиодан ишетүен, бәлки, хәтерләгәндер.

Фидая Гагарин урамы буендагы бакчада хикәяне укый калды.

Мин әйләнеп килгәндә, Фидая дәфтәрне тагын сыйпап утыра иде. Дәфтәрне сүзсез генә миңа сузды. Мин аның хөкемен көттем. Әмма ул эндәшмәде. Үзе тәфсилләмичә калдырган хәлләрне минем күзаллавымны дөрескә санадымы икән Фидая? Хикәядә катнашучыларның, заводның һәм шәһәрнең кайбер төшләре исемнәрен үзгәртүгә килешкәндер ул. Хәер, болары — awграк мәсьәлә...

Фидая урыныннан торды. Киемнәрен төзәткәләгәч:

— Күңелемне бушатырга кешесен тапканмын икән,— дип сизелер-сизелмәс кенә елмайды.— Мине аңлап тыңладыгыз. Рәхмәт. Китим инде мин. Әни көтәдер, соңладым бүген, борчыладыр. Әни... Мин аңа егерме ел буе әни дип эндәшмичә йөрдем бит, ә... Сантый мин... Әтине эзләп табасы иде, аңарга да минем ярдәмем кирәктер инде... Шәмсуарның әтиең белән, бәлки, хәзер табышырсыз, дигәненә егерме... егерме бер ел узган.

*1998*



# Кышкы чәчәкләр

Кыш саубуллашырга җыена. Төннең куе карасын елгыр таң бүген кичәгедән алдарак җуйдырды. Таңның көннән-көн иртәрәк уянып, җиң сызганып, көлемсерәп эшкә тотынуына карышмый кыш, шулай да аның гадәти кырыс йөзе моңсулана бара. Әнә, кояш көләчләнеп күтәрелә, аңа елмаймаска кыш инде әмер бирә алмый. Җил йомшак исә, аны дуамалландырырга кышның инде көче җитми. Ябалак кар анда-санда гына күренгәли, аны котырындырырга февраль ахыры кышының инде кулыннан килми.

Саура — Сәүрә, дип җиңеләйтеп-нечкәртеп әйткәнне яратмый ул, болай эндәшүче белән хәтта сөйләшми — елның шушы чагын Якын урман авызында дикъкатьләп күзәтте. Шушы хозурлык аның авышырга җыенучы аңын ачты.

— Ни кирәк булды икән миңа урманда? — дип үзалдына искәрде ул, ләкин моның сәбәбен барыбер тиз генә тапмады.

Якын урман белән авыл арасындагы атлыларны да, җәяүлеләрне дә тансыклап ямансылаучы юлда кичтән бирле йөренүенә Саура моңарчы игътибар итмәгән иде.

Юлда чана эзләре икәү генә икән, кемдер кичә урманга баргандыр йә күрше авылга йомышлагандыр. Юлның электәге чалуларын соңгы бураннар шыплап күмгән. Чана табаннары сызган эзләр арасында Сауралың төнозын йөренүеннән дә сукмак төшеп җитмәгән. Шулай инде — кеше тормышта күп нәрсәгә өлгермичә кала...

Кылынасы кылынмау, тормыш рәхәтлекләрен татырга өлгермәү турындагы уйларга барып җиту Сауралы аңына-акылына тоташлый кайтарды.

— Раббым ла! — дип ялварып карады ул кышкы дәү кояшка.— Шашынып алганмын лабаса мин...

Саура, бөтен гәүдәсе дерелдәп куркынып торгач, баскан төшеннән үк йөгереп кузгалды, үзәнлектән күтәрелеп, тәбәнәк үр түбәсенә җиткәч кенә адымлауга күчте — авыл якын ук иде инде.

— Раббым ла! — дип кабатлады Саура.— Шашуым шуның белән бетә генә күрсен... Берүк акылдан яздырмагыз мине, кешеләр... Ышанычгыз миңа, кешеләр, беркайчан да гөнаһ кылмам... Акылымда калыймчы... Минем Әсләхем бар иде бит, аның истәлеге өчен генә акылымда яшимче... Әсләхетдинем, әйдәче, икәүләп телик...

Саура кулындагы вак чыбыкларны хәзер генә күреп, аларга сәерсенеп карап торды. Урман буенда корыган чыбыкларны чәчәк бәйләменә охшатып тезүе исенә төште аның. Учма-бәйләмне ташламады ул, өенә кергәч, озынчарак чүлмәккә, таррак муенына җиткәнче җылымса су салып, таратып утыртты. Чәй куймакчы булды, ләкин чиләктәге су чәйнек төбен генә капларлык иде. Сыңар чиләк тотып, капка төбендәге колонкадан су алырга чыкты, ләкин суны аннан агызмады, ярым айдай ачык изүен учы белән каплап, чишмәгә йөгерде.

Чәй куймады, сусыны басылган иде. Тәненә салкын йөгереп өлгергән икән, урындык башындагы йонлач фуфайкасын кигәч, көзге каршында аны тәненә сыландырып сыйпаштырды. Яндагы ике тәрәзә арасына алга авыш итеп эленгән ай уемлы көзге Сауранын исенә эти-әнисен төшерде. Алар, язгы эшләр башланганчы дип, читтә яшәүче балаларын — Сауранын абыйапаларын күрергә киткәннәр иде.

— Әсләхетдинне озатырга кайтып җитмәделәр шул,— дип тагын үзалдына сөйләнергә керешә Саура.— Күрмәүләре әйбәтрәктер дә але... Ничек алай булсын ди инде? Әни гел дә үз малаедай итә иде бит Әсләхне... Кияве итеп саный иде инде ул аны... Әни күз яшен җыеп бетерә алмас инде... Бигрәк тә нечкә күңелле инде безнең әни...— Сыер мөгрәве ишетелде.— Абау ла,— дип куркынып ук куйды ул,— мин малларны карамаганмын бит...

Саура сарыкларны һәм сыерны, урманнан кайтуга ук, лапаска чыгарган иде, аларга терлек өеннән ташып туйганчы талык су эчергән, алларына мул итеп печән салган иде инде, ә сыерны савасы юк иде, ташлануына атна гына узган але.

— Караганмын икән,— диде ул һәм өенә керде.

Ашыгып көзге каршына барып басты. Көзге белән сөйләшәсе сүзе бетмәгән кебек иде, әкәмәт. Әллә көзгедәге үзен серләшергә ахирие итеп белде тагын...

— Безгә мирас булган әйберләрнең берсе, ди эти сине, җыйнак көзгем. Әйе шул, этинең әнисе — әби алдырган булган

аны. Ялтыравыгыңның кечтек кенә дә купкан төше юк. Менә бу аскы почмагындагы мөһер-тамгаң гына коелып бетеп бара... Ачуыгыз купса, кемгәдер үпкәләсәгез, үзегезне көзгедән карагыз, дип өйрәттеләр безне әни белән әти. Турсайган авызыгызны, җимерелгән йөзегезне күреп, үзегез үк оялырсыз, дия әни... Ә башыңны кайгы басса? Мондый чакта көзге белән киңәшергә яравын-ярамавын әти дә, әни дә әйтмәде шул... Безнең беркайчан да кайгыга батмаячагыбызга ышандылар инде әллә...

Көзгедән сылу гәүдәле, озынчарак йөзле, түгәрәк якты маңгаен бизәүче кара миңле, дулкын-дулкын карасу чәчле Саура кара күзләрен тегәп карый иде. Әллә ул көзгедәге шәүлә-күләгәсе киңәш бирер дип өметләнеп карый идеме?.. Саураның йөзен явыз сөрем каплады, дөньяны туздырып ташларга тели идедер бу дәһшәтле сөрем-болыт...

— Көзге ялгыш күрсәтәме, әллә йөземне, чыннан да, ямьсезлек җимердеме?..— дип коты очты аның, битен-маңгаен яскаңып ышкыды.— Әнә, әнә, бетте, бетте зәһәр сөрем-болыт! Шөкер, шөкер! Җитте, җитте, туктыйм авыр уйларымнан... Кайгыга бирелсәң, әни әйткәндәй, котанайга әверелерсең, убырлы карчык булырсың да калырсың...

Ул тагын көзгегә текәлде. Карашы сул кулының атсыз бармагындагы йөзегенең якты кашына җитеп туктады.

— Әсләх бүләге... Кулыңны да, күңелеңне дә тагын да нурландырсын шушы йөзек, дигән иде, бәгырькәем... Исемнән дә чыккан... Хәзер... Хәзерендә табабыз без аны... аларны! — диде дә, комодта актарынып, кулына ике кечкенә катыргы тартма алды Саура.— Балдакларыбыз... Җаныйларым ла... Алдан хәстәрлик, мин кайтуга туй ясыйбыз бит, дигән иде Әсләхетдинем... Монысы — аныкы, бармагына бик тә таман иде... монысы — минеке, миңа бигрәк тә килешлесен сайлады Әсләхетдинем...

Саура көзге каршына урындык тартып утырды. Озак кына вакыт узды.

— Менә сиңа туй...

Төш якынлашты.

— Иртәгә әтиләр кайтасы, өйне җыештырыйм әле...

Дымсу чүпрәк алып, иң элек түрдәге комод өстен сөртте, бая, балдаклар алганда, шунда тузан кунганын искәргән иде.

— Язмыш... Тузан... Әй лә, башка тагын әллә ниткән уйлар килә... Кеше... Тузан...— Шул сүзләрне алмаш-тилмәш кабатлый торгач, Саураның уйлары: — Кешене тузан бөртегенә дә күрми хәзерге ил башлыклары...— дигән көтелмәгән нәтиҗәгә барып чыкты.— Кеше кадере... Кеше кадерен...— диде дә туктады.

Аңы-акылы тагын чияләй төйнәлә инде әллә?!

Якын урман буеннан кайтуына Саура янына кемнәрдер килеп хәл белештеләр, бетерешмәскә киңәш иттеләр. Ләкин бу визитлар аның хәтеренә урнашмады. Изге теләктәге күршеләренең, хезмәттәшләренең һәм туган-тумачаларының үгет-нәсихәтләрен карусыз тыңлады ул, әмма берсенә дә кайтарып сүз әйтмәде, аларга игътибар итмәстән, бер үк сүзләрне кабатлыйкабатлый җырлады да җырлады. Акылы ныгыган чакларда да аңа өйдә үзе генә кебек тоелды. Тик ара-тирә генә, бик сирәк кенә... Әсләхе-Әсләхетдине белән сөйләшкәләде.

— Әсләх, дим, мин бүген эш калдырам булдымыни инде? Ярамас бит. Эшкә килмәссең, диделәр дә бит, килешмәс бит. Син ял итеп ал. Мин эштә озак юанмам, күренермен дә кайтырмын...

Әмма Саура эшенә туры бармады. Аның урманга таба йөгерүен күрүчеләр булды, тик берәү дә аны куып җитә алмас иде, җилдәй очты Саура.

Хуҗалык бухгалтериясенә — эшенә — Якын урман буеннан әйләнеп кайтышлый керде ул. Мамык шәле артка шуып төшкән, кыска тунының изүе чишелгән иде.

— Кызлар, дим, кызлар! Чәчәкләр алып кайттым үзегезгә! Менә. Һәркайсыгызга берәрне генә бирәм, яме. Үпкәләмәгез, яме. Әй, сез миңа үпкәләмисез лә! Әсләхетдинем дә үпкәләми миңа... Кызлар, дим, менә нинди матур чәчәкләр, име...

Саура урман буенда җыйган чыбыкларны хезмәттәшләренә берәмтекләп өләште. Кайсыдыр район үзәге ягыннан «ашыгыч ярдәм» машинасы килүен искәртеп пышылдады. Әмма Саура моны ишетте, машина килүенең үзенә кагылышлы булубулмавы аның өчен әһәмиятле түгел иде.

— Килсә соң! Килер дә китәр! — диде Саура һәм бер үк сүзләрне кабатлап җырлый-җырлый чыгып та йөгерде:

> ...шулай да
> Кайтырсың шикелле тоела...

Зиратка ашыкты Саура. Ләкин зиратка кермәде ул — хатын-кызга монда аяк басарга ярамый. Яңа кабер рәшәткә кырыенда иде. Саура Якын урман буеннан алып кайткан бериш чыбыкларны — чәчәкләр бәйләмен төптән тигезләп, кулъяулыгы белән кысып бәйләгән иде. Шул бәйләмне — кышның хушлашу чәчәкләрен — рәшәткә аркылы кызгылт кабер өстенә ыргытты. Бәйләм кабернең түбәсенә барып төште. Саура кулларын әйләндергәләп карады. Сул кулының атсыз бармагындагы кашлы йөзеге якты чәчә, уң кулының атсыз бармагындагы балдак — Әсләхе-Әсләхетдине аңа атап-сайлап алган балдак — кояшның соңгы нурларын тотып алып, ялтырый иде. Ә Әсләхенә-Әсләхетдиненә туй алдыннан үзе сөенеп киертәсе балдакны, бүтән бармакларына буш булгач, уң кулының баш

бармагына киеп йөри иде Саура. Бәйләмне ыргытканда, Әсләхе-Әсләхетдине балдагы, бармагыннан шуып чыгып, кабер өстенә барып төшкән икән...

Әйләнәсендә кешеләр дә йөргән кебек тоела Саурага, алар Әсләхен-Әсләхетдинен җирләгәннән бирле аның яныннан адым да китмәделәр кебек. Әллә Саура соңгы тәүлек буе япа-ялгызы булдымы — шулай да кебек тоела аңа...

Саура өенә кайтты, ишектән аның белән бергә күп-күп кешеләр дә кергәндәй тоелды, алар мыдыр-мыдыр сөйләшәләр дә кебек. Әллә инде капка төбендә ят машина тора...

Кыска туны бусаганы атлауга ук үзе салынып төште. Саура көзге каршына барып басты.

Көзгедән ак чәчле, сырлы маңгайлы, кәкрәеп төшкән авызлы, батынкы күзле, җыерчыклар киртләчләгән йөзле әби карый иде.

Саура аны түгәрәк һәм якты маңгаен бизәүче кара миңле, дулкын-дулкын карасу чәчле, кара күзле кыз итеп күрә, Әсләхе-Әсләхетдине исән чагындагыча итеп күрә иде.

Һәм, өй эчен тутырып, Сауранын җыры яңгырады:

...шулай да
Кайтырсың шикелле тоела...
...шулай да
Кайтырсың шикелле тоела...

Сауранын әфган сугышында һәлак булган Әсләхен-Әсләхетдинен җирләгәннән соң, аның Якын урман юлында төнозын йөренүеннән соң күп вакыт узды. Хәзер кыз өйдән чыкмый диярлек, күркәм көннәрдә дә ихата чиген атлап узмый. Аның төп урыны — көзге каршында.

Көзгедән исә ак чәчле, сырлы маңгайлы, ияген әйләндереп алырга теләгәндәй кәкрәеп төшкән авызлы, батынкы тонык күзле, җыерчыклар киртләчләгән борынгы йөзле котанай сыман әби карый.

Саура аны шома һәм якты маңгаен бизәүче кара миңле, дулкын-дулкын карасу чәчле, кара күзле кыз итеп күрә. Шуңадыр көзге каршыннан көнозын кузгалмый ул. Ярый әле Сауранын әбисе шундый әйбәт көзге алдыра белгән...

Әсләхе-Әсләхетдине ара-тирә аркасыннан сөйгәндә генә карашын егетенә төби ул. Аннары тагын җырын башлый Саура туташ:

...шулай да
Кайтырсың шикелле тоела...

*1998*

# Әманәт

Өченче ел бәрәңге казып бетергән көнне кичен Габдияр картның сул күзе бәбәге тәмамынча томаланды. Йорт-нигезне хәлдә тотучы төпчек улы белән килене каршы төшсәләр дә, тыңламады карт — көченнән килгәнчә бәрәңге чүпләште. Оныклары җитезлегенә тиңләшә алмаячагына сөенде ул — шөкер, көч салып эшләргә өйрәнәләр балалар.

— Сезнең чиләкләрегез чөмәләкәй тулганда, минекенең төбе капланып ук бетә,— дип шаяртты Габдияр. Ә бәрәңге төбен каерып куптарып, селтәбрәк чәчүче улы белән киленен: — Тыймагыз,— дип, йомшак, әмма кире каккысыз кисәтте.— Бала чагыма кайтыймчы...

Бәлки, иелеп бәрәңге чүпләү дөм сукырайткандыр Габдиярны. Ләкин күрмәве сәбәбен моңа сылтамады, бала чагына алып кайткан шөгыльне гаепләүне гөнаһ санады карт.

— Вакыты җиткән,— дип, улы белән килененең шелтәләвен иплән тыйды Габдияр.— Тәндә җан барында шушылай яшәрмен.— Уйланып торгач: — Яшәрбез,— дип төзәтте.— Сез мине нинди хәлемдә дә имгәккә санамаячаксыз. Тик...— диде дә, кирәкмәс тарафка борыла башлавын абайлап, сүзен йотты.

Улы белән килене, ниндидер хәлнең яшерелеп торуын искәрсәләр дә, бу хакта сорамадылар, тиеш санаса, әти-әткәйнең үзе әйтеренә ышаналар иде алар — кадерле кешене беркайчан да нәрсәгә дә булса мәҗбүр итәргә ярамый, аның җаен һәрчак җайлау үзе мәҗбүри ич.

Габдиярның уң күзе исә моннан биш ел элек сукырайган иде. Вакытында операция ясаучы кыстауларга ул:

— Күпме вакыт якты дөньяны күрергә язган — шул кадәресен күрермен,— дип каршы төште.— Тәнгә пычак тидертмәм, дигән сүзем булды бала чагымда. Кешеләргә һәм дә үзеңә үзең биргән сүзеңдә тору тиеш. Ант, вәгъдә һәм әманәт — алар иш.

Күрмәс булгач, Габдиярның ерак дигән сәфәрләре капка төбендә чикләнде, явымсыз чакта шунда чыгып утырды ул. Узган-барган кешеләр белән хәл-әхвәл белешеп әңгәмәләшү авылдашларыннан ерагайтмыйча тотты, түшәккә буйсынудан коткарды аны.

Җир туңды, хәйран ук ныгытты, шулай да кар төшәргә ашыкмый иде. Көннәр аяз торды, тик такыр сукмакларны лыҗырдатырга кояшның куәте җитми иде инде. Шундый чакта — көз белән кыш алышынганда — басу-кырларда турыдан кистереп йөрергә, урманга менгәләргә ярата иде Габдияр. Бу гадәте бала чагыннан ук килә. Шуңа күрә авылда аның мондый сәфәрләренә гаҗәпләнмиләр.

Әгәр:

— Инде урманына мен дә ди, ә менә басу буйлап титаклауның ни кызыгын табасың? — дисәләр:

— Басуның үз матурлыгы, ә урман шулай ук бүтән,— дияр иде ул.

Ярый ла йөреп калган, хәзер менә ни теләсә дә капка төбеннән уза алмый.

Беркөнне, улы белән килене эшкә киткәч, оныклары мәктәпкә йөгергәч, Габдияр, инде гадәтенчә, капка төбенә чыгып утырды. Әмма аның янына бу көндә, гадәттәгечә, башлап авылдашлары тукталмады, узучы-китүче нигәдер булмады. Ә бер көчек аның аякларына йомшак чинап сырпаланды.

— Син, яшьтәш,— дип эндәште аңа сукыр карт,— нигә болай соңардың соң әле? Эт кавемнәре кышка карап балаламый иде бугай. Бар, үз юлыңда булчы. Анаңа сыен.

Ләкин көчек китмәде. Габдиярның аяклары арасына керде дә, бәләкәй башын арткарак яшереп, алгы аякларын картның киез итекләре өстенә уңлап-суллап салды. Гомерендә эт асрамаган-тотмаган Габдияр көчекне куып җибәрмәкче иде, тик аякларын кымшата башлауга ук көчекнең йомшак чинавы аны мондый миһербансызлыктан тыйды. Агаем, мин сиңа кирәгрәк, дигән кебек тоелды көчекнең үз итеп тавыш бирүе, шул йомшак чинау, чын әгәр, буйсындырды да куйды картны. Һәм ул көчекне алдына утыртты, аны башыннан һәм сыртыннан сыйпаштырды.

— Йомгак хәтле генә икәнсең син. Нәселең шундый кечкенәдәнме? Шаять, шулайдыр.

Көчеккә шушы илтифат җитә калдыдыр, ул Габдиярның күкрәгеннән югарыга җитез үрмәләде дә картның шома битенә — улы этисенең битен иртән әйбәтләп кырган, сакал-мыегын кыскарткан иде — юеш борынын тидереп алды. Мондый кыюлыкка карт ачуланмады, шулай да кайбер теләкләрен шелтәсез генә искәртте — кеше белән сөйләшә диярсең, әй.

— Базымчан икәнсең,— дип дерелтәнә башлаган көчекне пәлтә изүен чишеп җылыга кертте ул.— Вәләкин бер-беребезне бимазаламаска сүз куешыйк. Кыек-кыеш гамәлләр кылмыйк. Фәһемле булырсың, яме, сезнең эт халкына да зирәклек бик кирәк. Минем белән дуслашырга теләсәң, иренчәклекне бөтенләй дә белмә. Их-х, икәүләп ерак-еракларга сәфәрләр кылырбыз әле...

Көчек тагын йомшак тавыш бирде, әллә ризалашуын белдерүе булды тагын.

— Кем соң әле син — иркәкме, инәкме? Җенесең нинди, дим. Шулаймы... Әмма ки тагын бер хакта элгәредән килешик — беркайчан да текә кыланмаска, менә бу юеш борыныңны чөймәскә, дим. Исемең юктыр әле синең. Нинди исем кушыйк соң сиңа, ә?

Габдияр көчекнең башыннан озаклап сыйпады, көчек, хуҗалы булу сөенеченнәндер, картның тонык күзләреннән карашын алмаска тырышты, әллә аның күрмәвен сизеп, моңа гаҗәпләнүе булды тагын.

— Сине тышта калдырып булмый. Керик соң өйгә. Бүтән хуҗаларың кайтканчы, сине өй эче белән таныштырыйм. Ә-ә, исем тапмадык бит әле сиңа йомшакҗан. Туктале, менә исемең дә булды ич — Йомшакҗан!

...Бу вакыйгадан соң ике кыш та бер җәй узды. Эт, Габдияр аны беренче иркәләвендә сиземләвенчә, тәбәнәкләр нәселеннән икән, карт аңа хәзер дә кайчакта Йомгак дип эндәшкәли. Йомшакҗан бу исеменә дә ияләште, хуҗасының төрлечә атавына да күнде. Тик баштарак аңа муенчагы ошап җитмәде, аны салып ташларга тырышкалап карады. Карт муенчакка озын каеш эләктереп, аны бушатмыйча тартып йөри башлагач, бәйне артыкка санамады тагын, хуҗасын әйдәләү бурычы үзенә йөкләнүен аңладыдыр.

Алар — Габдияр белән Йомшакҗан — баштарак авыл урамнары буйлап кына йөрделәр. Карт, борыласы тирәне алданрак чамалап, этне, иелеп, шул ягына чыгарды. Йомшакҗан моның сәбәбен баштарак төшенмәде, әмма мондый боеруларны хәтеренә сеңдерә алды. Шуннан соң картка эт ышанычлы кулавыз булды.

Җәен алар басу юлларына чыккаладылар, урманга да баргаладылар. Соңгыларында Габдиярның оныклары аларга баштарак ярдәм иттеләр. Беренче тапкыр урманга менгәч, оныкларына карт:

— Урманчының ташландык ихатасы урынын узгач ук юллар кисешәдер,— дигән иде.— Шуннан уңга каерылырбыз.— Һәм, борылып туксан адымнар чамасы киткәч (Габдияр бу санны, сукырайгач, адымнарым кечерәйде, дип, йөз унга җиткерде): — Авыл ягында юан каен күренәдер, аның кәүсәсендә, шулай ук авыл ягында, зур оры бардыр,— дип аңлаткан иде.— Шул тирәдә ял итеп алырбыз. Чәйләрбез, термоска чәй тутырдыгыз ич.

Каен төбендә утырганда да Габдияр, оныклары эт белән куышып уйнарга теләсәләр дә, Йомшакҗанның бәен кулыннан ычкындырмады. Каен төбенең җирдән кыйгач күтәрелгән юантык тамырлары арасының ниндилеген күңеленә сеңдерергә тырышып капшап утырырга онытмады карт.

— Шул тирәдә юан тупыл да бардыр,— дип, әңгәмәгә катышсыз рәвештә кыстырды Габдияр.— Кисмәгән булсалар.

Кисмәгәннәр икән тупылны. Оныклары шуның янына таба йөгергәч, эт тә алар артыннан тартылды, әмма олы хуҗасының сак-салмак атлавына җайлашырга мәҗбүр булды — Габдиярга адымнарын санарга кирәклеген Йомшакҗан белә алмый лабаса.

Бу сәфәр узган җәй башындарак булган иде. Кыш кергәнче, атнага кимендә бер тапкыр менделәр урманга Габдияр белән Йомшакҗан.

Һәм менә күрмәс карт белән кулавыз эт бергәләп икенче җәйне каршылыйлар. Урманга быелгы сәфәрләр майның унҗиденче көнендә — юллар кипшереп җиткәч башланды. Көннәр явымсыз торды, һәм карт белән эт урман юлын көн саен таптадылар. Моңа Габдиярны инде Йомшакҗан кыстый иде кебек, аның иртәнге чәйләп алуын ул тупсага утырып көтәргә, хуҗасын ара-тирә йомшак чинап ашыктырырга гадәтләнде. Әмма хуҗасы киенеп-әзерләнеп беткәч кенә, ишек яңагы янындагы тәбәнәк чөйдән каеш-муенчакны, алгы аякларын ниргәләр арасына куеп, тешләп алыр булды.

Бүген көн кояшлы. Урман кичәгедән дә бизәлебрәк каршылар аларны, шулай вакыт һәм табигать дигәннәрең үз кануннарын нык тоталар. Бүген — җәйнең беренче көнендә — вакыт вә табигать изге карт белән аның гөнаһсыз этен, яшәү бәхетенә чумдырып, сихри-бай урманда рәхәтләндерерләр.

Киттеләр. Күрмәс Габдияр һәм кулавыз Йомшакҗан.

Урманга җитәләр булыр — карт шулай чамалады. Эт тартылып баруын кинәт акрынайтты — картның кулына элмәкләп киертелгән каеш бушады.

— Ни булды, Йомшакҗан?

Эт теш арасыннан гына йомшак чинады. Алар туктамадылар. Ләкин карт кипшермәстән тәгәрмәч изгән эз кырыена сөртенде.

— Йомшакҗан, юлдан тайпыласың бугай. Ни бар? Урманга җиттектер.

Ләкин эт тавыш бирмәде, тукталып калган картның аяклары арасына кереп посты. Тик хуҗасының каршына кинәт чыкты да озын халаты итәкләрен тырнарга тотынды. Беренче очрашуда ук Йомшакҗанның Габдияр куенында рәхәтләнүе күңеленә сеңеп калгандыр, ул үсеп җиткәч тә шулай иркәләнергә ярата иде. Әмма бу юлы куенга керергә теләве рәхәт кыласы килүдән түгел иде кебек, кабаланып һәм катырак итеп тырный иде Йомшакҗан-Йомгак.

— Здравствуй... исәнме...абз...бабай...

Габдияр, тавышлану-фәлән, хәтта кыштырдау ишетелмәсә дә, тирә-юньдә җан иясе булуын Йомшакҗанның үзен тотышыннан әллә соң ерткыч җанвар сагалыймы безне, дип юраган иде. Мондый чуар сәламләүне һич тә көтмәгән иде ул. Өстәвенә эндәшүченең сүзләре генә түгел, ә тавышы да ала-кола иде — ни ир заты, ни хатын-кыз тавышы шунда, шулай да хатыннар тавышына тартымрак иде.

Малай чактан ук юлдашы — кул таягы белән җиргә төрткәләп алгач кына карт:

— Хәзергесенә шөкер,— диде.— Алай... Искәрмәстән булды исәнлек соравың. Поскан ояңнан атылып чыктың кебек. Кем...

— Кто мин — потом әйтә. Син Габ... Габдияр будешь?

Юлларында очраучының хатын-кыз булуына шиге калмады картның, тамак кыру ирләрчә түгел иде урман авызында көтеп торучының. Сәер сөйләшүче хатынны эре гәүдәле, кайсыбер ирләрне бөтәрләп салырдай көчкә ия, кырык яшьләр тирәсендәге кеше итеп күз алдына китерде ул. Үткен күзләре тирәнгә кереп утырган, йөзе исә кызгылт булып тоелды аңа. Боларын дөрес чамалады Габдияр. Ә ничек киенгән? Башында артка бәйләгән бизәкле яулыкмы? Киң итәкле күлмәге аяк йөзләренә җитәме? Бала итәкле ак алъяпкычтанмы? Боларында ялгышты карт. Хатынның башында берет, өстендә күн пинжәк иде. Киҗе-мамыктан тегелгән кара чалбарын бот тубыклары аерып җибәрер кебек иде.

— Нигә ответ бирмисең?

Карт ияген сыпырды, карчыгы басып биргән (һәм аның каderле бер төсе булып калган) ак тула эшләпәсен арткарак этәрде дә маңгаен ышкыштырды. Куенында ара-тирә чинапшыңшып куйгалаучы Йомшакҗанны эчкәрәк кертте. Башлап эткә эндәште.

— Гаҗәбрәк әле хәлләр, Йомшакҗан. Бездән сорау алмакчылар.— Шуннан соң башын хатын тавышы килгән якка күтәрде. Күзләре күрсә, ул хатынның карашындагы ашкыну галәмәтен һичшиксез сизәр иде.— Шуннан, фаразан, мин Габдияр булам, ди. Шуннан ни була икән инде?

— Минем исем — Нифака.

— Мондый исемне беренче ишетәм. Вә сине дә белмим.

— Фәйсалны знал?

Габдияр сискәнде, гәүдәсе калтыранды, бу калтырануда куркыну да, өстән күптәнге йөк төшәчәгенә өметләнү дә бар иде. Шулай да карт җавап кайтарырга ашыкмады. Йомшакҗанны җиргә төшермәкче булды, ләкин эт тырнакларын хуҗасының киемнәренә батырып карышты, кулавызлык вазифасын үтәргә теләмәде. Карт, таягын сузып суккалап, юл уртасынарак чыкты.

— Җитәсе төшкә җитик без, Йомшакҗан.

Габдиярның үзен тотышын илтифатсызлык буларак кабул итте Нифака исемле хатын. Хәтта хәйран саллы йодрыгы йомарланды — хатын-кызга хас түгел хәл, әкәмәт.

— Зналмы син Фәйсалны?! Минеке этине?

— Сөйләшүең элмә-телмә, тотар төше калмаган, теткәләнгән нәмәрсәкәйнең нәкъ үзе.

— Фәйсалны зналмы?

— Вафатмыни Фәйсал? Яшьтәш иде. Урыны җәннәттә булсын. Миңа да вакыт җитәдер...

Утызынчы елның язгы чәчүе беткән чак иде. Фәйсаллар гаиләсен авылдан сөрделәр. Кулаклар тамгасы сугылды аларга. Соңгысы хаклыдыр да, чөнки алар авылның иң бай кешеләре, хәтта череп баеган кешеләре иде. Йорт-җир тазаның тазасы, рәеш киемнәре гел дә затлыдан, табынга кунак сые көн дә тезелә, Фәйсалның этисе тарантаска яки кошевкага күк юртак җигә. Кулак дәрәҗәсен билгеләргә шушылар җитеп ашкандыр, күрәсең. Анысы Габдиярлар да ярлылардан түгел иде, һәммәсе дә җитеш иде. Ә аларны сөрмәделәр, урта хәллегә санадылар, алар колхозга кереп өлгергәннәр иде.

Фәйсалның этисе, сөрелү алдыннан, Габдияр исемле күрше малаена бер үтенечен әйткән иде.

— Син төптән нык чыккан, озак яшәрсең,— дигән иде ул.— Сугыш чыга калса да, сугышка алмаячаклар сине. Аксаклыгың мондый афәткә керүдән коткарыр. Фәйсал улым белән икегез мин биргән әйберне урманның үзегез сайлаган төшенә илтеп күмегез. Урынны онытмас өчен, тупыл чыбыгы алып барып кадарсыз. Тупыл тамырны тиз җәя, озын гомерле була. Тик Фәйсал кайткач кына казып алырсыз хәзинәне. Инде дә килеп үзе кайтмаса, варисларыннан берәрсе кайтыр. Вәләкин хәзинә турында берәүгә дә беркайчан да әйтмә. Әманәтем шундый сиңа. Вәгъдәме?

— Ә... ә... яра күргән аяк мине озак яшәтмәсә?

— Савыкты бит аягың, чатанлыгың гына саулыгыңа зыян итмәс. Антмы?

— Ант!

...Габдияр, өй түбәсеннән кар көрәгәндә егылып төшеп, уң аягын сындырган иде, шул сынык ялгыш ялганды да аягы кәкрәеп калды. Өстәвенә шул ук аягына зуп-зур шеш чыкты да шул тишелеп агып йөдәтте. Тимер юл стансасындагы больнистә духтыр шешнең авызын, терeләй ярып зурайтып, чокыйчокый чистарткан иде. Шуннан соң тәненә пычак тиюдән куркып яшәде Габдияр, күзләренә шуңа күрә операция ясатмады.

Фәйсалның кызы — Нифака исемле хатын — аксак һәм сукыр Габдиярдан әлеге хәзинәнең кайда күмелүен күрсәттермәкче икән. Әманәтне үтәргә вакыт җиткән икән. Риза соң моңа Габдияр, бик теләп риза. Югыйсә гомер кояшы тиздән баеп куюы ихтимал...

— Шулай да хәзинә нәрсәгә салынган соң? — диде Габдияр, ачыклауда-ышануда соңгы соравына җитте.

— Горшокта!

— Шулай да сөйләшүеңнең рәте-башы юк. Чүлмәктә, диген. Надан!

— Чүлмәктә.

— Шулай да аның эчендә нәрсәләр бар?

— Богатство!

— Тагын? Тыныч булчы, Йомшакҗан. Әманәтне үтибез бит.

— Молчи, Хилда! — дип этне ачуланды Нифака.— Син генә не хватал!

— Хилдасы ни була тагын?

— Ошибка... Мин үз собакасы исеме әйткән.

— Чүлмәктә ниләр бар?

— Сказала же. Алтын!

— Монысын беләм. Тагын нәрсә? Шунысын мин тәгаен белмим.

— А-а, совсем оныткан. Записка. Аны от имени бабая эти написал. Латинским шрифтом.

— Нигә авылдан эзләмәдең мине?

— Эти рассказыннан бу местоны нашла. Сине вчера монда видела. Зачем авылга? Сине бүген здесь ждала. Ышанды, что придешь.

Тупыл белән каенның орлы ягы арасындагы урталыкта иде хәзинә. Ярты метр чамасы гына күмелгән икән. Карт шул тирәләрдә кәсләрнең купкалавын абайлаган кебек булды. Бу хатын монда актарынган, ахрысы, дип уйлады ул, ләкин бу хакта сүз кузгатмады.

Нифака чүлмәкнең авызын каплаган калайны ачты, чүлмәк карындыкка төрелгән алтын кисәкләре белән тулы иде. Димәк, чүлмәкне ачып караучы булмаган, шунысы куандырды хатынны.

— Язуын укы.

— Записканы? — Нифака язуны озаклап укыды, тануы шуның хәтле булуы өстенә, эчтәлекне элгәре үзенең беләсе килә иде.— «Зур такта чәй ише сигез кисәк монда».— Хатын аларны берәмтекләп санады.— Все бар. Рәхмәт. «Әманәт...» — диде дә укуыннан туктады.

Нифака язудагы «Әманәт үтәүчегә бер өлеше тиешле» дигән сүзләрне укып бетермәде.

Нифака Габдиярны урман авызынача озатырга булды.

— Моннан йөрми идек без.

— Моннан прямо.

— Монда текә ярлы корган елга бардыр.

— Вон әнә там ул.

— Шөкер, әманәтне үтәдем. Офтанычта калмады...— Эт кинәт әрнеп өреп җибәрде.— Нишләвең, Йомшакҗан? Тыныч...

Габдияр сүзен әйтеп бетерә алмады, көчле куллар аны, дуамал төртеп, ярдан очырдылар. Ул елга төбендәге наратка элгәре башы белән бәрелде, аннары күкрәге белән сыланды. Куеныңдагы Йомшакҗан шулай ук...

*1999*

# Тәкать

Менә өченче ел инде Саримә һәр айның бер атнасын төптөгәл Васияләргә килеп яши. Ире Ислахның эчүгә сабышкан чагы була бу.

Васия аны гел:

— Килдеңме, балакай,— дип каршылый, хәтта беренче очрашуларында ук шулай үз итеп эндәшкән иде ул.

Сариманең дә сүзләре үзгәрми:

— Каялар гына барыйм соң бүтән. Мин сезгә генә сыена алам. Аннары бит башка берәүгә дә сыенырга теләмим...

— Аптыраган инде синең белән. Аның һәм синең белән, балакай. Аптырамыш...

Васиянең Сариманәгә кечерәйтеп эндәшүендә кимсетү төсмере юк, ул үзен озын-зур гәүдәле булганга күрә генә орчык буе Сарималдән — яшьтәшеннән! — өлкәнрәккә саный. Сариманәгә ихластан ярдәм итәргә тели Васия. Сариманәгә бәхетне сатып алырга мөмкин булса, моның өчен соңгы тиенен дә чыгарып бирер иде.

Әйе, бәхет саф күңелле кешеләрне ярата. Соң Саримә дә шундый гөнаһсыз җан лабаса, шулай булгач, нигә соң шушы изге балакай бәхетсезлеккә тарыган? Юк, юк, үзгәрергә тиеш Сариманең ямьсез язмышы, бәхет гел дә юлдаш булачак әле аңа! Күрерсез дә торырсыз менә...

Саримә иренә кайтып яшәгән чакта да аңа рәхәт тормыш килеренә өметләнеп уйлана да Васия, теләге бәхет тавы түбәсенә менеп туктала — кояш балкуына тиң итеп елмаеп килеп керер бит әле Саримә Васиянең өенә! Күрерсез дә торырсыз менә...

Хет бер генә күз төшерегезче сез Сариманәгә — әнә нинди бит ул! Кыяфәте-килбәте килешле, ир заты сокланмыйча карый алмыйдыр аның гәүдә-сынына. Мул чәчләренең серле каралыгы дисеңме; йөзенең чиста-шомалыгы йомшак куллар иркәләвен көтә; кашлары иң оста рәссам рухланып уеп сызган кебек; коңгырт күзләренең тирәнлегенә акылы һәм үткен холкы янәшә сыйган. Кулына ни тотса, шуны ут уйната, эшне ирләрнекенә, хатын-кызларныкына бүлми. Өстәвенә гыйлем иясе үзе, институтны кызыл дипломга тәмамлаган, самолетлар төзү заводында төпле һәм үз фикерле инженер буларак санлашалар үзе белән. Һәрьяктан килгән шушы кешенең дә бәхете булмасын инде, йә...

Васия чибәрлектә үзен Сариманәгә тиң куймый, куеп та булмавын аңлый ул. Мондый албасты гәүдәне ни теләсәң дә яшерә алмыйсың шул. Йөзгә-биткә ямьсез үк түгел дә үзе, озын һәм калын толымнарын күкрәгенә салып, аяу күзләрен тутырып, йөзенә ихлас елмаю җәеп, моңга чумган тавышы белән

җыр башласа, аның горурлыгына сокланасың. Үзешчәннәр концертларында сәхнәгә чыгып баскач, күп ирләрнең күңелләре уйнаклап куядыр. Ул да төшеп калганнар исәбенә керми, якынаерга сүз катучылар, ишле үк булмаса да, бик тә җитәрлек.

Тик Васия ирләрнең ямьсез ишарәләрен ишетмәмешкә салына, гаилә кору турындагы сирәк тәкъдимнәренә ышанмый. Шулай булмыйча соң — бер тапкыр сынап карады бит, әмма аңа да эчкече ир язган булган икән. Йөрешкәндә шул адәмнең атна буена югалып торуын эше күплеккә юраган иде. Өйләнешүләренең беренче аенда ук моның сәбәбе хәмергә тартылу икәнлеген белгәч, аяз көндә яшен суккандай булды аны — атна буена айнымыйча бирәндәй эчә икән аның сөекле саналган сөяге. Аек вакытында фәрештәнең дә фәрештәсе инде менә, ә авызын хәмергә чылатуга, ахмакның да ахмагына әйләнә дә төшә, имансызның имансызы...

Тормышның шундый ямьсезлеген кичергән Васия шундый ук хәлгә тарыган Саримәне бәхетсезлектән йолырга тиеш булды — тормыш дигәнеңнең аңлашылып җитмәгән әкәмәтләре бар инде аның, бар...

Бу юлы — елның иң озын көннәренең берсенең ашыкмас кичке ягында — Васия Саримәне каршылау сүзләрен бераз үзгәртте:

— Кайттыңмы, балакай...

Мондый үз итүдән Саримә дә гадәти җавабын үзгәртергә мәҗбүр булды:

— Кайттым, Васиякәем! — Һәм хуҗа хатынның куенына барып сыенды, шунда югалып, күренер-күренмәс булып калды.— Рәхмәт инде сезгә, Васия, гел дә үз иттегез мине. Гел дә үз өемә кайткан кебек сизеп килгән идем бүген. Шуны күңелегез белән тойгансыз инде.— Һәм сөйләшү атналап бергә яшәгәндә күп тапкырлар, хәтта көненә берничә мәртәбә кабатланучы сүзләргә корылып китте.— Каялар гына барыйм соң бүтән?! Мин сезгә генә сыена алам...

— Шешәгә үрелүеннән туктамас микәнни?..

— Иптәшләре ишек төбенәчә кайтардылар. Хәстәрен дә күргән — башланмаган ике шешә аракысын түшенә кыскан.

— Шул шешәләре белән башын ярасы да бит, каһәрнең...

— Мин беркайчан да беркемгә дә кул күтәрмәячәкмен.

— Кулыңны уйнат, дип киңәш итүем түгел лә. Аптыраганнан әйтүем.

— Шешәләрен өстәлгә утырттым да ризыкларны җитәрлек куйдым. Ашамас. Аракысыннан соң ипи валчыгы гына капкалый бит. Шуннары чыктым да йөгердем сезгә. Бәйләнергә тотынганчы.

— Бәйләнергә маһирлыгы җитеп ашкан аның.

— Әй, салмыш баштан гына ла анысы.

— Аек чакта сусыз юып, җилсез киптерергә оста шул.

— Соңгы айларда, әйтәм ич, бигрәкләр ямьсез гадәткә ияләнде. Анадан тума чишендертә дә ишекле-түрле йөгереп йөрергә куша. Бүген алданрак чыгып качтым менә...

— Гадәте әйткесез. Тик синең сылулыгыңа соклануыдыр аның. Үзенчә.

— Шул да булдымы соклану?! Мин арып егылгач, азапларга тотына бит ул... Әй, исеректән нинди юньле эш булсын соң...

— Шулай инде, балакай, иреңнән уңмау — сыңар аякта басып тору ул. Мине сыңар аягым гына күтәрә алмый, шуңа күрә аерылдым. Син түзем, балакаем, сыңар аякта басып тору гына түгел, йөрмәкче буласың хәтта. Мин ике уйлап тормадым — тоттым да аерылдым. Син дә аерыл, дип әйтүем түгел, ләкин...

— Аерыла алмамдыр инде мин аңардан.

— Шулай, ашыкма. Уйла. Әбиләр киңәше сиңа ярыйдыр да булыр. Ничек дигәннәр әле безнең әбиләр? Тәкатьлегә тау баш игән, дигәннәр.

Әңгәмә шушы төшкә җиткәч, Саримә гадәттә аны бүтән якка бора — Васиядән гафу үтенә. Бу юлы да сүзләр үзгәрмәде, моны кабатлау Саримәгә кирәгрәк идедер.

— Васиякәем, сез мине берүк аңлый күрегез дә гафу гына итегез.

— Аңлыйм да кебек. Тик нәрсә өчен гафу итәргә тиешмен? Синең гаебең юк ич. Минем алда, дим. Мин үземә кагылышлы мәсьәләне үзем хәл итәм. Гел шулай. Шулай булыр да бу.

— Әмма, Васиякәем...

— Җитте! Ешкынлыкның эченә үк керсәң, кирегә чигенеп чыгарга туры килмәгәе. Ә артка таба карап барып булмый.

— Әмма, Васиякәем, сезгә беренче килүем исемә төшә дә, гаепле саныйм үземне. Ничек килдем икән мин сезгә? Ничек сезгә киләсе иттем икән? Сездән башкага сыена алмавымны күңелем сизгәндер шул. Бусагадан атлатып кертмәсәгез дә, мине хурлап кире борсагыз да, акланырлык сүзем юк иде бит. Табаныгызны юарга әзер мин.

— Син балакайны үзем юындырам әле мин.

— Гаеплесен гаепле лә мин сезнең алда...

— Әйттем ич, минем язмышымда синең гаебең юк! Аннары, балакаем, адәм заты бер-берсен кимсетү өчен яшимени дөньяда?! Булмаганны! Күңелләрне берләштереп, җитәкләшеп йөрсәң дә, бик таманга килә бу заманда. Әйдә, чәеңне суытасың. Аша, нығытып аша. Озын-озак яшисең бар.

Әңгәмә шушы төшкә җиткәч, ишек катындагы урындыкка куелган күчтәнәчләре Саримәнең исенә төшә, үзе әйткәндәй, Васиякәен сыйлары белән куандырырга теләвен башы эшләмәүдән онытадыр, ахрысы, ул.

— Шундый инде мин, Васиякәем, кайчак түбәм тирбәлә бугай — зиһенем чуала. Мине чит итмәгәч, күчтәнәчләрне үзе-

гез алсагыз да була ич.— Һәм Саримә ризыкларын өстәлгә, ә кайберләрен суыткычка тезә.— Нервыларым да читкә караштыра кайчак.

— Мескенләнмә, яме! Эшләт башыңны! Ризыклар тутырмасаң да була иде. Бер сине генә бер атна ашатырлык кына хәзинәм юк мәллә минем?! Җитәрлек. Шөкер.

Чәйдән соң Васия Саримәне сабыйны иркәләгәндәй назлап юындыра. Саримә карышмый, Васиянең саллы кулларының йомшаклыгыннан рәхәтлек тоя, хәтта ара-тирә күзләрен йомып онытыла. Аннары Васия озын толымнарын башына урап, аларны чыландырмыйча коена. Һәм тагын чәй кайнатыла. Диванга һәм тахтага күперенке урыннар җәелә. Тик алар йокларга ашыкмыйлар. Саримә тахтага Васия янына килеп утыра да, аның биленнән узып юрган өстенә сузылган толымнарын сүтеп тарата, яшьтәшенең тыңлаучан чәчләрен озаклап тарап үрә.

— Үз чәчләрең кыска булса да, син чәчләрне миннән остарак үрәсең, балакай,— дип үсендерә Саримәне Васия.

— И-и, шулай дигән булыгыз инде...

— Дим шул! Дөресе шул. Балакай, әйдә, җырлыйк әле.

— Төн уртасы бит, Васиякәем.

— Булмагае! Кил монда, тәрәзәдән карыйк та тын гына җырлыйк. Күңел җырсыз түзми бит, балакаем.

— Күңел җырсыз яши алмый.

— Күңел — үзе җыр.

— Күңел хаҗәте — җыр.

— Күңелнең күрке дә — җыр, балакай.

Ниһаять, җыр тәмам. Тик алар һаман йокларга ашыкмыйлар, җәелгән урыннарына кара-каршы утыралар да әңгәмә тагын үз эзенә төшә. Ислах эчә башлаган атнасының беренче көне-төнендә ике яшьтәш хатын серләшүенең шушы тирәсендә, гадәттә, Саримә генә сөйли, Васия сүз кыстырмый диярлек.

— Сезнең йортлар янында, Васиякәем, карлыгачлар күп, име. Әле бүген дә, кичә кич инде, тукталып карап тордым шуларны. Парлашып очалар инде менә! Парлашып. Биек-биектән очалар. Аннары түбәнгәрәк төшәләр дә тагын югарыга күтәреләләр. Бәхетле парлашуларына сөенәләр инде. Нәсел калдыруларына шатланалар, име, Васиякәем. Бәхетле парлар...

Хуҗа хатын, яшьтәшенең матурлык күрүенә сөенеп, башын кагып хуплый. Саримә сөйләвендә кинәт бүтәнгә күчә.

— Васиякәем, беләсез бит инде, әйткәнем бар, мин гөлләр үстерәм. Безнең яктагы сирәк гөлләр. Ислах шуларга су сипсә ярый ла. Башка чакта корытмый иде гөлләремне. Үзе дә гөлләр ярата бит ул. Васиякәем, моннан соң сезнең белән очрашмый башласам, дим, әллә гөлләрне сезгә китереп куйыйммы, сезгә бөтенләйгә биримме икән, дим. Шулай итимче. Үзегез алып китсәгез, әйбәтрәк булыр иде. Үз кулларым белән бирергә көчем җитмәс йә. Сез ачуланмагыз, яме, мин боларны нәзер итеп әйтәм, яме.

Васия моны өнәмәвен сүзе белән дә, хәрәкәте белән дә сиздерми. Хупламавын бер ноктага озак кына текәлеп утыргач әйтә:

— Җебемә, яме! Башыңа тау төшмәгән. Җенем сөйми мескенләнүне! — дип, урыныннан кинәт кузгала да, ачуын тыяр өчен, кухняга ашыгып кереп китә. Аннан хуҗа хатынның: — Үзем гөл үстерә алмаслык мәллә мин,— дигән сүзләре ишетелә, тавышының инде йомшаруы сизелә.— Кирәк санасам, үстерермен. Тик гөлнең шау чәчәккә бизәлеп, соңыннан җаны кыелуы хәсрәтен күтәрә алмам кебек.— Саримә янына елмаеп чыкты Васия һәм бүген әңгәмәләрдә гадәттә кабатланмый торган сүзләр әйтте: — Син, балакаем, миннән нидер яшерәсең ич. Шулаймы?

Саримә коңгырт күзләрен шар ачты да Васиягә сөзеп карап торды, йөзенә салмак кына сөенечле елмаю җәелә барды, һәм ул хуҗа хатынның куенына атылды.

— Әйе...

— Юындырганда сиздем. Күпмелек?

— Ике ай... Шуңа күрә Ислах азаплый башлаганчы чыгып качтым. Салмыш чагында кулыма да кагылдырмыйм мин аны хәзер. Ислахтан бала үстерәсем бик тә килә минем, Васиякәем... Юлдан язмаган бит ул...

Васия Саримәне баладай итеп иркәләде, урынына баладай итеп җайлап яткырды, өстенә одеалны иплән япкач, аркасыннан тагын сөйде. Саримә карышмады. Тик аның йокларга исәбе юк иде, Васиянең күңелен китмәс өчен шактый вакыт селкенмичә ятты да, акрын гына торып, тәрәзә янына килде.

— Йокы керми, Васиякәем.

— Нинди йокы ди?! — дип, урыныннан кабаланып торды хуҗа хатын һәм Саримә янына барып басты.— Борчыла гына күрмә. Үзем әбиседәй булырмын улыгызның. Яле, карале миңа. Менә шулай. Әле, боерган булса, малаең белән кызыңны берьюлы алып кайтырсың.

— Абау, сез бигрәк инде... Васиякәем, нигә һаман таң атмый соң? Әллә ике төн көнсез генә бергә кушылдылармы икән?

— Җәйнең өч төне бергә кушылса да, кышның бер төненә тиңләшми. Сиңа гына озын тоела төн. Иреңне,— Ислахны исеме белән атамады Васия,— көткәнгә күрә шулай.

— Көтәсең, дип... Ә-ә, Ислахны әйтәм, гөлләргә су сибәргә онытмаса ярый инде, гөлләребезгә...

Таң атты.

Ишек кактылар.

Саримә аны очынып барып сорамыйча да ачты.

Әмма керүче күренмәде.

Васия дә ишек катына барып өлгерде.

Ишектән олы ук гәүдәле Ислах, йөзен аска яшереп, сүзсез керде. Өстендә сыек яшел төстәге рәеш костюмы иде. Башыннан җиңел эшләпәсен салды да яшьтәш хатыннарга бик тиз генә карап алды.

— Исәнме, Васия...

— Сәламеңне элгәре хәләлең Балакайга бир. Алса.

— Саримә, авырый гына күрмә. Мин... Мин... Эчмәдем мин бүген. Эчмәячәкмен моннан соң! Васия, син дә мине гафу ит. Мин сине дә күп җәфаладым...

— Мин җәфа чигеп тилмерә торганнардан түгел! Оныттым күптән. Әнә, Балакайны рәнҗетәсе булма! Бәбәй алып кайтырга җыена сиңа.

— Саримәм, чынмы?!

Балакай-Саримә йомшак кына ым какты, әле Ислахка, әле Васиягә карады, һәркайсына караган саен, аның зур коңгырт күзләреннән берәр генә бөртек яшь тәгәрәде.

— Әйе, Ислах... Васиякәем әйтә, кызың белән малаеңны берьюлы алып кайтырсың, ди...

— Ул... ул моны каян белә ди? Бәбәй тапмады бит Васия.

— Беләме-белмиме, анысы — синең эш түгел! Мин дә элекке Васия түгел, син белгән мәми Васия түгел. Ишетсен колагың, Саримә-Балакайны рәнҗетәсе булма! Югыйсә үзем үк күккә асып куярмын сине. Бергә яши калсам, күптән түшәмгә аскан булыр идем сине. Саримә-Балакайны тилмертсәң, сине шул мәлдә үк күк сагынып көтәр!

— Васия, сиңа кылган юньсезлекләрем өчен гафу ит мине... Саримәм, әйдә, кайтабыз.

Хуҗа хатын ишекне шартлатып бикләде.

— Беркая да китмисез! Бер атна минем белән яшисез! Мин синең Балакайның олылыгына соклануыңа үзем күреп торып инанырга тиешмен.— Васиянең эремәстәй күңеле кинәт йомшады.— Аннары... Бүтән сәбәбе дә бар — мин ай саен бер атна Балакай белән бергә яшәргә күнеккән бит инде...

— Васиякәем, әллә...

— Китмисез! Карышыр булсагыз, өйдә бикләп тотармын.

— Саримә, Васия үз сүзен итәчәк.

— Безгә эшкә йөрергә кирәк лә.

— Бергә чыгып китәрбез. Ә сезнең елмаешып кайтуыгызны күреп, ишекне төбенәчә ачып куярмын.— Аннары хуҗа хатын вакыйгаларга нәтиҗә ясагандай итте: — Балакаем, бу дөньяны синең түзем-тәкатең бизи...

Бу хәлләрне мин, Торак мәйданчыгы дип аталучы бистәдәге танышларыма баргач, Васиянең үз авызыннан ишеттем. Ислах, Саримә һәм аларның улы белән кызы — Саримәнең берьюлы малай белән кыз алып кайтачагын алдан белеп-сизеп әйтүенә бик тә сөенә Васия — бәхетле яшиләр икән.

Ә иң кызыгы, юк, иң сәере, юк, алай да түгел, иң әкәмәтлесе менә нәрсәдән гыйбарәт: Васия Ислахның беренче хатыны, Саримә икенчесе икән ләбаса!..

*1999*

# Йолу

Багдасар Исбаховның кайтуы турындагы хәбәр, кечерәеп баручы авылның бер башыннан кереп, гәрчә өйдән өйгә йөрсә дә, икенче очына шәп йөгереп барып җитте. Күптән күренмәгән иде егетебез, унбиш еллап булыр, юк, егерме ел ук икән. Монысын һәрнәрсәне хәтерләренә мачлап сеңдерүче авыл апайлары тиз акылдан исәпләп чыгардылар. Әхвәлен хат язып та белгертмәде Багдасар, хәер, чит-ят җирләргә китеп барганда ук авылда якын туган-тумачасы калмаган иде инде аның.

Шаять, ачу саклагандыр, наный. Барлык кешеләргә дә түгел, ә авылның атаклы этәлгесе-юньсезе Фәрдүс Зәбиховка гына үч тоткандыр, бәлки, үчегүе хәзер дә бетмәгәндер. Бәлки, масаю-тәкәбберләнү аңа ят булса да, горур дәрәҗәсен төшермәгәндер. Нигә әле аяк-саяк Этәлге Фәрдүскә нәфрәтләнеп, тынычлыгын бимазаласын Багдасар? Булмас, андый хәл булмас.

Ничек икәнлеге, мөгаен, тәгаенләнер — җете күзле авыл апайлары керфек кагуыңны да искәрәләр. Хәзергә исә апайлар фараз гына итteләр...

— Горбәттә йөргәндер безнең егеткәебез.

— Юктыр, Багдасар ил буйлап каңгырып йөрмәс. Холкы андый түгел.

— Шулай дисеңме, ахирәткәем. Анысы тормыш кешенең холкын сындыра да инде.

— Исбахныкылар холкынмы?! Булмастайны! Алар бернигә дә бирешмәүчән.

— Бик баеп кайтты микән?

— Калтасы калынлыгын үзе беләдер. Алар нәселенекеләр акчаларын гел күн янчыкта йөрттеләр.

— Машинасы менә чит илнеке түгел икән, үзебезнең «Нива» гына, ди.

— Авылның алама юлларына шунысы кулай. «Мерседес» дигәннәрен җимертмәс бит.

— Бардыр, «джип», диләрме әле, андые да бардыр. Бик затлыдан киенгән, ди. Аннары да килеп, машина җене яшьләй кагылган иде Багдасарга.

— Хатыны, балалары белән кайтты микән? Өйләнгәндер лә.

— Машинасында үзе генә булган, ди.

— Район башлыгы янына да үзе генә кергән икән.

— Бөтенләйгә кайткандыр да район үзәгендә фатир алмакчыдыр.

— Кем күргән соң аны?

— Шул инде, теге Этәлге Фәрдүснең райүзәктә тамыр батырган малае таныган Багдасарны.

— Райүзәктә калыр микәнни? Шунда кунакханәдә яшәп торыргадыр исәбе. Шуңа күрә әлегә авылыбызда күренмидер.

— Шулайдыр.

— Анысы, авылда йорт-җирен җиткергәнче, бездә яшәр иде.

— Сезгә дә, безгә дә, һәрбарчабызга да сыярлар Багдасарлар.

— Йорт-җир җиткерәсе булса, бәрәңге утыртырга быел соңлады инде.

— И-и ахирәткәем, бәрәңгегә интектермәбез лә инде Багдасарларны. Кайтып ихата корып кына җибәрсеннәр.

— Газиләгә белгертәсе иде бит Багдасарның кайтуын.

— Җәрәхәткә тоз сибү булыр анысы, ахирәткәем.

— Белгәндер-ишеткәндер Газилә. Багдасар райүзәктә тукталган ич.

— Әтәлге Фәрдүс белән очрашырлар микән?

— Ул юньсезнең кешегә күренерлеге калмаган икән инде. Бөтенесе түшәгендә, ди.

— Кыланасын кыланды инде. Үзе дә рәхәттә йөзми менә.

— Әтәлге шоңкар булмас, диләрме әле?

— Әтәлге лачын була диме инде?! Әтәлге Фәрдүс лачын сөтен чөмерүдән узмады ич. Аракының мичкәсенә чумды бит, явызның явызы.

— Авылда шул исерекбаш Әтәлге рәнҗетмәгән кеше юк та бугай.

— Багдасар рәнҗемәгәндер. Оныткандыр Әтәлгене.

— Онытырсың аны!

— Очрашмаслар алар. Әтәлгесе урыныннан кузгалмый, Багдасар аларның бусагасын атлап кермәс.

...Әмма дә ләкин кайбер мәсьәләләрдә читкәрәк тайпылып фикер йөрткәннәр икән авыл апайлары. Багдасар Исбахов авылга иртәгесен үк кайтты һәм соргылт «Нива»сын Фәрдүс Зәбихов капкасы төбенә үк китереп туктатты. Машинасын каты ук кычкыртты, каршыларга кеше чыгуын көтмичә үк, кече капканы шакымыйча ачып, ишегалдына керде. Өй почмагындагы оясыннан атылып чыккан ала бурзайга йодрыгын селтәде, ауга йөрмичә өрергә генә күнеккән эт койрыгын кысып оясына чумды, бу кешене өреп кенә куркытып булмаячагын төшенде бугай.

Авыл апайлары тагын бер фаразда хаталанганнар — йорт хуҗасы Фәрдүс Зәбихов түшәккә сеңәр дәрәҗәдә үк түгел икән. Багдасар кергәндә, ул, өстәл башында кырынрак утырып, шома зур стаканны ике куллап күтәреп, чәй йотымлый иде.

Йөзе бик үзгәрмәгән икән Әтәлге Фәрдүснең. Яңаклары һаман да каңгыл — очлыкый сөякле. Шәлпек иреннәре, яше олыгаюына карамастан, һаман да шул килеш, чәй эчкәндә, стаканның яртысына диярлек җитеп сәлперәеп торалар. Һаман да күсә — сакалы ике бөртек, таракан мыеклары кебек шулар, мөлаем татар картларыча сакал үстерергә насыйп булмаган моңа. Һәркем бер төк бирсә, күсә кеше дә сакаллы булыр, диләр бугай да, әмма авылда Әтәлге Фәрдүскә игелек кылучы табылмаган. Күзләре һаман да кылпа, моннан да ары кысыклану, мөгаен, мөмкин дә түгелдер. Йөзендәге-битендәге зур үзгә-

реш аннан итнең бөтенләй качуындадыр, үтә дә ядау-ябык Әтәлге Фәрдүс.

Йорт хуҗасы, ниһаять, чәен эчеп бетерде. Шуннан соң гына ишек катында сүзсез басып торган Багдасар, аягыннан туфлиен салып, өстәл янына килде, терәкле урындыкны тартты, аңа аксыл пинжәген элде, утыргач, хуҗага тагын бер карап алды, өстәлгә таянды, карашын тәрәзәгә күчергәч, күзләрен йомгалап, уйга чумды.

Йорт хуҗасы, ниһаять:

— Нигә исәнләшмисең? — дип сүз башлады.

— Мин синең белән саубуллашмадым. Исәнләшергә.

— Исәнлегең-саулыгыңның элә-танагы юк, дисеңме? Элеп киптергән балык кебекме мин?

Багдасар өстәлгә таянган уң кулын беләзектән түбән генә кымшатып куйды, юкны сөйлисең ягъни.

— Миннән, картларча әйтсәм, кыйсас алырга кердеңме?

Багдасар озак эндәшмәде.

— Ал соң үчеңне!

Багдасар Әтәлге Фәрдүснең бу кызышуына да җавап кайтармады. Йорт хуҗасы, ниһаять, урыныннан кузгалды, тәрәзә тупсасына кәкре башы белән эләктергән кул таягын (чаңгы таягын бөгеп ясалган иде) алды. Биек итеп урын-җир җәелгән карават янына барды, шунда менү өчен махсус әтмәлләнгән төрәнке-басмачаны аяк очы белән җайлады.

— Хәлең булса, ятагыңа аумыйча тор. Утырып сөйләшик. Сүз озакка сузылмас.

Инде Әтәлге Фәрдүс эндәшмичә торды, төрәнке-тәбәлдереккә бер аягы белән баскан килеш, икеләнеп калды, ютәле кинәт тотты, авызына тулган кирәксез хәзинәне ястык астына кыстырылган зур йомарлыктай чуар чүпрәккә бушаткач, өстәл башына килеп утырды.

— Мин кылган явызлыкка яхшылык белән җавап кайтармассыңдыр.

— Минем күңелгә юшкын утырмый, утыра алмый. Үч алырга теләсәм дә, моны әтәләнеп кылмас идем. Аннары... Туктале, кем дип эндәшим соң сиңа?

— Әтәлге, диген, үзең таккан кушамат.

— Бөркеткә тиңләгән булганмын сине. Ләкин канаты каерылганынадыр.

Багдасар урындыкка аркасын терәде. Бер мәлгә Фәрдүс Зәбиховка Багдасар Исбаховның киң җилкәләре, өйне иңләп, кара-каршы диварларга тиеп алдылар, чәче кырдырып алынган зур йомры башы түшәмнең ныклыгын чама кылып карагандай булды.

— Син марсыкны беләсеңме? — дип сискәндерде йорт хуҗасын көтелмәгән кунак.

— Анысы нәрсә тагын? Миңа яңа кушаматмы?

— Ю-ук! Гәрчә мондый кушамат синең кемлегеңәябышып кына торыр иде. Марсык яна белмәс, янса, сүнә белмәс, дия иде минем әти. Синдә шул тискәрелек янып киткән дә хәзергәчә сүнмәгән икән. Марсык — төп, агач төбе. Ярар, җитте. Үзең кирле-мырлы сөйләгәнгә генә әйттем боларны. Йомышым бүтән.

— Йомышың? Минем сиңа кирәгем чыктымы?

— Син кирәкмисең миңа! Ләкин бер мәсьәләне хәл итү сиңа кагылышлы.

— Минем кулдан хәзер эш килми.

— Электә дә юньлене кылганың сирәктер. Булса әле.

— Арттырасың. Алтмышка хәтле яшәгәч, гомер гел начарлык кына эшләп узмаган. Син үзеңне гел акыл иясенә санадың, ә акыллы кеше күп сөйләми, сүзеңне кыска тот.

— Сиңа, сезгә, йортларыгызны күчерергә туры килер.

Фәрдүс Зәбиховның күзләре шарайды, эг итте дә теле төенләнде. Бугазына йомырык килеп тыгылды һәм күзләре йомылып бетә язды.

— Мин күченергә тиешме?

— Әйе.

— Булмаганны! Күршедәге сезнең пуҗумда бәрәңге генә утыртабыз. Анысын кайтарып бирдем дә ди. Ләкин минем белән күршеләшергә үзең үк теләмәссең. Юк, бәрәңге бакчабызны да бирмим!

— Бүген кич авыл җыены була. Шунда хәл итәбез моны.

Бу кадәресе Әтәлге Фәрдүсне калтырандырды, авыл халкының аның файдасына энә күзедәй генә дә яхшылык эшләмәячәген аңлый һәм моңа үзе гаепле икәнлеген соңгарып булса да таный ул.

— Сезнең ихата мәчет һәм мәдрәсә урыны. Мәчетне элекке нигезенә күтәрәбез.

— Аның нигезе билгесез инде,— дип йомшак кына карышты Зәбихов.

— Чаманы чамага тартырбыз. Үз пуҗумыбызны үземә алырга җыенмыйм, ләкин анысы да сезнең биләмә булмаячак. Мәчет яны мәйданы итәбез аны. Болар хакында район түрәләре белән килешенгән. Тик алар авыл халкы белән киңәшергә куштылар.

— Син тотынгач, шулай булачагына шик юк,— дип, бик авырдан сулады Фәрдүс Зәбихов.— Үлеп котылган булсам икән бу хурлыктан!

— Хурлык?! Хурлык кынамы бу? Үз нигезегезне ташлап, мәчет урынына — авылның иң кулай төшенә — йорт-җир корганда, гөнаһ кылудан куркырга иде сиңа!

— Мин бит монда...— диде дә бүленде Әтәлге Фәрдүс. Бераздан: — Монда бит...— дип кабатлагач, тагын тукталды.— Бит монда минем...— Аның нәрсә әйтере моннан ары сүзләрендә дә аңлашылмады, бу кадәресе, хәер, Багдасар Исбаховны кызыксындырмады.— Монда минем күпме... күпме...

— Тик карышасы булма!

— Карышудан мәгънә чыкмас.

Фәрдүс Зәбихов өстәл тартмасыннан кәгазь белән каләм алды. Ризалыгын язды да тамгасын салды.

— Мә, ал.

— Алмыйм. Җыенга үзең китерерсең.

— Мин чыгып йөрмим.

— Илттерерсең.

— Карале...— дигәч, Багдасарга ничек эндәшергә белмичә тукталып торды Әтәлге Фәрдүс.— Карале... авылдаш, монда бер хәзинә бар иде,— дип, өстәл артыннан шешә тартып чыгарды йорт хуҗасы.— Башланган башлануын, шулай да безгә җитәрлек.

Багдасар урыныннан торды, өйнең урта төшенәрәк барып басты, Фәрдүскә таба борылды.

— Эчмәдем! Эчмим! Боера күрсен, эчмәмен!

— Мин капкалыйм. Авырту басыла төшә. Карале, теге чакта салмыш идең ләбаса син! Комбайн...

— Эчмәгән идем! Авызыма якын да китергәнем юк аракыны!

— Ялгыштым микәнни? Аек кеше комбайн белән...

— Аны аек кеше генә эшли ала!

...Моннан егерме ел элек, Фәрдүс Зәбихов колхоз рәисе чагында, солдат хезмәтеннән язын кайтып төшкән Багдасар Исбахов, чәчү бетүгә, комбайнын төзәтергә керешә. Барлык кирәк-ярагын үзе юнәтте дә (әлбәттә, колхоз исәбенә) армиягәчә үзе эшләгән комбайнын аякка бастырды. Гөрләп торган комбайнын йөртеп тә карыйсы килде егетнең. Һәм, озын-озак уйлап тормастан, авыл урамнары буйлап әйләнде — сөенеп соклансыннар авылдашлары Исбахныкыларның соңгы буыны уңганы Багдасарга!

Ләкин колхоз хуҗасы Фәрдүс Зәбихов аның гамәлен бүтәнчә бәяләде, комбайн белән йөргән кызы янына чаба, техниканы сак тотмый, дип судка бирде. Хөкем итүчеләр монда җинаять күрмәделәр күрүен, рәис яласын кире кактылар, Багдасарның тәртип бозуын, кирәксә, иптәшләр судында тикшерү ихтималын искәртү белән чикләнделәр.

Фәрдүс Зәбихов исә мондый мөмкинлекне кулыннан ычкындырмады, Багдасардан зур штраф түләттерүгә ирешә. Горур егет рәнҗетүне кичерә алмады, штраф бәрабәренә йортын, каралты-курасын колхозга бирде дә авылдан чыгып китте.

Хәер, Әтәлге Фәрдүснең Исбахныкыларга, димәк, Багдасарга да, кылган әшәкелеге моның белән генә бетми әле. Багдасар җиденче сыйныфта укыганда, Фәрдүс Зәбихов (ул чакта авыл советы башлыгы) Исбах карт, Багдасарның әтисе ягъни, Советка яла яга, авыл халкын дин тотарга өнди, дип, авылның соңгы мулласын хөкем каршына бастырды. Алтмышына якынлашучы Исбах хәзрәт төрмәдә вафат булды, бердәнбер һәм соңга-

рып туган улы Багдасар, авылны ташлап чыгып киткәнче, ялгызы көн күрде. Әнисе, улын тудыргач, озак яшәмәгән иде...

— Үзең үк мулла буласыңмы?

— Юк! Гыйлемлегем җитми. Әти биргән дин сабаклары онытылмый онытылуын. Табарбыз хәзрәтне. Киләчәк өчен берәрсен укырга җибәрербез.

Әтәлге Фәрдүс шешәнең файдасын күрмичә кире куярга теләмәде, ашъяулыкны ачып, стакан ише рюмкага яртылаш итеп аракы бүлде, аны сөзеп эчте, артыннан ризык капмады.

— Үпкәдә генә түгелдер бу чир...— дип, гамәлен акларга тырышты йорт хуҗасы.— Бавыр да челтәрләнгәндер...

— Гомер буе чөмерүгә бер әгъза да түзмәс,— дип, Фәрдүс Зәбихов каршына кире утырды Багдасар Исбахов.

— Сизеп торам, әйе. Синең тагын бер нәмәрсәкәйне искәртергә исәбең.

— Искәртү түгел. Төгәлен тәгаен белергә тиешмен!

Әтәлге Фәрдүснең Багдасарга кылган өченче әшәкелеге дә бар иде. Монысын ул Газиләдән ишетеп белә иде, шулай да бу хәлне Зәбиховның үз авызыннан әйттерәсе килде.

...Багдасар белән Газилә яратыштылар. Егетнең солдаттан кайткан елы көзендә алар өйләнешергә килештеләр. Тик Багдасар комбайны белән урам әйләнгәннән соң, вәгъдә бозылды. Юк, Газилә егетен урамнарны иңләве өчен гаепләмәде, егете сөенеченә сокланды. Ләкин Багдасарны төрмәгә утырту куркынычы беркатлы авыл кызын бөкте дә салды. Моннан исә Фәрдүс Зәбихов оста файдаланды. Газиләне аулакта очратып, егеткәеңнең төрмәгә утыруын теләмәсәң, кызлыгыңны миңа бирәсең, дип турыдан ярды. Карышты Газилә, ләкин ул вакытта әле гайрәтле Фәрдүс Зәбихов теләгенә барыбер иреште... Тик моның Багдасарны гаепсезгә рәнҗетелүдән йолуга, әлбәттә, файдасы тимәде. Хәер, Газилә моңа баштан ук ышанмаган да иде.

— Кирәкми, сөйләмә! Кабих син! Газиләнең бәхетен кистең син, азгын! — дип, урыныннан ашыгып торды Багдасар Исбахов һәм өйдән кызуланып чыгып китте.

...Әтәлге Фәрдүсләрнең йорт-каралтыларын шул җәйдә үк үзләре пуҗумына күчереп салдылар. Авылның яше-карты көче белән. Бушка. Зәбихов бер тапкыр да өмә чәе оештырмады. Авылдашлары моңа өметләнмәгәннәр дә иде. Әтәлге Фәрдүснең өенә кереп ризык җыйган авыл кешесе моңарчы да булмады лабаса. Ә менә йорт әйберләрен күчергәндә, бер хәл Зәбиховның авылдашларын, хәтта хатынын һәм дә балаларын гаҗәпләндерде, юк, алай гына да түгел, ә шаккатырды, хәйранга калдырды.

Кирпеч келәт астында тирән баз казыткан Фәрдүс Зәбихов. Шуннан тугыз тоннадан артык (үлчәделәр!) арыш белән бодай чыкты. Тик агач ларлардагы бу хәзинә-ризык сөрсегән

иде инде. Базда унике тартма (берсеннән биш шешә алынган) аракы таптылар.

— Белмәдем! Мин белмәдем! — дип, акылыннан шашу дәрәҗәсенә җитте Әтәлге Фәрдүснең хатыны.— Антлар итәм, авылдашкайларым! Белмәдем... Ачкычын гел үзендә тотты ул... Үзе генә ташып тутыра алмаган бит инде боларны, кемдер булышкан. Миңа әйтмәделәр. Кичерегез, авылдашкайларым... Монда минем гөнаһым юк... Юк!..

Авылдашлары хатынны гаепләмәделәр, аның ихласлыгына ышандылар.

Бер апай:

— Безне гомерең буе кыерсыттың, хатыныңны гел дә җәфа чиктергәнсең икән! — дип, Әтәлгенең йөзенә бәрде.— Палачның палачы син!

Бу апай Газилә иде.

Ләкин Фәрдүс Зәбиховның мондый бәяләмәгә керфеге дә селкенмәде.

— Буласы булган. Хәзер үкенүдән файда юк,— дип, оятсызлыгын яшермәде, яшерергә дә теләмәде Әтәлге Фәрдүс.

— Гел кисәтә килдем ләбаса мин сине, Ходай каршысына басасыбыз бар, дидем,— дип, тагын өзгәләнде Зәбиховның хатыны, ләкин ире аның ягына кулын гына селтәде.

...Зур булмаган мәчетнең түбәсен шул җәй ахырына ябып өлгерделәр, чыгымнарны һәркем күтәрде, әмма зур өлеш төньяк котыпта эшләп мул ук хәзинә туплаган һәм Мәскәүдәге өч бүлмәле фатирын саткан Багдасар Исбаховтан иде. Эчке эшләр киләсе язга-җәйгә калды.

— Авылыбыз элекке хәленә җитеп зурайгач, тагын мәчет салырбыз,— дип, авыл халкына киләчәккә өметен ирештерде Багдасар әфәнде, һәм мондый теләкне һәркем — Әтәлгедән башкасы, ә аңа барыбер идедер инде — хуп күрде.

...Яңа мәчет алдында беренче җеназа Фәрдүс Зәбиховка укылды. Аны авылдашлары соравы буенча хәзрәтлек вазифасын башкаручы Багдасар Исбахов башкарды. Вазифасы вакытлыча булганга күрәдер, хәзрәтләр киеменнән түгел иде ул. Шулай да башында әтисеннән калган кырпу бүрек иде. Укып бетергәч:

— Ходай ярлыкасын сине,— диде Багдасар Исбахов.— Гөнаһларыңны йолсын. Без фанилардан ризалык-теләк шул.

Исбаховларга йорт салып бетереп, каралтыларын җиткергән көннәрдә булды Фәрдүс Зәбиховның вафаты. Өйле булу уңаеннан Коръән уку мәҗлесенә Фәрдүс Зәбиховны чакырмакчы иде Багдасар, хатыны һәм балалары да моңа каршы түгелләр иде. Тик нишләмәк кирәк, Ходай башкача кылды. Фәрдүс Зәбиховны гөнаһларыннан тизрәк йолырга уйладымы? Әллә... Әйе, кеше гөнаһын кешеләр йола алмыйдыр, бу кадәресе бер Аллаһыбыз кодрәтендә ич.

*1999*

# *Оҗмах агачы*

Шушманың уң яры өстендә — Балтачның яңа мәһабәт мәчете турындарак — таллар тезелешкән. Елганың кырт тугаен ураган бу таллар, күккә үк ашмасалар да, сокланырлык юаннар, зуп-зур ябалдашларын киереп, иркенгә җәеп үскәннәр.

Әхмәдияр белән Фәрхизә олпат талларны борынгы тугайның күрке итеп саныйлар, хәтта берсен — нәкъ борылыштагысын — тубай агачына тиңлиләр.

Кыз, монда килгән саен:

— Оҗмах агачы бу! — дип сөенә дә моны егеттән: — Әйеме, Әхмәдияр? — дип сорап раслата.

Егет бик teләп:

— Синең оҗмахың агачы,— ди.

Шуннан соң алар озак кына сүзсез торалар. Аннары Фәрхизә, күзләрен кысыбрак, йөзенә сихәтле елмаю җәеп, Әхмәдиярның карашын үзенә текәлдерә һәм аның колагына:

— Икебезнеке дә...— дип пышылдый.

Алар, Шушмага карап, тагын сүзсез калалар.

— Әхмәдияр...

Егет башын кагып кына җавабын — тыңлыйм сине, сине генә тыңлыйм, Фәрхизә! — кайтара.

Тик җәһәт фикерләүчән кыз күңелендәге хисләр барышын сүз белән әйтерлек хәлдә түгел бугай.

— Фәрхизә...

Инде кыз башын кагып кына җавабын — мин сине гел, гел тыңларга әзер, Әхмәдияр! — кайтара.

Тик кодрәт иясе егет күңелендәге ташкын көчен сүзләргә сыйдыра алмый бугай...

Ә Шушма, борынгылыгына сөенеп, горуранә ага да ага.

— Фәрхизә, күр әле, күр, Шушма сикәлтәсез юлдан үр төшә ич! Әнә, шуа ул, Шушма рәхәтләнеп шуа!

— Аның агымы синең холкың кебек — тигез дә, йомшак та. Син минем күңелне ашкындырып куандыра торган сүзләрне табып кына торасың. Сабый син, Әхмәдияр, сабый!

— Икебез дә...

Аннары алар кырт борылыштагы иң юан тал — үзләренең тубай агачы янына киләләр дә икесе ике ягына басалар.

— Әхмәдияр, их-х, колачлыйсы иде оҗмах агачын!

— Икебез кулга-кул тотынып кочакласак?

Алар җитәкләшәләр, тик икенче куллары бер-берсенә җитми. Аяклары очларына басып, агачның нечкәрәк төшенә үреләләр, икенче кулларының урта бармаклары очлары бер-берсенә тиеп ала.

— Фәрхизә, безнең әле берничә ел үсәсебез бар. Тагын да үскәч, тубайны ныгытып-ныгытып кочакларбыз.

— Оҗмах агачы да үсәр-юанаер бит, Әхмәдияр.

— Без тизрәк, тиз үсәрбез. Икебез дә...

Алар агачтан читкәрәк китәләр, әмма куллары җитәкләшкән килеш кала.

— Әхмәдияр, күрче, тубай төптән үрелеп үскән, әйеме. Шуңа күрәдер бу тал җир толымы кебек, әйеме.

— Синең толымың кебек, Фәрхизә.

— Ә талның ябалдашы синең күпергән чәчләрең кебек.

— Без шушы тубай сыман. Икебез дә...

Егет, текәлеп, агачның кәүсә төбе үрелүе-әйләнмәлеге серен чишмәк була, кыз ябалдашның түбәнге читенә карый да таң кала.

— Әхмәдияр, минем әнә шул яфракны битемә тидереп карыйсым килә.

— Хәзер! Шунда гына тор! Урыныңнан кучмә! Күзеңнән җуйма шул яфракны! Әнә ул, әнә, очтан икенче! Шулмы?!

Фәрхизә сүз әйтергә өлгергәнче, Әхмәдияр авылга таба йөгерде. Бераздан, кулына озын кәшләкә күтәреп, җилдәй очып килеп тә җитте.

— Нәрсәгә инде бу ыргаклы колга, Әхмәдияр?

— Тал ботагын шуңа эләктереп бөгәм хәзер.

— Мин әйттем, син тыңладың дигәндәй. Тиледер мин...

— Икебез дә...

Егет тал-тубайның ботагын кызның алдына ук иелдерде, үзе аның янәшәсендә үк диярлек иде.

— Син менә шушы яфракны әйттеңме, Фәрхизә?

Кыз раслап башын какты.

— Бигрәк йомшак монысы,— диде егет.— Төсе дә ямьяшел. Өлгереп җиткән. Җәй башында гына тубайның яфрагы шундый буладыр.

Кыз башын тагын сүзсез генә какты, егеткә үзенә таба иелергә ишарәләде. Ул яфракның өске ягы белән Әхмәдиярның ике битен сыпырды, аннары гына үз битләренә тидерде.

— Фәрхизә, син яфракны элгәре үз битләреңә тидермәкче идең ич. Нигә башлап мине иркәләдең?

Кыз уйчан карашын егеткә төбәде, якты зур күзләренең каралары шаярулы уйнаклап алдылар — һай, егеткәем, үзең аңла сәбәбен! Шулай да ул егетнең соравын җавапсыз ук калдырмады.

— Белмим...

— Мин дә белмим...

— Икебез дә...

Бу юлы мондый нәтиҗәне кыз чыгарды. Ул ике чигәсен тиз-тиз ышкыды. Аның киң беләзекләре кояшта ялтырарга өлгерде.

Әллә соң алар икесе арасындагы мөнәсәбәтләрнең сәбә-

бен-серен бeләләр идеме? Шулайдыр. Серне чишәргә иртәрәк икәнен төшенәләрдер, хыял-теләкне чынга ашырырга ашыкмаулары шуңа күрәдер.

— Фәрхизә, әйдә, су коенабыз!

Кыз Шушмага озаклап карап торды. Егетнең түгәрәк беләгенә бармак очларын гына тидерде.

— Әхмәдияр... Әнә, Шушма, син шул сүзләрне әйткәч, үкереп-улап елый башлады. Шушмакай, елама берүк! Яшер күз яшьләреңне. Коенмыйбыз әлегә. Иртәрәк безгә бергәләп коенырга. Тыңла безне, Шушмакай, елама син, елама. Әнә ич, Әхмәдияр да шулай дип үтенә синнән...

Ә Шушма элеккечә — горуранә ага да ага иде...

Әхмәдияр белән Фәрхизә, горур карашларын бер-берсенә текәгәннәр дә, бер-берсенең язмыш китапларын укыйлар иде. Алай гына да түгелдер, ә уртак язмыш китабын язалар иде.

...Шушмада кармак салып утырам. Эләкмәве бер хәл иде, чиртеп тә карамый балык. Әмма Шушманың миңа балык тоттырмавы сәбәбе бик зурдан икәнлеген яныма егет белән кыз килеп туктагач кына аңладым мин. Шушма, танышларым Әхмәдиярга һәм Фәрхизәгә сокланып, миңа балык чиртерергә оныткан икән ич!

Алар минем янда озак тормадылар, хәл белешкәч, җитәкләшеп, Шушма буйлап китеп бардылар. Аларның назлы-сөелүле баруы Шушманың рәхәтләнеп шуучы агымыча горуранә иде. Әхмәдияр белән Фәрхизәнең ераклашуы экияти (әллә чынмы!) күренеш булып минем күңелемә сеңде.

...Узар заманнар, егерме беренче гасыр керер, аның да ахыры җитәр. Шул чакта борынгы Шушманың мәһабәт мәчет турындагырак кырт тугаенда яшьлек чалымнары пакь йөзләрендә сакланган Әхмәдияр белән Фәрхизә — әнә генә ич алар! — янәшә басып торалар икән. Бабай, укалы тирән түбәтәен аз гына кыңгырайтып, җиләнен төз гәүдәсенә сыландыра да:

— Фәрхизә,— ди,— синең карашыңа тиңләшерлек гүзәллек юк.

Әби маңгаена яртылаш төшереп артка бәйләгән бизәкле яулыгын чигәләре тирәсендә төзәткәли, ак алъяпкычы өстеннән кигән камзулын тулылыгы белән сылу гәүдәсенә җайлый да:

— Әхмәдияр,— ди,— синең карашыңнан өстен нәрсә була алмый.

Тугайдагы иң өлкән тал-тубай агачы — җир толымы — бу ачышны ишетеп сөенә...

Әхмәдияр белән Фәрхизә, әнә, көймәдә янәшә утыралар. Мөлдерәмә тулы Шушма ак көймәне талгын-җай гына йөздерә дә йөздерә...

*1999*



# Чәй

Яланны тиз уздык, тагын урманга кердек. Яланда таң яктысы сизелә башлаган иде, урманда төн караңгылыгы җуелырга ашыкмый. Яланнан узганда, күңелгә рәхәт сагыш тула. Урманнан барганда, күңелне чытырманлы уйлар җилкендерә. Яланда поезд акрын юырта, урманда ажгырып чаба...

Вагон аралыгында мин ялгызым, юлдашлар ял итәләр — Ригага ерак әле. Әйе, Ригага барыш минем. Шушы көзне кичергән борынгы шәһәр янында — Дубултыда — язучыларның иҗат йорты бар. Шунда яшәп, Таукашның беренче кар яуган көнен — вакыйгаларга бай көнен үзәккә куеп, шул авыл кешеләре турында озын хикәя язарга исәбем. Таукашны мин күптән беләм, анда еш булам, безнең Казаннан автобус белән сәгать ярымлык юл Таукашка. Нәкъ аның кешеләре турында уйлану тынгылык бирми миңа, инде төн уртасыннан бирле яланнар белән урманнар аралашуын вагон тәрәзәсеннән карап, уйланып барам. Таукашта кырлар карга капланып калды, мин анда беренче кар төшкән көндә — әле узган атнада гына булдым, ә монда кырлар ялангач. Таукашта инде яктыргандыр, безнең яклар белән Балтыйк буе арасында вакыт аермасы шактый ич. Һәм Таукашта бүген дә беренче булып эшкә башлаучы Рәйсә исемле яшь кыз булгандыр...

Тагын ялангa чыктык. Яктыра.

## 1

Рәйсә бүген дә йокыдан беренче булып уянды. Тугызынчы класска бармыйча укуын ташлап, эшкә башлаган көненнән бирле аны уятырга кирәкми, авыл мәшәкатьләренә күнегергә тиешлеген беренче сентябрьдән ныклап аңлады ул. Аңлавын аңлады, шулай да таң йокысыннан бүленүе авыр ла, тагын бераз гына черем итсәң икән дә бит — ярамый, фермага төшәргә соңлы. Үзе уянмаса, кыңгыраулы сәгать шәрран ярырга тотыныр иде. Ул дүртенче яртыга куелган, аның шалтырарына ун минут кына калган икән. Рәйсә сәгатьнең төймәсенә басты, чәрелдәмичә тор ягъни, башкалар тынычлап йокласын әле.

Кыз әбисе Сәрвия белән шушы урта өйдә йоклый. Аларның караватлары кара-каршы почмакларда, икесенә дә чыбылдык корылган. Аш-суны шушында әзерлиләр, шунда ук ашыйлар. Рәйсә, юынып, газ плитәсенә чәйнек куйганда, әбисе чыбылдыкны ачты.

— Йоклыйсы иден, әби,— дип акрын гына эндәште кыз.— Мин үзем әзерләнеп китәм бит.

— Бигрәк иртәли башладың, кызым. Әллә йокыдан кала-

сың инде,— дип, Рәйсәнең аркасыннан сөеп узды карчык.— Кичтән китап укып та озак утырдың.

— Хәзер, әби, элек тыелганнарны язалар. Буленмичә укый торган итеп. Менә бу журналны үзем белән алам әле. Кайбер төшләрен Моназыйрга укып күрсәтермен. Көн саен чакыртмыйча калмый ул мине.

— Абау, кызым, синме соң бу? Минем оныгым буласыңмы син? Олы кешегә абый дип әйтергә кирәген дә белмисең ич!

— Моназыйрга абый сүзе әрәм. Барлык әйбәт сүзләр әрәм аңа! Үзең дә беләсең ич моны! Миннән әйбәтрәк беләсең!

— Синең эшең түгел анысы! — дип кычкырыбрак әйтеп ташлады Сәрвия. Әле башкалар йоклавын искәреп, тавышын янә акрынайтты.— Кирәкмәскә катышма, яме. Күрәләтә ут эченә керергә торасың. Галияр абыең, ичмасам, элгәре ныклап уйлый, әтиеңә охшаган бу яктан. Әниеңнең дә юкка орыну-бәрелү гадәте булмады. Ә син чирканчык алмыйча ук бозлы суга ташланасың!

— Ташу суы озаклап чирканчык алуыңны көтми, әби! Ургылып ага да тиз бетә ташу суы!

— Житте соң, әче таңнан әллә нәрсәләр сөйләп, башымны катырмачы. Әле көн үткәрәсе бар. Көне шатлыклы да, нигәдер авыр да булыр кебек.

— Көне авыр булыр, дигәнеңнең сәбәбен беләм инде! Галияр абый бүген дә кайтып житмәс дип кара таңнан борчыласың!

Сәрвия җавап кайтармады, тормыш итү серләрен сизенүеңаңлавың яшеңнән бик күпкә алдан бара дип уйлады, табын әзерләгән оныгы янына килеп, үзе күпертеп пешергән ак калачны турарга кереште. Торыр вакытлары җитмәсә дә, Сәрвия белән Рәйсәнең сөйләшүенә уянып, түр өйдән Тимерша белән Мөхтәрәмә чыкты.

— И-и сайрашалар соң ике ахирәт! — диде Мөхтәрәмә.— Балаларны уятасыз бит, таң сандугачлары!

Һәм урам як өйнең ишеген ачып — монда Рәйсәнең ике энесе һәм ике сеңлесе йоклый — эчкә күз төшерде дә ишекне ныклап ябып куйды. Тимерша эндәшмәде. Ул йокысы ачылырачылмас түгел, эштә кулдашлары куерткан әңгәмәгә дә сирәк кушыла, үз эченә бикләнгән үк кеше булмаса да, сүзчәнлекне өнәми. Өйдәгеләр аның бу гадәтенә ияләнгән инде. Хәтта әнисе Сәрвия дә, бердәнбер баласы көне буена сыңар сүз әйтмәсә дә, аны сөйләштерергә тырышып бимазаламый. Үз эшен тыныч һәм җай гына эшләвендә Тимерша. Шуңа күрә өйдәгеләр аның мал-туар янына чыгып керүенә игътибар итмәделәр.

Дүртесе бергәләп чәй эчтеләр. Рәйсә кузгалырга торганда, Тимерша тамак кырып куйды. Әтисенең иртәдән сүз башларга җыенуына сәерсенеп, Рәйсә хәтта көлеп җибәрә язды. Мөхтә-

рәмә иренең нәрсәдер әйтергә теләвен шулай ук сизенде, аның чәен сүзсез генә яңартты. Сәрвия малаеның әйбәт хәбәр ирештерүенә өметләнде. Тимершага текәлде. Ә Тимершаның әйтер сүзе бик тә гади икән һәм бу хәбәр әлегә бары тик юрау гына икән:

— Бүген Галияр кайтыр, дим. Төшемә шулай керде.

— И-и улым, шулай була күрсен! Рәхмәтләр яусын үзеңә изге сүзең өчен! — Тагын кычкырыбрак башлаган иде Сәрвия, килене Мөхтәрәмә балалар ягына ым каккач, тавышын пышылдауга ук калдырды.— Үземнең төшләремә бер генә тапкыр да кермәде Галияр. Гөнаһым да юк лабаса үзенең каршында. Исәнсау гына кайтып керә күрсен инде Галияр...

— Әфганстан туры килде шул язмышына... — Мөхтәрәмә тирән итеп сулап куйды. Бу аның олы баласын зарыгып көтүдән күңеле сызуы иде.— Балакаема...

Төшен малае Галиярның бүген Әфганстан җиреннән исәнимин кайтырына юраса да, Тимершаның күңеле нечкәрүе сизелмәде. Рәйсә киенгән иде инде, китәргә җыенганда гына:

— Әби, син Галияр абыйны кайтуга ук минем янга җибәр, яме,— диде.— Өйдә генә тор, биләмгә чыгып китә күрмә тагын.

— Минем кайчан биләмгә йөргәнем бар? Булмаганны! — дип ачуланды Сәрвия.— И-и бу теленнең зәһәрлекләре, кызыкаем! Кемгә генә охшадың соң син? Әллә инде... — Карчык оныгы Рәйсәне кемгә охшатуын әйтеп бетермәде.— Боерыкәмер бирергә яратасың. Сугыш командиры кебек. Юл куйсалар, бөтен дөньяны кулыңда тотар идең!

— Дөньяны кулында тотарга теләгән кеше юл куюны көтми, әби! Галияр абыйны кайтуга ук безнең янга җибәр! Без анда өчәү — әти, әни һәм мин, ә Галияр абый кайтып кергәндә, син өйдә ялгызың гына булырсың әле. Миңа Галияр абыйның ярдәме бик-бик кирәк. Мин киттем!

Кызы чыгып киткәч, Мөхтәрәмә:

— Әнкәй, ачуланма инде син Рәйсәне,— диде.— Үзем дә бер ачуланмакчы булам да, сүз сөреше әйбәт, уе-фикере дөрес булуына сокланам да, тыелып калам.

— Ачуланырсың аны! Бер сүзеңә мең җавап таба бит ул!

— Ачуланмагыз,— дип, урыныннан кузгалды Тимерша һәм өзә-төтә тезде.— Бөтен ил яңара. Безнең Таукаш һаман сөрсеп ята. Әлегә моңа бер Рәйсә генә борчыла. Шуны аңлап җиткермибез.

— Менә син ә, бөтен гаепне миңа өеп калдырмакчылар! — дип каршы төште Сәрвия.— Теленне йотып йөрмә,— дип, Тимершага турылап әйтте ул.— Балага әтисе дә киңәш бирмәгәч, кем сүзен тотсын соң инде ул?!

Әмма Тимерша әңгәмәне дәвам итмәде, болай да күп сөй-

ләндем дип уйладымы — фермага эшкә китәргә сүзсез генә әзерләнде.

— Мин Рәйсәне әрләмим ич, гаепләмим мин аны,— диде Сәрвия.— Без аңардан алдарак басып уйланырга тиеш тә бит, булдыра алмыйбыз шул.

— Шулай шул менә, үз башыбыз эшләми,— дип, Рәйсә турында сүзне тәмамлауга борды Мөхтәрәмә.— Рәйсә яшьләй сөртенеп куймагае дип куркам. Балакаем...

Рәйсә, олы урамнан төшеп, авыл уртасынарак җиткәндә, Кече күпер урамы башында бер кеше басып торуын шәйләде. Әле караңгы, кем икәнен танырлык түгел иде. Кыз бүген беренче очраган кешегә сәлам бирмичә узып китәргә уңайсызланды, урамның уң ягына чыкты.

— Ә-ә, син икәнсең бит, Моназыйр Шәгаетов... абый! Исәнме,— диде ул, һәм исәбе тукталмыйча үтеп тә китәргә иде.— Хуш булып та тор.

Ләкин Шәгаетов:

— Тукта, ашыкма, Мостафина! — дип, кызның каршына төште.— Кая барасың?

— Менә сиңа әкәмәт, шуны да белмисеңмени, иптәш авыл советы рәисе?! Фермага эшкә барам!

— Мәктәпкә бар! Шуны әйтер өчен таңнан көтеп торам сине монда!

— Синең моны миңа көн саен берничә мәртәбә тукымыйча калганың юк, Шәгаетов абый! Укырга бара алмыйм мин! Нигә телеңне әрәм итеп мине үгетлисең? Нигә иртүк телеңне ардырасың? Эчеңдәге зәһәрне көне буе чәчәргә телеңнең егәре кирәк булыр. Берәрсенә яла ягарга җыенсаң — бигрәк тә.

— Кем яла яга?! Минем сиңа укырга барырга кушуым яла ягумы? Авызыңны чамалап ачмасаң, тәртипкә өйрәтә белермен мин сине, Мостафина! Ярыймы?! Власть кешесе мин! Авыл советы канцеляриясенә кил! Шунда сөйләшербез!

— Куркыттың да өркеттең, өркеттең дә өнсез иттең! Килермен соң! Тик элгәре фермада иртәнге эшләрне бетерергә кирәк, эти белән әнинең икәвенә генә авырга төшә. Колхозның бөтен бер фермасын өчәвебез генә карыйбыз бит, иптәш власть башлыгы!

Һәм кыз, сүзен ары озайтмастан, үз юлын алды. Фермага җиткәнче, аска карап уйланып барды. Аска карап бармасаң, хәер, юл каты-котысына сөртенеп, уп-па итүең дә ихтимал иде. Башына бу гәүдәң белән барып мәтәлсәң, туңган җирне сытарсың, җаным, дигән уй кергәч, көлеп үк җибәрде ул һәм иртәнге тынлыкны бозган тавышына үзе үк сискәнде. Төнлә беренче кар төшкән төшүен дә, әмма ул юлның чокыр-чакырларын тигезләп күммәгән иде. Рәйсә карның күпме явуын белмәкче булып чүгәләде дә юл читендәге карны ялангач кулы белән

сыпырды, юка иде шул быелгы беренче кар катлавы. Аягүрә басканда, офыкта таң яктылыгын каплаган болыт тауларын күреп алды Рәйсә. Шул болыт-кыялар бер-берсенә сыенышкан да, бер-берсеннән аерылышкан да кебек иде. Күңелне җилкендерүче бу кыяларны безнең Таукашта хәзер тагын кем күрә икән дип уйлады яшь кыз. Шуны бик беләсе килде аның хәзер.

— Моназыйр Шәгаетовмы? — дип үзалдына әйтеп куйды Рәйсә.— Юк, ул булмас. Юк, ул түгелдер! Шәгаетов кыяларны күрсә дә, аларның бер үк вакытта якынаеп-ерагаеп торуларын аермастыр. Кыялар җәлеп итмидер Шәгаетовны. Кызык ич әле бу табигать дигәнебез — Таукаш кешеләренә безнең якларда булмаган могҗизаларны үзенчә бүләк итә икән! Якындагы-еракъагы кыялар безнең Таукаш каршына таңнан ук килеп басканнар!.. Шулай иткән, ди, син тиле башка могҗиза күрсәтә, ди, табигать! — дип, үзенә бәя бирде Рәйсә.— Берәрсе ишетеп торса, көлеп эче катар, валлаһи! Истә-уйда юк нәрсәләр башыма кереп тинтерәтә. Сәрвия әби әйткәндәй, безнең нәселдә миңа охшаган кеше гомер-гомергә булмагандыр һәм хәзер дә юк! Әйдә, Рәйсә түтекәй, хыялларыңны ташла да, Тукаебыз кушканча, эшкә башла! — дип, сарыклар абзары ишеген ачты Рәйсә.

...Сәрвия күкрәгенә печән кысып лапастан чыкканда, капка ачылды.

— Галияр?!

— Мин шул, әби! Исәнме, әби!

Карчык печәнен ташлады да оныгы каршына ашыгып теркелдәде, сырмасына кунган печән сабакларын барышлый каккалап төшерде, күзләрен яртылаш каплаган бүреген күтәрде.

— Әйбәт йөреп кайттыңмы, улым? — дип, Галиярны аркасыннан сөйде Сәрвия.

— Әйбәт, әби!

— Шөкер, исән-имин уздыргансың хезмәтеңне,— дип, солдатның битләрен сыйпады әбисе.

Оныгының ияк очындагы кытыршылыкны учы тойды. Галияр оныгына чын ир кыяфәте куна икән, ике ел элек кенә иягендә бала йоннары гына иде, алары да сирәк-мирәк кенә иде. Уза гомеркәйләр! Галиярның чигәләрендәге берничә чал бөртек тә карчыкның күзләренә чалынды, ләкин ул моңа ышанмады — булмаганны, ничек инде япь-яшь Галиярның чәчләре агара башласын ди, күреп бетермидер карчык, җитмешкә баручы кешенең күзләре ялгышуы ихтималдыр лабаса. Шуңа күрә ул:

— Сау-сәламәт кайтуыңа мең шөкер,— дип кабатлады һәм оныгын тагын сөйде.

Уң калак сөяге астына әбисенең кулы тигәч, Галияр өскә тартылып куйды да сулга кыйшайды, Сәрвиянең кулы һавада асылынып калды. Оныгының бу хәрәкәтен баласытып сөюдән оялуы итеп санады карчык.

...Шулай инде, уза гомер дигәнең, әле кайчан гына Сәрвия итәгенә тагылып йөргән Галиярың, әйтерең бармы, әбисеннән бер башка озын хәзер. Сәрвия үзе дә тәбәнәк буйлылардан түгел, сугыш беткән елда авылдагы җиткән кызлар арасында иң эре, иң таза гәүдәлесе иде. Чибәре булмаса да. Хәер, яшең барган саен, кайтышланасыңдыр да инде. И-и, уза шул гомер, сугыш бетүенә дә кырык ике ел үткән. Сугыш тынган елда, юк ла, кырык алтынчының язында — хәтереңне саектырма, Сәрвия карчык, син моны онытырга тиеш түгелсең — авылга немец әсирләре килеп торган иде. Күп иде алар, өч йөзләп булгандыр. Әсирләр клубта һәм сугыш башланган елда салынып бетәсе ике катлы мәктәп бинасында тордылар. Булачак мәктәпнең идән-түшәме җәелмәгән, ишек-тәрәзәләре такта белән генә капланган иде. Ярый ла осталар, сугыш кубып, мәктәп салу тукталасын белгәндәй, түбәсен япканнар. Югыйсә, бина кысада гына утырса, бүрәнәләре чери үк башлар иде. Вильгельм исемле әсир дә әнә шул булачак мәктәп бинасына эләккән иде. Сәрвия бик тә кызганган иде шунда яшәүчеләрне, яз башы булса да, төннәрен салкын бит әле. Клубтагылары туңмыйдыр, анда мичләр бар, ә менә тәрәзәсез-ишексез мәктәп кысасында төн чыгулары үзәкләренә үтәдер әсирләрнең, мескенкәйләрнең.

Анысы, кызганырлык та түгел инде үзләрен, безгә корал төбәп килгән кешеләр алар. Сугыш беткәч, әллә миһербанлык көчәйдеме, әллә кулларында хәзер корал булмагачмы, дошман итеп саныйсы да килми тагын шул әсирләрне. Менә шул ук Вильгельмның безгә нинди дошманлыгы булсын икән инде, йә? Карашы йомшак шул Вильгельмның, миһербанлы, мәрхәмәтле, шәфкатьле шул Вильгельмның карашы...

Сәрвия Вильгельмны әсирләр килүенең икенче көнендә үк очратты. Туфрак өлгереп җитмәсә дә, тракторларны басуга бата-чумдыра чыгарттылар быел, язгы чәчүне сугышчан әзерлектә каршылыйк, янәсе. Шуңа күрә Сәрвия белән алмашчысы көндезләрен трактор янында кизү торалар. Төшкә чаклы — Сәрвия чираты. Кизүдән кайтышы иде кызның. Салынып бетмәгән мәктәп тирәсендә төркем-төркем әсирләр тора. Шуларны якыннан күрәсе килде Сәрвиянең, күңелендә шундый кызыксыну уяну сәбәбен үзе дә белмәде ул. Әмма кыз төркемнәр янына барырга уңайсызланды. Ә, әнә ич, читтәге тумран өстендә бер әсир ялгызы утыра. Сәрвия сукмагын аңа таба турылады. Аның килүен күрми иде әсир, иелеп, баш төртүче үләннәрне онытылып карый иде, сабый үләннәрнең үсешен күреп торырга тели кебек. Янәшәсеннән диярлек атлаучы чабаталы аякларны күргәч, әсир сискәнеп башын күтәрде һәм җәһәт кенә аягүрә торып басты. Аның бу хәрәкәте инде Сәрвияне сискәндерде, ул кулыннан бәләкәй төенчеге төшеп китүен дә сизмәде, әсирнең якты йөзенә текәлде, аяклары атламас булды.

Әсир дә Сәрвиягә сөенеп карый иде. Аларның карашлары очрашу озак дәвам итмәде, ләкин бу мизгелне алар икесе дә мәңгелек итеп тойдылар...

Кыз аска карады. Әсир төенчекне үрелеп алды, аны кызга тоттырды. Шул мәлдә кул кулга тиеп китте, кулларның язгы җил сеңдергән салкынлыгын йөрәкләр кайнарлыгы җылытты... Сәрвия, аптырап-каушап:

— Исәнмесез! — диде.

Әсир моны башкача аңлаган икән. Ул:

— Вильгельм,— дип үз исемен әйтте.

Танышуның болай булуында зыян юктыр, Вильгельм Сәрвиянең исемен соңрак барыбер беләчәк, бу исемне язып та күрсәтәчәк әле...

Сәрвия атлый-йөгерә китеп барды...

Әсирләрнең урамнан тезелешеп узуына очраса, Сәрвия гел шул Вильгельмны гына карап кала. Якты йөзле, бераз салынкы җилкәле бу әсирнең урыны сафның уртасында. Йөзенең яктылыгы белән аерыла Вильгельм башкалардан. Кемнәре бар икән аның? Әтисенә охшаган микән, әллә әнисенәме? Әнисенәдер, анага охшаган бала аерата шәфкатьле була. И-и бу язмыш дигәнең, уйда бөтенләй юкларны кыла да куя. Кайчан да булса татар авылына барып чыгармын дип башына да китермәгәндер Вильгельм...

Инде менә ничә еллар Сәрвия Вильгельмны онытмый. Калган гомере Вильгельмны белә башлаганнан соң узган вакыттан күп кыска, инде бу елларда гына якты йөзле шәфкать иясен онытмас. Кызык, әй, солдат Вильгельмның иленә кайтып, әбисе аркасыннан сөйгәч, ул да оныгы Галияр кебек гәүдәсен тайпылдырган идеме икән?..

Сәрвиянең башыннан, Галияр сулга кайшалып, кулы һавада асылынып торган арада, әнә шундый уйлар җәһәт йөгереп узды. Һәм карчык, Галиярны каршылагандагы салмаклыгын бетереп, әлеге җитез уйларыннан калышмаска теләгәндәй, кызуланып тезеп китте. Кинәт үзгәрүе аңа ерак еллар хатирәсеннән аерылу өчен дә кирәк иде бугай.

— Ни, Галияр, бар әле, син өйгә керә тор әле. Мин шушы печәнне бәрәннәр алдына саласы идем. Теге кашка сарык быел тагын көздән бәрәнләде бит. Үзенә охшаган ике кашка бәрән китерде, икесе дә саулык. Чемченергә өйрәнә торсыннар, дим. Ә-ә, әйдә, синең дә күрәсең киләме? Күр, күр. Шаяннар инде менә, кәҗә бәтиләре диярсең! — Галияр дипломатын өйалды баскычына куйды, һәм алар бәрәннәр абзарына таба киттеләр.— Әтиеңнәр эштә, энеләрең-сеңелләрең укуда. Рәйсә сеңлең дә эштә, ташлады бит укуын.

— Ничек инде? Уку ташлыйлар диме инде? Урта мәктәп тәмамлау мәҗбүри куелган лабаса бездә!

— Куелган да... Барыбыз да үгетләп карадык, авыл советыннан һәм мәктәптән килеп тинтерәтеп бетерделәр — бар-

мый гына Рәйсә мәктәпкә! Хәзергә шушы сигез класс белемем җиткән, ди. Кирәген тойсам, тагын укырмын аннары, ди.

— Син хупламыйсыңдыр бит?

— Колхозда хайван карарга шул белеме җитәр дип уйлыйм да, әмма үзенә алай дигәнем юк-югын. Башкаларга ияреп, мин дә үгетләгән булам шунда.

— Синең башкаларга бик ияреп торган гадәтең юк иде, әби, Рәйсәне укымаска үзең үк үгетләмисеңме икән әле?!

— Шулай иткән ди! — Сәрвия бәрәннәр абзары ишеге тоткасын каты итеп тартты, аннары ачыла башлаган ишекне шапылдатып япты.— Шулай иткән ди! Минем үгетләвем генә җитмәгән ди аңа! Үзе күрми ди ул, белми ди ул! Һе! Син аның солдаттан кайтуын сагынып көтәсең, ә ул капкадан керүгә сиңа гаеп ташлый! Күр әле ничек кыюланып кайткан безнең Галиярыбыз!

Инде әбисенең аркасыннан Галияр үз итеп сөйде. Әбисе оныгы кебек читкә тайпылмады.

— Шулай шул менә! — дип йомшарды Сәрвия.— Киреле-мырлы сөйләнсәң, кашка бәрәннәрне күрсәтмәм дә үзеңә!

Әбисенең әрләү сүзләрен елмаеп кына тыңлады Галияр.

— Әле исәнме-саумыны әйтеп бетермәгән — әбисенә сүз тидерә, әй! Кемнән тәрбия алдың син болай? Кемнән булсын, үземнән инде! Минем сөйкемле сөягем бит син!

— Әйбәт яшисез икән бит, әби. Шуны белдем менә.

— Һе, белми ни! Өйгә кермәстән, барысын да сөйләтеп бетертте дә мактанып тора әле өстәвенә! Астыртын җан!

Ике кара бәрән тупсага менеп көтеп торганнар икән, ишек ачылуга, сикереп җиргә үк төштеләр һәм, хуҗаларын онытып, лапас авызына таба чабып бардылар да туктап калдылар. Җирнең болай агаруын күргәннәре юк иде әле аларның, төнлә җирне каплаган кырпак куркытты үзләрен, ялт кире борылдылар да абзарга кереп качтылар. Кашка бәрәннәрнең арлы-бирле чабышып алуына Сәрвия белән Галияр сөенеп карадылар.

Өйгә кергәч, Сәрвия самавыр куйды, җиңелчә — башта ашсыз гына — табын әзерләргә кереште. Галияр, түр өйгә узып, ак күлмәген, чыгарылыш кичәсенә тектергән кара костюмын алды, хәрби киемен алыштырып киде.

— Әби, ничек? — дип чакырды ул алгы яктан әбисен.— Ничегрәк?

Сәрвия, юка каптагы каклаган казны күтәргән килеш, урта ишеккә килде дә Галиярга карап тукталып калды. Оныгының шушы костюмын кигән чагындагы килеш-килбәте онытыла төшкән, аның әле генә хәрби киемнән булуына күзе күнегә башлаган иде, шуңа күрә бу тиз үзгәрешкә сәерсенеп торды. Менә нинди булып үзгәргән икән аның олы оныгы Галияр ике елда... солдатта чакта! Ике ел элек кенә тектергән киеме шифоньерда торып утырган, диярсең әй! Пинжәгенең җиңнәре

беләзектән кул яссуы югары калган, изүе, төймәләгәч, чишеләсе килгәндәй тартылган. Хәтта чалбар балаклары да тубыгына җитәрдәй кыскарган. Галиярның киң маңгайлы, калын кара кашлы киң йөзенә костюмның карасу-зәңгәр төсе килешә икән дә, тик кечерәйгән шул костюмы. Дөресе, кием кечерәймәгән инде, Галияр үзе үскән. Күр әле син егетнең буй-сынын! Теге ерак замандагы Вильгельмнан гәүдәгә бөтенләй дә кайтыш түгел. Тазарак та булмаса әле. Ә йөзгә-биткә тамчы да охшамаганнар инде бер-берсенә. Вильгельм сары кыска чәчле иде, кашлары да саргылт иде, ә Галиярның чәч-кашлары чем-кара, сакал-мыегы да кап-кара булып төртеп чыккан әнә.

— Курач тора, улым, костюмың. Син бу киемнән үсеп чыккансың икән инде,— диде Сәрвия һәм кул хәрәкәте белән Галиярга әйләнергә кушты.— Пинжәгең арттан да малайсытып күрсәтә. Туктале, болай итик без, Галияр улым. Әйдә, чәй эчеп алыйк та, солдат киемнәрең белән урамны бизәп, кибеткә төшеп меник.

Өстәлгә тәм-томнарны күп тезде Сәрвия. Аннары итле шулпа бүлде, өресе ялтырап торган тәлинкәне, башка савыт-сабаларны кыса төшеп, Галияр алдына куйды. Газ плитәсеннән кайнар өчпочмаклар алды. Өстәлдә бу ризыкка, кайбер тәм-томнарны шүрлеккә куеп, урын бушатырга туры килде.

— Кемгә шушы хәтле әзерлисең, әби?

— Сиңа, улым.

— Кунак ризыклары пешергәнсең. Минем бүген кайтасыны белмәдең ич син!

— Белдем шул! Әтиең әйтте.

— Әти дә белмәде!

— Төш күргән әтиең! Бүген Галияр кайта, диде, иртүк әйтте. Мин сине бер тапкыр да төшемдә күрмәдем менә. Әллә хәтерең калганы булды инде миңа, Галияр улым?..

Егет кинәт кашларын җыерды, иреннәрен кысты. Әбисе аның йөзендәге бу үзгәрешне күрмичә калды. Галияр нәрсәдер әйтергә җыенды.

— Мин...

Шунда тукталып кала алуына сөенде ул, йөзенә елмаю кабат җәелде.

— Мин сиңа нигә үпкәлим ди, әби? Юкны сөйләмәче!

— Бик рәхмәт, алайса. Әйдә, әйдә, ризыкларның тәме китмәсен, аша син.

Галияр госпитальдә әбисен үзе төштә күрүен сөйләмәкче булган иде. Саташулы төш иде бу. Кайтып керүгә шуны әбисенә сөйләргә ярамавына ярый ла төшенеп алды ул. Газаплы төшне әбисенә сөйләмичә калмас Галияр, әмма хәзер сөйләргә ярамый иде. Бәлки, төшендәге соравына әбисе өнендә җавап бирер, Галиярның үлем белән тартышындагы соравы җавапсыз калмаска тиештер ләбаса...

Сәрвия, Рәйсәнең таңда кат-кат кабатлавын исенә төшереп, Галиярны башта кибеткә алып бару уеннан кире кайтты.

— Улым, элгәре болай ит,— дип, табак-савытны җыештыра башлады ул,— элгәре әтиеңнәр янына төш. Элгәре әти-әнинең хәлен белергә кирәк. Их-х, шулай инде, Галияр улым, картаям инде, минем сүз белән йөрер заманнарың узган. Әтиеңнәрне күрмәгән килеш, кибеткә куам бит, әй!

— Әби, әйдә, фермага бергә барабыз! Әтиләр янына!

— Бергәме? Әйдә соң. Башка көннәрне мин төш вакытына бара идем фермага, әтиеңнәр ашарга кайтыр чакта. Караучысыз калдырырга ярамый, колхозда да сарыклар бәрәнли.

— Нигә сарыклар? Әти дә, әни дә сыер фермасында эшлиләр иде бит.

— Хәзер сарык фермасын бөтенләе белән үзләренә алдылар. Хәзер колхоз эчендә колхоз оештыру гадәткә керде бит. Солдатта чакта ишетеп тә бетермәгәнсеңдер.

— Гаилә подрядымы?

— Шулай да диләр, килешенеп алынган эш, дип тә әйтәләр. Миңа калса, барыбер колхоз эчендәге колхоз инде ул сезнең подрядыгыз. Шуңа барып чыгачагын әтиең белән әниең аңлап җиткермиләр. Рәйсә ничек уйлыйдыр тагын, фикерен анык әйтми.

— Әби, нигә минем подряд булды әле бу? Сез оештырган ла аны!

— Юк, бу подрядның оешып китүенә минем печтик кенә дә өлешем кермәде. Моның юньле нәрсәгә китереренә ышанып җитмим. Сине Әфганнан кайтуыңа сөенеп каршыларга вакытлары да юк бит, ичмасам, әтиең белән әниеңнең. Ашау да эш, эшләү дә ашык-пошык ашау. Шул булдымы тормыш? Башта тормышны гаиләгә терәлгәнче таркауландырдылар да хәзер барысын да оештыруны гаиләгә калдырдылар. Ышанып җитмим мин бу подрядка. Элегрәк вакытлыча эшне, фәләнне пәдрәткә алдым, диярләр иде. Ә безнекеләр мәңгегә җигелделәр бугай.

— Ышанмыйсың, ә үзең фермага барып булышып йөрисең икән.

— Подряд дигәне булмаса да, булышыр идем инде. Гаилә казнасына минем дә өлеш салуым кирәк ич.

— Гаилә казнасына салырга синең пенсияң бар, әби.

— Тәпи басканнан диярлек колхозда эшләп, янчык төбен генә күмәрлек пенсия алам бит мин, улым.

Әңгәмәнең ямьсез якка китүен теләми иде Галияр. Хәер, моны Сәрвия дә теләми иде. Әмма нишләмәк кирәк — сүз тормышның онытырга ярамый торган четереге турында бара лабаса.

— Синнән гаилә казнасына өлеш таләп итүче юк, әби. Түр башында гына утырырга тиешле кешебез син безнең.

— Түр башында утыручы кеше түрә дип атала. Ә мин түрә булмадым, шөкер. Булмам да, Аллаһы боерса. Акчада гынамы

хикмәт, Галияр улым! Совет властена нәкъ җитмеш ел тулды, шуның ничә елын авыл кешесе бушка эшләгәнен санарга тотынсаң, башыңны селкеп утырудан башка чараң калмаса... Бушка эшләвенә дә, пенсиясе бәләкәй булуына да без күнеккән инде. Минем буын кешеләре аерата күнеккән.

— Хезмәтең үзеңә дә, башкаларга да, ягъни җәмгыятькә дә, файданы зурдан китерсен өчен оештырыла гаилә подряды. Кем әйтмешли, сиңа да, миңа да.

Галиярның, солдаттан кайткач, туган йортында беренче чәй эчүе шундый әңгәмә белән болганып барды. Әбисенең, читтән кайтучыны гадәттә йомшак сүзләр белән каршылау кирәклеген онытып торып,— хәер, аңа төчеләнү гомеренә ят һәм бу сыйфат аңа хәзер генә ятышмас та иде — оныгын дөньяви хәлләргә турыдан һәм кичекмәстән алып керергә сәбәбе булгандыр, күрәсең. Тормыш дигәнең, усал телле апайлар сүзе белән әйтсәң, колхозда бушка эшләп черегән Сәрвияне һәрнәрсәне бөтереп тотарга күп чак камчылап өйрәтте.

— Миңа да, сиңа да булгач, менә син дә бик әйбәтләп кенә эшләрсең сарык фермасында, яме.

— Туктачы, әби, болай үтә дә гадиләштереп җибәрмә син! Нигә фермада эшләргә тиеш ди мин?!

— Фермада эшләргә нияте юк икән Галияр улыкаемның, әй! Ичмасам, кадерсез сүзләрен ишетеп торырга кешесе дә юк бит аның шушында! Әйтсәң, кеше ышанмас!

— Ышанырлар, әби, синең ялган сөйләмәвеңне бөтен дөнья белә! — диде Галияр һәм чынаягын каплап, читкә этәрде. Чәйризык өчен рәхмәтен әйтеп, әбисенең җилкәсенә кагылды да урыныннан кузгалды.— Инде минем эш яратканны белеп...

— Мактанчык...

— ... ышанмаска теләсәләр, үз авызым белән әйтермен.

— Ничек диярсең икән? — дип, башын Галиярга таба кыйшайтып алды Сәрвия.

— Мин безнең гаилә подрядына катнашмыйм, мин бары тик авыл советы рәисе булырга телим, диярмен.

Сәрвия Галиярның аркасыннан сөйде, бу юлы кулын солдаттан кайткан оныгының калак сөяге тирәсенә күтәрмәде, бая аның кинәт каерылуына игътибар иткәндер, ахрысы. Карчык егеткә елмаеп карады, шатлануы күзләрендә сизелә иде аның.

— Әле дә ярый син бар, Галияр балакаем! Синең белән рәхәтләнеп сөйләшергә ике ел буе сагынып көттем бит мин! Беләсеңме шуны?! Әтиеңнең дә, әниеңнең дә — тфү, тфү, киленне яманлау булмасын тагын! — сеңелләреңнең-энеләреңнең дә авызларыннан сүз тартып алып булмый бит. Олы сеңлең Рәйсәне генә, авызыннан ут чәчә башласа, туктата алмыйсың! Көенә килмәсә инде — аны да сөйләштерермен димә! Кешеләргә ачык күңелле булырга өйрәтәм канә үзен, юк кына — үз эченә бикләнә дә куя кайчак. И-и Аллам... Ярар инде, әтиеңне

үстергәндә, бала тәрбияләү тәҗрибәм булмаган ди. Ничә еллар бер түбә астында яшәп, әниеңә печтик кенә дә йогынты ясый алмыйм, сеңелләреңэнеләрең тагын минем якны тартмады. Рәхмәт яугыры, син гел дә үзем инде менә, ичмасам!

Китәргә торганда гына Сәрвия Галиярны җиңеннән тотып туктатты.

— Улым, дим, авыл советы рәисе булам, дип шаярып кына әйтәсеңдер бит? Ары укымассыңмы?

— Нигә шаяртыйм ди? Һәм рәис булачакмын! Хак әйтәсең, әби, укымыйча ярамый. Читтән торып укырмын.— Егет сүзне бүтәнгә күчерде.— Кайтышлый Ваһим абый очраган иде. Нигәдер кәефсезрәк.

— Эчкәли бит.

— Өзә-төтә генә сөйләште. Авылның кадере бетте, ди. Ал әле авылны үз кулыңа, ди. Ә, әби, авыл советының рәисе һаман да...

— Һаман да шул! Шуны сайладылар.— Сәрвия, бераз уйланып торгач: —Сайлаттылар,— дип өстәде.

— Сез җебеп торгач, сайлатырлар шул! Мин авылның власть башында кунаклап кына утырсам, һич тә җебеп тормаячаксыз, мәтәлдереп кенә төшерәчәксез мине, монысын инде суга сәнәк белән язмаган, бик белеп торам мин шуны!

— Шуны белә торып, рәислеккә дәгъва итәсеңме?

— Итәм!

— Теләгеңә ирешсәң...— дип тукталды Сәрвия.

— Теләгемә ирешсәм — нәрсә?

— Теләгеңә ирешсәң...— дип кабатлады карчык,— капкачлы кесә сәгате бүләк итәм үзеңә! Көмеш чылбырын кесәңнән салындырып, кыяфәтеңә килештереп йөрерсең.

— Һоп-па, әби, гафу, яме! Хәзер!

Галияр ишек катындагы урындыкка куелган дипломатын ашыгып ачты һәм аннан төргәк алды. Газетасын сүтте дә яшел, кара, кызыл бизәкләр төшерелгән шәльяулыкны әбисенең башына япты.

— Әби, сиңа солдат бүләге, яме!

— Рәхмәт яугыры! Сырхау белмичә яшә, улым.

— Ошаттыңмы, әби? Урта Азиядә — мин соңыннан булган якта — мондый шәльяулыкны әбиләр бик яратып бөркәнәләр. Туктале, дидем, минем Сәрвия әбиемә дә бик килешергә тиеш бу шәльяулык, дидем дә, сиңа бүләккә шуны алдым.

— Синең бүләк белән кайтуыңа өметләнмәдек тә инде без, улым. Сау-сәламәт кайтуыңны теләдек.

— Сәламәт кайттым, әби, сәламәт. Күрәсең ич, аякларым йөри, кулларым эшли.— Галияр кителен төймәләде, көзге каршында фуражкасын төзәтенеп киде. Әбисенең шәльяулыкны төрүен көзгедән күрде дә солдатча артка борылды.— Әби, алыштырма яулыгыңны, әтиләр янына шуны бөркәнеп төш. Син борчылма, аларга да бүләкләрем бар.

— Фермага кунак шәльяулыгы бөркәнеп төшәргә ди! Әллә син әбиеңнең акылы сөртенгән дип beләсеңме?

— Минем әби акылын беркайчан да җуймаячак! Бүләк яулыгыңның читләрен менә шушылай чыгарыбрак калдырып, мамык шәлеңне ура да — әйдә, киттек! Син фермага эшләргә бармыйсың.

— Көтүче хатыны кич бизәнә дигәндәй, син мине гомерем киченә таба бизәндермәкче буласың мәллә?

Галияр шаркылдап көлеп җибәрде.

— Әле син кызларга тиң, әби!

Гадәттә кешенең яшьлек төсмерләрен саклавына ишарә итеп әйтелә торган бу сүзләр карчыкның күңелен тырнарга тиеш кебек иде. Ләкин оныгының сүзләре мәгънәсен аңлый Сәрвия. Аның бердәнбер баласы Тимерша әтисе кем булуын белмичә үсте. Заманында, Сәрвия Тимершаны тудыргач, авылда, хәтта күрше-тирә авылларда да, гайбәт куерган иде. Сәрвияне гаепләүчеләр дә, гөнаһсыз баланы атасына тагарга киңәш итүчеләр дә күп булды. Беренчеләренең гаепләвеннән Сәрвия, сугыш китергән кайгысына шаяртуын да кушып, миңа дигән егет сугышта һәлак булып кайткач, Ходай, мине ялгызымны гына калдырмас өчен, Тимершаны миңа үз кулы белән бирде, дип акланырга теләсә, икенчеләренең киңәшен, үз балам — үзем үстерермен, дип, кире какты. Һәм Тимершаның әтисе һәм, димәк, Галиярның бабасы кем булуын авылда хәзергәчә белмиләр. Сәрвиянең үзеннән башка, әлбәттә. Ә баласын үстергәндә авырлыкларны күтәрергә ялгызының көче җиткән икән, хәзер бигрәк тә ачылмастыр шул. Аннары бит авылда да, гаиләдә дә бу мәсьәләне кузгатучы юк...

Өйалды ишегенә келә салып, капкага җиткәндә, оныгының изге нияттән әйткән сүзләренә әйләнеп кайтты Сәрвия. Шунда аның яшьлегендә кылынган эшен, кем әйтмешли, үз каланчасыннан торып, хәзер дә якларга әзер икәнлеге ачык сизелде.

— Кызлар кебек булмаска ни! — диде ул һәм усал ук итеп өстәде.— Үзем беләм мин! — Тагын: — Үзем беләм! — дип кабатлады.

Галияр саташулы төшендәгечә: «Мин дә бабайны белергә тиеш!» — дип әйтеп җибәрә язды, ләкин үзен тагын тыеп өлгерде. Чөнки таләбен әбисенең бер сүзенә бәйләп кенә, ягъни сүз уңаеннан гына әйтергә ярамый иде. Бу хакта алдан ныклап уйлангач кына һәм әбисенең кәефе бозылмаслык чагында гына сорарга тиешлеген егет күңеленә ныклап беркетте.

## 2

Утыз сигезенче ел иде. ТБУМның чыгарылыш классы — җиденче класс укучылары соңгы имтихан тоткан көндә, уналтынчы июньдә, Таукаш авылына яңа укытучылар килде. Төш вакыты, авылның тынып калган чагы. Шуңа күрә дә ике атка

төялеп килүчеләрне урамда күреп торучылар уенга мавыгып, ашавын оныткан балалар гына булды. Бала-чага боларны авыл аша узучылар дип уйлаганнар иде, чөнки атлары Таукашныкы түгел, ә балалар үз авылы атларын таныйлар, хәтта аларның элек кемнәр атлары булуын яки кем атыннан тууын беләләр. Хәбибрахман аты, Мостафа биясе колыны — бу иркә колын Сәрвияләр атыннан туды — дип, атның элекке хуҗаларын атап, малайлар мактанышырга да яраталар. Сәер, килүчеләр авылның ындыр артына ике катлы итеп салына башлаган мәктәпкә генә чыга торган берьяклы урамга — Кече күпер урамына борылдылар һәм, хуҗалары язылып читкә киткәч, инеш буендагы буш торучы йорт янына туктадылар. Димәк, аларның күченеп киләсе авыл җитәкчеләренә алдан билгеле булган инде. Югыйсә буш йортка басып алгандай барып кермәсләр иде. Алгы атның дилбегәсен тоткан сигез яшьләр тирәсендәге малай, капка ачылып ишегалдына узганда, артка борылып, биек читле фуражкасын батырып куйды да кызыксынып карап торучы балаларга йодрык күрсәтеп өлгерде. Авылның район үзәгенә чыгара торган урамы буйлап төшкәндә, һәр йорт-җирне җентекләп күзәткән Моназыйр исемле бу малайның Таукаш авылына — аның уртасына җиткәч! — бирелгән беренче сәламе шул булды. Малайның, килүчеләр арасында иң кечкенәсе булса да, үзен өстен тотып йодрык күрсәтүендә эчкерлелек, гәрчә монда әле берәү белән дә аралашмаса да, яман булып сизелде. Ул әйбәт Таукашка күчеп килүенә канәгать түгел дә, әйтерсең аның күченүенә шаккатып карап торучы балалар гаепле. Миһербансыз җан, безнең әйбәт Таукаш кешесе булып китәргә печтик кенә дә охшамаган!.. Әти-әнисе дә, йөкләр тирәсендә бөтерелеп йөрүче чандыр гәүдәле абыйсы да салкыны бөркелеп торган Моназыйрга бөтенләй тартым түгелләр, кешелекле күренәләр.

— Йодрык күрсәткән була тагын! — диде Сәрвия.

Аның, җиденче класс өчен соңгы имтихан тапшыргач, өстеннән зур йөк төшкәч — сер түгел, авырдан укыды ул — инеш буенда ялгызы гына йөреп тынычлангач, өенә кайтуы иде.

— Утырган атының ябагасы да коелып бетмәгән үзенең! Җәй җитеп! Кыланмышы! Йодрык күрсәт! Адәм актыгы!

— Безнең авылда ябагасы коелмаган ат юк та! — дип кушылды аңа төркемнән бер малай. Сәрвия, аның башыннан сыйпап, елмаеп узды.— Безнең авылның барлык атлары шәп!

Әмма Сәрвиянең дә, Таукаш атларын мактаучы малайның да сүзләре килүчеләргә ишетелмәгәндер, аларга җавап кайтаручы булмады. Моназыйр, ишетсә, һич тә җавапсыз калмас иде, Сәрвияне үзеннән өлкән дип тормас, әче сүзен тапкан булыр иде. Йодрыклы малайның үз сүзен аста калдырырга яратмавын ул соңыннан белде. Хәер, Моназыйрның мондый даны авылга килгән көннәреннән үк таралды. Һәм Моназыйр, әле бала

гына булуына карамастан, тыйнак Таукаш күгендә үзенең корбанын эзләп-сагалап очучы тилгән кебек күренә башлады. Аңа, озак көттермичә, кушамат та ябышты — Тилгән Моназыйр.

Аның әтисе дә, әнисе дә алдагы уку елында мәктәптә укытачаклар икән. Күр инде, галәмәт, ике укытучы нинди явыз күңелле бала үстергәннәр бит, әй! Кем уйлар диген! Соңрак ачыкланды — Моназыйрның әтисе белеме буенча укытучы түгел икән үзе. Ул район үзәгендәге нindидер оешмада хисап эшендә булган да, шул эшеннән чыгаргач, аны укытучылыкка җибәргәннәр икән. Ләкин Тилгәннең әтисе Таукашта укытмады, мөгаллимлек үз һөнәре түгеллеген аңлагандыр, күрәсең. Эшләгән урыны соңыннан ачыкланды — август башында ул райпо дигән оешмада кабат эшли башлады. Эшеннән тиешсез чыгарылуын исбат иткән дә урынына кире алырга мәҗбүр булганнар, диделәр. Әмма гаиләсен район үзәгенә кире күчермәде, көн саен барып-кайтып эшләп йөрде, ара ерак түгел ич — биш чакрым гына. Авыл тормышына якыннан катнашмады агай. Сугышка Таукаштан китте. Аралашырга яратмаучы бу кеше сугышка киткәндә кемгәдер:

— Бер урында тамыр җәеп, төпләнеп яшәргә насыйп булмаган икән миңа,— дигән, имеш.— Сугыш һич тә уйламаган җиргә төпләп куячак икән мине... Чит җирнең салкын куенына...

Һәм ул сугыштан кайтмады. Батырларча һәлак булуы турындагы язуны һәм солдат дуслары җибәргән сугышчан бүләкләрен хәзер кече малае Моназыйр үзендә саклый.

Моназыйрның әнисе Таукаш мәктәбендә тарих һәм география укытты, әйбәт укытучы саналды, сугышка чаклы салына башлаган мәктәпне өлгерткәч, анда география дәресләрен барлык класслар өчен дә үзе бизәгән бүлмәдә үткәрү тәртибен керткән иде. Авыл кешеләре хөрмәт итә иде бу укытучы апаны. Кешеләргә кулыннан килгәнчә ярдәмен кызганмады ул, киресенчә, кемгәдер ярдәме тисә, моңа иң башлап үзе сөенә иде. Аның бераз гына озынчарак йөзе, авыл кешеләре белән танышкандагы матур елмаюы Таукаш халкының күз алдында калды. Вафат инде ул. Аның вафатыннан соң олы малаеның авылга кайтканы юк, Чиләбе ягында яши. Бер яшьтәше белән хат алыша, ләкин бертуган энесе Моназыйр белән хәбәрләшми икән.

Таукашта бу гаиләдән, килүенә беренче очраган кешеләргә — уен остасы балаларга — йодрык күрсәтсә дә, Моназыйр төпләнеп калды. Һәм... нык тамыр җәйде. Юк, алай гына да түгел! Колачын да җәйде!

Утыз сигезенче елда үзләре килеп урнашкан йортны, читкә киткән элекке хуҗалары белән хат аша килешеп, сатып алганнар иде Моназыйрлар. Иске йорт янына илле бишенче елда Моназыйр алты почмаклысын җиткерде. Шуннан соң гына элеккесен сүттерде. Утыз елдан артык торды Моназыйрның авылда иң зурысы булган алты почмаклы йорты. Һәм тагын да

торырлык иде әле. Дүрт баласы да калага барып урнашып, Моназыйр үзе дә хатыны Ниса-Гөлниса гына калгач, таза, иркен һәм килешле йортны сүтеп, яңасын җиткерергә хаҗәте юк иде кебек. Ләкин авыл кешесенең бик хаҗәте булмаганда чыгым ясамау гадәте, крестьянлыгының кайбер бүтән сыйфатлары белән беррәттән, юкка чыга бара. Кесә байлыгы рухи байлыкны узып китү галәмәтедер инде бу. Һәм син күр дә мин күрнең ямьсез чагылышыдыр.

Эш яшеннән чыгар чагы җиткәндә, йорт яңартырга исәпләмәгән иде Моназыйр. Әмма хатыны өзмәде дә куймады, бу мәсьәләдә ирен бөтереп кенә алды. Моназыйрның хатыны Таукаш тумасы түгел, Моназыйр аны илле бишенче елда, әле беренче йортын салган елда, Пенза ягыннан кәләше итеп алып кайткан иде. Армиядә хезмәт иткәндә танышканнар икән. Утыз елдан артык бергә яшәп, гаиләдә Моназыйрның сүзе аста калганы юк иде, ә яңа йорт салу мәсьәләсендә хатыны җиңде. Бәлки, монда хатыны теләгенең Моназыйрның үз теләгенә туры килүе дә булгандыр, югыйсә Моназыйр сынмаган булыр иде.

— Күр син башкаларны, нинди пулатлар салганнарын күр кешеләрнең! — дип көнләшеп әйткән иде хатыны.— Авылда синең электә иң зур йортың хәзер иң кечкенәсе булып калып бара бит. Күр инде син бу йортны, бүгенге заман өчен алачык кына бит инде бу йорт хәчтерүше! Йөрисең шунда авыл советы преды булган булып! Адәм мәсхәрәсе!..

Мондый тәнкыйтькә генә колак салмаган да булыр иде Моназыйр, өстәвенә хатыны шулай бер тавыш чыгарып ала да бу хакта оныта аннары, кабат моңа әйләнеп кайтмый. Ләкин үз күңелендә дә көнчелек калкынган иде шул, әнә шуңа күрә яңа йорт салуга керешәсе итте. Балаларыннан ярдәм сорамады, хатыны сакчыл кеше, үз янчыкларындагы хәзинә җитәрлек, кешеләргә теләнеп йөрисе түгел. Һәм былтыр җәй, чыршы бүрәнәләрдән салынган алты почмаклы йортны сүтмәстән, бакча эченә, инеш буенарак, буласы йортның кысасын кирпечтән өйдереп тә куйдылар. Быел, биксән җиденчелең җәендә, җиткереп тә чыктылар. Хәзер суына да үз турыларындагы чишмәгә төшәсе юк, краннан ага су, җылытуын да парга көйләделәр. Һәм авыл советы рәисе Моназыйр Шәгаетовның йорты Таукашта тагын иң зурысы булды. Әйе, Таукаш тумасы түгел Шәгаетов, ә авылда күп нәрсәдә нәмүнә күрсәтә, хәтта күп нәрсәдә үрнәк булуны вазифасы итеп саный Таукашка йодрыгы белән янап килеп кергән Моназыйр...

Каз-үрдәкне ишле үстерсәләр дә, Моназыйрларның өмә ясаганнары юк. Өчәр-дүртәрләп чала да Моназыйр, хатыны көнендә эшкәртергә ялгызы да өлгерә. Җир алдан туңдырып, узган төн кырпак төшкәч, шәһәрдәге дүрт баласына кучтәнәч итеп җибәрү өчен, бүген дүрт казны суясы иттеләр. Моназыйр иртәнге якта, Рәйсә белән очрашканнан соң ук, эшенә барды,

хатыны мал-туар карап, өйдәге вак-төяк эшләрне бетергән чакка өенә кайтты. Сәрвия белән Галиярга очраганда, дүрт казны чалып, тагын эшенә барышы иде аның. Район үзәгенә чыгарга торган урамга борылуга, каршына Сәрвия белән Галиярның — кайткан икән оныгы, дип уйлап алды авыл советы рәисе — килүен күрде Моназыйр. Сәрвия ялгызы гына булса, исәнләшмичә дә узар иде ул. Таукашта илле ел яшәп, Сәрвия белән иплэп сөйләшкәне сирәк аның, болары да моннан бик күптән булды. Моңа Моназыйр иптәш Сәрвияне генә гаепле итми, үзенең холкы да сәбәпчел икәнлеген белә. Шулай да Сәрвия алдында фигылен үзгәртергә бүген дә нияте юк иде. Ләкин карчыкның янәшәсендә солдат оныгы булгач, баш кагып сәламләп кенә узу, тукталып күрешмәү килешмәс иде. Алты яшьлек кунак кайтса, алтмыш яшьлек күрешә бара, диләр бит әле. Ә бу очракта Галияр катына барасы юк, үзе үк каршыга очрап тора.

— Ә-ә, солдат кайткан икән! Исәнме, Галияр! — дип кулын сузды егеткә Моназыйр. Аның уң кулы, сеңгере тартышыпмы шунда, терсәктән бөгелебрәк калган иде, шуңа күрә егеткә кулын биргәндә, Моназыйр алга иелде. Аннары Сәрвиягә борылып: — Исән-сау йөрисеңме син дә, Сәрвия,— диде, карчыкның яшькә өлкәнрәк булуын белә торып, хәзер дә апа дип олыламады.

Сәрвия башын кагып исәнләште дә алга узды. Гел көтмәгәндә каршына килеп чыга бу Шәгаетов, дип уйлады карчык. Гомеренә шулай. Сәрвия, урамның каршы ягына чыккач, Галияр белән Моназыйрга борылып карады.

— Һе,— дип көлемсерәде ул һәм үзалдына сөйләнеп алды.— Һе, теге заманда ук әле, мин әсирләрнең тезелешеп узуларын карап торганда да, бу Моназыйр нәкъ шул төштә калкып чыккан иде. Әкәмәт...

Ә теге заманда...

Кичке уңай иде. Сәрвия төнгә эшкә барганда, әсирләрнең район үзәгеннән кайтышы иде, аларны МТС ихатасын койма белән әйләндерергә йөртәләр. Сәрвия әсирләр арасыннан Вильгельмны тапты, Вильгельм да аны күрде, Сәрвия турысыннан узганда сөенеп елмайды, кыз да аңа елмайды, Вильгельм башын иде. Сәрвия, үзе генә ишетелерлек итеп:

— Исәнмесез,— диде.

Вильгельм да нәрсәдер әйтте. Кызның сүзен бу юлы да башкача аңлады, үз исемен кабатлады, ахры.

Әсирләр узып киткәч, урамның каршы ягында Моназыйр калкып чыкты. Соңгы елда буйга кинәт тартылып киткән Моназыйр әсирләрдән артта калып килүче капитан Сафаның каршына төште, аның белән кул биреп күреште. Һич кенә дә тыкшынмаган җире юк бу Моназыйрның, әсирләргә башлык булып калган Сафа белән дә танышып өлгергән икән. Килешкилбәтен, кыяфәтен күрсәңче, капитан Сафага, кулларын болгый-болгый, нәрсәдер сөйли. Әллә акыл сата тагын?!

Галиярны көткәндә, шушы вакыйганы күз алдыннан кичерде Сәрвия карчык. Гаҗәп хәл, Сәрвия әсир солдат Вильгельмны бүген икенче тапкыр исенә төшерә инде. Оныгы Галиярның солдат хезмәтеннән кайтуы сәбәпче булды бугай моңа. Солдат кайчан да, кайда да солдаттыр шул...

Карчык оныгын чакырып эндәшмәкче иде, тик кире уйлады — Галияр әбисе җитәкләвенә мохтаҗ түгел ләбаса. Ә Галияр белән Моназыйрның әңгәмәсе куерып кына бара иде.

— Авылда калу уең юктыр, шәһәргә китәргәдер исәбең,— диде Моназыйр. Ул башын арткарак ташлады, үзен бик өстен куеп, егеттән көлеп алырга теләведәй тоелды аның бу хәрәкәте.— Яшьләрдән авылда калучылар бер кул бармаклары белән генә санарлык.

— Юк, мин китмим.

— Бик шәп! — дип үзгәрде Шәгаетов.— Югыйсә минекеләр дә китеп югалды. Авылны оныттылар. Ә авылга яшьләр кирәк. Әтиеңнәр яңача эш оештырып йөри. Булышырсың үзләренә.

— Юк, мин гаилә подрядына кермим.

— Колхозда эш бетмәгән, бүтән эш тә табарбыз.

— Юк, мин үземә эшне үзем табам. Авыл советы рәисе булу һәм шәп итеп эшләү минем теләгем.

Моназыйр беравык өнсез торды. Кыска туны изүенә озынча ияген тартып яшерде, аннары, башын чөеп, ияген алга чыгарып, тагын шөкәтсез салындырды. Егеткә туры карап елмайды, йөзенә җәелә башлаган мөлаемлык сыпырып алгандай кинәт бетте, болай да зур күзләрен акайтып, Галиярга зәһәрле чәнчеде.

— Минем урынгамы? — дип, кашларын җыерды аннары.

— Сезнең урынга инде! Бер авыл советында ике рәис була алмый.

— Шаяртуың түгел, ахрысы...

— Чынлап торып тотынам! Авылда властьны тәртипкә китерергә җайлы чак җитте.

— Таукашта власть көчендә бит, Галияр энем. Хафаланасың юк иде. Рәис булу өчен башта депутат булып сайланырга кирәк.

— Беләм. Сайланырмын. Нигә мине сайламаска тиешләр икән? Койрыгым-гөнаһым юк.

Моназыйр, кулын селтәп, китәргә адым да ясаган иде дә, Галиярның чынлап сөйләвенә ачуы тулып җитеп, кырт борылып туктады, тавышын калынайтып:

— Шулай итеп, мине чөеп ташламакчы икәнсең, Галияр энекәш, ә! — диде.— Ай-һай ла, партия-совет эшендә тәҗрибәсе ташып торган кеше белән, Моназыйр абыең белән ягъни, алышуы җиңел булмастыр. Авыл советларына сайлаулардан соң биш ай гына узды, энекәем. Киләсе сайлауларга чаклы шактый вакыт бар, диюем. Монысы — беренчедән. Икенче-

өченчеләрен һәм башкаларын санап та тормыйм. Элгәре, авыл советына килеп, хәрби исәпкә бас, солдат иптәш.

— Тәртипне бозмам, борчылмагыз, Моназыйр абый. Әле кайтып кына төштем. Әти-әнине күрим элгәре. Фермадан кайтышлый авыл советына керермен. Документларым кесәмдә.

— Их-х,— дип тирән сулады Моназыйр,— тормышны аңлап җиткермисез шул сез, яшьләр! Киләчәкне уйламыйсыз. Кулыгыз ныгымастан, замана дилбегәсен тотмакчы буласыз!..

Галияр, урамның икенче ягында көтеп торучы әбисенә ашыгуын аңлатып ишарәләде дә, Моназыйр белән сүзне өзәргә булды. Мондый бәхәсне урам уртасында куертуның мәгънәсе юк иде, хәер. Шулай да әңгәмәгә ноктаны үзе куясы итте ул.

— Киләчәк турында фәлсәфә куертырга яратасыз инде сез. Һәрчак кесәгездә йөрткән, хәтта телегезгә сеңгән козырь ул сезнең. Тик, киләчәкнең матурлыгы мәгънәсенә төшенмичә, кирәктә-кирәкмәстә чыгарып сала башлагач, кәртегез тузды бит. Ә тормыш дилбегәсенә килсәк, сез аны, барыр юлыгызны белмичә, малай чактан ук тоткансыз. Дөрес әйтәсез, дилбегәне кул ныгымастан тотсаң, кулның гарипләнүен көт тә тор. Ә минем куллар, менә, ныгыган, солдатта булган крестьян куллары.

Моназыйрның кулы гариплегенә искәртү кебек иде бу кадәресе, әмма инде сүз әйтелгән, аны кире ала алмыйсың. Аннары кул ныгу мәсьәләсен Моназыйр үзе башлады, шулай булгач үкенергә кирәкмәс, дип уйлады Галияр. Ләкин ул, авыл советы рәисенең кулы гариплегенә ишарәләп, аны тагын өнсез иткән иде. Моназыйрга бу хакта йөзенә бәреп әйткәннәре юк иде әле, шуңа күрә кул гарипләнү сәбәбен авылда белмиләрдер дигән ышанычы бар иде. Беләләр икән, Сәрвиянең онытгы белә икән менә. Сәрвия сөйләгән булуы мөмкин. Хатын-кыз лабаса ул, бу хакта авызын ачмаска да тиеш иде. Әй-й, хатын-кыз сер тота диме соң...

— Сәрвия нәселеннән моңарчы юньлелек күрмәдем, моннан ары көтмәм! — дип ачуланышуны дәвам итмәкче иде авыл советы рәисе.

Әмма аның бу сүзләрен Галияр инде ишетмәде, ул, Моназыйр өнсез торган арада, урамның теге ягына, әбисе янына чыгып җиткән иде, һәм алар юлларын дәвам иттеләр. Ә Моназыйр, кая барырга белмичә, баскан урынында озак катып торды. Авыл советы канцеляриясенә барса да, өенә кире кайтса да, Галияр солдатның йөзгә бәреп әйтелгән нияте тынгы бирмәячәк иде аңарга — Таукашны илле еллап кулында тоткан Моназыйрны урыныннан очыртмакчы да үзе авылга хуҗа булып алмакчы икән Галияр! Җитмәсә, иртәнчәк сеңлесе Рәйсә яла ягу турында тәкелтәп маташты... Гәүдәсен бераз янтайтып, карашын Галияр белән Сәрвия киткән якка текәсә дә, Моназыйрның йөзендә һәм зур ачылган күзләренә бернәрсә дә күренмәүдә ачуы ярылып тора иде. Әйе, үлчәүнең ачудан үҗәтләнеп

үз киресен итү тәлинкәсеме, әллә кешеләрне кыерсытуы, урынсызга рәнҗетүе өчен гафу үтенергә теләп бармак очлары белән ябышкан ягымы басачагын хәл итәргә тиешле халәте идеме Моназыйр атлы җитәкченең. Заман үзгәрешләре һәркемнән иң башлап үз рухи дөньясы хәзинәсен барлауны таләп итүен аңларга телиме һәм шуны аңларлык көче бармы соң Таукаш авыл советының бүгенге рәисенең? Әллә гомеренә кушуны каруланмыйча, кешеләрне кысрыклауда өстәвенә үз иҗади яңалыкларын тормышка катгый үткәргән Тилгән Моназыйр басып торган урыныннан кинәт кенә юньле булып китә алмасмы? Әллә нәкъ менә кырыслыгы кискен борылыш ясатырмы Моназыйр иптәшне? Мондый үзгәреш һәр кешенең рухияте байлыгыннан тора, хәер...

Моназыйр авыл советы канцеляриясенә бармаска булды, өенә кайтырга да борылмады. Район үзәгенә чыга торган шушы озын урамнан бераз күтәрелгәч, ике якта алтышар гына йортлы урамга керде. Таукаш авылы шулай салынган инде — аның озын урамы, болын эченә кереп, Мишәгә керә торган инешкә, туры сызыктай булмаса да, параллель диярлек бара. Башка озын урамнары юк авылның, ә кыска урамнар җидәү, алар озын урам белән бала-чага коенырлык тугай-борылышлары булган инешне тоташтырып торалар. Әлеге җиде урамның һәркайсының зурлыгы озын урам белән бормалы инеш арасындагы ераклыкка бәйле. Иң кечкенәсе һәр якта өчәр генә йортлы, ә арада зурысы — Моназыйр борылганы. Инеш аша күпер шушында, күрше авылга юл шушыннан китә. Моназыйр яши торган урам исә, бер генә яклы булса да, җиде йортлы. Шушы урам турысында инеш аша таш баганалы кечкенә күпер-басма бар, авыл халкы гомер-гомергә нык хәлдә тотты аны, сугышка чаклы кысасын күтәреп, түбәсен ябып өлгергән мәктәп шушы берьяклы урам турысында, бу тирәдә шактый тәбәнәкләнгән тау өстендә. Шушы урам белән Моназыйр борылганы арасында зур мәйдан бар, монысында йортлар юк, монда элек мәчет булган. Мәчетне сүтеп, ак кирпечтән зур гына клуб салганнар иде, китапханә шунда, җыйнак һәм килешле бу бинаның икенче катына авыл советы һәм колхоз идарәсе канцеляриясе урнашкан.

Канцелярия ягына карамыйча да узды Моназыйр. Күпергә кергәч, таянса янына килеп, инешкә текәлеп торды. Инеш буйлары кырпак кардан акланган, су күммәгән ташлар өстенә төнлә кунган кар бөртекләре эреп бетәр-бетмәс кенә калган, таштан су җылысы бәрә бит. Инеш суы тирә-юньдәге аклык арасында карарак булып күренә, Таукаш инешенең суы Моназыйрга гел аксыл төсле булып тоела иде югыйсә. Күпердән аскы яктагы шарламаны кыш буена боз капламый, кышкы аклык уртасында кабаланып гөрләгән шарламаны Моназыйр моңарчы да күрә иде, ләкин суның кышын каралуына игътибар итмәгән икән. Бәлки, җир өсте агаргач кына инеш суы карала торгандыр, әкәмәт.

...Ага су. Аккан су артыннан күзәтеп торуы гаҗәп икән, әй. Синең яннан тормыш китеп бара кебек, борылышлар да, берсенә берсе terәлешкән ташлар да аны тоткарлый алмый. Ага... Инде беркайчан да Таукаш инешенә әйләнеп кайтмау нияте белән ага. Тормыш дигәнең дә шулай хушлашмыйча китәме? Агымсуның артына басып күзәтү үткән заманга кайтырга тырышу кебек икән. Киләчәк дигәнең күренми бу агымда. Әгәр суның агымына каршыдан карасаң?..

Моназыйр, ашыгып атлап, күпернең өске як таянсасы янына басты. Тик бу якта да агым киләчәк кебек булып тоелмады. Әле әнә өстәрәк, биек таллар турысында, агымның матур серлелеге бар кебек үзе, ләкин бу серлелек тә киләчәккә охшамаган, аның сихри чагылышы түгел. Агым уртасында тора Моназыйр — күпердә! Ә бу агымның гүзәл киләчәге түбәндәме, әллә өске яктамы икәнлеген аера алмый. Һәрхәлдә, киләчәк дигәнең түбәнге якта түгел, моны түбән сүзенең мәгънәсе ачык аңлатып тора. Өске яктамы ул? Ярар, шулай да булсын, ди. Әмма инешкә кыска урамнарның югарыдагысыннан төшеп карасаң, хәзер синең каршыңа килгән агым түбәнге якта — үткән заманда булып чыга түгелме соң?!

Менә син, әй, гомере буе киләчәкнең матур булачагы турында әгитләү алып барган Моназыйр, инеш агышын тормыш агышына тиңләп, киләчәкнең кайсы якта икәнен тәгаенли алмады.

Беренче тапкыр болай чагыштыруы иде аның. Шуңа күрә киләчәккә юнәлешне абайлап җиткермәгәндер. Аннары, агым уртасында торса да, бу урталыкны тоюы шартлы бит, чөнки агымның эчендә түгел, ә, уртасына турылап, күпер өстендә тора. Агымны да тоймакчы, юешләнмәскә дә исәбе.

Сул кулыннан ак йон перчаткасын салып, таянсага учын җәеп куйды Моназыйр. Бераздан инешкә кулын каты итеп селтәде, таянсадагы кар эреп, иләмсезләнеп төшкән учы эзен сөртеп җибәрмәкче булды, ләкин кулын кинәт кире алды, аннары, бармакларын киң җәеп, учын таянсадагы эзгә тәңгәл китереп кабат куйды.

— Сәрвия оныгының тиле сүзләреннән минем дә башка инеш кебек сай уйлар керә башлады, каһәресе,— дип сукранды ул.— Ирек куйсаң, кыланып күрсәтер Сәрвия нәселе! Кыланып кына калырмы синең!..

Күпер чыккач, юлның ике ягында кимендә икешәр йорт утыртырлык тигез мәйдан бар. Тик анда йортлар салмаганнар, гомумән, авыл буена мондый тигезлекләр тагын булса да, инешнең уң ягында йортлар юк. Инешнең суы мул булганда, бу төшләрне ташу баскандыр, күрәсең. Аннары балаларга таудан чана-чаңгы шуарга иркен урыннар кирәклеген истә тотканнардыр авылны салучылар. Каз-үрдәк йөрергә дә, бозау арканларга да иркенлек кирәк бит әле. Тагын шунысын да искәргән-

нәрдер — авыл буена сузылган тау биек, инешнең уң ягына иртәнге кояш соң төшә.

Таукаштан Мишәнең өске уңаендагы күрше авылга юл шушы төштән салынган. Текә тауны кайчандыр уеп кискәннәр, йөк белән йөргәндә, сөзәклек уңайлы. Ә йөкне күп йөртергә туры килә моннан. Юл, тау менгәч, икегә аерыла, турысы күрше авылга, уңга борылганы урманга бара. Тау юлын төзек һәм күперне нык хәлендә тота авыл халкы.

Баруының максатсыз икәнлеге Моназыйрның башына юлның тау эченә кисеп кергән төшенә җиткәч китереп сукты. Шулай да кире борыласы итмәде — берәрсе күреп торса, нигә юләрләнеп йөри икән авыл советы рәисе, дип бәяләве мөмкин ич. Сөзәк юлдан күтәрелеп, басуга чыгуның да кирәген тапмады — ындыр арты тунга сөрелеп калды, анда арыш чәчелгән булса, кызыксынып сораучыларга, ужымнарны карадым, дияр иде, кырпактан соң ягъни. Ужым турында уйлаганда, ул юлның уң ягыннан текә тауга менеп бара иде инде. Болайга борылуын абайламыйча калган иде, тик кире төшеп китәргә дә соң инде — авылдан Моназыйрны күзәтеп торучы апайлар Тилгән кылырын кылмыйча, ярты юлыннан кире борылды, дип бәяләячәкләр бит.

Ю-ук, алай бәяләмичә торсыннар әле! Ниятен тормышка ашырмады Моназыйр, имеш! Гомерендә беренче тапкыр Тилгән ярты юлда тукталды, янәсе. Тукталмас! Гомере буена киләчәккә омтылып яшәде Моназыйр Шәгаетов абыегыз! Киләчәкне тизрәк якынайтырга, юк, киләчәккә йөгереп кенә барып җитәргә тырышты. Тукталмыйча! Хәзер тау менгәндә дә тукталмаячак. Белегез! Һәм беләсез сез моны, агай-энеләр! Галияр энекәш, син генә шуны аңышып җитмәсәң инде. Син дә белерсең, энекәш, белдерербез! Сеңлең Рәйсәгә дә тәртипне төшендерербез!..

Ул кәҗә-сарык йөреп киртләчләнгән сукмак-баскычтан тау уртасын узганчы җиңел менде. Өскә таба сукмак-басмалар авышлана барды, аннары бетте. Тыны кысмаса да, менүе авырайды — кырпакта аягы тая иде, чүсинкәсенә киерткән яңа галош сырларының да файдасы булмады. Шуңа күрә, тау кашына җиткәнче, яны белән борылып, кырын басып менде.

Тауның өстендә түмгәк сыман ак таш бар, җирдән йомры башын гына чыгарган кебек ул. Тау эченә җәелеп кереп киткән, тамыры тирәндәдер кебек, шуңа күрә аны кузгата алмыйлардыр. Борынгылар ташны монда махсус менгереп, итәген күмгәннәр; бу таш кайчандыр бик зур булган, шуның түбәсенә басып — каланчадагы кебек — борын заманда күзәтче торган, дип сөйләнә Таукаш авылында хәзергәчә онытылмаган риваятьтә.

Борынгылардан истәлеккә калган ак таш өстеннән карны сыпырып-өреп җибәрде дә, тунының түбәнге төймәсен ычкын-

дырып, шул ташка утырды Моназыйр. Авылны югары очыннан түбән очына хәтле акрын гына күзеннән кичерде. Күрче, Таукаш авылының урамнары, тыкрыклары сызып салган кебек туры икән ләбаса. Авылда йөргәндә, моңа игътибар ителми, әй. Болын эчендә Мишә боргалана, ә инеш авылга керделе-чыктылы. Таукашта ярты гасыр яшәп, шушы турылыкка һәм кәкребөкрелеккә уй итмәгән Моназыйр. Югыйсә тау өслэтеп күп йөрергә туры килде аңа. Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе, хәер...

Моңарчы маңгай күзе белән генә күргән нәрсәләр шактый җыела, ахрысы. Инешен әйт син, әй. Башындамы, әллә тамагындамы аның киләчәге? Башында! Ю-ук... Тамагында! Булган ди, беткән төштә киләчәк булган ди...

Моназыйр күпер өстенә озак карап торды. Шулай текәлеп карау уйларын оныттырыр кебек иде, ләкин борчылуы бетмәде. Сәрвиянең... уйнаштан туган малаеның малае күңеленә салган борчу бу, агай-эне! Сүзен сүз итә торган Галияр, диләр аны, малай чагыннан ук авыл халкы Галиярны шушы сыйфаты өчен хөрмәтли. Нигә Галиярны шул сыйфаты өчен хөрмәт итәләр дә, нигә Моназыйрга Таукаш кешесе инде илле ел буена кырын карый? Анысы Моназыйр Шәгаетовның да абруе бар. Авылда һәм районда Таукаш җитәкчесе буларак танылуына инде кырык ел. Унҗиде яшеннән колхозның бригадиры булды. Аннары ферма мөдире, авыл советы секретаре, тагын бригадир, амбар мөдире, колхоз рәисе, илле яше тулгач, колхоз белән җитәкчелек итү авырайды, дип, колхоз рәисе хезмәт хакын саклап, авыл советы рәисе итеп күчерүне сорады. Бу постта җиде ел эшли, тәҗрибәсе җитәрлек.

...Шулай, Галияр энекәш, Моназыйр абзаң Шәгаетовны авыл советы рәислегеннән чөеп ташларга буының ныгып җитмәгән синең. Кырык ел буена постта эшләгән кеше янәшәсендә син бер селәгәйсең! Пенсиягә ике ел ярым калып бара. Юк, мине алыштырмаячаклар. Авыл советы рәисе булам, дигән сүзеңне сүз итә алмассың. Мин гомерем буена сүземне сүз иттем — шуны онытма! Таукаш кешеләре белә моны, шәп белә. Тик аларның сине олылавы мине зурлауларыннан үзгәрәк. Төгәл генә атавы да кыен бу үзгәлекне. Сине чын күңелдән хөрмәтлиләр, диимме әллә соң, үз итәләр, дип әйтү дөресрәкме? Мине зурлау дәрәҗәмә тиеш булганлыктан килә кебек. Туктале син, Моназыйр Шәгаетов, үзеңне нигә бер... селәгәй дәрәҗәсенә калдырып мескенләнәсең? Сүзен сүз итә торган Галияр, имеш! Малай чагыннан ук хас аңа бу сыйфат, имеш! Ә Моназыйрга да үз ниятен кылу кечкенәдән үк хас түгелме? Хас! Моназыйр Шәгаетов абыеңа җитәкче булу малай чагыннан ук килешеп тора иде. Моназыйр абыең моны... туктачы... моны кайчан белде соң? Ә-ә, әйе, Таукашта мәчет манарасын төшергәндә, Моназыйр исемле сигез яшьлек малайга авылның хәзрәте башын игән иде...

Моназыйр карашын инде авылның түбән очыннан югарыга таба күчерә барды. Күзләре авылның урта төшендәге ак кирпеч бинага төбәлде. Әйбәт бина. Клуб, китапханә, канцелярияләр шунда. Медпунктка, спорт залына арткы яктан керешле. Бу бинаны салганда, Моназыйр күп көч түкмәде түгүен, аны колхоз үз акчасына төзетте, мәшәкате колхоз идарәсе өстенә төште. Шулай да авыл советы рәисе төзелештә үзенең дә катнашы зур дип саный. Бина мәчет мәйданына салынды, мәчетнең төньяк башына. Намаз укулар, гыйбадәт кылулар тукталганнан бирле клуб ителгән мәчетне яңа бина өлгергәч үк сүтмәделәр әле. Мәчетнең искергән бинасы ак бинаның, Моназыйр әйтмешли, төсен җибәреп ике ел торды. Моназыйр активлык күрсәтмәсә, бәлки, хәзер дә торыр иде.

Яңа бинаны салдыруда минем өлеш иң зурдан булмаса да, аның култык астына сыенгандай торган мәчетне сүттерү — минем хезмәт, агай-энеләр, дип масаеп уйлады Моназыйр. Авыл советы балансында иде мәчет! Әле болай да ике елга артык яшәде мәчет. Манарасын төшерү истә калган. Ничә ел узган хәзер моңа? Илле була икән. Хәзер сиксән җиденең кышына керәбез. Утыз сигезенченең июль уртасында төшерелгән иде манара. Мин беренче классны бетергән идем, тугызынчы яшьтә идем, бала гына булсам да, күңелгә сеңдереп калганмын бит, дип сөенде Моназыйр.

...Мәчет манарасын төшерү хәбәре авылда күптән йөрде. Бу хакта кешеләр чышын-пышын сөйләштеләр, бергәләп фикер алышуны оештырырга омтылучы табылмады. Авылның һәр кешесенә кагылышлы мәсьәләләр элегрәк җыенда фикерләшеп хәл ителә иде югыйсә. Соңгы вакытта борынгыдан килгән кулай гадәтне санга сукмыйлар, бу гадәтнең ниндидер начарлыгын күрәләрдер инде.

Алга йөгереп барыш заманында безнең барыбыз өчен дә бөек юлбашчыбыз уйлый. Әйе, уйлап-исәпләп торырга вакытыбыз юк, алга йөгерәбез, безнең өчен уйларга бөек кешебезгә ышанабыз. Ә барлык халыклар юлбашчысы, беркайчан да ялгышмыйча, безнең турыда кайгырта. Шуның өчен дә илебездәге барлык халыкларның да атасы ул. Мәчет манараларының безгә матур яшәргә комачаулавын да иң башта бөек юлбашчыбыз күреп алган, шуңа күрә манараларны кисеп ташларга кушкан. Бетсен искелек калдыклары! Ә... мәчет манарасы искелекме соң? Авызыңны чамалап ач, иптәшкәй, искелек булмыйча, ни булсын тагын! Алайса, мәчетне дә сүтәргә кирәк, хәзер анда барыбер гыйбадәт кылмыйлар. Ашыкмыйк, мәчетнең бинасы кирәк хәзергә, шушы бина булмаса, клубны кайда ясар идең? Шул шул менә...

Авыл җитәкчеләре мондый уй-фикерләрен уртага салып киңәшүдән курыктылар, хәтта мондый уйларының кемгә дә булса беленүеннән котлары очып шүрләделәр.

Өлкән агайлар, икәүдән-икәү калып сөйләшкәндә, манара кисүгә мөнәсәбәтләрен белдерсәләр дә, власть каршына үтенеч-таләп белән күмәкләшеп барудан мәгънә тапмадылар. Моны авылның Рухан хәзрәте шулай киңәш иткән, диделәр. Аның белән кем — әллә кемнәрме? — сөйләшүе билгесез калды, хәзрәтнең киңәшен авылда һәркем белсә дә, моны белмәмешкә салыштылар. Хәтта авыл җитәкчеләре дә моңа колак салмагандай иде, хәзрәтнең каршы төшмәве аларга әйбәт кенә иде. Хәер, барлык татар авыллары диярлек кабалана-узыша мәчет манаралары кискәндә, иң киме — авыллар матурлыгына килгән афәтне Таукаш мулласы гына туктата алмас иде. Каршы төшеп бер генә сүз әйтсә дә, аны тотып ябачаклар иде. Бу кадәресен дә әйбәт төшенгәндер Рухан хәзрәт. Колхозлашкан чакта, электән авыл халкын рәнҗетмәвен истә тотып, сөрмәгәннәр икән, хәзер дә аңа миһербанлык күрсәтерләр, дип өметләнергә һич тә ярамый. Заманы бүтән, утыз сигезенче елның уртасы узды. Бүген теләсә кемне халык дошманы ясавы үтә җиңеләйде. Ахыр чиктә кулакка чыгарып куярлар үзеңне. Хәзрәтне кулакка тиңләрлек сәбәп юк-югын, гади колхозчы ул, яше алтмышка җиткән булса да, колхозның арба-чаналар ясау остаханәсендә эшләп йөри. Тыныч холыклы бу кешенең балта эшенә кечкенәдән үк кулы ятып торды. Үз басуында чәчүен-уруын да үз гаиләсе көче белән башкарырга тырышты. Үзенең ялланып эшләүчеләрдән сыйфатлырак итеп эшләвен белә иде чөнки. Шушы авыл нәселеннән, Сатыш мәдрәсәсендә укып, муллалыкка указ алганнан бирле үзенең Таукашында, мәчеттә гыйбадәт кылу туктатылганчы, хәзрәтлек итте. Хәзер мәет озатуда гына дини вазифаларын үти. Аз сүзле кеше, кылганы алдан уйланган булыр, ашык-пошык карар чыгармас. Юлбашчының «Уңышлардан баш әйләнү» дигән мәкаләсе басылгач, колхоздан чыгучылар булды, ә хәзрәт гаризасын кире алырга ашыкмады. Колхоздан чыгучыларга тагын керәсегез булыр, дигән иде, сүзләре дөрескә килде.

Шулай, мәчет манарасын кистерүгә бөтен барлыгы белән каршы булса да, Рухан хәзрәт манараны кистермичә калуга үз көче җитәчәгенә ышанмады. Ә моңа ирешү өчен көч-кодрәтнең ташып торуы кирәк иде. Алты дистәне тутырган кешедә мондый көч, әлбәттә, юк иде, дөнья фани, аның белән алышбирешен көйле генә тәмамларга бара иде инде ул. Өстәвенә авыл җитәкчеләренең, гәрчә төпкәчә уйлап җиткермәсәләр дә, манараны барыбер кистерәчәкләрен аларның йөзеннән үк күреп торды хәзрәт. Рухиятне аңлаган хәзрәтнең моны аермачык күрүе гаҗәп түгел иде. Нәкъ менә шуңа күрә, бу очракта барлык диярлек авыллардагы тоташ агымны туктата алмаячагын белгәнгә күрә, мәчет манарасын кистерүгә каршы тору турында киңәш сораучыга — әллә сораучыларгамы? — хәзрәт:

— Мине олылавыңа рәхмәт,— дигән.— Әмма ки каршы

төшүнең мәгънәсен тапмыйм. Мин манара кисүгә каршы. Ләкин ки агымга каршы йөзәргә көчем җитми. Агымы каһәрле. Һәм гөнаһлы. Үз юлыннан тайпылып чыгып котырынучы агым. Әй-йе. Манара кисүнең ни-нәрсәгә китерүе соңрак, күп еллар узгач күренәчәк. Манара кисү дин тотуны тыю гына түгел... Тыеп та динне бетереп булмаячак. Аллабыз барыбер калачак. Ул безгә бәйсез, ул бездән өстен, ул бездән көчле. Кеше аны беркайчан да алыштыра алмый. Аллабыз мәңгелек. Йә Тәңрем, булган гөнаһларыбызны ярлыка, гөнаһлардан сакла!..

Рухан хәзрәт мәчет яныннан таң беленүгә әйләнеп кайтты. Кабат килүендә монда халык җыелган иде инде. Шулай да кисә башлауларын ярты сәгатьләп көтәргә туры килде. Күп кешеләр мәчет тирәсен әйләндереп алган рәшәткә эченә үк кергәннәр, тышкы якта рәшәткә буйлап тезелүчеләр ишлерәк, урамның каршы ягында торып күзәтүчеләр дә шактый. Хәзрәт мәчетнең ишек ягында, урта бер төштә басып тора иде. Ялгызы.

Мәчет ишеге төбендә таза-таза өч ир кеше кайнаша. Пычкы-балталарын, арканнарын барлыйлар. Тып-тын калган Таукашта шушы өч кешедән гайре хәрәкәтләнүче бу мәлдә юк идедер. Әзмәвер өч агай Таукашныкы түгелләр. Алар район авылларында мәчет манараларын төшерү өчен махсус оештырылган бригада тәшкил итәләр икән. Тәҗрибәләре зур, димәк. Эшнең җаен тиз үзләштереп алганнар, күрәсең, үзләрен тыныч тотып, кабаланмыйча, осталыкларын дәрәҗәсен белеп әзерләнәләр. Ара-тирә манарага карап, сүз алышкалыйлар. Берсе мәчетне әйләнеп чыкты, иптәшләренә нәрсәдер әйтте. Өчесе бергә манарага карадылар, сизелер-сизелмәс җилнең кайсы яктан икәнен иснәгәндәй булдылар. Аннары, шулай ук өчесе берьюлы, манара авачак якны төртеп күрсәттеләр. Хәзрәт нәкъ шул турыда тора иде. Хәзер авылда шушы өч кеше генә хәрәкәтләнәдер, дип кабат уйлап куйды Рухан хәзрәт. Ул манараның кайсы якка аударыласын белеп баскан кебек, әмма үзе бу хакта башына да китермәгән иде. Басып торган урыныннан мәчеткә кадәрге араны карашы белән үлчәде Рухан хәзрәт — манара аңа җитмәячәк иде. Шулай булгач, урыныннан кузгалырга кирәкми, тып-тын торган авыл кешеләре арасыннан берьялгызың ыгы-зыгы башлау мәгънәсезлек булыр иде, хәер. Баксаң, хәрәкәтләнүчеләр әлеге өч агай гына түгел икән — хәзрәт рәшәткәнең эчке ягына кереп баскан кешеләр арасында кечкенә башына зур яшел картуз кигән бер малайның кыбырсып йөрүен күреп алды. Малай мәчет мәйданында басып торучыларны сафка тезәргә тырышып йөри кебек иде. Һәм ул хәзрәт янына атылып килә башлады, хәзрәт аның җил-җил ашкынуыннан сискәнеп тә куйды. Малай хәзрәт каршында шып туктады, аякларын киңрәк итеп күчереп басты, сул кулын аркасы белән арттан биленә куйды, уңы белән картузына кагылды һәм, хәзрәткә күтәрелеп карамыйча гына:

— Мулла... мулла карт,— диде. Тавышы яшенә караганда калынрак иде. Башын кыегайтып хәзрәткә карап алды да сүзен дәвам итте. Сөйләве олыларча иде, юк, коры иде, балаларга хас гадилек һич тә сизелмәде.— Манара сытканын күтәсең мәллә?! Күрмисеңмени, манараны бу якка төшерәләр! Кит моннан! Сиңа аерым әйтергә кирәкме? Кит! Әнә тегендә чиген!

Хәзрәтнең күз алды томанланды, ул сәерсенеп тә, ачуы кубып та катып калды. Аңа моңарчы беркемнең дә болай дорфа мөнәсәбәттә булганы юк иде. Әти-әнисеннән дә беркайчан да ачуландыртмады ул, аларның сүзен һәрвакыт тыңлаучан булды. Хәзрәт, хәлне аңышып:

— Миңа...— дип сүз башлаганда, дорфа малай аның яныннан китеп барган икән инде.

Рухан хәзрәт әйтәсе сүзләрен уенда бетерде.

...Кем... дорфа малай, кем... Моназыйр атлысың бугай, ә-ә, әйе, олан, миңа аерым әйтү кирәкми. Гомерем буена үземне кешеләрдән аерым тотмадым. Бәхетем дә шушы минем. Әйе, кешеләр мине кырык елга якын Таукаш хәзрәте итеп белделәр һәм олыладылар. Мәчеттә гыйбадәт кылуны бетергәч тә хөрмәтлиләр. Киресен әйтерем юк. Хөрмәтләреннән ташламадылар. Үзем дә аларга тугры хезмәт итәргә тырыштым. Барлык өндәвем изгелеккә тарту булды, хак юлдан тайпылып, гөнаһ юлына басудан йолып калырга булыштым. Ю-ук, аерылмадым мин авылдан! Һәм аерылмам. Боерган булса. Тик каладан да, саладан да ни Алла, ни власть каршында гөнаһсыз кешеләрне таш капчыкка ябулар ишәйде. Ябучылар зур гөнаһ кыла. Чагучылар да. Алла бар ул. Вә боларны онытмас ул. Хаклыкны кайтарыр Аллабыз. Әмма вакыт үтәр шул, шактый вакыт үтәр. Хәзергә кешеләр кылган вәхшилеккә Тәңре аптырап калгандыр, ышана алмыйдыр соңгы заман ерткычлыкларына. Аңына килә алмаганга күрә генә бу әшәкелекләрне тыймыйча торадыр. Адәм уйламаслык, Ходай башына да китермәслек кыру бит... Ә, мәчет манарасы, кем, Моназыйр, сытмаячак мине, миңа җитмәячәк манара — үзем дә абайламыйча чамалаганмын шуны. Син буыны ныгымаган малай килеш бүген авылда башлык булып йөрсәң дә, шуны да уйламагансың, манараның миңа кагылмаячагын белмисең. Хәер, син авылдагы башлык түгел үзең. Рәсми башлыклар бүтәннәр. Тик ни кылганнарын үзләре дә аңламаучы башлык-түрәләрне син гәүдәләндерәсең бүген. Шулай, манара миңа турылап аударылса да, миңа бәрелмәячәк ул, җиргә җитәрәк үзе үк читкә тайпылачак. Чөнки Аллам каршында тамчы да гөнаһым юк. Һәм власть каршында да. Шулай, манара төшерүдән берәү дә яра алмаячак. Гөнаһсызларны Алла каргамый. Гөнаһлы бәндәләргә гөнаһсызлар каргышы кайчан да булса барыбер төшәчәк. Ходай Тәгаләнең язмышыннан узмыш юк...

Колхозда тәртипнең күмәк рәвештә беренче тапкыр бозылуы бүген булды. Хатын-кызларга төрле эшкә чыгарга бригa-

дирлар кичтән үк әйткәннәр иде әйтүен, ләкин хатын-кызлар моны иртәгесенгә онытып җибәргәннәр, күрәсең. Һәркайсының өендә ашыгыч шөгыле табылган, һай. Ир-атның күбесе үз эш урынына барды, ләкин атын да җикмичә яки кулына эш коралын тотып та карамыйча, өенә әйләнеп кайтты. Балалар да күңелле итеп уйный алмадылар бүген. Таукаш кешеләре, сүз берләшкәндәй, авыл күгенә күтәрелеп карарга курыктылар. Зур тавыш-гаугалар куптармыйча, күндәмлеге һәм оешканлыгы белән элек-электән үк тирә-юньгә танылган Таукаш халкының, мәчет манарасын төшерүгә каршылык белдерүеннән бигрәк, гомер булмаган хәлдән югалып, аңсызланып калуы иде бу. Шулай да мондый хәл тавышсыз протестка якын иде. Әйе, күмәкләшеп эшкә чыкмау протестка тартым гына иде, чөнки, әйтелгәнчә, ул халыкның югалып калуыннан гына туды, оешкан халыкның дәррәү каршы күтәрелергә оешканлыгы җитмәде.

Таукаш халкының күмәк рәвештә тәртип бозуының беренчесе дә, соңгысы да шушы булды. Хәтта егерме тугызынчы-утызынчы елларда чагыштырмача бердәм колхозлашкан иде Таукаш кешеләре, «уңышлардан баш әйләнгән» чакта да колхоздан чыгып торучылар аз булды. Авылның татарга гомумән хас күндәм һәм сирәк очракта шәп оешканлык сыйфатлары, шөкер, бүгенгәчә яши. Явызлык, күрәләтә кеше канын сыгу гадәтләрен кешеләр авылга кертмәгәннәр иде. Заман дигәнең коточкыч буталып тора, кайбер хәлләргә бәя бирү түгел, алар турында хәтта бик соңлап кына ишетеп беләсең.

Әйе, кешеләрнең кулына эш йокмады бүген — мәчет манарасын төшергән көнне. Киләп сарып йөрделәр шунда. Һәр таңны эш белән башлап, көнне рәхәтле ару белән тәмамларга күнеккән Таукаш кешесенә мондый максатсызлык һич тә килешми иде. Таукаш кешесе үзе дә кайчан да булса мондый мәгънәсезлек кылырмын дип башына-уена китермәгәндер.

Таукашта бүген кызып эшләүче мәчет манарасын кисүче өч агай гына булды. Алар манараны төш вакытына сүтеп тә бетерделәр, тиз тоттылар. Манара әйберләрен, өч арбага төяп, район үзәгенә алып та киттеләр. Киселгән манаралардан район үзәгендә ниндидер бина җыймакчылар, имеш.

Рухан хәзрәтнең йорт-җире мәчет мәйданыннан авылның югарыгы уңаендагы беренче кыска урамында, сул чатта иде. Манара төягән кәрванны ул капка төбендәге эскәмиядә утырып карап калды. Кәрван башында, юл күрсәткән кебек, иртәнге якта — манара кисү алдыннан — хәзрәткә артка чигенергә боерган Моназыйр исемле малай бара иде. Бераздан малай, кулларын артка куеп, олы-олы атлап, урам уртасыннан кире төште. Ул якынайгач, хәзрәт, ни өчен икәнлеген үзе дә уйламыйча, урыныннан торды. Шул ук мәлдә Моназыйр, борылып, хәзрәткә таба килә башлады.

— Мулла абзый,— дип, хәзрәтнең каршына туктады ма-

лай,— миңа рәхмәт әйт, мин кисәтмәсәм, манара изә иде бит үзеңне. Торасың шунда баскан төшеңдә катып! Ярамый алай.

Хәзрәтне тагын өнсез итте Моназыйр. Кем өйрәтә сине шушылай, дип сорамакчы булды. Сорый алмады. Каян барысын да белеп торасың син? Монысын да сорый алмады. Туганчы ук барысын да белгәндер бу малай дип нәтиҗә ясады. Әмма Моназыйрга сүзе бүтән булды.

— Кем... Моназыйр... олан...— Ни әйтергә белмичә тотлыкты.— Чәйгә кер... Абыстаң...

— Юк! Керә алмыйм. Вакыт юк. Моңарчы мулла йортына аяк басканым булмады. Моннан соң да кирәге чыкмас.

Гаҗәп, бик тә гаҗәп — дорфалыкка, юньсезлеккә каян өйрәнеп өлгергән бу малай? Моңарчы, дип сөйләргә иртә ич аңарга. Ата-анасы да начар кешеләр түгел кебек, әнисе — мөгаллимә, үзе тәрбияче. Күрәсең, Моназыйр атлы бу малайның күзләре иң башлап кешеләрдәге әшәкелекне күреп үз итәргә, колаклары юньсезлекне, шулай ук башлап ишетеп, күңеленә сеңдерергә сәләтледер. Имансыз замана тудырган малайдыр бу. Замана бозучы кешедер...

Моназыйрның чәйгә керүдән баш тартуы әйбәт булды. Югыйсә хәзрәт тә дорфа малай белән бер табынга утырырга тиеш булыр иде. Ә аның бүген тәгам капканы юк, капса да, ризык тамагыннан узмас иде.

Малайның сүзләре хәзрәтне элгәре буталчык-салмак, анналры кинәт җәһәтләнеп киткән уйларыннан бүлдерде.

— Зур эш эшләнде бүген. Мәчет манарасын төшердек. Онытма моны, мулла абзый.

Ничек башына килә икән мондый фикерләр бу малайның? Кеп-кечкенә үзе...

— Онытмам! — дип сузыбрак һәм тавышын күтәребрәк әйтте Рухан хәзрәт.— Авылның башын кисүне онытырга мөмкин түгел! Әдәпле кеше моны онытмас. Онытмас! Син дә онытма!..

Хәзрәт кинәт туктады һәм малайга авыл кешеләре кушкан Тилгән дигән кушаматы белән эндәшүдән үзен тыеп калуына сөенде. Ул бу кушаматны малайның йөзенә бәреп әйтмәүләрен белә иде. Әйтмәвенә сөенүе шул кушаматын Моназыйрга беренче тапкыр ишеттерүдән куркып түгел, ә авызы чиста калудан иде.

...Моназыйрның карашы элеккеге мәчет мәйданына текәлгән булса да, ул андагы ак кирпеч бинаны да, юан тупылларны да, җәенке ябалдашлы талларны да күрми иде. Тау башына төркеме белән каргалар очып килгәч кенә бүгенгесенә кайтты Таукашның авыл советы рәисе. Каргалар чокыррак төштәге карда коенмакчы булалар. Киләчәге кайсы якта булуы билгесез инештә коенмыйлар, әй, дип көлемсерәп уйлады Моназыйр. Хәйләкәрләр, суның йоннарына ябышып катуы ихтимал шул, ә

кар коела да бетә. Моназыйрның кинәт карга ятып ауныйсы килде. Тик шул мәлдә үк үзен тилермә, дип туктатты. Сыерчыклар килүенә куанып, малай чакта да карга ятып аунамаганны, бүген бөтен авыл каршында — тау башында! — Моназыйр җирдә аунасын, имеш! Моназыйрны авыл советы рәислегеннән төшермәкче Галияр аерата көлеп тә сөенеп рәхәтләнер иде бугай. Көтсен! Көтсеннәр! Беркайчан да аунамаячак Моназыйр! Ауната да алмаячаклар! Хәзер үк авыл советына барырга кирәк, уку ташлаган Мостафинаны акылга утыртырлык кодрәт бар хәзер Шәгаетовта!..

## 3

Күтәрткән юл авылның түбән очыннан, болын читләтеп, елга агышы уңаена чыга. Ярты чакрым гына аның озынлыгы, фермаларга җитеп туктый ул. Сыер абзарлары бирерәк, ә сарык абзарлары алардан йөз адымнар чамасы ары, анда юл сыер абзарларын өске яктан урап төшә. Таукашның дүрт ягыннан киткән дүрт юлга хәзергәчә таш җәелмәсә дә, фермалар юлына сугышка чаклы ук таш түшәгәннәр иде. Илленче еллар азагында, илле тугызда бугай, авыл хуҗалыгын текә күтәрүне кызуландырган вакытларда ягъни, фермага авыр тракторлар һәм машиналар кереп йөри башлагач, райкомның шул чактагы секретаре булган эшлекле җилкуары юлга — башка эш тапмагандыр йә таба белмәгәндер — икеләтә күтәртеп, инешнең үзле балчыклы вак ташын җәйдертте. Берәмтекләп тезелгән, шомарып агарган эре ташлар аста калып әрәм булды.

Хәзер юл элеккедән дә битәр чокыр-чакырланды, яз-көз өзекләрендә үтмәле түгел. Беренче кар төшсә дә, ныклап туңдырмаганлыктан, уртадан йөреп булмый иде. Шуңа күрә Сәрвия белән Галияр өске яктагы сукмактан аллы-артлы бардылар, юлның болын ягындагы сукмак адым саен диярлек аркылыга ермакланып беткән, ул ермакларны сикереп яки озын атлап чыгарга кирәк. Сукмакның өске ягы да катмарлы, чамаламыйча бассаң, сөртенүеңне көт тә тор. Һәм Сәрвия белән Галияр, аяк астына карап барып, каршыга килүче Рәйсәне күрмичә калдылар.

— И-и мактанчыклар, күтәрелеп тә карамаган булалар! — дип шәрран ярды әбисе белән абыйсы янына килеп җитәрәк Рәйсә.— Мине күрмәгән дә булалар! — Һәм, әбисен читләтеп узып, Галиярның җилкәсенә асылынды.— И-и абыем, сагынып-лар да сагындым инде мин сине! Минем кебек,— диде дә беравык тукталып торды, әбисенә күз төшереп алды, аннары тагын кычкырып әйтеп салды,— булачак җиңги дә сагынмагандыр!

— Һаман да, көеңә килгәндә, оста тәкелдисең икән син, Рәйсә! — дип, аркасыннан сөйде сеңлесен Галияр.— Көеңә килгәндә, һаман да шәрран ярасың икән. Әллә тавышың тагын да көчәя төшкән тагын...

— Көчәймичә! Үсәм ич!

Рәйсә кулларын абыйсының муеныннан алды, Галияр сыгылыбрак гәүдәсен төзәйтте, онытының мондый хәрәкәтенә Сәрвия иртән игътибар итеп җиткермәгән иде, хәзер исә, Галиярның гәүдәсен үз җаена тотарга тырышуының сәбәбе бар икән, дип күңеленә салып куйды. Рәйсә абыйсының гәүдәсен төзәтүен үзе муенына асылынгач, шинеле җайсызланган булгандыр, дип уйлады.

— Үсүең шәп лә, тик укуыңны...

Рәйсә Галиярга сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде, абыйсының күзләренә туры карап, тезеп китте. Сөйләгән уңайдан әбисен куенына тартып елыштырды.

— Ташладым укуны, абый! Сигезенчене бик яхшы билгеләренә бетердем дә тугызынчыга бармадым. Шушы сигез класс белемем җитә миңа. Сәрвия әбием тулы булмаган урта мәктәп белеме белән һич тә надан түгел әле.

— Белемне беркайчан да җитәргә санау ярамый, Рәйсә,— дип каршы төште Галияр.

— Соң, абый, дим, мин дә укымаска кирәк, димәдем ләбаса! Хәзерге заманда сыер савучы йә сарык карауючы булырга сигез классым җитә, дим. Шул гына.

— Укыйсы иде. Иң киме — урта мәктәпне тәмамларга иде.

— Сарык карауючының ун класс белеме булырга тиешлеген кем билгеләде икән? Әйттең сүз! Кирәкне күп кабатларга өйрәнеп кайткансың икән син, абый. Мөгаен дә түрә булып китәрсең, күрермен дә торырмын менә.— Рәйсә акрын гына башын чайкады, кашларын җыерып алды.— Мин сине башка кеше булып кайтырсың дип көткән идем. Ә син, очрашып күрешүгә үк, укырга кирәк тә укырга кирәк, дип тәкелди башладың. Тәкелдәсәң, бер хәл икән әле, такмазалыйсың бит. Акыл иясе, имеш!

— Ай-яй, усаллангансың син!

— Усал кеше — әйбәт кеше. Әлегә усалланып җитмәдем. Исәбем бар. Солдаттан кайтуга, син үзәккә басарга тиешсең кебек иде. Ә синең чамаң чамалы бугай.

— Менә, ичмасам, каршыладың абыеңны, сеңелкәем!

— Каршыладым! Беләсең холкымны — акыл сатма! Теләсәң, акылга өйрәт.

Галияр бу сүзләрне шаяртуга алды. Ә Сәрвия Рәйсәнең соңгы вакытта холкы тиз үзгәрүенә күнегеп бара, кызның абыйсына хәзерге дорфалыгын гафу итте. Галияр белән Рәйсәнең бер-берсенә хөрмәте җуелмаячагына ышана иде карчык. Сәрвиянең яшьлегендәге хыялы ишле балалар үстерү иде. Балаларымның татулыгын күрүдән дә зур бәхет булмастыр, дип уйлый иде ул. Тик ишле балалар үстерергә насыйп булмаган икән, малае Тимерша ялгызы гына үсте. Шөкер, оныклары ишле, аларның татулыгын күреп сөенә карчык. Үз балалары ук булмасалар да, малаеның балалары бит, бер кан, Сәрвия каны...

Ул Рәйсәнең җилкәсенә кунган печән чүпләрен сыпырып төшерә иде.

Алар фермага таба кузгалдылар.

— Нишләп йөрүең эш вакытында, дип сорый да белмисез, ичмасам,— дип, башын алга иеп алды Рәйсә.— Авыл советына барышым, иптәш Моназыйр Шәгаетов чакырды. Укырга барырга куша инде. Көн саен минем белән бер тапкыр әрепләшмәсә, тамагы туймыйдыр, валлаһи гынам. Укырга барыбер бармыйм! Ни калган ди анда миңа? Абый, менә син укырга китәсеңме соң?

— Мин...

— Бик беләсең килсә, сине Тәнвирә апа беркая да җибәрмәячәк! Мине барасы юлымнан бүлдереп, фермага тәки кире алып килделәр болар, әй. Ярар инде, иптәш Шәгаетов бераз көтеп торыр. Абыйны Тәнвирә апа белән барыбер мин очраштырырга тиештер инде. Әби, син әтиләр янына бар, алар сарык астына салам түши калганнар иде, абзар эчендә булгач, абыйның килүен күрмиләр ич инде алар. Әби, син әтидән дә, әнидән дә зур сөенче сора, яме, бәләкәенә риза булма. Әйдә, солдат абый, киттек,— дип култыклап алды Рәйсә Галиярны.— Менә мин бу җебегән акыл сатучыны булачак җиңги белән күрештерәм дә аннары әтиләр янына йөгерәбез. Җиңгәчәй яныннан сәлам дә бирмичә узып китәргә ярамый ич инде. Ә-ә, әнә ич, Тәнвирә апа утарга сыерлар чыгара. Солдат Галиярын күреп алса, аптыраплар да калыр инде... Ул да сине бик, би-ик сагынды. Киләсе елга институтка китеп барыр да, мине бөтенләй онытыр Галияр, ди. Ялгызым яшәп калырмын инде мин, ди. Шулай ди, миннән сер яшерми ул. Ә син, чыннан да, институтка китәсеңме соң?

— Китмим.

— Тракторчы буласыңмы?

— Юк.

— Кем буласың соң?

— Авыл советы рәисе булам.

— Тилгән урынынамы? — дип, Моназыйр Шәгаетовны кушаматы белән атады Рәйсә.

— Онытылып барган нәрсәләрне искә төшермә, кушамат яңартма.

Мондый кисәтүгә исе китмәде кызның.

— Бик җенемне кузгатса, үзенә дә кушаматы белән эндәшермен Шәгаетовыңның! Бөтен авыл дер калтырап яшәгән шул Моназыйрдан! — дип каршы төште ул.— Әйтәм аны-ы,— дип сузып кына көлеп җибәрде аннары Рәйсә,— мине укырга өндисең! Менә сере нәрсәдә икән — авыл советы рәисе булгач, сеңлеңнең мәктәп ташлавы өчен җавап бирүдән куркасың икән ич... Әйдә әле, әйдә, җәһәтрәк, мондый җаваплы эшне Тәнвирә апа белән дә киңәшмичә ярамый. Әле, бик беләсең килсә, синең рәис булырлык акылың бармы-юкмы икәнлеге буенча үзем имтихан алырмын. Лозунг кычкырып кына җитәкче булу

заманнары узды. Бүген һәр төбәкнең, һәр авылның үз лидеры кирәк! Мин дә беләм ул акыллы сүзләрне, абыйкаем! Башкаларны әйди белүче атаман кирәк бүген! Безнең Таукашта син иләмән булырсың дип көттем мин, Галияр абыйкаем! Ә, тукта-ле, ничек була инде ул — Тәнвирә апа белән киңәшмәгән килеш рәис булырга йөрисең? Аны санга сукмыйча, әй! Әнә, үзе дә безне күреп алды, үзе күренмәскә тырышкан була, кошчыккаем, үзе качмый да, оялчаным. Тәнвирә апа, Тәнвирә апа, дим! Солдатыңны каршыла! Күр әле, ишетмәгәнгә салыша. Ах, сине!..

Таукашта солдаттан кайткан һәр егет хөрмәтенә шул көнне үк авыл клубында кичә уздырыла. Бу гадәт сугыш вакытыннан — Сәрвиянең әтисе Мостафаны каршылаудан башланган иде. Шуннан бирле аны бер тапкыр да бозганнары юк, ягъни һәр солдат хөрмәтенә уздырыла кичә, димәк, авылда мондый тәртип нык урнашкан. Заман узу белән кичәләрнең эчтәлеге дә үзгәрә бара, тормыш яңалыкларын өсти, төзәтмәләрен кертә. Мостафа солдат сугыш хәлләре турында мәчет-клубта төн уртасынача сөйләгән иде. Залга тезелгән артсыз эскәмияләрнең соңгы рәттәгесенә кырыйга утырган иде ул, тездән түбән киселгән сул аягын эскәмиягә салган, тумранга охшап тора иде шул аягы. Ничек яралануы турында сөйләргә керешкәнче, клубның гармунын сорап алды да, шул киселгән аягы өстенә куеп, өздерепләр дә уйнаган иде! Кушылып җырладылар, елаучылар да булды, күп булды. Елау күңелне моң кузгатудан түгел иде, әмма сугыш афәте күңелне сыга иде. Сугышка чаклы, тыныч вакытта, кайгы килгән кеше күз яшьләрен башкаларга күрсәтмәскә тырыша иде. Сугыш дәһшәте кешеләрне яшеренмичә һәм күмәкләшеп еларга мәҗбүр итте. Мостафа солдатның хикәятләрен һәм гармун уйнавын тыңлаучыларның күз яшьләре матчага озын тимерчыбыкка асылынган унлы лампа яктысында күңелне яралап күренә иде.

Хәзер солдат каршылау кичәләре уен-көлке белән уза. Әгәр сөйгән егете кайткан кызның күзләре дымсулана, хәтта яшькә тула икән — монысы инде шатлык яшьләре ләбаса!..

Әйе, бүген Галиярны каршылау кичәсе дә күңелле узар. Галиярның олы бабасын — әбисе Сәрвиянең әтисе Мостафаны каршылаганда гына кайгы янәшәндә дуамалланып бөтерелеп йөргән, бүген исә хәсрәт чигәргә сәбәп юк. Ә-ә... Ә Галиярның кече бабасын, әтисенең әтисен ягъни, каршыламаганнар. Аның кем булуын Таукашта белүче Сәрвия үзе генәдер, Сәрвиянең иргә чыкмыйча Тимершаны табуы турында Таукашта хәзер искә алучы юк кебек. Шулай, Тимершаның әтисен Сәрвия үзе генә белә. Хәзер бу кешене Галияр да белергә тиеш. Госпитальдә саташулы төш күргәннән соң, шундый катгый карарга килде ул. Тик, алдарак искәртүебезчә, моны сорарга әбисе Сәрвияне әзерләргә кирәк санады. Онычының солдаттан исән-имин кайтуына сөенүдән очынып йөрүче Сәрвиянең кәе-

фен кыруың бик тә ихтимал югыйсә. Моны иртәгә дә, хәтта атналар узгач та сорарга мөмкин, чөнки Сәрвия белән аның малаеның атасы арасындагы мөнәсәбәт ничек булган, дөресе, ничек булмаган, моннан соң да барыбер шул килеш калачак.

Ә бүгенге кичә, әйе, күңелле узачак. Таукашта армиягә озату кичәләре дә кызыклы була. Әмма мондый кичәдә, аны ни мактасаң да, сагыш сизелә инде, барыбер сизелә. Озату кичәсе берничә кеше хөрмәтенә, ә каршылау кичәсе гел диярлек берүзең хөрмәтенә оештырыла бит әле. Бүгенге кичә дә Галиярның берүзе хөрмәтенә. Һәм ул, әйе, күңелле узачак. Тик кичәне тасвир кылуны хикәянең ахырынарак калдырып, элгәре геройларыбызның көндезге эшләре — һәм үткәннәргә кайткалап — турында сөйлик.

...Галияр белән Рәйсә әти-әнисе янында озак кына булдылар. Ата-ана, Сәрвия хәбәр ирештергәч, Галияр каршына йөгереп үк килделәр. Әфган җиреннән — сугыш эченнән исән-сау кайту зур бәхет, бу очракта шатлык яше түгү һич тә гөнаһ саналмый. Һәм Галиярның әнисе Мөхтәрәмәнең күзләре яшьтән кибеп тормады. Галияр әтисе Тимершага тартыла башласа, Мөхтәрәмә улының беләгеннән кысыбрак тотты. Әгәр кулын ычкындырса, әтисе Тимерша Галиярны тотып калырга өлгерә алмас һәм улын тагын сугышка илтеп тыгарлар кебек тоела иде анага. Юк, ана моннан ары улын беркая да җибәрмәячәк! Тимерша — каты күңелле ир — сөенечтән дулкынлануын яшерергә тырышты. Ләкин уртада утырган Галиярның чыннан да үз улы булуына ышанып җитмичә, сугыш афәтен кичкән малаена ара-тирә озаклап карый. Шул чакта ата кешенең дә — кырыс холыклы Тимершаның да — күзләре дымлана. Моны күрмәс өчен, Галияр карашын аска ялгерә. Бу очрашуда сүзләр күп булмады, хәзер сөйләнмәгән сүзләр озын кичләр буена, инде ишетелгән вакыйгаларга да кайта-кайта, сөйләнәчәк әле. Галиярның исәнлеге сөенече хәзергә барлык сүзләрдән дә өстен. Шуңа күрә бу очрашуда ата һәм ана:

— Улым... Улым... — дип, ә солдат-бала:

— Әни... Әти... — дип кабатлаудан узмадылар.

Ике туган — Галияр белән Рәйсә — фермадан кайтышлый авыл советы канцеляриясенә керделәр. Егеткә, хәрби комиссариатка барганчы, кайтуын белдереп, исәпкә басарга кирәк иде, ул туры авыл советы секретаре янына узды.

— Галияр Мостафин, хәрби хезмәтен тутырып, Таукашына исән-сау кайтты! — дип шаяртып рапорт бирде егет.

— Рәхмәт яугыры, мине командирың иттең бит, Галияр энем! — дип, аягүрә басып күреште аның белән секретарь хатын.

Исәпкә теркәү үзара хәл белешеп сөенүләр белән барды. Сеңлесе Рәйсә каршындагы Моназыйр бүлмәсенең ишеген шакуга ук ачып кереп киткән иде, һаман чыкмый, әңгәмәләре озакка китәрдер, ахрысы. Галияр, сеңлесен көтмичә, кайтырга кузгал-

ган гына иде, шул мәлдә рәис бүлмәсенең ишеге эчтән каерылып ачылды, аннан Рәйсә күренде. Моназыйрның, гәрчә тавышын күтәрмәсә дә, кинәт:

— Тукта! — дип ысылдагандай әйтүе, шушы мәлдә бу бинадагы һәркемнең колагына тырнап барып җитеп, һәркайсын сискәндереп куйды.

Ишек ачык булса да, Моназыйрның түрдәге өстәлгә, кулларын җәеп, терсәкләре белән нык таянып утыруы секретарь хатынга һәм Галиярга күренер-күренмәс, чөнки бусагада тукталып калган Рәйсә ишек уемын гәүдәсе белән бөтенләй диярлек тутырып тора иде.

— Законны бозучыларга ни булганын беләсеңме син, Мостафина? — Моназыйр бу сүзләрен дә ысылдап әйтте.— Шуны төшенерлек кенә булса да аңың бармы синең? Закон бозучыны элегрәк шалт итеп кенә төрмәгә ябалар иде! Хәзер тәртип йомшарды. Ләкин законны санга сукмаучыларны хөкемгә тартмаска дигән әмер юк.

— Соң, Шәгаетов абый... — дип, Моназыйрга таба борылып, башлаган иде Рәйсә, кинәт күзләрен челт-челт йомып, башын иеп тукталып калды. Бераз шул халәтендә торгач, авыл советы рәисенә усал итеп карады.— Әйтсәң дә, барыбер бушка әйтү инде сиңа, шулай да тагын бер тапкыр тыңла әле, —дип, тынычрак тавыш белән дәвам итте Рәйсә.

— Бүген үк мәктәпкә бар, дим мин сиңа!

— Бармыйм, иптәш Шәгаетов! Минем дәлилләрем синең «бар-бар»ыңа караганда көчлерәк.

— Закон — һәркем өчен дә закон!

— Соң, урта мәктәпне мәҗбүри тәмамлату турында закон чыгарганда, минем кебекләр буласын нигә истә тотмаганнар алайса? Ялкауланып укырга теләмәүчеләрен мәҗбүриләсеннәр дә инде, ярар. Мин бит менә укырга телим, укый алмыйм. Шушы гәүдәм белән ничек мәктәпкә барыйм ди мин? Унынчы класстагы укучылар да минем бил тиңентен генә ләбаса! Ичмасам, мәктәбендә, аяк очларына бассалар да, минем җилкәмә җитәрдәй бер укытучысы булса икән, барысы да пенсиягә чыгарга торучы, түбәнгә үсүче әбиләр бит. Каланча башыннан торып караган кебек бит мин аларга, үземә оят. Сигез класс белемем миңа колхоз фермасында мал-туар карарга бик тә җиткән!

Галиярның аяк очларына гына басып, көлемсерәп, коридор буйлап тышкы ишеккә юнәлүен, аны секретарь хатынның озата чыгуын күрмәде Рәйсә, ул, Моназыйрга авыз ачарга да ирек бирмичә, үзенекен тезә иде.

— Син урта мәктәпне тәмамлаганга аттестат алгансың, минем сигез классыма да тормый бит синең үзеңнең белемең! Туктале, иптәш Шәгаетов, нигә син мине төрмә белән куркытмакчы булдың әле? Төрмәгә ябалар иде, имеш! Гаепсезләрне дә төрмәгә яптыра идем, диген син!

— Кем? Минме? — дип, урыныннан кузгала башлаган иде Моназыйр, әмма гәүдәсенә авыр герләр тагылгандай тоелды, шул герләр аска басалар кебек булды, урынына лып утырды.— Авызыңны чамалап ач та сүзеңне үлчәп сөйлә...— дип, тавышында үзе үк мескенләнү сизгәч, тукталып калды.

— Кем дә минме, имеш! Өркетмәкче тагын үзе... Соң, Шәгаетов абый, олы кеше бит син, үзең уйлап аңларга тиешсең!

— Өлкәннәргә хөрмәтең юк синең, Мостафина, гомумән, сезнең нәселдәгеләр өлкәннәрне санга сукмаска гадәтләнгән инде. Өлкәннәргә сез, дип эндәшергә кирәк, Мостафина, белемең җитмәве шуннан ук аңкый.

— Һай икән, Шәгаетов абзаң мескенләнә үк башлады, кызганыгызчы үзен... Күплек санга мин әйләндермәсәм дә, кылган начарлыкларың белән болай да күп булып тоеласың син, хөрмәткә түгел, ләгънәткә лаек син, Тил... иптәш Шәгаетов иптәшкәй! Юк инде, иптәш Шәгаетов, кызганмыйм мин сине! Хәтерлә әле,— дип, рәис бүлмәсенә кире керде һәм Моназыйрның каршысына барып басты Рәйсә,— безнең Сәрвия әбине ни өчен төрмәгә утырттырганыңны хәтерлә! Сугыштан соң бит, кырык сигезенче елда утырткансың. Әти сабый килеш ана назыннан биш елга мәхрүм булып калган. Син утыртканын Сәрвия әби белмидер дисеңме? Белә! Шуңа күрә хәзергәчә сиңа авыз ачып сүз эндәшкәне юк аның.

— Мәктәбеңә бар!

— Әйттем йөз тапкыр — бармыйм!

— Бар, дим! Унбиш яшеңнән кияүгә чыга алмыйсың, закон тыя, синең өчен генә яңа закон кабул итмәсләр!

— Кем әйтте мине кияүгә чыга дип? Яшем җиткәч, кияүгә чыгып та гаилә камыты кияргә өлгерермен әле.

— Сүзләрең! Каршыда унбиш яшьлек кеше тора, дип кайчан туганыңны белмәсәм, ышанмас та идем, әй.

— Нишләгән ди без — унбиш яшьтәгеләр? Академтеатрның «Нихәл, яшь иптәш?» дигән спектаклен кара әнә. Венгр язучысы әсәре буенча куелган. Минем иш аның герое, ә акылы-уе белән күпләрне узып киткән. Һе! Йөртер идең бугай унбиш яшьтәгеләрне сабыйга санап, хезмәт тормышына аяк бастырмыйча! Ун ел буена этә-төртә укытканга күрә хөрәсәннәр ишәйде илдә, шул турыда уйла син. Һе! Күр син аны, сүзне бик иплә кенә бүтәнгә бормакчы булды Моназыйр Шәгаетов абзаң!

— Кит, дим, кит моннан тизрәк!

— Әйтәсе сүзем беткәч, секунд та тормам! Бүлмәңнең сөрсегән һавасын сулыйсым һич тә килми. Шәгаетов абый мине төрмәгә утыртмакчы икән, ә. Юк инде, Моназыйр абый, монысына өметләнмә. Фермада җир җимертеп эшләп йөргән кешене төрмәгә утыртмыйлар. Тырышып эшләп йөрүчеләрне төрмәгә тыгу заманнары түгел хәзер! Әнә, урамда тырай тибүчеләрне тәртипкә чакыр син. Мине мәктәпкә барырга кыстый, ә.

Мәктәп ишегеннән бөкерәеп кермәсәм, түбәм бәреләбит минем — анысын уйламый. Хәзергә исән булып тор, Шәгаетов иптәш. Онытма ләкин, әбине җәфа чиктергән өчен үзем сорау алачакмын синнән! Галияр абыйны рәис итеп сайлармарлармыюкмы, әмма сине урыныңнан үзем төшерттерәм! Авыл кешеләренең канын моңарчы эчүең дә җиткән, җитеп ашкан! Таукашның суын да эчертмәс идем мин сиңа! Эндәшмичә йөргәч тә, мине җебегәнгә саный икән бу абзый. Телем бер ачылса, утта көйдерәчәкмен мин синең ишеләрне!..

## 4

Галиярларның йорты элгәре алты почмаклы иде, түбәсе толь белән генә ябылган килеш торды. Дүрт елда ике тапкыр яңа толь япсалар да, уңмадылар, әллә тольнең начары туры килде, әллә япканда тишкәләнде шунда, астарлык тактага яңгыр саркый торган урыннар кала бирде. Югыйсә түбәне Тимерша үзе яба иде, ә ул җентекләп һәм иплән эшләүчән оста, тик килешле һәм зур итеп салынган йортка толь тышлы бүрек кидерүне өнәмәде, әнисенең һәм хатынының хәзергә толь ярап торыр, аннары калайга алыштырырбыз, дигән сүзләренә ачу итепме, тольне үзе үк начарлата иде бугай. Күңелендәгечә, үзе дигәнчә эшләүгә каршы төшсәләр, Тимершаның мондый кәмитләр ясый торган гадәте бар, ахыр чиктә барыбер үз сүзен итмичә калмый ул. Ике ел элек, Галияр солдатка китәсе елда, йортны бакча ягына тагын бер торыкка үстергәч, Тимерша түбәне тоташтан тутыя калай белән япты, акчасын кызганмады. Йортлары балкып тора хәзер! Толь түбә төсен бөтенләй дә алып торган икән. Дүрттереп салган йортны да этисе, Галияр солдатта чакта, тегеләренә иш итеп, бизәкләп, кыска такталар белән тышлаган иде.

Кайтып кергәч тә, иртәнге якта, каралты-куралардагы үзгәрешләргә күз йөгертеп кенә узган иде Галияр. Әти-әнисе белән күрешеп менгәч, бөтен йорт-җирне йөреп чыкты, бакча уртасындагы сукмактан инеш буена да төште. Монда яңа киртә тоткан икән этисе, эген җегенә китергән соң, шушында, күбесенчә бала-чага гына йөри торган төштә, киртәләр күргәзмәсе оештырсаң, сокланмаган кеше калмас иде, валлаһи! Имән баганаларның башына такта каккан, черемәсен өчен монысы. Түбән буйларга киртәләрне араларын аз калдырып салган, казүрдәк кермәсен өчен инде.

Егет бастырык юанлыгы өске киртәгә сикереп утырды, терсәге белән багана башына таянды да, инешкә озаклап карады, каршыдагы тауга күз йөгертте — таныш җирләр, балачак дөньясы иде монда. Яр буена тезелешкән талларның шәрә ябалдашларына карашын текәп торды. Каршысындагы тал кәүсәсе буйлап карашын җиргә төшерде дә тагын аның түбәсенә күтәрде — ике елда, Галияр солдатта чакта, үскән дә, үсмәгән дә

кебек иде тал. Үскән, әлбәттә, Галияр үзе үскәнгә күрә генә талның үсүе сизелмидер. Тау, әнә, үсми, ул элеккедән тәбәнәгрәк сыман, монысы Галияр, утырган урыныннан сикереп төшеп, аягүрә басып карагач та шулай тоела, монысы Галиярның солдатта үзенең үсеп китүенә бер дәлилдер.

Инеш буеннан менгәч, Галияр йорт каршындагы төз түбәле такта алачыкка керде. Бу алачык этисенең остаханәсе иде. Аны бабасы Мостафа салган булган — урам коймасыннан соң биш аршынлап ара калдырган, анда миләш утырткан. Коймадан алачыкка кадәрге рәшәткә яшелгә буялган, аннары зур тәрәзәле алачык, ул дарчин төсендә, аннары мунчагача тотылган рәшәткә сыеграк зәңгәр төсле. Алачык әнә шулай, агач бакчасы эченә кереп тора, аның, бөркү чакта күтәреп кенә куяр өчен, бакча ягында тагын зур капкач-тәрәзәсе бар. Монда, кем әйтмешли, булмаган нәрсә юктыр, әмма бу байлыкның — эш коралларының һәркайсының үз урыны билгеләнгән, әйтик, чүкеч, өтерге кебекләре, саплары тишелеп, кадакларга эленгән. Верстак элеккесе, Галияр солдатка киткәнчегә кадәргесе икән, чәй тәлинкәсе хәтлерәк бер төше балта очы игәүләүдән кытыршыланган, юк, балта түгел, өтергеме, әллә пәкеме кебек корал эзе икән — этисе савыт кырган, димәк. Галияр шушы кытыршы төшне сыпырды, утны яндырып сүндерде. Унынчы класста укыганда, көзге-язгы җылырак көннәрдә, дәресләрен шушы алачыкта әзерләргә ярата иде ул. Монда инде дәрес әзерләргә иренеп тормыйсың, мондагы һава үзе үк эшләргә боера кебек.

Кызык, бу... бу алачыкны алар нигә төрлечә атыйлар икән? Алачык, диләр, остаханә, дип тә әйтәләр. Тагын бер исеме бар — һөнәрханә. Монысын олы бабасы Мостафа кушкан булган, элегрәк заманда хәзерге мастерскойларның шундый матур исеме булгандыр, күрәсең. Хәер, эш урыннары кайчандыр кярханә дип тә аталган икән, моны бер китаптагы искәрмә-аңлатмада очратканы бар иде Галиярның. Язганда, төрлесен яза бирсеннәр, юнышу алачыгы, дисәләр дә, Галияр риза, әмма үзара сөйләшкәндә бабасы Мостафа кушкан исемен кайтарырга кирәк бу кураның — һөнәрханә! Югыйсә борынгыны гына түгел, ә моннан ярты гасыр чамасы гына элек яратып әйтелгән сүзләребезне — сүзләребезне генәме соң, күп кенә гадәтләребезне! — оныттык. Җитте, «Һөнәрханә» дип бик матурлап язам да, ал якка кадаклап куям шуны, дип уйлады Галияр һәм, ишегалдына чыгып, язуның ничегрәк торасын күз алдына китереп, башын боргалый-боргалый һөнәрханәгә карап торды.

Капка келәсен күтәрделәр. Шул тавыш Галиярны уйларыннан бүлдерде, ул кечкенә капкага таба борылды, капка ачылганчы, күрешә керүчедер, дип уйлап өлгерде. Шулай икән, авылның танылган балта остасы Ваһим икән. Иртән очрашканда авыл язмышы турында әйткән фикерләрен тәфсиллисе бардыр йә, шулай икән — бик әйбәт. Әйдә, өйгә рәхим итсен, өлкән

кешене чәй эчермичә чыгару ярамый, әбисе чәй кайнаткандыр, пәдрәтче хәсрәтләр кайтыр чак җитә, дип ашыгып йөри иде ул. Өйгә дәшсен кунакны Галияр. Күбәүләп чәйләү күңелле булыр.

Ваһимның каршына барды егет, әмма аны өйгә чакырырга өлгермәде, Ваһим һөнәрханәгә таба атлады, анда Галиярдан алда кереп, ишек уңаендагы уртасы чокырайган бүкәнгә утыргач, тун изүенең өске төймәләрен ычкындырды. Биргән дә соң монда сәламәтлекне, дип уйлады Галияр, туңуны да белми, авыруны да санга сукмый, майка өстеннән генә тун киеп йөри. Галияр Ваһимны өйгә дәште, Ваһим кул гына селтәде, егет кыстамады һәм Ваһим каршындагы, верстак янындагы бүкәнгә утырды. Хәлләр белешеп гадәти хуплаулар әйтелгәч, Ваһим һөнәрханә эчен, башын авырдан боргалап, тырпайган кашларын җыерып күзәтте.

— Күптән кергәнем юк иде монда,— диде ул һәм горгылдатып кикерде. Сөрсегән ис бәрелгәч, Галияр башын читкә борды, авыл кадере түгел, үз кадере йөртә, ахры, Ваһим абзыйны, дип уйлады.— Бабаң Мостафа исән чакта, әле синең атаң да ыштансыз малай гына иде ул вакытта, төн кунган чаклар була иде минем монда. Агач эшенә Мостафа абзый өйрәтте бит мине. Мәрхүм, яралы аягы сызлап интектерә иде үзен. Сиздермәскә тырыша иде, мәрхүм. Карале, Ваһим, дияр иде, бу агач аякка да киез итек кимичә булмас, салкын шуннан менә бугай тәнгә, дияр иде. Иртә китте, Мостафа абзыйны әйтәм, алтмышка да җитә алмады, шул аягы бозылды бит. Илленче елның азагында үлдеме әле ул?

— Сәрвия әби шулай ди,— дип, бабасы турындагы сүзне дәвам итүгә каршы төшмәде Галияр, олы бабасын үзе күреп калмагач, Мостафа турындагы истәлекләр кадерле иде аңа.

— Сәрвия әбиең белеп әйтәдер, хәтере нык аның. Тик Мостафа бабаңны җирләгәндә, әбиең Сәрвия сөргендә калды — минем дә хәтер ялгышмый. Әбиең Сәрвия сөргендә безнең Таукашның соңгы хәзрәтен очраткан бугай. Ничек очрашуларын берәүгә дә сөйләмәгән, илле өченче елда әйләнеп кайткач, хәзрәтне очраттым, абыстай һәм кызлары күптән вафат икән, дип әйтеп кенә уздырган. Кабат алып китүләреннән курыккандыр, шәт.

Монысы Галияр өчен яңалык иде. Сәрвиянең биш ел утырып кайтуын гаиләдә искә алырга яратмыйлар, Сәрвия әбисе, бу хакта кем дә булса сүз кузгата башлауга ук, йөзен җимереп кычкырып ук җибәрә:

— Җитте!

Һәм барысы да шым булалар.

Әбисенең тормышындагы яман хәлне искә төшермәскә Галияр да күнегеп үсте...

Ваһим кинәт:

— Нихәл? — дип, Галиярны гаҗәпләндерде.

Галияр көлемсерәде.

— Әйбәт, дим бит.

— Әйбәт тә әйбәт... Синең хәлләр әйбәттер дә, минем хәлләр начар!

— Махмыр бугай синең, Ваһим абзый! Алтмыштан узган кешегә эчү бигрәк тә килешми инде.

— Нигә килешмәсен? Минем үземә бик тә килешә! Кая, алып кайтмадыңмы соң?

— Чынлап әйтәсеңме син, Ваһим абзый?

— Шаяртырлык чама юк, баш чатный, төзәтергә кирәк. Хәзер авылда аракы сатмыйлар бит, кысу белән кыстылар, әй. Нигә күзләреңне шарландырдың? Шәһәрдән буш кул белән кайтырга башыңның бөтенләй дә эшләмәве кирәк. Аракысыз тормыш алып бармакчылар, ә! Бармагае! Мәүлидә карчык миңа тәрәзә рамнары ясатты да акчалата түләмәкче була. Нишлим ди мин хәзерге заманда акча белән? Тапсын аракы, шуңарчы рамнарын бирмим. Өенең бер кат тәрәзәсеннән салкын керүенә түзә алмас, нибуч табар!

— Туктале, Ваһим абзый, син ерткычка әйләнгәнсең икән ич! Ничек инде син, ялгыз карчыкны җәфа чиктереп, үзең рәхәт күрмәкче буласың?

— Ялгыз түгел ул, балаларын шәһәргә очырмасын иде. Мин үз балаларымны Таукаштан җибәрмәдем. Мәүлидәнең кызлары бизәнергә яратып үстеләр. Хәзер ике кызының берсе шәһәрдән аракы күтәреп кайтырга да ярамый. Ә мин хәзер эшләгән эшемә түләүне күбрәк аракы белән алам. Элек кенә акчалата түләү ярый иде, хәзергесе көндә аның инде мәгънәсе юк. Кибеткә кесәмне тутырып акча белән кереп, ике кулымны селтәп чыгарга тиешме мин?

— Тор әле урыныңнан! Кузгал, дим! Ю-ук, Мостафа бабайдан яхшылыкка өйрәнеп кала алмагансың син! Минем эти юне чамалы кешеләргә бушка эшләргә дә өйрәнгән менә! Олы кеше бит син, сугыш күргән кеше, мәрхәмәт дигән нәрсәне бөтенләй дә белмисеңмени соң син?!

Ваһим урыныннан киерелеп торды, һөнәрханә эчен тагын бер карап үткәрде, верстак астына да күз төшерде, үз верстагы астына аракы куярга гадәтләнгәч, монда да шешә булуы ихтималдыр, дип уйлады, күрәсең.

— Мәрхәмәт синең үзеңдә юк, Галияр солдат. Минем үләр чиккә җиткәнне аңлар идең син, мәрхәмәтең булса әгәр. Әфганстанда йөргән кешедән мәрхәмәт көткән мин җүләр тагын! Һе,— дип сөйләвен дәвам итеп, капкага таба юнәлде Ваһим,— Галияр солдатның этисе Тимерша кешеләргә бушлай эш эшли икән, ә?! Эшләсен! Тиле егәре күптер. Синең атаң шулай эшләү килешәрәк төшә, миргә эшләү килешә, үзе дә мир баласы бит ул.

— Тай, дим, моннан! Олы башың белән дөнья болгатып йөрисең, адәм көлкесе!

— Әтәчләнмә,— дип горгылдады Ваһим һәм, кечкенә капканы ачкач та, чыкмыйча торды. Усал сүзләрне бозлы яңгыр

итеп яудырырга теләде ул. Әле күптән түгел генә, Галиярларга килгәнче, үз тормышын бәяләгәндәге явызлыгын кабат кабартырга ниятләп алды. Югыйсә тормыш хакыйкате ачылыгын яшермичә ачып салып, ил-җирләр күреп кайткан Галиярга күңелен бушатырга иде бит исәбе. Шундый әңгәмәдә хәмер йотымлау телгә куәт биреп җибәрер дип соравы булган иде аракыны. Аңламады шуны Галияр. Һәм Ваһим үзе дә теләгән тәфсилләмәде.— Бернәрсә белән дә тондыра алмыйсың син миңа. Нигәме? Исәбең — авыл советы рәисе булу. Үзем үк әйттем сиңа шуны. Хәзер бу хәбәр таралып та өлгергән. Ә миңа кул тидерсәң, абруең төшеп кенә калмаячак, төрмәгә ябачаклар да түрә булудан колак кагачаксың. Иң киме шулай. Хәзерге җитәкче кычкыру-бакыру белән берәүне дә тыңлата алмый.

Галиярны сискәндереп җибәрде бу сүзләр, ул, һөнәрханә ишеге яңагына тотынып, уйга калды, бераздан, борылмыйча гына, кулындагы пүләнне эчкә атты. Галиярның авыл советы рәисе булырга теләве турында Ваһим карт кемнән ишетте икән — шунысы сәер-серле. Бу хакта егет чит кешедән Моназыйрга гына әйткән иде, Моназыйр мондый хәбәрне үзе таратырмы икән — ай-һай. Рәйсә дә белә абыйсының теләген, ул шәрран ярмас, кирәгендә сер саклый белә, ара-тирә күп сөйләшеп ташласа да, кирәкмәсен ычкындырмас. Әбисе Сәрвия Галиярдан аерылмады, димәк, ул да әйтмәгән. Тиз дә тарала соң авылда хәбәр...

Өйалды ишегеннән, җылы сулы чиләкләр күтәреп, Сәрвия чыкты. Галияр аңа булышырга барды. Алар малларга су эчертергә абзарга таба киттеләр. Әмма әбисе, көннең җылынарак төшкән чагы, дип, сыерны һәм сарыкларны утарга чыгарырга кирәклеген әйтте, һәм малларга суны шунда эчерделәр. Шуннан соң гына Сәрвия Галиярга:

— Ваһим абзаң аракы сорадымы? — дип әйтеп куйды.

— Сорау гынамы! Давайлый!

— Олы кешене ачуланасың калмаган. Картая Ваһим абзаң да, таза гомер итте, сугыштан да таза-сау кайтты ул. Аракы эчмәсә, мең яшәр мәгәр. Әле аракы эчә торып та моңарчы сәламәтлеге сынатмады. Олы кешене аракы сораганы өчен генә ачуланмыйсы идең. Эчү аның авыруы инде, эше өчен мәгәричен куеп, эчәргә үзе өйрәтте халык аны. Аракыбыз юк, дип кенә әйтергә иде. Бер башласа, эчмичә түзә алмый инде ул. Ташлап торыр көне җиткәнче.

Сәрвия Ваһимны кызганып сөйләде кебек, эчкечеләргә аңардан каты әләгә иде югыйсә. Әтисе Мостафадан Ваһимның һөнәргә өйрәнеп йөргән вакытларны исенә төшерде, ахрысы.

— Ваһим абзыйның, аракы сораудан тыш, тагын нәрсәләр сөйләвен белмисең бит син. Белсәң, үзең үк куып чыгарган булыр идең.

Карчык оныгына каршы төшмәде, сүзне бүтәнгә борып җибәрде.

— Улым, табын әзер, яме. Мин хәзер әтиеңнәрне ашка кайтарам. Шул санлы ишле малны караучысыз тотып булмый, көндез турында мин төшеп торам фермага,— дип, иртән әйткәнен онытып кабатлады Сәрвия.

— Әби, мин дә төшимме соң синең белән?

— Кирәкми. Энеләрең-сеңелләреңнең дәрес бетерер чагы җитә, шаулашып хәзер кайтып та керерләр,— диде Сәрвия һәм беләзегенең эчке ягына каратып бәйләгән сәгатенә күз төшереп алды.— Дәресләре бетте менә кечкенәләрнең. Чәйләгәч, алар мине алыштырыр. Шулай инде ул, улыкаем, гаилә подряды дигәннәре. Һәркайсына эш табылып кына тора, улыкаем. Тик кооператив та подряд дигәннәре бу хәлләрендә нәрсәгә алып барып чыгар, белгән кеше юктыр моны. Фермасын тулай карарга алынгач, азыгын үзебез әзерләү кирәк аның. Үз малына дип әзерләнгән печән булыр иде, дим. Әле мин кара исәбем белән Галияр улым, солдаттан кайткач, сарыкларга азык әзерләүне үзенә алыр дип йөри идем. Синең уең башкада икән.

— Авыл советы рәисе булмаска кушасыңмыни миңа, әби? — Урамга чыккач, Галияр Сәрвияне берара озата барды.— Мин чынлап торып авыл башлыгы булырга телим, әби. Булдырачакмын мин бу эшне.

— Үзең кулыңа эш тотмыйча, башкаларны өйрәтеп йөрмәкче исәбең-ниятең.

— Нишләп өйрәтеп кенә ди? Бәлки, хәзерге заманда, әби, өйрәтүдән бигрәк, халык сүзен тыңлый белү һәм ул теләгәнгә фатиха бирү кирәгрәктер? Аннары, әби, нигә мине печән әзерләүдә булышмас дисең? Булышырмын,— дип басым ясап әйтте Галияр һәм, акрынрак итеп: — Көчемнән килгәнчә,— дип өстәде.

— Ике җирдән акча каерыпмы?

— Нишләп ике эштән берьюлы акча алыйм ди? Колхоз төзелгән чакларда колхоз рәисләре кырда башкалар белән тиң эшләгәннәр, мин дә эшләрмен. Печән һәм урак өсләрендә эшсез йөрүчеләр болай да бихисап, миннән башка да, дим.

— Булышсаң, бик канә дә, белмим шул. Ир кеше эшләре әтиеңә генә калса, тиз бирешер ул. Инде кайчаннан бирле менә абзарлар төзәтүдән бушаганы юк, әниең дә кадак каккалап йөри, тәмам хәрабәгә калган булган икән абзар-лапаслары.

— Борчылма син, әби, әти бу эшкә алынган икән — ныклап уйлаган, димәк. Минем әти бит ул! Һәм синең малаең! Барысын да җайга салгач, әти, ике кулын кесәсенә тыгып, бариндай күкрәк киереп кенә йөрер.

Оныгының шаярту кушып сөйләве Сәрвиягә ошап куйды, шулай да сүзне уенга кайтарып калдырмады.

— Әтиеңме соң инде кул кушырып, бүтәннәр эшләгәнне тамаша кылып утыра торган кеше! Әйттең тагын син дә сүз!

— Шулай да борчылма син, әби, әйтәм ич, әти эшләячәк эшләрен элгәре уенда карышлап чыккан инде ул. Аннары аның үз

дигәнен кылмыйча калганы юктыр, һәрхәлдә, андый очракны мин белмим. Омтылышлы үҗәтлеге белән бабайга охшагандыр ул!

Галияр, урынсыз сүз ычкындыруын абайлап, тукталырга тыелгандай итте, ләкин болай эшләү бабасы турындагы сүзенә әбисенең игътибарын юнәлдерү булырын аңлап, туктамады. Әмма көтелмәгән ишарәне әбисе сизеп алган иде.

— Каян килеп охшатасың ди син этиеңне бабаңа? Мостафа бабаңны этиең үзе дә хәтерләп бетерми әле аны, бабаң вафат булганда, этиең сабый гына иде. Әтисен Мостафа бабасына охшата икән, әй...

Сәрвия сүзеннән капылт туктады, үз сүзенең мәгънәсен, ягъни бабай дигәндә кемне күз алдында тотуын Галияр да аңлатмады. Сәрвия карчык китеп барды, Галияр баскан урынында шактый озак торды. Әбисенең әйләнеп каравыннан нигәдер курыкты егет. Аңа әбисе карашын тоймыйча гына уйлану кирәк иде.

...Ачлыгына да, ялангачлыгына да чыдаган, хәтта кимсетүләргә түзгән, хаксызга җәзалауны күтәргән Сәрвия әби. Ләкин ничек соң әле Сәрвия әби, шушы авырлыкларны күрүе өстенә, мәхәббәт һәлакәтенә-көенеченә бирешмәде икән? Нинди кодрәткә ия икән минем Сәрвия әби?..

Дөрес уйлый иде Галияр, Сәрвия тормышның бихисап ачысын да татыды, мәхәббәте дә балкышланмады аның. Дөрес болары. Тик бер нәрсә — көенечле мәхәббәт — Галияр фараз иткәнчә түгел иде. Бу мәхәббәтне, ихтимал, Сәрвия һәм аның сөйгән егете үзләре генә белгәндер. Сәрвия дә, аның сөйгән егете дә, бер-берсенә яратам, дип әйтеп, бер-берсен сөендерә алмаганнар. Их-х, әгәр Сәрвия сөйгән егетенең яратам, дигән сүзен бер генә тапкыр ишеткән булса, ачлык-ялангачлыкларны, кимсетү-җәзалауларны җиңелрәк кичергән булыр, аңа яшәве рәхәтрәк булган булыр иде...

## 5

Кешеләрне күп тапкырлар ачуланырга туры килде Моназыйрга. Үзенә буйсынучыларга түрә һәрдаим «сабак укытырга», аларны шул ысул белән кысып тотарга тиеш — Таукашта озак еллар төрле җитәкче урыннарда эшләгән Моназыйр Шәгаетовның мәсләге шундый иде, һәм ул шушы иманын һәрвакыт тотарга тырышты. Җитәкче һәрвакыт хаклы ягъни. Буйсынырга тиешле кешенең каршы сүз әйтүенә юл куймады, үзеннән югары җитәкчеләр юлына аркылы басмады. Үзеңнән түбәннәр белән әрепләшү, хәтта бәхәсләшү дәрәҗәсенә төшәргә һич тә ярамый иде аныңча, чөнки бу хәл ике якның тигезлегенә ишарә булыр иде. Унбиш яшьлек Рәйсә белән сөйләшүдә нәкъ менә шушы мәсләген тота алмавына үкенде Моназыйр. Бу әрепләшү-бәхәстә ике як бер дәрәҗәдә булып кына калмады, дөнья күрмәгән яшь кыз җиңеп чыкты хәтта.

...Нәрсә ди, әбине хаксызга җәфа чиктерүең өчен үзем җавап алам синнән, диме? Әйтер, рәис башың белән җебеп торып, әйтергә юл куйгач, әйтмичә нишләсен? Мине бик теләп төрмәгә утыртыр иде, әй, ирек куйсаң. Юк шул, минем төрмәгә утыртырлык гаебем юк. Һәм беркайчан да булмады. Һәм булмас та! Аннары бит, вак-төяк гаебем табыла калса да, андыйлар өчен генә төрмәгә япмыйлар хәзер. Җинаятең күренеп торса да, хөкемгә тартмыйча, халык контроленә яки иптәшләр судына тапшыралар, ә аларга шелтә бирүдән яисә фәләнчә сум штраф салудан артыкка хокук тәтемәгән. Бөтен район яки республика күләмендә җинаять кылган абзыйларың да кисәтү сүзләре белән котылып калалар әле. Ил башлыкларын әйткән дә юк! Мин андый «дәрәҗә»дән түбән, аларның җинаятенә тиң хилафлык кылмадым. Кайберәүләр кебек хәрәмдә сылулар тотмадым, төрмәләргә кеше яптырмадым. Гомумән, мин җинаятькә бармадым. Юк инде, Рәйсә сеңелкәй, зурдан авыз ачарга сиңа юл куймам!..

Ләкин Моназыйр Рәйсәгә карата нинди чара күрергә кирәклеген, кыз дуамалланып чыгып киткәч, ялгызы гына бүлмәсендә утырганда да, секретарь хатын янына кереп, эш барышы белән кызыксынганда да, гәрчә бу уе башында кайнашса да, хәл итә алмады. Рәйсәнең кирәкмәс сүзләр сөйләвенә чик кую әмәле, таудан төшкәндә бик гайрәтләнсә дә, уйлап-уйлап та нигәдер табылмады. Рәйсә киткәч, Моназыйр канцеляриядә озак тормады, монда бозылган кәефен монда ук төзәтеп булмастыр кебек тоелды аңа. Шуңа күрә секретарь хатынга:

— Сорасалар, әйтерсең. Өй тирәсендә вак-төяк эшләрем бар. Ашыгыч кирәгем чыкса, дәштерерсең,— дип кайтып китте ул.

Кайтышлый аны Ваһим очрап туктатты.

— Моназыйр, хәл мөшкел.

— Нәрсә, тагын эчү атналыгың башландымы? Ешайтасың, Ваһим абзый.

— Тыясыңмы?

— Тыймыйм! Сине тыярга соң инде, үзең белмәгәч. Әнә, Сәрвия нәселе Галияр минем урынны алмакчы. Ул тыяр синең кебекләрне!

Моназыйр, чаттан борылып, өйләренә таба ашыкты, ләкин Ваһим аңардан калышмады, кем әйтмешли, аның үз хәле хәл иде, Моназыйрның рәислектән төшүдән куркуына игътибар итмәде.

— Моназыйр, син хәстәрле кеше, маяга тоткан шешәң бардыр. Биш бәясенә сатып алырга риза! Уф-ф! Түзәр хәл-чама юк! Эшләтәсе эшең чыгар.

— Әйдә.

Бу чакыру, гәрчә илтифатсыз гына әйтелсә дә, Ваһимга коеп яуган боз астында шәрә тән торган кешенең кинәт парлы мунчага барып керүе кебек тәэсир итте, бер мәлгә аның күз алды караңгыланып торды, тез буыннары йомшап, чүгеп куйды, йөрәге тибүдән туктагандай булды хәтта.

— Өйгә кереп тормабыз,— диде Моназыйр. Баскыч төбенә җиткәч: — Ниса каз йолкыйдыр,— дип аңлатты.— Аның быжгуын ишетәсе килеп тормый тагын. Хәзер мин кабарга бирәр нәрсә кыстырып чыгам, син мунчага бара тор. Мунчага кичә генә яккан идек, җылысы бетмәгәндер.

— Ә, Ниса җиңгәчәйне әйтәм, казны мунчада йолкымыймы соң?

— Юк. Ризыкны мунчага кертми ул.

— Әйдә, миңа салкын мунчада да эчәргә ярый. Мин Алланың кашка тәкәсе түгел. Син дә хатыннан шүрлисең, ә, Моназыйр энем.

— Алай-й,— дип сузып кына каршы төште Моназыйр.— Хатыны алдында сыгылучы Моназыйрмы мин? Кемгә тиңләвең мине?

— Шаяртып кына әйтүем, Моназыйр энем. Беләм мин синең кемлегеңне!

— Шаярта! Шаяртырлык хәлең булгач, чиккә терәлмәгәнсең икән әле!

Мунча суынмаган, идәне кипшереп җитеп килә иде, чиста иде монда. Ваһим, тәртип-чисталыкны күргәч, чүсинкәсеннән галошларын салды да аларны, ишек ачып, алачыкка ташлады. Моназыйр кергәндә, тәбәнәк урындыкларның какшау аякларын кисәү агачы белән кага иде ул. Алар шул урындыкларны тәрәзә каршына куеп утырдылар. Хуҗа чүллидән калын конус стаканга яртылаш аракы салды, кулын селкеп, Ваһимга күтәрергә кушты. Ваһим, аракыны калтыранып эчеп, йөзен җыерып, күзләрен йомып шактый торгач кына, тәрәзә төбендәге чынаяк тәлинкәсеннән коймак алып капты. Моназыйр үзенә аракы бүлмәде. Ваһим уң тезенә таянды, сул аягын сузып җибәрде.

— Һәйбәт! — диде һәм, кинәт кузгалып, башыннан бүреген салды да, аны матчага кагылган тимер тырма тешенә элгәч, элекке халәтенә кайтып утырды.— Гел дә кирәкмәс төшкә ат тырмасы теше кагып куйгансың ич, Моназыйр энем. Матчага юан тырма теше кагуның хаҗәте юк. Кирәкмәс төшкә кагылган чөй, әй! — дип башын чайкады Ваһим һәм бүреген үрелеп чөйдән алды да янәшәсенә куйды.

— Торсын. Кыенламый. Хет тонналы әйбер асып куй — бөгелмәячәк.

Моназыйр стаканга илле грамм чамасы аракы салды да тагын Ваһимга эчәргә ымлады.

— Үзең?

— Башта эчәсе килгән иде дә, хәзер теләк бетте. Миңа карама син, миңа эшкә барырга туры килер әле. Авыздан хәмер исе сизсәләр, Сәрвиянекеләр урыныңнан чөеп кенә ташларга да күп алмаслар.

Ваһим Моназыйрның рәислектән төшерү ишарәсенә бу юлы да игътибар итмәгәндәй булды.

— Миңа ярый, минем беркем алдында да җавап тотасы юк,— диде Ваһим эчкәч, коймак сыныгын чәйнәр-чәйнәмәс йотып җибәрде.

— Миннән аракы сорап, канцеляриягә барышың идеме? — дип, кинәт бүтәнгә күчте Моназыйр.

— Анда ук барырга туры килмәде бит, каршыга үзең очрадың. Авылда аракысы да бик сирәк кешедә инде аның хәзер, ә синдә булырына ышандым.

— Бурыч аласыңны онытмыйсың син, ә, Ваһим абзый! Хәтер шәп синең!

— Бурыч, дип... Минем синнән бурыч аласым юктыр ич.

— Хәйләләмә! Шушы мунчаны салып бетергәч, мин сиңа, башка осталардан аерып, ярты куймаган идем. Авылда сине, өмәдә катнашсаң да, соңыннан аерып сыйларга тиешләр бит. Әгәр шушы тәртип сакланмаса, аны бозган кешенең икенче гозерен тыңлап та бетермисең син.

— Моназыйр энем, синең бер нәрсәне уйлап караганың бармы соң — минем бит эшем дә башкалар эшеннән аерылып тора. Шәп якка аерылып тора! Шулай булгач, ни өчен миңа хөрмәт тә аерым булмаска тиеш икән?! Син гомереңдә начальник булган агай, кешеләрне аерып карауга һәм үзеңә аерып карауларына күнеккәнсең. Шулай булгач,— дип нәтиҗә ясау гадәтен кабатлады Ваһим,— нигә мине аерып хөрмәтләмәскә тиешләр икән?! Әмма монысын ялгыш әйттем. Дөресе болай — мин үземә аерым хөрмәтне осталыгым башкалар осталыгыннан өстен булуы өчен таләп итәм! Дөрес таләп.

— Мин үземә хөрмәтне, әйтик, авыл советы рәисе булуым өчен генә таләп итәмме?

— Анысын үзең беләсеңдер. Кешегә бәяне сирәк бирәм мин. Анда да иң элгәре аның эшен бәялим.

— Минем эшем начар барамы? Халык өчен эшлим мин! Ә син үзеңә кирәкне генә каерып яшисең.

— Һәркем шулай. Син дә, Шәгаетов, үзеңә кирәкне генә кайгыртасың. Аннары килеп, авыл советының бүгенге корамасының да миңа кирәге юк. Хаҗәте юк миңа аның. Нишлим ди мин синең авыл советың белән? Нәрсә эш майтара аласыз соң сез? Ә хәтер мәсьәләсенә кайтсак, син дә хәтерсез түгел, мунча салгач, мине аерып сыйламавыңны исеңдә тоткансың.

— Шул бурычымны түлим менә.

— Әмма ярты урынына чүлли генә куйдың.

— Мин эчмим. Ярты куеп, мин дә эчсәм, сиңа барыбер шуның хәтле генә тияр иде.

Ваһим стена буендагы шешәгә карап алды, икегә бүлеп эчәрлек чамада бар икән әле аракы, иллешәр граммлап. Шулай да җитәр, стакан тутырып чөмерүләр заманы узды.

— Исәп итә беләсең,— диде Ваһим һәм башын селтәп көлемсерәде.— Артыгын чыгарасы түгел, әй! Саран! Кысмыр җан

син! Дөньялыкта әйбер кызганма, тегендә баргач, бернәрсә дә кирәк булмаячак. Гүр ул кысан, әйбер-сәйбер тутырырга урын юк анда. Син дөньялыкта рәхәт күреп кал. Һәм хыял итеп! Тегендә хыял итәргә туры килмәячәк.

— Тукта мондый сүзләреңнән, Ваһим абзый! — дип ачуланды Моназыйр.

— Туктыйм соң. Минем бит ике дөньяга бер генә моржа чыгарган чакларым да бар. Эчеп алганда. Ә сиңа ни өчен мунча салыштым мин — шуның сәбәбен беләсеңме? Син үзең чакырып эшкә кушмадың бит мине. Үзем килеп кушылдым. Сәбәбеме? Сәбәбе мондый, Шәгаетов. Безнең Таукашта хәзер синекеннән шәп йорт-җир юк. Хәтта Тимерша, үз кулы белән эшләсә дә, синнән уздырырга байлыгын җиткерә алмады. Таукашта мондый йорт-җир бөтен тарихына санаулы булгандыр. Шундыйлардан мин Рухан хәзрәт йортын, абзар-курасын гына беләм. Хәзрәтнең үз кулы эш белә иде. Аннары аңа Сәрвиянең әтисе Мостафа оста булышкан, мине һөнәргә өйрәткән Мостафа. Һәм менә хәзер Таукашта иң дәү, матур йорт синеке. Әйбәт осталар эшләде, минем дә катнашым бар, хәер. Шушы балкып торган йорт-җиргә мескен мунча салып куйсалар, бөтен Таукашның ямен алырлар, дип куркып, син чакырмыйча да эшләшергә кушылдым мин, бик беләсең килсә! Аракы сыена калган адәм булып түгел!

— Ярап куйды бит әле аракысы да! — дип үз җаена сөрде Моназыйр.

— Әйтәм бит, аракыңның ун бәясен түли алам мин сиңа! Мунчаң шәп чыкты, шунысына сөен син, Шәгаетов. Борынгы байлар мунчасы да моңа тиң булмагандыр. Ә син шуның матчасына кирәкмәскә тырма теше какkансың да утырырга какшау урындыклар куйгансың. Гомергә булмаганны! Таукашта булмаганны!

Ваһим, таянып, стенага терәп ясалган киң эскәмиягә утырды, тәбәнәк урындыкны, аягы белән этеп, шуның астына качырды. Моназыйр эндәшмәде, башында бүтән уйлар иде бугай. Ваһимның хәзер сөйләшәсе дә сөйләшәсе килә иде, ул тунының җиңнәрен салды, ләкин тунын җилкәсеннән төшермичә, стенага терәлде, маңгаена ябышкан кыска чәчләрен ышкып янга сыпырды.

— Шулай, Моназыйр энем, йорт-җирең Рухан хәзрәт йортҗиренә торышлы. Әйбәтрәк тә. Әмма, әйткәнемчә, хәзрәт үзе дә эшләгән иде, ә синең монда кадак та какканың юктыр, әнә шул тырма тешеннән башка, дим. Аерма шунда. Кирәкмәс төшкә — тимер чөй.

— Чөй тегермән ташын күтәрә.

— Бу андый чөй түгел. Бу чөй тукмак таләп итә торганы. Яки же... Ярар, тыңлап кына утыр. Ә, Моназыйр иптәш, чөйләр аермасы турында уйлаганың бармы синең? Юктыр. Чөнки хыялга чамалы кеше син. Мостафа абзыйга тиң кеше булмагандыр Таукашта, дим мин үзем, хыялга чумуда, дим. Рухан хәзрәт

йортына тиң булсын иде Таукашта һәр йорт, дип хыяллана иде Мостафа абзый, революция тигез байлыкка ирешү өчен ясалган бит, дияр иде. Ә андый йорт әле хәзер дә Таукашта берәү генә, син генә салдыра алдың андый йортны. Башкаларның да, хыялга бай кешеләрнең дә, байлыгы җитмәде. Сәрвиянең малае бер Тимерша тырыштырып килә. Мин үзем өметләнмим инде, яңа йорт салып изаланунның кирәге юк хәзер миңа. Тагын бер нәрсә турында уйлаганың бармы синең: Таукашта шәп йортлар элегрәк булдымы икән? Әй, син белмисең лә, безнең авыл кешесе түгел лә син.

— Нишләп Таукаш кешесе булмыйм ди мин? Илле ел шушында яшим ләбаса!

Моназыйрны Таукаш кешесе санамауда бәхәсләшеп торасы итмәде Ваһим, сүзне бүтәнгә борды:

— Их-х, тукмап та күрсәтте соң безне тормыш! Сугыш алдыннан шушы тып-тыныч, кешеләре әйбәт авылда, ялгыш сүз ычкындырмагаем, дип, дер калтырап яшәдек, сугышта газраил белән якалаштык. Таукаштагылар ачка интеккәннәр. Сугыштан соң аякка басып китә алмыйча азапландык, бераз күтәрелебрәк карасак, баш түбәсенә тондырып тордылар. Аннары, мактануга көчтек тә, барысы да ал да гөлгә әверелде, имеш...

Мунча хуҗасы эндәшмәде. Ваһим сөйләгәндә, үзенең берничә мәртәбә искәртүенә эчкече останың битараф калуын ошатмады ул һәм үзе дә илтифатсыз булырга тырышты. Шулай да Ваһимны сөйләүдән тыймады, куып чыгарса, йортын һәм каралтыларын салуда баш оста булган кешегә бурычлы калыр кебек тоелды — чүллидә йөз граммлап аракы бар, аны эчәргә Ваһим ашыкмый иде.

— Их-х, хыяллар киселде шул! — дип тагын сөйләп китте Ваһим.— Таукашта һәр йорт балкып торырга тиеш иде минем хыялымча! Балта остасының шуннан да шәп хыялы була алмый. Ә син, һәр сүзең саен киләчәкне кабатлап, авылда ничәмә еллар җитәкче урын биләп, шушы изге матурлыкны, ягъни революция кушканны оештыра алмадың. Өстәвенә мин авыл советы рәисе, дип күкрәк киерәсең! Авылны бетерүче икәнеңне белмисең! Кодрәтеңнән килсә, Таукашны чабуың белән томалар идең! Авыл өстенә тилгән булып кунган бәндә син!

— Ни сөйләгәннәреңне төшенәсеңме?! Җавап...

— Төшенәм! Кирәксә, җавабын да бирермен!

— Җенемне кузгатсаң, сиңа да управа табармын!

— Ай-һай ла! Хәер, син кешегә кара ягарга оста җан. Бу тарафта хыялга бай...

Моназыйр моңа җавап кайтармады, тешләрен шыгырдатып куйды. Ваһим да бераз сүзсез торды, маңгаен угалады. Бер мәлгә алар бер-берсен оныттылар. Ниһаять, Ваһим йодрыгын йодрыгына бәрде, уфылдады да сөйләвен дәвам итте, офтануы сизелә иде. Моназыйр ни сәбәптер аны бүлдермәде.

— Хыял... Хыяллар... Мин бит бала чакта язучы булырга хыялланган идем! Һәм булачак та идем. Чын әгәр! Тормыш җай чыгармады, хәтта җиде класс белем белән калдырды. Күңелдә кешеләргә сөйлисе күпме вакыйгалар тулып тора бит минем! Аларны мин хәзер дә күңелемнән сөйләп-шомартып йөрим. Тыңла, бер хикәямне сиңа сөйләп күрсәтәм. Анда шәп йорт та бар. Бәлки, ул синең йорттан, хәтта Рухан хәзрәт йортыннан да шәбрәктер. Таукашта ук булгандыр, бәлки, бу йорт. Тик йорт хикәянең үзәгендә түгел. Күңелсез вакыйга, ачы вакыйга тасвир кылына минем хикәядә. Ерткычлык турында борынгы заман хикәясе бу. Хыялның тәэсир көче зур, шул көчне кабул итеп алырга һәм бәрәкәтләп тота белергә кирәк. Мин боларны беләм. Мин беркайчан да исереп аңымны җуймадым. Хәзер дә аңым җете. Тыңла, сөйлим.

Айдашны куды Әбүсөгыт бай. Егетне тегермәннән менүенә чакыртып алды да, киеменә сыешмыйча, калтыранып бакырды.

— Чыгып кит! Ун, йөз, мең ялчы килер миңа! Китерермен дә! Егет, имеш! Ябагай йолкыш! Анаң белән бергәләп ычкыныгыз! Байлыгыма сарылмакчы булган икән! Янә күземә буталсаң...

Язмышында хәвеф тууын, кызган кыршауның тормышын сытып кысарга торуын абайлап җиткермәде Айдаш. Байның кимсетеп, хезмәтчесенең кешелеген аяк астында таптап җикеренүен каушап, аңышмыйча тыңлап торды. Ялгызы калгач, лапас эчендәге утын яру бүкәненә утырып, куылуының сәбәбен эзләде.

...Малай чактан ук шушы Әбүсөгыт байның аты-абзары тирәсендә бит, кулыңнан эш килмәсә, бер хәл икән, байның бөтен тизәген дигәндәй җыештыра — кол хезмәте, эт тормышы инде. Нишләп ошамады әле Айдаш?! Элегрәк Айдаш хезмәтеннән канәгать иде бит бай әфәнде.

Приказчиклар Айдаштан чагыштыргысыз рәхәт яшиләр, хәтта ара-тирә шәраблы мәҗлесләр дә ясыйлар, әрәмәлек буенда кичке уенны калдырмыйлар, кибетләрне, бай югында, соңлап ачкан чаклары була. Шулай да Әбүсөгыт аларны гафу кыла, соңгы вакытта гел Айдашка каныга. Приказчикларга акчалата түли бай, ә Айдашка — калган ризык, тузган кием.

Әнисе картайган. Ул да гомер буена Әбүсөгыткә көчен түккән, хәзер дә ике катлы йортны байбичәгә ошарлык-килешерлек итеп җыештырып тора, көн саен диярлек тау-тау керләрен уа. Кунар почмак бар иде әле үзе, тамак бер ашаудан икенчесенә ялгана иде.

Китәр анысы Айдаш, ялынмас Әбүсөгыткә. Моңарчы да байның мыскыллавына-изүенә сабыр холкы гына түздерде аны. Китәрләр, шахта якларына барып әйбәтләп урнашырлар да, әнисен өр-яңадан киендереп, үзенең дә өс-башын бөтәйтеп, кесәсен акчага тиендереп, туй хәстәрләгән ата-аналарны егетнең

дә егете бу Айдаш, аңа кызыңны биру — үзе бәхет, дип әйттерерлек итеп кайтып та төшәрләр. Себер якларына китсәң дә ярар иде, анда инде беләге таза кешегә эш муеннан, ди; акчасы да шәп төшә икән. Урман эшенә дә риза, алтын эзләргә дә була. Тик үтә дә ерак, диләр инде ул җирләрне. Аннары әнисенең бөти кебек төреп тагып йөри торган, гомере буена җыйган биш тәңкә акчасы белән генә анда ук барып җитә алмассың шул. Күмер шахтасы язгандыр инде безгә. Шахталарда үзебезнең татарлар да күп, ди.

Әнисе:

— Улым, әллә соң Газимҗан байга ялланып карыйммы? — ди дә, әмма байлар алдында тез чүкмәячәк Айдаш моннан ары. Әбүсөгыткә бил бөгүе дә җитте, бик җитте, һәммәсе дә бер тубал коелдыклары алар, байлар. Белдек, бик шәп белдек инде аларның кемлеген. Әнисен күндерергә дә, иртәгә үк сәфәр чыгарга. Сагындырыр инде сагындыруын туган җир, әмма түзәрбез. Гомерлеккә китү түгел, бер ел, күп дигәндә — ике ел; юк, бер елдан барыбер дә әйләнеп кайтырлар Айдаш белән әнисе. Каладан салага, пар ат яллап, тарантаска утырып кайтып керерләр. Юк, атларны, барлык дирбиясе белән, калада ук үзе сатып алыр Айдаш. Аннары авылда йорт салдырыр. Аларның йорты авылда иң-иң матуры, иң-иң зуры булыр. Йортның ишеге, керер кешене каршылап, һәрчак ачык торыр. Күрче, ә, ничек шәп көйләнәчәк бит эшләре! Читкә китү турындагы уй башына нигә элегрәк кермәде икән? Күптән инде йорт-җир тотып яшәрләр, тормышларын матур итеп корып җибәргән булырлар иде. Әнисе оныкларын иркәләп үстерер иде.

Китәр Айдаш. Ә Сөмбелә? Кала. Әтисе Әбүсөгытнең Айдашны куып җибәрүен беләме икән әле ул? Бүген ишегалды тирәсендә бөтенләй күренмәде, көне буе бүлмәсендә утырды бугай. Әллә этисенең хөкеме белән килешәме Сөмбелә? Бәлки, Айдашны яратмыйдыр да ул. Торыр куышы булмаган Айдаш череп баеган Әбүсөгыт кызы Сөмбеләгә тиңме соң?! Их, Айдаш, Айдаш, тиң түгел бит син Сөмбеләгә! Аның сиңа җылы мөгамәләсе үзенчә мыскыл итеп кенә йөрүедер. Соңгы көннәрдә сирәк күренә башлады Сөмбелә, очрашканда да салмакбасынкы исәнләшә, эти-әнисе кинаясеннән шикләнәме, әллә инде Айдашның күңелен котыртып уйнаудан туйдымы? Нигә шушы Әбүсөгыткә ялландылар икән соң? Сөмбеләгә Айдашның гыйшкы төшмәгән булыр иде.

Юк, болай әйтү дөрес түгел! Әле, уйласаң, Сөмбеләне яратуы яхшы — яшәү күңелләләнеп китте. Сөмбелә дә яратадыр, яратмыйча буламы соң! Айдаш ярлы егет, әмма төшеп калганнардан түгел лә. Их, киләсе сабан туена шахтадан балкып кайтып керер Айдаш, Әбүсөгытнең күзләре шар акаер. Сөйләшә белер ул чагында бай белән, Әбүсөгытең дә куккә сикерә алмас, Айдашка «кияү» дип дәшәргә барыбер мәҗбүр булыр. Узы-

нып-тузынып күрсәттең бу көннәрдә, бай абзый! Шулай да Айдаш теләгәнчә барыр дөньялар.

Беркөнне Сөмбелә белән минем алма бакчасында күрешкәннән соң башланды синең үтә каныгуың. Сөмбелә әйткән иде аны, безне әни күргән, этигә җиткергән, дигән иде...

Бу кич Айдашның гомерендә иң-иң бәхетле чагы булган иде. Әбүсөгыт бай җәйге кичләрдә табын әзерләтә торган, тирә-ягы җимеш агачлары белән төрелгән кечкенә аланлыкта җидегән йолдыз әйләнә башлаганчы утырды алар. Сөйләшмәделәр дә диярлек үзләре. Янында Сөмбелә утырганда, шундыен да рәхәт икән ул — сөйләшмәсәң дә була, аның сулышын тою да җитә. Сөмбеләнең сулышы битеңне мәрхәмәтле сыйпый, йөзеңә мәхәббәт җылысы сеңдерә.

...Сөмбелә Айдашның сызганган күлмәк җиңен тагын бер әйләндереп күтәрде.

— Килешә сиңа сызганган җиң,— диде.

Аннары Айдашның яңакларын, иркәләү көткән күзләрен йомшак куллары белән сөйде.

— Күзләрең якты синең, Айдаш,— диде һәм егетнең иреннәрен татландырып үпте дә сикереп торып өйгә таба йөгерде.

— Сөмбелә!

Җавап ишетелмәде. Әллә берәр агач төбенә качты гынамы соң?

— Сөмбелә! Тукта... Китмә инде...

Йортның бакча ягына чыга торган өйалды ишеген шыгырдатмыйча гына ачып кереп китте Сөмбелә, шудырып кына баскан аяк тавышын иkенче катка менеп җиткәнче ишетеп торды Айдаш. Их, барыбер дә, Сөмбелә туктамаса да, күңеле мәхәббәт дөньясына чумган иде егетнең!..

Иртәгә китәсе бит инде, Сөмбелә белән ничек кенә очрашасы икән соң? Әбүсөгыт бай төшермеш иде, салган-салган — лаякыл исергәнче эчсен иде, ичмасам, йокыга түнәр иде аннары. Айдаш, караңгы эленгәч, Сөмбеләне алма бакчасына чакырыр иде, тәрәзәсе турына барып, сандугач булып сайрап кына җибәрер иде. Айдашның сандугачтай сайравын аңлап алыр иде дә коштай очып кына чыгар иде Сөмбелә.

Кич җитә инде. Гашыйклар бәхетенә генә булыр изге төннәр.

Туктале, Әбүсөгыт бай, синең «хәерче» дип кимсетүең белән генә дөнья бетми, мәхәббәт хәерчелеккә киенми икән бит, яратышу — үзе байлык, синең алтын-көмешең мәхәббәт каршында чүмәлә генә бит ул. Ә мәхәббәт — зур кибән...

— Айдаш!

— Сөмбелә!

Күзләр күзләргә мәхәббәт сөйләде.

— Мин... Без... китәбез.

— Беләм...

Килде, хушлашырга үзе килде аның Сөмбеләсе! Килде! Әм-

ма бакча эчендәге кечкенә аланга түгел. Егетнең лапаста үзе генә икәнен күреп, шул аулакка керде ул.

Сөмбелә, җиң эченнән алып, Айдашка кулъяулык бирде. Айдаш кулъяулыкны тезләренә җәеп куйды.

Менә нинди була икән ул сөйгән кызның бүләге! Читләрен кызыл җеп белән каймаган, почмагына чәчәк төшергән. Алма чәчәге. Әнә, чәчәк элпәге ачылып тора. Чәчәкнең уң ягына әлиф суккан. Монысы «Айдашка» дигәнне аңлата икән. Икенче якта «С» хәрефен сырлап куйган — «Сөмбеләдән». Әйе, «Айдашка — Сөмбеләдән».

Күзләр вәгъдә биреште:

— Кулъяулыгым сиңа мине оныттырмасын!

— Мин кайтырмын!

— Мин көтәрмен!

Хушлашу аларга тирә-юньне оныттырган иде.

— Ах, сасы чикмән, син әле мондамыни? Күздән югалырга куштым бит мин сиңа!

Айдаш белән Сөмбелә Әбүсөгытнең үкерүеннән сискәнеп киттеләр. Егет кулъяулыкны тиз генә кесәсенә тыкты.

— Иртән китәргә уйлаган идек, бай әфәнде, җыенасы-сугыласы да бар...

— Алама, төенчек төйнәргә ничә көн кирәк сиңа! Бай кызына үрелгән, ә, Әбүсөгыт кызына гыйшкы төшкән, кулъяулыклы булган, ә! Теге юньсезе дә этисенең исеменә тап төшерүдән тайчанмаган! Яратам, ди. Анысы да ахмак! Яраттырыйм соң үзенә, кулларымның кычытуы тәмам басылганчы яраттырыйм!..

Әбүсөгыт исереклек җитезлеге белән Сөмбеләнең башын төйде, аны кулларыннан тотып селтәп ыргытты, кызы буралы абзар нигезенә кайшалып очып төште. Айдаш аларның арасына керергә өлгерә дә алмыйча калды. Аннары Әбүсөгыт бай, йодрыкларын яшендәй уйнатып, Айдашка ташланды һәм егетнең бугазыннан эләктереп алды. Айдашның тыны капылт кысылды, ава башлады. Әмма тезе белән Әбүсөгытнең эченә тибеп өлгерде. Бай бүкән төбенә бөгәрләнде.

— Бай абзый, акылыгызга килегез, нигә Сөмбеләне кыйныйсыз? Аның ни гаебе бар? — Айдаш Сөмбеләгә таба атлады.— Сөмбелә, кереп кит моннан тизрәк. Сөмбелә... һушын җуйган. Их, Әбүсөгыт бай, Сөмбеләне нигә кыйнарга инде?..

Бай бүкән читенә чабылган балтаны алды.

— Үтерәм! Чабам! Җир йөзендә бер хәерче кимегәннән дөнья бетмәс!

Айдаш аның селтәнгән кулын һавада ук тотып алырга җитешеп беләген кысты, балтаны ычкындыртты.

— Бай, тукта...

— Бугазыңны чәйнәп...

Һәм Әбүсөгыт тешләре белән Айдашның бугазын эләктер-

де. Егет аның башын этәрә, әмма тешләр ычкынмый. Айдаш тырнакларын Әбүсөгытнең бугазына батырды.

Әбүсөгыт ыңгыраша, ә тешләре чәйни.

Айдашның башы артка ташланган, ә бармаклары байның муенына батып кергән...

Әбүсөгыт чүгәли башлады, ә тешләрен ычкындырмый, инде ычкындыра алмый — Айдашны үзе белән җиргә өстери.

Айдаш бармакларын ычкындырмый, инде ычкындыра алмый — бөтен гәүдәсе белән Әбүсөгытне аска баса.

Күзләргә берни чалынмый.

Алар лап итеп җиргә аудылар.

Тешләр һаман тирәнрәк бата.

Бармаклар һаман ныграк кыса.

Әбүсөгыт ыңгыраша.

Айдаш гырлый.

Тешләр үткен.

Бармаклар көчле...

Кинәт икесе дә чалкан кайтарылып төштеләр.

Сөмбеләә күзләрен ачты, әмма лапас эчендә уйнаклап узган хәвефне башта төшенеп җитмәде.

Әнә этисе белән Айдаш нигәдер янәшә сузылып ятканнар.

Этисе. Йөзе күгәрә, җыерчыклы маңгаенда тир тамчылары тап калдырып кибә. Авыз читләрендә алсу кан оеша. Иреннәре бүлтәеп, авызы ачылган.

...Эти кеше, син Сөмбеләгә тормыш бирдең. Үзең тормыш биргән кызыңнан бәхетен нигә кызгандың?

Айдаш. Күзләре йомык. Муен итләре өзгәләнергә җитеп салынган. Кулъяулыгын кесәсеннән алырга көче җиткән, ярасын сөртмәкче булгандыр. Кулъяулык кыскан кулы күкрәге өстендә катып калган.

...Айдаш, син Сөмбеләгә мәхәббәт бүләк иттең. Мәхәббәтнең бәхетен дә нигә бирмәдең?

Туктагыз әле, ни соң бу? Әллә инде... Әллә инде... этисе дә... Айдаш та...

Куркыныч күренеш Сөмбеләнең аңын, ачыкланып җитәргә ирек бирмичә, тагын томалады. Ул этисенең һәм сөйгән егетенең арасына тезләнде, кулларын күккә сузды:

— А-а-а...

Ваһим, бераз тынып торганнан соң:

— Хикәя менә шушы,— дип әйтеп куйды.— Әбүсөгыт байның йорты монда тәфсилләп тасвир кылынмый, аның ике катлы, бакча якка аерым ишеге булуы гына әйтелә. Әмма ки ул гаҗәеп булган. Хыялың белән күз алдыңа китер син аны, Шәгаетов! Башың эшләсә! Ерткычлык турындагы хикәяне мин сиңа атап чыгардым. Ә хатының Гөлниса — изге кеше, Сөмбеләә кебек гөнаһсыз. Хәйрелбәшәргә багышлап хикәя чыгара-

сым бар әле минем, шагыйрь җанлы Гөлниса Хәйрелбәшәргә багышлап! Киләчәк тә киләчәк синең телеңдә, ә киләчәкне күз алдына китерергә көчсез адәм син!

Моназыйр Ваһимның мондый фикеренә дә битараф калды.

— Әбүсөгыт байның йорты кайда икәнлеген дә белмиләр икән хәзер. Рухан хәзрәт нигезе дә бетте. Синең нигез кайчанга чаклы торыр — билгесез. Әбүсөгыт байның нигезе нигә беткән? Чөнки йортның хуҗасы игелек дигәнне белмәгән. Кешеләрнең бугазын син тешләрең белән чәйнәмичә өзәсең. Синең йортның да нигезе корыр. Нәтиҗә ясыйк: Таукашта мин белгән өч шәп йорт-кураның икесе — Әбүсөгыт байныкы һәм синең йорт — хуҗаларының игелек белмәвеннән бетә. Ә өченче йорт, хуҗасы Рухан игелекле булса да, бетте. Аны син туздырдың. Әбүсөгыттән бер аермаң шунда. Ә-ә, Шәгаетов, син Айдаш белән Әбүсөгытнең кайсысы урынында булыр идең шулай да?

— Һе, ниткән тиңләргә маташу бу тагын?! Шуны beләсең киләме, хыялый абзый?! — дип мыскыллап әйтте Моназыйр.— Бел соң, ләкин яңа хикәялек сүз ишетмәссең. Кайсысы урынында булсам да, мин үлмәгән булыр идем!

— Син аларның берсе дә була алмыйсың! Алар, ерткычлыкка җитсәләр дә, ачыктан-ачык сугышта үләләр. Ә синең ерткычлыгың яшерен! Димәк, син аларның уртасына да гөнаһсыз булып баса алмыйсың! Мин Әбүсөгытне дә, Айдашны да акламыйм. Аларның язмышы — үзе фаҗига. Алар ерткычка борынгы заманда әверелгәннәр. Ә син бүген, дөнья алга киткән заманда, ерткыч! Һәм нинди әле!

— Син авызыңны чамалап ач, яме!

— Чамаланган! Куркытма! Малай чагыңнан ук Рухан хәзрәтне сөргенгә җибәрттердең! Сәрвияне төрмәгә тыктың, баласын ана сөюеннән аердың!

— Кем? Минме?!

— Син! Тагын саныйммы синең корбаннарыңны?! Санап кына калмам, исбатлап та күрсәтермен. Сөйләшкәндә тавышың да дыңгырдык юлда буш машина әрҗәсе чыгарган тавыш кебек икән бит синең! Моңарчы шуны аермаганмын, саңгырау колак мин. Без, Таукаш кешеләре, җебегәннәр булдык, синең әшәкелекләреңә илле ел буена түздек. Авыл кешеләренең баш түбәсендә малай чагыңнан биедең син, ерткыч җан!

Ваһимның ярсуы чиктән ашып килә иде, хәтта Моназыйр аңа каршы сүз әйтергә куркынып калды. Ваһим шешәдәге аракыны стаканга горгылдатып бушатты. Бер кулына шешә, икенчесенә аракылы стакан тоткан килеш иреннәрен кысып уйланып торды да, шешәне һәм стаканны мич авызы алдындагы ташка томырды.

— Таукашта һәрьяктан килешле бер йорт-җир булсын дип эшләштем мин! Шуның сиңа булуы бик тә кызганыч! Хәер, әйтәм ич, авылда башка берәүнең мондый йорт салдырырга

байлыгы җитмәячәк иде. Тик синең йорт-каралтыларың төссез күренә. Үз кул көчем керде югыйсә, шулай да төс бирә алмадым. Дөресе — мин биргән төсне синең күләгәң каплый, кай төшенә генә карасаң да, шул төшне күктә канат какмыйча очкан тилгән күләгәсе томалый да ала. Җитте! Авыл башлыгы булуыңнан чөябез сине! Әмма шуны бел: мин сиңа беркайчан да ялланмадым! Ә син мине ялчы итеп тоясың икән! Мунчасына чакырып сыйлый, имеш! Өенә чакырырга җирәнә! Мә, җирәнсәң!..

Һәм идәнгә косык җәелде. Ваһим мунча ишеген шартлатып ябып, кече капканы төбенәчә ачык калдырып чыгып китте.

Галияр янына шуннан соң тынычланып җитмичә кергән иде Ваһим. Солдаттан бүген генә кайткан егет белән күңелен бушатып сөйләшмәкче иде. Барып чыкмады нияте. Махмырдан чатнаган башы мунча хуҗасы салып биргән аракыдан соң җиңеләеп торган арада хикәясен сөйләп алуы Моназыйрның яшерен ерткычлыгын күрмәскә тырышудан иде. Тик кабынып-ярсып китүдән аракы да, Моназыйрның явызлыгына күз йомарга тырышу да тыя алмады. Галиярдан аракы соравы да шул ярсуын басарга теләүдән иде. Ләкин аның ярсуы сәбәбен Галияр сизмәде, Ваһим үзе аңлата белмәде. Моназыйр мунчасында утыруы күз алдыннан китмәгәнгә күрә, солдат егет белән сөйләшүе кырт-кырт һәм мәгънәсез чыкты...

Моназыйрның хатыны Гөлнисаны авылда тыныч холыклы итеп беләләр. Ул беркайчан да кешеләр алдында чәпчемәде, өйдәге сүзне урамга ташымады, урамда ишеткәннәрен өйгә алып кайтмады. Баштарак Таукаш халкы Моназыйр кылган әшәкелекләрдә хатынының өлеше бардыр дип шикләнә иде. Гөлниса-Ниса исә моны шик дип түгел, бәлки, иремне яратмаганга күрә миңа кырын карыйлардыр, дип бәяләде, халык акны карадан үзе аерасына ышанды. Өстәвенә ире Моназыйрның башкалар язмышы белән уйнавын баштарак күңеленә дә китермәде. Бала чактан ук гайбәт ише пычраклыклар аңа ят иде, аларның гаиләсендә турыдан бәреп сөйләшүдән бүтәнен, ягъни әләк-гайбәтне белмәделәр. Пенза ягы кызы ул, Моназыйр аның белән армиядә хезмәт иткәндә танышты. Моназыйр хезмәт срогын тутырып кайтып киткәч, алар хат алыштылар. Егетнең ярату турындагы сүзләрендә самимилек тойды кыз, явызлыкның чаткысы да сизелмәде хатларда. Моназыйр, армиядән соң ике ел бригадир булып эшләгәч, Нисаны килен итеп алып кайтты. Бу вакытта абыйсы, Моназыйр белән ачуланышкач, Таукашка син исән чакта кайтмам, дип, Урал ягына чыгып киткән иде. Ниса каенанасы белән ике еллап яшәп калды.

Баштарак авыл кешеләре Нисаның сөйләшен аңлап җиткермиләр иде, яшь килен безнең яклар сөйләшенә тиз өйрәнеп алды тагын, үз тирәсе хатыннар аның бу сәләтен мактагач, Тукай сүзләрен кабатлап, җенесән бу зат мишәрдер, Хәйрелбәшәрдер, дип мактанып та куйган иде, адәмнең затлысы булам мин ягъни.

Шунысы гаҗәбрәк булды Моназыйрга: Ниса, Тукай җиреннән еракта туып үссә дә, шагыйрьне Моназыйрдан күбрәк белә иде. Ләкин үзенең бу очракта артта калуына пошынмады Моназыйр, бүгенге заман Тукайга бәйләнешле түгел, социализм хәзер, дип үзен тынычландырды. Бүгенге заманның кануннары үзгә, әнә шул кануннарны белү кирәк ягъни.

Төрле эшләрдә йөрде Ниса, җитәкче хатыны булуына иркәләнеп эшкә чыкмыйча калмады, һәр елны кыш уртасында Пенза ягына кайтып-барып килделәр, ире ык-мык торса, балаларын алыр иде дә юлга чыгар иде. Моназыйрга ялынмады. Хәзер дә шулай. Ә җәен сабан туена Нисаның туганнарыннан берсе булса да килә. Туган ягы белән элемтәне өзми Таукаш килене Ниса. Шунысы сәер менә: авыл халкы Гөлнисаны Таукашка килен итеп кабул итсә дә, аның ире Моназыйрны хәзер дә Таукаш кешесе итеп санамый. Аңлавы кыен моны. Кешеләр Нисадан Моназыйрның хәлен белешмәделәр, Моназыйр алдында Нисаның исемен телгә алсалар, бу аларга Таукашка ерак Пенза якларыннан килен булып төшкән Хәйрелбәшәрнең исемен таплау булыр кебек иде.

Нисаны изеп яшәгәнме Моназыйр, әллә Моназыйрны Ниса беркайчан да санга сукмаганмы — билгесез иде болар. Ниса белән Моназыйрның үзара мөнәсәбәтенең нинди булуын осталардан эш эшләткәндә генә ачыклау да мөмкин түгел иде. Бүтән чакта аларның йортына аяк басучы сирәк иде, Ниса үзе авылдагы һәр өйне эченә кереп күрсә дә, авыл апаларын үзе нигәдер чакырмады. Әйе, аларның гаилә тормышы авылның күз алдында акмады.

...Моназыйр косыкны ачулана-сүгенә җыештырды. Моның барыбер үзенә калачагын — Ваһимны чакырып мунча идәне юарга мәҗбүр итеп булмаячагын, хатыны да җыештырмаячагын белә иде. Моназыйр үзе өенә нибарысы өч тапкыр исереп кайтты, өчесендә дә, ишегалдына чыгып җитә алмыйча, өйалдының эчке баскычын косып пычратты. Ниса эндәшмәде, юарга да ашыкмады, кипкән пычракны кырып чистартырга Моназыйрның үзенә калды.

Иренең Ваһим оста белән кайтуын тәрәзәдән күргән иде Ниса, өйгә керәләрдер, дип, йолкып бетермәгән казны ләгәне белән мич артына куйган иде. Моназыйр калган коймакны эндәшмичә генә алып чыгып киткәч, тәрәзә яктысына кире күченеп, каз йолкуын дәвам итте. Ваһим останың кече капканы төбенәчә ачык калдырып китеп баруын күргәч, аның ире белән ачуланышуын абайлап алды, Моназыйрның, авыз эченнән мыгырданып, диванга сузылып ятуы да ике арада сүзнең кәеф бозардае булуына дәлил иде. Ниса казларны агач келәткә терәп салынган кирпеч сарайга чыгарып урнаштырды. Шуннан соң гына иренә:

— Сиңа әйтәм, Казанга барасыңмы әллә соң? — дип сүз кушты.— Балаларны әйтәм, каздан яңа шәбендә үк авыз итәр-

ләр иде. Бик һәйбәтләп симергән казларыбыз. Хәзер үк китсәң, иртүк әйләнеп тә кайтырсың. Казан ерак ара түгел.

— Ничек барыйм ди мин бүген?! — дип әйләнеп ятты Моназыйр.

— Ничек барасың — утырасың да барасың. Автобуслар авыл башыннан үтә.

— Эш көне бүген.

— Диванда аунап ятканчы, диюем иде. Балаларга сый тәме белән ирешсен, дим. Туктале, сау-сәламәт килеш нигә сырхауга әйләнеп барасың әле син? Тор соң, әнә, чәй эч тә лапас авызын капла. Шуңа дип алган такталарың аркылы-торкылы ята. Йә эшеңә бар.

— Эшкәме?.. Рәислектән төшерергә җыеналар. Өй каравылчысы булып китмәгәем әле.

— Сине чыгаралармы?! — дип гаҗәпләнде Ниса. Ул моны каты ук кычкырып әйтте, ә йөзеннән елмаю чаткысы күренеп узды.— Ай-һай ла, чыгара алырлармы икән сине, җитәкче эшкә тумышыңнан бирелгән кешене. Ваһим картка сине постыңнан төшерү кирәкме? Аңа авыл советы әллә бар, әллә юк — балта тотуыннан бүтәнне белмидер лә ул.

— Ничек кенә белә икән әле! Әллә кайчангыларны казып чыгармакчы абзаң! Сәрвияне син утырттың, дип тә бәйләнмәкче.

— Нигә мескенләндең әле? — дип кинәт усалланды Ниса.— Дөресне әйтү бәйләнү була диме?

— Нәрсәсе дөрес?!

— Сәрвия апаны утыртуың соң. Әллә авылда шуны белмәгәннәрдер дисеңме? Белмәгәннәр ди сиңа! Кулыңның гарипләнүе дә Сәрвия апа трактор тимере белән сукканнан соң бит синең.

— Нәрсә-ә?!

Диваннан сикереп үк торды Моназыйр, хәтта хатынына ташланмакчы булды. Ләкин Нисаны мондый кизәнүләр белән генә өркетеп туктатырга мөмкин түгеллеген онытып җибәргән икән ул. Ниса, кинәттән ачылып, тезәргә керешде:

— Нәрсә дә нәрсә! Сәрвия апа төрмәдән кайтып, тракторда эшләгән вакытны хәтерлә әле! Тракторны төзәткәндә, басуда, алга иелгән Сәрвия апаны, үзең төрмәгә утырткан Сәрвия апаны, арттан килеп көчләмәкче булган син түгелме соң? Айгыр булган Моназыйрың! Сәрвия апа кулыңа шунда тимер белән тондырган бит инде. Ат дулап, тарантастан егылдым, дип, мине гомер буена алдап йөрисең.

Акланырга сүз тапмады Моназыйр, уфылдап кына куйды.

— Шулай ул, Моназыйр, тормыш дигәнең. Кылганнарыңа җавап бирмичә, тамталга качып китә алмыйсың. Хәтта җәһәннәм капкасын ачмыйлар икән гөнаһыннан ваз кичмәүчеләргә. Замана үзгә хәзер, акны төгәл аерыр чак җитте. Сине халык үз алдына бастырасын көтеп йөри идем мин, ә син шушы хөкем килерен көтмәдең. Сәрвия апаны гасый ясамакчы булган икән-

сең, айгыр булып атланмакчы булгансың. Гөнаһ җыюдан тыелырга көче җиткән Сәрвия апаның!

— Гөнаһсыз Сәрвия...— дип мыскыллап кыстырды Моназыйр.— Бердәнбер баласы Тимершасын уйнаштан тапты синең гасыйсыз Сәрвияң!

— Тапсын! — дип кычкырды Ниса.— Гомеренә ялгыз калырга тиеш идеме ул? Сугыштан егетләр кайтмагач, ир күрмичә, бала үстермичә калырга тиеш идеме? Ул да дөньяга бер генә килгән. Тудырган Тимершасын, беркемнән дә ярдәм таләп итмичә үстергән. Хәзер, әнә, нинди игелекле гаилә башында тора Тимерша.

— Игелекле... Шул Тимершаның кызы Рәйсә һәм малае Галияр белән ачуланышып бозылды минем бүген кәеф! Аннары Ваһимы...

— Галиярмы? — сискәнеп бүлдерде ирен Ниса.— Кайтканмы? И-и, рәхмәт төшкере, исән-сау кайткан икән балакай! Әфганстаннан исән кайту бәхет инде ул.

— Исәнлеге әле...

— Син моннан соң Сәрвия апа нәселенә тел-теш тидерәсе булма! Таукашта иң изге кешеләрнең берсе әле ул Сәрвия апа. Тимершаны табып дөрес иткән. Менә мин дә синнән ике малай белән ике кыз таптым. Әмма үземне Сәрвия апа белән бер күрәм. Чөнки син балаларга ата була белмәдең. Менә шулай, Моназыйр, без ят кешеләр булып гомер иттек. Сәрвия апа дәрәҗәсеннән без түбән, сугыштан соң ир чыкмаячак заманда аның бала табуы гөнаһ түгелдер, синең белән мин зуррак гасыйлар.

— Телеңне тый, дим! Чалуга мәтәлеп барасың бит!

— Мәтәлмәм! Мәтәлсәм дә, торып юлга менәрмен. Чалуга төшү таудан тәгәрәү түгел. Әле күптән түгел генә тау башында күренә идең. Мин сине, гөнаһларын чиста карда юар өчен, тәгәрәп төшәргә менде микән әллә, дип шиккә дә калган идем. Кирәкмәс эшләрең күп булды синең, Моназыйр. Шундый эшләреңне өйдә дә хисапсыз кылдың бит инде. Мин түздем. Тормышка кагылган чөй кебек булып тоеласың син кайчакта. Үзең дә кирәкмәскә чөй кагу гадәтеңне гел куасың. Йә, мунча матчасына кем тырма теше кагып куя ди инде?! Кирәкмәс төшкә. Шулай да үз тәнеңне чебен тешләгән хәтле дә авырттырасы түгел син. Таудан тәгәрәмәдең, тәнең авыртудан курыктың.

— Көлмә!

— Көлмим. Тормыштан тәгәрәүне таудан тәгәрәү белән алыштыра алырсыңмы икән тик? Булмас шул, булмас. Тауга менгәндә адымнарың мескен иде, сыерның беренче бозавы — сараяк бозау адымы кебек иде атлауларың. Төшкәндә, чонтык эткә охшатасым килде сине. Чонтыкның нәрсә икәнен беләсеңме? Койрыгы киселгән хайванга чонтык, диләр.

— Мин хайванмы?!

— Түгел! Хайван булсаң, куркуыңнан койрыгыңны кысар

иден, тумыштан койрыксыз булмасаң. Ерткыч син! Озын койрыклы ерткыч чонтык, эт түгел!

Тышкы кыяфәте белән Таукашта иң күркәм һәм мәһабәт йортның хуҗасы үзен башкалардан күбрәк белүче кеше — хатыны чыгарган хөкем каршында көчсез иде. Ул үзен аратирә аңын югалткан кебек тойды, шундый чакта хатынының сүзе аның йөрәгенә тавышсыз гына барып кадалды, хатынына нигезле җавап оештырырга зиһене җитмәде.

— Алайса, нигә минем белән яшәдең соң син? — дип акрын гына әйтте Моназыйр. Бераз вакыт узды, Ниса эндәшмәде.— Нигә хәзер минем белән яшисең алайса?

Иренең мәсьәләне хәзерге заманга күчерүенә Ниса җавапсыз калмады.

— Яшим мин синең белән, яшим, ялгызымны калдырыр дип курыкма. Яшь чагым булса, өстәвенә хәзерге акылым булса, ике дә уйламыйча ташлап китәр идем. Хәзер нишли алам соң?! Таукаш кешеләренә һәм миңа син китергән хәсрәттән мине малайларым, кызларым, оныкларым булуы коткара. Сәрвия апага да Тимершасы һәм оныклары сугыш җәфаларын, синең кебекләрнең әшәкелеген оныттырып торадыр. Сугыш ир затын кыргач, Сәрвия апага Тимершасын табарга менә ни өчен кирәк булган. Ә сиңа, Моназыйр, бер генә чара кала: Таукаш кешеләреннән гафу үтен син. Гафу итсәләр, калган гомереңне кешечә яшәрсең, ичмасам. Мине, балаларыңның анасын, гомер ахырында булса да кешегә санарсың, ичмасам. Син бит миңа моңарчы чүре итеп карадың, үземнең дә сиңа хезмәтче булудан, служанка булудан котылырга көчем җитмәде. Хәзер генә мин синнән аерылып китә алмыйм инде, соңладым, бик тә соңладым. Син үзгәрсәң, күпмедер гомер — берничә ай гына булса да! — рәхәтләнеп яшәп калыр идек. Башкалар гафу итсә, мин гафу итәм сине, Моназыйр! Алар гафу иткәнче үк гафу итәм мин сине, Моназыйр... Ирем бит син минем. Сора, башлап Сәрвияападан гафу сора. Фани дөньяныкы монда калсын, диген. «Галиябану» көен башка көйгә кушып сөйләгәнең өчен мин утырттым сине, диген...

Моназыйр калтыранып башын күтәрде, Нисага карап торды, хатынының күзләрендә ялвару да, үз итү дә сизелә иде.

— Кем каршында гаебең булса, аның алдына тезлән, гафу сора. Синнән җәфа чигүчеләрнең мәрхүмнәре дә бар. Зиратка кер дә аларның каберләрен үп. Тик берсенең каберен таба алмассың. Рухан хәзрәтне әйтәм. Аның утыртылуына син гаепле булган, аның бер сүзен тиешсез урында кабатлагансың. Монысын әле син явызлыктан да эшләмәгәнсеңдер, аңышмыйча әйткәнсеңдер, аңышсаң да, малайлык акылсызлыгы булгандыр анысы. Рухан хәзрәт сиңа ачу тотмаган бит, сине балалыктан ялгышкан, дигән. Сәрвия апа Рухан хәзрәт белән сөргендә очрашкан бит... Моназыйр, дим, тауның кашында түгел бит синең урының, авыл кешеләре каршына чык та тезлән, башыңны

иеп тезлән! Бүген җае да чыгып тора бит, клубта Галиярны каршылау кичәсе булачак бит инде... Үтенәм синнән, Моназыйр, үтенәм... Бәхетнең нәрсә икәнлеген мин дә татыймчы!..

Шуннан соң алар сәгать чамасы бер-берсе белән сөйләшмәделәр. Моназыйр түр өйдә диванда кузгалмыйча утырды, Ниса, тынычлана төшеп, йорт эшләрен караштырды, аяк өсте генә өзә-төтә бер чокыр чәй эчеп алды, ирен чәйгә чакырмады, ирендә чәй кайгысы юклыгын белә иде.

— Әйдә, Казанга бергә барып кайтыйк,— дип, түр өйгә керде Ниса.— Әйдә, чыннан да! Мал-туарны карарга күршеләргә әйтәм. Казанга тагын өч автобус узасы бит әле бүген. Кайсысына чыксак та, юлда бастырып калдырмаслар. Оныкларымны бик сагындым. Син дә сагынгансыңдыр ич инде... И-и сөенешерләр соң, безне бергә күргәч!

Ләкин Моназыйр башын чайкады.

— Алайса, мин үзем генә барып кайтам. Яме, дим, Моназыйр?

Ире акрын гына баш какты.

— Пешкән ризыклар бар, яме. Кучтәначне яңа шәбендә тапшырыйм, дим. Балалар сөенсеннәр әле. Син инде мин әйткәннәрнең кайберләрен оныт та, яме. Дуамалланыбрак киттем шул. Хатын-кызның акылы инде тагын, аның барлык сүзен колакка алырга да ярамый. Илеңне сатмадың син. Илен сатучылар да булды болганчык заманнарда. Синең күңелең яхшы да була белә. Шулай булмаса, сине гомерең буе җитәкче эшләрдә тотмаслар да иде. Балаларга синнән сәлам әйтермен, яме. Кайтып йөрергә җыенмасыннар, шимбә-якшәмбегә әтиегез үзе килә, диярмен. Сиңа да тынычлык кирәк инде, ал юк, ял юк, авыл да колхоз, колхоз да авыл. Ерак сәфәрең — район үзәге, бөтенләй дөнья күргәнең юк. Җитәр монда сөрсеп яту, курортта ял итәргә сиңа да тиештер. Иң шәп курортка, кыйммәтлесенә бар. Ә-ә, аннары ни дип уйлап торам әле, автобуска чыгышлый, юл уңаеннан, дим, Галияр белән күрешеп китәрмен дигән идем. Сәрвия апаның да хәлен белешүем булыр. Кичә очрашкан идек әле аның белән очрашуын. Әйдә, ярар, авылдашларыңның хәлен еш белешү әйбәт ул. Карале, Моназыйр, дим, Галиярны каршылау кичәсенә чыкканчы, мичкә ягып ал, яме. Торбалар суынып беткәнче, дим. Төнлә үзеңә салкын булмасын. Газ плитәңне яндырган килеш калдыра күрмә. Тагын нәрсәләр әйтәсем бар икән соң? Бетте бугай. Әй-й, син бала түгел сәнә, кулыңнан эш килмәсә икән. Такылдадым тәмамысы. Ярар, әйбәт кенә тор. Иртәгә иртүк кайтып җитәм мин, яме.

Моназыйр, хатыны сүзләренә ризалашып, тагын башын кагып утырып калды. Ялгызлык баса башлагач, бүлмәдән бүлмәгә йөренде. Кинәт башына тау башына тагын менеп төшәргәме әллә дигән уй килде.

...Нәрсә ди хатын, сараяк та чонтык, диме? Әйтеп кенә бетермәде, менгәндә дә, төшкәндә дә бозау идең син, дияргә бул-

гандыр исәбе. Менгәндә — яңа туган бозау, төшкәндә — койрыгы киселгән бозау. Барыбер бозау. Моназыйр тилгән икән, бозау икән. Тилгән кушаматы ярасын да ди әле, ә бозавы нигә ди миңа? Кешегә кайчан һәм ни өчен бозау диләр инде? Үзен яклый алмаганда һәм башка очракта җебеп төшкәндәме? Юк, хатын минем таудан төшүне эт төшүенә тиңләмәкче булган, төшкәндә дә мине бозау итеп күрсә, турыдан ярып салыр иде моны Хәйрелбәшәр. Туктале, ул бит мине чонтык эт итеп күрергә теләгән генә, ә күрүен бозау итеп, аның да сараягы итеп күргән була түгелме соң? Начар ният тән әйтмәде бугай ла боларны Ниса... минем Гөлниса... Хәйрелбәшәрем... Алай...

Гомереӊ буена кеше сүзен кирегә борырга гадәтләнгәч, бу гадәтне тиз генә онытуы кыендыр шул. Моны бары тик көчле кешеләр генә кыла аладыр. Үз хатасын төзәтергә көче җиткән дошманың хәтта хөрмәткә лаеклы. Моназыйр ирештергән сүзләрне Рухан хәзрәт аңа мәчет манарасын төшергән көнне икенче мәртәбә очрашу вакытында әйткән иде. Хәзрәтнең «авылның башын кисү» турындагы сүзләрен онытмаган Моназыйр, ә хата төзәтү турындагы хикмәтле фикерен исендә тотамы икән Тилг... тфү! Шәгаетов!

Моназыйр бусагада туктап калды һәм, каты ук кычкырып, ишек яңагына:

— Бозаумы?! Минме?! — дип китереп сукты.— Бозауны күрсәтим соң мин сезгә!

Ул, кабаланып, сугым пычагын алды, өстенә дә кимичә, ашыгып, өйдән чыгып, абзарга керде дә майда туган коба бозауны бакчага сөйрәде, аякларын бәйләп, җилтерәтеп екты, муенына пычак та салды.

Шул чакта хатыны тавышы ишетелде:

— Моназыйр, дим, сиңа әйтәсе сүзем калган икән. Моназыйр, кайда соң син? Өй ишеген ябарга оныткансың. Моназыйр, ашыгам бит. Әле минем Сәрвия апаларга да керәсем бар...

Гөлниса-Хәйрелбәшәр, абзар артында чалынган бозауны һәм кан тамып торган пычак тоткан Моназыйрны күреп, өнен югалтты. Озак торгач кына аның күз алдыннан томан таралды.

— Кеше түгелсең икән...— дип сузды Гөлниса.— Мин бит бу бозауны сәдака итеп бирергә ниятләгән идем. Сәрвия апага... Рухан хәзрәт синең гөнаһларыңны кичерсен өчен... Шуны әйтеп, сине сөендерергә кире борылган идем...

Моназыйр тезләнгән җиреннән торды, пычактагы канны чүсинкә кунычына каты ышкып сөртте, хатынына таба сүзсез генә атлады. Гөлниса-Хәйрелбәшәр урыныннан кузгалмады.

— Минем хатын сәдака өләшмәячәк! Сәрвиягә сәдака бирә, имеш! Әнә бозавың — каргаларга сәдака! Мин беркемнән дә гафу үтенмәячәкмен! Мин бозау түгел!..

Хатыны янына җитмичә туктады Моназыйр. Гөлниса баскан урынында каткан кебек тора бирде.

— Әйтәм аны соңгы вакытта дингә авыша башладың, Сәрвиягә сәдака бирү икән ниятең! — дип тагын кызды Моназыйр.— Минем хатын диндар булмакчы, әй! Ачуымны кабартсаң, сугымлыкка дигән үгезне дә хәзер үк чалып ташлыйм!

Гөлнисаның аңына Моназыйрның сүзләре әллә барып җитмәде, әллә ире булган кешенең тагын да зуррак әшәкелек эшләвен теләмәде, акрын гына борылды да:

— Мин киттем,— диде.

## 6

Төшке ашка бөтен гаилә җыелып алды. Сәрвия дә фермадан кире менде. Рәйсә, ни кыстаса да, Тәнвирәне генә чәйгә алып кайта алмады.

— Никахлашмыйча сезгә керсәм, оятын кая куярмын, Рәйсә сеңелкәем,— дип төпле акланды Тәнвирә.

Мәҗлескә тиң бу түгәрәк табын Галияр хөрмәтенә булды. Бүтән көннәрдә табын оешып җитми, кайсы кайта, кайсы китә тора иде. Галиярның әтисе һәм әнисе, Рәйсә, шау-гөр килгән табыннан соң, фермага ашыктылар. Тагын ике энесе һәм ике сеңлесе, Галиярны төрле сораулар белән тинтерәтеп бетергәч һәм солдат хәлләрен күпләп белеп алгач, таралышып беттеләр, кайсы әти-әнисенә булышырга фермага китте, кайсы уенга тайды. Галияр, әбисе белән икәве генә калып, бабасы турында четерекле сөйләшү башларга торганда, Ниса килеп керде. Ул, керешенә үк, солдат Галияр белән исәнләшмәстән, Сәрвияне кочаклап алды, карчыкны кочагында тоткан кыска гына арада күзләреннән яшьләр дә тамды, өйне яңгыратып кычкырып көлде дә Ниса. Сәрвияне кочагыннан ычкындырганда:

— И-и әйбәт кеше лә син, Сәрвия апакаем! — дип, карчыкның сөякләрен шыгырдатып, күкрәгенә тагын кысты. Аннары: — Исәнсау гына кайттыңмы, Галияр энекәем! — дип егеткә барып сарылды.

Озак юанмады Ниса, плюш курткасының изүен чишеп, мамык шәлен җилкәсенә төшереп, бераз гына утырды, дога кылды. Шуннан соң:

— Сәрвия апа, әйдә, капкагача озатчы,— дип чакырды.— Казанга барырга исәпләп чыктым бит, автобуска соңламагаем, дим.

Өйалдында калдырган ике зур төенчеген, тоташтырып бәйләп, җилкәсе аркылы салды да бүтән сүз әйтмичә китеп барды. Сәрвиянең:

— Юлың уң булсын, бәла-казасыз йөреп кайт,— дигән сүзләренә бөтенләй игътибар итмәде.

Нисаны озатып кергәч, Сәрвия:

— Әллә... Әллә инде... Әллә ничек...— дип фикерен әйтерәйтмәс торды.

Галияр, әбисенең нәрсәгә ишарәләвен сизенеп:

— Нигә шулай тәэсирләнгән икән Ниса апа? — дип гаҗәпләнде.

— И-и Галияр улыкаем, Ходай түземлеген бирсен инде Ниса апаңа! Үз хәлен үзе генә беләдер Хәйрелбәшәркәй,— дип, Ниса-Гөлнисаны кушаматы белән атады Сәрвия.— Түзем дә җан икән. Елгасыз төштә күпер салучы кеше белән гомер итүләре җиңел булмагандыр, җиңел түгелдер Гөлниса апаңа. Шөкер, балалары игелекле. Тик үзе янында торып калмадылар шул.— Сәрвия балаларның әйбәт булуын ана кешегә генә бәйләде.— Атнасына бер булса да балалары янына бара, мескенкәем. Балалары сирәк кайталар, шуның сәбәбен кешеләргә сиздерәсе килми Ниса апаңның.

— Балалары да балалары, дисең, ул балаларның атасы да бар бит әле, Моназыйр абый катылап әйтсә, эшкә дә моннан йөрерләр балалары! Нибуч! Казан ерак түгел! Ата-ана сүзеннән чыгып булмый ул.

— Әнә шул ата ягыннан балаларның ятим икәнлекләрен сиздерәсе килми инде Ниса апаңның.

— Һе, Моназыйр балалары әтисезме?! Ятимнәр икән! Тамаклары тук булды, теләгән киемнәрен киделәр Моназыйр балалары, ике малае институтта укыды, ике кызы техникум бетерде.

— Ялгышма, Галияр улым, болары — Хәйрелбәшәр тырышлыгыннан.

— Белмим шул,— дип икеләнде Галияр.— Моназыйр абзаң гаиләне бай тотмаса...

— Белмисең, аңламыйсың икән, карышма! — дип бүлдерде оныгын Сәрвия.— Чүпрәктәме соң байлык?.. Елан белән үбешергә әзер кеше янәшәсендә гомер итә Ниса апаң.

— Шулай да Моназыйрның балалары ятим түгел. Безнең менә әти ятим үскән. Ятимлек монысы.

— Нәрсә?!

Әтисенең әтисе турында әбисе белән сөйләшүне үзенчә алдан әзерләп, әбисенең хәтерен калдырмаслык итеп башларга уйлаган иде Галияр, әмма бу хәбәренең башы Сәрвия карчыкның Моназыйр кыланышларына гасабиланган чагында теленнән ычкынды. Галияр, иренен тешләп, кулларын буташтырабуташтыра йөренде. Сәрвия, ябык йодрыкларын йомарлап, торaташ басып торды.

— Нәрсә дидең син?! — дип ачуланды Сәрвия бераздан, һәм ишекле-түрле йөренгән Галиярны беләгеннән тотып туктатты.— Телеңне тыя бел! Әтиеңне тапкан өчен миңа Мостафа бабаңның да кинаяле сүз әйткәне булмады! Гомер үткәч, син авыз ачып маташасың! Сугыштан соң безнең Таукашта немец әсирләре...— диде дә, сүзеннән капылт туктап, оныгының җиңен ычкындырды карчык.

Галияр өстәл башындагы урындыкка утырды, бармакларын клеенканың шакмаклы бизәкләре өстеннән ашыгып йөртте. Сәрвия оныгына текәлеп карый, аның көтелмәгән сүз әйтергә җыенуын сизенә иде.

— Ачуланмыйча тор әле, әби,— диде Галияр, өстәлгә иелебрәк төште, шакмакларны ышкуыннан туктамады.— Мин госпитальдә ятканда,— дип, гәүдәсен турайтты ул һәм әбисенә туры карады,— төш күргән идем. Төш, дип үк әйтеп тә булмыйдыр аны. Үлем белән тартышкандагы саташу булды ул. Нигәдер инде шул чакта бабамның кем булуын беләсем килде. Кем минем бабай?!

Ләкин Сәрвиянең күңел серен оныгының үлем хәлендә яткандагы теләге дә ачтыра алмады. Бу серне берәүгә дә әйтмәскә дигән карары катгый булган икән.

— Мондый сүзләреңне башка кабатлыйсы булма,— дип тыныч кына әйтте Сәрвия.— Беркайчан да! Беркемгә дә! Кирәк санаса, әтиең моны миннән сорар. Мин аның алдында гына җаваплы! Белдеңме?! Тагын шуны бел — әбиең беркайчан да азып-тузып йөрмәде. Сугыш ирсез калдырды минем кебекләрне... Оныт бу теләгеңне! Мин кичерәм сине...

Сәрвия күзләрен куллары белән каплап утыручы Галиярның башыннан сыйпап узды.

## 7

Көннәрнең кыска чагы хәзер. Сәгать өчләр тирәсендә үк караңгы тиздән төшәчәген сиздерә башлый. Шушы вакыт җитәрәк, Таукашның көнбатыш ягында карасу-зәңгәр болытлар иләмсез зур таулар тезмәсе булып оештылар. Иртән Рәйсә күргән болыт-кыялардан болары аермалы иде, болары — авыр һәм хәрәкәтсез болытлар. Алар һич тә болыт түгел, ә чыннан да киртләч-киртләч һәм менәле-төшәле, күк гөмбәзенә җиткән җиңелмәс-ишелмәс таулар кебек. Тауларны, түбәләренә җан ияләре менә алмасын өчендер, исәпсез үткен кыялар каплап тора. Бәрхәдәрсез, шәфкатьсез кыялар...

Күңелгә уй килә: авыл инешенең төньягындагы тау да кайчандыр шундый мәрхәмәтсез кыялар белән капланган булгандыр кебек. Иртәнге якта Моназыйр тау кашында утырып торган таш та шул кыяларның берсенең калдыгыдыр сыман. Табигать, кешеләргә яшәү уңайлыклары тудыру өчен, бу тирәдәге кыяларны бетергәндер. Моның өчен күп гасырлар кирәк булгандыр. Табигать кешеләргә мәрхәмәтле ул: Таукашның көнбатышындагы кыя-болытларны, кешеләргә кәефләрен бозып тәэсир итсәләр, таркатыр да җибәрер. Болыт-кыяларны юкка чыгарырга, гәрчә алар коточкыч зур булсалар да, бер генә өрүе дә җитәр табигатьнең...

Эшендә төштән соң да озак булмады Моназыйр, күңелен-

нән белсә дә, авыл советына сайланган депутатлар исемлеген өстәл тартмасыннан бер алып, кире салып утыргач, колхозның хисапчылар бүлмәсенә максатсыз сугылгач, кайтырга җыенды.

Кыя-болытларны бинадан чыгуга күрде ул, имәнеп артка чигенде хәтта — баш түбәсенә кадалып аварга торгандай шул кыялар, әкәмәт. Аннары тау башындагы иртән үзе утырып торган ташка карады. Әллә шунда менеп төшәргәме соң, дип уйлады ул. Ниса киткәннән соң бу уй аның башына икенче тапкыр килде. Ниса һәм тау. Ни бәйләнеш бар соң әле монда? Әллә ире Моназыйрның тауга менүен, тауга менгәндә, Таукаш кешеләренә кылган начар гамәлләрен түбәндә калдырып, сараяк хәлсезлеге белән түгел, бәлки егетлек җитезлеге белән ашкынуын теләдеме Хәйрелбәшәр?.. Тау башына кабат менү теләге дә күңелендә генә калды Моназыйрның. Авыр кыяфәте белән үзен куркытып җибәргән кыя-болытларны да онытты инде ул...

Кибет алдында берничә кеше, Галиярны уртага алып, сөйләшеп торалар иде. Сәрвия карчык һәм Галиярның сеңлесе Рәйсә дә шунда. Рәйсә төркемнән читкәрәк баскан, кулына шактый зур төенчек тоткан иде. Моназыйр, төркемне күрүгә, урамның каршы ягына кыйгачлап чыкты. Кайтып җиткәч, урыс капканың ачылмый торган бүлемендәге эскәмиягә утырды. Кышны башлап кар төшкән көндә монда утыруы ялгыз өйгә керәсе килмәүдән түгел иде. Ялгызлыкны ярата ул, әгәр мөмкин булса, берәү белән дә сүз алышмас өчен көннең-көн буе япа-ялгызы гына калыр иде. Бүген эшкә кулы бармаганга, үзенә урын тапмаганга күрә монда утырды Моназыйр. Хәзер үзе генә каласы килсә, өенә керер иде дә ялгызлыкка чумар иде. Кешеләр аны үзләре яныннан бөтенләй җибәрмиләр дә, киереп ачылган кочакларына да алмыйлар. Кешеләр белән очрашмаска тырышып кайтты, инде монда, ичмасам, берәрсе, тукталып озаклап сөйләшмәсә дә, исәнләшеп узсын иде дип көтә. Кешеләр белән сөйләшүнең дә рәте-юне юк бүген. Иртәнге якта солдат Галияр синең урыныңа рәис булам, дип күңеленә шөбһә салды, унбиш яшьлек Рәйсә җавап тоттырмакчы булды, Ваһим оста йөзенә төкереп дигәндәй дулады, боларга өстәп, бергә гомер иткән хатыны Гөлниса-Ниса сараяк та чонтык турында искәртте.

— И-их,— дип тирән сулады Моназыйр,— карга ятып аунасаң икән хәзер! — Саташкан кешедәй үзалдына сөйләнә бирде ул.— Кары да юк, ичмасам! Иртәнге каргалар да коенырлык кар таба алмадылар...

Галияр кибет яныннан Сәрвия һәм Рәйсә белән бергә китте. Авылдашлары белән хәл-әхвәл белешеп торганда, Таукаш гөмбәзенең түбәсенә диярлек ашкан болыт-тауларны күргән иде ул. Хәзер, барган юлыннан борылып туктап, әбисенә һәм сеңлесенә еpoints кыяларны күрсәтте.

— Матур бит! — дип, кулын сузып, шул болыт тауларына

үрелде егет.— Яратам мин тауларны! Әфганстанда таулар күп, биекләр үзләре, төрлеләр, һәркайсының үз төсмере, матурлыкта үз байлыгы. Кыяларның иң биегенең очына менсәң икән!.. Хыял...

— Космоска оч та хыялыңны тормышка ашыр соң! — дип мәсьәләне ансат кына хәл итте Рәйсә.

— Юк, космоска оча алмыйм мин.

— Син, Рәйсә кызым, дөрес үк әйтмәдең, һәркемнең үз хыялы, үз кыясы...— диде Сәрвия, Галиярга күтәрелеп карап.— Шундыен да изге теләгең булгач, син аны беркайчан да онытма, улым,— дип өстәде.

— Хыяллар матур ла,— дип кабатлады Галияр.— Әфганстанда үзебезнең яклар кары сагындырды. Бүген Таукашта мин кайтасын белеп яуган кар.

Берәүләрне авыр булып күренеп имәндергән, икенчеләрне хыялга тарткан кыя-болытлар ишелеп таралыша инде. Караңгы төшеп җитә — ерактагы карлы кыялар ачык күренми башлады.

Сәрвиянең әтисе Мостафаның, сугыштан аяксыз кайткач, клубта авылдашлары — яшүсмерләр, хатын-кызлар һәм картлар белән әңгәмәсеннән башланган солдат каршылау кичәсенең матурлыгы аның җыелыш рәвешен алмавында иде. Мондый тантаналар бер-берсенә охшамыйлар. Чөнки һәр кичәнең хуҗасы төрле кеше була, ягъни солдаттан кайткан егет кичәне үзе алып бара.

Галияр, фойеның уртасына чыгып басып, тирәли тезелгән урындыкларга утырган авылдашларына башын иеп сәламен бирде, Әфганстан җирендәге хезмәте турында тәфсилләмәде.

— Хезмәттән мин бернәрсәне барыбер аңламыйча кайттым,— диде Галияр һәм Рәйсә белән янәшә утырган Тәнвирәнең бу сүзләрдән сискәнүен күрде.— Бернәрсәне аңламадым,— дип кабатлап дәвам итте солдат.— Кешеләрнең нигә сугышканлыкларын сугышта күреп тә аңламадым. Баскан җиребез барыбызга да уртак, күтәрелеп караган күгебез барыбызга да бер. Шулай булгач, омтылышыбыз да уртак — бер-беребезгә яхшылык теләү булырга тиеш иде. Алай түгел шул. Барлык-барлык халыклар үзара дус булсалар, гаскәр тоту да кирәк булмас иде, дим мин. Рәхәтләнеп эшләп, җырлап, уйнап та көлеп кенә яшәр идек ич! Әйдәгез, җырлыйк, биик! Әйлән-бәйлән уйныйк!

— Уртада башта син үзең каласың, сиңа җәза бирәбез! — дип уенын-чынын бергә әйтте кайсыдыр.

— Риза!

Җырлашып әйләнделәр.

— Нинди җәза бирәбез?!

— Җырласын!

— Әкият сөйләсен!

— Үзенең яратмаган кешесе булып күрсәтсен!

— Яраткан кешесе булып, диген, тиле!

— Акыллы баш! Галияр ничек Тәнвирә булып күрсәтсен ди инде?!

Уенга чакырып дөрес иткән Галияр: кичә, башлануына ук, шаян-күңелле юлга төште.

— Алайса, Галияр белән Тәнвирә парлап биесеннәр!

Галияр Рәйсәгә елышып баскан Тәнвирәнең каршысына барып, аны уртага чакырды. Алар парлы биюне мәктәптә бергә укыганда бишенче класстан ук бииләр иде. Шушы биюгә чыгарасыларын белептер, Тәнвирә чиккән кулъяулыкларын да алган булган икән. Җитәкләшеп, кулларын өскә күтәреп әйләнгәндә, кулъяулык Галияр кулына күчте, аңа алмашка Тәнвирә кулына бәләкәй тартма сеңде. Егет белән кызның бүләкләр алышуын сизүчеләр дә булгандыр, әмма алар моны сүз әйтеп бәяләмәделәр, Галияр белән Тәнвирәнең бәхетенә күңелләреннән сөенделәр. Шушы сөенечтәндер берсе:

— Тагын биесеннәр! — диде.

Җырга-биюгә Таукаш кешеләре кыстатамы соң инде! Бигрәк тә бүген — Әфганстан дәһшәтләреннән исән кайткан егет һәм аны каршылаучы кыз ялындырып торырлар диме! Баянчы солдат вальсын уйнап җибәрде.

— Сагындым! — дип пышылдады Галияр, аның иреннәре кызның чәчләренә тиеп китте.

— Сагындырдың!

Тәнвирә сул кулын егетнең җилкәсеннән аркасынарак төшерде, егетен кысып кочасы килде аның, әмма бу кадәресе әдәпсезлек буласын онытмады, тыелды. Шулай да аның кул хәрәкәтеннән егет аркасын җыерды, кыз моны егетнең кисәтүе дип аңлады һәм егетне аркасыннан йомшак кына сөеп куйды.

— Тәнвирә,— диде Галияр, һәм кыз аның йөзе чытыла баруын күрде.— Тәнвирә, кулыңны арканың ул төшеннән күчерче. Нәкъ яра өстенә бастың. Яра төзәлеп җитмәде әле. Мин бит госпитальдән чыктым гына әле.— Галияр инде үзе Тәнвирәне бармак очлары белән генә кешеләргә сиздермичә сөйде.— Төзәләчәк ул яра.

Кыз бию тизлеген кинәт киметте.

— Язмадың...

— Ачуланма, Тәнвирә.

— Ачуланмыйм да, белсәм, авырттырмаган булыр идем.

— Төзәлә ул! Исәнлек кадерле!

Галияр белән Тәнвирә вальс биегәндә, аларның сөйләшүе мәхәббәт сүзләреннән генә торуына шикләнүче булмады. Гел ярату сүзләре генә әйтелмәгән икән шул, күңелсезе дә булган. Ләкин Тәнвирә бу күңелсезлекне кичәдә катнашучыларга сиздермәскә тырышты. Рәйсә:

— Абый нигә йөзен чытып алды ул? — дип сорагач, күзләрен зур ачып, аңа текәлеп карап торды.

— Белмисеңме?

— Нәрсәне?

— И-и Рәйсә сеңелкәем, авылда мин белмәгән нәрсә юк, дип мактанган буласың тагын! — дип шаяруга борды Тәнвирә.— Соңыннан, яме, ашыкма.

Кичә үз җае белән бара бирде. Күмәкләшеп җырладылар-биеделәр дә, ял итеп, төркем-төркем бүленеп, әңгәмә дә корып алдылар. Хәтта өлкән яшьтәгеләр дә һөнәрләрен күрсәтте. Сәрвия карчыкны, элек оста биегәнен әйтеп, биергә чакырдылар, ул да, хәрәкәтләре җиңелдән булмаса да, уртадан бер әйләнеп керде. Ваһим оста сораганнарын да көтмәде, кулына тальян алды да, аркасын стенага терәп, башын горур күтәреп, борынгы көйләрне уйнады, көйләре агышына аякларын селкетеп булышты. Уйнап туктагач, түгәрәк бүреген маңгаенарак төшерде, пинжәге изүен төймәләде. Аның йөзе чиста-якты иде. Солдат Галияр яныннан чыгып киткәннән соң эчмәгән, күрәсең, мунча керенеп тә алган. Югыйсә тәнендә-рухында чисталык булмаса, бәрән тиресеннән тегелгән бүреген кими иде ул. Күңел ачуга катнашмыйча, аның барышын күзәтеп утыручы бер Моназыйр гына иде. Ләкин ул кичәгә кушылырга уңай вакыт кына көткән икән. Кешеләр инде арый-тала төшкәч, кайберәүләр китәргә җыена башлагач, аягүрә басты да көр тавыш белән:

— Галияр, нигә авылдашларыңнан хәлеңне яшерәсең? — дип кычкыру дәрәҗәсенә җитеп сорады.— Яраң турында да сөйлә, документка язылганны яшереп булмый. Үзең минем урынны алмакчы буласың, үзеңнең, документларыңны карап баксаң, бу эштә эшләрлек сәламәтлегең дә юк икән. Күрсәт яраңны! Минем урында эшли алмаячагыңа ышансын халык!

Бу хәтәр сүзләрдән соң кешеләр тынып калдылар, мондый әшәкелек аларны беравыкка өнсез итте.

Беренче булып Тимерша аңына килде. Ул, йодрыкларын йомарлап, Моназыйрга таба бара башлаган иде дә, юлына Сәрвия аркылы басып өлгерде.

— Пычранма, улым. Ничек хәл итәргә Галиярның үз акылы җитәр. Ярасы бар икәнен кайтып кереп күрешүенә үк сизенгән идем балакаемның...

Ваһим, тамак кырып, урыныннан томырылып торды да Моназыйрны, беләгеннән кысып тотып, ишеккә таба җилтерәтеп алып бара башлады. Әллә җен ачуы да кушылганга күрә, Ваһим остада, мондагылар арасында яше ягыннан иң өлкәне булса да, баһадир куәте бардыр кебек иде.

— Ваһим абзый, тукта! — дип кычкырды Галияр.— Мин чишенәм, күрсен яраны Шәгаетов!

Туктадылар, әмма Ваһим Моназыйрның беләгеннән кулын ычкындырмады.

Тәнвирә белән Рәйсә Галияр янында иделәр.

— Ниткән кеше мыскыл итү ди ул! — дип кычкырып җибәрде кайсыдыр.

— Сугыштан кайткан кешедән кара йөз ясамакчы Шәгаетов!

— Сөйгән кызы алдында егетне чишендермәкче була!

— Житте инде ул Шәгаетовка! Кеше канын эчеп яшәргә!

— Кан суырырга яра тапкан бит!

Тавышланунын мәхшәргә әйләнүе, каннары кызышкан кешеләрнең Моназыйр Шәгаетовка шушында ук хөкем ясап ташлаулары бик тә ихтимал иде.

— Жәмәгать, ашыкмыйк. Мине мыскылларга сәбәп юк.— Галияр кинәттән көлемсерәп җибәрде.— Миңа бит әле сезнең белән бергә яшисе һәм эшлисе, шулай булгач, мине бик яратканда, аркамның кай төшеннән сөймәскә кирәклеген сез белергә тиешсез бит.

Елмаюыннан туктамыйча, Галияр Тәнвирәгә текәлеп карады, сөйгәненнән рөхсәт соравы кебек иде аның бу карашы.

— Галияр, мин сиңа карамам, яме...— диде дә Тәнвирә, тамагына төер килеп, тукталып калды, очкылык тоткандай иткәч, күзләреннән яшьләр тәгәрәп төште.

Егет кителен салып этисенә бирде, ак күлмәген һәм майкасын чалбарыннан бергә чыгарды. Сулыш алу кыенлыгын Таукашка кайтканнан бирле, хәтта биегәндә дә сиздермәскә тырышкан Галиярга ике кулын да югары күтәреп күлмәк-майкасын салганда, калак сөяге астына пычак белән яңадан кадаган кебек булды.

Ваһим оста Моназыйрны һаман ычкындырмаган иде, ул аны ишеккә таба этте, Ваһим остага ике егет булышты. Шәгаетовны ишектән чыгарып җибәргәндә, егетләрнең берсе:

— Бу кыланмышың өчен сау-сәламәт тәнеңне кимендә унбиш тәүлек саф һавада тагын да чыныктырачаксың икән син, Шәгаетов иптәш,— дип кисәтте.

Клубтан Моназыйрны куып чыгаргач, Ваһим оста, башын әле як-якка, әле аска-өскә селкеп, Галияр янындагы төркемгә кушылды.

— Дөньяның кемнәре генә юк... Кирәкмәгәндә сөрән салып мөкиббән китәбез, кирәктә тиешлесен әйтүдән куркып авыз йомабыз,— дип аптырый иде ул.

...Солдат егетнең ярасына ике изге җан сулышларын өрәләр. Галияр, артына борылып карамыйча да, аларның кемнәр икәнлеген белеп тора: берсе — әнисе, икенчесе — Тәнвирә. Ана нәкъ шушы чакта — булачак килене белән, башны-башка куеп, малаеның ярасына өргән чакта — Галияр язмышын Тәнвирәгә тапшырды...

Таукашта беренче кар яуган көн шундый шатлыклар һәм ямьсезлекләр белән үтте.

## 8

Моназыйр Шәгаетовны йокы алмады. Өйдәге барлык утларны яндырып куйды. Нәрсәдер эшләргә кирәк иде, ләкин күңеленә канәгатьләнү китерерлек шөгыль тапмады. Төн уртасы узгач, өйалдына чыкты. Утны яндыргач, зур ләгәндәге эчбашны күреп, сискәнеп китте — башның акайган күзләре куркыныч иде. Бозауны каргаларга калдырмады ул. Тунап, итентиресен келәткә урнаштыргач, эч-башын монда кертүен оныткан да булган. Ләгәнне аягы белән тибәрде, һәм шул мәлдә башына бер уй килде — шикаять язарга кирәк ләбаса! Моназыйр шатлыгыннан кулларын уды, йөзенә елмаю җәелде, өйгә кереп кәгазь-каләм алганда да аның шатлыгы ташый иде әле. Яза башлагач кына юка иреннәре бөтенләй югалды, тешләре еш ашалды.

Беренче шикаять Ваһим оста өстеннән иде — Шәгаетовны җилтерәтеп йөртергә ни хакы бар аның? Бу шикаятькә Моназыйр имзасын салды. Икенче шикаятьтә авыл советы рәисен клубтан чыгарып җибәрергә булышучы ике егеткә пычрак атылды. Монысына имза куюны кирәк санамады Шәгаетов.

Инде яктырып та килә иде. Моназыйр ашык-пошык кына капкалады да эшенә китте. Мал-туарны карамады, Ниса карасын әнә, йөрмәсен авыл белән шәһәр арасында киләп сарып.

Ләкин хатыны Гөлниса өенә туры кайтмады. Сәгать уннар тирәсендә Сәрвияләргә атылып-бәрелеп керде ул. Курткасының өске төймәләре ычкындырылган, муены бөтенләй ачык, җилкәсенә төшкән мамык шәленең чуклары арадан ертылып зурайган, башын алга бәйләгән ак яулыгы гына кысып тора. Күзләре тонган кебек, җансыз кебек. Хәйрелбәшәрне Таукашта мондый юбалгы кыяфәттә күргәннәре юк иде, аның үзен җыймыйча йөргән чагы Таукаштан читтә дә булмады.

Иртән өлкәннәрен эшкә, кечкенәләрен мәктәпкә озатып, өйдә ялгызы калып (Галияр да фермага эшкә китте), берәр чынаяк чәй эчмәкче булып, самавыр яңартып йөри иде Сәрвия. Нисаның кыяфәтенә карап, аптырап калды ул. Хәйрелбәшәр исә төенчеген һәм сумкасын ишек катына атып бәрде дә Сәрвияне килеп кочаклады.

— Нишләвең бу, Ниса?

Ниса эндәшмәде, Сәрвияне күкрәгеннән аерып, аңа нәүмизләнеп карады да курткасын һәм шәлен салып идәнгә ташлады, өстәл башындагы артсыз урындыкка утырып, уфылдап сулады. Кинәт күлмәгенең изүен ике куллап тартты да шытырдатып аерып җибәрде.

— Сәрвия апа, матур әле мин, кызлар кебек әле мин, әйеме,— дип кабатлап сөйләнә-сөйләнә, шәрә имиләре белән уйнады.— Тагын кияүгә чыксам да була әле, әйеме. Сәрвия апа, бик тәмләп чәй эчәсем килә. Бал белән эчәбез, яме. Балың

бармы синең? Булмаса, тиз генә бездән алып мен. Олы келәттә ике тәпән тулы бал бар. Былтыргыдан калганын ун литр сыешлы ак кәстрүлгә тутырып куйган идем. Сәрвия апакаем, дим, моннан соң мин сездә торам, яме. Сәрвия апа, мин синең сүзеңне гел тыңлармын, нәрсә кушсаң, шуны эшләрмен, яме. Сәрвия апа, карале, бу безнең өй икән ич! Синең безгә бер дә кергәнең юк иде, ничек керәсе иттең әле? Мине сагыныптыр инде. Ни арада кайтып җиттем соң мин, үзем сезгә кермәкче идем ич. Рәхмәт яугыры, син үзең безгә килеп көтеп торгансың ич. Балаларым янына барып кайттым бит әле. Кичә сездән киттем, бүген сезгә кайттым менә. Туктале, сездә икән ич мин. Туктале, бардыммы соң мин балалар янына? Бардым шул. Сиңа сәлам әйттеләр, аерып әйттеләр. Хәзер мин сиңа шәһәр хәлләрен сөйлим, яме. Син минем балаларымның акыллылыгын белсәң, Сәрвия апа, дөньяда алардан да миһербанлы балалар юк та! Менәтерәк! Сәрвия апа, нигә чәй эчмибез инде?..

Сәрвия хәлне төшенә башлады, Нисаның кичәге сәер тәртибе дә сәбәпсез булмаган икән.

— Хәзер эчәбез, Гөлниса, хәзер! Киемнәреңне җыеп куйыйк та, баллап чәй эчәрбез. Өс киемен болай атып бәрү ярамый ич инде.

— Әй-й, кием нәрсәгә соң ул! — Ниса көлмәгән алдан акрынлап кына аерып чыгарды, тагын имиләре белән уйнады.— Шушы сул имиемне кызларым да, улларым да яратып имделәр, уңын күбрәк тешлиләр иде, сөте аз булгандыр шул инде.

— Гөлниса, олы кешегә табын янында болай утыру килешми. Менә бу халатны киеп куй. Өстеннән шушы фуфайкыны киярсең. Төймәлә. Туңгансың ич.

— Әллә тагын... Туңганмынмы?

— Син бит-кулларыңны сабынлап юып ал, мин чәй ясыйм, яме.

Чәйне ашыкмыйча һәм сөйләшмичә эчте Ниса. Аннары йокым килә, дип ятты, ләкин ярты сәгать чамасыннан сикереп торды, төзәтенеп киенде, чәчен тарап үрде. Сәрвия аны өенә илтеп куярга да, күрше-тирәдән берәрсен чакырыр өчен ялгызын калдырып чыгарга да курыкты. Ниса ара-тирә кызуланып сөйләде, карашын бер ноктага текәп, озаклап тын да утырды, ләкин Сәрвияне һич тә күзеннән ычкындырмады, ул түр өйгә керсә дә, аңа иярде.

— Сәрвия апа, Моназыйр синнән гафу үтенмәдеме? Мин аңа барысы-барысы өчен дә гафу үтенергә кушкан идем. Сиңа кул салмакчы булганы өчен дә гафу үтенер әле ул синнән. Нгытып әйттем мин аңа...

Мескенкәй Ниса, Галияр солдатны каршылау кичәсендә ире Моназыйрныңниләр кылануын белми иде шул. Әгәр хәзер Сәрвия аңа, Моназыйр миннән гафу үтенде, мин аны гафу иттем, дисә, Нисага акылы кайтыр иде сыман. Кешегә игелек эш-

ләү хакына мондый изге алдауга барыр да иде Сәрвия, ләкин Хәйрелбәшәр, әйбәт хәбәрдән кинәт сәламәтләнүгә үк, ире Моназыйрда үзгәреш булмавын күреп, тагын акылын җуяр һәм аның авыруы тагын да көчәер иде. Димәк, мондый алдау изге була алмый икән.

— Син, Гөлниса акыллым, дим, тынычлан,— дип, Нисаның соравына туры җавап кайтармады Сәрвия.— Бернәрсә турында да уйлама син. Хәзер, шөкер, тормышыбыз әйбәт — шуңа сөен. Ял ит син, ял ит. Бигрәк аз йокладың бит. Арыгансыңдыр.

— Арыганмынмы?..

Нисаның хәле турында Моназыйрга Сәрвия төш турында үзе барып әйтсә дә, Шәгаетов хатынын алырга килмәде. Галияр шәһәргә Гөлниса балаларына телефоннан шалтыратты. Олы кызы һәм кияве, тагын өч баласы караңгы төшкәнче кайтып та җиттеләр, Сәрвияләргә тукталдылар. Моназыйр янына кияве машина белән генә төшеп менде. Ике арада нинди сөйләшү булуын ул туганнарына гына әйтте. Нисаның кичә Казанга бармавы балалары ашыгып кайтканнан соң ачыкланды. Төнне кайда уздыруын Ниса үзе генә белгәндер. Бәлки, аңы кайткан чакларда да моны хәтеренә төшерә алмагандыр.

Балалары аны танылган врачларга күрсәттеләр, врачлар безнең шифаханәдәге хәлләр аңа кире тәэсир итүе мөмкин, өйдә үзегез карау әйбәтрәк булыр, авыруның башлангычы гына, теләгенә каршы килмәгез кебек киңәшләр генә бирделәр. Олы кызы белән киявендә торды Ниса, тынычланды, авыруы узар да кебек иде. Таукашка кайтасы килсә, олы кызы-киявенең үз машиналары иде. Ләкин Ниса һәр кайтуында Сәрвияләрдә тукталды, үз йортлары уңаена адым да атламады. Ирен күргәне булмады, Моназыйр үзе дә Сәрвияләргә аяк басмады. Сәрвия белән фермага булышырга төшеп йөрде Гөлниса. Гаиләдә аны чит итмәделәр, кызгандылар. Җиңеләюе кабатлана башлаганда, Ниса Сәрвиянең куенына каз бәбкәсе әнисе канаты астына тырыша-тырыша кергән кебек сыена. Мондый чакларда балалары юнәтеп биргән даруны шул мәлдә үк эчертүнең бераз файдасы тия. Тавышын күтәрми, элеккедән бик акрын һәм күбесенчә Сәрвия белән икәве калгач кына сөйләшә. Үз хәлен аңлый да Хәйрелбәшәр.

Беркөнне фермага төшеп барганда:

— Имгәк булдым инде мин сезгә, Сәрвия апа,— дип әйтеп куйды ул.

— Нигә юкка борчыласың инде, Хәйрелбәшәр!

— Хәйрелбәшәр?! — дип елмайды Ниса.

— Ошатмадың мәллә?

— Ошаттым. Үземә үзем таккан кушамат бит.

— Их, балакай, балакай, әнә шул үзеңә үзең исем кушкан чактагыча гел шар ярып йөрисең калган икән! Ә син барысын да эчеңә җыйгансың да җыйгансың. Онытырга тырыш син үт-

кәннәрне. Безгә борчу ясыйм дип тә хафаланма. Син мине иң якының итеп ихласыңнан санагач, менә ирењә карата күңелемдәге төерләр эри башладылар. Күңелеңдә төерләр булган килеш яшәве дә кыен бит, Гөлниса.

Хәтсез ара сүзсез барганнан соң, Ниса:

— Нигә Рухан хәзрәт турында сөйләмисең? — дип сорады.— Аның язмышында да Моназыйрның катнашы булуын әйткән идең. Мин ул кешене ишетеп кенә беләм бит. Син аны тегендә очраткансың бит. Ә хәзрәтнең сөргендәге тормышы турында авылда берәүгә дә тулылап сөйләмәгәнсең. Миңа шул хакта сөйлә әле, синең сөйләгәннәреңне беркемгә дә әйтмәм, Сәрвия апа. Валлаһи менә! Антлар итәм!

— Кирәкмәс, ул заманны бөтенләй дә искә төшерәсем килми. Әйтәм ич, күңелем эреп тә бара инде. Хәтерләүләр кирәкмәс бу очракта.

— Кирәк, миңа кирәк, Сәрвия апа! — дип ялварды Ниса.— Килен булып килгәч, Моназыйрның шундый начар гадәтен белеп, бер тапкыр аңгырая язган идем инде. Мин аны тыярга тырыштым. Тик тыя алмадым. Моназыйр әшәкелек эшләгән кешеләрнең барысыннан да аның өчен үзем гафу үтенермен, мәрхүмнәренең каберләренә барып егылырмын! Сөйлә, Сәрвия апакаем. Рухан хәзрәтне һәм үзеңне ничек рәнҗеткәннәрен сөйлә! Боларны мин белмим бит, болары мин килгәнче булган.

— Аның нәрсәсен сөйлисең инде, Ниса сеңлем!..

— Сөйлә, яме, Сәрвия апа. Мин авыру түгел хәзер, синең сөйләгәннәреңне мин ялгыш ишетмәм. Миңа белергә кирәк, Сәрвия апа! Аңла хәлләремне!..

Рухан хәзрәткә утыз сигезенче елда, мәчет манарасын төшерүдән соң ике ай чамасы вакыт узгач, авылда социализм төзүгә каршы актив көрәш алып баруда гаепләп, ун ел сөрген җәзасы бирделәр. Гаиләсен ел азагында җибәрделәр, явыз сәяси дошманның карчыгына һәм балаларына Таукаш авылында урын юк икән, алар монда яшәргә хокуксыз икән. Хәзрәтнең гаиләсенә Казахстан далаларына гына барып урнашу рөхсәт ителгән, дип сөйләделәр. Ләкин шуның дөреслеген төгәл белүче булмады. Руханның үзен Себергә сөрделәр. Алтмыш яшьлек карт урман кисүдә әллә ни майтара алмаган булыр һәм тиз бетеренер иде, ярый әле, аның бәхетенә, ул яшәячәк авылда аңа кулай эш табыла. Мәктәпкә парта-эскәмияләр, башка кирәк-яраклар ясарга билгелиләр аны, кайсыдыр начальникның миһербанлы чагы булган инде. Бәлки, бу картның, урман эченә кертмәсәң дә, күп яшисе калмаган, дип уйлаганнардыр. Әмма аяк сузмый Рухан хәзрәт, кем әйтмешли, нык тамырлардан икән. Сөрген срогын исән-имин тутыра ул, тик менә Таукашка кайтарып җибәрергә ашыкмыйлар. Шуның сәбәбен белмәкче булгач, сөргендәге кешеләргә күзәтчелек итүче:

— Нәрсә, мулла әфәнде, авылыңа кайтып, тагын корткычлык алып бармакчы буласыңмы? — дип рәнҗетә.

Эндәшмичә чыгып китә Рухан, шулай да, чыгуга, кире керә.

— Туган туфракка кайтып гүр иясе буласы иде,— ди.

— Барыбер түгелме?! Монда сират күперен кичүе җиңелрәк дигән хәбәрләр алабыз теге дөньядан! — дип көлә күзәтчелек итүче.— Шуңа күрә кабер казырга заказыңны бирә тор.

Күзәтчелек итүче монысы белән бигрәк тә рәнҗетә. Әмма нишли аласың?

Рухан кайтып китәсе кырык сигезенче елда монда үзе кебек өч иптәше белән Сәрвияне китерәләр. Сәрвия фатирга урнашып, хуҗалар аның татар кешесе икәнлеген белгәч, авылда бер татар карты яшәвен әйтәләр. Әйберләрен урнаштырып та тормый Сәрвия, шул карт янына йөгерә.

— Син, сеңлем, Мостафа кызы буласың түгелме соң? — дип танып ала Рухан карт.— Исемеңне Сәрвия дип кушкан кебек хәтерлим.

Башта тыела алмыйча елый Сәрвия, аның елавына чит-ят җирдә авылдашын очрату шатлыгы да, гаепсезгә сөрелүенә нәфрәте дә кушыла.

— Нинди гаеп тактылар, сеңлем?

— Хәзрәт, дим,— дип Рухан картка авылдагы тәртип буенча эндәшә Сәрвия һәм соңыннан да бу тәртипне үзгәртми,— ил каршында энә күзе хәтле дә гаебем юк минем! Тракторчы бит мин, сугыш вакытында шул һөнәргә өйрәткәннәр иде. МТСта бер киңәшмә булды. Шуның ахырында директор сикереп торып: «Хәзер «Интернационал» җырлыйбыз»,— дип кычкырды. Киңәшмәдә теге Моназыйр Шәгаетов та бар иде, колхозның комсомол оешмасы секретаре иде бит ул, бригадир да аннары.

— Ә-ә, хәтерлим мин ул малайны! — дип бүлдерә Рухан.— Хәтерләмичә соң!.. Истән чыкмый ул малай.

— Малай, дип, җиткән егет инде ул хәзер, быел армиягә алынырга тиеш.

— Шулайдыр. Әмма минем күз алдында ул, кулларын артка куеп, эре кыяфәткә кереп йөрүче малай булып калган. Йодрыгы белән кадак какмакчы иде ул малай. Әмма моны һәркем дә эшли алмый.

— Йодрык, дигәннән, Таукашка күченеп килгәч, Моназыйр беренче эш итеп авылга йодрык күрсәткән иде.

— Әмма күңелендәге йодрык тагын да әшәкерәк булган икән аның. Шөкер, үземнең күңелемдә әшәкелек беркайчан да булмады. Һәркемгә һомай күләгәсе төшүен теләдем. Беләсеңме, һомай күләгәсе — бәхет кошы күләгәсе төшкән кеше бәхетле була, диләр. Ә минем үземә, сиңа да, һомай күләгәсе түгел, тилгән күләгәсе төште. Күләгә генәме әле... Тилгән бөркет була алмый, диләр. Һомай да була алмый тилгән. Әйе, шул малай да җыелышта иде, диден.

— Киңәшмәдән соң Таукашка Моназыйр белән бергә кайттык. Директорның «Интернационал» җырларга кушуы исемә төште дә көлеп җибәрдем. Көй юк та инде миндә, дидем, башкаларга кушылып «Интернационал» җырлый башладым да «Галиябану»га барып чыктым, дип көлдем үземнән... Бу турыда бүтән берәү алдында да кабатламадым, оныткан да идем инде мин аны. Тик тиешсез урынга барып ирешкән шушы сүзләрем. Төнлә килеп алып киттеләр, авылдашлар белән хушлаша да алмадым. Өченче яшенә генә киткән балам йокысында калды... Әти белән түшәк өстендәге әни кулына... «Интернационал»ны «Галиябану»га тиңләп, партиянең нигезен җимермәкче буласың, дип гаеп тактылар. Партиянең нигезе нәрсә икәнен аңлап та җиткермим бит мин! Башлары шәп эшләгәч, шуны уйласыннар иде, ичмасам! Сигез ел бирделәр... Ичмасам, урысчасын да юньләп белмим, нишләрмен мин монда...

Рухан карт хуҗа хатыннан чәй әзерләтә. Чәй янында Сәрвиядән авыл хәлләрен сораша, сугыштан кемнәрнең кайтуынкайтмавын, Таукашның һәр йортын күз алдына китереп белешә.

— Хәтерлисеңдер, минем кияүгә чыкмаган ике кызым бар иде, икесе дә сугышта вафат булганнар,— дип, үз хәлләрен дә сөйләп ала Рухан.— Өлкән яшьтәрәк иде шул инде алар. Егетләр, мулла кызлары дип, өйләнергә курыкты, ахрысы. Советка каршы бару була, янәсе. Шәфкать туташлары булып, сугышка үзләре теләп киткәннәр. Булмаган гаепләрен юарга ниятләгәннәрдер, бәгырькәйләр. Алар мине сугышка чаклы эзләтеп тапканнар иде, аларны Казахстанга куган булганнар. Хатлар алыштык. Аллага шөкер. Авылда безнең йорт иң әйбәте иде, хәлемнән килгәч, авыл матурайсын дип тырышкан идем. Йортҗирне туздырганнардыр инде? — дип, сүзне кинәт бүтәнгә күчереп сорый Рухан.

Сәрвия башын кага:

— Абыстайларны җибәрүгә үк. Ә абыстай исәнме соң, хәзрәт?

— Сугышка чаклы ук вафат инде. Далага китереп ташлагач, тугыз ай да биш көн генә яшәгән. Әйбәт җирләгәннәр, үзебезчә, анда безнең халык күп булган. Кызларым шулай дип язган иде. Нишләмәк кирәк, үз гомеремдә күпләрне ләхеткә куйдым, ә карчыгымны һәм кызларымны озата алмадым. Таукашта туган өч җанның гүре өч җирдә булырга насыйп кылынган икән. Миңа да Таукаш туфрагына кайтып гүргә иңү насыйп түгелдер. Кайчакта күңелем шулай сизә. Ходай шулай язгандыр, дим. Нишләмәк кирәк. Аллаһы Тәгалә ихтыярыннан узмыш юк. Монда җеназа укучы да булмас. Шулай да, сеңлем, кайтырга ышанычым зур. Йортыбыз туздырылган булса да, берәрсе куышына алыр иде әле.

— Безгә туры кайтырсың, хәзрәт! Безнең өй иркен!

— Мостафа да, әниең дә карышмас анысы. Тату яшәдек

үзләре белән. Әйе. Монда мин, сеңлем, ун ел буена бернәрсәгә икеләнеп яшәдем. Мине, Сәрвия сеңлем, өч сүзем өчен гаепләделәр. Мәчет манарасын төшергән көнне әнә шул сиңа да яла яккан малай алдында: «Авылның башын кистеләр»,— дигән идем. Бүтәннәр алдында бу сүзләрне әйтмәдем. Ун ел шикләндем, шул малай сүзләремне ирештергәндер, дип уйлап, гөнаһлы булудан курыктым. Аның сиңа да пычрак ыргытканын белгәч кенә, шул малайның мине монда ун ел черетүенә ышандым. Малай чагыннан ук күңеле пычрак белән тулуын башка китерерлек түгел. Аллаһы Тәгалә каршына барып баскач та, бер кешегә бәхиллек бирмәдем, диярмен. Хәер, Ходай Тәгалә моны хәзердән үк белеп тора. Вафатым Таукашта буласын белсәм, шул малайны җеназама кертмәскә васыять әйтер идем. Ходай сакласын, безнең коллык язмышын бүтән берәүгә дә бирмәсен, хокуксыз булырга берәүгә дә язмасын. Ходай үзе сакласын. Мине Таукашта кайчан да булса яхшылык белән искә төшерәчәкләр. Авыл халкына начарлыгым тимәде. Мин гомерем буе кешеләрне гөнаһ кылмаска өндәдем. Шулай... Мәчет манарасын төшереп, авылның башын кистеләр. Манараны ансат төшерделәр. Әмма утыртуы кыен бит манараны...

Фаҗигале үлем белән китә Рухан хәзрәт. Сәрвиянең килүеннән алты ел элек авыл читеннән бүре баласы тапкан була ул. Күрәсең, ана бүрене аучылар аткан булган да, сабыйкай, башкаларыннан аерылып, кешеләрдән ярдәм сорап, авыл янына килеп чыккан булган. Шул бүре баласына Рухан хәзрәт Маэмай дип исем куша, аны әйбәтләп карап үстерә. Бәйдә тота, үзе белән йөрергә чыкканда да, муенчагын салдырмый, бауны кулыннан ычкындырмый. Авыл кешеләренә зыяны тими Маэмайның. Инде срогым тулды, кайтарырлар, сөргендәге кешеләргә күзәтчелек итүче мине куркыта гынадыр, мине азат итәргә кушарга югарыда онытып кына торалардыр, дип өметләнә Рухан хәзрәт. Тиз арада кайтыр юлга чыгарын бик көтә ул, ерак сәфәргә әзерләнүен Сәрвиягә көн саен кат-кат әйтә. Һәм Маэмайны урманда адаштырырга була хәзрәт. Башка чарасы юк, урманда Маэмайны кардәш-ырулары чит итмәсләр, иреккә чыгуына Маэмай үзе дә сөенер дигән исәптә була карт.

— Таукашка алып кайтыр идем Маэмайны, барыбер рөхсәт итмәсләр, поездларда йөрттермәсләр. Ия булырга теләүче дә юк. Син аны карый алмаячаксың. Аннары, үзең кайтканда, аны кемгә калдырырсың? Атарлар тугры җан иясен. Шулай булгач, урманга озату хәер. Сабый чагында, мин табып алмасам, күптән вафат булган булыр иде. Табуым яхшы булды, алты ел яшәде, үз кардәшләре белән тагын озак яшәр,— ди ул Сәрвиягә.

Шуннан соң Маэмайга: — Апаң белән хушлаш әле,— дип куша. Бүре акрын гына улап куя.— Шулай тиеш, рәхмәт,— дип сөя аны хуҗасы.

...Инде тайгага ерак керәләр, Руханның бу тирәләргә үк җиткәне булмый. Маэмай инде муенчаксыз, ул Руханнан аерылып та киткәли, әмма карт кайту ягына юл алуга, аның каршына чабып килеп чыга. Тагын да эчкәрәк керәләр. Аерылып йөргән Маэмай Рухан янына кинәт атылып килә. Ни була? Руханны һәм Маэмайны бүреләр камый. Себер урманында кәкре хәнҗәрнең дә кирәге чыга, дип, шушы авыл кешесе бүләк иткән ятаганны фатирында калдырган була Рухан. Хәер, бүреләр өеренә каршы кәкре хәнҗәр белән генә каршы тора алмас иде. Җитмешне узган картның ыжгырып килгән ерткычлар белән көрәшергә беләгендә көч тә юк лабаса...

Үз итмиләр Маэмайны кардәш-ырулары, Маэмайны да, Руханны да күз ачып йомганчы буып ташлыйлар...

Аларның таланган-теткәләнгән гәүдәләрен икенче көнне генә табалар. Руханны җирләүне Сәрвия оештыра, авылның үз кешеләре дә, сөргендәгеләр дә ярдәмнән калдырмыйлар. Җеназа укучы гына булмый, анысын Сәрвия, илле өченче елда Таукашка кайткач, кешеләрдән яшереп, авылның бер картыннан укыта.

...Сәрвиянең бу тарихны Нисага сөйләве кирәк булмагандыр.

— Гасабиланып ялваруына түзә алмадым шул,— дип аңлатты Сәрвия сөйләве сәбәбен.

Һәм ул сөргендә Рухан хәзрәтне очратуы турында миңа да хикәя кылды. Монысы минем үтенеч буенча инде. Ниса Сәрвиядән әлеге авылның адресын алган, әйтмәсәң, күз алдыңда ук үземә кул салам, дип куркыткан. Һәм ул моны, Сәрвия карышса, шул мәлдә үк эшлисе булган.

Аның: «Мин Рухан хәзрәт каберенә Моназыйр өчен башымны ияргә киттем»,— дигән язу калдыруына шактый вакыт узды. Олы кияве белән төпчек малае Рухан җирләнгән авылга барып та кайттылар. Ниса анда бармаган. Балалары һәм Сәрвия гаиләсе һаман эзләтәләр аны, әмма әлегәчә табылмый Хәйрелбәшәр. Ире Шәгаетов, хатынымны Сәрвия тилертте, дип, судка биргән...

Хикәянең бу бүлегендә төрле тарафларга еш «йөгергәләү» — Таукашның беренче кар яуган көнен генә тасвир итүдән ераклашулар, соңыннан беленгән вакыйгаларга таянып, асылда, Гөлнисаның язмышын ачыклау һәм Сәрвия белән Руханның сөргендә очрашуын сөйләү теләкләреннән туды. Шулай да читкә тайпылырга этәргән бүтән сәбәпләр — мин соңрак белгән хәлләр дә бар. Менә берсе.

Сәрвиянең яшьлегенә бәйле вакыйганың очын мин Таукаш авылыннан бик еракта — бу озын хикәямнең башында ук бер сәфәрем турында искәрткән идем — һәм очраклы рәвештә

ишетеп кайттым. Шуннан соң гына Сәрвия карчыктан бу вакыйганы сөйләтә алдым. Хәтерлисезме, Галиярның солдаттан кайтып керүен тасвирлаганда, Вильгельм исеме берничә тапкыр кабатланган иде. Вильгельм исемле немец әсиренең Таукашта булуын киңрәк сурәтләргә менә хәзер вакыт җитте булыр.

Сәрвия... Әлбәттә, аның Рухан хәзрәт кушкан исеме бүтән. Гомумән, хикәядәге геройларның барысының да исемнәре үзгәртелде. Авылның исеме дә Таукаш түгел. Әмма хикәядәге вакыйгалар, авылның Мишә буенда утыруы һәм тау башында кыя калдыгы булуы хак. Шулай ук сиксән җиденче елның кар төшкән көнендә авыл каршында болытларның гаҗәеп биек һәм кыя очлы таулар тезмәсе сыман иртән һәм ахшам җитәрдә күренүе дә күзәтелде.

...Язучыларның Дубултыдагы иҗат йортында, иртәнге аштан соң, иң югары катка менәргә лифт көтә идем. Яныма утыз яшьләр тирәсендәге бер ир килде, кулында газеталар. Елмаеп, баш кагып исәнләште. Йөзеннән елмаю һич тә китмидер, ахрысы, бу кешенең, кашлары җитез селкенә дә авыз читләре уйнап ала. Лифт кабинасына кердек.

— Сезгә кайсы катка? — дип сорыйм.

— Аңламый,— дип, өченче зат турында сүз баргандай җавап кайтарды ул. Күкрәгенә бармагы белән төртте дә: — Росток, росток,— диде, мин Ростоктан ягъни.

Димәк, миңа кайсы катка кирәклеген әйтергә калды.

— Айн, цвай, драй...— Немецча саный белү шуннан артмады һәм, кайсы катка кирәклеген аңлатып, тугыз бармагымны җәйдем. Ул үзенең кайдан булуын әйткәч, мин кемлегемне белдерүне тиеш санаганмындыр инде, бармакларымны күкрәгемә бәргәли-бәргәли: — Казан, татар,— дидем.

— О-о, татар?! — дип гаҗәпләнеп күзләрен зур ачты ул, ә үзенең йөзеннән елмаю китмәде.

Шундый аз сүзле әңгәмә корып, без Вальтерның (исемнәребезне әйтергә дә бармакларыбыз ярдәм итте) җиденче катын узып та киткәнбез икән. Бүлмәмә чакырып ишарәләдем, ә ул мине кулымнан тотты да үз катына алып төште. Шөкер лә, Вальтерлар группасын йөртүче тәрҗемәче үз бүлмәсендә икән, ә Вальтер, иртәнге аштан соң, газеталар алырга аерылып калган икән.

Вальтерны минем Татарстаннан булуым кызыксындырган, һәм моның сәбәбе менә нәрсәдә икән. Аның әтисе Вильгельм сугышта безнекеләргә әсир төшкән, Арчада булган. Сугыш беткән елда әсирләрне нигәдер якын-тирәдәге авылларга җибәреп торганнар, бәлки, алар туган илләренә кайтыр алдыннан Арчада күпләп тупланганнардыр да яшәтергә урын җитмәгәндер, ә Таукашта төзелеп бетмәгән мәктәп бинасы вакытлыча яшәп торырга яраклы, әлбәттә. Әнә шул чакта Таукашка Вильгельм да килгән. Бу авылны онытмаган Вильгельм. Вальтер

миңа әтисенең Таукаштагы Sarbia исемле (Вальтер шулай язып күрсәтте) кызны хөрмәт белән искә алуын сөйләде, ә минем Таукашны һәм Таукаштагы Сәрвияне белүем турында ишеткәч, кочаклап ук алды. Вальтерга да, миңа да татар кызы Сәрвия һәм әсир немец солдаты Вильгельм турында сөйләшү кызыклы иде, тәрҗемәче дә безнең озаклап әңгәмә коруларыбызга каршы килмәде. Гел елмаеп кына тормый икән Вальтер, әңгәмәдә йөзе кырысланган чаклары да булды аның. Ул, мин Татарстан җиренә кунакка чакыргач, вакыт тимәвен аңлатып, җитдиләнеп кулларын җәйде.

Немец язучылары Дубултыда өч көн булдылар. Бәлки, Таукаш хәлләрен ишеткәч, Вальтер да әтисе Вильгельм һәм Сәрвия турында хикәя язар. Әмма без — Вальтер һәм мин — алар турындагы вакыйганы куертып хикәя язарга сүз куешмадык, бер үк вакыйганы чагылдыруда ярышу дәрте тумады. Аннары бит Вальтер хикәяне әтисе сөйләгәннәргә нигезләнеп язачак, ә миңа, Сәрвия һәм Вильгельм турында язганда, Таукаш Сәрвиясенең, үткән тормышын сөйләгәндә, сүзгә бик тә саранлыгын искәртергә кала. Шуңа күрә дә мин бу вакыйганы Сәрвия сөйләгән күләмнән арттырмыйм.

Һәм менә ул — безнең хикәяләвебезнең Сәрвия һәм Вильгельм мөнәсәбәтенә кагылышлы тагын бер өлеше.

...Капитан Сафа, олы урамнан бер төркем әсирләрне ияртеп барганда, Сәрвия белән Мостафаның бәрәңге утыртуларын күрде. Мостафа, култык таякларына таянып, Сәрвия казыган чокырларга иелмичә генә бәрәңге сала, ялгыш төшкән бәрәңгеләрне Сәрвия ояларга җайлап куярга мәҗбүр иде. Шулай да дөрес төшкәннәре дә бар, Мостафаның беләгенә чиләк элеп йөрүе бөтенләй үк файдасызга түгел, ярдәме тия гарип солдатның. Булдыра алмыйм, дип акланып утырыр чак түгел, бәрәңге утырту вакыты узып бара. Мостафаның карчыгы урын өстендә ята, әтисе дә булышмаса, Сәрвия үзе генә кайчан өлгерер әле, өстәвенә Сәрвиягә авырга да туры килә, эштән кайткан-киткән арада гына күп нәрсә майтарып булмый. Колхозда да чәчү бетмәгән, тракторны тик тотып, эш калдырырга ничек җөрьәт итмәк кирәк. Бүген дә бәрәңге утыртырга яктырып җитмәстән үк чыктылар, Сәрвия смена алыштырырга киткәнче, әллә ни үрчетә алмасалар да, алга китеш барыбер булыр. Бүген ерак басуга барасы түгел, тракторы авыл янында гына сөрә, гөрелтесе ишетелеп тора әнә, сөрелгән җиргә авылның өлкәнрәк яшьтәге апайлары бүген үк бәрәңге утырта башларга да тиешләр.

Сафа әсирләрне туктатты да, Вильгельмны ияртеп, Сәрвияләр янына килде.

— Алла куәт бирсен сезгә! — диде ул, һәм чиләкне, Мостафа кулыннан алып, Сәрвиягә тоттырды, Вильгельмга көрәк бир-

де.— Менә шушы әсир егет ярдәм итәр сезгә. Нинди эшегез булса да, миңа әйтерсез дә мин Вильгельмны җибәрермен. Ә Вильгельм һәр эшне ялт иттереп эшли. Син, абзый кеше, йөзеңне җыерма, әсир синә кол булып түгел, тиешле булганга булыша. Аягың исән булса, син ярдәмгә мохтаҗ кеше түгелсең.

Вильгельм бәрәңгене берьялгызы кичкә утыртып бетергән иде. Сәрвия сменасын тапшырып ашыгып кайтканда, этисе Мостафа, киртәгә таянып, тоташ тырмаланган бакчага таң калып карап тора иде. Әсирнең ял да итмичә эшләгәнен әйтте ул, Мостафаны булыштыртмаган, һәр ояга бәрәңгене абзар буендагы черегән тиресне чиләкләр белән ташып салып утырткан. Мостафа әсиргә чәйне дә бакчага алып чыгып эчерткән.

— Башта әсирне бер дә ошатмаган идем, мине аяксыз калдыручы шулдыр кебек иде,— дип сөйләп бетерде көндезге хәлләрне Мостафа.— Егет, әсирне әйтәм, крестьян затыннан икән, җир эшен сагынуын күргәч, миңа атучы ул түгелдер кебек булды. Игенчене дә сугышка китереп тыкты Гитлер...

— Сине гарипләндерүче бу әсир булмагандыр ла, әти...

— Үзем дә шулай дим бит. Хәвеф-хәтәр тимичә генә үсә күрсен бәрәңгебез. Тырышты әсир егет... Йомырка пешереп илт үзенә, май белән бәрәңге дә ал. Мин биргәч, ашамады. Арыгандыр.

Сәрвиянең күчтәнәчләрен Вильгельм риза булып алды һәм кызның күз алдында ук иптәшләре белән бүлеште. Сәрвияне өенә капитан Сафа озатты. Капка төбендә аларның сөйләшүен этисе һәм әнисе шактый вакыт ишетеп яттылар. Аннары тавышлар тынды, Сәрвия өйгә таң уңаенда гына ишекне шыгырдатмаска тырышып ачып керде.

Вильгельм Сәрвияләргә көн саен диярлек килде. Сафа җибәрә идеме аны, әллә үзе рөхсәт сорап килә идеме — бу кадәресен Мостафа да, Сәрвия дә белмәде. Килә дә Мостафага күз карашы белән нидер әйтә һәм, шөгыль табып, эшкә дә башлый. Өй-абзар түбәләрен дә төзәтте әнә: Мостафа, үзе балта остасы булса да, бер аяксыз килеш анда менә алмый, ә сугыш башланганнан бирле кул тимәгән түбәләргә карау-суккалау кирәк иде. Кичке якта Сәрвия эштән кайтмыйча китми Вильгельм. Сәрвиянең әсир егеткә эше өчен кул кушырып рәхмәт әйтүенә сөенеп елмая. Алар бер-берсенең исемнәрен дә кабат белештеләр, Вильгельм үз исемен кәгазьгә язды, Сәрвия дә үз исемен латин хәрефләре белән аның исеме янәшәсенә үк язып куйды. Шул чакта куллары тиешеп алды аларның, Сәрвиянең тәне дерелдәп алды.

...Юк, кирәкми, Вильгельм! Бәлки, син дә гашыйксыңдыр... Кирәкми! Без барыбер бергә була алмаячакбыз, мәхәббәтне яралгысында калдырыйк. Мин бит инде кыз түгел. Инде менә ничә көн... син безгә бәрәңге утырткан көннән башлап... капитан Сафа озатып куйгач...

Шулай да Сәрвия, эштән кайтканда, үзен шушы түгәрәк йөзле, елмаерга яратучы әсир егет каршылавын тели иде.

Әсирләр иртәгә китәчәк икән. Сәрвия, алмашчысына тракторны тапшырды да, юынып та тормады, өенә йөгерде. Ләкин бүген Вильгельм килмәгән иде. Әллә җибәрмәделәрме икән? Сәрвия, юк йомышын бар итеп, салынып бетмәгән мәктәп ягыннан әйләнде, Вильгельм күренмәде, күренсә дә, караңгы төшәр алдыннан аны җибәрмәсләр иде. Ә капитан Сафага рөхсәт сорыйсы юк, ул үзе башлык, әйтеп кенә китә. Һәм Сафа Сәрвияне бүген тагын озатып куйды...

Вильгельмны башка күрә алмады Сәрвия, әсирләрне алып киткәндә, ул ерак басуда җир сөрә иде.

...Сәрвия, ялгызы калгач, урам якка караган урта тәрәзә янына еш килә. Кайчак ул:

— Бу пар каеннарны ул утырткан иде,— дип үзалдына сөйләнә, немец егетен исеме белән атамый.— Соңлабрак утыртылса да, тамырны тиз бикләгән иде каеннары. Суны еш сиптем шул. Кайчак, онытылып, шул каеннарга хәзер дә су сибәм. Картаеп барган каеннарга су сибеп йөрү яшьлекне сагынудан саташудыр инде...

Сәрвия сүзсез кала. Каеннарга озак карап тора.

Аннары:

— Исән микән Виль...— дип пышылдый.

Галиярның авыл советы рәисе булу нияте әлегә барып чыкмады. Каршы төшәләр. Таукашта каршы килүчеләр, бәлки, аздыр, бармак белән генә санарлыктыр. Ләкин райбашкарма яңадан сайлаулар уздыруны кирәкмәс саный. Райбашкармада бездә Моназыйр Шәгаетовтан начаррак рәисләр дә бар дигән карашта торалар. Димәк, җитәкчене бөтенләй эшләмәгән очракта гына төшерергә мөмкин икән. Шәгаетовның Рухан хәзрәткә һәм Сәрвиягә кылганы җинаять түгел икән. Инде болар җинаять саналса да, җәза бирү вакыты күптән узган лабаса.

— Аннары,— диделәр Галиярга райбашкармада,— шәхес культы заманнарында яла ягучыларның исәннәре ил буенча хәзер дә күп. Ләкин андыйларның берсен дә хөкем алдына бастырмыйлар кебек. Ни өчен моны без башларга тиеш икән?

— Мин Моназыйр Шәгаетовны төрмәгә ябыгыз, димәдем,— дип фикерен исбатлады Галияр райбашкарманың шушы мәсьәләне тикшерү өчен җыелган утырышында.— Гәрчә моны таләп итәргә нигезле дәлилләрем булса да, әбием Сәрвиянең яла ягучыга рәнҗүе бетмәвен онытып торып, авыл язмышы турында сүз алып барам мин. Авыл Шәгаетов җитәкчелегендә яши алмый!

— Син, Мостафин, үзең турында бик тә югары фикердә икәнсең. Таукашта Совет власте юк, имеш! Ничек телең әйләнә? Үзеңне үзең рәислеккә тәкъдим итү, хәзер мондый очраклар

булса да, иң кимендә — тыйнаксызлык. Безнең халыкның тыйнак булуын онытма.

— Онытмыйм. Рәис булгач, халкыбызның гадәтләрен һәм, авылыбызның балта остасы Ваһим абзый әйткәнчә, ганганәләрен торгызу-баету өчен тырышачакмын.

— Моның өчен генә авыл советы рәисе булу мәҗбүри түгел. Клуб мөдире булу да җитә.

— Ләкин минем эшләячәк эшләрем болар белән генә бетми! Авылыбызны яшәтергә телим мин!

— Аңлашылды! Хәзергә Таукаш авыл советы депутатлары барысы да исән-сау, һәм берсенең дә вәкаләтен алырга сәбәп юк.

Райбашкарма утырышыннан кайтканда, Галияр авыл советы рәисе булу өчен көрәшүдән баш тартып тормакчы да булган иде. Чөнки бу мәсьәләне хәл итүдә райбашкармадан узып булмый, ә анда, Шәгаетовны яклап, нык торалар. Тик үзгәреш заманында авылда сизелерлек алга китеш булмавы өчен борчылуы өстен чыкты.

Кичен әнисе Мөхтәрәмә:

— Улым, булышмачы шушы кеше җанын аңламас Шәгаетов белән,— дип тыймакчы булгач, Галияр әнисенең фикерен иплән кенә кире какты.

— Алай димә, әни. Таукаш язмышы турында сүз бара.

— Безнең янда әйбәт кенә эшләп йөрисең. Ичмасам, яраң төзәлеп җиткәнче үзең үк борчу эзләмәче.

Әңгәмәдән Рәйсә дә читтә калмады:

— Андый киңәш биреп ялгышасың, әни! — диде ул.— Власть тотардай бүтән кеше юк бүген Таукашта!

— Шәгаетов үзе эшләп торсын соң,— дип, малаеның зур камыт кияргә җыенуына һаман да каршы төште Мөхтәрәмә.

— Ничек инде эшләсен?! Бернинди хокукы юк аның анда эшләргә! Элекке юньсезлекләренә өстәп, күптән түгел абыйны кешеләр алдында шәрә калдырттымы? Монысы — бер. Икенчесе. Сәрвия әбине хөкемгә тарттырмакчы булып йөриме? Безнең әби Ниса апаны юләрләндергән, имеш! Әбинең Хәйрелбәшәрне каравына рәхмәте монысы Шәгаетовның! Болары — Моназыйр абзагызның соңгы вакытта бер безнең гаиләгә эшләгән әшәкелекләре. Кеше кыерсытмыйча калган көне юк лабаса аның!

— Үч алган кебек, кызым.

— Түгел, алай түгел, әни!

— Мине судка чакыртканнары юк, Рәйсә кызым,— дип кушылды Сәрвия.— Бәлки, судка бирмәгәндер.

— Судка биргән, әби,— дип ачыклык кертте Галияр.— Бүген белешеп чыктым. Тикшерүне ничек башларга белмичә аптырап калдык, диделәр.

— Бер генәләр дә иманы юк икән! Мине икенче тапкыр утыртмакчы булып, чынлап торып җыена икән алайса...

Тимерша моңарчы эндәшмичә тыңлап утырды, катнашмаска иде исәбе. Ләкин әнисенең соңгы әрнүле дә, хафалы да сүзләре аны тамак кырырга мәҗбүр итте, димәк, ул да сүз әйтәчәк икән.

— Галияр,— диде дә фикерләрен барлап тукталып торды Тимерша.— Улым, көрәшергә мәйданга чыкканчы, беләгеңдәге көчеңә, бигрәк тә башыңдагы акылыңа үзең үк бәя биреп карау тиеш. Омтылуың яшьлегеңнең йөгәнсез кыбырсуы гына түгелме? Син хәзергә үзең дә безнең өчен генә җаваплы. Бер түбә астындагы һәркайсыбызның холкы кырыкка төрләнә. Авыл власте турында сөйлибез, гаилә башлыгы турында гына түгел. Ә Шәгаетов башлык булып яралгандыр ул... Уйла әле син. Ә авылыбызга үзгәреш ихтыяҗ. Бик тә ихтыяҗ.

Тимершаның гомер булмаганча озын сөйләвеннән соң, әңгәмә беразга тынды. Уйлану һәркайсына кирәк иде. Сүзне Рәйсә яңартты.

— Һәркем үз ягына каера һәм һәркем үзенчә хаклы кебек,— диде ул.— Авылның башлыгы булырга тиешме? Тиеш! Футбол уенында да чын лидерсыз булмый әнә, чын лидерлы команда гына дөнья чемпионлыгына чыга, гап-гади хакыйкать бу. Таукашның барча кешесен үз артыннан җәлеп итәр егет Галияр абый булыр, дим мин. Тик Галияр абыйда кыюлык җитми. Их, үзем алыныр идем мин!.. Кимендә унсигезем тулу кирәк шул... Риза булсалар, ун класс өчен иртәгә үк экстерн тәртибендә имтиханнар тапшырам! И-их!

— Мин көрәштән ваз кичмим, эти,— дип җавабын Тимершага кайтаруны тиеш тапты Галияр.— Һәм җиңелмәячәкмен! Иртүк Моназыйр Шәгаетовның үзе янына барам!

Ләкин иртәгесен Моназыйр янына Галиярдан алда Ваһим оста килеп өлгергән иде. Һәм Ваһим белән Галияр Моназыйрларның капка төбендә очраштылар. Танылган балта остасы авыл советы рәисе яныннан чыгып килә иде. Аның йөзе ачулы, ул тунын бер төймәләп, бер чишеп торганнан соң гына Галиярга кулын биреп күреште.

Ваһим оста Галиярны каршылау кичәсеннән соң күңелендә тынычлану сизә иде. Инде пенсиядә булса да, ул, үзе сорап, эшкә чыкты. Тимершага сарык абзарларын төзәтүдә булышты, ярдәмгә килүенең сәбәбен башта ук Тимершага ачыктан әйтте.

— Сезнең подряд-арендагызда катнашым юк,— диде ул.— Әмма булышам. Мондый хәрабәне тәртипләү сиңа да Галиярга гына озакка сузыласы өчен түгел. Сезнең нәселгә бурычым бар. Бабаң Мостафа абзыйга. Мине һөнәрле иткәне өчен. Каралты-кураңны эшләүдә син мине катнаштырмадың. Дөрес иттең — син үзең оста, кем әйтмешли, бер казанга түгел, бер ихатага да сыймаган булыр идек. Ә фермагыз абзарларын төзәтүдә булышуны тыймаячаксың. Чөнки ашыгыч эш монысы. Анысы, тәртипкә салып бетергәч, монда чит кешедән кадак кактыру түгел, аяк та бастырмаячаксың. Белеп торам. Әйе, олы-

гайдым. Олыгаям. Кешеләрдә бурычым калмасын. Сиңа абзар төзәтүдә булышып кына Мостафа абзыйга бурычымны түләп тә бетереп булмас. Шулай да, димен.

Соңгы вакытта авыл халкы язмышының уртасына керергә тәвәккәлләвенә ни-нәрсә сәбәп булгандыр, бу хакта берәү белән дә фикерен уртаклашмады Ваһим. Күрәсең, оста булып танылып, башкаларга бәйсезлеккә күнегүе холкында ныгыган иде аның. Сүзен-киңәшен Таукашта игътибарсыз калдырмаячакларына хәтта ышана иде. Ялгыз гына яшәүче Моназыйр янына да аны үзенә ышанычы китерде.

Капка баганасындагы кыңгырау төймәсенә баскач, Ваһим Моназыйрны тиз генә чыкмас дип уйлаган иде. Ләкин Моназыйр ишегалдында булган икән, аңа өйдә кыңгырау шалтыравын ишетүенең кирәге булмады. Ул, капка төбенә кеше килеп басуын күреп, бастырыкны этеп, кечкенә капканы ачты.

— Исәнме, Моназыйр,— дип салмак кына эндәште Ваһим.

— Ярыйсы. Начар түгел.

— Сиңа сүз бар.

— Бүген сиңа дигән аракым юк.

— Мин аракы сорамыйм синнән! — дип ачуланды Ваһим.— Синең мунчаңда эчкәннән соң, авызга да алмыйм. Алмам да! Кая, тагын мунчада гына сөйләшәбезме, әллә өеңә керәбезме? Ә-ә, яңа келәтең ачык ич менә.

Ваһим эчтә ут янып торган келәткә юнәлде, хуҗа, келәт байлыгын чит күз күрүен өнәп бетермәсә дә, остага иярде.

— Миңа кырын карама, синең байлыгыңны тикшерергә килмәдем,— диде Ваһим һәм келәтнең ишеген эчтән япты.— Безгә икәүдән-икәү генә сөйләшергә кирәк.

— Тыңлыйм соң.

— Син урыныңны Галиярга бир! Акылга килүеңне депутатлыгыңнан ваз кичүдән башла.

Моназыйр көлеп җибәрде һәм, тешләрен кысып:

— Ю-ук! — диде.— Юк! Андый хәл булмаячак!

— Тилелегеңне ташла, Моназыйр. Мин сиңа да яхшылык теләп килдем.

— Димче булып!

— Ашыкма, дим. Димче түгел мин. Димче булсам, мин Галияр катына үгет белән барган булыр идем.— Ваһим тын алды, аңа Моназыйрга каты бәрелеп сөйләүдән тыелу кыен иде.— Килеш минем һәм Галиярның тәкъдименә. Галиярда тормышыбызны үзгәртергә өмет бар. Һәм моңа көче дә җитә аның.

— Мин көчсезме?! Теләсәм, әле хәзер дә бөтен Таукашны бөтереп алам!

— Алай... Игелек кирәсе юк икән сиңа...— Ваһим, китәргә җыенып, келәт ишеген ачты.— Шулай да ахыры үзең өчен бик тә ямьсез булыр бит...

— Тукта, Ваһим абзый, нигә син авыл советы өчен борчыла

башладың соң? Әле теге сөйләшүдә генә авыл советыгызда катнашым юк, дип, властьны санга сукмаучы син түгелме? Әллә оныттыңмы моны?

— Онытмадым! Ләкин моңарчы авыл властена битараф булып ялгышканмын. Читкә басып, властька кул селтәп тордым мин моңарчы. Хәзер читтә калмаячакмын!

— Уртага чыгып басарга соң түгелме?

— Түгел!

— Соң инде, Ваһим оста! Надан син!

— Власть турында уйларга минем зиһен тартмыймы? Тыңла алайса. Бүлдермичә тыңла. Мин сиңа Айдаш һәм Әбүсөгыт турында хикәя сөйләгән идемме? Алар бер-берсенең бугазларына шулай чатырдатып ябышалар. Ю-ук, мин синең белән бугазга-бугаз килмим! Син Совет власте бугазына ябышкансың! Властьны бумакчы буласың! Бу кадәресе барып чыкмас, Шәгаетов! Син хикәямнең ишарәсен аңламагансың. Менә син гомерең буе киләчәк тә киләчәк, дип, авыз суыңны корыткан бәндә. Ә минем хикәяттән үз киләчәгеңне аңларга тырышмадың. Киләчәк... Килер киләчәк, аны китермичә калу мөмкин түгел. Вә ләкин бүгенгебез бар бит әле, шунысы да әһәмиятле. Киләчәк... Якын киләчәктә Американы куып җитмәкче булган идек. Буш сүз булып калды. Шулай бугаз киерүгә җаваплы кешесен дә таба алмыйсың бүген, әкәмәт. Хәзер инде ике меңенче елга илне ал да гөл итәргә җыенабыз. Нигә бүген түгел? Нигә ике меңенче елны көтәргә? Кулыбыздан эш килми торган кешеләрме без?

Ваһим боларны Моназыйрга туры карап әйтте. Ара-тирә аларның карашлары очраша да, Моназыйр, Ваһимның усаллыгын күрмәс өчен, башын түбән ия иде. Ул ишек яңагына ябышты, ләкин кулын ишеккә кысылудан курыккандай тартып алды да, эндәшмичә, шулай да тешләрен шыгырдата-шыгырдата, җәй өчен куелган караватка барып утырды. Ваһим, Моназыйрның бу хәрәкәтләренә игътибар итмәстән, инде тынычрак тавыш белән дәвам итте.

— Тормышны синең кебекләр ямьсезли. Шуңа күрә, әйбәтлеккә гел астыртын аяк чалганга күрә, Таукашка җитәкче булырак кирәгең юк синең. Бәлки, Таукашка гомумән кирәгең юктыр.

— Авылдан сөрмәкче буласың инде әллә? Булмас! Үзеңне эчүчелектән дәвалау җиренә җибәрүдән шүрләп йөр син, Ваһим карт!

— Мине анда җибәртә алмыйсың! Әйтәм бит, синең мунчаңда аракыңны косканнан соң, авызыма эчемлек алганым юк. Галияр кайткан көннән бирле. Галиярның авылыбыз җитәкчесе була алырына ышангач, дим. Ә сине авылдан сөрү дөрес булыр иде.

— Буең җитмәстәйгә үрелмә!

— Галияр кичәсеннән соң иң киме унбиш тәүлеккә утыртырга иде сине! Авыл советы рәисен ничек утыртасың, янәсе!

— Мине утырта алмый идегез. Чөнки депутат мин, брат! Аннары бит Галиярның ярасы турында дөресен әйттем. Ә менә сине исерекләрне айныта торган җиргә җибәреп була.

Ваһим бу кабат кисәтүне игътибарсыз калдыргандай тоелды, күптән узган заманга әйләнеп кайтты.

— Электәге гап-гади әдәплелекне дә оныттык, закон белән генә эш итәбез. Законга барысы да сыеп бетми, язылмаган законнар да бар. Белгән кешегә...

— Без язылганнарын шәп беләбез!

— Хәтерлисеңме, Шәгаетов, Таукаш мәчете манарасы кыелып төшкән мәлдә кыбырсып йөрүче бер син булган идең. Манара ауганда, хәтта аны кисүчеләр дә тын торды. Ул чакта син Моназыйр дигән бер малай гына идең югыйсә. Шулай да манара җимерелүенә йөрәгенә кан саумаучы адәм актыгы Таукашта бер син генә булдың!

— Манараны мин төшертмәдем.

— Ләкин моңа сөенүче бер син генә идең! Мәчетне дә сөенеп сүттердең! Бүрәнәләреннән милиция башлыгы үзенә йорт салдыртты, сатып алды ягъни, буш бәясенә. Манара авылның изге кыясы иде. Тагын бер нәрсәне хәтерлә. Галияр солдаттан кайткан көнне син авылның тавы кашына мендең. Күреп тордым. Тауның кашында кыя нигезе бар. Ләкин кыя эзләп менмәдең син тауга, чөнки менүең дә, төшүең дә мескенлегең иде, кыяга менә алмыйча гомерең узуына үҗәтләнүең иде. Шул мәлгә чаклы Таукашта кыяга менәргә сәләтле кеше булмавына сөенә идең син. Галияр кайтып, аның кыяга басардай көче булуын сизгәч, тауга күтәрелеп, үзеңне сынадың. Шунда син беренче тапкыр мескенлегеңне сиздең дә хәзер властька ныклабрак ябышмакчы буласың. Хәзер Таукашның кыяга басардай егете бар! Галияр бар! Аны власть башына кую җаен табарбыз. Авыл халкын үзем күтәрәм! Их-х, аңгыра баш мин, тормыш агышын аңышып тордым лабаса! Шул тормыш агышы турында күңелемнән хикәяләр язып йөрим дә, шуңа канәгать булам, янәсе! Битараф яшим, миңа ни-нәмәрсә җитмәгән, имеш! Баксаң, күп нәрсә җитмәгән икән. Көрәшче булу җитмәгән миңа! Ә күңелем хикәяләрен тагын язармын әле.

— Язучы табылды!

— Мыскыл итәргә маташма. Ул хикәяләрем тормыш турында үземчә уйлануым минем, һәм иң беренче итеп синең чөй булуың турында язачакмын.

Моназыйр, иренен тешләп, гырылдагандай тавыш чыгарды, караваттан кузгалып, Ваһимга таба атлап куйды. Авызын бер ача да бер ябып, аскы иренен ялый иде — әйтерсең Ваһим останың бугазын чәйнәргә әзерләнә, Ваһим да Моназыйрга таба атлап куйды.

— Тукта! — дип кычкырды ул, хәвеф кубу шиге якынаеп җитүен сизенгән иде.— Миңа көчең җитмәячәк синең! Минем кеше канын эчкәнем юк! Ә син Галияр кичәсендә дә солдат ярасына тыкшындың! Әйе, чөй син! Тормышка кирәкмәс чөйсең!

Ваһим, келәт уртасында тешләрен шыгырдатып басып торган Моназыйрга кулын селтәп, чыгып китте. Моназыйрның:

— Бүрәнә ярырга суккан чөй түгел, ә тормыш йөген күтәреп торырга утыртылган багана мин! — дип ысылдаганын ишетмәде.

Һәм капка төбендә үк Галиярны очраткач, Ваһим беравык аптырап торды. Егет белән күрешкәннән соң гына фикерен җыеп өлгерде. Галиярны култыклады да юлыннан борды.

— Юньләп сөйләшәм дә игенә килер, дип өметләнмә, Галияр энем,— диде Ваһим.— Вәхши бу бәндәчек. Йа Ходай, ничек моңарчы түздек икән моның вәхшәтенә!.. Киттек! Элгәре икәү киңәшик. Барыбер безнеңчә булачак! Чын мәгәр!

...Моназыйр, ялгызы яши башлагач, көндезен чәй белән канәгатьләнергә гадәтләнде. Кайтуга газ плитәсенә чәйнек куеп җибәрә дә, табын әзерләгәнче, чәй кайнап чыга, кабат эшкә киткәнче, терлек-туарны карарга вакыты да кала. Хәйрелбәшәр булмаса да һәм шәһәрдәге балалары кайтып булышмасалар да, Моназыйр терлекләрен бетермәде, түләү биреп, күрше хатыннан карата. Чәйләгәннән соң маллар янына чыгарга торганда, өйалды ишеге келәсе күтәрелгән тавыш ишетелде. Ишекне ачып карамыйча да аңышып тора Моназыйр — керүче кеше болдырда итекләрен озаклап себерде, аннары аякларын берберсенә бәреп какты. Ишекне япкач, идәнгә каты басып атлады керүче. Йөреше стена аша да таныш тоела, дип уйлап та бетерә алмады Моназыйр — ишекне каерып ачып, Хәйрелбәшәр килеп керде.

— Ниса?! Гөлниса?! — дип югалып калды Моназыйр.

— Мин шул, Моназыйрым! Мин кайттым! Хәйрелбәшәрең исән-сау йөреп кайтты.

Гөлниса Моназыйрның муенына барып асылынды, ирен аркасыннан сөйде, аннары, ике кулы белән ике яңагыннан тотып, күзләренә озак текәлеп карады да, уфылдап сулап, өстәл башындагы урындыкны тартып утырды.

— Ни... Гөлниса... Чишен...

— Чишенермен лә! Әле менә киенгән килеш кенә өйне әйләнеп чыгыйм да ишегалдын, каралты-кураларны карап керермен. Сагындым. Барысын да сагындым! Үз нигезебез бит! Казанда балалар янына да тукталып тормадым.

Ул өйдәге әйберләрне тоткалап карый-карый йөренеп сөйләнде.

— Барысын да тәртипле тоткансың, Моназыйркаем. Ирем бит син минем, яратам бит мин сине! Аллаһы боерса, рәхәтләнеп яшәрбез икәүләшеп нигезебездә, боерсын инде. Әйбәт йө-

реп кайттым. Бүтән беркая да китмим инде. Балалар янына Казанга да бармыйм. Үзләре кайтырлар. Гел шулай итәргә күндерербез. Хәбәрләре бармы соң үзләренең, Моназыйр?

— Ни, Гөлниса...

— Ярар, борчылма, хәбәр итәрбез дә сәгате-минуты белән очып кына кайтып җитәрләр. Тигез яшәрбез, Аллаһы боерса. Йорт-җиребез Таукашта иң әйбәте, мин йөргән җирләрдә дә безнең йортка тиңе юктыр, валлаһи гынам. Йорт яңартып дөрес иттек.

Ул идәннән түшәмгә җиткереп махсус эшләтелгән көзге каршында киемнәрен рәтләде, яулыгын бераз чәчләрен чыгарып калдырып бәйләде.

— Киемнәрем дә тузмаган, име, Моназыйр. Бик сак йөрдем шул. Салкын тидереп, Томскида больницада ятып чыктым. Ярый соң паспортымны калдырмаганмын, шуңа башым эшләгән. Акчам әзрәк калды да әле, акчаны күп алып дөрес иткәнмен. Акчаны күп алганга ачуланмагансыңдыр ич? Китәр алдыннан син югында өйгә кереп чыктым бит мин.

— Ни... Гөлниса...

— Ачуланмагансың икән. Тик менә күчтәнәчләрем юк инде сиңа, яме. Башта, акчам җитмәс дип, алмаган идем, Казанда күчтәнәч турында бөтенләй оныткანмын. Синең яныңа ашыктым.

— Ни бит, Гөлниса, син үзең...

— Беләм инде, беләм, мине бик көткәнсең! Юлларым уң булды, Моназыйркаем! Таптым Рухан хәзрәтнең гүрен, таптым! Каберен үбеп, синең өчен гафу үтендем.

— Нигә?!

— Пәрәмәч! Нигә, дип, синең аның каршындагы гөнаһыңны юу өчен инде. Гафу иткәндер Рухан хәзрәт. Каберен рәтләдем, тимердән чардуган ясатып куйдым, «Таукаш авылының элекке хәзрәте Рухан» дип язуын яздырдым, атасының исеме белән фамилиясен белмәдем менә. Анысы гына гөнаһ түгел. Сәрвия апа тактаны чокып язган язуы таныр-танымаслык иде, тактасы череп бетеп бара иде. Гүрнең иясе булды менә хәзер. Өч-дүрт еллардан чардуганын тагын буяп кайтырбыз әле.

— Анда... Анда барырга кем кушты сиңа?!

— Менә тагын! Синең өчен Рухан хәзрәт каберен үптем, дим ләбаса! Әллә сөенмисең инде шуңа? Сөенәсеңдер лә, мине жәлләп кенә әйтүеңдер, үзем барган булыр идем, диюеңдер. Ярар, ярар, тагын барырбыз, икәүләп барырбыз, юлын беләм хәзер. Мин ихатабызны йөреп керим дә иркенләп сөйләшербез, яме. Нигезебезне сагындым...

Рәйсә, ишектән керүгә үк:

— Әби! Сөенче! Ниса апа кайткан! — дип шәрран ярып хәбәр салгач, Сәрвия ашык-пошык киенде дә кабаланып чыгып та китте.

Хәйрелбәшәрләргә җитәрәк:

— Тукта, әби, мин дә синең белән бергә! — дип йөгереп куып җитте карчыкны Рәйсә.— Синең аларга кергәнең юк бугай ла. Икебез бергә керү әйбәтрәк.

— Синең кергәнең бармы? — дип, кашларын җыерып алды Сәрвия.— Үзе Гөлниса апаларының ишеге кай якка ачылганын да белми инде ул, үзе миңа юл күрсәтмәкче була тагын. Әйдә соң, батыр йөрәк, куркак җан! Гөлниса апамны үземнең дә күрәсем килде, диген, ичмасам!

Өйалды ишеген Рәйсә шакыды. Чыгучы булмады. Сәрвия кыңгырау төймәсенә басып алды.

— Әллә ишетмиләр инде? — диде Рәйсә һәм төймәгә өзәтөтә басты.

Бераздан гына Моназыйр чыкты, җилкәсенә тунын элгән иде, кулындагы бүреген башына киде.

— Ни булды? Нәрсәгә...

Ләкин Рәйсә Моназыйрны:

— Без килдек! — дип бүлдерде.— Гөлниса апаны сагынып килдек! Гөлниса апа кайда? Нигә безне каршыларга чыкмый?

— Әллә кәефе начармы, Ходаем? — дип борчылды Сәрвия.— Өйдәме соң ул?

Моназыйр ишегалдына ишарәләде. Сәрвия һәм Рәйсә белән сөйләшергә исәбе юк иде аның. Шулай да, аларның аптырашып торуларын һәм китәргә җыенмауларын күреп, теләмичә генә:

— Шул тирәдәдер,— диде.— Каралты-кураны карыйм, дип, хәтсездән чыгып киткән иде. Күптән. Һаман керми. Нигезне сагынган Гөлниса сөеклегез, ирен түгел...

Әмма Моназыйрның соңгы сүзләрен Сәрвия белән Рәйсә ишетеп тә җиткермәделәр. Алар абзар авызына ашыгып бардылар.

Сәрвия акрын гына:

— Гөлнисау! — дип аваз салды.

Җавап булмады.

— Ниса апа! Хәйрелбәшәр апа! — дип абзар эченә кычкырды Рәйсә.

Җавап тагын булмады.

Аның каравы Сәрвия белән Рәйсәне болдырда басып торучы Моназыйрның ысылдагандай тавышы сискәндерде:

— Нигә сөрән саласыз?!

— Кайда соң Ниса апа?

— Гөлниса күренми ич,— дип, кулларын җәеп гаҗәпләнде Сәрвия.— Әллә, Ходаем, тагын китеп барганмы?

— Кая китсен ул! Бүтән беркая да китмим инде, диде. Шул тирәдәдер.

Моназыйр тунын киде, изүен төймәләмәде. Абзар эченә кереп, утларны яндырды. Ниса күренмәде дә, тавыш та бирмәде.

Моназыйр бакчага күз төшерде, йорт һәм каралты-кура артларын әйләнеп чыкты. Сәрвия белән Рәйсә дә Гөлнисаны эзләштеләр.

Моназыйр:

— Әллә мунча ягарга җыенып йөриме соң? — дип үзалдына сорап куйды.— Мунчага кичә генә ягып кергән идем әле. Калган суларын да түкмәгән, мунчаның җылысы да бетмәгәндер,— дип һаман үз-үзенә сөйләнде, һәм мунча тәрәзәсенә иелеп карады да кинәт артка кайшалды.

Мунча алачыгыннан Рәйсә:

— А-а-а! Ай-й!.. А-а-а! — дип калтыранып-күкрәп атылып чыкты.— Әби! Әби! Анда Гөлниса апа асылынган!..

Гөлнисаны чөйдән алырга Сәрвиянең генә көче җитмәде, ярдәмгә күрше-тирә хатыннарын чакырырга Рәйсәгә кушты. Моназыйр эндәшмәде. Моназыйр үзе дә хатыны гәүдәсен элмәктән ычкындырырга ярдәм итү турында уйламый иде бугай. Ул, мунчаның ачык ишегеннән хатынының ялангач гәүдәсен күргәч, алачык почмагындагы киң эскәмиягә барып утырды, тезләренә таянып, башын түбән үк иде. Гөлнисаның гәүдәсен алгач та хатыннарның акрын гына сөйләшүе Моназыйрга бик ерактан ишетелгән кебек булды.

— Хәйрелбәшәркәй, элгәре коенган, балакай.

Монысы Сәрвия тавышы иде.

— Тәне чиста булуын теләгән инде, мәрхүмәкәй.

Монысы Рәйсә тавышы бугай.

— Каян шушындый сүс бавын тапкан диген.

— Баудамы хикмәт...

Боларының кемнәр тавышлары икәнлеген аермады Моназыйр.

— Кем инде мунча матчасына тырма теше кагып куя, йә инде? Асылынып өчен каккан кебек бит бу.

Монысы тагын Сәрвия тавышы иде.

Ләкин Моназыйр моңа каршы аклану эзләмәде, чөнки хатыны вафатына үзен һич тә гаепле санамый иде.

Гөлниса-Хәйрелбәшәрне хатыннар өйгә үзләре генә алып керделәр. Моназыйр монда да булышмады, салкын йөрәкнең хәзер дә эрер исәбе юк иде. Мәрхүмә Гөлниса җирләнмәгән килеш, ягъни, өлкәннәр элегрәк әйткәнчә, мәет өстендә аның вафатына кемнедер гаепле санау гөнаһ саналыр иде. Шулай да Моназыйр — Таукаш дөньясына моннан илле ел элек йодрык күрсәтеп килеп кергән Моназыйр Шәгаетов — мунча матчасына тимер тырма тешен үз кирәгенә какмаган булып чыкты. Ваһим оста да, Сәрвия карчык та дөрес бәялиләр:

— Кирәкмәс төшкә чөй сукмыйлар...

— Елгасыз төшкә күпер салмыйлар...

*1987–1989*

# Тар тыкрык сукмагы

Назыйм Айгузин Казанга баручы бер поездны уздырып җибәрде. Утырмавының сәбәбе ашыгыч шөгыле булмаудан түгел анысы, мәхшәргә тартым бу заманда ялгызакның да чират көткән эшләре бихисап. Поездга утырудан тотып калган сәбәп — көне гаҗәеп, шәһәргә һич тә кайтасы килмәслек. Менә әкәмәт — Назыйм Айгузинның кәефенә һәм кылырына табигать тәэсир итсен инде, әй! Мондый хәлнең булганы юк иде ләбаса!

Кар бөртекләре ярышып очалар. Күбесе ябалак кар бөртекләре. Шулары җил тынып торган арада җиргә кунакларга өлгерәләр дә, болытлар арасыннан кояш куанып чыккач, күзләрне сөендереп җемелдиләр. Җиле дә сәер — бер мәлгә кайдадыр посып тора да аннары йөзгә иркәләп кагыла, тагын тына һәм элекке юнәлешенә каршыдан шәбәеп исәргә тотына. Өермә сыман булып акрын бөтерелә башлый, кинәт дуамалланып, кар бөртекләрен югарыга кире алып менеп китә. Тагын шып туктый, һәм кар бөртекләре җиргә кунып җемелдәргә ашыгалар — кояш берүк чыга күрсен. Хәзерге заманда фән-техниканың котырынып үсүеннәнме, әллә дөньякүләм алга сикерештә безнең илнең читтә йокымсырап торуыннанмы, көн итү табигатьнең шушы манзарасына охшаш: кояшы-болыты, гарасатынлыгы бергә буталган; яктысын болыт каплаган, рәхәтен гарасат күмгән чаклары ешрак әмма.

Айгузин, Обсерватория тукталышының поездга утыру мәйданчыгыннан төшеп, урманлы тау итәгендә дачаларга илтүче сукмакка керде. Туктады, дачасына кире бару нияте юк иде. Әнә кар ява. Җиле, әйе, сәер. Өермәсе әлегә сабый кебек, көчсез. Кояш куана. Ябалак кар бөртекләре җемелди. Назыймга үзен табигатьнең сихри үзгәрүчән манзарасы эчендә тою рәхәтлек бирде. Югыйсә ул табигатьтәге һәм дә яшәештәге тиз үзгәрешләргә мөкиббән китмәүче кеше һәм бу гадәтенә яшьтән күнеккән, мондый битарафлыгыннан зыян күргәне дә булмады. Аһ орып каңгырмавың, ыгы-зыгыга ашкынып тыкшынмавың, онытылып шатланмавың хәерле — шушы кагыйдәгә табынып яшәде Айгузин. Һәм начар яшәмәде.

Яшьлегендә күтәрелеп бәрелгән чаклары булгалады булуын. Ләкин шунда ук сүртенде. Вакыйгадан бөтенләй читтә калгалады. Ләкин аны юксынмадылар. Димәк, тормышның котыпларына ук барып чыгу хаҗәт түгел, яхшы-яманның уртасында торуың хәвефсез. Михнәт дәрьясын кичмәде, рәхәт диңгезендә йөзмәде Назыйм Айгузин — хискә бирелүчеләргә булсын бу котыплар.

Табигатьне тоеп, кинәттән хәзерге рәхәтләнүенә бик тә гаҗәпләнде ул. Көтелмәгән уйлар өермәсен һәм, гомумән, хәзерге халәтен, табигать кешене сөендерү җаен таба белә икән, дип аклады. Шулай, табигать сарсар-давыллар да куптара, әмма мон-

дый явызлыкны сирәк — адәм баласының әшәке гамәленә җавап итеп кыла. Шулай, юньсезлекне беркайчан да гафу итми табигать, кырыс җәзасын бирә. Ә давыллар кешеләр тормышында ешрак кузгалучан. Һәм аларны кешеләр бер-берсенә ачу тотып дулаталар, дип күңеленнән нәтиҗә ясады Назыйм Айгузин. Шулай, кешеләр бер-берсеннән гафу үтенешәләр. Ләкин яраны гафу савыктыра алмый. Кылган юньсезлекләре өчен адәм заты арасында җәзадан котылуның тагын да гөнаһлырак әмәлләрен табучылар күп. Димәк... димәк, табигатьне тормыш итүгә охшату дөрес түгел икән, алар бер-берсенә һичкайчан тәңгәл килмәячәк. Һәм Назыйм Айгузин, тирән сулап, үзалдына әйтеп куйды:

— Дөнья, диген...

Чираттагы поезд Обсерватория тукталышына ташкын башыдай ыжгырып керде, соңламавына сөенүедер. Уртадагы вагоннарда гадәттә кешеләр азрак була, һәм Назыйм бишенче вагонны сайлады. Бу тукталышта төшүче дә, утыручы да башка юк иде.

Вагонда ике генә кеше. Унсигез-егерме яшьләр тирәсендәге кыз, тәрәзә яңагына башын куеп, вагон стенасына терәлгән төенчеккә таянып, барыр уңайга аркасы белән утырган. Башындагы ак шәле, ябалак кар диярсең, җемелди иде — монысын Айгузин беренче булып күрде. Кызның каршындагы киң җилкәле ир, зур гәүдәсен тулгай-тулгай китереп, нигәдер кыбырсына, йонлач бүреген башыннан суырып алгач, озынча чәчләре күперде дә зур карбыздай башы түгәрәклеген җуйды. Ул кар көрәгедәй кулларын буташтырып нидер сөйли, Назыйм аның сүзләрен ишек катыннан ишетмәде. Кыз җавап кайтармый, ир кешенең сөйләвен тыңларга теләми, карашы тәрәзәдә. Тирән, бик тирән итеп сулады, күзләрен йомып торды кыз, түгәрәк йөзе кинәт агарды да тагын кызарды. Әтисе белән кызы, ахры, болар, дип уйлады Айгузин, ир кешегә, күзен-йөзен тулаем күрмәсә дә, кырык биш яшьләр биреп куйды. Кызын нигәдер әрли бугай әти кеше, ачуланыштан ерак торуың хәер, дип, ишек катындагы каршы як эскәмиягә утырды. Тик әти кеше баласына әйтмәскә тиешле сүзләр ишеткән кебек булды Назыйм. Колакларын торгызып тыңлады. Сөмсез сүзләрне аермачык ишетте.

— Әйткәнне тыңла, җүләр! Йөз тәңкә аяк астында ялтырап ятмый синең!

Ир кешенең куллары кызның күкрәкләренә кагылды, кыз йөзен чытты, гәүдәсе җыерылып алды, ләкин ир кешенең кармалауларына-кымтырыклауларына каршы хәрәкәт ясарга көче җитмәде кебек, урынына бәйләгәндәй утыра бирде. Кинәт кычкырып җибәрде:

— Ерткыч!..

— Кыланма! Юдинода төшеп калабыз. Анда минем таныш

яши. И йөз тәңкә — синеке! Иелеп аласың да юк. Яратам тулуы җиткән хатыннарны! Әйдә, миннән булсын яхшылык — йөзне азсынсаң, йөз дә...

— Кит!..

Назыйм атылып килеп җиткәндә, ир кеше, кызны почмакка кысрыклап, аның корсагын иләмсез олы кулы белән туктаусыз капшый-кыскалый иде. Айгузин, бер мәлгә катып торгач, авыр сумкасын утыргычка куеп, бөтен көчен җыеп, көмәнле яшь ханымга бәйләнүче бәндәне кулыннан каерып торгызды.

— Син... син акылыңнан шаштың мәллә?!

Үзеннән бер башка озын, кабарынкы яңаклы бу кешегә кырык биш яшь биреп ялгышкан икән Айгузин. Кырыкка да җитмәгән булыр көмәнле хатынны мәсхәрәләүче. Каушап калмады ул, уттай янучы күзләрен кыса төшеп, Назыймга карады; гаҗәпләнеп, башын як-якка кыйшаткалады, Назыймның колагына иелеп пышылдады:

— Кулыңны ал, абзыкай.

— Алмыйм!

— Тәрәзәдән очасың бит хәзер! Кулларың канат урынына кирәк булыр.

Боларны Айгузинның йөзенә өреп әйтте.

— Очмыйм! — Назыйм тегенең кулыннан кысыбрак тотты.— Ычкын моннан! — дип, көче җитмәячәген белсә дә, аралыкка таба тарткалый башлады.

— Картлач, юньләп әйткәнне аңламыйсың, ахрысы. Син Сәвади Сайгушевның юлына аркылы төшмәкче буласың бит!

— Бернинди Сайгушевны да белмим мин! Ә Сәвадинең каралык икәнен беләм! Менә мин — Назыйм Айгузин, хәзер сиңа сарсар ясыйм, давыл-өермә куптарам!

Назыйм картның кулы кинәт хәлсезләнде, Сайгушев аның беләгенә кырлы тимер белән суккан кебек булды, ләкин Сәвадинең кулында әйбер күренмәде, ул кулының сөялле кырын Айгузинның борын төбенә китереп терәгән иде. Назыймның кулы Сәвади беләгеннән үзеннән-үзе ычкынды. Картның эченә типте кебек Сайгушев, ләкин бу хәрәкәтне Айгузин күрмәде, ул эчен тотып бөгәрләнде.

Сәвади акрын гына:

— Озак такылдыйсың,— диде һәм Назыйм картны, култыкларыннан эләктереп, җиңел генә күтәрде дә, каршыдагы эскәмиягә дыңгылдатып утыртты.

Үзе китмәде, Айгузинның аңы кайтуын көтте. Карт башын күтәреп күзләрен ачкач кына, аңа тезен терәп утырды.

— Рәхәте уздымы?

Карт эндәшмәде.

— Сүзсез утыруың хәер. Мин бу буазны Юдинода алып төшәм,— дип, башын артка — көмәнле хатын ягына ташлады Сайгушев.— Урыныңнан кузгаласы булма!

— Кем син? Юлбасар...— дип сүзләрен көч-хәлгә әвәләде Назыйм.

— Ялгышасың, картлач! Юлбасар түгел, синең кебек ыгы-зыгы куптаручыларны юлга бастыручы мин.— Сайгушев куен кесәсеннән кызыл тышлы таныклык чыгарды, аны ачып күрсәтмәде, кесәсенә кире салды.— Ә бу асыл кошны — ул башын тагын артка ташлады — милициягә тапшырам. Фатир басарга җыенганда тоттым мин аны. Әле берәр фатирны талап та өлгергән булыр. Төенчегенә бауны аркылы гына салуын күрмисеңме әллә? Ашыгу билгесе бу.

— Булмас-с,— дип сузды Назыйм.— Ана булырга торган бер генә хатын да кеше әйберсенә кагыла алмый.

— Булмас, имеш! Ничек кенә булыр әле! Үз күзләрең белән күреп, үз колакларың белән ишетеп торырсың. Сине дә Юдинода алып төшәм. Тик әнә хәерче сумкаңны онытма.

— Булмас!

— Ә син моның булмаслыгын берничек тә исбатлый алмыйсың! Каракны тотучы мин. Аны ничек каптыруымны үзем генә беләм. Читләр әйберсенә кагылу корсаклы хатынга да тыела!

— Кем син? Игелексез икәнсең... һөнәрең юктыр синең. Һөнәр иясе игелексез була алмый.

— Һөнәремме? Бар! Акчалы кеше мин! Акчалы кеше!

— Шул көчсезне кыерсытырга соң... Ана булырга торса да, бала гына бит әле ул...

Айгузин каршы якта утыручы көмәнле хатынга карамакчы булды, ләкин ул турны Сайгушев зур гәүдәсе белән каплаган иде. Алар акрын сөйләштеләр, хатын аларның сүзләрен ишетмәгәндер, ишетсә дә, Назыйм картка булышырлык хәлдә түгел ләбаса ул.

Кинәт вагонны тутырып ачы тавыш ишетелде:

— Әни-и-и!!!

Көмәнле хатын, утыргыч терәгендәге сапка тотынып, ачыргалана иде.

Аны тулгак тота иде инде.

— Әни-и... Ай-й-й...

Хатын, ачы тавыш белән кычкыра-кычкыра, утыргычка ауды.

Назыйм Айгузин килеп җиткәндә, хатын күзләрен йомып ыңгыраша иде.

Поезд Юдинога җитеп туктады. Вагонга кешеләр керде. Ирләр, хәлне аңлап, кире борылдылар, күрше вагонга күчтеләр.

— Балам ла, шушы хәлеңдә ничек юлга чыгасы иттең соң? — дип, көмәнле хатын янында кайнашты бер карчык.— Хәзер, балам, хәзер, Алла боерса, барысы да әйбәт булыр. Балакаем ла... Читкәрәк китегезче, бүтән вагонга күчеп бетегез, миңа булышырга берегез җитә. Менә син кал. Ә син нигә монда әле? — дип эндәште карчык аннары Сайгушев суккан уң ку-

лын изүенә тыгып, сул кулы белән эчен тотып торучы аптыраган Назыйм Айгузинга.

— Мин... Мин — аның бабасы...

— Бабасы булсаң да, әнә теге башка ук бар. Кызыкаем,— диде карчык бала тудырырга җыенучы хатынга,— менә шулай ят әле, яме. Ярый ла үземә очрадың. Бәхеткәең бар икән. И-и акыллы да соң син... Тырыш, яме, кызым... Мин Мөхибә әбиең булам. Кияүгә чыкканчы ук кендек әбисе идем инде мин. Үзем дә олы малаемны урак урганда таптым. Синең дә беренче балаң малай булырга охшаган. Кызым, кызым, тыныч кына, яме... И-и рәхмәтләр яугыры...

Сәвади Сайгушев, Казанга җиткәнче дә, вокзалда «ашыгыч ярдәм» машинасы көткәндә дә, Назыймның күзенә чалынмады. Аның Юдинода төшеп калуын күрмәгән иде Айгузин.

«Ашыгыч ярдәм» машинасына Мөхибә белән Назыймны утыртмадылар, яшь ананы сабые белән кайда урнаштырачакларын әйттеләр, хәлләрен шунда килеп белерсез, өч-дүрт көннән чыгарырлар да, оныгыгызны каршыларга әзерләнегез, диделәр. Шулай итеп, кырык ел хатыны белән яшәп бер генә баласы да тумаган Назыйм Айгузин бабай исеме алды. Әмма моны баланың анасы белмәде, моңа «ашыгыч ярдәм» машинасын бергәләп озатып калучы Мөхибә генә чынлап торып ышанган иде.

— Хатын-кызны шундый хәлендә юлга алып чыгалар диме инде?! — дип әрләде Назыймны карчык.— Гомер иткән кеше ләбаса син!

— Мин... ни, кем... әбекәй...— дип тотлыкты Назыйм, карчыкның әрләвеннән акланырга тиз генә җавап таба алмады.

— Мөхибә дим бит инде үземне! Хәтерсез икәнсең.

— Исемеңне мин ишетмәгән идем. Башкага әйткәнсеңдер. Эш болай бит әле. Бабасы түгел мин бу яшь ананың.

— Ничек, ничек?! — дип башын алга сузды Мөхибә. Муенын нәрсәдер кыскандай булды да ияген каймалы, инде борынгыга әйләнеп бара торган тунының якасына ышкыды.— Бабасы булмагач, кеме соң син аның? Ире түгел ич инде. Хәер, Ходаем сакласын, имансызлар күбәйгән хәзерге заманда...

— Беркеме дә түгел мин аның.

Һәм Айгузин бу вакыйгага ничек тап булуын сөйләп бирде.

— Ай-й Аллам икән лә! — дип каушап төште Мөхибә. Нинди карарга килергә, ни эшләргә белмәде, кызыл шакмаклы ашъяулык белән кысып бәйләнгән төенчеген бер кулыннан икенчесенә күчергәләде.— Нигә башта ук әйтмәдең моны? Нишли ди ул бала ялгызы? Кеме дә булса бар микән инде аның? Казаннныкы микән соң ул? Башта ук әйткән булсаң, докторларның ай-ваена карамас идем, калмас идем, ичмасам, үзләреннән. Каян табам ди инде мин аларны? Бу Казанда йөри дә белмим бит мин. Автобус белән Сабамнан киләм дә трамваена утырып вокзалына төшәм, аннары поезд белән Юдингә, оныкларым

янына. Кайтыр юлым тагын таныш. И-и Ходаем ла! Син... исемеңне ничек диден әле? — Назыйм фамилиясен дә кушып әйтте.— Син, Назыйм карт, әйтәм ич, гомер иткән кеше ләбаса үзең! Нигә җибәрдең аларның үзләрен генә? Каян табам ди инде мин аларны? — дип баягы сүзләрен кабатлады Мөхибә.

— Алар киткән бала тудыру йорты... Бишбалта ягындарак булырга кирәк.

— Шуны да тәгаен белмисең, ичмасам! Шәһәрдә яшәп!

— Белеп бетермим шул. Чөнки бала табу йортларына йөргәнем булмады. Гомеремә.

— Тупаслыгы тагын! Синнән бала таптырган кеше юк! Алар киткән йортны күрсәт кенә син!

— Анысы табылыр ла. Ниятенә керешсәң.

— Монысы ни дигән сүз тагын? Ике... ике сабыйны ярдәмсез калдырмакчы буласың мәллә? Әйдә, тап! Илтеп куй мине шунда! Ходаем ла, бүген кайта алмам, ахры, Сабама. Кичке автобуска өлгерсәм инде. Тик мине шушында хәтле озатып куярсың.

Карт, күзләрен читкә текәп, сүзсез тора иде. Битарафлыгы сизелә иде аның — гаҗәп холык, әй, әле күптән түгел генә яшь ана язмышы өчен ихластан кайгырган кебек иде югыйсә.

— Нигә урыныңнан кузгалмыйсың? — дип тезә бирде карчык.— Тап, дим бит! И-и Аллам ла, өемне бер генә көнгә дип калдырып киткән идем, күршекәем көтеп интегер инде. Нигә терәлеп каттың? Җәһәт бул, дим!

— Кул...

— Йөрергә аяк кирәк, кул түгел! Ә-ә, кулыңа ни булган соң?

— Сызлый,— дип, уң кулының беләзеген ышкыды Назыйм.— Картлык галәмәтедерме...— Кулының Сәвади Сайгушев сугуыннан соң авырта башлавын әйтергә теләмәде.— Картлыкны сиздереп аласы итте бугай,— дип шаярткан булды Айгузин.

— Җитмеш яшеңнән сызлануга биреләсең, адәм көләр! Мин менә сиксәнне узып та сызлануны белмим. Аллага шөкер!

— Күрәзәче, ахры, син, Мөхибә әби,— дип авырдан елмайды Назыйм.— Ел башында җитмешемне бәйрәм иттем. Ялгызым гына.

Мөхибә төенчеген сул беләгенә элде, Назыймның сызлый торган кулына үрелде, ләкин кулын кире тартып алды.

— Ходаем, кичерә күр,— диде ул, сүзләрен дога укыгандай акрын гына әйтте.— Кичерә күр. Хәләлемнән соң ирләр белән күрешкәнем дә булмады, үз тәнемә дә кагылдырмадым. Әмма, Ходаем, синең Назыйм колың бик тә сызлана, йөзенә чыккан. Кичер гөнаһымны, Назыйм колыңа изгелек кылырга теләвемне кабул ит.

Карчык йомшак бармак битләрен картның кан тамырлары күпергән беләзегендә сыйпагандай шудырып йөртте.

— Картлык галәмәте түгелгә охшаган бу...— дип, Назыймның кулына якынрак иелде Мөхибә.— Түгел. Сәбәбе башка. Авыртуы менә шушыннан тараламы?

Назыйм тешләрен кысып баш какты.

— Карт сөяккә шушы гына җитмәгәндер,— дип, кулын алды Мөхибә.— Сөяге чатный башлаган беләгеңнең. Йа Ходаем, нинди юлга чыктым булды соң мин?.. Монда сиңа килешле дәвам юк шул,— диде карчык, төенчегенә кагылды.— Әйдәле, тизрәк бәбәй тапкан наныебыз янына барыйк әле,— дип, тагын кызуланыбрак сөйләүгә күчте ул.— Шунда синең кулыңны да бәйләтербез.

Айгузин каршы төшеп сүз әйтергә җыена башлауга ук, Мөхибә аны ымлап туктатты.

— Бәйләрләр, бәйләрләр,— диде карчык.— Докторлар изге җанлы була, бала табу йортларында иң шәфкатьлеләре эшли аларның.

...Бала табу йортында яшь ананың һәм сабыеның хәлләре ярыйсы булуын, инде ананың өенә хәбәр ителүен әйттеләр. Яшел Үзән шәһәреннән икән яшь ана, паспорты үзе белән булган, өенең адресын һәм телефон номерын, кәгазьгә язып, кесәсе саен салган икән, шуны үзе әйтеп аңлаткан ди докторларга. Балакай, акылы җиткән, күрәчәгенә алдан хәстәрләнгән.

— Сабыен яшертен табарга җыенган кебек бит әле бу. Әллә соң ата-анасыннан...— дип нәтиҗә ясый башлаган иде Назыйм, тик Мөхибә аны шып туктатты.

— Ничек телең бара? Гомер иткән адәм ләбаса син! Тузга язмаганнарны уйлыйсың ич! Уйлавы гына җитмәгән, авызын тутырып әйтә өстәвенә!

Карчык кинәт өченче затка күчте, монысы Айгузинны мәрхәмәтсез итеп санамаудан иде. Ләкин Назыймның холкы шактый кытыршы булуын, кайчак үҗәтләнүдән тыелып калмавын белми иде ул.

— Гомер иткән булганга андый фикергә килүем түгел,— диде Айгузин, тавышы Сәвади Сайгушевны беләгеннән тартып торгызгандагыча көр чыкты.— Минем гомернең беренче яртысында уйнаштан бала табу хурлык санала иде. Соңгы заманда гына атасыз бала табу батырлыкка әйләнде.

— Атасыз бала булмый,— дип, Назыймның сүзен юкка чыгармакчы иде Мөхибә.

— Була! Хәзерге замандамы...— диде дә кинәт туктады Айгузин, поездда Сәвади Сайгушев белән булган вакыйганы сөйләргә җыенды.— Көмәнле хатынны...— дип дәвам итмәкче иде, тик тагын төртелеп калды.

Карчык, шул тукталудан файдаланып, сүз сөрештә өстенлекне тагын үзенә алды. Моңарчы таныш түгел ике кешенең сөйләшүе ара-тирә сүз көрәштерүгә охшап китә иде. Картлыкларында аларга балаларча самимилек кайтканмы, әллә алар

ачык күңеллелекне беркайчан да җуймаганнармы — хәзергә моны тәгәл бәяләп булмый иде.

— Минем янда ямьсез сүзләр әйтәсе булма,— диде Мөхибә, тавышында ачулану төсмере юк иде, шулай да ул йомшак сүз әйтүне тиеш тапты һәм шуның белән Назыймның кабынып китүен тыйды.— Яме.

Карт эндәшмәде. Бала табу йортының ишек төбендә алар тагын бераз таптанып тордылар. Яшь ананың тәрәзә янына килергә әлегә хәле юклыгын шәфкать туташы, ишек ачып, икенче тапкыр искәртте, салкында туңып тормаска кушты, ананың өлкән юлдашларының монда килүләренә сөенүен һәм рәхмәтен җиткерде. Әмма Мөхибә карчыкның туны җылыны шәп тота, аның башында мамык шәл, аякларында яңа баскан киез итекләр иде. Назыймның, шәфкать туташы салкын турында кисәтүеннән соң, тәне чымырдап алды, ул аякларын бер-берсенә какты, ботинкалары шакылдар хәлгә җиткәннәр икән. Табигатьнең Обсерватория тукталышындагы сихрилеген инде яшерүенә, кар бөртекләренең шаярышып очмауларына һәм ара-тирә өермәдәй бөтерелмәвенә хәзер генә игътибар итте ул. Чалт аяз һәм кояш төштән күп авышкан иде. Айгузин сәгатенә карады. Ике тула.

— Шәһәрдә йөри белмим, дисең. Әйдә, автовокзалга илтеп куям,— диде Назыйм.— Бир төенчегеңне, үзем күтәрим.

— Шушы төенчекне дә күтәрмәслек мәллә мин? — дип, баскычтан төшә башлады Мөхибә һәм баягы фикерен куәтләүгә күчте.— Ямьсез сүзләреңне оныт. Матур сүзләр ишетү кешеләргә дәва икәнлеген бел. Юньлегә өйрәнергә яшең узмаган.— Шаяртуы түгел иде.— Бала тапкан ананың исемен сорарга онытканбыз менә. Озын гомер итеп шуңа да башыбыз эшләмәгән. Балакай, бәбәен юлда табу ихтималын сизгән инде, биләү әйберләрен әзерләгән, бүтән чүпрәк-чапрагы да мулдан иде.

Айгузин бүлдермичә тыңлады.

— Өендә кеше югында чыгып киткәндер. Сәбәбе дә, Назыйм энем, син әйткәнчә, ямьсез түгелдер. Хатын-кыз, Назыйм энем, ераккарак карап уйлаучан була. Аның күңеле тирәнрәк, күпне сыйдыра. Аның күңел түре — оҗмах тәхете. Шуны аңлап җиткерми күп ирләр,— дип, ямьсезлек турында башлаган сүзеннән шушы нәтиҗәгә килеп чыкты Мөхибә.— Шулай, энем,— дип, Айгузинга исеме белән эндәшүне ешайтты сәфәрче карчык,— болытлардан биек таулар бар. Надан кеше түгелсең, таулы якларны барып күргәнең булмаса да, укып беләсеңдер. Болытлардан биек таулар күп. Күп...

Троллейбус тукталышына җиткәч, Мөхибә Назыймга озата йөрмәскә кушты.

— Туп-тулы сантый түгел лә мин,— диде ул.— Бер узган юлымны онытмыйм. Урманнарыбыз куе чакта да адашмадым. Их-х, урманга җиләккә йөреп тә карадым соң! Яшь чакта. Хә-

зер дә баргалыйм, кыш буена җитәрлек итеп киптерәм кура җиләген. Каен җиләген кайнатам, анысы да оныкларыма күчтәнәчкә җитә. Ризык, әрәм-шәрәм итмәсәң, бәрәкәтле була. Озатмасаң да, адашмыйм,— дип, тагын баштагы фикеренә әйләнеп кайтты карчык.— Вокзалда кайсы трамвайга күчеп утырасын беләм. Кулың тиз сихәтләнә күрсен. Адашмыйм, Алла боерган булса. Вокзал янындагы таш йортларны күрүгә танып алам мин.

Таштан түгел, кирпечтән алар, дип төзәтмәкче иде Назыйм, элеккерәк заманда мондый йортларны шулай атау исенә төшеп, үзе дә борынгыга әйләнеп барган карчыкның тасвирына сөенеп куйды, сүз әйтмәде. Ул Мөхибәне автовокзалга тикле илтте. Карчык моңа инде каршы төшмәде, һәм озатуы әйбәт тә булды. Чөнки кассада билет юк, диделәр. Алай да Айгузин, сугышта катнашучы булуын искәртеп, соңгы рейска билет алды, моның серен сиздермәскә булды. Әмма Мөхибә өнле карчык, Назыймга билет бәясен тиененә хәтле түләде дә, офтанып:

— Шулай инде бездә тәртип,— диде, күңеле сыкрануын яшермәде,— сугышта калган кешенең тиңенә кимсетебрәк карыйлар. Югыйсә без толларга игелекле мөнәсәбәт булырга тиеш иде. Теләп алынган толлык түгел... Һай, тол калу сугыш ярасыдай лабаса!.. Шөкер, сугыштан исән кайтучыларга кайбер өстенлекләр бирделәр. Азаясыз шул сез дә. Сугыш тол иткән хатыннар да азая.

Назыйм моңа өстәргә сүз тапмады, хатын-кыз белән сөйләшү җайларын оныта бара инде ул — хәләле вафатына өч елдан артык вакыт узды. Айгузин буфетта кофе эчәргә тәкъдим итте.

— Аягүрә ашау гадәтем юк,— диде Мөхибә.— Ризыкның туклыклылыгын җуйдырырга оста андагылар. Юл чатында ризык кадерен бетерүчеләр алар. Карыным ачса да, түзәм мин, түзәм. Ачлык кичергән кеше. Аннары да килеп, унике яшемнән бер генә көн дә уразамны калдырмадым. И-и заманалар, диген...

Назыйм иртәнге якта үзенең дөнья, диген, дип әйтеп куюын хәтерләде. Карчык заvotаманы күплеккә әйләндерде, күргән газап-михнәте дә күплектә, ахрысы, бу әбекәйнең, дип уйлады Айгузин. Шулай да әби бик бетерешмәгән, таза, озын гомерле нәселдән булыр, гәүдәсен туры йөртә, йөрүе акрын акрынын, хәер, сиксәндә түгел, җитмештә дә чатыр чаба алмыйсың. Назыйм, әңгәмәне тоту җаен тапмаса да, Мөхибәне утыртып җибәргәнче көтәргә булды. Карчык үзе дә моңа риза иде, белмәгән кешеләр арасында калганчы, юл матавыкларын бергә күргән карт белән сөйләшеп утыруны тынычка санады, ә аның якташлары автовокзалда әлегә күренмәде. Картның сүзгә катнашмавына борчылмады ул, сөйләвен белде.

— Үзгәрде заманалар, нык үзгәрде, Назыйм энем. Бигрәк тә

яманы — кеше гомерен кисүне чүпкә санаучылары ишәйде. Партия дигәнегезнең дә гөнаһы зур шунда, тотанаклы эш итә белмәде партиягез, барысы да әйбәт, дип мактанудан узмады.

Партия өчен мин җавап бирмим, мин партия әгъзасы түгел, партиядән күптән чыгарылган кеше булам, дип уйлады Айгузин. Карчыкның фикеренә каршы төшмәсә дә, бу кадәресендә үзен гаепсез санады. Ләкин өнле карчык бөтен гаепне башкалар өстенә ташларга җыенмаган икән.

— Үзебез дә гаепле,— диде ул һәм,— үзебез күбрәк тә гаепле,— дип кабатлады.— Яшьләрне гомер-гомергә өлкәннәр тәрбияли килгән. Без шушы изге гадәтне санга сукмадык. Ялкавын да, юлбасарын да үзебез үстердек. Үзебез үк фатиха биргәнбез аларга. Кешене тәрбияләүдә партиягезгә ышанып ят инде, йә! Ышанычсызлыгын күрәләтә белә торып бит әле! Үзебез гөнаһлы. Үзебез! — дип ачыргаланды Мөхибә.— Намазыңны үз балаңнан яшереп укы да, шул баладан игелек көт, аңа өмет багла инде, йә?! Коммунист булып китте малаем. Әнисен догадан тыеп.

Карчыкның сөйләвеннән аның электә кем булуын абайлыйсизенә алмады Назыйм. Гади авыл хатыны, дип нәтиҗә чыгарыр иде, Мөхибә укымышлы фикер йөртә; зур урында эшләгәндер, дияр идең, гомере буе дин тотуын искәртә. Диндарлар власть тирәсендә яшертен дә кайнаша алмадылар лабаса — власть кешеләре, әле сугышка чаклы ук, белгән догаларын капылт оныттылар. Дөнья йөзендә иң йогышлы чир — власть, дигән бугай бер акыл иясе. Моны Назыйм Айгузин үзе кичерде. Түрәлеккә күтәрелә иде ул заманында, шул чакта дин кануннарын күңеленнән җил очыртты. Хәтәр җил булган икән, хәзер Назыйм бисмилласын да ахырынача хәтерләми, тырышып карасa да, яңадан ота алмый. Өлкәннәр мәҗлесләренә туры килгәндә, амин тотуы да иреннәрен селкеткәләп, яңакларын калтыравык сыпыргалаудан узмый. Ә Мөхибәнең ихластан диндар булуына шик юк, әнә, хәзер дә, шушы шау-шулы бинада да, догасын Назыйм ишетерлек итеп кабатлый. Тик аның нәрсә укуын карт белми, диндә шыр надан ул. Гыйбадәт кылучыны бүлдерергә ярамавы, шөкер, әдәп кагыйдәсе булып күңеленә сеңгән. Шуңа күрә Мөхибәне, карчык дога укыганда гына түгел, ә дөньяви хәлләр турында сөйләгәндә дә, бүлдерергә базмый Назыйм.

Мөхибә, догасын тәмамлап, бераз тын утыргач:

— Әллә ниткән борчулы юлга чыкканмын икән бүген, Ходаем,— диде.— Догаларымны ишек бавын тотар алдыннан да кат-кат кабатлаган идем югыйсә. Аллаһы Тәгалә кабул итмәгәндер шул. Үзем сизмәгән гөнаһым булды микән соң... Шулайдыр да, бу озын гомердә гөнаһ та кылганмындыр. Заманы хак юлдан тайпылдырырга гына тора бит, өстәвенә юл дигәне гел дә тайгак. Ходаем, инде сәфәремнең калган өлешендә хә-

вef-хәтәргә юлыктырма! Туган туфрагыма исән-сау кайтырга язсын.

Карчык тагын пышылданды. Назыйм сәгатенә күз төшерде.

— Каян тап булдым бу акылын җуяр карчыкка, дип офтанасыңмы? Теләсә ни сөйләнә, дисеңме? Кеше турында алай начар уйлама,— дип елмаеп алды Мөхибә, әмма Айгузин аның елмаюын, бу карчыкның йөзенә күтәрелеп караган арада булса да, бөтен самимилеге белән күрмәде, сикәлтәле җыерчыклар елмаюның балкышын телгәләгәннәр иде.— Сәгать чамасы бардыр шул әле автобус китәргә,— диде дә Мөхибә, тәрәзәгә караш ташлады.— Әйе, сәгать өч тирәседер.— Ялгышмый иде карчык, һәм аның төгәл сизенүе Назыймның баягы нәтиҗәсен ныгытты, чынлап та, күрәзәче бит бу Мөхибә әбекәй, дип уйлады. Карчык исә Назыймның мондый бәясен белми иде, сүзен үзенчә сөрә бирде ул.— Сәгать хәтта төгәл өчтер. Кояшның торышы шулай күрсәтә. Төш җитәрәк капылт аязды да куйды, Ходаем. Бәбәйне биләүләп бетергәндә, чалт аяз иде инде, рәхмәт яугыры. Исән-имин үсә күрсен сабыем, ата-анасына игелеге тисен. Хәерле сәгатьтә тугандыр, бәбкәм. Яшәргә атлыгып тора, наныем. Илгә иләмән булырлык кодрәт һәм гакыл бирсен балакаема.— Һәм Мөхибә: — Бар, кайт, Назыйм энем,— дип сүзен кинәт бүтәнгә борды.— Әле докторларның эш сәгате чыкмаган, күрен үзләренә, кулыңа шифалы дәвасын табар докторлар. Мин моннан автобуска күземне йомып та чыгып утырам. Аннары бит, Назыйм энем, инде Саба кешеләре килә башлар, үзләре үк мине күреп алырлар. И-и якташларымны сагындым да шул инде... Рәхмәт яусын сиңа, Назыйм энем, мәрхәмәтле җансыңдыр.— Мөхибә тагын тәрәзәгә карап алды.— Шөкер, кояшның йөзе сөйкемле тора, ачуы юк. Шәт, ай буе хәтәр хәлләр булмас. Бүген төнлә Алланың рәхмәте белән искечә февральгә керәбез. Ходай тынычлыгын бирсен. Ярабби...

Назыйм врачка күренә кайтты. Рентген бүлмәсе эшләми иде инде. Анда керергә иртән килергә куштылар, сөяк чатнаган булуы бик тә ихтимал, диделәр, нәрсәләрдер сөрткәләп бәйләделәр. Кулының сызлавы басылды. Ләкин өенә кайтып чишенгәндә, сызлау тагын сиздерде. Тулы чәйнекне ялгышып уң кулы белән күтәргәч, Назыйм ыңгырашып ук куйды. Беләгендә елан угы кармалана кебек иде.

Табынын җыештырып бетергәндә, ишек кактылар. Ике тапкыр. Кыңгырау шалтыратмыйча, ишек төя, ят кеше инде, дип уйлады Назыйм. Гадәтенчә, ишек шакучының кемлеген сорамыйча, йозакны ачмакчы иде, кинәт шөбһәләнеп, тишектән карады. Ишек төбендә, бит мускулларын уйнатып, Сәвади Сайгушев тора иде. Айгузин каушады, башында төрле сораулар кайнашты: нигә килгән бу, ничек тапкан, ни кирәк аңа, инде кулны имгәтүе җитмәгән, әллә нияте тагын да әшәкерәкме?.. Шулай да тавышын танытмаска тырышып үзгәртеп, башка сорау бирде.

— Кем кирәк?

— Син кирәк, Назыйм карт. Кызлар кебек тишектән карап торма. Ач.

Хуҗа кеше ачмаска сәбәп тапмады. Сайгушев, ишектән йәлт кереп, йозакны бикләп тә куйды, бу йортта булганы бар һәм йозак төймәсен кайсы якка борасын электән белгән кебек иде аның хәрәкәтләре.

— Каян... ничек... нигә...— дип тотлыкты Назыйм.

— Каянмы? Урамнан. Ничекме? — дип, өстеннән пальтосын сала башлады Сайгушев. Күзрикле, колакчынсыз, кепкага охшаш бүреген чөйгә элгәндә: — Таксига утырып,— диде.— Нигәме? Сине сагынып, картлач.

Айгузин ни әйтергә дә белмәде, Сайгушевны кертүенә үкенде, аны төрткәләп чыгарырга көче җитмәячәк, үзе чыгып качар иде — Сайгушев ишекне гәүдәсе белән каплаган. Нишләргә соң, каравыл кычкырырга микәнни, дип куркынды йорт хуҗасы, ләкин җебеп төшмәскә исәп итте.

— Юньсез икәнлегең әллә каян билгеле,— диде ул, Сайгушевны үткәрергә теләмичә, түргә уза торган ишеккә аркылы басты.— Юньсез бәндә булмасаң, яманлап йөрмәс идең. Чәй эчеп бетергәч килдең. Табын җыештыргач.

— Ә, әйе, чәеңне куй. Эчәсе килә. Әнә, вареньеларың сумкада. Карт башыңнан юлда әйберләреңне онытып йөрисең.

— Мин... мин сумкамны онытмадым! Син аны, мин күрмәгәндә, үзең алып качкансың! Син алдан төштең! Вагонга башка кеше кермәде. Син...

— Чамаңны онытма, абзый! Әйберләреңнең исән булуына сөен дә китергән өчен миңа зур рәхмәтләреңне укы. Шуны да искәртим, паспортны, кадерләп, куен кесәсендә йөртергә кирәк.

— Паспорт?! — дип кычкырып ук әйтте Назыйм һәм, дача базында иелгәч, паспортының кесәсеннән төшеп, аны сумкасына гына салуын хәтерләде.— Бир паспортны!

— Ашыкма, абзыкай. Соңрак бирермен. Чәеңне кайнат. Тамак кибеп бара.

Сәвади, Назыймны җиңел генә читкә этәреп, түр якны карап чыкты.

— Ике бүлмәле икән фатирың. Күршеләрең тасвирлаганча, ярыйсы. Нигә аптырыйсың? Аптырама. Мин монда көндез килеп киткән идем инде. Ялгыз кеше икәнлегеңне баштан ук әйтмәдең бит, гаеп үзеңдә. Шуңа күрә кемлегеңне элгәре күршеләреңнән сорарга мәҗбүр иттең. Назыйм абзый фатирга кертмәкче иде, дидем үзләренә. Ышандылар. Нигә терәлеп каттың?! Чәй кайнатырга куштым түгелме мин?! Саңгырау түгел идең кебек. Әйберләреңне чәлдерүдән куркасыңмы, шуңа күрә мине саклап торасыңмы? Кирәкми миңа синең иске-москың. Әйдә соң, алайса, чәйне бергәләп кайнатыйк,— диде Сайгушев һәм Назыймның җилкәсенә кагылып алды.

— Чәй кайнар әле ул,— дип йомшап төште хуҗа кеше.

— Барыбер яңартырга кирәк, һинд чәең бардыр, шунысын пешер. Сәвади Сайгушевтан әйбер кызганма, абзый. Кызганасы булма!

Сәвади чәйне үзе пешерде һәм чәйне үзенә генә ясады. Өрә-өрә коры килеш эчеп бетергәч, куе чәйне стаканга тагын яртылаш агызды. Назыймның дачасыннан кайткан кайнатмаларның һәркайсыннан берәр калак салып болгатты, нәрсәдер җитмәгәндәй, өстәл өстен күзләп чыкты.

— Бал тотарга кирәк, абзый кеше,— диде һәм Назыймның кулына ымлады.— Нигә бәйләдең аны?

— Сызлый.

— Катырак эләкте бугай шул.

— Сөяге чатнаган булмагае.

— Үзең гаепле. Кирәкмәскә кысылмый акыллы кеше.

— Оятсыз син! Имгәтүең җитмәгән, өстәвенә мыскыл итәсең! — Назыйм үзен белештермәс дәрәҗәдә калтыранды, өстәлдәге пычакка үрелде — гаҗәп, бүгенге хәлләрнең үзен бер котыптан икенчесенә ташлавына каршы тора алмый иде. Айгузинның кулы кинәт хәлсезләнде, Сайгушев аның кулын зур учына каптырып өлгергән иде. Алар күзгә-күз караштылар.

Бераздан Назыйм:

— Ай-й-й! — дип, нечкә тавыш белән сыкранды, гәүдәсен Сайгушев капкынындагы кулы ягына кыйшайтты, кулына карап өнсез торды, бармаклары агара иде, кан килми башлаган.— Ай-й! Җибәр...— дип үтенде карт, тавышы инде балаларча елак иде.

— Менә шулай, абзый, икенче кулсыз кала яздың бит,— дип, урынына утыртты Назыймны Сайгушев һәм, ниһаять, картның кулын ычкындырды.— Селкет кулыңны, бармакларыңны җәһәтрәк йөрт, кан тизрәк төшәр,— дип мыскыллап киңәш бирде.— Кызу канлы үзең, ә! Йә беләккә атылып ябышасың, йә сынык пычакка үреләсең.

Сайгушев пычакны Назыймга таба тәгәрәтеп җибәрде, картның күзләре шар булды, Сәвадинең пычакны ничек сындыруын күрмичә дә калган иде. Айгузин ярдәмгә чакырып кычкырырга җыенганчы, Сайгушев:

— Тавыш куптарма, картлач. Кычкыра башлаганчы, авызың томаланасын искәр,— дип кисәтеп өлгерде.— Минем яхшы киңәшемне тот. Кем әйтмешли, хур булмассың.

Йорт хуҗасына тын утырудан бүтән чара калмады, кулларын угаларга да курыкты ул. Бүген аны Мөхибә карчык игелек иясе булуы белән аз сөйләштерсә, Сайгушев дигән бәндә ерткычлыгы белән телдән яздырды.

— Озакка сузам. Миңа болай килешми. Дәрәҗә төшә,— дип тезде Сәвади Сайгушев.— Җавапларыңны кыска тот. Кулыңны күрсәтеп, милициягә бардыңмы?

— Мин...
— Җәвит иттеңме, дим?
— Юк.
— Дөрес иткәнсең. Мә паспортыңны.
Сайгушев паспортны эчке кесәсеннән имән һәм урта бармаклары арасына эләктереп чыгарды да Назыймга таба очыртып җибәрде. Карт тотарга өлгермәде, паспорт, су кранына бәрелеп, раковинага төште. Назыйм аны борылып алды, кая куярга белмичә әйләндергәләде, кулындагы бәйләүгә кыстырмакчы булды, паспорт анда сыймады.
— Кабаланма, картлач. Паспортыңны кире алмыйм, кирәге юк аның миңа. Малаең барлыгы язылган анда, ә мин — гомер буе өйләнмәгән кеше. Кирәкми миңа бала, артык шаһит. Минем балаларым юк. Малаеңны үзең белән яшәтмисең, ә, иркенлек яратасың, ә. Бу яктан миңа охшагансың.
— Малай... Малай юк инде...
— Ничек юк? Паспортыңа теркәлгән бит. Син паспорт алганда, унсигезе дә тулмаган булган. Картаеп беткәч, хатыныңнан бала таптыргансың. Бүтәннәрне кыерсытырга, хәтта изәргә яратасың икән, абзыкай. Ярамый алай. Юньле булу кирәк. Минем кебек.
— Малай юк инде...— дип тагын уфылдады Назыйм. Сайгушев ни кылса да, аңа сүзе белән дә каршы төшәрлек хәлдә түгел иде, хәтта бу ерткыч бәндәнең — Сәвади Сайгушевның юлбасар икәнлегенә шикләнми иде инде Назыйм — каршысында утыруына битараф иде ул.— Югалды малай...
— Югалыр шул! Синең кебек начар ата белән яшәргә хурлангандыр. Артыңа борылып карамыйча качарсың син карун яныннан!
Айгузин башын акрын гына чайкады, хәлнең ничек булуын Сайгушевка сөйләүнең мәгънәсезлек икәнен аңыша иде ул.
— Акчаң күпме? — дип уйларыннан сискәндереп айнытты хуҗаны юлбасар.
— Акча?.. Мин бай кеше түгел. Акчам юк минем,— дип, гәүдәсен турайтты Назыйм, ләкин торып басмады.— Син үзеңне акчалы кеше, дигән идең бит. Нигә сиңа тагын акча?
— Мин акчаң бармы, димим, күпме, дим! Фәлсәфәгә бирелмә. Минем акчада синең эшең юк!
— Синең дә минем акчада...
— Сораганмын икән, димәк, минем синең акчада эшем бар! Карунланма, югыйсә... Минем гадәтне төшенгәнсеңдер. Акча ул, абзыкай, коштан да битәр, очарга ярата. Аннары, белергә тиеш идең, акча беркайчан да кесәне тишми. Теге корсаклы хатынның да халат кесәсеннән нибары егерме бишлек кенә табылды.
— Кеше түгел икәнсең! — дип гырлый-гырлый әйтте Назыйм, аның Сайгушевка юлбарыстай ташланып, аны кисәкләр-

гә өзгәлисе килде. Моны беркайчан да эшли алмаячагын белеп, көчсезлегеннән гомерендә беренче тапкыр хурланды. Тыныч тормышта кеше җанын алырга кул күтәрергә теләве дә беренче мәртәбә иде.— Шул баланы шундый хәлендә тала инде, йә... Башка сыйдырырлык түгел! Фашистның фашисты син!

— Картлач, кызма. Акчаң кайда? Миңа чүпрәк-чапрак кирәкми.

— Комодта. Өске тартмасында. Үлемтеккә дип җыйган. Кит кенә тизрәк!

— Үләр чамаң юк әлегә синең. Тагын җыярсың.— Сайгушев кайнатма җимешләре төбенә утырган чәйне сөзеп эчте, стаканны өстәлгә тавышын чыгармыйча куйды, урыныннан торып, калын фуфайкасын итәгеннән тарткалап рәтләде. Алгы якка чыгып киенде, Назыйм янына кире керде.

— Тавышланасы булма! — дип бармак янады.

Түр бүлмәдән комод тартмасын ачкан тавыш ишетелде. Сәвади Сайгушев Назыйм янына әйләнеп тә чыкты, акчаны тиз тапкан, димәк. Йорт хуҗасы, ике терсәге белән өстәлгә таянып, учлары белән йөзен каплап утыра бирде.

— Кайгырма, картлач! Исәнлегеңә сөен! Кулың — вак нәрсә. Үзең гаепле. Ун сумыңны маяга калдырдым. Үлемтегеңә акча җыярга онытма. Ә мине оныт! Онытмасаң, мин дә сине онытмам! Милициягә хәбәр салма! Соңгы ялгышың шул булыр ату. Минем хакта берәүгә дә сөйләмә. Аң бул!

Сәвади Сайгушев дигән бәндә ишекне йомшак ябып чыгып китте. Назыйм ишек бикләргә дә тормады.

Озак утырды ул. Әгәр урыныннан кузгалса, Сайгушев тагын килеп керер кебек тоелды. Ниһаять, урыныннан җәһәтләнеп торды, ашыгып өстенә киенде, ишек тишегеннән коридорны озаклап карады, колагын куеп та тыңлады. Кеше йөргәнебарлыгы сизелмәде. Ачык йозакны ачмакчы булып бимазаланды, аны Сайгушев киткәннән соң бикләмәвен хәтерләп, сүгенә язып куйды, һәм күңеленә кинәт мондый уй килде — әгәр бандит урамда көтеп торса? Бардырыр ул сине милициягә! Милициягә түгел, теге дөньяга илтеп үк куяр! Инде караңгы төшкән, сине бәреп китүен берәү дә күрмәс. Бүтән әмәлен табарга кирәк, дип тынычлана төште Назыйм. Ашау бүлмәсенә керде, Сайгушев тоткан әйберләрне юмады, чүп чиләгенә ташлады. Тик пычак сыныкларын аннан кире алды. Ләкин аларның эшкә ярарлыгы юк иде, шуңа күрә чиләккә атып бәрде. Өс-башын алыштырасы итте, озын калын халатын киде. Аның җиңе киң дә иде, кул бәйләве күренерлек түгел. Назыйм телефоннан шалтыратырга күршеләренә кергәч, сиздерергә теләмәде. Белсәләр, Сайгушев турында баштанаяк сөйләргә туры килмәгәе иде. Мондый очракта милиция генә белүе хәерле. Ә күршеләр милициягә шалтыратуымны аңышачаклар бит инде, дип уйлады ул. Әгәр болай эшләсә?!

Айгузин башта төрле номерлар җыйды һәм шунда ук өзә барды яки бер цифрны җыеп бетермәде.

— Йә сөйләшә, йә җавап бирми,— дигән булды ул.

Һәм, ниһаять, хуҗаларга сиздермичә генә нуль икене җыйды. Төребкәне тиз алдылар.

— Ни хәлләрең бар? Исәнлекме? — дип хәйләсенә керешә Назыйм карт, ләкин дөрес шалтыратмыйсыз, дип, төребкәне куйдылар.

Айгузин тагын нуль икене җыйды.

— Нигә ташлыйсың төрепкәне? Син ич инде бу, тавышың синеке. Тиз генә килеп кит әле. Бик тиз,— дип ашыктырды карт. Бу сүзләре милициядә кызыксыну уятты бугай, әллә инде кызык тыңлыйсылары килдеме, инде төрепкәне ташламадылар.— Адресны онытмагансыңдыр. Шулай да кабатлыйм, язып ал.— Назыйм адресын әйтте, йортны ничек тиз табасын да өйрәтте.— Әйе, әйе, Назыйм абыең инде, Айгузин. Күптән күрешмәдек шул. Юк, җитмеш яшьлек юбилейны уздырмадым. Шатлыгын шатлык та, җитмеш яшь җитмеш инде, агай-эне. Аннары гел дә ялгызым гына яшим бит. Карчыгымның вафатын беләсең, малай турында да ишеткәнсеңдер.— Назыйм, бүлдерүләреннән куркып, тукталмыйча сөйләде.— Синең белән иркенләп утырасы килде. Сөйләр сүзләр күп җыелды. Шуңа күрә өзлексез такылдыйм менә. Киңәшәсе иде. Ашыгыч шул. Иртәгә минем барасы җирем бар. Хәзер үк кил! Әйе, әйе, күршеләрдән шалтыратам. Мин сиңа аларның телефон номерын биргән дә идем. Әйе, шул, онытмагансың,— диде Айгузин һәм күршеләренең телефон номерын әйтте.— Ә-ә, отставкага чыкмадыңмы соң үзең? Иртәме? Шактый бар шул әле сиңа. Кунакка гражданскийдан йөрим, дисеңме? Ярар соң, сиңа анысы да килешә.— Шушы читләтеп әйтүе милиция дежурныен тәмам ышандырды бугай, төрепкәдән көтегез, дигән сүз ишетелде.— Көтәм, яме. Шешә бөкесен дә ача торырмын. Сиңа әз-мәз каплалау зыянсыз, мин генә сезнең сафтан төшеп калдым менә,— дип сөйләвен кырт туктатты Назыйм.

Аның формадан килмәскә искәртүеннән соң әйткән сүзләрен милициядә инде тыңламыйлар, телефон төрепкәсе сулкылдый иде.

Назыйм чакыруы буенча килгән кеше түгәрәк йөзле, уртача буйлы, киң җилкәле ир уртасы яшьләрендә иде. Сабан туе көрәшчесенә охшап тора, нык бәдәнле. Өстендә көрәнсу җәйге пальто, башында йонлач бүрек, аны батырып кигән. Өйгә кергәч, кулларын кесәләреннән алмыйча торды. Карашы белән түргә ишарәләде — андамы, дип соравы иде.

— Беркем дә юк, үзем генә,— дип иркен сулады Назыйм.

— Нигә чакырдыгыз алайса? — дип кырысланды милиция кешесе.

— Миңа хәзергә урамга чыгарга ярамый. Аның аста сага-

лап торуы ихтимал, һәм сагалыйдыр. Ул башкисәрдән гомер уйламаган әшәкелекләрне күтәргә мөмкин. Адәм җанын кызганучылардан түгел.

Алдандык, ахры, дип уйлады милиционер һәм кашларын сикертеп көлемсерәде.

— Сез, абый кеше, милицияне, төпсез чуманга утыртып, Чулман кичтермәкче буласыз бугай,— дип ризасызлыгын белдерде ул.— Чулманны төпле чуман белән дә кичеп булмавын онытып җибәргәнсез.

Инде Назыйм көлемсерәде.

— Минем телефоннан сөйләвемнең хәйлә икәнлеген аңладыгыз. Рәхмәт. Хәйлә шуның белән бетте,— дип, милиционерга түргә узарга ишарәләде Назыйм.— Шаяртуга оста түгел мин. Айгузин абыең мәзәк кора белми, зур кимчелекләренең берсе шул аның. Һәм ул шушы кимчелеген белә! — дип, өстәл яныннан ике куллап урындык тартты.

— Шулай да нәрсә булды соң?

— Ул бәндәдән кан исе килә! Валлаһи, кеше каны исе бөркелеп тора! — Назыйм дулкынлана башлады, әле аягүрә басып, әле утырып, Сәвади Сайгушев белән бүгенге очрашулары турында сөйләде. Айгузин сөйләгәннәрне милиционер язып бармады, баштарак бүлдермичә тыңлаган иде, ахыргарак сорауларын күп бирде, Сайгушевның йөзе-кыяфәте тасвирларын кабатлаттырды.

— Сайгушев... Сәвади... Сәвади...— дип үзалдына әйтте милиционер.— Яңа «кош» булырга охшый бу... Яңа очып килгәндер бу...

— Бәлки, вокзал белән аэропорт тирәләрен караштырырсыз. Тиз үк очып китүе дә ихтимал бит. Минем биш йөз тәңкә җитеп торырга да мөмкин аңа. Ун сумын маяга калдырдым, дигән иде. Калдырыр...

— Биш йөз! Биш йөз бер сездән ул, Назыйм абый. Бүген шәһәрдә әллә бер сезне генә талаганнар дип уйлыйсызмы?

Милиционер, әгәр Сайгушев турында Назыйм нәрсә дә белсә, кая хәбәр итәсен әйтте, Сайгушев, очрап, нәрсә таләп итсә дә, карышмаска кушты.

— Бер көндә бер минем алда ике җинаять кылды,— дип, милиционер фикеренә кушылды Назыйм.

— Ул тоткан әйберләрне инде юдыгызмы? — дип китәргә җыенып беткәч сорады милиционер.

— Ишек тоткаларын юдым да комодны сөрттем. Башкасын, әнә, чүп чиләгенә ташладым.

Ике кулын кесәләренә тыгып килгән милиционер төргәк күтәреп китте. Назыймның малае югалуы турындагы хәбәренә ул төгәл җавап кайтара алмады, моның белән башка тикшерүче шөгыльләнүен, бу хәлне ишетеп кенә белүен әйтте, белешергә ышандырды. Тикшерүче киткәч, Айгузин барлык бүлмә-

ләрдәге утларны кабызды, ләкин утлар ялгыз күңелне барыбер яктырта алмады.

...Их, дип сыкранып уйланды ул, карчыгым янымда булса, малаем күрсә, Сайгушев миннән йөз чакрымга ерак йөрер иде бит!.. Күңелне генә газаплап калмый шул ялгызлык... Карчыгым вафатына өч ел... Малайның югалуына өченче ай... Карчыкны үз кулым белән җирләдем, монысына ышанмыйча ихтыярың юк. Ә малай... Малай исәндер. Нигә, алайса, бер хәбәр дә бирми ул? Ни гаебем бар минем аның алдында? Нигә мине ялгыз калдырырга тиеш иде ул? Нигә?! Акыллы бала иде ич ул! Нигә... Ни булды икән аңа, ниләр булды икән?..

Айгузин төн буена йокламады. Күзләре йомыла башласа, каты чәйне коры килеш кенә эчте. Утларны әле сүндерде дә тагын кабызды. Уйламаган нәрсәсе калмады кебек, ләкин озын гомернең хатирәләре, алдагы кыска гомергә өметләр уйлар тезмәсен суза да суза иде. Әллә соң Сайгушев дигән бәндә аны бер сәбәпсезгә капкынга кысарга җыена да, гомеренә йомгак ясыймы Назыйм карт? Шулай булса, киләчәккә өметләнү мәгънәсезлек ләбаса. Юк! Өметсезлеккә бирелмик! Хатирәләр үзләре үк өмет уята. Хәтерлик...

Назыйм Айгузин куркаклардан түгел. Үз йортлары белән Казанның Савин ягында яшәгәндә, дөм караңгы урамнарны ялгызы узу аны һич тә шикләндермәде. Юлбасарлар котырынган чакларда да шүрләмәде. Исән калачагына ышанып җитмәсә дә, сугышта үлемнән дә курыкмады. Сугышта үлем үзен иркен сизә дигән гыйбарәне кайсыдыр китаптан әле ул чакта укымаса да, куркып үлемнән котылып булмавын аңлый иде. Шулай, куркып яшәмәде Айгузин. Шуңа күрә, рәсми әйтсәк, партиясовет эшендә әйбәт кенә күтәрелеп барганда, иң аскача тәгәрәвенә дә офтанмады ул. Монысы болай булган иде.

Госпитальдән кырык икенең мартында чыкты Назыйм. Уң аягының балтыр сөягенәчә сугыш чәпәгән яра тиз төзәлеп җитмәячәк иде, һәм аны кайтарып җибәрделәр, мондый яра озакка сузыла, аны өйдә дә дәваларга мөмкин, диделәр. Кайтуын көтеп кенә торгандай, элекке эшенә чакырдылар. Эшләмичә дә булмый иде, тамакны яра туйдырмый. Бер айдан аны инструкторлыктан райбашкарма рәисенең урынбасары итеп күчерделәр. Син — яшь коммунист, үсәргә мөмкинлек бирәбез сиңа, укытырбыз, тик хәзер түгел, сугыш беткәч, дип өметләндерделәр. Тырышты Назыйм, ярты төнгәчә эшендә булды, ялны белмәде. Аягы төзәлә төште, таяксыз йөри башлады. Яшьлек яраны сыпырып ташлагандай итәр кебек иде, бу чакта аңа егерме ике яшь кенә иде. Тик, каһәре, ярасы хәзер дә ике-өч елга бер ачылгалый, яралануына илле елга якын вакыт узгач та ябылып бетми.

...Кырык өчнең урак өстендә шәһәрдән авылларга вәкилләр җибәрделәр — шәһәр кешесе өйрәтеп тормаса, авыл апайлары һәм малайлары ура-суга белмәгәннәрдер шул. Шәһәрдә

туып үскән Назыйм Айгузин да вәкилләр арасына эләкте. Ындыр табагын, әвен куюны — ул җәйдә, фронтка ашлыкны тизрәк озату өчен, әвеннәр суктырылды — беренче тапкыр күрде егет. Ләкин аның авыл кешеләрен крестьян эшенә өйрәтү вәкаләте бер генә атна дәвам итте.

Айгузин әвеснектә көрәк белән атып арыш җилгәрүчеләрне карап тора иде. Ике хатын ике яктан алмашка ыргыталар. Оста чөяләр соң! Арыш көшел булып якынрак өелә, алабута орлыклары итәккә каралып җәелә, җиңелрәк чүпләр ераккарак оча. Җилгәрүчеләр ялга туктагач, Назыйм да атып карады, ләкин чүпләр арыш көшеле өстенә төштеләр. Хатыннарның өлкәнрәк яшьтәгесе озын саплы себерке белән көшел өстен себерде, егетне ачуланмады.

— Көчең чамалырак, ахры, энем,— диде ул.— Аннары җилнең агышын битең белән тоеп торырга кирәк. Син җил көчсезләнгәндә чөйдең.— Себеркесен куеп, агач көрәкне алгач: — Син алыштыра алсаң, берәр көн эштән калмакчы идем,— дип шаяртмыйча әйтте.— Башкаларның кыш чыгарлык алабута җыярга карт-карчыклары, бала-чагалары бар, минем булышчым юк бит, нәрсә ашатырмын аяксыздан-күтсез ике балага... Алабутасыз да калам бит...

Кулларын тезләре арасына кысып, кемгәдер ялварулы карап утыручы ике бала күз алдына килде Назыймның. Шуларга ярдәм итәргә җай табуына сөенеп:

— Кайгырма, апа,— диде ул һәм, көшел итәгендәге алабутага төртеп: — Сиңа менә шушы әзерен бирербез,— дип куандырмакчы булды ачлык киләчәгеннән шөбһәләнүче апайны.

Хатынның йөзе җимерелде, нәрсәдәндер җирәнә иде ул, кинәт күзләре акайды, көрәк сабын төптәнрәк каты кысып тотты.

— Син миңа алабута ашатмакчы буласыңмы?! — дип кычкырып, Айгузинга таба килә башлады хатын.— Син миңа ашлык бирдермәскә исәп итәсеңмени әле?! Минем балаларым үскән чагында ипи күрмәсеннәрмени? Шуларны ач утырту өчен көне буена колхоз... колхоз...— дип тотлыгып торды ул,— колхозда тир түгәммени мин? Балаларыма дигәнемне кисә алмассың! Үзем иписез дә яшәрмен. Алла боерган булса. Сөт, чәй, бәрәңге белән тук булырмын. Балаларым өлешен беркемнән дә кистермәм! Күземә күренмә!

Һәм бу хатынны Назыйм башка күрмәде, басу уртасындагы әвеснеккә бүтән барырга туры килмәде аңа. Шул көнне кичке уңайда ул вәкиллеген тәмам кылды.

Амбарда төнге смена оештырмыйча булмый иде. Кайткан ашлыкны — орлыкка дигәнен эшкәртеп өлгерә алмыйлар, кыза башлавы ихтимал. Колхоз рәисе, төштән соң өй борынча йөреп, картларны күндерергә булды, ә Айгузин фермага төште, анда эшләүчеләргә төнге сменага әйтергә тиеш иде. Әмма төнлә дә эшкә чыгарга бәрәү дә атлыкмады, һәркайсы сәбәбен тапты.

— Өемне төнгә дә ялгыз калдыра алмыйм,— диде берсе.— Балалар үзләре генә кунарга куркалар.

— Абый җаным, иртүк фермага килә алмыйбыз бит без аннары,— дип ялваргандай әйтте Айгузин белән бер яшьтәгерәк кыз.— Малларыбыз көтәчәк бит безне. Иртәгә мин көтүгә чыгарга тиеш, минем чират. Ярар инде, мин яшь кеше, бер генә тапкырга түзәрмен дә ди, өйдәгесенә дә катнашмыйм ди, әбиебез барысын да тәртиптә тота, кайттым — бар, киттем — юк дигәндәй. Бу апалар соң... Белмим инде... Кеше ич инде без дә. Машинаны да ял иттерәләр.

Озынрак буйлы, тулы гәүдәле хатын:

— Мин авырыйм,— диде, кызгылт йөзен сыпырды, чигәләрен ышкыды.

— Синме?! — дип гаҗәпләнде Айгузин. Көче кайнап торган мондый кеше авыруны белмәскә тиеш кебек тоелды аңа һәм аның шушы уе авызыннан сүз булып очып та чыкты.— Син авырыйсыңмы? Шушы гәүдәң беләнме? Кай төшең авыртсын ди синең?!

Хатын-кызлар абзар өрлекләренә дип кайтарылган, каезлангач, ике ел ачыкта ятудан көлсу төс йоккан имән бүрәнәләр өстендә утыралар, Назыйм аларның каршында басып торып сөйләшә иде. Кырыйда утырган авыру хатын куллары белән этенеп торды, башын игән килеш бармаклары белән чигәләренә баскалады. Акрын атлап Назыйм янына килде һәм егетнең күлмәк җиңеннән чеметеп тотты.

— Кай төшемме? — дип сорады ул.

Назыйм ни әйтергә дә белмәде. Иртәгә көтүгә чыгачак кыз пырхылдап көлеп җибәрде, урынсыз көлүеннән уңайсызланып, учы белән авызын каплап, маңгае тезенә тигәнче башын иде.

— Әйдә,— дип, Назыймны җиңеннән иләп кенә тартты авыручы хатын,— абзар артына чыгабыз. Кай төшем авыртканны күрсәтәм!

Шәһәр вәкиле күлмәк җиңен ачу белән селтәнеп ычкындырды да эндәшмичә китеп барды. Хатын-кызлар шәрран ярып көлделәр. Назыйм Айгузинның кешеләр белән мөнәсәбәттә бер көндә алган икенче сабагы булды бу.

Урамда аңа колхоз рәисе очрады. Рәис сораганчы ук:

— Күнмәделәр,— диде Назыйм.

Моны ишетүдән кәефе кырылмады рәиснең, ул елмаебрак:

— Төнге сменага чыгачаклар алар. Беренче тапкыр гына аларга барып егылуыбыз түгел,— дип, егетнең сүзләрен кире какты.— Аларны үгетләргә кирәкми. Хәлне аңлыйлар. Әйбәтләр. Кешеләр барысы да әйбәт лә анысы. Тик адәм баласының мөмкинлеге чамалы, ялсыз-йокысыз яши алмый...

Фермада эшләүчеләр төнге сменага барысы да чыккан иде. Алар ярты төнгәчә ял итмичә эшләделәр, шуннан соң колхоз рәисе аларны кайтарып җибәрде. Эшчән хатыннар көндез На-

зыйм Айгузинга чынлап та каршы төшкәннәрме, әллә егет белән, аны юри котыртып, шаярып аласылары килгәнме — сугыш заманындагы хатыннар патшалыгында бу кадәресе гөнаһ саналмас — вәкил кеше моны соңыннан да белмәде. Ерак басудагы уракчылар янына барам, дип, колхоз рәисеннән атын сорады ул. Һәм, тарантаска утырып, атны урам иңләтеп кирегә борды. Гарип сатучыны кибеткә китертеп, аңардан ике буш шешә таптырды, аларга аракы тутыртты — сугыш заманында аракыны мичкәдән дә саталар, хәзергечә кысынкылык юк иде, шулай да авыл аракыга баш имәде, сугыштан эшкә яраксыз хәлдә яралылар кайткан көннәрдә генә хәмердән авыз иткәләделәр.

Назыйм уракчылар янына туктамады, алар турысыннан атын юырттырып узды. Урман читенә җиткәч кенә дилбегәне тартты. Юлның бер ягында — арыш, икенче ягында бодай чәчелгән иде. Ике яктан да учларын тутырып башаклар өзде. Кабымлыкка башка ризыгы юк иде. Урман эченәрәк кереп, бәләкәй аланда туктап, бер шешәнең авызыннан аракының яртысын чөмергәч кенә, өлгереп җитмәгән миләш чемнәре өзде, чикләвек кәлшәләрен шактый тапты. Аракы артыннан кабарга урман җимешләре ярап куйды. Болай булгач, ике шешә аракы исертмәс кебек иде. Ләкин — кешенең мөмкинлеге һәрьяклап чамалы! — Назыйм лаякыл исерде. Ярый ла икенче шешә аракыны, тарантас башын өстәл итеп, чуманга утырып эчте, югыйсә урманда аунап калган булыр иде.

Авылга кайчан һәм ничек кайтуын хәтерләмәде ул. Ат үзе борылып юлга төшкән булыр, дилбегә тәгәрмәчкә уралып өзелгән, мескен атка башын каерып хәтсез ара узарга туры килгәндер. Урман чыккач, басуларның иркенлегенә хәйранлап хозурланган кебек тә тоела, колхозчы агай-энеләрнең кырда ничек эшләүләрен шушы калкулыктан күзәтеп кенә торам, бинокль белән, дигән карарга килгән кебек. Ындырда көрәк күтәреп куган хатынга ачуы кабарып алды, кышын шушы басуларда агач көрәгең белән кар тоттырам әле мин сиңа, дип, ачу алмакчы булды хатыннан, абзар артына чакырган албасты гәүдәле хатын белән икегезне пардан куярмын, дип төкереген чәчте. Юл кайтуын авыл кешеләре күргәннәрдер, караңгы төшмәгән булгандыр әле. Чөнки томан аша гына бер малайның:

— Абый, күпер дыңгырдыгында кепкаң төшеп калды,— дип, тарантаска кепка ыргытканын күргән кебек була.— Исерек абый! Исерек абый! — дип үртәп һәм кушамат тагып качты бугай малай.

Иртәгесен айныгач, башка бернәрсә дә исенә төшмәде шәһәр вәкиле Айгузинның. Бәлки, урман авызында туктап, усал телле ике хатыннан үч алырга карар итүе төш кенә булгандыр, исерек Назыймнан куркып чатыр чабучы малай да очрамагандыр. Хәер, болары булмасын да ди, ләкин барыбер авыл кешеләренең күзләренә күренерлеге юк инде аның. Колхоз

рәисен ат утарында эзләп тапты, иртә иде әле, ат җигүчеләр килмәгән иде.

— Мин киттем,— диде ул колхоз рәисенә һәм, кием-салымнары, бүтән кирәк-ярагы тутырылган юл биштәрен асып — солдат гадәте — капкага борылды.

Колхоз рәисе эндәшмәде, шәһәр вәкилен капкагача озата барды, Назыйм тыкрыкка борылгач кына:

— Берничек тә ярдәм итә алмыйм шул,— диде.— Зыяным тимәде сиңа, файда итә дә алмыйм.— Кычкырып туктатмады, чөнки: — Авыл гафу итмәс шул сине,— дигән ышанычы үзгәрмәслек иде.— Кеше — уракта, мин — кунакта, димеш мәсләгеңне кабул итми авыл.

Вәкил Назыйм авылдан шулай чыгып качты.

...Айгузин авылда исереп хур булуын, ике хатынның үзен ничек мыскыллауларын төшереп калдырып, райбашкарма рәисенә үзе сөйләде. Аны эшеннән алдылар, партиядән чыгардылар, шөкер, сугышта ярaлануын искәреп, хөкемгә тартмадылар, үсеш баскычы җимерелүнең сөенече шул гына иде. Монысы, шөкер, бәхетсезлектә килгән бәһасез бәхет иде. Ә теге бер көндә ике сабак укыткан усал телле хатыннарны, бу хакта берәүгә дә сөйләмәсә дә, гомере буе онытмады. Аларга фурияләр дип исем кушты. Фуриянең нәрсә аңлатуын китаптан укыган иде — укырга ярата ул — фурия Рим мифындагы үч алучы хатын-кыз Алла икән. Авыл хатыннары, Алла ук булмасалар да, урак өстенең эшсез вәкиле Айгузиннан, уйлый-сөйләшә белмәгәне өчен, үчләрен оста алганнар иде.

Назыйм партиягә яңадан керү өчен тырышмады. Ун класс белеме белән калды, җитәкче эш бүтән кызыксындырмады аны, үсеш баскычыннан бер тапкыр мәтәлеп башы тишелүне бик тә җитәргә санады, һәм, үзенең уйлавынча, ялгышмады, токарьлыкка өйрәнеп, пенсиягә чыкканчы заводта эшләде, үзенә үзе хуҗа булды.

Урак өсте вәкиленнән эшче сыйныф вәкиленә шулай әйләнде ул. Эшче сыйныф исә илдә өстенлек итте, диктатура аныкы, пролетариат диктатурасының өстенлекләре чиксез саналды. Айгузинның куркып яшәмәвенә, бәлки, менә шушы күрсәтмә дә сәбәптер.

...Әнә, эшчеләргә фикердәш тиешле крестьян агае — фуриясе белән! — бушка тир түгүдән, налогын түләмәсә, кычкыртып сыерын алып чыгудан, череп баюга китерүе ихтимал бакчасын кисүдән дер калтырап яшәсен! Телләрен тыярлар!..

Назыймның, сабак укыткан ике хатын исенә төшкәндә, шулай уйлаганы да булды. Ләкин ялгышуын бик соң — ялгыз фатирында йокламыйча чыккан төндә генә аңлады. Аның фикерен Сайгушевның үкертеп талавы түгел, ә Мөхибә карчыкның көндезен кылган игелеге — юк, юк, алай гына да түгел, аңа калса, Айгузин, бала көткән хатынга ярдәмгә ташланып, үзе дә

игелек кылды лабаса! — Мөхибә карчыкның тормышны яратуы үзгәрттерде. Мөхибәнең шушы изгелеген — дин тотуы изге итәдер аны — йокысыз төн чыкканда төшенде. Мин Мөхибә әби рухын аңлаганда, фурияләр киләчәктә миңа сүз катарга куркырлар дигән нәтиҗә ясады Назыйм карт. Тик килер гомере кыска калгандыр, баш очында Сайгушев карчыгадай очып йөргәндә, гомернең эх иткәнче киселүе бик тә мөмкин, «милиция минеке» булса да, мине генә саклап тормас...

Хәтер капчыгы актарылганда, Айгузинның моңарчы да курыкканы исенә төште. Малай чакта ук ике тапкыр курыккан икән ул.

...Назыймнарның үз алмагачлары да бар, сигезәү хәтта. Ел саен күп итеп алма бирәләр, җиргә коелганнарын җыеп та бетермиләр. Ә сул күршеләре алмагачларын Назыйм белгәндә генә утырттылар, аларның алмагачлары яшь, былтыр чәчәкләрен өзгәннәр иде, быел беренче алмаларын көтәләр. Шул алмалар кызыктыра малайны, үз алмаларын ул инде ашап туйган, тәмлелеккә үз алмалары да тәмле, ләкин алмагачлары Назыйм туганчы ук утыртылган, картаеп баралар. Әнә, күршеләрнең яшь агачларындагы алмалар тәмлеләрнең дә тәмлеләредер! Күрше абыйдан әнә теге алсуланганнарының берсен сорыйсы килә, кыймый, бирмәстер кебек. Чәлдерсәң иде шул агачтан бер алманы, санамаганнардыр, бер алмалары югалуын сизмәсләр әле.

Һәм малай, күршеләренең өйдә юк чагын чамалап, киртә өстеннән сикереп төште дә, бәрәңге сабаклары арасыннан иелеп барып, алмагач төбенә чүгәләде. Хәзер алманы үрелеп тә алып була, аскы ботактагысына аягүрә басмыйча да буе җитә. Этләре өрә башласа да, куркыныч түгел, Акбай, дип пышылдап эндәшсәң, туктаячак, Назыймның тавышын таный, бәйдән ычкындыргач, Назыйм белән уйнарга ярата. Өрсә ни тагын, котырынып өрсен, хуҗалары барыбер дә өйдә юк бит.

Назыйм алмага үрелде. Кулы менә җитәм, менә җитәм, дип тора. Һәм Назыймны кызыктырган алма малайның учына үзе керде. Тик шул мәлдә малайның бөтен тәненә салкын йөгерде, эссе көндә дә шундый өшеткеч салкын булыр икән... Өзмәде Назыйм алманы, үзләре бакчасына, бер атлап, ике сикереп дигәндәй, очып кына чыкты. Шунда гына тәненең өшегәне кайтты.

Әллә кайчангы хәлләрне бергә тезеп уйлансаң, алар арасында гаҗәп эзлеклелек, бәйләнеш барлыгын беләсең икән. Назыймның икенче тапкыр куркуы беренчесенең дәвамы ләбаса, кеше әйберсенә кызыгудан икән анысы да.

Кайсы елда икән соң бу? Ә, әйе, утыз икенең кыш көнендә, Назыймга унөченче яшь киткәч, аны әтисе Йошкар-Олага алып барган иде. Кунак йортында тордылар, икесенә аерым бүлмә, зур гына үзе, кояш ягында, искергән бинада мондый яңа кебек бүлмә булыр икән, әй. Икене кундылар. Әтисе көндезләрен йомыш белән йөргәндә, Назыйм шул бүлмәдә укып утырды, урам-

га чыкса да, кунакханәдән ерак китмәде. Урамда уйнарга танышлары юк, көннең дә рәте буталган, буран да буран, каян табыладыр шулхәтле кар — өзлексез ява. Казанда да кар явып калган иде, кышкы каникул көртләр өюдән бүтәнне белмәде быел. Иртәгә китәләр инде, Казанда аяздыр, каникул беткәнче, тимераякта шуып, чаңгыда йөреп рәхәтләнергә өлгерер әле Назыйм.

Кичен этисе бер абый белән кайтты.

Әтисе, чәй янына утыргач:

— Теләнеп йөрүләре кыен ла соң! — диде.— Үзем өчен түгел ләбаса, дәүләт агачын дәүләт заводы өчен сорыйм. Әллә ничәмә кәгазьгә кул куйдырттылар. Болай барса, илнең бөтен агачы рөхсәт кәгазе эшләүгә китмәгәе.

Малай бу офтануның мәгънәсенә төшенеп җитмәде.

Таныш түгел абыйның:

— Элемтәнең ныклыгын кәгазь беркетә, агай-эне. Тик моның бер генә «ские» бар — кәгазьне тамга бизәсен. Тамгалар күбрәк булган саен — шәбрәк,— дигән сүзләре колагы яныннан гына узды аның.

Абый иелә төшкәч, малайның борынына аракы исе бәрде. Назыйм, күзләрен тутырып, әтисенә карады, эчкәне сизелми иде әтисенең. Эчә күрмәсен, эчсә, атна буена туктамый аннары. Йошкар-Олада, матур кала булса да, тагын атна торасы һич тә килми Назыймның. Абый кеше чалбар кесәсеннән капкачлы сәгатен чыгарып карады, аны өстәлгә куйды, чылбырын эләктермәгән икән. Әтисе белән абый кеше тәмәке көйрәтергә чыгып киткәч, Назыйм сәгатьне теге абый кебек еракка тотып карады, колагына куеп тыңлады, бер көйгә теркелди иде сәгать. Әгәр... әгәр Назыйм сәгатьне алып яшерсә? Абый кеше, аракы эчкән килеш, сәгатен өстәлгә куюын хәтерләмәс тә бит. Әтисе таптырсамы? Ничек таптырсын ди, абый кешенең сәгатен өстәлгә куюын күрмәде бит ул, соңыннан да сәгатькә игътибар итмәде. Алмадым, дияр Назыйм, ә сәгатьне... Кая яшерер икән соң сәгатьне? Әй, сәгате булса, яшерер урын табылыр ла! Бәдрәфкә, дип чыгар да, кар астына тыгар. Аннары Казаннан килеп алып китәр. Йошкар-Олага юлны белә хәзер. Әтисе Назыймны әрләмәс тә әле. Нигә әрләсен икән, малаеның сәгатьле булуы начар түгел ич, Назыймга сәгать алып бирергә барыбер акчасы юк ич аның.

Сәгать хуҗасы тәмәке тартырга чыкканнан кире кермәде. Бик тә шәп әле бу, хәзер сәгать, урламыйча да, Назыймныкы була. Һәм малай сәгатьне кесәсенә салып алды, аннары куенына яшерде. Шул мәлдә коты очардай булып нәрсәдәндер курыкты, авызыннан бөтенләй көтелмәгән сүзләр атылып чыкты:

— Әти, теге абый сәгатен оныткан. Табабызмы инде без аны капкачлы сәгатен бирергә?

Сәгатьне бирергә теге абыйларга әтисе белән барды На-

зыйм. Тик абый кеше сәгатен кайтаруга әллә ни сөенмәгән кебек иде, сәгатьне өстәлгә ташлагандай итеп куйды ул.

...Алма һәм сәгать вакыйгаларыннан соң Назыйм кеше әйберенә кызыкмады, гомумән, әйбер колы булмады, өендә иң кирәкле нәрсәләрне генә тотты, хатынының еш кына кабатлауларына карамастан, мая өстенә мая өймәде, хатынына да рөхсәт итмәде. Сайгушев талаган биш йөз сум акчасы беренче запасы иде. Үлемтеккә дип җыйган. Хатынын җирләгәндә, мондый чыгымга әзер булу зарурлыгын белде ул.

...Таң алдыннан Назыймны йокы басты. Әмма карт бу төнне йокламаска дигән сүзендә торды. Салкын су белән юынды. Яктырып кына килә, урамда йөрүчеләр ишле түгел.

— Ярый ла алманы һәм сәгатьне алмаганмын! — дип сөенде Назыйм карт.— Ярый ла курка белгәнмен! Шул чакларда коелып төшмәсәм, бурлык юлына басасым икән. Йөрер идең хәзер кеше әйберен Сайгушев сыман урлап-талап! Хәер, моңарчы төрмәдә черер идең инде. Җинаятьчеләр арасыннан астыртын эш йөртүчеләр генә озаграк яши...— Төн утырып ясаган нәтиҗәсен кемгәдер ныклап аңлатырга теләп сөйли иде ул, тирәсендә кемнәрдер бар кебек иде.— Ә... Ә бүген Сайгушевтан куркуым — үз гомеремдә өченче тапкыр куркуым икән. Монысы малай чактагы куркуларыма бөтенләй дә охшамаган...

Назыймга хатыны иртәнгә гел җылы ризык әзерли иде. Ялгызы калгач та, шушы тәртипне тотты ул. Тик бүген ризык пешерәсе килмәде, элекке көннән калган тавык шулпасын кичә үк бетергән иде, шуннан соң кичәге ыгы-зыгылы, давыллы көн коры-сары белән узды. Кайткач, бәрәңге йә ботка пешерермен әле, дип уйлады. Иртәнге якта шәһәр яны поездларында кеше күп була, шәһәрдән Юдинга һәм Васильево бистәсенә эшкә ашыгучылар шактый, балыкчылар Обсерваторияне узып та китәләр, бу чакта Сәвади Сайгушев поездда йөрмәс. Милиция хезмәткәренә, бандит белән очрашса, җебеп төшмәскә ышандырса да, куркуы көчәя генә барды. Иртәнге поездны сайлап дөрес иткән иде Назыйм, ләкин Обсерватория тукталышында берүзе генә калгач, Сайгушевны очратудан куркуы калтырануга ук әйләнде. Монда торып та куркуны басып булмый, Казанга баручылар теге яктан тиздән киләчәк поездга утырып китәчәкләр, һәм карт тау итәгендәге дачасына урамнан әйләнеп керде, тар тыкрык сукмагы үзе үк шикләндерде аны. Әгәр Сайгушев аны дачасында көтеп торса? Юк ла инде, болай уйлау чиктән аша, бандит аның дачасының кайдалыгын түгел, дачасы барлыгын да белми бит. Беләдер, кичә кайнатмаларны сумкасы белән урлаган иде. Паспортны карагач, дачасы кайда, дип сорашып йөргән булмагае...

Дачасында озак кайнашмады Айгузин, базда кайнатмаларны, кәгазьгә аерымлап төргән алмаларны карчыгы йөрткән сумкага — Сайгушев тоткан сумканы милиция кешесе алып кит-

те бит — тутырды да кайтыр юлга ашыкты. Табигатькә кичәге кебек сокланып торырга теләге юк иде. Бүген көне дә кичәгечә тынып та дуамалланып тормый, гел дә тыныч, бу аязлык шактый сузылыр кебек. Ә картның күңелендә гарасат һаман котыра, әллә тынарга исәбе юк тагын. Сайгушев очрау ихтималы да поездда йөрүчеләр күбрәк чакта кайтырга ашыктырды аны.

Айгузин килгәндә, Мөхибә карчык бала табу йортының айванындагы озын эскәмиядә мул төенчегенә таянып утыра иде. Назыйм, аны күреп, артка тартылып куйды, карчыкны очратырмын дип уена да китермәгән иде. Ә Мөхибә йөз чакрымдагы Сабасыннан килеп тә җиткән, әллә кайтмаган да инде.

Мөхибә Назыймны ишарәләп чакырды, янәшәсендәге күн тышлы тәбәнәк кәнәфигә күрсәтте. Карт, изүен чишеп, бүреген салып, шунда җайлап утыргач кына, карчык:

— Исән-имин уздырдыңмы көнне-төнне, Назыйм энем? — дип пышылдабрак сорады һәм кучтәнәчләр бирү тәрәзәсенә ымлады.— Тавышланырга ярамый монда.

Назыйм, моңа үзе күреп ышанырга теләгәндәй, кечкенә тәрәзәгә карады. Шуннан соң гына карчыкның хәл белешүенә:

— Әйбәт,— диде.— Әйбәт. Исән-сау. Кулларның...— диде дә шып туктады, икенче кулын да Сайгушев кысып авырттыруын сиздерәсе итмәде, Сайгушев белән поездда булган хәлне дә әйтмәгән иде ул.— Кулның сызлавы басылды. Чатнавы зур түгел икән, әле врачка күрендем.

— Кичә, шушы бала хәле белән,— дип, тагын ишарәләп кенә коридор ишегенә күрсәтте карчык,— сорамаганмын,ваемсызланып,— дип, үзен әрләде.— Нишләттең соң кулыңны?

— Әй-й, булды инде шунда! Дачага барган идем бит кичә дә. Беләзеккә... шүрлектән... чүкеч төште...

— Төшми ни, шүрлеккә чүкеч яшергәч соң! Гомер итеп, чүкеч урынын да белмәгәч,— дип әрләү сүзеннән Назыймга да өлеш чыгарды Мөхибә.— Ә-ә, Назыйм энем, мин теге баланың исемен белештем бит. Гөлсәхра икән аның исеме. Гөлсәхраның әти-әнисе дә, каенатасы белән каенанасы да кичә үк килгәннәр,— дип, шәфкать туташы әйткәннәрне Назыймга ирештерүгә күчте карчык.— Оныклары туугa бик сөенгәннәр, ди. Гөлсәхра өеннән качып чыгып киткән икән. Син уйлаганча ямьсез түгел икән сәбәбе. Кеше турында начар итеп уйларга атлыгып торган чакларың еш бугай синең. Дөнья ул, Назыйм энем, әйбәт кешеләр белән тулы.

— Сай...— Айгузин, Сайгушевлар белән дөнья тулы, дип, каршы төшмәкче иде, бандит турында Мөхибәгә әйтмәскә булуы келт итеп исенә төште. Сүзенең бүленүенә сәбәп итеп йөткерде.— Саерак шул минем акыл.

— Шулай, Назыйм энем, Гөлсәхраны поездда бәбәй табарга бүтән нәрсә мәҗбүр иткән. Үзе шулай теләгән. Аны гаепләргә ярамый.

Карт җилкәләрен сикертте.

— Хатын-кыз тузга язмаганны эшләргә оста инде.

— Һаман да начарга түнеп уйлыйсың бит, кем, Назыйм! — дип, картны ачуланды Мөхибә.— Гөлсәхра тол калган икән инде! Син юкны такылдыйсың! Тфү, тфү! Гөнаһка кертәсеңме инде мине, гомер итеп, яхшыны өстен итә белмәгән башың белән, дим!

— Шул яшеннән тол калганмы?! — дип ышанып җитмичә сорады Назыйм.— Корсаклы килешме?

— Шул яшеннән! Әле иренең кырыгы да җитмәгән! — дип, үзенә хас булмаганча кызуланды карчык.— Синең холкыңда, Назыйм энем, ак белән кара бергә кушылырга атлыгып торалар икән. Үзең Гөлсәхрага күчтәнәч китергәнсең, үзең Гөлсәхрага яла якмакчысың.

— Бардыр холыкның чатаклыклары,— дип, аска карады карт.

Мөхибә тиз генә тынычланмады. Моңа, Назыймның кирлемырлы сөйләве белән бергә, шәфкать туташыннан ишеткән хәбәрләре дә сәбәпче иде.

— Үтергәннәр Гөлсәхраның киявен! Поездда йөрәгенә чәнчегәннәр! Шуннан соң, баламны поездда табам, дип, үзенә сүз куйган Гөлсәхра. Исерекләр чәнчегән!

Сайгушев чәнчегәндер, дип сискәнде Айгузин.

Ләкин карчык:

— Исерекләр поездда теләсә кемгә бәйләнеп йөргәннәр, Гөлсәхраның ире шуларны тыйган,— дип ачыклагач, шикләнүе кимеде.

Сайгушев түгелдер, Сайгушев үз ишләре арасыннан да шаһитлар ияртмәс, дип уйлады Айгузин.

— Өчәү булган исерекләр,— дип, авыл хатыннарына хас рәвештә төгәлли барды карчык.— Тотканнар, ди инде шуларны. Хөкем ясаячаклар, ди. Хөкемдә генәме соң хикмәт — ана тол калгач, бала ятим тугач... Поезд тулы кеше өч исерекне тыя алмасыннар инде, йә...

Димәк, Сайгушев Гөлсәхраның ирен чәнчүчеләр арасында булмаган, чөнки тегеләрне тотканнар, ә Сайгушев ирektә һәм аның яңа җинаять кылуы ихтимал. Хәер, җинаятьчеләр өч исерек һәм Сайгушев белән генә бетсә икән дигән фикергә килде Айгузин.

— Баласы бәхетле була күрсен, Гөлсәхра бүтән зур кайгы кичермәсен,— диде Назыйм.

— Хатын-кызга тол калудан да авыр кайгы юк, Назыйм энем,— дип йомшады карчык.— Толлыкның ни икәнен кичергән кеше генә белә...

— Шулай, шулай... Үзем дә карт көнемдә ялгызым. Өстәвенә малаем да югалды. Әллә Гөлсәхраның ирен чәнчегән кебекләр кулыннан узды инде...

— Малаең? Син менә мондый йортларга йөрмәдем, дигән

иден бит кичә. Алдаша торган кешемени син? — дип аптырады Мөхибә.

— Юк, мин алдашуны белмәдем,— дип башын чайкады Назыйм карт.— Бар иде малаем. Малаебыз. Уллыкка алган идек. Балалар йортыннан. Алты яшендә. Үз хәтере тота башлагач. Әти-әнисе балалар йортына үзләре биргән. Акыллы бала иде. Упкынга төшкәндәй юкка чыкты менә. Чит итмәдек. Ялгышып бармак белән дә чиртмәдек,— дип, хәсрәтен ачты карт.— Үзе дә безгә мәрхәмәтле иде. Үз ата-анасыдай күрде. Безнең малай түгеллеген белсә дә. Шундый хәлләр, Мөхибә әби...— дип тирән сулады карт. Боларны Мөхибәгә сөйләгәч, күңеле бушанды, карчыкны кеше кайгысын җиңеләйтерлек игелекле кодрәт иясе итеп саный иде. Сиксән яшьлек карчыкны бүген шул әүлиялык сәфәр чыгарган лабаса.— Инде бер өметем,— дип дәвам итте Назыйм карт, өметенең чынга ашырлыгын тикшереп карарга теләгәндәй, күзләрен кыса төшеп, уйланып торды,— өметем, Мөхибә әби, малаем, малаебыз үз әти-әнисен эзлидер, дим. Миңа белгертәсе килмәгәндер ниятен. Әти-әнисен тапкач, миңа хәбәр салмыйча калмас. Балага үз ата-анасы якынрак. Якын. Тапсын иде әти-әнисен! Сөенер генә идем! Үземне барыбер ташламасына ышанам мин аның... Гөлсәхраның баласы гомеренә җуелмас кайгыга карап туган икән. Һич гаепсезгә. Ускәч, гөнаһсыз адәм, ул да әтисен эзләп йөрер инде...

— Бу дөньяда берәү дә кайгы-хәсрәтсез булмый микәнни?..— дип, Назыймның сөйләвенә йомгак ясагандай әйтте Мөхибә.— Шулайдыр шул. Шуңа күрә дә Ходай Тәгалә адәм баласын гөнаһ кылмаска өндидер. Гөнаһ кылмаучыларга гына җәннәт ишеген ача ул. Гөнаһ кылмаучыларны гына оҗмахта яшәтеп, аларның кайгы-хәсрәтен бетерә Аллаһы Тәгалә...

Күчтәнәчләрне сәгать дүрттә ала башлаячаклар, аңарчы сәгать чамасы вакыт бар иде. Карчык белән картның, күптәнге танышлар булмагач, сөйләшер сүзләре бетеп торды.

Назыймны йокы баса башлады, аның, күзләре йомылып, башы салынып төшә дә кинәт сискәнеп китә ул. Мөхибә моны күрә, талчыга карт, җитмешендә бирешкән, кайгылары авырдан икән шул, килер көннәргә өметен басмагайлары, дип уйлана. Назыймны юатырга сүзләр эзли, хәзергә таба алмый.

Карт, черемнән айнып, күз төпләрен каты басып сыпырды.

— Йокы сагынып алды үземне,— дип шаяртты. Һәм: — Йорт-җирең исән-сау торганмы, соңлаган өчен күршең әрләмәдеме соң? — дип сорады.

Аның соңлаган соравы Мөхибәгә сүзне яңа эзгә салырга җай булды. Урыныннан кузгалып куйды ул. Назыймга табарак борылды, шушы хәрәкәтләре аның бөтен тәненә һәм сөйләвенә җиңеллек бирде.

— Әйе шул, ике көн буена гел ямьсезлек турында сөйләшәбез,— диде карчык.— Әйттем ич инде, дөнья әйбәт кешеләр

белән тулы. Үзебез танып бетерә алмыйбыз шуларны. Кайтуым да, килүем дә хәвеф-хәтәрсез узды, Назыйм энем. Өйдәгеләр дә исән-сау.

— Өйдәгеләр? Өемдә күршем калды, дигән идең бит әле кичә. Син үзең төрлечә сөйләргә яратасың, ахры, Мөхибә әби,— дип, карчыкны ялганда тотмакчы булды Айгузин.

Мөхибә кеткелдәде.

— Хәйлә корсам, мин үземне тоттырырлык итмим! Авылның хәзерге тормышын аңлап җитмәгәнгә шикләнүеңдер. Малаем, киленем, өч оныгым белән бергә яшим мин. Хак дөресе. Ә өемдә күршем калды. Хәзер бит авылда карт-карчык үз балаларының хезмәтчесенә әйләнде. Ничекме? Менә болай. Яшьләр бөтен хуҗалыкны карт-карчыкка ташлыйлар да йә эшенә, йә укуына чыгалар да китәләр. Өйдә гамьнәре юк. Сиксәнен тутырган карчык пешерсен дә төшерсен, эшем кешеләренең кайтуына ризык өстәлдә торсын, йөзләрен чытмыйча гына ашасыннар иде, дип борчыла белсен әле өстәвенә. Менә шуңа күрә күршекәем белән беребез сәфәр чыкканда, икенчебез ике өйне бер итәбез. Төенчегемдә Гөлсәхрага күршем биргән күчтәнәчләр дә бар, бәбәй ашыбыз булыр, диде. Гөлсәхраның бәбәенә биләү әйберләре дә юнәттек. Ә балаларым барысы да әйбәт минем.— Мөхибә мамык шәлен төшергән иде, яулыгы кысыбрак торган, аны бушатыбрак бәйләде.— Малаем бик дәрәҗәле,— диде карчык, озаклап елмайды.

Айгузин бу елмаюда шаянлык сизмәде, намазлыкка кунаклаган әбидә нигә шаянлык булырга тиеш икән, дип гаҗәпләнде.

— Малаем арада олысы,— дип дәвам итте карчык,— ике кызымнан олысы. Әйтәсе юк, мәртәбәленең мәртәбәлесе. Кулыннан эш килә, авылда дәрәҗәсе бик тә зур. Кичә төнге унда машина белән китереп куйдылар үзен. Тәрәзәдән карап тордым, машинаның ишеген кечкенә капкага туп-туры итеп туктаттылар. Арыганын белгәннәр инде. Малаем балта остасы минем хәзер, көне буе балта чабу да чүкеч сугу элеккечә өстәл төю түгел шул — бер генә дә артык адым ясамасын, дигәннәрдер. Керде балакаем өйгә. Менә, Назыйм энем, уңга да сөялә, сулга да сөялә улым, бөтенләй беткән. Киленем чишендереп яткырды. Иртүк торып тагын эшенә китте, айнып җитмәгән иде. Исән чыгып китте, ничек кайтып керер инде... Малаем, коммунистлыкка кергәч, намаз укудан тыймакчы иде мине. Аңардан яшереп укыдым. Хәзер минем намазлык җәйгәнне күрергә вакыты юк, бик тә эшем кешесенә әйләнде. Балта белән акча суга. Үзенә җитә тагын акчасы.

Инде Назыйм башын чайкап көлде, исерекләргә гомеренә көлеп кенә карады ул, вәкил чагында лаякыл исерүеннән соң, аракыны авызына якын китермәде. Мөхибәне сүз әйтеп бүлдермәде, тыңлап кына утырды.

— Киленемнең әйбәтлеген белсәңме?! Бөтен Сабасында юк минем киленемә тиң! Чын менә! Күршекәемнең киленен

хурлавым булмасын, аның килененнән дә әйбәт минем киленем! Әнкәй, дип бөтерелеп йөри янымда, авырый калсам, эшендәге чут төймәләрен оныта, баш очымнан китми. Киленем тота йортны. Миннән ни файда соң, өй каравыллаудан бүтәнгә ярамыйм. Шулай да какмый киленем. Үзем дә, ботка пешерсәм дә, куерак ягыннан киленемә бүләм...

Мөхибәнең киленена ихластан хөрмәте йөзенә чыккан иде. Әүлия килен туры килүенә сөенече гомерле, дип уйлады Назыйм.

— Олы кызым Юдинда, үз йортлары белән торалар. Киявем поезд йөртә, Харьков дигәненә дә бара, Мәскәвенә дә. Кече кызым авылда, яңа йорт җиткерделәр. Абыйлары, улым инде, бик тә булышты, рәхмәт яугыры, кулында эш уйнап тора шул, туганнарына ярдәмен кызганмый. Кече кызымның һөнәре генә ошап бетми үземә. Кешенең... Йомшак җиренә инә кадарга өйрәттеләр аны. Тфү, тфү, гөнаһымны кичер. Ярабби...— Карчык авызын учы белән каплап торды.— Юдиндагы кызым доктор бит, авылдагысы апасы эзеннән китмәкче иде, тик институтка алмадылар, хәзер, балалар үстергәндә, укуын онытты, укол кадавыннан уза алмас.

— Шәфкать туташлары врачлардан күбрәк дәвалый авыруларны,— дип сүз катыштырды Назыйм.— Һөнәре әйбәт кече кызыңның.

— Шулай булмагае! — дип кырт кисте карчык.— Нәрсәнең юньле, нәрсәнең начар булуын аермый ди Мөхибә! Аермам менә! Укол кадау да дару эчерү доктор кушканны үтәү генә! Үз башыңны эшләтәсе юк! Үз башыңны эшләтергә иренмәскә кирәк! Башың эшләмәсә, ялкауга чыгасың, хәерчегә каласың. Нигә кызым сораныргa тиеш ди?! Ялкауланырга барыбер дә юл куймам мин аңа! Төпчек баланы иркәләү хәтәр икән. Иркәрәк үсте ул. Гел дә хатын-кызга гына кадап калмый ич инәсен! Азуы да бар яшь кешенең...

Айгузинның шәфкать туташының мактаулы якларын яклап әйтерлек дәлилләре булса да, эндәшмәде ул. Диндар карчыкны кызының бүтәннәрнең ялангач тәнен күрүенә борчылуын бетерерлек сүз эзләмәде.

Бераз вакыт тагын тын утырдылар. Ләкин Мөхибәнең балалары һәм оныклары турында сөйләүдән теләге кайтмаган иде.

— Тамак кыруымнан ук аңлагансыңдыр, хәзер кызымның кызын мактыйм,— дип сөйли бирде карчык, бу искәртүенең Назыймга ничек тәэсир ясавын белер өчен, аңа карап алды.— Мактыйм гынамы соң, мактанам! Менә кече кызымның кызы чынлап торып начальник инде! Эшләгән төшендә аның сүзеннән чыккан кеше юк. Биетеп тә күрсәтә инде ул кул астындагыларны! Берсе-берсе каршы сүз әйтергә базмый үзенә, кушканын үтәп кенә торалар. Әй-лә, ил башында утыручыларның сүзләрен шулай тыңласыннар иде ул. Юк шул, аларның сүзен

тотмыйлар. Менә син дә каршы төшәсеңдер әле,— дип, кинәт башкага күчте карчык.— Без, без, дип, кушканның гел дә киресен кылырга күнеккән бит сез. Анысы, бу дөньядан китәр заманым җитсә дә, иләмәнебезнең вәгазьләренә үзем дә ышанып бетмим. Бигрәкләр дә боргалый да сыргалый, һич кенә дә төгәл сүзе юк. Ил тәхетендә утырган кешегә ярамый болай. Торгынлык дигәнегездән әллә кайларга чигендек ләбаса. Хәзергесенә, заманалар узгач, чигенү чоры дип исем тагарсыз микән? Исем кушу белән котылырсыз аннары. Безнең илдә юньсезлек кылган түрәдән җавап сорарга гадәтләнелмәгән, лаеклы ялга җибәрәләр андыйларны, лаеклы түгеллеген һич кенә дә исәпләп тормыйлар.

— Сез, сез, дигәннәрең миңа кагылмый, Мөхибә әби,— дип бүлдерде Айгузин.— Мин дә синеңчә уйлыйм. Гомеремдә иркенлекне һәм муллыкны күрәм икән бер дип ышанган идем башта. Сиксән бишенче елда. Шуннан соң ышанычым кимеде дә кимеде, инде бөтенләй бетте. Яшермим фикеремне.

— Нигә яшерергә ди?! Бөтен ил шуны сөйли бит. Безне төрмәгә утыртып, берни дә кыра алмаслар. Шуңа күрә иркенләп сөйлибез бит менә. Без әйтмәсәк, кем әйтер боларны? Яшьләрме? Яшьләрнең шүрләүчеләре дә булыр. Без әйтик әле, безнең хакыбыз зуррак, илнең таудан тәгәрәвенә дә элек-электән без шаһит! Сине төрмәгә ябудан халыкның хәле яхшыра, дисәләр, үзем барып керәм төрмәләренә! Чын менә! Үз илеңдә тәртип урнаштырып байыйсы урында, дөнья буйлап хәер сорашып йөр инде, йә?! Шулмы ил башлыгының эше! Яратмыйм хәер сорашуны! Шуңа күрә кече кызымның, үз башын эшләтмичә, ялкауланып, хәерче хәленә төшүеннән куркам...— дип, үзенә турыдан кагылышлы мәсьәләгә килеп чыкты карчык.— Чит кешеләр санын күреп, күңеле азмагае, дим. Күңел азу — анысы инде ялкаулык билгесе.

...Ике карт кешенең сәясәт дигән нәстәкәйнең эченә кереп сөйләшүе гаҗәбрәк иде. Ләкин мондый әңгәмә булды. Чөнки хәзерге буталчык һәм азгынлык көчәйгән заманда берәү дә читтән күзәтеп кенә тормый, һәр вакыйгага мөнәсәбәтен белдерә, ахырында, телен әйләндереп әйтмәсә дә, күңеленнән һәркем нәтиҗә ясый. Туры сүзле Мөхибә белән Назыйм да фикер иясе кешеләр, ил язмышы турында олыдан кубып уйлану аларга һич тә ят түгел (хәер, Назыймы, акны карадан аерып, тәгаен сөйләргә гадәтләнмәгән). Аннары, Мөхибә әйткәндәй, аларның хаклары зур, алар илнең җитмеш еллап гомерен үзләре күреп беләләр.

— Ерактан әйләнеп йөрдек, Назыйм чордаш,— диде карчык, тынычланган иде ул.— Кызымның кызы — зур начальник, дигән идем. Начальник шул! Балалар бакчасында тәрбияче ул. Таптың түрә тәхете, дисеңме? Ю-ук, Назыйм энем, балаларны тыңлата алу иләмән хезмәтеннән авыррак. Беләсеңме, өйдә

әйбер тотуда гел дә үземә охшаган шул оныгым! Өйдә юньлерәк җиһаз да торгыза алмыйлар, барлык юньлене балалар бакчасына ташый. Өйдәге тәм-томны да, балаларның кайсына бирәсен әйтә-әйтә, иртәдән тутыра башлый. Рәхмәт яугыры! Әйбәт кияү туры килсен үзенә, бәхетле яшәсеннәр. Тик йөргән егете юк әлегә,— дип тирән сулады карчык.

— Тормыш дигәнең без теләгәнне генә кылып тормый шул.

— Балаларымның балалары гел кызлар минем. Берсе дә кияүгә чыкмады әле. Малайлы кеше кызыңны киленлеккә бир, дип сорап бара, малаеңны кияүлеккә алабыз, дияргә гадәтләнелмәгән. Оныкларымның башлы-күзле булганнарын күрсәм канә... Олыгаебрак киттем. Аякларым бик сызлау, болай чатыр чапкандай йөрүемнең газабын үзем генә беләм.— Карчык туны итәкләре өстеннән тез башларын ышкыды.— Озын гомер ителде. Күзләремнең нуры бетә. Монысы,— дип, сул күзе төбен сыпырды ул,— бөтенләй күрми. Уңын да томан каплый бара. Ходайның рәхмәтедер,— дип тагын көлемсерәде карчык,— оныкларым чамадан узып шаярышканны уңы күрми башласа, шул наныйларыма бармак янарга сул күзем күрә! Ышанмаслык хәл менә!

— Күңел күзең җете, Мөхибә әби! — дип сөендерде карчыкны Назыйм.— Әүлия син!

— Әүлия ук түгелдер дә, тик начар кеше дә түгелмен. Әүлиялыкка зур гыйлемлек тә кирәк, Назыйм энем. Революция дигәннәренә чаклы кечкенә булып укый алмадым. Совет чорында дүрт сыйныф кына укып калдым. Гарәп әлифбасында. Латин һәм урыс әлифбаларын соңыннан өйрәндем. Киленем яздырган гәзитләрне үзем укый идем, хәзер аның укыганын тыңларга гына калды. Әбием, әтиемнең әнисе, бик тә укымышлы иде. Булган гыйлемемне әбием бирде. Тормыш та өйрәтте. Гап-гади авыл карчыгы мин. Шуннан бик тә канәгать үзем. Аллага шөкер.

...Бала табу йортына килүчеләр ишәйде. Шәфкать туташы тавышланмаска кушты, кереп китәргә җыенгач, коридор ишеген кире япты да карчык белән карт янына килде.

— Бик озактан утырасыз, бирегез күчтәнәчләрегезне,— диде ул.— Гөлсәхра кемегез соң сезнең? Әтисе белән әнисе бүген иртән дә килгәннәр иде инде. Гөлсәхрага күп ризык кирәкми бит.

Назыйм пакетын шәфкать туташына ачмыйча сузды, ләкин кыз аны актарды, яшь анага ашарга ярый торганнарын гына алды. Мөхибә кинәт каушады, бер үк сүзләрне дә кабатлады.

— Мин... мин Гөлсәхра малаеның кендек әбисе булам. Кендек әбисе китергән ризык сабыема анасы сөте белән керсен. Баланың кендек әбисе мин. Әйберләремнең барысын да ал, анда ярамас ризык юк. Сабыйга нәрсә кирәген кендек әбисе әйбәтрәк белә. Кендек әбисе мин сабыйның. Тәһарәтем бар,

шөкер, тәһарәтсез йөрмим. Кичә һәм бүген калган намазларымны иртәгә җыеп укыйм, Аллаһы боерса... Карале, дим, кызым, кайчан чыгарырлар икән аларны?

— Берсекөнгә чыгарырлар да инде. Икесенең дә кәефләре әйбәт кенә.

— Шулай була күрсен. Ярабби. Гөлсәхра, наныем ла инде үзе, җиңелдән тапты бәбәен, Аллага шөкер. Карале, дим, кызым, бу картның күчтәнәчләрен аерып бир, яме, поездда синең өчен борчылган Назыйм исемле карттан, диген. Күчтәнәчләребезне алдан алуың әйбәт, кызым. Болай булгач, соңгы автобуска калмыйм икән, аннан алдагысына өлгерәм. Рәхмәт, кызым, игелек күр, сабыйга мәрхәмәтеңнең савабы үзеңә тисен. Шулай ул, кешенең бәхете — башкаларга игелек кылуда...

Айгузин Мөхибә карчыкны автовокзалга бүген дә озатты. Карчыкның шәһәр йортларын исендә калдыруы турындагы кичәге сүзләренең мәгънәсен бүген белде бит ул — зур әйберләрне генә шәйләп йөри икән ич Мөхибә әби.

Бүген Назыймга сугышта катнашучы таныклыгын күрсәтергә туры килмәде, автобуста буш урыннар бар иде. Шулай да ашыгырга мәҗбүр булдылар, юлаучылар автобуска утырышканнар иде. Назыйм Мөхибә карчыкны автобуска кертеп үк утыртты. Бер егет, алдагы урынын карчыкка биреп, артка күчте.

— Рәхмәтләр яусын сиңа, Назыйм энем. Авырмыйча яшә. Чир күрмә. Кулың тиз савыксын. Малаеңны көт. Тиз кайтыр ул, Мөхибә карчык әйткән иде диярсең,— дип саубуллашты Мөхибә.

— Үзеңә дә изге теләкләрем, Мөхибә әби,— дип, башын иде карт.

Аларның соңгы очрашуы булган икән бу...

Назыйм шәһәр үзәгеннән әйләнеп кайтасы итте. Үзәктәге «Табигать байлыклары» дигән кибеттә үзгә ризыклар саткалыйлар, онытылганда бер ат ите чыгаргалыйлар, бәлки, шул вакытка туры килер, чираты озын була инде озынын, торыр, ашыгасы җире юк. Дачадан кайткач пешергән бәрәңгесе, кем әйтмешли, коелып бетте, кичкә озаклап кайнатып аш пешерер, бу яшьтә ачлы-туклы йөрү сәламәтлегенә шәп тондырыр югыйсә. Әмма кибеттә ат ите юк иде. Сыер ите алды, җелекле сөяклесен үзе салдырды, ашка өресе мул чыга андый итнең. Троллейбус тукталышы янындагы хуҗалык әйберләре кибетенә керде, пычак сайламакчы иде. Ләкин сайларга түгел, сайламыйча алырга да юк икән пычак. Бу кибеттә күптән булмаган иде, шүрлекләрнең шәрәләнүенә хәйран калды. Нишләде бу тормыш, кая барабыз без, бармыйбыз, алтынчы ел инде элекке үребездән дә кирегә тәгәрибез, дип уйлады Айгузин. Каһәр суккыры Сайгушев, азгын җан, пычакны сындырды, кибеттә пычак юк чагында. Пенсиягә чыгар алдыннан үзе ясаган пычагының йөзе дугаланып килгән иде, бәрәңге әрчергә җайлы иде тагын. Үткен һәм

очлы, бәрәңге күзәнәкләрен чокып кына ала иде. Кибеттә пычак та калмасын инде, йә?

Шулай уйланганда, Мөхибә карчыкның троллейбуста сөйләгән мәзәк хәле исенә төште.

Мөхибә троллейбуста Назыймга:

— Сиңа да тиштерим әле талон,— диде.— Күбәйде болар.

— Мин бушлай йөрим бит. Кирәкми.

— Кирәктер, димим лә. Кая куйыйм ди бу талоннарны?

— Нигә шулай күп алдың соң? Гел шәһәрдә йөрергә, ахры, исәбең.

— Юк ла,— дип йодрык хәтле генә калган төенчеген селтәде карчык.— Үз өемдә эшем бетмәгән. Бүген Гөлсәхра да бәбәй хакы өчен генә килдем. Ниятемне киленем бик тә хуплады, аның да сүзен аяк астына салып таптарга ярамый, алай итсәм, юньсез булырмын, Ходаем, кичер...

Карчык, бала табу йортына барганда, бер егеткә акча сузган. Бер генә талон сораган, акчасы өчлек икән. Шаян телле егет булгандыр, әбигә мондый киңәш биргән.

— Әби, кибеттән әйберләр алырга килгәнсеңдер инде син авылдан,— дигән егет.— Кибетләрдә барыбер бернәрсә дә юк, әби, ичмасам, троллейбус талонын учыңны тутырып алып кал, анысы да бетәр.

— Беләм инде егетнең шаяртканын,— дип аңлатты карчык талоннары күплеген.— Шаяртуына сөенеп куйдым бит шул егетнең! Алайса, өч сумлык бирсен, дидем, бер дә аптырап калмадым! — Карчык, гадәтенчә, еракка китеп нәтиҗә чыгарган.— Боздык ла тормышны. Сикәлтәле-чалулы булса да, юлдан бара идек, көн итү тарафында, дим. Тар тыкрыкның чокырчакырлы сукмагына капылт кына кердек тә киттек...

Тар тыкрык, тар тыкрык, дип күңеленнән кабатлады Назыйм. Иртән дачасына барганда, Сайгушев очраудан куркып, тар тыкрыктан турыга бәрмәгән иде ул. Сайгушев кичә, сумкадагы кайнатмаларны күреп, Айгузинның дачадан кайтуын сизенгәндер дә. Обсерватория поселогы кешеләреннән Назыймның дачасы кайсысы икәнен белешкәндер, тар тыкрыкта бүген көтәдер кебек иде аңа. Сайгушев, пычрак җан, тар тыкрыкта адашып калгыры, шунда сине дөмектерергә дә күп сорамас. Уйлап та тормас. Аннары Сайгушевның Назыйм дачасы кайдалыгын иртүк белә алмавы сәбәбен китереп чыгарды — бандит кичә Айгузинны өе янында саклаган, Айгузинның милициягә хәбәр салуыннан шүрләгән, бүген монда килеп җитәргә өлгермәс. Шулай да, куркырга сәбәбе булмаса да, иртән тар тыкрыкка, әйе, кермәгән иде Назыйм. Бүген көндез табуы ихтимал картның дачасын Сайгушев, менә монысы — мөмкин хәл. Казаннан табан ялтыратмаса...

Өенә туры кайтмады Назыйм. Чистай урамы тукталышында троллейбустан төшеп, Савинга борылды. Мондагы асфальт җәелгән бердәнбер урамнан шактый ара узгач, аңа арттан эн-

дәштеләр. Тавышы таныш иде, әмма Сайгушев тавышы түгел, юлбасарның пышылдавын да аера Айгузин, онытмас ла кеше талаучының тавышын. Адымын акрынайтса да, артына карарга шикләнде карт. Эндәшүче үзе куып җитте — кичә килгән милиционер икән ләбаса! Милиционер, каршыга килүчеләр узып киткәндә, Савинда гомер булмаган урам исемен сорады, төрле юнәлешкә төртеп күрсәтте, шул якта түгелме, янәсе.

— Төштән бирле эзлим үзегезне,— дип, уенсыз сөйләүгә күчте ул аннары.— Болар арасында Сайгушев юкмы? — дип, берничә фотоны кәрт колодасыдай җәеп җибәрде.

Айгузин күзләренә ышанмыйча торды. Арада Сәвади Сайгушев фотосы да бар иде.

Карт, калтыранып:

— Монысы,— диде.

Милиционер фотоларны тиз генә кесәсенә тыкты.

— Зур кошны очырганбыз, Назыйм абый! Сәвади дә, Сайгушев та түгел ул. Татарда булмаганчарак аның исем-фамилиясе. Сабир Сабируллин диелер бу юлбасар! Башкача йөрүе дә бик мөмкин. Ярый, рәхмәт, иптәш Айгузин,— дип, аркылы урамга җиткәч туктады милиция кешесе.— Күрешкәнгә чаклы. Кирәгегез чыкса, мин үзем табармын сезне. Әмма Сабируллин-Сайгушевны очратсагыз, безгә хәбәр итмичә калмагыз. Шулай да бик чыгып йөрмәвегез хәерле. Дачагызга да бармагыз. Бу бандит кулларын кеше каны белән юудан чирканмый,— дип кисәтте ул һәм аркылы урамнан ашыгып китеп барды.

Тикшерүченең соңгы сүзләре Назыймның күңеленә минем малайны шушы Сайгушев юк иткән мәллә дигән шик салды. Их-х, малай... Малаебыз... Акыллы бала иде соң... Иртән институтына китте, кичен кайтмады...

Назыймның туган йортын сүтүләренә инде чирек гасырлап узды. Ләкин төп нигезе урынын онытмый, монда еш килә ул. Төп нигез гел үзенә чакыра кебек аны. Ни сагынсаң да, монда кайтып нигез яңартып булмый, монда күптән биш катлы йорт күтәрделәр. Шул йорт Айгузиннар нигезен бөтенләй диярлек каплады. Назыймнар йорты урыныннан кырлары метр чамалы гына өчпочмактай җир буш калды. Шунда чүп-чар ташлыйлар, кадерле җирнең кадерен бетерәләр. Пычракка чумуын абайламый адәм баласы, чүплек ерак түгел ич, шунда илтүне ярамыйга сан礼йлар мәллә, үзләре торган йортның почмагына калдык-постыкларын түкмәсәләр соң... Назыйм чүпләрне җыеп пакетка тутырды.

— Бабай, бабай! Чүпче бабай! Әнә тегендә чүп тагын да күп! — дип үртәләде Назыймны бер малай. Картның куып тота алмаячагын белә, шуңа күрә Айгузинны оятсызланып мыскыллады.

— Синең гаебең юк, бала,— диде аңа Назыйм.— Без гаепле, өлкәннәр гаепле. Акыл бирә белмибез сезгә! Тар сукмакка үзебез үк төшерәбез сезне.

Ләкин малай аның сүзләрен ишетмәде, дөресе, тыңлап та тормады.

— Чүпче бабай! Чүпче бабай! — дип, үз табышына сөенгәндәй үчекли-үчекли, йортның аргы башына таба йөгерде малай.

Гаҗәп, әй, аңа гомерендә ике кушамат тактылар, ике тапкырында да малайлар эше булды бу: Исерек абый да Чүпче бабай. Ярый ла бу кушаматларны ишетеп тормадылар.

...Айгузин күршеләре белән генә аралашты, үтә кирәкле йомышы купканда гына өеннән чыкты. Ерак туган-тумачалары — аның якын туганнары инде юк — һәм бергә эшләгән иптәшләре килеп йөрмәде, һәркем тормыш куа, Назыйм картның хәлен белмәгән өчен берәүне дә гаепләргә ярамый. Заманасы шундый, кешеләр якыннан аралашуның мәгънәсен онyта баралар. Милиция тикшерүчесе дә онытты Айгузинны, инде икенче ай хәбәр бирми. Сайгушев-Сабируллин эшен дә, кем әйтмешли, тартма төбенә салдылар бугай. Мөхибә карчык белән бер сөйләшеп утырса, ичмасам, күңеле бушаныр иде. Әмма аны кайда очратасың ди. Авылына барсаң инде. Килүеңнең сәбәбен ни дип аңлатырсың тагын. Мәгънәсез сәфәр булыр бу, бикләнеп утыра бир, Назыйм карт, өеңдә. Кешеләргә синең кирәгең беткәндер. Малаең да, ахрысы, бөтенләйгә югалды. Гөлсәхраны күрәсе килә килүен, яшәгән җирен бала табу йортында белешер иде. Ләкин ни дип барып керерсең аларга? Мин, сеңлем, сине бандит кулыннан коткардым, диярсеңме? Тузга язмаганны! Мактанып әрсезләнү генә җитмәгән иде җитмеш яшеңдә! Ялгызлыкны күпмегәдер онытып торырга бер генә чара каладыр — Мөхибә карчыкны күрергә кирәк. Юк, анысы да тормышка ашырырлык теләк түгел — кеме ди ул Мөхибә карчыкның? Аннары аның, сугыш вакытындагы вәкиллегеннән соң, бер генә авылга да бер генә тапкыр да барганы булмады. Теге чакта авыл апайларының бер көндә, чынын-шаяруын бергә кушып, ике сабак укытулары гомеренә онытылмады. Авылда барысы да Мөхибә әби кебек түгел. Назыймны ындыр табагында һәм фермада мыскыл иткән хатыннарга ишләре хәзер дә бардыр. Шәп сабаклар алды Айгузин, аларның кабатлануына бөртек тә ихтыяҗ юк...

Шунысы да бар бит әле: Мөхибә карчыкның да теле үтә чарланган. Айгузин аның бер сүзен һаман онытмый.

Назыйм карт беренче очрашуда:

— Мин кешеләргә начарлык та, яхшылык та кылмадым,— дигәч, Мөхибә усал итеп:

— Яхшылык кылмагач, гомерең заяга узган икән,— дигән иде. Һәм мондый киңәшен дә биргән иде: — Назыйм энем, син кешеләргә изгелек кыл. Инде алар синең яхшылыгыңны аңламаслар дип шикләнсәң дә, барыбер изгелек эшлә үзләренә. Инде аңламасалар, кешеләргә кылган яхшылыгыңны суга сал. Адәм затына эшләгән изгелегеңне балыклар аңлар.

...Апрель азагы якынлаша. Бакчада җиң сызганып эшләргә вакыт җитте. Ә бакча корты Назыйм Айгузин — үзенә үзе биргән бәясе шундый аның — февраль уртасыннан бирле бакчасына аяк та басмады, һәм... Әй-й, нигә Сайгушев-Сабируллиннан кот очарга тиеш соң әле, аның алдында гаепле кеше сыман, барам бакчага, күңел шунда тынычланыр, дигән катгый фикергә килде Айгузин.

— Утыртыр-чәчәр вакытта, сырт сөякләрен иркәләп, өйдә ятмассың ич,— дип үзалдына әйтеп куйды Назыйм.— Сөякләрне бакчада язу килешә миңа. Мөхибә әби әйткәндәй, Аллаһы боерса, быел да бакча килешер үземә.

Ярый барган икән дачасына. Бакчада рәхәтләнеп эшләде, ару-талуны белмәде, әй-й, бакчада талуы да рәхәт кенә ич! Куллары эш сагынган икән, сөяге чатнавы сизелмәде, төзәлгәндер, ике айдан артык вакыт узды бит Сайгушев-Сабируллинның тимердәй кулы белән сугуына. Шатлык өстенә шатлык: кичке уңайда кайтканда, Гөлсәхраны очратты ул! Вагонга керүгә, аның күзләренә таныш йөз чалынды кебек. Аралыкта басып торып, вагондагы кешеләрне күзәтте. Әнә ич таныш йөз, Гөлсәхра ич! Бәбәен күкрәгенә кыскан.

Карт, кешеләрне аралый-аралый, Гөлсәхра янына барды. Яшь ана беравык аңа аптырап карап торды да танып алды.

— Бабай, Назыйм бабай ич сез!

Назыймның күзләренә яшь килде — гомер булмаганны! Гөлсәхраның аркасыннан сөйде. Яшь ананың да күзләре дымлы иде. Ул картка үз урынын күрсәтте, әмма Гөлсәхра күршесендәгеләр кысылышты да Назыйм да сыйды.

— Улым, улым, Назыйм бабай шушы инде,— дип сөенде Гөлсәхра.— Бабай белән таныш әле, улым. Күреш, күреш, әйбәт бабай ул.

Бәбәйне үзенә чакырды карт, ләкин түгәрәк йөзле, зәңгәрсу күзле сабый Назыймның ите кипшерә башлаган кулларына карап кына торды — бу таныш түгел кулларның нигә үзен чакырулары сәбәбен белергә теләгәндәй уйлана кебек иде бәбәй. Назыймга шулай тоелды.

— Улым, кулыңны бирмисеңмени бабайга? Алай ярамый ич,— дип, Гөлсәхра малаеның кулын картның учына куйдыртты. Сабый кулының йомшаклыгы Назыймга бу фани дөньяда гөнаһсызлыкның гел яңарып торуын тәнендә тойдырды. Гөлсәхралар очрамаса, шуны белмичә үләсе икән. Назыйм Айгузинның, җитмешенә җитеп, сабый кулына кагылганы юк иде бит. Малае, уллыкка алганда, алты яшьлек иде, малаеның кул кимерчәкләре катыланган иде инде. Малаеның куллары да йомшак иде лә аның!

— Рәхмәт яусын! — дип, сабыйның маңгаен сөйде ул.

— Менә шундый инде без, Назыйм бабай,— диде Гөлсәхра, ана күңеленең киңлегенә хас булганча, баласы белән үзен бер

җан ияләре итеп сөйләде.— Үсәбез инде без. Кунакка йөри башладык. Кендек әби янына да барачакбыз әле без, име, улым. Җәй генә җитсен, име. Хәзер Казанга барабызмы, улым? Казанга барабыз, име, улым. Безнең йокы вакытыбыз да җиткән, име, улым. Менә шушы имезлекне суырабыз да йоклап та китәбез әле без. Йоклап та үсәбез без, үсүдән башканы белмибез әле без, име, улым...

Гөлсәхралар Назыймны эзләгәннәр, ләкин ничек табасың ди, аның турында, исеменнән башка, берни дә белмиләр бит. Исемен Мөхибә карчык әйткән. Ул Гөлсәхралар бала табу йортыннан чыккан көнне каршыларга килгән икән. Хәзер, Юдиндагы кызы янына килгән дә, Яшел Үзән шәһәренә бара икән, бәбәйне бик тә ярата, ди.

Игелек кылуда гомере буена тынгылык белмәгән һәм белмәс Мөхибә карчыкның хәлен белешмәү гөнаһ лабаса, димәк, Назыйм карт авылга һичшиксез барачак.

Сабый йоклый иде. Назыйм аңа еш кына озаклап карап тора, мондый чакта Гөлсәхра, гәүдәсен кымшатып, малайның йөзен карт күрерлек итеп бора. Гөлсәхра Назыймга бәбәй табу йортына китергән күчтәнәчләре өчен рәхмәт әйтте.

— Теге чакта вагонга сез кергәч,— диде Гөлсәхра, йөзенә кинәт хәсрәт җәелде,— сумкагызга башлап күзем төште. Дачадан кайта икән бабай, дип уйлап алдым да кинәт кенә карлыган кайнатмасы ашыйсым килде.— Һәм, Назыймны сумкасына үрелүдән туктатып: — Юк, юк, Назыйм бабай, хәзер кирәкми,— дип дәвам итте Гөлсәхра.— Мин Казанда чагында ук китереп сыйладыгыз бит. Безнең үз бакчабыз да җимешле. Шундый чакта кайнатма ашыйсы килүе сәер инде. Ашау турында уйларлык идеме соң ул чакта...

Ана, кулын тидерер-тидермәс кенә итеп, бәбәен битеннән сөйде. Аның йомшак күкрәгендә сабые изрәп йоклый иде. Әтисенең нык һәм ышанычлы күкрәгенә беркайчан да сыена алмаячак бу гөнаһсыз бала...

Гөлсәхра Назыймны үзләренә чакырды, карт, сумкасыннан кәгазь-каләм алып, адресны язды, барырга ышандырды, Мөхибә карчыкны Гөлсәхраларда очратырга өметләнде. Мөхибә белән ешрак очрашса, аңардан тормышны яратырга өйрәнер иде ул, моңа җитмеш яшьтә дә соң түгелдер. Югыйсә тормышта эз калдырмыйча китәр кебек иде. Яшел Үзән каласына Мөхибә әби якшәмбе саен килә икән.

Ләкин Назыйм Айгузин Гөлсәхраларга бара алмады. Ә Казан вокзалында аны бүген үк бүтән төрле очрашу көтә иде.

Поезд, Юдин ягындагы платформаны узып, Арча юнәлешендәге платформага барып туктады, тегесендә буш юл булмавын радиодан хәбәр иттеләр, моны вокзалдагыларга алдан белдергәннәр икән, Гөлсәхраны туганнары көнчыгыш платформада көтәләр иде. Назыйм Гөлсәхралардан шунда аерылды, аларга

һичшиксез барачагын кабат әйтте, аларны үзе дә кунакка чакырды.

Вокзалның төп бинасы алдыннан тугызынчы трамвайга таба бара иде ул. Бина башы турына җиткәндә, товар йөртүче поездның алгы вагоныннан төшеп, җиргә чүгәләүчеләрне күрде Айгузин. Нигә алай итәләр икән, дип уйлады. Чүгәләгән кешеләр түгәрәген әйләндереп алган кораллы солдатларга игътибар иткәч кенә аңлады — кулга алынган кешеләр икән болар. Бүтән шәһәрдән китергәннәрдер, вагонга утыртмыйлар, төшерәләр иде бит.

— Сайгушев ич тегесе! Сабируллин! — дигән сүзләр авызыннан атылып чыгуын сизмичә дә калды Айгузин.

Сабируллин-Сайгушев та Назыймны күреп алды. Картка сикереп ташланырга теләп, күтәрелә башлады ул, ләкин аның аркасына шул мәлдә үк автомат көпшәсе терәлде.

— Картлач, телеңне тыярга кушкан идем түгелме мин сиңа?! — дип үкерде бандит.— Барыбер башыңа җитәрмен!

Аның аркасына катырак итеп төрттеләр. Сабируллин-Сайгушев ава язды. Таяна алмый, куллары богауда иде, башкаларына богау салмаганнар, аларның кулларын артка куйдырганнар иде, димәк, Сабируллин-Сайгушев бу җинаятьчеләр арасында иң куркынычы икән. Бандитның богауда һәм чолганышта булуы Айгузинга яшьлек көче кайтарды кебек, ике айдан артык шушы бәндәдән куркуы юып алгандай югалды. Карт, юлбасарны нык каптыруларына инде тәмам ышанып, тегеңә җирәнеп, нәфрәтләнеп карап узды. Ычкына алмассың капкыннан, Сайгушев-Сабируллин, богаулагач та әшәкелегеңне чәчеп маташма, дип, бандитның йөзенә бәрәсе, җырлап яшә, дип мыскыллыйсы килде Айгузинның, ләкин боларны әйтергә мөмкин түгел иде. Хәер, юлбасар үзенең хәлен болай да аңлыйдыр, үч алмакчы булуы котырынуы-ярсуы гынадыр...

Өендә очынып йөрде Назыйм. Авыз эченнән көйләде. Тик җыр сүзләре белми икән. Кайсыдыр җырның баштагы сүзләре, бүтәненең ахыргы сүзләре генә исенә төшә. Матур җырламасын да инде, аны сәхнәгә чыгып җырларга мәҗбүр итмиләр ич. Гомер итеп, ялгызың гына калганда, хәсрәтеңне басарга йә шатлыгыңны зурайтырга җыр белмә инде?! Җырсыз үтте гомер. Өйрәнергә кирәк. Соң түгелдер...

Ә хатыны җырлый иде Назыймның. Әмма аның җырлавын да яратмады ул. Хатынын:

— Сарык кебек мөгрәмә! — дип тыяр иде.

Хатыны:

— Сарык мөгрәми. Үзегез Савинда торып мал асрагансыз, үзең шуны да белмисең. Сыер гына мөгри,— дип каршы төшсә:

— Синең җырың — сарык мөгрәгәндәй! — дип тындырыр иде аны.

Берчакны, туганнарына баргач, хатыны телефоннан кемгә-

дер яңа көй өйрәтеп маташа. Тартып торып алды Назыйм телефон төребкәсен, хатыны акаеп калды. Әллә суккан да тагын төребкә белән, хатыны кич буе колагын тотып утырды. Ачуланмаган иде хатыны. Өйләренә кайткач:

— Даруыңны эчә күр, онытма,— дигән иде.

Назыймны яратуын сиздерүе инде. Шул тугры хатынны җырдан тый инде, әкәмәт. Назыймның күңеле тарлыктан инде бу. Хатыны белән бергә җырларга өйрәнсә, ни булган? Син җырлый белмисең, дип һич тә кыерсытмас иде хәләле. Их-х, акыл, диген... Җырсыз гомер кичер инде... Өйрәнергә кирәк, әле гомере бардыр, сырхау кеше түгел. Ялгызлыкта җыр бигрәк тә кирәк...

Ишек кыңгыравы шылтырады. Назыйм, элеккерәк гадәте буенча, кем булуын сорамыйча, йозакны ачты, хәзер Сайгушев-Сабируллиннан куркырга кирәкми иде бит инде. Ләкин, ишекне бәреп, бандит атылып керде. Бер мәлгә икесе дә, күзләренә карашып, сүзсез тордылар. Ниһаять, карт кухняга чигенә башлады. Юлбасар, бармакларын кәкрәйтеп җәеп, корбанына ташланырга җыенган ерткыч кебек, Айгузинга таба атлады. Ашыкмый Сайгушев-Сабируллин, Айгузинның котылыр чарасы юклыгын белә.

Назыйм өстәлдәге пычакны алды. Бандит пычакны теге чактагыча сугып төшерергә өлгермәячәк иде, ара ераграк, сикереп ташланса, пычак аңа барыбер кадалачак. Ләкин карт пычакны җәһәт кенә үз йөрәге турына китерде, күкрәгенә киерде. Сабируллин-Сайгушевның күзләре тагын да акайды, гәүдәсе артка чайкалды.

— Картлач... Нишләвең? Ташла пычагыңны!

— Ташламыйм! Син мине үтерергә килгәнсең! Каным синең пычрак кулыңа йокмасын! Кузгалма! Урыныңнан аз гына миңа таба селкенсәң дә, кадыйм пычакны йөрәккә!

— Картлач... Назыйм абзый, ташла, дим, тимим мин сиңа. Кунып кына чыгармын. Яшеренергә синең фатирдан да ышанычлы урын юк. Алар мине монда килер дип уйларына да китермәячәкләр. Аннары минем үз юлым.

— Чыгып кит! Югыйсә...

— Җүләрләнмә, абзый! Сине вокзалда юри куркыттым. Акчаңны бише белән кайтарырмын... Миңа тактырасың бит үлемеңне... Онытмачы, син сугышта да кулыңа агач мылтык тоткансыңдыр...

Ишеккә китереп типтеләр. Назыйм моны ишетерлек хәлдә түгел иде, ә бандит ишек ягына борылды да, пистолет тоткан ике милиционерны күреп, кухняга ташланды. Картның акрын ауган гәүдәсе бандитның икенче кат тәрәзәсеннән сикерү юлын бүлде. Назыйм Айгузинның күкрәгенә күптән түгел үзе ясаган очлы пычагы — монысы да сыгылмас пычак — сабына хәтле кергән иде...

Сабируллин-Сайгушев калтырана, аның тез буыннары гомерендә беренче тапкыр тотмый иде. Ул идәнгә сыгылып төште.

— Мин түгел... Миңа сылтамагыз! Ул үзе... Мин үтермәдем аны! Үзе! Ү-з-е!

Җинаятьләре өчен дүрт тапкыр тотылган, өч тапкыр төрмәдә утырган Сабир Сабируллин-Сәвади Сайгушевның болай ачынып беркайчан да ялварганы юк иде. Дүртенче тотылуында кулына богау салгач та качу әмәлен тапкан бәндәнең бишенче тотылуында кылганнары өчен явызланып һәм ерткычланып горурланырга көче җитмәде бугай.

Юлбасар, сул аягына тезләнеп, башын иеп, милиционерларның хәрәкәтләрен кырын карап күзәтә иде.

— Ал кулыңны кесәңнән! — дип кычкырды аңа милиционерларның берсе һәм, богау тотып, җинаятьчегә таба атлады. Сабируллин-Сайгушевка монысының гәүдәсе белән пистолет тоткан иптәшен каплавы гына кирәк булган икән — ул, юлбарыс җәһәтлеге белән атылып торып, богау тоткан милиционерның касыгына тондырды, икенче милиционер атарга өлгергәнче, елтыр пычак белән (килешли каяндыр тапкан бит, әй!) аның күкрәгенә кадады. Богау тоткан милиционер аңына килгәнче, аның аркасына йөрәк турыннан пычак кереп батты.

— Шулай, агай-энеләр,— дип акрын гына әйтте Сабируллин-Сайгушев.— Хуш...— Бу сүзне күплектә уйлаган иде бугай, әмма кинәт яртылаш кисте,— җебегән картлач...

Пычагының канын богау салырга теләгән милиционерның кителенә сөртте. Әле генә ике кешенең гомерен кискән пычакның кыны кесәсендә булган икән — хәнҗәр сыман пычак шунда шуып керде. Аннары Сабируллин-Сайгушевның түш кесәсенә оялады.

Сабир-Сәвади мәетләргә күз ташлады, үлүләренә ышанды, һәм, киемнәрен төзәткәләп, ашыкмыйча чыгып китте. Гаҗәп, чыгу юлында аның каршына берәү дә очрамады. Югыйсә милиционерларның ишек ватып керүен күршеләр ишеткәннәрдер, бәлки, хәзер алар ишекләренә колакларын куеп тыңлап та торалардыр, ләкин Сабируллин-Сайгушевның юлын берәү дә кисмәде. Хәер, бу заманда кемдә кем кайгысы соң?!

Яңгыр сибәли. Кышын Обсерватория тукталышында табигать манзараларына — бигрәк тә аның сарсарына сокланучы Назыйм Айгузин язгы яңгырның шавын ишетә дә, аның тәрәзәне иркәләп сөюен күрә дә алмый инде. Тормышны яратырга бик соңлап өйрәнә башлаган иде мәллә соң ул? Тормышында начарлык эшләмәвең әйбәт. Ләкин кешеләргә яхшылык кыла белмәвең үзе үк начарлык түгелме икән?..

Хәер, Назыйм Айгузинның бу хакта, тирәнгә төшеп, беркайчан да уйланганы булмады.

*1990*

# Эчтәлек


Иртәнге яңгыр . . . . . . . . . . 6
Ак колын . . . . . . . . . . 10
Зөбәрҗәт әби бирнәсе . . . . . . . . . . 17
Соң . . . . . . . . . . 20
Ул урамнан дүрт уза... . . . . . . . . . . 27
Мәхәббәт бит ул... . . . . . . . . . . 35
Йолдызлардан ары — йолдызлар . . . . . . . . . . 40
Ак таң . . . . . . . . . . 46
Исәнме, Раушания!.. . . . . . . . . . . 54
Тау каршында — тулы ай . . . . . . . . . . 61
Яр өстендә — яшел җәннәт . . . . . . . . . . 65
Кеше күңеле — үзе бер кояш . . . . . . . . . . 72
Иңә дә иңә карлар . . . . . . . . . . 81
Кулаклар колхозы . . . . . . . . . . 89
Кубыз . . . . . . . . . . 109
Айның уты сүнгән... . . . . . . . . . . 116
Кич утырганда . . . . . . . . . . 126
Мәгарә . . . . . . . . . . 132
Укалы карлар . . . . . . . . . . 139
Һомай кошлары . . . . . . . . . . 145
Түбәтәйле кыз . . . . . . . . . . 151
Төннең бикле тәрәзәсе . . . . . . . . . . 156
Кавырсын һәм айбалта . . . . . . . . . . 165
Киртә буенда . . . . . . . . . . 173
Каңгый илендә . . . . . . . . . . 181
Мәңгелек эзләр . . . . . . . . . . 188
Фидая хикәясе . . . . . . . . . . 214
Кышкы чәчәкләр . . . . . . . . . . 223
Әманәт . . . . . . . . . . 228
Тәкать . . . . . . . . . . 235
Йолу . . . . . . . . . . 241
Оҗмах агачы . . . . . . . . . . 248
Чөй . . . . . . . . . . 252
Тар тыкрык сукмагы . . . . . . . . . . 342

Литературно-художественное издание

*Магсум Хузин*
*(Хузин Магсум Хамитович)*

**Угасшая луна**

Рассказы

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы *С.Б.Зайцева*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Л.Ш.Шәфыйкова, Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 9.06.2004. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «Antiqua» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 20,16 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 21,42. Нәшер-хисап табагы 23,49 + форз. 0,36. Тиражы 3000. Заказ Э-395.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.